Россия Фәннәр академиясе
Россия Мәгариф академиясе
«Просвещение» нәшрияты

А

Мәктәпләр өчен академик дәреслек

Җәмгыять белеме

10



ПРОСВЕЩЕНИЕ
ИЗДАТЕЛЬСТВО

10
ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ

Россия Фәннәр академиясе
Россия Мәгариф академиясе
«Просвещение» нәшрияты

А Мәктәпләр өчен академик дәреслек

ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ

10 сыйныф

Гомуми белем бирү
учреждениеләре өчен дәреслек

ПРОФИЛЬЛЕ ДӘРӘҖӘ

*Л.Н.Боголюбов, А.Ю.Лазебникова,
Н.М.Смирнова редакциясендә*

*Россия Федерациясе
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тәкъдим итә*

*Тәрҗемә Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан расланган*

3 нче басма

Москва
«Просвещение»
2009

Казан
«Хәтер»
2009

УДК 373.167.1:3
ББК 60я72
О28

«Мәктәпләр өчен академик дәреслек» сериясе 2005 елда оештырылган
«Россия Фәннәр академиясе, Россия Мәгариф академиясе, «Просвещение» нәшрияты — Россия мәктәпләренә» проекты
Проект җитәкчеләре: Россия Фәннәр академиясе вице-президенты, акад. **В.В.Козлов**, Россия Мәгариф академиясе президенты, акад. **Н.Д.Никандров**, «Просвещение» нәшрияты генераль директоры, Россия Мәгариф академиясе мөхбир-әгъзасы **А.М.Кондаков**
Сериянең фәнни редакторлары: Россия Мәгариф академиясе академик-секретаре, пед. фән. д-ры **А.В.Кузнецов**, Россия Мәгариф академиясе академигы, пед. фән. д-ры **М.В.Рыжков**, икътисад фән. д-ры **С.В.Сидоренко**

Дәреслек Россия Фәннәр академиясе галимнәре катнашында РМА Укыту-белем бирүнең эчтәлеге һәм методлары институтының җәмгыять белеме лабораториясендә әзерләнде

Авторлары:
Л.Н.Боголюбов, РМА академигы — § 1, § 14, § 15, § 17, § 19, § 20; йомгаклаулар, сораулар һәм биремнәр, I, III бүлекләргә «Имтиханга әзерләнәбез».
А.Ю.Лазебникова, пед. фәннәре д-ры (РМА) — § 1–4, § 9–10, § 13, § 16, § 21–22, § 24; II, IV бүлекләргә йомгаклаулар, сораулар һәм биремнәр, «Имтиханга әзерләнәбез».
Н.М.Смирнова, философия фән. д-ры (РФА) — § 11–12, § 25.
Ю.И.Аверьянов, философия фән. канд. (РМА) — § 8.
Э.В.Захаров, философия фән. канд. (РФА) — § 18.
Л.Ф.Иванова, пед. фән. канд., РФның атказ. укытучысы (РМА) — § 7, § 23, § 26, § 27–33, § 39; V кисәккә йомгаклаулар, сораулар һәм биремнәр, «Имтиханга әзерләнәбез».
А.Т.Кинкулькин, РМА мөхбир-әгъзасы — § 14.
А.С.Королькова, пед. фән. канд. (РМА) — § 5–6.
Т.Е.Лискова, пед. фән. канд. (РМА) — § 37.
Е.Л.Рутковская, пед. фән. канд. (РМА) — § 34–36, § 38.

Дәреслеккә Россия Фәннәр академиясе һәм Россия Мәгариф академиясенең уңай бәяләмәләре алынды.

О28 **Җәмгыять белеме**. 10 сыйныф: гомуми белем бирү учреждениеләре өчен дәреслек: профильле дәрәҗә / [Л.Н.Боголюбов, А.Ю.Лазебникова, Н.М.Смирнова һ.б.]; Л.Н.Боголюбов һ.б. редакциясендә.— 2 нче басма.— М.: Просвещение, 2009.— 416 б. — ISBN 978-5-09-019940-7.
Русчадан М.Х.Харисов тәрҗ.— Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты, 2009.— 416 б.—ISBN 978-5-94113-303-1

Дәреслек беренче тапкыр социаль-гуманитар яисә социаль-икътисади профильле сыйныфларда укучыларга җәмгыять белеменең социология, политология, социаль психология, фәлсәфә мәсьәләләре буенча белемнәрне колачлаган тирәнтен курсын тәкъдим итә. (Курс хокук белеме һәм икътисадның аерым курслары белән бергә өйрәнелә.) Дәреслек укытуның актив формаларына юнәлеш тоткан методик аппарат, таблицалар, схемалар белән тәэмин ителгән.

УДК 373.167.1:3
ББК 60я72

ISBN 978-5-09-019940-7
ISBN 978-5-94113-303-1

© «Просвещение» нәшрияты, 2007
© Сәнгатьчә бизәлеш. «Хәтер» нәшрияты, 2009

Эчтәлек

Авторлардан 5

I бүлек. Социаль-гуманитар белемнәр һәм һөнәри эшчәнлек

§ 1. Фән һәм философия 7
§ 2. Кеше һәм җәмгыять элеккеге мифларда һәм беренче фәлсәфи тәгълиматларда 17
§ 3. Яңа һәм Өр-яңа заманнарда философия һәм җәмгыять белеме 27
§ 4. Рус фәлсәфи фикере тарихыннан 38
§ 5–6. Социаль-гуманитар өлкәдәге эшчәнлек һәм һөнәри сайлап алу 48

I бүлеккә йомгаклаулар 67
I бүлеккә сораулар һәм биремнәр 69
Имтиханга әзерләнәбез 70

II бүлек. Җәмгыять һәм кеше

§ 7. Кешенең барлыкка килүе һәм җәмгыять оешу 70
§ 8. Философия проблемасы буларак кешенең асылы 81
§ 9. Җәмгыять һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләр 90
§ 10. Үсә баручы система буларак җәмгыять 100
§ 11–12. Җәмгыятьләр типологиясе 109
§ 13. Кешелек дөньясының тарихи үсеше: социаль макротеорияләр эзләү 127
§ 14. Тарихи процесс 136
§ 15. Иҗтимагый прогресс проблемасы 147
§ 16. Кеше эшчәнлегендә ирек 157

II бүлеккә йомгаклаулар 166
II бүлеккә сораулар һәм биремнәр 166
Имтиханга әзерләнәбез 167

III бүлек. Эшчәнлек — кешеләрнең яшәү ысулы

§ 17. Кешеләрнең эшчәнлеге һәм аның күптөрлелеге 168
§ 18. Рухи эшчәнлекнең эчтәлеге һәм формалары 180
§ 19. Хезмәт эшчәнлеге 192
§ 20. Сәяси эшчәнлек 203

III бүлеккә йомгаклаулар 213
III бүлеккә сораулар һәм биремнәр 214
Имтиханга әзерләнәбез 215

IV бүлек. Аң һәм танып-белү

§ 21. Дөньяның танып-беленүе проблемасы 216
§ 22. Хакыйкать һәм аның критерийлары 227
§ 23. Дөньяны танып-белү юлларының күптөрлелеге 237
§ 24. Фәнни танып-белү 248
§ 25. Социаль танып-белү 258

§ 26. Белем һәм аң 269
§ 27. Үз-үзеңне танып-белү һәм шәхеснең үсеше 278
IV бүлеккә йомгаклаулар 287
IV бүлеккә сораулар һәм биремнәр 289
Имтиханга әзерләнәбез 289
V бүлек. Шәхес. Шәхесләр арасындагы мөнәсәбәтләр
§ 28. Индивид, индивидуальлек, шәхес 290
§ 29. Кешенең яше һәм шәхеснең ныгып урнашуы 301
§ 30. Шәхеснең юнәлгәнлеге 310
§ 31. Аралашу — мәгълүмат алмашу 320
§ 32. Үзара аралашу — үзара хезмәттәшлек 330
§ 33. Аңлашу буларак аралашу 340
§ 34. Кече төркемнәр 349
§ 35. Төркемдәге тупланганлык һәм үз-үзеңне конформлы тоту 361
§ 36. Төркемдә бүленү һәм лидерлык 370
§ 37. Гаилә — кече төркем 380
§ 38. Антисоциаль һәм криминаль яшьләр төркемнәре 391
§ 39. Шәхесара мөнәсәбәтләрдә конфликтлар 401
V бүлеккә йомгаклаулар 411
V бүлеккә сораулар һәм биремнәр 414
Имтиханга әзерләнәбез 414

Авторлардан

Тарихны һәм җәмгыять белемен төп мәктәптә өйрәнеп сез инде җәмгыять турында күпне белдегез. Хәзер сезнең алда булган уку китабы аны тагын да тирәнрәк аңларга ярдәм итәр дип ышанабыз.

Дәреслектә җәмгыять тулы, динамикалы үсүче система буларак карала, җәмгыятьнең аерым өлкәләре, институтлары характерлана. Социаль җан иясе буларак, кеше аның адаптив (яраклашучан), коммуникатив үзгәртеп кору эшчәнлеге бердәмлегендә ачыла. Игътибар аеруча кешеләр эшчәнлегенең социаль-психологик якларына бирелә.

Дәреслектә төп мәктәп курсларыннан сезгә инде таныш булган кайбер сорауларны (җәмгыять тормышы өлкәләре, аның социаль структурасы, дәүләт төзелеше, кече төркемнәрдәге аралашу һ.б.) очратырсыз. Әмма алар тагын да тирәнрәк, системалырак, башкача бәйләнешләрдә һәм мөнәсәбәтләрдә ачыла. Әлеге темаларга иҗтимагый фәннәрнең генә түгел, ә бәлки аларның аппаратының, мантыйгының һәм дәлилләү системаларының нигезләмәләре һәм йомгаклаулары да яңа сыйфат бирә. Социаль-гуманитар белемнең дүрт өлкәсе — философия, социология, политология һәм социаль психология, авторлар фикеренчә, әлеге дәреслектә шактый тулы яктыртыла. Икътисад һәм хокук белеме профильле әзерлек кысаларында мөстәкыйль уку тармакларына әверелделәр.

Кызыксынучан укучыбызда материалның һәркемгә аңлаешлылыгы аның фәннилек корбанына әверелмәгәнме дигән сорау туарга мөмкин. Бәхәсләшмибез, кемгәдер аның аерым параграфларының артык катлаулы, фәнни терминологияләр белән тутырылган булып күренүе мөмкин. Ләкин без үзебезнең төп адресатыбызның — иҗтимагый фәннәр буенча тирән әзерлек алуны үзе теләп сайлаган өлкән сыйныфта укучыбызның мөмкинлекләренә һәм сәләтенә ышанабыз. Без мәктәп баскычында ук фәнни белем һәм танып-белү эшчәнлеге процедуралары белән танышу иҗтимагый тормыш чынбарлыкларын тагын да тирәнрәк фикерләргә генә түгел, ә бәлки югары мәктәп стандартларына һәм таләпләренә яраклашуны да җиңеләйтер дип уйлыйбыз.

Дәреслекнең һәр параграфы, аерым теманы чагыштырмача камил үзләштерүне күздә тоткан уку материалын бәян итүдән

тыш тагын кайбер нәрсәләрне дә үз эченә ала. Һәм аларның барысы да, уку текстының үзе кебек үк, бик тә мөһим. Параграфны «Исегезгә төшерегез» дигән рубрика алдан искә төшереп куя. Аңа мөрәҗәгать итү яңа материалны элек өйрәнгәннәр белән бәйләргә һәм шуның белән белемнәргә системалы характер бирергә ярдәм итәчәк. Параграф ахырында сез, үзегезне тикшерү өчен бирелгән сораулар белән бергә, проблемалы танып-белүгә һәм белемнәрне практикада куллануга юнәлтелгән биремнәр дә табарсыз. Аларны башкарып, сез мәгълүматны анализлау, объектларны чагыштыру, төп нәрсәне ачыклау, билгеле бер караштан торып бәя бирү, теорияне конкретлаштыру һ.б. кебек бик тә мөһим интеллектуаль осталыкларыгызны камилләштерерсез.

Чыганаклар белән эшләү зур әһәмияткә ия, алардан өзекләр шулай ук параграфлар ахырында урнаштырылды. Чыганакларны анализлап, алардагы сорауларга җавап биреп, сез җәмгыять белеме буенча Бердәм дәүләт имтиханнарының иң катлаулы мәсьәләләренең берсен чишүдә бәһаләп бетерә алмаслык тәҗрибә алырсыз.

Һәр бүлекне тәмамлаучы йомгаклауларга һәм шунда ук урнаштырылган биремнәргә аеруча игътибар итүегезне сорыйбыз. Алар арасында Бердәм имтихан таләпләре форматында төзелгән биремнәр аерым блок итеп бирелде.

Уңышлар телибез!

I бүлек

СОЦИАЛЬ-ГУМАНИТАР БЕЛЕМНӘР ҺӘМ ҺӨНӘРИ ЭШЧӘНЛЕК

§ 1. Фән һәм философия

Исегезгә төшерегез:

җәмгыять белеме тарихтан нәрсә белән аерыла? Аларда урталык нәрсәдә? Физика, химия, биологиядән алар нәрсә белән аерыла?

Физика һәм тарих, биология һәм химия кебек уку предметларының шундый ук исемнәрдәге фәннәр нигезендә төзелүен сез, әлбәттә, беләсез. Ә «җәмгыять белеме» бер генә фәнне түгел, җәмгыятьне һәм кешене өйрәнүче фәннәрнең тулы бер комплексын аңлата. Әлеге фәннәр бирә торган белемнәрне социаль-гуманитар фәннәр дип атыйлар. (Шунысын да әйтик, гуманитар фәннәр шулай ук үзләрендә филология фәннәренең тулы бер комплексын: лингвистика, тел белемен һ.б. колачлыйлар.)

ТАБИГЫЙ-ФӘННИ ҺӘМ СОЦИАЛЬ-ГУМАНИТАР БЕЛЕМНӘР

Беренче карашка барысы да гади кебек. Табигать фәннәре — табигатьне, социаль-гуманитар фәннәр җәмгыятьне өйрәнә. Ә кешене нинди фәннәр өйрәнә? Тегесе дә, монысы да икән. Аның биологик табигатен — табигать фәннәре, ә кешенең социаль сыйфатларын иҗтимагый фәннәр өйрәнә. Табигать фәннәре белән иҗтимагый фәннәр арасында арадашлык итүче фәннәр дә бар. Андый фәннәрнең мисалы — география. Белгәнегезчә, физик география — табигатьне, ә икътисади география җәмгыятьне өйрәнә. Экология дә шундый ук хәлдә.

Әйтелгәннәр «иҗтимагый фәннәр табигать фәннәреннән сизелерлек аерылып тора» дигәнне кире какмый.

Әгәр табигать фәннәре кешедән башка яшәүче һәм яши алучы табигатьне өйрәнсә, иҗтимагый фәннәр җәмгыятьне, анда яшәүче кешеләр эшчәнлеген, аларның уй-фикерләрен һәм омтылышларын өйрәнмичә генә танып-белә алмыйлар. Табигать фәннәре табигать күренешләре арасындагы объектив бәйләнешларны өйрәнәләр, ә иҗтимагый фәннәр өчен төрле социаль процесслар арасындагы объектив үзара бәйлелекне генә түгел, ә аларда катнашучы кешеләрнең уй-фикерләрен ачып бирү дә мөһим.

Табигать фәннәре, кагыйдә буларак, гомумиләштерелгән теоретик белемнәр бирәләр. Алар аерым бер табигать объектын гына түгел, ә бертөрле объектлар җыелмасының уртак сыйфатларын характерлыйлар. Социаль фәннәр бертөрле иҗтимагый күренешләрнең гомуми билгеләрен генә түгел, ә бәлки аерым, кабатланмас вакыйганың сыйфатларын, социаль әһәмиятле эш-хәрәкәт үзенчәлекләрен, билгеле бер чорда илдәге җәмгыятьнең торышын, конкрет дәүләт эшлеклесенең сәясәтен һ.б. да өйрәнәләр.

Сез алга таба социаль фәннәрнең үзенчәлекләре турында тагын да күбрәк белерсез. Барлык үзенчәлекләренә карамастан, иҗтимагый фәннәр — зур фәннең аерылмас өлеше, алар анда башка предметлы (табигать, техник, математик) өлкәләр белән үзара эш итәләр. Фәнни тикшеренүләрнең башка өлкәләре кебек үк, социаль фәннәр чын хакыйкатьне табу, җәмгыять яшәешенең объектив законнарын, аның үсеш тенденцияләрен ачу максатын куялар.

СОЦИАЛЬ-ГУМАНИТАР ФӘННӘРНЕ КЛАССИФИКАЦИЯЛӘҮ

Социаль фәннәрнең төрле классификацияләре бар. Аларның берсе буенча, иҗтимагый фәннәр, башкалары кебек үк, аларның практика белән бәйләнешләренә (яки аннан ераклашуына) карап, фундаменталь һәм гамәли фәннәргә аерылалар. Беренчеләре әйләнә-тирә дөньяның объектив законнарын ачыклыйлар, икенчеләре әлеге законнарны җитештерү яисә социаль өлкәләрдә гамәли бурычларны хәл итү өчен куллану проблемаларын чишәләр. Ләкин фәннең бу төркемнәре арасындагы чик шартлы һәм хәрәкәтчән.

Гомум кабул ителгәне булып тикшеренү предметы (һәр фән турыдан-туры өйрәнә торган элемтәләр һәм бәйлелекләр) аның нигезен тәшкил иткән классификация санала. Бу күзлектән чыгып караганда, социаль фәннәрнең түбәндәге төркемнәрен аерып күрсәтергә була:

тарих фәннәре (ватан тарихы, гомуми тарих, археология, этнография, историография һ.б.);

икътисад фәннәре (икътисад теориясе, икътисад һәм халык хуҗалыгын идарә итү, бухгалтерия исәп-хисабы, статистика һ.б.);

философия фәннәре (философия тарихы, логика, этика һ.б.);

филология фәннәре (әдәбият белеме, тел белеме, журналистика һ.б.);

юридик фәннәр (дәүләт һәм хокук теориясе һәм тарихы, хокук тәгълиматлары тарихы, конституцион хокук һ.б.);

педагогика фәннәре (гомуми педагогика, педагогика һәм мәгариф тарихы, белем һәм тәрбия бирү теориясе һәм методикасы һ.б.);

психология фәннәре (гомуми психология, шәхес психологиясе, социаль һәм сәяси психология һ.б.);

социология фәннәре (социология теориясе, методологиясе һәм тарихы, икътисади социология һәм демография һ.б.);

сәясәт фәннәре (сәясәт теориясе, сәясәт фәне тарихы һәм методологиясе, сәясәт технологияләре һ.б.);

культурология (мәдәният теориясе һәм тарихы, музейлар эше белеме һ.б.).

Профильле сыйныфта аерым игътибар тарих, социология, сәясәт, психология, икътисад, юридик, хокук фәннәренә һәм философиягә бирелә. Тарих, икътисад һәм хокукның үзенчәлекләре мөстәкыйль курсларда ачыла. Философия, социология, политология, социаль психологиянең асылы шушы курста карала.

ИҖТИМАГЫЙ ФӘННӘР БУЛАРАК СОЦИОЛОГИЯ, ПОЛИТОЛОГИЯ, СОЦИАЛЬ ПСИХОЛОГИЯ

Киңрәк мәгънәдә **социология** — җәмгыятьне һәм иҗтимагый мәсьәләләрне өйрәнүче фән ул. Әмма җәмгыятьне төрле фәннәр өйрәнә. Аларның һәрберсе (икътисад теориясе, культурология, дәүләт һәм хокук теориясе, политология), кагыйдә буларак, җәмгыять тормышының нинди дә булса бер өлкәсен, аның үсешенең нинди дә булса билгеле бер ягын тикшерә.

Хәзерге социологик энциклопедия социологияне тарихи билгеләнгән социаль системаларның үсеше һәм яшәешенең гомуми һәм специфик социаль законнары һәм закончалыклары турындагы, әлеге законнарның кешеләр, социаль төркемнәр, сыйныфлар, халыклар эшчәнлегендә эшләве һәм чагылу формалары механизмнары турындагы фән буларак билгеле. «Социаль» сүзе мондый билгеләмәдә иҗтимагый мөнәсәбәтләр, ягъни кешеләрнең бер-берсенә һәм җәмгыятькә мөнәсәбәтләре җыелмасын аңлата. «Социаль» дигән сүз кешеләрнең үзара аралашуында һәм бер-берсенә тәэсир итүендә чагыла торган уртак эшчәнлеге нәтиҗәсе булып аңлашыла.

Социология — бербөтен система буларак җәмгыять, аның оешуы, эш итүе, үсүе закончалыклары турындагы фән. Ул кешеләрнең социаль тормышын, социаль фактларны, процессларны, аерым кешеләрнең, социаль төркемнәрнең мөнәсәбәтләрен, эшчәнлекләрен, аларның ролен, статусларын һәм социаль үз-үзләрен тотышын, аларның оешуының институциональ формаларын өйрәнә.

Социология белеменең өч дәрәҗәсе турында күзаллау киң таралган. *Теория дәрәҗәсе* җәмгыять төзелеше һәм яшәешенең гомуми мәсьәләләрен чагылдыручы гомумсоциологик теориядән гыйбарәт. *Гамәли социологик тикшеренүләр дәрәҗәсендә* төрле ысуллар файдаланыла: күзәтү, сорашып белешү, документларны өйрәнү, эксперимент. Алар ярдәмендә социология җәмгыятьтә бара торган конкрет процесслар турында дөрес белемнәр бирә. *Урта дәрәҗәдәге теорияләр* (гаилә социологиясе, хезмәт социологиясе, конфликтлар социологиясе һ.б.) гомумсоциологик теорияләр белән реаль чынбарлык күренешләре турында фактик мәгълүматлар бирүче гамәли тикшеренүләр арасында тоташтыручы буын булып торалар.

Социология тулаем хәзерге тормышка карый. Ул җәмгыятьтә бара торган хәлләрне аңларга һәм фаразларга ярдәм итә.

Сәясәт фәне (политология) җәмгыятьнең сәяси практикаларын, сәяси тормышын гомумиләштерүче булып тора. Ул сәясәтне иҗтимагый тормышның башка өлкәләре белән үзара бәйләнештә өйрәнә. Политология предметлары — хакимият, дәүләт, сәяси мөнәсәбәтләр, сәяси системалар, үзеңне сәяси тоту, сәяси мәдәният. Политология төрле социаль, этник, дини һәм башка иҗтимагый төркемнәрнең хакимияткә карата мөнәсәбәтен, шулай ук сыйныфлар, партияләр һәм дәүләт арасында мөнәсәбәтләрне өйрәнә.

Политологияне ике төрле аңлаталар. *Тар мәгънәдә* политология — сәясәтне өйрәнүче фәннәрнең берсе, төгәлрәге — сәясәтнең социаль субъектларның хакимият һәм йогынты ясау мәсьәләсендә, хакимлек итүчеләр һәм аларга буйсынганнар, идарә итүчеләр һәм аларга буйсынганнар арасындагы аерым тип мөнәсәбәтләрнең специфик закончалыкларын өйрәнүче гомуми теориясе. Сәясәт теориясе хакимиятнең төрле концепцияләрен, дәүләт һәм сәяси партияләрнең теорияләрен, халыкара мөнәсәбәтләр теорияләрен һ.б. ны үз эченә ала.

Киң мәгънәдә политология үз эченә барлык сәяси белемнәрне ала һәм сәясәтне өйрәнүче дисциплиналар комплексын: сәяси фикер тарихын, сәяси философияне, сәяси социологияне, сәяси психологияне, дәүләт һәм хокук теориясен, сәяси географияне һ.б. колачлый. Башкача әйткәндә, политология сәясәтне һәрьяклап тикшерүче бердәм, интеграль фән булып тора. Ул төрле ысуллар, шул исәптән социологиядә һәм башка иҗтимагый фәннәрдә булган ысуллар кулланылучы гамәли тикшеренүләргә таяна.

Политология сәяси хәлне анализларга һәм фаразларга ярдәм итә.

Социаль психология, җәмгыять белеме тармакларын классификацияләгәндә күргәнегезчә, психологик фәннәр төркемене

керә. Психология психиканың үсү һәм тәэсир итү закончалыкларын, үзенчәлекләрен өйрәнә. Ә аның бер тармагы — социаль психология — кешеләрнең социаль төркемнәргә кушылу факты нәтиҗәсендәге үз-үзләрен тотышлары һәм эшчәнлекләре закончалыкларын, шулай ук әлеге төркемнәрнең психологик характеристикаларын өйрәнә. Үзенең тикшеренүләрендә социаль психология бер яктан — гомуми психология белән, икенче яктан социология белән тыгыз бәйләнгән. Ләкин нәкъ менә ул иҗтимагый-психологик күренешләрнең, субъектлары индивидлар һәм социаль бергәлекләр булган процесслар һәм хәлләрнең формалашу, эшләү һәм үсү закончалыклары, индивидның социальләшүе, шәхеснең төркемнәрдәге эшчәнлеге, төркемнәрдәге аерым шәхесләрнең үзара мөнәсәбәте, кешеләрнең төркемнәрдәге уртак эшчәнлеге табигате, аларда барлыкка килгән аралашу һәм үзара тәэсир итү кебек мәсьәләләрне өйрәнә.

Социаль психология җитештерү, фәнни, уку-укыту коллективларында психологик климатны яхшырту; идарә итүчеләр һәм аларга буйсынганнар арасындагы мөнәсәбәтләрне оптимальләштерү; мәгълүмат һәм рекламаларны кабул итү; гаилә мөнәсәбәтләрен җайга салу кебек һ.б. күпләгән проблемаларны хәл итәргә булыша.

ФИЛОСОФИЯ ФӘНЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

«Эшләгән чакта нишлиләр ул философлар?» дигән сорау турында уйлана инглиз галиме Б.Рассел. Шушы гади сораугa җавап фәлсәфә кору процессының, аның нәтиҗәсенең үзенчәлекләрен билгеләү мөмкинлеге бирә. Рассел болай дип җавап бирә: философ барыннан да элек табышмаклы һәм мәңгелек проблемалар турында уйлана: тормышның мәгънәсе нәрсәдә һәм, гомумән, ул бармы? Дөньяның максаты бармы, тарихи үсеш кая да булса илтәме? Табигать белән чынлап та законнар идарә итәме, яки безгә һәрнәрсәдә ниндидер тәртип күрү ошыймы? Дөнья принципиаль төрле ике өлешкә — рухка һәм материягә бүленгәнме, әгәр шулай икән, алар ничек итеп үзара янәшә яши ала?

Ә немец философы И.Кант төп фәлсәфи проблемаларны менә ничек формалаштыра: мин нәрсә белә алам? Мин нәрсәгә ышана алам? Нәрсә ул кеше?

Мондый сорауларны кеше фикере күптән куйды, алар үз әһәмиятләрен бүген дә саклый, чөнки аларны тулы ышаныч белән *философиянең мәңгелек проблемаларына* кертергә мөмкин. Һәр тарихи дәвердә философлар әлеге сорауларны төрлечә куялар һәм җавап бирәләр.

Аларның бу хакта башка фикер ияләре һәм башка вакытта ни уйлауларын беләселәре килә. Философларның үз тарихларына мөрәҗәгать итүе аеруча мөһим була бара. Философлар, үзләреннән элгәреләрнең иҗади мирасына үз заманы күзлегеннән тәнкыйди карап, алар белән туктаусыз фикер диалогында яшиләр, яңача якын килүләр һәм чишелешләр тәкъдим итәләр.

> «Философия яшәешне кешедән һәм кеше аша таныпбелә, мәгънәне чишүне кешедә күрә, фән исә яшәешне кешедән читтә, кешедән аерылып танып-белә. Шунлыктан яшәеш философия өчен — рух, ә фән өчен яшәеш — табигать».
>
> **Н.А.Бердяев**

Булдырыла торган яңа фәлсәфи системалар элек тәкъдим ителгән концепция һәм принципларны юкка чыгармыйлар, алар белән бердәм мәдәни һәм танып-белүле киңлектә янәшә яшәүләрен дәвам иттерәләр. Шунлыктан философия үз мәктәпләрендә һәм юнәлешләрендә һәрвакыт *плюрализмлы*, күп төрле. Кайберәүләр хәтта «философиядә күпме философ булса, шулкадәр үк хакыйкать» дип раслыйлар.

Фән белән эш башкача тора. Ул күпчелек очракта үз заманының мөһим проблемаларын хәл итә. Гәрчә фәнни фикернең үсеш тарихы шулай ук мөһим һәм гыйбарәтле булса да, актуаль проблеманы тикшеренүче галим өчен ул философ өчен аның элгәреләре идеяләре ия булган кебек үк зур әһәмияткә ия түгел. Фән ачкан һәм нигезләгән положениеләр объектик хакыйкать характеры ала: математика формулалары, хәрәкәт итү законнары, мираслык механизмнары һ.б. Алар һәр җәмгыять өчен гадел, «кешегә дә, кешелек дөньясына да бәйле түгелләр». Философия өчен норма булган нәрсәләр — төрлечә якын килүләрнең янәшә яшәве һәм билгеле булган капма-каршылыгы — фән өчен — фән үсешенең әле җитәрлек өйрәнелмәгән өлкәсенә караучы аерым бер очрак: без анда фәнни мәктәпләр көрәшен, гипотезалар көндәшлеген күрәбез.

Философия белән фән арасында әле тагын шактый мөһим аерма бар — проблемаларны эшкәртү ысуллары. Б.Рассел билгеләп үткәнчә, фәлсәфи сорауларга лабораториядә тәҗрибәләр ясап җавап таба алмассың. Фәлсәфә кору — бары тик фикерләүгә нигезләнгән эшчәнлек төре. Гәрчә күпчелек очракта философлар үзләренең фикер йөртүләрен рациональ нигездә корсалар һәм нәтиҗәләрнең логик дәлилләнгәнлегенә омтылсалар да, алар дәлилләүнең формаль логика кысаларыннан чыга торган аерым ысуллар да кулланалар: бербөтеннең каршы якларын ачалар, сәер фикерләргә (мантыйклы фикер алышканда

мәгънәсез нәтиҗәләргә килү), хәл ителмәслек проблемаларга мөрәҗәгать итәләр. Мондый ысуллар һәм алымнар дөньяның каршылыклы булуын һәм үзгәреп торуын тоярга ярдәм итә.

Философиядә кулланыла торган күп төшенчәләр гомумиләштерелгән, абстракт характерда. Бу исә аларның күренешләрнең киң даирәсен колачлавы белән бәйле, шунлыктан аларның һәрберсенә хас гомуми билгеләр аз. Шактый киң, күренешләрнең бик тә зур классын колачлаучы философия төшенчәләренә «яшәеш», «аң», «эшчәнлек», «җәмгыять», «танып-белү» һ.б. категорияләрне кертергә мөмкин.

Шулай итеп, философия белән фән арасында аерма аз түгел. Шул нигездә күпләгән тикшеренүчеләр философияне дөньяны танып-белүнең бик тә үзенчәлекле ысулы дип карыйлар.

Ләкин шунысын да күз уңаеннан ычкындырырга ярамый: философия белеме күпкатлы; югарыда күрсәтелгән кыйммәтләргә (*экзистенциальләргә* — лат. existentia — кыйммәтле) кертү һәм фәнни юл белән төшенү икеле булган мәсьәләләрдән тыш, философия инде «тиешле»гә түгел, ә «чын»га юнәлдерелгән башка кайбер проблемаларны да өйрәнә. Философия эчендә шактый күптәннән инде белемнәрнең чагыштырмача яңа өлкәләре барлыкка килде: яшәеш турында тәгълимат — *онтология;* танып-белү турында тәгълимат — *гносеология;* әхлак турында фән — *этика;* чынбарлыктагы гүзәллекне, сәнгатьнең үсү законнарын өйрәнүче фән — *эстетика*.

Игътибар итегез: белемнең бу өлкәләрен кыскача характерлаганда без «фән» төшенчәсен кулландык. Очраклы түгел бу. Философиянең әлеге бүлекләренә кергән сорауларны анализлау ешрак фәнни танып-белү мантыйгында бара һәм «чын» яки «ялган» белем позициясеннән бәяләнә ала.

Философия белеменә җәмгыятьне һәм кешене аңлау өчен мөһим булган кешенең асылы һәм табигате турындагы, кешенең үзенчәлекле яшәү сәләте турындагы фән — *фәлсәфи антропология*, шулай ук *социаль философия* керә.

ҖӘМГЫЯТЬНЕ АҢЛАУГА ФИЛОСОФИЯ НИЧЕК ЯРДӘМ ИТӘ

Социаль философиянең предметы — җәмгыятьтә кешеләрнең уртак эшчәнлеге. Җәмгыятьне өйрәнү өчен социология кебек фән мөһим. Иҗтимагый төзелеш һәм кешенең социаль үз-үзен тотышының формалары турында үз йомгакларын һәм нәтиҗәләрен тарих ясый. Кешеләрнең дөньяны аңлавына нәкъ менә философия нинди яңалык кертә соң?

Әлеге мәсьәләне социальләштерү — шәхеснең җәмгыять барлыкка китергән кыйммәтләрне һәм мәдәни үрнәкләрне

үзләштерүе мисалында тикшерик. Бу очракта социологның игътибар үзәгендә бүгенге җәмгыятьтә алар йогынтысында гамәлгә ашырыла торган социальләштерү процессы факторлары (иҗтимагый институтлар, социаль төркемнәр) булачак. Социолог шәхеснең кыйммәтләр һәм нормаларны үзләштерүендә гаилә, белем бирү, яшьтәшләре төркемнәре, массакүләм мәгълүмат чаралары йогынтысы ролен тикшерәчәк. Тарихчыга билгеле бер тарихи чордагы конкрет җәмгыятьтә социальләшүнең реаль процесслары кызыклы. Ул, мәсәлән, түбәндәге сорауларга җавап эзләячәк: XVIII гасырда Көнбатыш Европаның крестьян гаиләсендә балада нинди кыйммәтләр тәрбияләгәннәр? Россиядә революциягә кадәрге гимназиядә балаларны нәрсәгә һәм ничек өйрәткәннәр, укытканнар һ.б.

Ә социаль философ ничек эш итә? Аның игътибар үзәгендә тагын да гомумирәк проблемалар торачак: социальләштерү процессы җәмгыятькә ни өчен кирәк һәм ул шәхескә нәрсә бирә? Формалары күптөрле булган хәлдә, аның кайсы компонентлары тотрыклы характерда, ягъни теләсә кайсы җәмгыятьтә кабул ителә? Шәхескә билгеле бер иҗтимагый тәртипләрне һәм өстенлекләрне көчләп тагу аның эчке иреге белән ничек яраша? Ирекнең кыйммәте нәрсәдә?

Күрәбез ки, социаль философия гомумирәк, тотрыклырак характеристикаларны анализлауга йөз тота; ул күренешне тагын да киңрәк социаль контекстка куя (шәхси ирек һәм аның чикләре), кыйммәти якын килүләргә тартыла.

> «Социаль философиянең предметы — җәмгыять үзе нәрсә, кеше тормышында нинди әһәмияткә ия, аның чын асылы нәрсәдә һәм безне нәрсәгә мәҗбүр итә дигән сорау ул».
>
> С.Л.Франк

Үзенең тулы кыйммәтле өлешен социаль философия киң даирә проблемаларны эшләүгә кертә, алар: бербөтен буларак җәмгыять (җәмгыять һәм табигать нисбәте); иҗтимагый үсеш закончалыклары (алар нинди, иҗтимагый тормышта ничек чагылалар, табигать законнарыннан нәрсә белән аерылалар); система буларак җәмгыятьнең структурасы (җәмгыятьнең төп компонентларын һәм ассистемаларын аерып күрсәтүнең нигезләре нинди, җәмгыятьнең тулылыгын элемтә һәм үзара бәйләнешләрнең нинди төрләре тәэмин итә); иҗтимагый үсешнең мәгънәсе, юнәлеше һәм ресурслары (иҗтимагый үсештә тотрыклылык һәм үзгәрүчәнлек бер-берсе белән ничек ярашалар, моның төп чыганаклары нинди, иҗтимагый-тарихи үсешнең юнәлгәнлеге нинди, иҗтимагый алгарыш нәрсәдә чагыла

һәм аның чикләре нинди); җәмгыять тормышының рухи һәм матди якларының үзара нисбәте (әлеге якларны аерып күрсәтү өчен нәрсә нигез булып хезмәт итә, алар бер-берсе белән ничек үзара эш итә, аларның берсен әйдәп баручы дип әйтеп буламы); социаль эш итү субъекты буларак кеше (кеше эшчәнлегенең хайваннарның үз-үзләрен тотышыннан аермасы, аң — эшчәнлекне җайга салучы); социаль танып-белүнең үзенчәлекләре.

Әлеге проблемалардан күп нәрсәләрне без алга таба тикшерербез.

Төп төшенчәләр: иҗтимагый фәннәр, социаль-гуманитар белем; фән буларак социология; фән буларак политология; фән буларак социаль психология; философия.

Терминнар: фәннең предметы, фәлсәфи плюрализм, коры фикерләүгә нигезләнгән эшчәнлек.

Үзегезне тикшерегез

1. Иҗтимагый фәннәрнең табигать фәннәреннән төп аермалары нәрсәдә? 2. Фәнни белемнең төрле квалификацияләреннән мисаллар китерегез. Аларның нигезенә нәрсә салынган? 3. Тикшеренү предметы буенча аерымланучы социаль-гуманитар белемнәрнең төп төркемнәрен атагыз. 4. Социология предметы нинди ул? Социологик белем дәрәҗәләрен тасвирлагыз. 5. Сәясәт фәне нәрсәне өйрәнә? 6. Социаль психологиянең фәнни белемнең төрдәш өлкәләре белән бәйләнеше нәрсәдә чагыла? 7. Философияне һәм фәнне нәрсә аера һәм нәрсә якынайта? 8. Нинди проблемаларны һәм ни өчен философиянең мәңгелек мәсьәләләренә кертәләр? 9. Фәлсәфи фикер плюрализмы (төрлелеге) нәрсәдә чагыла? 10. Философия фәненең төп бүлекләре нинди? 11. Җәмгыятьне аңлауда социаль философиянең ролен күрсәтегез.

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Ике немец философы әйткәннәрне анализлагыз.

«Фәннәр үз өлкәләрендә ышандырырлык дөрес һәм гомумтанылган белемнәр алсалар, философия исә, мең еллар дәвамында тырышуына карамастан, моңа ирешә алмады. Шуны инкарь итми булмый: ахыргача танып-беленгәнгә карата философиядә бердәм караш юк... Философиянең теләсә кайсы образы бердәм карашка ия түгел икән, бу аның эшләре табигатеннән килеп чыга» (К.Ясперс).

«Философия тарихы шуны күрсәтә... төрле булып күренгән фәлсәфи тәгълиматлар фәкать аның үсешендәге төрле баскычларындагы бер философиядән гыйбарәт» (Г.Гегель).

Боларның кайсысы сезгә ышандырырлык булып күренә? Ни өчен? Ясперсның философиядә бердәм караш булмау «аның

эшләре табигатеннән килеп чыга» дигән сүзләрен сез ничек аңлыйсыз?

2. Платонның билгеле бер нигезләмәсе болайрак белдерелә: «Хакимлек итүчеләр фәлсәфә сатудан яки философлар хакимлек итүдән туктамый торып, кешелек дөньясының бәхетсезлекләре тукталмаячак...» Әлеге раслауны «чын» философиягәме, әллә «тиешлесенә» кертергәме? Үз җавабыгызга аңлатма бирегез. Фәнни белемнең туу һәм үсү тарихын исегезгә төшерегез һәм «философия» дигәндә Платонның нәрсәне күздә тотуы турында уйлагыз.

Чыганак белән эшләгез

В.Е.Кемеров китабыннан өзек укыгыз.

Философия җәмгыять белеме турында

«Социаль-гуманитар танып-белү» термины үзе үк җәмгыять белеменең танып-белүнең ике тереннән «төзелүен» күрсәтә, ягъни бу термин элемтәне генә түгел, аерымлыкны да терки. Бер яктан, структураларны, гомуми элемтәләрне һәм закончалыкларны өйрәнүгә йөз тоткан *социаль фәннәрне*, икенче яктан — иҗтимагый тормышның кешеләрнең үзара хезмәттәшлегенең һәм шәхесләрнең күренешләрен һәм вакыйгаларын конкрет индивидуаль сурәтләргә кушкан *гуманитар танып-белүне* аерып, фәнни җәмгыять белеменең ныгып урнашуы бу аермалыкларны «ныгытты». Җәмгыять белемендә социальлекнең һәм гуманитарлыкның нисбәте турындагы мәсьәлә даими бәхәсләр предметы булды. Әлеге бәхәсләр вакытында әле — дисциплинаны төгәл методологик билгеләү (һәм шул рәвешле бүлү) яклылар, әле аларны методологик якынайту (һәм шул рәвешле предметлы интеграцияләү) яклылар җиңде. Әмма шунысын билгеләп үтү мөһим: фәнни җәмгыять белеменең социаль һәм гуманитар дисциплиналарын болай аеру һәм каршы кую нигездә «табигый», кешелек эшчәнлеген бүлү һәм бәйләүнең гомуми логикасына туры килә торган хәл буларак аңлатылды. Әлеге хәлне формалаштыру үзе фәнни җәмгыять белеме ныгып урнашуның озын һәм еракта булмаган тарихында, кагыйдә буларак, игътибарга алынмады.

Социаль фәннәрнең һәм гуманитар танып-белүнең аерымлыгы фәнни җәмгыять белеменең кешеләрнең көндәлек аңы белән мөнәсәбәтләрендә дә чагыла. Социаль фәннәр, көндәлек аңга көндәлек тормышларында кешеләрне турыдан-туры чагылдыру өстеннән «күтәрелеп торучы» теорияләр, төшенчәләр һәм концепцияләрнең махсус өлкәсе буларак, көндәлек аңга ачыктан-ачык каршы куелдылар (догматик марксизмдагы

фәнни дөньяга карашны кешеләрнең көндәлек үз-үзләрен тотуларына кертү дә шуннан). Гуманитар танып-белү кешенең көндәлек тәҗрибәсе схемалары белән шактый дәрәҗәдә исәпләште, аларга таянды, ул гына да түгел, еш кына фәнни төзелешләрне аларның индивидуаль яшәеш һәм аң формалары аша бәяләде. Башкача әйткәндә, социаль фәннәр өчен кешеләр әлеге фәннәр билгеләгән объектив күренеш элементлары булсалар, гуманитар фән өчен, киресенчә, фәнни эшчәнлек формалары үз әһәмиятләрен кешеләрнең уртак һәм шәхси тормышына кушылган схемалар буларак ачыкладылар.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Җәмгыять белеменә танып-белүнең нинди ике төре керә? 2. Социаль фәннәр гуманитар танып-белүдән нәрсәсе белән аерыла? 3. Социаль һәм гуманитар фәнни дисциплиналарны нәрсә берләштерә? 4. Таблица төзегез, аның беренче баганасына тексттан социаль фәннәрне характерлаучы барлык уй-фикерләрне, икенчесенә аларга караган гуманитар дисциплиналар исемнәрен языгыз.

§ 2. Кеше һәм җәмгыять элеккеге мифларда һәм беренче фәлсәфи тәгълиматларда

Исегезгә төшерегез:

борынгы халыклар мифларында дөнья ничек сурәтләнгән? Борынгы Һиндстанда каста строе ничек характерланган? Антик полисның сәяси төзелеше борынгы Көнчыгыш дәүләтләрнекеннән нәрсәсе белән аерылган?

Кеше элек-электән үк үзе, үзен чолгап алган дөньяда үзенең урыны, тирә-юньдәге кешеләр белән мөнәсәбәтләре, коллективның, бергәлекнең, дәүләтнең үсүенә юнәлеш бирүче югары хакимиятнең килеп чыгуы һәм характеры турында уйланган. Дөнья картинасы һәм кешенең андагы урыны барлык халыкларда диярлек булган борынгы мифларда чагылыш тапкан. Борынгы Һиндстанда, Кытайда, Грециядә тәкъдим ителгән фәлсәфи идеяләр һәм тәгълиматлар «чын»ны фикерләүдә һәм «тиешле»не нигезләүдә яңа этап була. Кешелек дөньясы үсешенең әлеге элгәре чорында философия үзенә дөнья һәм кеше турындагы белемнәрне туплаган.

Борынгы кешеләрнең дөнья һәм үзләре турындагы күзаллауларына мөрәҗәгать итеп, без әлеге карашларның чыганакларын һәм эволюцияләре юнәлешләрен, бүгенге кешенең дөньяга карашының үзенчәлекләрен тирәнрәк аңлый алабыз.

БОРЫНГЫ КЕШЕНЕҢ МИФОЛОГИК АҢЫ

«Миф» сүзе грекча mythostан килеп чыга — риваять, хикәят. Моны исәпкә алып, кайберәүләр мифны легенда, сихерле әкият белән тәңгәлләштерәләр (мәгаен, сезнең күбегез дә тарих дәресләрендә танышкан борынгы грек мифларына шундый караштадыр). Борынгы кеше өчен мифта бәян ителгәннәр, гәрчә аларда сүз бүгенге кеше бернинди логика күрми торган мажаралы вакыйгалар турында баруы ихтимал булса да, уйлап чыгарылган нәрсәләр булмаган. Мифның әкият белән риваятьтән аермасы турында сез тулырак итеп параграф ахырында урнаштырылган чыганактан өзекне укып белерсез.

Тарих курсыннан белгәнегезчә, борынгы кешеләр һәрвакыт кешене бергәлекнең бер өлеше дип исәпләгәннәр, ә бергәлекне табигатьнең бер өлеше дип уйлаганнар. Аларның аңында кеше һәм табигать бер-берсенә каршы тормаган. Табигать дөньясы кеше характеристикаларына ия булган. Борынгы кешеләр аңының бу үзенчәлеге мифларда бик ачык чагылган. Ләкин аларда дөньяны аңлауның башка, тикшеренүчеләр соңрак *мифологик аң* дип атаган сыйфатлары күренгән.

Бүгенге кешенең дөньяны ничек кабул итүе белән чагыштырып, мифологик аңның үзенчәлекләрен аңларга тырышыйк. Мисалга, без таң атуларны һәм кояш батуларны күзәтәбез һәм аларның Җирнең әйләнүенә бәйле икәнен беләбез; бер баланың, өлкән бер кешедән икенчесенә йөгереп барып, һәр икесенә дә шатланып үз исемен әйтүен күреп торабыз һәм балада узаң формалаша баруын аңлыйбыз. Башкача әйткәндә, безне күренешне турыдан-туры кабул итүебез белән аны аңлаешлы итә торган фикер арасында ниндидер гомумиләштерүләр, нәтиҗәләр, универсаль законнар һ.б. тора. Борынгы кешеләр күренешләрне ниндидер теоретик йомгаклауларга кертмәгәннәр, аларның кабул итүе «тышкы»га һәм «чын»га, «чынбарлык»ка һәм «күренгән нәрсә»гә бүлүне белмәгән. Акылга, хис һәм ихтыярга турыдан-туры тәэсир иткән һәрнәрсә «чын» булган. Төшләр дә чынбарлык, өндә алынган тәэсирләр буларак каралган һәм хәтта, киресенчә, тагын да әһәмиятлерәк булып тоелган. Шунлыктан борынгы греклар һәм вавилоннар еш кына, төштә ачышлар өмет итеп, төннәрен изге урыннарда үткәргәннәр.

Дөньяны аңлый барып, төрле күренешләргә очрап, без шундый сораулар куябыз: ни өчен һәм ничек була бу? Борынгы кеше өчен хакыйкатьне эзләү «кем?» дигән сорауга җавап эзләүгә кайтып калган. Ул һәрвакыт эшне тәмамлаучы максатка юнәлешле ихтыярны эзләгән. Шифалы яңгыр яуса, димәк, Аллалар кешеләрдән бүләк кабул иткән; яшь кеше үлсә, димәк, аңа кемдер үлем теләгән.

Борынгы кешеләрдә вакытны кабул итү дә безнекеннән аерылып торган. Вакыт идеясе үзе абстракцияләндерелмәгән, вакыт кеше тормышының чиратлашуы һәм ритмы аша кабул ителгән: туу, балигъльк, өлгереп җитү, картлык, кешенең үлеме; табигатьтәге үзгәрешләр дә шулай ук: көн белән төннең, ел фасылларының алышынуы, күк җисемнәренең хәрәкәт итүе.

Борынгы халыкларның мифологик аңына дөньяны илаһи һәм демоник, космик һәм хаотик көчләр көрәше мәйданы итеп кабул итү хас була. Кешеләр, үзләре ышанганча, әйбәт яшәүләре аларга бәйле булган игелекле көчләргә ярдәм итәргә тиеш санала. Борынгы кеше тормышының ритуаль-йола ягы шулай туа.

Мөһим вакыйгалар календарь бәйрәмнәргә туры китерелә. Мәсәлән, Вавилониядә тәхеткә утырту һәрвакыт яңа табигать циклына кадәр кичерелеп торыла, яңа храмны ачу фәкать яңа елның беренче көнендә генә бәйрәм ителә.

Архаик мифлар аларны тудырган чорлар белән бергә артта калды; философия, дин, аннары фән дөньяның яңа күренешен барлыкка китерделәр. Ләкин мифологик фикер йөртү элементлары массалар аңында бүгенге көндә дә саклана әле.

БОРЫНГЫ ҺИНДСТАН ФИЛОСОФИЯСЕ: ДӨНЬЯ ГАЗАПЛАРЫННАН НИЧЕК КОТЫЛЫРГА

Борынгы Һиндстанда дини-фәлсәфи акыллылык чыганагы булып берничә йөз (б.э.к. 1200 – 600 еллар) дәвамында җыелган, мифологик аң чагылышлары көчле булган күп текстлар җыелмасы — *ведик әдәбият* санала («веда» — белем). Анда дөнья Космос белән Хаосның мәңгелек капма-каршылыгы булып күзаллана, аллалар еш кына табигый көчләрне гәүдәләндерүчеләр итеп сурәтләнәләр.

Текстларның икенче бер төркеме, соңрак барлыкка килгән *Упанишадлар* (бу сүз акыл иясенең үз шәкертләрен укыту вакытын белдерә) — аңлаешлырак һәм шуның белән фәлсәфирәк. Нәкъ менә әлеге текстларда беренче тапкыр реинкарнация — үлгәннән соң тере җан ияләренең җаннары башкаларга күчү турындагы идея чагылдырыла. Кешенең яңа тормышта кем яки нәрсә булачагы аның кармасына бәйле. «Эш, гамәл»не аңлатучы «карма» һинд философиясендә төп төшенчә булып тора. Карма канунында язылганча, игелекле эшләр кылган, әхлак нормалары кушканча яшәгән кеше киләчәк тормышта җәмгыятьнең иң югары кастaларыннан берсенең вәкиле булып туачак. Ә инде гамәлләре дөрес булмаган кешенең яңа тормышта кагылгысызлар кастасы вәкиле яки

хәтта хайван, янсә үткән тормышындагы гөнаһлары өчен меңләгән кеше тибеп китәчәк юл буендагы таш булуы ихтимал. Башкача әйткәндә, һәркем үз өлешенә тигәнне алачак.

Начар карманы алыштырырга яки аннан котылырга буламы? Киләчәктә яхшы өлешкә лаек булу өчен, кеше элек ящәгәннәре өчен карма бурычын саваплы эшләре һәм дөрес яшәве белән акларга тиеш. Моңа иң ышанычлы юл — дәрвиш тормышы. «Яшәү агымын кичкәндә үткәнеңнән ваз кич, киләчәгеңнән ваз кич, алар арасында булган нәрсәләрдән ваз кич. Акылың азат ителсә, ни генә булмасын, син яңадан җимерелүгә һәм картлыкка килмәссең».

Җанны азат итүнең тагын бер ысулы булып *йога* (кушылу, элемтә) тора. Йога системасының практик күнегүләре комплексын үзләштерү өчен түземлек, үҗәтлек, тәртипле булу, үз-үзеңә катгый контроль кирәк. Тренировкаларның төп этапларының максаты — үз-үзеңне тота алу, хисләреңне тышкы тәэсирләрдән аеру, фикерләреңне туплау, медитация (читтән күзәтү). Шул рәвешле, йогның барлык тырышлыкларының мәгънәсе үзеңнең искиткеч мөмкинлекләреңне күрсәтү һәм кешеләрне шаккаттыру түгел, ә бәлки җанны азат итәргә булышлык итүче халәткә килү.

Якынча б.э.к. V гасырда Һиндстанда еш кына «атеистик» (Алласыз дин) дип йөртелә торган яңа философия — *буддизм* барлыкка килә. Яңа тәгълиматка нигез салучыны, ул кеше тормышының төп мәсьәләләре буенча белемнәр туплагач, Будда (ачык, яхшы күңелле) дип йөртә башлаганнар.

Бу тәгълимат та кешене рухи азат итү юлларын эзләүгә юнәлтелгән. Андый азат итү халәтен Будда «нирвана» дип атаган. Нирванага омтылучы кеше үзен бу дөньяда аны бәйләп торган бар нәрсәдән азат итәргә өйрәнергә тиеш була. Будда дүрт «игелекле хакыйкать» игълан итә: дөнья газаплар белән тулы; кеше газапларының сәбәбе — физик теләкләрдә, дөньяви дәрттә; теләкне бетерсәң, дәрт тә үләр, һәм кешенең газаплары да юкка чыгар; теләк булмаган халәткә ирешү өчен билгеле юлга — «сигезлек» юлына барырга кирәк.

Әхлак кагыйдәләрен дә үтәү мөһим: җан ияләренә зыян салмаска, кешенекен алмаска, тыелган җенси элемтәләргә кермәскә, мәгънәсез, буш сүз сөйләмәскә, исерткеч эчемлекләр кулланмаска.

Шулай итеп, борынгы һинд философиясенең төп мотивы чынбарлыктан газаплар һәм өметләр булмаган үзеңнең эчке дөньяңа китеп, аның тигезсезлеген һәм камилсезлеген җиңү була.

БОРЫНГЫ КЫТАЙ ФИЛОСОФИЯСЕ: НИЧЕК ИТЕП «ҖӘМГЫЯТЬ ӨЧЕН КЕШЕ» БУЛЫРГА

Борынгы кытайлар күзаллаганча, караңгыны һәм яктыны, хатын-кыздагыны һәм ир-аттагыны, пассивны һәм активны берләштерүче кеше дөньяда ниндидер уртаклыкны алып тора һәм дөньяның ике башлангычка: *инь* (караңгы башлангыч, пассив көтү) һәм *янга* (танып-белү юлын яктыртучы ниндидер активлык) аерылуын җиңәргә тиеш. Мондый хәл кешенең урталык юлын, аның арадашчы ролен дә билгели: «Тапшырам, әмма югалтмыйм». Күк улы Кеше аша һавадагы рәхәтлек җиргә иңә һәм һәркайда тарала. Кеше Җиһан патшасы түгел, ул табигать белән идарә итә алмый. Кеше өчен үз-үзен иң яхшы тоту — вакыйгаларның табигый агышына иярү, чаманы бозмыйча эш итү («у вэй» принцибы). Берәр нәрсә үзенең соңгы чигенә җитсә, ул үзенең капма-каршысына әверелә: «Бәхет булган нәрсә бәхетсезлеккә әйләнәчәк, ә бәхет бәхетсезлек өстендә тора».

Әлеге нигезләмәне борынгы кытай философиясе юнәлешләренең берсе — *даосизм* («юл турындагы тәгълиматлар») яклылар үстерә. Аның зур вәкиле фикер иясе Лао-Цзы була. Лао-Цзы өчен төп төшенчә — ешрак «юл» дип тәрҗемә ителә торган «дао».

Даосизмның читтән күзәтүеннән аермалы буларак, *конфуцианлык* җирдәге проблемалар белән тыгыз бәйләнештә була. Бик тә йогынтылы һәм Кытай җәмгыяте тормышында зур әһәмияткә ия булган әлеге тәгълиматны булдыручы Конфуций (б.э.к. 551–479 еллар) якынча Будда һәм Пифагор (грек философы һәм математигы) яшәгән елларда яши. Конфуций яшь чагында ук инде укыта, өч меңнән артык укучысы була. Безгә аның фикерләре шул укучылары белән әңгәмәләр рәвешендә килеп ирешкән.

Фикер иясе үз философиясенең үзәгенә кеше төшенчәсен куя. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә гуманлылык, игелеклелек (жень) өстенлек итәргә тиеш. Көндәлек тормышта билгеле бер кагыйдәләр белән эш итәргә кирәк. Аларның иң мөһиме — кешеләргә үзеңә теләмәгәнне эшләмә. Мондый халәткә ирешүгә катгый тәртипкә (ли), этика нормаларына иярү ярдәм итә. «Әгәр намуслы ир тегәл булса һәм вакытын бушка сарыф итмәсә, башкаларга карата әдәпле булса һәм тәртипне бозмаса, дүрт диңгез арасындагы кешеләр аның туганнары булачак», — ди Конфуций.

Җәмгыятьне дәүләт белән тәңгәлләштереп, философ «дөрес» дәүләт төзелеше мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Аның фикеренчә, алла итеп күргән императордан тыш, үзләрендә философ, әдип, галим һәм түрә сыйфатларын берләштергән кешеләр

катлавы (жу) югары дәрәҗәгә ирешкән дәүләт әнә шундый булып санала ала. Дәүләт — «Күк улы» хаким «халыкның әтисе дә, әнисе дә» булган бер зур гаилә ул. Әлеге «гаиләдә» җайга салу ролен барыннан да элек әхлак нормалары үти. Бу бергәлектәге һәр әгъзаның бурычлары аның социаль хәле белән билгеләнә. Хакимнең һәм буйсынучыларның мөнәсәбәтләрен философ мондый сүзләр белән белдерә: «Әфәнденең асылы — җилнеке, ә гади кешеләрнеке үләннеке кебек. Үз өстеннән җил искәндә үлән сайлый алмый, ул иелә».

Конфуциантлык Кытайда әкренләп дәүләт идеологиясе буларак раслана. Кытай мәдәнияте һәм җәмгыятендә ул бүген дә мөһим роль уйный.

Борынгы Һиндстан һәм Кытайдагы философия тәгълиматларын тикшерүгә йомгак ясап шуны әйтик: тулаем алганда, борынгы Көнчыгыш философиясендә кеше турында аны шәхес буларак күзаллау юк. Иң югары кыйммәт булып кеше түгел, ә ниндидер билгесез абсолют (Галәм рухы, Күк һ.б.) санала. Динифәлсәфи агымнарның күпчелеге кешене читтән күзәтүче, җәмгыятьнең гаделсезлекләрен котылгысыз бирелгән нәрсә дип кабул итүче, үзенең эчке халәтендә гармония эзләүче итеп күрә. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салуга юнәлдерелгән конфуциантлык кына искәрмә булып тора.

БОРЫНГЫ ГРЕЦИЯ ФИЛОСОФИЯСЕ: ТАБИГАТЬ ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬНЕ АҢЛАУДА РАЦИОНАЛЬ БАШЛАНГЫЧ

Борынгы греклар бик тә ачык һәм тәэсирләндерүче мифлар иҗат иткәннәр. Алар беренчеләрдән булып дөньяны тикшерүнең яңа ысулына күчкәннәр һәм сүзнең үз мәгънәсендә «философия» дип атарлык төшенчә тудырганнар («философия» термины — «акыл кызыксынуы» да грекчадан килеп чыккан).

Якынча б.э.к. VI гасырда яшәешнең кабатланмас нигезен эзләү белән мәшгуль булган берничә фикер иясе (Фалес, Анаксимен, Анаксимандр, Гераклит), һәрберсе үз юлы белән, беренчел нигезне барлык «чын»ның килеп чыгуы алдындагы ниндидер вакытлыча халәт дип түгел, ә беренчел сәбәп, өстәвенә нигезле (интеллектуаль) аңлап була торган беренчел сәбәп дип аңларга кирәк дигән нәтиҗәгә килә. Алар нәсел башлыгыалланы яки ыруг башлыгын тасвирламыйлар, алар «чын»ның шактый дәрәҗәдә, хәзергечә әйткәндә, матди нигезен эзлиләр. Аларны берсе — суда, икенчесе утта күрә. Демокрит хәтта бар нәрсәнең нигезе — ниндидер бүленми торган нәрсәләр — атомнар дигән идея дә тәкъдим итә. Ләкин безнең өчен әлеге конкрет, ихтимал, бүген беркатлы булып күренгән тәгълиматлар түгел, ә дөньяга карашның кискен үзгәрүе мөһим: безнең

хисләребез буталчыклыгы астында яшеренгән бердәм тәртипне аңлап була; әйбер-вакыйгалар элемтәсен эзләргә кирәк. Моның өчен Гераклит «логос» дип атаган акыллылык кирәк. Борынгы Грециядә туып килә торган философиянең Көнчыгышның фәлсәфи фикереннән аермасы әнә шул акыл белән аңлый алуга мөрәҗәгать итүдә һәм ышанычта чагыла да инде.

Борынгы грек философиясе фәлсәфи фикер тарихында якты эз калдыра. Аның күп вәкилләренең карашлары җентекләп өйрәнүгә лаек. Иң зур фикер ияләре — Платон һәм Аристотельнең җәмгыятькә һәм дәүләткә карата булган фикерләрен тикшерик.

Платон (б.э.к. 427–347 еллар) камил (идеаль) шәһәр-дәүләт турында уйлана. Андый дәүләттә хакимият идеяләр белеменә ия булган, шунлыктан саф күңелле аз санлы кешеләр кулында булырга тиеш. Платон аларны философлар («экспертлар») дип атый. Иң яхшыларын сайлап алырга Платон тәкъдим иткән белем бирү системасы ярдәм итәргә тиеш була. 10–20 яшь арасында барлык балалар бер үк төрле белем ала. Бу этапта мөһим предметлар булып гимнастика, музыка һәм дин санала. 20 яшьтән иң яхшылары сайлап алына, алар укуларын математикага аеруча игътибар итеп дәвам иттерәләр. 10 ел укыгач — тагын сайлап алу. «Яхшылардан яхшылар» тагын 5 ел философия укыйлар, аннары, идарә итү күнекмәләре алып, 15 ел җәмгыять эшендә актив катнашалар. Шуннан соң бик тә җентекләп сайлап алынган һәм яхшы әзерләнгән элита дәүләт белән идарә итүне үз кулына ала.

Беренче этапта сайланганнан калганнар сәүдәгәр, һөнәрче, җирдә эшләүчеләр була. Аларның төп яхшы күңеллелеге — урталыкны тоту. Икенче сайлауны үтә алмаганнар — булачак идарәчеләр һәм сугышчылар (сакчылар), аларның төп өстенлекләре — батырлык. Шул рәвешле, белем бирүнең яңа системасы нәтиҗәсендә дәүләтнең нигезен тәшкил итүче өч социаль сыйныф барлыкка килә. Һәм аларның һәрберсе, сәләтенчә, үз дәүләтенә файдалы булу хәлендә кала.

Платон күзаллаганча, берәү күбәүгә тулысынча буйсынырга тиеш: дәүләт кеше хакына яшәми, ә кеше дәүләтнең чәчәк атуы өчен яши. Шунлыктан Платон хосусый милеккә һәм югары сыйныф вәкилләрендә гаиләне саклауга каршы була — бүгенге тел белән әйткәндә, әлеге иҗтимагый институтлар хосусый мәнфәгатьләр тудырырлар һәм кешеләрне гомуми яхшы яшәү турында кайгыртудан читкә этәрерләр иде. (Шунысын әйтик, соңга таба философ бу мәсьәләдәге карашларын бераз йомшарта төшә.)

Платонның шәкерте *Аристотель* (б.э.к. 384–322 еллар) борынгы заманның даһи философы һәм галиме була. Ул күплә-

гән фәннәргә, шул исәптән җәмгыять турындагы фәнгә дә, нигез салучы булып исәпләнә. Платон идеяләрен үстерә барып, Аристотель дәүләт белән бергә бергәлекнең тагын ике төрен — гаиләне һәм торулыкны (поселение) аерып күрсәтә, әмма дәүләтне барысыннан да өстен куя. Аристотель хосусый милекне инкарь итми һәм җәмгыятьнең урта катлаулары дәүләтнең терәге булырга тиеш дип саный. Үтә дә ярлыларны ул икенче категория гражданнарга кертә, бик байларның байлык туплауда «гайре табигый ысуллар» куллануына ишарә ясый.

Аристотель идеаль дәүләт моделе төземи. Ул реаль сәяси тормышны анализлау нигезендә аны төзүнең яхшы формаларын табарга тырыша. Философ 158 грек полисы тасвирламасын җыю белән җитәкчелек итә һәм билгеле бер критерийлар буенча әлеге материалга анализ үткәрә. Нәтиҗәдә ул «идарә итүнең мөмкин булган иң яхшы формасы — уртача демократия» дигән фикергә килә.

Философ дәүләтнең төп бурычларына аерым шәхесләрнең сәяси хакимияте артык үсүгә юл куймауны, гражданнарның мөлкәтне артык күп туплавына чик куюны кертә. Платон кебек үк, Аристотель дә колларны дәүләт гражданнары дип тапмый, үз-үзләрен тотышлары өчен җавап бирә алмаган кешеләр үзләрендә күпләгән яхшылыклар тәрбияли алмыйлар, алар табигатьләре буенча — коллар һәм фәкать башкалар ихтыярына гына буйсына алалар дип исәпли.

Тулаем алганда, борынгы грек фикер ияләре дәүләт мәнфәгатьләренең шәхес ихтыяҗларыннан өстен булырга тиешлеге идеясен яклыйлар.

Төп төшенчәләр: миф, мифологик аң, даосизм, буддизм, конфуциантлык.

Терминнар: веда, реинкарнация, йога, дао, логос.

Үзегезне тикшерегез

1. Борынгы кешеләрнең мифологик аңының үзенчәлекләре нинди? 2. Борынгы һинд философиясендә булган реинкарнация идеясе нәрсәне аңлаткан? Борынгы философлар фикеренчә, начар карманы нәрсәләр белән бетереп булган? 3. Будда нинди «игелекле хакыйкатьләр» игълан иткән? 4. Буддизмны ни өчен «атеистик дин» дип атаганнар? 5. Даосизмның читтән күзәтүе нәрсәдә чагыла? 6. Конфуциантлык социаль тормышның нинди нормаларын раслаган? 7. Платонның «идеаль дәүләт»енең төп сыйфатларын тасвирлагыз. Аны Конфуцийның «дөрес хөкүмәт»енең үзенчәлекләре белән чагыштырыгыз. 8. Платон җәмгыять үсешендә мәгарифкә нинди роль биргән? 9. Аристотель җәмгыятьнең кайсы катлауларына ныклылык һәм тотрык-

лылыкны тәэмин итүче социаль көчләр ролен биргән һәм ни өчен? 10. Платон һәм Аристотельнең җәмгыятькә, дәүләткә карашларын чагыштырыгыз. Уртаклыкны һәм аермаларны күрсәтегез.

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Түбәндә китерелгән характеристикаларның кайсысын мифологик аң чагылышына кертеп була?

Барлык очракларны аерым вакыйгалар итеп карау; реаль фактларга логик анализ; барлык чын нәрсәләргә кеше сыйфатлары бирү; абстракт фикерне аллегория һәм гыйбрәтле хикәя «киеменә» киендерү; дөньяны яхшы һәм яман көчләрнең драматик капма-каршы торуы дип аңлау; чынбарлыкны күренгәнчәгә һәм чынга аеру.

2. Үзегез сайлаганга аңлатма бирегез.

Немец философы Ницше «буддизмның идеалы кешене яхшыдан һәм яманнан аерудан гыйбарәт» дип исәпли. Философ монда әлеге җәмгыятьнең уңай якларын күрә. Буддизмның шушы параграфта китерелгән тасвирламасына таянып, Ницшеның әлеге фикерләвенә үз мөнәсәбәтегезне белдерегез.

3. Сез буддизмның асылына карата мондый карашны уртаклашасызмы? Үз карашыгызны дәлилләгез.

«Бәхетсезлек килде — кеше аны үзе тудырды, бәхет килде — кеше аны үзе үстерде. Бәхетсезлекнең һәм бәхетнең эшеге бер»,— дип өйрәтә Конфуций. Мондый раслау белән килешәсезме? Сезнеңчә, кеше тормышына тышкы хәлләр ничек йогынты ясый?

4. Сезнеңчә, безнең заманда борынгы көнчыгыш философиясе белән кызыксыну артуының сәбәпләре нидә?

Чыганак белән эшләгез

Узган гасырның 80 нче елларында нәшер ителгән «Дөнья халыклары мифлары» дигән китаптан өзекне укыгыз.

Миф, әкият, хикәят

Миф белән әкиятне аерганда бүгенге фольклорчылар, миф әкиятнең элгәресе булып тора, әкияттә миф белән чагыштырганда... бәян ителә торган фантастик вакыйгаларның чынлыгына, аңлы уйлап чыгаруның үсешенә катгый ышану кими (миф иҗат итү аңсыз-әдәби характерда була) һ.б., дип билгеләп үтәләр. Мифны тарихи хикәятләрдән, риваятьләрдән аеру ул шактый дәрәҗәдә шартлы булган саен күбрәк каршылыклы фикерләр тудыра. Шәһәрләргә (Фив, Рим, Киев һ.б.) нигез салыну, сугышлар, күренекле тарихи эшлеклеләр һ.б. турындагы

хикәятләр шундыйлардан. Әмма бу билге мифны һәм тарихи хикәятне аеру өчен һәрвакытта да җитәрлек түгел. Моңа ачык мисал — күпләгән борынгы грек мифлары. Билгеле булганча, аларның составына шәһәрләргә нигез салу турындагы, Троян сугышы, аргонавтларның яулары һәм башка зур вакыйгалар турындагы, еш кына поэтик яки драматик форма алган төрле хикәяләүләр керә. Әлеге хикәятләрнең күбесе археологик һәм башка мәгълүматлар белән расланган (мәсәлән, Трояндагы, Микендагы казынулар һ.б.) чын тарихи фактларга таяна. Ләкин әлеге хикәятләр (ягъни тарихи риваятьләр һәм мифлар) арасында чик уздыру бик читен, җитмәсә, бер карашка тарихи булган хикәятләргә аллаларның һәм башка фантастик җан ияләренең мифологик образлары кертелгән.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Әкият мифтан нәрсәсе белән аерыла? 2. Тарихи риваятьләрне мифның бер төренә кертеп буламы? Үз нәтиҗәләрегезне дәлилләгез.

Бу хакта бәхәсләшәләр

Т.П.Григорьеваның «Дао һәм логос» китабыннан һәм «Философиягә кереш» уку әсбабыннан (И.Т.Фролов редакциясендә) өзекләр белән танышыгыз.

Көнчыгыш философиясе: яшерен белемме яки традиционализммы?

Греклар «яшерен»не ачык иттеләр, Көнчыгыштан килгән белем аларда саклану тудырмады... Бер яктан, алар серләрен ачтылар, аларның үтә кыю даһилыгы белән яңартылган белем кешелек дөньясын җимешләндерде. Әмма белем, аны дөрес кабул итәргә сәләтле булса, кешене күтәрергә, әгәр аның әхлакый үсешеннән узып китсә һәм әгәр кешенең рухы каһиннар укымышсызлардан яшергән кануннарның изге мәгънәсен аңларга сәләтсез булса, кешегә зыян китерергә мөмкин... Греклар исә борынгы акылны кабул итәргә әхлакый өлгермәгән булалар.

...Борынгы Азия җәмгыятенең социаль яшәеш үзенчәлекләре үлчәү тәлинкәләрендә «шәхеснең алга таба үсеше өчен уңайсыз» булган якка тартмый кала алмаган. Бу, үз чиратында, гасырлар дәвамында традицион фикерләү структураларының йомык киңлегендә калып, аларга күбрәк аңлатмалар бирү белән мәшгуль булган (Көнчыгыш. — *А.Л.*) фәлсәфи фикер үсеше язмышын да билгеләгән.

Нишләп соң Көнчыгышта ... Яңарыш, Мәгърифәт һәм Реформация булмаган, нишләп рационализм традицияләре үсмәгән?.. Безгә Көнчыгыш биргән һәм галимнәр аларга җавап бирергә тиешле сорауларның бер өлеше әнә шулар.

§ 3. Яңа һәм Өр-яңа заманнарда философия һәм җәмгыять белеме

Исегезгә төшерегез:

реформация йогынтысында католик чиркәвенең хәле ничек үзгәргән? Яңарыш чоры җәмгыять үсешенә нинди яңалык керткән? Социалист-утопистлар кешелек дөньясының киләчәген ничек итеп күргәннәр?

Урта гасырларга алмашка килгән чорны Яңа дип юкка гына атамаганнар. Ул үзе белән җәмгыять тормышының барлык өлкәләренә тирән үзгәрешләр алып килгән. Җәмгыятьне һәм андагы кешене яңача аңлау да формалаша башлаган. Башта ул философия агымнары кысаларында урнашкан, соңрак җәмгыять тормышының аерым якларын өйрәнүче иҗтимагый фәннәр: социология, политология, икътисад теориясе һ.б. барлыкка килгән.

Бу чорда иҗтимагый чынбарлыкны тирәнрәк аңларга ярдәм итәргә тиешле күпләгән яңа идеяләр, үзенчәлекле якын килүләр тәкъдим ителгән. Вакыт сынавын аларның барысы да үтә алмаган. Бүген дә тикшеренүчеләр җәмгыятьне бөтенлекле килеш тә, аерым конкрет чагылышларында да өйрәнүләрен дәвам иттерәләр. Шул ук вакытта караш һәм бәяләмәләрнең элекке чорларда формалашкан күптөрлелеге яши бирә.

КЕШЕ ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬ ТУРЫНДА УРТА ГАСЫР КҮЗАЛЛАУЛАРЫ КРИЗИСЫ

Тарих дәресләрендә сез Урта гасырларда европалыларның дөньяга карашының тулысынча христиан дине тарафыннан билгеләнгәнлеген белдегез. Философия дин хакыйкатьләрен расларга тиеш була, шунлыктан аны «дин тәгълиматлары хезмәтчесе» дип юкка гына атамаганнар. Шул ук вакытта христиан дине антик чорлардан килгән философия фикеренә яңа идеяләр дә кертә. Барыннан да элек кешегә караш үзгәрә. Әгәр борынгылар философиясендә ул космоста башкалар белән бергә яшәүче җан иясе булса, Урта гасырларда башкача аңлау урнаша: кеше — Алланың төп иҗаты, ул җирдәге теләсә нинди башка нәрсәләрдән бәһаләп бетергесез дәрәҗәдә кыйммәтрәк.

Борынгы греклар күзаллавынча, игелек кылу үзеннән-үзе мөһим була; христиан дине, кешенең беренче гөнаһыннан һәм аның киләчәктә котылуы идеясеннән чыгып, игелекле тормышны әлеге котылуга юл дип карый башлый. Грек-рим дөньясында таралган тарихны «циклы өзлексез хәрәкәт» дип карауга алмашка тарихның сызыклы (Хөкем көненә юнәлтелгән) характерын аңлау килә.

Урта гасырның үз фикер титаннары була. Алар рәтенә беренче чиратта «Алла Грады һәм җир Грады» турында тәгълимат булдырган *Августинны* (354–430 еллар) кертергә кирәк: җир дәүләтендә идарә итүчеләр Алла тарафыннан тәртипне саклау өчен билгеләнгән; оешма буларак, чиркәү җанны коткару өчен кирәк. Ул чорның икенче бер даһи фикер иясе *Фома Аквинский* (1225(26)–1274) Аристотель һәм христиан тәгълиматларының үзенә күрә синтезын тәкъдим итә. Үзенең акылы нәтиҗәсендә кеше әйберләр-вакыйгалардагы универсаль асыл нәрсәләрне танып-белә ала. Универсум Алла тарафыннан булдырылган; димәк, акыл һәм ышану (ачыш) аерылгысыз гармониядә яшиләр. Аристотель кебек үк, Фома кешене акыллы, рухи, социаль җан иясе итеп карый, аның өчен җәмгыятьтә яшәү — үз-үзен реальләштерү өчен кирәкле шарт. Үлгәннән соң 50 еллап үткәч, Фома Аквинский католик чиркәү тарафыннан канунлаштырыла, ә XIX гасырда аның тәгълиматлары чиркәүнең рәсми философиясе (томизм) итеп таныла.

Урта гасырлар фикерләү рәвешенә беренче һөҗүмнәрне чиркәүнең рухи абруен һич тә төшерергә уйламаган кешеләр — теология яклы францисканчылар *Р.Бэкон* (1214–1292 еллар) һәм *У.Оккам* (1285–1349) ясыйлар. Бэкон акыл һәм инануны тагын да ачыграк аеру зарурлыгы турындагы фикергә килә, бу исә котылгысыз рәвештә классик философиянең теологиядән бәйлелеген киметүгә китерә. Философ яңа белем үзләштерү Изге Язу абруена таянудан бигрәк тәҗрибә белән бәйле дип исәпли. У.Оккам Алланың чынлыгын логик чаралар белән билгеләп булмый (аерым алганда, Ф.Аквинский шуңа омтыла), аны хисси тәҗрибә аша да белеп булмый; Аллага бердәнбер юл — инану дип раслый.

Традицион күзаллауларга яңа чөйне *М. Лютер* (1483–1546) һәм аның тарафдарлары кагалар. Инану — Алла белән бердәнбер генә түгел, ә бәлки турыдан-туры элемтә. Котылуны чиркәү-йолача аңлау тәнкыйтьләнә. Тарих курсыннан сез әлеге чорда инанган кешеләрнең җанын коткаруда чиркәүнең роле турындагы карашны яңадан карауның Реформация исеме алуын беләсез.

Яңарыш чоры үзе белән грек философиясе, кеше белән кызыксыну алып килә. Рухи мәдәниятә йогынтылы юнәлешләрнең берсе **гуманизм** була. Реаль тормыш тәҗрибәсенә, аны аңлау-фикерләүгә һәм үзгәртеп коруга һаман саен күбрәк игътибар ителә. Эмпирик тикшеренүләрнең артуы тиздән фән өлкәсендә нык уңышларга китерә. Н.Коперник планеталар системасы үзәгендә Кояш булган яңа астрономик модель тәкъдим итә. Г.Галилей һәм И.Ньютон математиканы һәм

табигать белемен үстерүгә гаять зур өлеш кертәләр. Хакыйкать мәсьәләләрендә югары абруйга теология түгел, ә фән ия була.

Тагын да дөньявирак нигезләмәләрне эзләү җәмгыятьне һәм аның институтларын аңлауга юнәлтелгән философик тикшеренүләрне дә колачлый.

СӘЯСӘТ ҺӘМ ДӘҮЛӘТ: ЯҢАЧА КАРАШ

Яңарыш һәм Яңа чор философларының иҗтимагый тормышның төзелеше турындагы уйлануларының башлангыч пункты инде тулаем җәмгыять түгел, ә үзенең асылы белән эгоист аерым кеше, индивид була. Әлеге эгоизмны йөгәнләү өчен тышкы көч — дәүләт таләп ителә.

Н.Макиавелли (1469 — 1527) һәм *Т.Гоббс* (1588 — 1679) кебек фикер ияләре нәкъ шул карашлардан чыгып эш итәләр. Макиавелли үзенчә идарә итү тәгълиматы эшли. Сәясәтнең максаты итеп ул хакимияткә килүне, аны саклауны һәм тотрыклы дәүләт төзүне саный. Мөстәкыйль дәүләт законнарны һәм әхлак нормаларын үзе эшли. Шул рәвешле ул әхлактан һәм хокуктан өстен тора.

Гоббс, Макиавелли кебек үк, җәмгыять һәм дәүләт рациональ, фәнни позициядән аңланырга тиешләр дигән караштан чыгып эш итә. Ике фикер иясе дә бер фикердә: кеше табигате үзгәрешсез, ул — тарихтан тыш. Дәүләткәчә кадәр, «табигый» хәлдә «барысының да барысына каршы сугышы» барган: кешеләр һәрвакытта да җитмәүче матди уңайлыкларга мохтаҗ булган. Бары тик югары идарәчесе иҗтимагый мәнфәгатьләрдә хәтта аерым кешенең тормышы белән дә идарә итә алган көчле дәүләт кенә бу сугышларны туктату сәләтенә ия. Дәүләт ничек төзелә соң? Аңа башлангычны һәркемнең дәүләт файдасына үз ирегеннән баш тартуына нигезләнгән иҗтимагый шартнамә сала. Шартнамәгә нигезләнгән һәм көче белән якланган дәүләт — җәмгыять тормышының нигезе.

Икенче бер инглиз философы — Гоббс идеяләрен үстергән *Дж.Локк* (1632–1704) югары хакимиятнең бер кулда яки бер органда болай туплануының максатка ярашлы булмавы турындагы нәтиҗәгә килә. Локк законнар чыгару һәм башкарма хакимиятләрне аеру идеясен тәкъдим итә. Соңрак француз философы *Ш.Монтескье* (1689–1755) хакимиятнең бәйсез өченче — суд тармагын аеру зарурлыгы турында нәтиҗә ясый. Яңа чорның бик тә мөһим сәяси-хокукый фикере — хакимиятләрне аеру идеясе әнә шулай формалаша һәм әкренләп ныгып урнаша. Соңрак ул Көнбатышның күп илләрендә конституцион гәүдәләнеш таба һәм бүгенге дәүләтләрнең сәяси төзелешенең сәяси нигезе булып әверелә.

МӘГЪРИФӘТ: АКЫЛГА ҺӘМ ПРОГРЕССКА ЫШАНУ

Тарихка якты чор булып кереп калган Яңарыш дәвере тулы бер искиткеч фикер ияләре плеядасын бирә. Философ-мәгърифәтчеләр кешене югары күтәрәләр. «Барлык җан ияләреннән кеше — иң камиле»,— дип раслый француз философы *Вольтер* (1694–1778). Ул чор философлары кешеләр үзләренең табигатьләре белән яхшы күңелләләр һәм теге дөньядагы рәхәтлекләрдән бигрәк реаль җәмгыятьтә лаеклы, мул тормышта яшәргә омтылалар дип исәплиләр. Һәм бу максатка фәнгә һәм мәгърифәткә таянганда ирешергә мөмкин. Соңгысы җәмгыятьтәге хорафатларны, йомшаклыкны, түзә алмаучылыкны җиңәргә булышачак. Мәгърифәтле, укымышлы кешеләр котылгысыз рәвештә әхлаклырак булалар. Җәмгыять өчен яңа, яхшырак хәлгә күчү мөмкинлеге иҗтимагый үсешнең прогресслы характеры турында сөйли. Шулай итеп, иҗтимагый-тарихи процесска караш яңадан туктаусыз хәрәкәттән җәмгыятьнең Тәүрат тарихының төп этаплары буенча сызыклы хәрәкәте турындагы постулатка, аннары кешелек дөньясының үсеш алган җәмгыятькә эзлекле хәрәкәте турындагы тезиска кадәр үзгәрә.

Мәгърифәтчеләрнең күп идеяләрен уртаклашкан, әмма шул ук вакытта кайбер мөһим мәсьәләләр буенча үзенекен тәкъдим иткән француз философы *Ж.-Ж.Руссо* (1712–1778) карашлары турында аерым әйтергә кирәк. Мәгърифәтчеләр кебек үк, Руссо кешене табигате буенча игелекле дип саный. Ул кешеләрнең аңына һәм үз-үзләрен тотышына үтеп кергән явызлык аларның томаналыгына түгел, ә цивилизациягә бәйле: шәһәр тормышы һәм фән кешедә булган табигый нәрсәләрне бозалар дип исәпли. Шуннан инде ул тәкъдим иткән табигатькә кире кайтырга өндәү бик тә аңлашыла. Моны философның иҗтимагый тормыш нигезләрен кире кагуы дип аңларга ярамый. Киресенчә, Руссо җәмгыятьнең кешегә йогынты ясавына бик зур игътибар бирә: башкалар белән бергә яшәмәсә, кеше тел, акыл, игелек иясе кебек сыйфатлар булдыра алмас иде. Философ үз заманы җәмгыятен кешенең иң яхшы сыйфатларын басып торуда гаепли.

ИҖТИМАГЫЙ ФӘННӘРНЕҢ ФОРМАЛАШУЫ

Инде билгеләп үтелгәнчә, җәмгыятькә, табигатькә карашлар философия кысаларында формалаша. XVII гасырда табигать фәннәре мөстәкыйль статус ала. XVIII гасыр ахыры — XIX гасырда фәнни җәмгыять белеме ныклап урнаша башлый.

Асылда, икътисад теориясен фәнни нигездә беренче тапкыр үз хезмәтләрендә инглиз философы, икътисадчысы *А.Смит* (1723–1790 еллар) бәян итә. Ул хезмәтне бүлүнең җитештерү

нәтиҗәлелегенә йогынтысын тикшерә, хезмәтнең иҗтимагый байлыкның төп чыганагы булуы турындагы идеяне үстерә, аннан соң К.Маркс файдаланган бәя теориясен нигезли, базарның гомуми теориясен эшли. Аның төп идеясе: һәркем, шәхси максатын күздә тотып, иҗтимагый әһәмиятле максатларны үтәргә ярдәм итә дигән фикер була. Базар икътисадының үз-үзен көйләүче механизмын гәүдәләндерүче «базарның күренмәс кулы» дигән данлыклы образ киләчәктә нигездә базар хуҗалыгы проблемаларын яктыртучы барлык тикшеренүләргә һәм дәреслекләргә керә.

Смит икътисади чәчәк атуның төп шартларына хосусый милекчелекнең өстенлек итүен, дәүләтнең икътисадка тыкшынмавын, шәхси инициативаны үстерү өчен киртәләр булмавын кертә. Тикшеренүче җәмгыятьнең социаль структурасында ялланган эшчеләр, капиталистлар һәм эре җир хуҗалары сыйныфларын аерып күрсәтә, аларны нигездә керем чыганакларына карап бүлә: хезмәт хакы, табыш һәм рента (эшмәкәрлек эшчәнлеге белән бәйләнмәгән җирдән алынган табыш). Эшчеләр белән мал-мөлкәтле сыйныфларның мәнфәгатьләре капма-каршы булуны Смит котылгысыз хәл дип саный.

Социологиянең фән буларак барлыкка килүе О.Конт, Г.Спенсер исемнәре белән бәйле. «Социология» терминын *Конт* (1798–1857) тәкъдим итә. Ул җәмгыятьне фәнни тикшеренүне «фәлсәфи спекуляцияләр»дән аерырга омтыла, иҗтимагый тормышның реаль фактларын өйрәнергә өнди. Конт «социаль статика» (җәмгыятьнең хәле, аның төп структуралары) һәм «социаль динамика» (иҗтимагый үзгәрешләр) төшенчәләрен кертә. Үсешнең төп факторы итеп ул рухи үсешне саный, ләкин шул ук вакытта климатның тәэсирен, нинди расага карауны, халыкның үсеш темпларын һ.б. факторларны да инкарь итми.

Спенсер (1820–1903) беренче булып җәмгыятькә карата «система», «институт», «структура» төшенчәләрен куллана. Ул кешелек дөньясы үсә барган саен иҗтимагый оешмаларның катлауланы турындагы идеяне әйтә һәм нигезли. Ч.Дарвин тәгълиматлары йогынтысында булган хәлдә, Спенсер табигый сайлап алыну идеясен җәмгыятькә карата кулланырга тырышып карый. «Яшәү өчен көрәштә» интеллектуаль яктан ныграк үскән кешеләр өстенлек ала дип саный ул.

Күрәбез ки, социология үзенең үсеш башында күп яктан табигать фәннәрен, барыннан да элек биологияне кабатлый. Күп кенә, аерым алганда — «эволюция», «организм» кебек сүзләр шуннан килә; социологлар җәмгыять үсешендәге шундый ук фундаменталь законнарны, мисалга, бөтендөнья тартылу законын ачу бурычын куялар; социология үзе дә күпмедер вакыт «социаль физика» дип атала.

Социаль күренешләр үзенчәлеген тирәнрәк аңлау, иҗтимагый үсешнең фәннең алга таба үсүенә генә түгел, ә бәлки тарихның реаль барышына да йогынты ясаучы тагын да киңрәк теориясен булдыру К.Маркс өлешенә төшә.

ГАДЕЛ ҖӘМГЫЯТЬ ҺӘМ АҢА ЮЛ

Күпләгән фикер ияләре идеаль иҗтимагый төзелеш һәм дәүләт (җәмгыять белән дәүләт арасындагы аерымлыклар танылмаган чорларда) төзелеше проектларын тәкъдим итәләр. Үткән параграфта сүз Конфуцийның «дөрес дәүләт»е һәм Платонның «идеаль дәүләт»е турында барды. Тарих курсыннан сез социалистик идеянең барлыкка килүе һәм үсүе турында беләсез. Башта Т.Мор һәм Т.Кампанелла идеаль иҗтимагый төзелеш турындагы үз фикерләрен үстерәләр, аннары *А.Сен-Симон* (1760–1825) һәм *Ш.Фурье* (1772–1837) һәрберсе үзенчә җәмгыять үсешенең теләгән перспективасын сурәтлиләр. Беренчеләренең карашлары «утопик» дигән исем ала (Морның «Утопия» дигән китабы исеменнән, ул бәхетле-имин ил, «булмаган урын» дигәнне аңлата). Икенчеләренең идеяләрен марксизмга нигез салучылар «утопик социализм» дип атыйлар, чөнки, француз философлары фикеренчә, яңа җәмгыятькә юл җитештерүне, фәнне, халык мәгарифен үстерү аша ята.

Утопистлар исәпләгәнчә, социаль гармония һәм барлык гражданнарның мәнфәгатьләр уртаклыгы, иҗади иркле хезмәт һәм тигезлек хас җәмгыять социалистик җәмгыять булырга тиеш. Шулай ук сәнәгать җитештерүе һәм авыл хуҗалыгы дәүләт планлаштыруы нигезендә үсәргә тиеш дип фаразлана. Җәмгыятьнең барлык әгъзалары мәҗбүри рәвештә эшләргә, ә алар булдырган байлыклар хезмәткә карап бүленергә тиеш. Андый җәмгыять кешенең кешене изүе була алмый.

А.Сен-Симон, Ш.Фурье, Р.Оуэн үз заманы капиталистик строен хаос һәм таркаулык, үз-үзеңне генә ярату һәм комсызлык, индивидуальлек һәм эгоистлык, талаш һәм дошманлык дөньясы булганы өчен тәнкыйтьлиләр. Социалист-утопистлар пролетариатның хәлен яхшырту проектлары төзиләр, иганәчелек эше белән шөгыльләнәләр. Р.Оуэн АКШта уставы тигезлек коммунизмы принципларына нигезләнгән «Яңа гармония» берлеген оештыра. Ләкин предприятие, Оуэнның бөтен мөлкәтен диярлек йотып, таркала. Утопистлар, җәмгыятьне социалистик идеал нигезендә үзгәртеп кору өчен акча бирүләрен сорап, патшалык итүче затларга, дәүләт эшлеклеләре, танылган язучы, полковникларга мөрәҗәгать итәләр.

Җәмгыятьне үзгәртеп коруның тулырак теориясен немец фикер ияләре К.Маркс белән Ф.Энгельс эшли.

ҖӘМГЫЯТЬ ТУРЫНДА МАРКС ТӘГЪЛИМАТЫ

Тарих курсыннан сез индустриаль (капиталистик) үсеш стадиясенә кергән дәүләтләрдә тормышның барлык өлкәләрендә нинди әһәмиятле үзгәрешләр булуын беләсез. Әлеге үзгәртеп коруларга үзләренең теоретик аңлатмаларын, җәмгыятьне алга таба үстерү тенденцияләренә карата үз фаразларын *К.Маркс* (1818–1883) һәм *Ф.Энгельс* (1820–1895) бирә.

Барыннан да элек алар фәндә хакимлек иткән «җәмгыять үсешендә төп рольне кешеләрнең рухи эшчәнлеге уйный» дигән нигезләмәдән баш тарталар. Аның сизелерлек ролен таныган хәлдә, марксизмга нигез салучылар иҗтимагый тормышның һәм үсешнең төп нигезе итеп матди ихтыяҗларны канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән хезмәтне, җитештерү эшчәнлеген саныйлар. Гади генә итеп әйткәндә, фән, философия, сәясәт, дин белән шөгыльләнгәнгә кадәр кешегә ашарга, эчәргә, торaклы булырга һ.б. кирәк. Бу ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен кешеләр (җитештерүче көчләр булдырып) табигать белән үзара эш итәләр, үзара билгеле бер (җитештерү) мөнәсәбәтләренә керәләр, үзләренең объектив (аңнан бәйсез) үсеш законнары хас булган иҗтимагый яшәешләрен оештыралар. Шул рәвешле, марксизм өйрәткәнчә, иҗтимагый яшәеш иҗтимагый аңны, ягъни җәмгыять тормышының рухи ягын билгели.

Теләсә кайсы җәмгыятьнең төп җитештерүче көче – белемнәргә һәм хезмәт күнекмәләренә ия булган кешеләр. Җәмгыять булдырган җитештерү кораллары (эш әйберләре һәм кораллары) да мөһим роль уйный. Иҗтимагый мөнәсәбәтләр системасы җитештерү средстволарына милекчелек мөнәсәбәтләре белән билгеләнә. Кешенең җитештерү системасындагы роле, хезмәт продуктын бүлү һәм җитештерелгәнне сатудан алынган керемне үзләштерү аның андый милке булу-булмауга һәм аның нинди күләмдә булуына бәйле. Капитализм вакытында җитештерүче көчләргә ия булучылар (капиталистлар) эш хакы формасында товар җитештерүгә киткән хезмәтнең фәкать бер өлешен — эшче көче бәясен (эшченең һәм аның гаиләсенең нормаль тормыш эшчәнлеген булдыру өчен кирәкле товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр бәясен) генә түлиләр. Икенче өлеше — эш барышында булдырылган өстәмә кыйммәтне кире кайтаргысыз үзләштерәләр. Буржуаз җәмгыятьнең барлык гаделсезлекләренең нигезендә ятучы капиталистик изүнең асылы менә шунда дип исәпли Маркс.

Житештерүче көчләр һәм житештерү мөнәсәбәтләре икесе бергә иҗтимагый-икътисади формациянең нигезе булып торучы житештерү ысулын барлыкка китерәләр. Житештерү мөнәсәбәтләре — җәмгыятьнең өскормасын билгеләүче базис: дәүләт строе, хокукый формалар, сәяси, фәлсәфи теорияләр, әхлак күрсәтмәләре, дини карашлар. Шул ук вакытта өскорма элементлары үсештә чагыштырмача мөстәкыйльлеккә ия. Үзләренең бердәмлекләрендә һәм үзара йогынтыларында базис белән өскорма иҗтимагый-икътисади формация — җәмгыятьнең конкрет-тарихи формасын булдыралар. Аларның һәрберсе (марксизмга нигез салучылар тарафыннан) кешелек дөньясының иҗтимагый прогресс юлында хәрәкәтенең бер баскычы буларак карала. Шул рәвешле, иҗтимагый-тарихи үсешнең соңыннан күпләгән тикшеренүчеләр кулланган стадияле моделе тәкъдим ителә.

Марксизм классиклары, капитализмга алмашка яңа — җәмәгать милкенә, матди байлыкларны чын-чынлап гадел бүлүче (башта «хезмәтенә карап», аннары «ихтыяж буенча») коммунистик формация килергә тиеш дип уйлыйлар. «Коммунистик җәмгыятьнең югары фазасында, кешене изүче хезмәтне бүлүгә буйсыну беткәч; шуның белән бергә акыл һәм физик хезмәт арасындагы каршылык юкка чыккач; хезмәт фәкать яшәү өчен средство гына булудан туктагач, ә хезмәт үзе яшәешнең беренче ихтыяҗына әверелгәч; индивидларның һәръяклы үсеше белән бергә житештерүче көчләр дә үскәч һәм иҗтимагый байлыкның барлык чыганаклары тулы ташкын булып ага башлагач, — фәкать шул чакта гына буржуаз хокукның тар офыгын үтү мөмкин булачак һәм җәмгыять үзенең байрагына «Һәркемнән — сәләтенчә, һәркемгә — хаҗәтенчә!» дигән лозунгны яза алачак».

Киләчәкнең бу күренеше, әлбәттә, бик нык кызыктырырга мөмкин. Шуның белән бергә «Гомумән андый иҗтимагый төзелешнең булу мөмкинме?» дигән хаклы сорау тууы ихтимал. Күпләгән тикшеренүчеләр һәм публицистлар: «Социаль аерымлыклары һәм каршылыклары булмаган андый идеаль төзелешнең яшәргә сәләтлелеге икеле; хезмәт итү өчен тышкы стимулларга ихтыяж кичермәгән «яңа кеше»нең барлыкка килүенә өметләнү — утопик»,— дигән фикер әйтәләр. Шул ук вакытта кайбер авторлар коммунистик идея — бик тә ерак фараз, аны эшләгәндә нинди генә ысуллар кулланылса да, анда котылгысыз рәвештә утопик элементлар бар дип исәплиләр; шунлыктан иң мөһиме — андый фаразга якын киләчәкнең конкрет проекты итеп карамау.

Маркс һәм Энгельс, аннары *В. И. Ленин* да (1870–1924), социал-утопистлардан аермалы буларак, бары тик сыйнфый

каршы тору, социаль революция генә яңа стройга юл сала алалар дип исәплиләр. Алар фикеренчә, көчләү тарихи котылгысыз гына түгел, ә бәлки әхлакый яктан акланган да, чөнки пролетариат революциясе һәрвакыт хакимлек итүче сыйныфларның хезмәт ияләре өстеннән системалы төстә, гасырлар дәвамында көчләвенә җавап булып тора.

Ләкин үзгәртеп коруны җәмгыятьнең бер өлешенең икенчеләренә карата рәхимсез, репрессия чараларыннан башлап якты дөнья төзү мөмкинме соң? Мондый чаралар кулланганда максатлар үзгәрмиме? Узган гасырдагы драматик вакыйгалар, аеруча безнең илдәгеләре, бу сорауларга тулы җавап бирделәр кебек.

XX ГАСЫРНЫҢ СОЦИАЛЬ-ФӘЛСӘФИ ФИКЕРЕ

Марксистик тәгълимат XX йөзьеллыкта иң йогынтылыларының берсе була. Өстәвенә ул радикаль вариантта да,— аның яклылар аның революцион аспектына (дәүләт хакимиятен көч кулланып алу, иске дәүләт машинасын вату, пролетариат диктатурасы урнаштыру, хосусый милекне тулысынча юк итү) зур әһәмият бирәләр,— уртачыл, реформачыл рәвештә дә (Көнбатыш җәмгыятьтә урнашкан демократик институтларны сакларга тырышу, икътисадны һәм җәмгыять тормышының башка өлкәләрен әкренләп реформалау, сыйнфый көрәш җәелдерүдән баш тарту) яши. Марксизмның беренче аңлатмасын Россиянең Ленин җитәкләгән революционерлары яклый, икенче карашны Көнбатыш Европа социал-демократлары алга сөрә. Марксизмның яңа «юрама»-ларыннан тыш иҗтимагый үсешнең берничә теориясе барлыкка килә һәм яши.

Иҗтимагый фикер юнәлешләренең берсе *технократизм* була. Аның яклылар иҗтимагый үсешнең хәлиткеч факторлары — техника, җитештерү технологияләре дип ышаналар. Кеше акылы һәм кулы белән булдырылган техник цивилизация үзүсешкә, даими прогресска сәләтле. Андый җәмгыятьтә аерым урын фәнни-техник белемнәргә ия кешеләргә — технократларга бирелә. Хакимияткә килгәч, бу кешеләр социаль процесслар белән белеп идарә итүне оештыралар. Технократизм идеяләре Америка икътисадчысы Дж.Гэлбрейт хезмәтләрендә чагылдырылган.

Компьютер техникасының барлыкка килүе технократизм идеяләре белән кызыксынуның яңа дулкынын тудырды. Шуның белән бергә, бүген аны тәнкыйтьләүчеләр дә аз түгел. Шунысы да игътибарны җәлеп итә: техника һәм индустриянең ролен күпертеп күрсәтү табигатькә вәхшиләрчә мөнәсәбәт

тудырды һәм бүгенге кешелек дөньясы алдына исән калу проблемасын куйды. Шулай ук технократизм карашын яклаучылар җәмгыять тормышының рухи мәдәнияте кебек мөһим ягын бәяләп бетермиләр.

XX гасырдагы йогынтылы философик юнәлешләрнең берсе — *экзистенциализм.* Аны яклаучылар кешенең яшәү тарихилыгын аның һәрвакыт ул исәпләшергә мәҗбүр булган бер хәлдә булуында күрәләр. Шуның белән бергә, кеше аңа бирелгән вакытта конкрет хәл чикләрен үтеп чыга һәм ирекле була ала. Ирекне үз тормышының үз кагыйдәләрен таккан чикләрдән чыгучы нәрсәгә юнәлгәнлеге белән яулап алырга мөмкин. Ул Аллага (дини экзистенциалистлар) яки үзенең субъективлыгына (шартлыча әйткәндә, атеистик экзистенциализмга) юнәлгәнлек булырга мөмкин. Соңгысы яклылар (алар арасында — француз философы һәм язучысы Сартр) кеше үз-үзен «проектлаганда», үз тормышындагы хәлләргә карамастан нәрсәдер булдырганда ирекле дигән караштан торып эш итәләр. Ирек йөген күтәрү җиңел түгел. Кеше аннан баш тартырга, башкалар кебек булырга мөмкин, ләкин андый очракта ул шәхес булудан туктый.

Төп төшенчәләр: гуманлылык, хакимиятне бүлү, социалистик идеал, марксизм, технократизм, экзистенциализм.

Терминнар: социаль статика, социаль динамика.

Үзегезне тикшерегез

1. Реформация һәм XVII гасырның фәнни ачышлары кеше һәм җәмгыять турында Урта гасырлардагы күзаллауларга ничек йогынты ясаган? 2. Т.Гоббс һәм Н.Макиавеллиның дәүләткә карашларында нинди уртаклыклар һәм нинди аермалыклар бар? 3. Сезнеңчә, хакимиятне бүлү идеясе ни өчен беренче тапкыр нәкъ менә философлар тарафыннан тәкъдим ителгән? 4. Философ-мәгърифәтчеләр иҗтимагый фикер үсешенә нинди яңалык керткәннәр? 5. А.Смит икътисади тәгълиматларының төп нигезләмәләрен тасвирлагыз. 6. Социология фәненә нигез салучы дип кемне исәплиләр һәм ни өчен? 7. К.Маркс һәм Ф.Энгельс җәмгыять һәм аның үсеше турында нинди яңа идеяләр тәкъдим иткәннәр? 8. Булачак иҗтимагый төзелешкә һәм аңа күчү юлларына карата социалист-утопистларның һәм марксизмга нигез салучыларның карашларын чагыштырыгыз. Гомуми һәм аермалыклы карашларны күрсәтегез. 9. XX гасыр башында марксизмның нинди яңа «юрама»лары барлыкка килгән? 10. Технократизм идеясенең асылы нәрсәдә? 11. Философ-экзистенциалистлар «ирек» төшенчәсен ничек аңлаталар?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. «Гражданин турында» дигән хезмәтендә Гоббс җәмгыятьне сәгать белән чагыштыра. Сәгатьнең эшен тикшерергә теләгәндә без аны сүтәбез, аерым детальләрен өйрәнәбез. Сәгатьне җыйганда детальләрне бер-берсенә туры китерергә, аларның һәрберсенең вазыйфасын белгеләргә тырышабыз. Шул рәвешле бездә сәгать механизмының бербөтен буларак эшләвен аңлау формалаша. Җәмгыять белән дә шулай: аны уйда гына өлешләргә аерырга, аларның һәрберсен өйрәнергә, аларның үзара элемтәләрен һәм эшләвен күрергә кирәк. Нәтиҗәдә безгә җәмгыятьнең нәрсә икәне аңлашылачак.

Ул чакта хакимлек иткән күзәтү алымы белән чагыштырганда җәмгыятьне мондый «сүтү-җыю» алымының өстенлеге нәрсәдә? Сезнеңчә мондый алымның киләчәге нәрсәдә?

2. Маркс: «Җитештерүне үстерүнең билгеле бер баскычын, алмашуны һәм куллануны алыгыз, һәм сез билгеле бер иҗтимагый строй, билгеле бер гаилә, катлау һәм сыйныфлар оешмасы табарсыз»,— дип раслаган. «Җитештерү ысулы» һәм «иҗтимагый-икътисади формация» төшенчәсен кулланып, шул ук фикерне формалаштырыгыз. Җәмгыять тормышында икътисадның өстенлеге турындагы марксистик карашны уртаклашасызмы? Үз җавабыгызны дәлилләгез.

3. Платонның һәм Маркcның гадел (идеаль) иҗтимагый строй турындагы күзаллауларын чагыштырыгыз. Аларның карашларында һәм күзаллауларында уртаклык нәрсәдә, сизелерлек аермалар нинди?

4. Философ-экзистенциалистлар мәгърифәтчеләрдән, марксизм яклылар һәм башка юнәлешләр вәкилләреннән аермалы буларак, тарихның акыллы (прогресска юнәлдерелгән) мәгънәсен эзләүдән баш тарталар. XX гасырдагы нинди вакыйгалар үткәндәге фикер ияләренең тарихи оптимизмын шик астына куйганнар?

Чыганак белән эшләгез

1932 елда немец философы О.Шпенглер язган «Кеше һәм техника» дигән хезмәттән өзек укыгыз.

Без аска күрә торып төшәбез

Дөнья тарихы безнең заман хыялларына охшамаган. Үсемлекләр һәм хайваннар тарихы белән үлчәсәң, — планеталарның озак гомере турында сөйлисе дә юк инде, — кеше тарихы кыска. Кинәт кенә күтәрелү һәм берничә мең елдан соң төшү — Җир язмышы өчен бик үк мөһим түгел, ләкин безнең өчен, монда

һәм хәзер туганнар өчен, бу тарих фаҗигале биеклеккә һәм көчкә ия. Без, XX гасыр кешеләре, аска күрә торып төшәбез...

Бу кечкенә планетаның «мәңгелек» йолдызлар өерендәге язмышы нинди булыр, кыска гына вакыт эчендә иксез-чиксез киңлек буйлап ул кая юнәлер, монысы бөтенләй дә борчымый... Әмма безнең һәрберебез — үзенчә берни дә булмаганнар — *әйтеп бетерә алмаслык* дәрәҗәдәге кыска мизгелгә бер тормыш озынлыгындагы бу мәхшәргә ташланган. Шунлыктан ул — әлеге кечкенә дөнья, әлеге «дөнья тарихы» — безнең өчен чиксез кадерле. *Язмыш* һәркемне гомуми дөнья тарихына урнаштырмый, әмма һәркем кайсыдыр йөзьеллыкта, билгеле бер урында, халыкта, диндә, сословиедә туа. Христоска кадәр 3000 ел элек Мисыр миһманы улы булып туганбызмы без, Персия патшасы яки бүгенге сукбай булыпмы — анысын безгә сайларга *бирелмәгән*. Әлеге язмышка яки очракка буйсынырга кирәк. Ул безне нинди дер хәлләргә, тамаша кылуга, эшләр башкаруга мәҗбүр итә. Философлар лыгырдаган «үзе эчендәге кеше» юк, әмма үз вакыты, урыны, расасы кешесе бар. Ул үзен раслый яисә аңа *бирелгән* дөнья белән көрәштә җиңелә; аны чолгап алган илаһи Галәмне бу һич тә борчымый. Бу көрәш — тормышның *үзе*, нәкъ менә Ницше мәгънәсендәге хакимияткә ихтыяр кебек явыз, рәхимсез көрәш...

Сораулар һәм биремнәр. 1. Автор нинди мәңгелек фәлсәфи проблемаларга кагыла? 2. Сезнеңчә, автор позициясендә XX гасырның беренче яртысы кешесенең дөньяга карашы ничек чагыла? 3. Сез философ карашларында каршылыклар күрмисезме? Күрсәгез, аларны күрсәтегез.

§ 4. Рус фәлсәфи фикере тарихыннан

Исегезгә төшерегез:

Киев Русенда, Мәскәү дәүләтендә дини мәдәният үсешенә нәрсә хас булган? Петр реформалары йогынтысы астында җәмгыятьнең мәдәни тормышында нәрсәләр үзгәргән? Көнбатышныкылар белән славянофиллар арасында идея «субүләре» кайда яткан?

Россиянең иҗтимагый фәлсәфи фикере бай һәм үзенчәлекле. Аның Россия һәм дөнья мәдәниятенә әһәмиятле өлеш керткән зур фикер ияләре бар. Россия цивилизациясенең үзенчәлеге, җәмгыятебезнең үсеш характеры һәм юнәлешенең үзенчәлекләре турындагы мәсьәлә фикер ияләрен һәм тикшеренүчеләрне кайчак килешмәс төркемнәргә аеручы бик тә кискен мәсьәлә булып кала.

«Тарих философиясе һәм социаль философия... — рус философиясенең төп темалары менә шулар. Россиянең фикер ияләре булдырган иң әһәмиятлеләре һәм үзенчәлеклеләре шушы өлкәгә карый».

С.Л.Франк

XI–XVIII ГАСЫРЛАР РУС ФӘЛСӘФИ ФИКЕРЕ

Күпләгән тикшеренүчеләр фикеренчә, Россиядә философиянең мөстәкыйль, системалаштырылган белем өлкәсе булып формалашуы XIX гасырга туры килә. Ләкин бу алдагы чорларда фәлсәфи фикер булмаган дигәнне аңлатмый. Инде Киев Русена ук христианлык белән чиркәүнең латин һәм грек аталарының, Византия дин белгечләренең беренче тәрҗемәләре килеп ирешкән. Әлеге әсәрләргә таянып, рус руханиларының кайбер вәкилләре, рус философиясен тикшерүче Н.О.Лосский фикеренчә, «византиялеләрнең дини һәм фәлсәфи хезмәтләрен дәвам иттерергә тырышып караганнар». Аларга Киев митрополиты *Иларионны* (XI гасыр) кертергә мөмкин. «Закон һәм бәрәкәт турында сүз»дә ул дөнья тарихында борынгы чор законының бәрәкәт чорына алышынуы турындагы тәгълиматларны үстерә. Бәрәкәтне Ходайның рухи бүләге дип кабул итеп, кеше үз өстенә зур әхлакый җаваплылык алырга тиеш. Иларион Рус җирен «хакыйкать һәм бәрәкәт» тантанасының гомумдөнья процессына кертә.

Изге Русьның борынгы идеалы Мәскәү патшалыгы барлыкка килгән һәм ныгыган чорда яңа үсеш таба. Тарих курсыннан белгәнегезчә, бу Византия империясенең таркалуы белән бәйле. Халык аңында «Мәскәү дәүләте — Византиянең тарихи роле варисы ул» дигән караш урнаша. «Мәскәү — Өченче Рим» идеясе Псков монастыре игумены Филофей сүзләрендә аеруча ачык әйтелә. Бөек князь Василий III кә мөрәҗәгать итеп, Филофей болай дип яза: «Шуңа игътибар ит, тәкъва падишаһ: барлык христиан патшалыклары бер синдә килеп берләште, ике Рим җимерелде, өченчесе тора, ә дүртенчесе булмаячак».

XVIII гасыр ахырында философия әкренләп дини өйрәтүләрдән аерыла башлый. Яңа типтагы уку йортларында — Киев-Могилян академиясендә һәм Мәскәүдәге Славян-грек-латин академиясендә — мөстәкыйль философия курслары кертелә. Мәскәү академиясендә беренче укытучылар бертуган Лихудлар була. Алар чиркәү атакайлары әсәрләренә моңарчы кабул ителгәннән сирәгрәк мөрәҗәгать итәләр, аның каравы бик еш Аристотельдән, Фома Аквинскийдан өзекләр китерәләр, католизмга уңай мөнәсәбәтләрен белдерәләр. Бу исә философия сый-

ныфларын яптыру өчен сәбәп була, алар үз эшләрен бары берничә елдан гына һәм башка укытучылар белән яңартып җибәрә алалар. Ләкин Урта гасыр схоластикасын әкренләп кысрыклый баручы дөньяга киңрәк караш ташлау омтылышы саклана. Мәсәлән, академиядә укучыларны Птолемейның дөньяга карашы белән генә түгел, Коперник өйрәтүләре белән дә таныштыралар.

XVIII гасырда Россия җәмгыятендә барган сизелерлек үзгәрешләр, рухи мәдәниятне дә кертеп, аның барлык өлкәләрен колачлый. Петр I нең «галимнәр дружинасы» интеллектуаль үзәкләрнең берсе була. Аңа Ф.Прокопович, В.Н.Татищев, И.Г.Посошков, А.Д.Кантемир кебек үзенчәлекле фикер ияләре һәм зур җәмәгать эшлеклеләре керә.

Ф.Прокопович (1681–1736) үз эшчәнлеген Киев-Могилян академиясе профессоры, аннары ректоры булып башлый. 1716 да Петр I аны Мәскәүгә күчерә, ул анда югары чиркәү вазыйфалары ала, Изге Синод җитәкчесе була, үзенең төп фәлсәфи хезмәтләрен яза. Аның шактый каршылыклы фәлсәфи карашларында яңа идеяләр һәм карашлар була. Тикшеренүчеләр бу фикер иясе Россиядә беренчеләрдән философ-деист — Алла тарафыннан яратылган табигать соңрак мөстәкыйль рәвештә үсә башлый дигән тәгълиматны яклаучы була дип исәплиләр. Прокопович фикеренчә, табигатьне практик фәннәр танып-белергә тиеш, ә ул фәннәрне һәрьяклап якларга кирәк.

В.Н.Татищевның исеме (1686–1750) ватан тарихын өйрәнү белән мавыккан һәркемгә таныш. Үзенең «Иң борынгы заманнардан башлап Россия тарихы» дигән хезмәтендә ул, беренчеләрдән булып елъязмалардан һәм документлардан актив файдаланып, вакыйгаларны фактологик бәян итүдән күтәрелергә, киң йомгаклаулар ясарга омтыла. Иҗтимагый үзгәрешләрнең нигезе итеп Татищев «кеше акылы көче»н саный; бу исә, белгәнегезчә, Яңарыш чоры философларына бик тә хас. Халыклар һәм мәдәниятләр яшәешен ул аерым кеше тормышы аналогы буенча карый: кешелек дөньясы тарихын җәмгыятьнең «сабыйлык халәте» ача, аны «үсмерлек» алыштыра (нәкъ менә шул чакта язу барлыкка килә). Христианлыкны кабул иткәч, кешелек дөньясы «ирлек» чорына аяк баса. Һәм, ниһаять, үзенең уйлап табулары, «ирекле» (дин күзәтүендә булмаган) фәннәре, «файдалы китаплар» таратуы белән тулы өлгергәнлек башлана.

А.Кантемир (1708–1744) үз эшчәнлеген сатирик булып башлый. Аның фәлсәфи-сатирик шигырьләре, мәсәлләре Прокоповичның мактавына лаек була. Киң даирә мәсьәләләр арасыннан Кантемирны аеруча әхлак проблемалары борчый. «Мин үз теләгемдә ирекле һәм шуның белән Ходайга охша-

ганмын»,— дип яза ул. Шулай булгач, кеше үз гамәлләре өчен тулысынча җаваплы. Кантемир үзенчәлекле әсәрләр язып кына калмый, үзен талантлы тәрҗемәче итеп тә таныта. Ул рус теленә күпләгән антик һәм Көнбатыш Европа философлары Платон, Аристотель, Р.Декарт, Дж.Локк, Ш.Монтескье һ.б. әсәрләреннән фрагментлар тәрҗемә итә.

Петр I чорыннан соң фәлсәфи фикер *М.В.Ломоносов* (1711–1765) һәм *А.Н.Радищев* (1749–1802) кебек даһи фикер ияләре хезмәтләрендә тагын да үстерелә. Аларның карашлары һәм иҗтимагый эшчәнлекләре турындагы күп нәрсәләрне сез тарих һәм әдәбият дәресләрендә белдегез.

Йомгаклаганда шуны билгеләп үтик, Россиядә фәлсәфи фикер үсеше үзәкләренең берсе 1755 елда нигез салынган Мәскәү университеты була. Анда оста сөйләү, физика, тарих, философия кафедралары белән философия факультеты булдырыла. (Уйлагыз: ни өчен физика һәм тарих нәкъ менә философия факультетында укытылган?) Әлеге факультетка университетның барлык студентларына мәҗбүри булган башлангыч икееллык баскыч роле бирелә.

XIX ГАСЫРДА ФӘЛСӘФИ ЭЗЛӘНҮЛӘР

Инде билгеләп үтелгәнчә, философия белемнең мөстәкыйль, системалаштырылган өлкәсе сыйфатында Россиядә XIX гасырда өлгереп җитә. Философия белеменә хас булганча, анда күпләгән агымнар, юнәлешләр була. Фәлсәфи-дөньяга караш фикерләренең барлык байлыгын өстән-өстән генә дә тасвирлау мөмкинлеге булмаганлыктан, бары тик бу гасырда барлык мәгърифәтле рус акыллыларын дулкынландырган проблемага гына кагылыйк, ул — Россиянең дөньякүләм тарихи процесстагы урыны һәм роле.

Дөнья тарихында Россиянең юлы турында бүгенге көнгә кадәр туктамый торган бәхәсләр чыганагы башында билгеле бер дәрәҗәдәге ватанның иң якты фикер ияләренең берсе, данлыклы «Фәлсәфи хатлар»ның авторы *П.Я.Чаадаев* (1794–1856) тора. Хәтта бүген, йөз илле елдан артык вакыт үтсә дә, философ әйткәннәр академик рәвештә битараф кабул ителмиләр: күп нәрсәләр хисне уята, соклану яки, киресенчә, актив кабул итмәү, бәхәсләшү, кире кагу теләге тудыралар. Ә инде замандашларының Чаадаев әсәрләренә карата көчле реакциясе яхшы мәгълүм. Ачулану, аптырау хисләре, авторны җәмәгатьчелек алдында җәзага тартырга өндәү өстенлек итә. Нинди идеяләр тудырган соң шундый көчле реакцияне?

Философ тарихны гамәлгә ашыру — Алла ихтыярын гамәлгә ашыру ул дип исәпли. Анынча, Көнбатыш илләренең

мәдәни казанышлары нәкъ менә Көнбатышның Хак Тәгалә тарафыннан үз максатларын тормышка ашыру өчен сайлап алынуын дәлилли,—Чаадаевның европацентризмы, аның католизмга яратып каравы әнә шуннан.

Россиянең дөнья процессындагы урынын һәм ролен билгеләү философ иҗатында еллар үткән саен үзгәрә бара. Беренче «Фәлсәфи хатлар»да Россия артта калган, цивилизацияле дөнья читендә торучы ил итеп сурәтләнә. Философ фикеренчә, Европа белән бердәм үсеш линиясен бозучы вакыйга бөтәшеп барган Византиядән православиене кабул итү: «Бөтенләйгә үзебезне үзебезгә калдырып... Хак Тәгалә безне үзенең кеше акылына игелекле йогынты ясавына кертмәде». Соңрак язган мәкаләләрендә һәм хатларында Чаадаев Россиянең үзенең тарихи миссиясе бар дип исәпли: «Без социаль тәртиптәге проблемаларның күп өлешен чишәргә... кешелек дөньясын борчыган мөһим сорауларга җавап бирергә тиеш».

Беренче «Фәлсәфи хатлар» басылып чыккач, галиҗәнап фәрманы белән, ул акылдан язган дип игълан ителә.

Күпләгән тарихчылар XIX гасырның төп идеясе — дөньяга караш юнәлешләренең берсе булган көнбатышлылыкның башында нәкъ менә Чаадаев торган дип саныйлар. Аның төп күрсәтмәләрен *А.И.Герцен*, *К.Д.Кавелин*, *Т.Н.Грановский* һ.б. уртаклаша. Славянофиллык идеяләрен үстерүче философлар һәм язучылар даирәсе дә шактый билгеле: *А.С.Хомяков*, *И.В.Киреевский*, бертуган *Аксаковлар*.

Тарих курсыннан белгәнегезчә, славянофиллар Россиянең үзенчә яшәве, аның Көнбатыш Европадан принципиаль аерымлыгы идеясен яклыйлар; аның үсешен Көнбатыш Европа агымына теләсә нинди юнәлтүне алар чит кыйммәтләрне көчләп тагу дип бәялиләр. Көнбатышлылар, киресенчә, Россия, гәрчә тарих барышында тормышның күп кенә Азия формаларын алса да, Европа иле булып тора һәм аның киләчәге — Көнбатыш юлы белән үсү.

Күренекле рус философы *В.С.Соловьев* (1853–1900) үзенең иҗат эшчәнлеген мәгърифәтле славянофил булып башлый. Алга таба аның карашлары нык үзгәрә. Соловьев фәлсәфи тәгълиматының башлангыч төшенчәсе — бөтенбердәмлек категориясе: Җирдә барлык тереклек иясенең яшәү мәгънәсе — Аллаһы акылы белән кушылуга омтылыш. Кешелек яшәеше табигать патшалыгыннан әкренләп барысы да яңадан хаостан җыела һәм яши башлаячак Аллаһы Патшалыгына килә.

Тарихи процесска үз карашын философ инде баштагы хезмәтләрендә үк белдерә. Тарихны өч көч, өч мәдәният гәүдәләндерә: мөселман Шәрыгы, Көнбатыш цивилизациясе һәм славян дөньясы. Беренче көчнең символы — бер әфәнде һәм

күпләгән кол. Икенче көчнең чагылышы — «гомумкүләм эгоизм һәм анархия, аерым берәмлекләрнең бернинди эчке элемтәсез-нисез күплеге». Әлеге көчләр гел кара-каршы көрәшәләр (ә бер-берсен эзлекле рәвештә алыштырмыйлар). Аларның чиккә чыгуларын татулаштырырга, каршылыкларны йомшартырга өченче көч — Россия булыша. Соңга таба Соловьев Көнбатыш цивилизациясенә бәя бирү мәсьәләсендә үз карашын үзгәртә. Ул күп кенә уңай тенденцияләр күрә һәм алар Россия белән бергә уңай көчне гәүдәләндерәләр дип исәпли.

Россиядә фәлсәфи фикер традицион академик формаларда: университет курсларында, фәнни трактатларда, вакытлы матбугатта бәхәсләшүләрдә генә үсми. Яшәешнең фундаменталь мәсьәләләре турында киеренке фикер йөртүләрне, искитмәле фәлсәфи зирәклекне без рус классик әдәбияты әсәрләрендә дә табабыз. Бу яктан *Л.Н.Толстой* һәм *Ф.М.Достоевский* иҗатлары аеруча әһәмиятле. Соңгысының иҗаты турында философ Н.А.Бердяев менә ничек яза: «Ул чын философ, даһи рус философы була... Достоевскийның иҗаты фәлсәфи антропология өчен, әхлак философиясе өчен чиксез мөһим».

РОССИЯНЕҢ ЦИВИЛИЗАЦИЯЛЕ ЮЛЫ: БӘХӘСЛӘРНЕҢ ДӘВАМ ИТҮЕ

Узган гасырның беренче чиреге ватан философларының тулы бер плеядасының актив иҗади эшчәнлеге чоры була. Алар арасында — *Н.А.Бердяев* (1874–1948), *С.Н.Булгаков* (1871–1944), *П.А.Флоренский* (1882–1937), *Г.Г.Шпет* (1879–1937). Төрле философик агымнар барлыкка килә (аларның күбесе үзләренең тамырлары белән узган чорларга китә): материалистик марксистик философия, дини экзистенциализм, рус космизмы һ.б.

Күп кенә фикер ияләренең игътибар үзәгендә элеккечә үк Россиянең цивилизация ягыннан кайсы якка керүе мәсьәләсе кала бирә.

Шул агымнарның берсенә — бүгенге философлар идеяләрен безнең заманга аһәңдәш дип санаган *евразиячелеккә* тулырак тукталыйк. XX гасырның 20 нче еллар башы евразия доктринасы: Россия ул Евразия, өченче, урта материк, аерым тарихи һәм этнографик дөнья дип раслый. Көнбатышның хакимлек итү дәвере Евразиянең лидерлык итү вакыты белән алышынырга тиеш. Әлеге юнәлеш тарафдарлары мәҗүсилекне башка христиан диненә караганда потенциаль яктан православиегә якынрак тора дип саныйлар. Евразиялеләрнең Көнбатышка каршы торуында славянофиллар идеяләре йогынтысын күрергә мөмкин.

Күпләгән рус философлары яңа агымга тәнкыйть күзлегеннән карыйлар, катгый дисциплиналы һәм идея ягыннан бердәм партиянең чикләнмәгән хакимияте фикерен кабул иткән евразиялеләрнең фәлсәфи-тарихи гына түгел, сәяси позицияләрен дә кире кагалар. Көнбатышка каршы булулары евразиячеләрне славянофиллар белән якынайта, ләкин евразиячелекне тәнкыйтьләүчеләр бу охшашлыкны бары тик тышкы охшашлык кына дип исәплиләр.

Яңа идеология артка таба бер адым буларак бәяләнә: рус идеясенең чиркәү һәм бөтенгаләм тибы җәмгыятьнең билгеле бер «мәдәни тибының» өстенлеге өчен көрәш белән алыштырыла.

Н.А.Бердяев, евразиялеләрнең сәяси карашлары аларны «идеаль диктатураның үзенчәлекле утопиясе»нә алып килде, дип билгеләп үтә. Философ үзе, үзенең элгәресе В.Соловьев кебек үк, Россиянең Көнбатыш һәм Көнчыгыш арасындагы хәленнән чыгып эш итә. Ләкин Бердяев Россия җәмгыятендә төрле башлангычларның гармоник кушылмасын күрми. Киресенчә, ул Россия «Көнчыгыш һәм Көнбатыш элементларының бәрелеше һәм каршы торуы мәйданына әверелде» ди. Бу каршы тору «рус җанының полярлашуында, җәмгыятьнең рухи таркалуында (түбән сыйныфларның — традицион һәм югары катлауларның — Европа мәдәнияте), эчке сәясәтнең тирбәлүендә (реформалар чоры һәрвакыт диярлек реакция һәм торгынлык белән алышына), тышкы сәясәтнең каршылыкларында (Көнбатыш белән союздан аңа каршы торуга кадәр) чагыла. «Рус халкының тарихи язмышы бәхетсез һәм газаплы булды,— дип язды Бердяев, — һәм ул фаҗигале темпларда, өзеклекләр һәм цивилизация тибын үзгәртүләр аша үсте».

Совет чорында социаль философиядә һәм тарих фәнендә шактый догматик рәвештә марксистик формацион якын килү расланды. Дәреслекләрдә һәм фәнни басмаларда, башка илләр кебек үк, безнең җәмгыять иҗтимагый прогрессның билгеле бер баскычлары буйлап хәрәкәт итә, бер формация икенчесе — тагын да үсканрәге белән алышына дигән фикер үткәрелде. Бу позициядән торып караганда, безнең илне ниндидер башка илләр төркеменә каршы кую нигезсез, чөнки ахыр чиктә барысы да бер тарихи юлдан бара (шул ук вакытта илгә яки төбәккә хас билгеле бер үзенчәлек инкарь ителмәде). Совет тикшеренүчеләре фикеренчә, безнең дәүләтнең төп аермасы шунда ки, ул үсешнең яңа, тагын да югарырак баскычына күтәрелде (башкаларга әле күтәреләсе бар) һәм үзенең иҗади хезмәте белән бөтен кешелек дөньясына киләчәккә юл сала.

80–90 нчы еллар чигендә илебез җәмгыять белемендәге марксистик идеология монополиясен бетерү, якын килүләр һәм

бәяләүләр плюрализмын торгызу җәмгыятьнең формацион моделен тәнкыйтьләүгә һәм бердәнбер чагылышларын (бигрәк тә мәдәни-рухи өлкәдә) күбрәк анализлауны күздә тоткан цивилизацияле якын килүгә игътибарны көчәйтүгә китерде.

Россиянең цивилизация ягыннан кая каравы турында яңадан бәхәсләр башланды.

Кайбер тикшеренүчеләр, Россия бүген дә традицион кыйммәтләр өстенлек иткән илләр төркеменә кертелергә тиеш, диләр. Моны раслау өчен сәбәпләр: дәүләт хакимиятенең югары дәрәҗәдә үзәкләштерелүе; Көнбатыш илләре белән чагыштырганда икътисади үсешнең түбәнрәк булуы; шәхеснең төп хокуклары һәм ирекләренең, шул исәптән хокукый милеккә хокукларының ышанычлы гарантиясе булмау; дәүләти һәм иҗтимагый кыйммәтләрнең шәхси кыйммәтләрдән өстенлеге; өлгергән гражданлык җәмгыяте булмау.

Башкалар Россия ул — Көнбатыш (индустриаль) цивилизациясенең «куып җитеп килүче» тибы варианты дип уйлыйлар. Алар, аерым алганда, ил икътисадында сәнәгать җитештерүенең әйдәүче роленә, халыкның югары дәрәҗәдә укымышлылыгына, фән һәм фәнни белемнең җәмгыятьтәге кыйммәтенә таяналар.

Россия җәмгыятен үсешнең нинди дә булса цивилизацияле тибына якын китерү мөмкинлеген инкарь итүчеләр дә аз түгел. Бу исә алга таба үсешнең яңа, өченче юлын таләп итә.

Шагыйрь В.Я.Брюсов болай дип яза:

> Ашмас хыяллар кирәкми,
> Кирәкми матур буш сүз.
> Һаман әле баш ватабыз:
> Карт Европада кем без?

Әлеге юллар язылганнан соң күп дистә еллар үтте. Әмма без һаман шул ук мәсьәләне чишәбез.

Төп төшенчәләр: цивилизацияле якын килү, мәдәни таркалу, куып җитеп килүче тибындагы цивилизация, бербөтенлек.

Терминнар: деизм, мәдәни тип.

Үзегезне тикшерегез

1. XV–XVIII гасырлардагы рус фәлсәфи фикере нәрсәсе белән характерлы? 2. Россиянең беренче уку йортларында философия нинди урын тоткан? 3. Россиянең дөньякүләм мәдәни-тарихи процесста тоткан роленә П.Чаадаевның фәлсәфи карашларын тасвирлагыз. Аларның үзгәрүен күрсәтегез. 4. Көнбатышлылар белән славянофиллар арасындагы бәхәснең фәлсәфи мәгънәсен ачып бирегез. 5. Иҗтимагый-тарихи процессны В.Соловьев ничек итеп күргән? 6. Россиянең тарихи

үсеш юлына карата евразиячеләрнең карашларында нинди аермалык булган? 7. Россиянең дөньякүләм мәдәни-тарихи үсешендәге урынын һәм ролен Н.Бердяев ничек бәяләгән? 8. Россиянең кайсы цивилизациягә каравы мәсьәләсендә бүгенге философларның карашлары нәрсә белән характерлана?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. А.Кантемир философиядә дүрт өлешне аерып күрсәтә: телдән белдерү (логика), табигатьлелек (физика), дәвамчанлык (метафизика, өстен көчләр турындагы белем), этика (әхлаклылык).

Болай якын килүдә баштагы Яңа вакыт чоры философиясе турындагы күзаллаулар ничек чагылган? Бүгенге көн карашларыннан чыгып, әйтелгәннәрнең кайсысын философия составында калдырыр, кайсысын аңа кертмәс идегез? Ни өчен?

2. Табигатьнең фәлсәфи концепциясен төзеп, М.Ломоносов дөнья яралуның беренче кирпечләре итеп ике формада: элементларда — бик тә вак бүленмәс беренчел кисәкчәләрдә һәм корпускулаларда — элементар кисәкчекләрнең ассоциацияләрендә (кушылмаларында) яшәүче «хиссез кисәкчекләр» не саный. Шуның белән бергә галим, гәрчә элементлар һәм корпускулалар күзгә күренмәсәләр дә, алар чынлыкта яшиләр һәм аларны танып-белеп була дип басым ясап күрсәтә.

Әлеге күзаллауларны алдагы йөзьеллыкларда атом һәм молекуланы ачуны алдан әйтү дип буламы? Физика һәм химия дәресләрендә алган белемнәрегезне җәлеп итеп, үз нәтиҗәләрегезне дәлилләгез.

3. XIX гасырның танылган философлары һәм публицистлары язган ике фрагментны укыгыз.

«Европалыларның һәрберсе диярлек һәрвакыт, горур төстә үз йөрәк турысына сугып, башкаларга һәм үзенә, минем намусым чиста, мин Алла һәм кешеләр алдында гаепсез, Алладан бер генә нәрсәне — башка барча кешеләрнең дә миңа охшавын телим, дип әйтергә әзер... Рус кешесе исә, киресенчә, үзенең кимчелекләрен һәрвакыт яхшы сизә, әхлакый үсеш баскычыннан югарырак күтәрелгән саен, үзеннән күбрәкне таләп итә һәм шунлыктан үзеннән шулкадәр үк канәгатьсез була».

«Шәхси энергиябез артык үсү, йөзебезнең тимердәй ныклыгы, иреккә омтылышыбыз, үз хокукларыбызны вакланып һәм көнләшеп саклавыбыз белән мактану өчен без, күрәсең, беркайчан да сәбәп таба алмадык. Бездә аппетит авырттырганга кадәр үсә, ләкин эшләргә, аларны максат белән канәгатьләндерергә, каршылыклар белән көрәшергә, үзебезне һәм үз фикерләребезне якларга теләк тә, сәләт тә юк... Без гомергә хыялланабыз, гомергә беренче очраклы нәфесебезгә бирeләбез.

Без үз хәлебезгә, явыз язмышка, һәртөрле игелеккә һәм файдалы эшкә карата гомуми битарафлыкка һәм кул селтәүгә зарланабыз».

Авторларның кайсы юнәлеш (көнбатышлылармы, әллә славянофиллармы) яклы икәнен билгеләгез. Үз нәтиҗәләрегезне дәлилләгез.

4. Еш кына шулай да булган: хакимиятләр философиягә һәм аның белән шөгыльләнүгә дәүләтчелек һәм әхлаклылык нигезләрен какшатучы артык иркен фикер йөртү чыганагы итеп караганнар. Бу параграфта яратмаган фикер ияләрен кысу һәм җәберләүнең нинди мисаллары бар? Тарих курсыннан алган белемнәрегезгә таянып, шундый ук башка мисаллар китерегез.

5. Россиянең бүгенге философы, үткән гасырның 20 нче елларында тәкъдим ителгән әлеге идея турындагы мәсьәлә «махсус карауны, анда булган тотрыклыландыручы мөмкинлекләрне ачык аңлап, аны яңа сыйфатта яңартуны таләп итә... Гаять тә зур роль рус һәм ислам мәдәниятләре үтеп керүенә бирелергә тиеш. Шунысын әйтик, безгә «латин христианлыгы»на караганда традицион ислам белән уртак тел табу җиңелрәк»,— дип яза.

Сүз нинди идея турында бара? Сез авторның соңгы тезисы белән килешәсезме?

Чыганак белән эшләгез

Философ Н.О.Лосскийның (1870–1965) «Рус философиясе тарихы» дигән китабыннан өзек укыгыз.

Сәяси ирек һәм рухи ирек

Соборлык күп затларның Аллага һәм барлык абсолют кыйммәтләргә уртак мәхәббәте нигезендә бердәмлеге һәм ирекне кушылмасын аңлата. *Соборлык* принцибының чиркәү тормышы өчен генә түгел, ә бәлки индивидуализмны һәм универсализмны берләштерү рухында күпләгән мәсьәләләрне хәл итү өчен әһәмияте зур икәнен күрү кыен түгел. Күп кенә рус философлары *соборлык* принцибын рухи һәм иҗтимагый тормышның төрле мәсьәләләрен караганда куллана башладылар инде.

Күпләгән рус дин философлары тарихи процессның асылы турындагы мәсьәлә белән кызыксыналар. Алар позитивлык теорияләрен тәнкыйтьлиләр һәм җирдә яшәү шартларында камил иҗтимагый стройны гамәлгә ашыруның мөмкин түгеллеген әйтәләр. Теләсә нинди иҗтимагый строй бары тик өлешчә яхшыртулар гына эшли, шул ук вакытта яңа җитешсезлекләре һәм явызлыклар эшләү өчен мөмкинлекләре була. Тарихның кызганыч тәҗрибәсе күрсәткәнчә, бөтен тарихи процесс бары

тик кешелек дөньясын тарихтан *метатарихка*, ягъни Ходай Патшалыгындагы «киләчәк тормышка» күчүгә әзерләүгә генә кайтып кала. Теге патшалыкта камиллеккә ирешүнең әһәмиятле шарты — җанны һәм тәнне яңарту яки Ходай рәхмәте белән сафлану-илаһлану.

Диалектик материализм — СССРда рөхсәт ителгән бердәнбер философия... Россия коммунистик диктатурадан котылгач һәм фикер иреге алгач ук, анда, теләсә нинди цивилизацияле башка илдәге кебек, күпсанлы төрле фәлсәфи мәктәпләр барлыкка киләчәк. Рус философиясенең дин өлкәсендә генә түгел, гносеология, метафизика һәм этика өлкәләрендә дә күпләгән кыйммәтле идеяләре бар. Әлеге идеяләр белән танышу гомумкешелек мәдәнияте өчен файдалы булачак.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Философ соборлык төшенчәсен ничек аңлата? 2. Рус дин философлары ни өчен идеаль иҗтимагый строй төзү мөмкинлеген инкарь итәләр? 3. Дөнья мәдәнияте өчен рус философиясенең әһәмиятен Н.О.Лосский ничек бәяли?

§ 5–6. Социаль-гуманитар өлкәдәге эшчәнлек һәм һөнәри сайлап алу

Исегезгә төшерегез:

кешелек дөньясы тарихында хезмәтне нинди зур иҗтимагый бүлүләр булган? Хезмәт базары кайчан һәм ни өчен барлыкка килгән? Аның үзенчәлекләре нинди? Сезгә социаль-гуманитар профильдәге нинди профессияләр билгеле?

Мәктәпне тәмамларга сезнең ел ярымнан аз гына артык вакытыгыз калып бара. Күбегез инде белем алуын кайсы вузда, лицей, көллияттә дәвам иттерәчәген якынча беләә, кемдер әле икеләнә, кемдер күптән сайлаган, һәм юлның бер өлеше инде үтелгән. Ләкин аларга профильле социаль-гуманитар әзерлекнең нинди һөнәри мөмкинлекләр ачуы, киләчәктә һөнәри эшчәнлектә нинди проблемалар килеп чыгу ихтималы турында тагын бер тапкыр уйлану файдалы булыр.

ИҖТИМАГЫЙ ИХТЫЯҖЛАР ҺӘМ ПРОФЕССИЯЛӘР ДӨНЬЯСЫ

«Профессия» төшенчәсе шактый киң, һәм ул билгеле бер әзерлек таләп итүче хезмәт эшчәнлеге, мәшгульлек төрен аңлата. Тарихтан сез һөнәрләрне төрләргә бүлүгә беренче эре

иҗтимагый хезмәт бүленеше, хуҗалык эшчәнлегенең теге яки бу төрендә специальләшү башлангыч бирүен беләсез.

Цивилизациянең мең еллар яшәве дәвамында һөнәрләр даирәсе бик тә нык киңәя. Кешеләрнең даими үсеп торучы ихтыяҗлары, белемгә сусау фән һәм техниканың үсүенә китерә; бу исә, үз чиратында, яңа ихтыяҗлар, шуның белән бергә яңа профессияләр таләп итә. Социологлар исәпләвенчә, хәзерге вакытта безнең илдә 20 меңләп профессия бар. Аларның саны һаман арта тора. Яңа профессияләр барлыкка килү белән беррәттән, традицион һәм кайчак әле күптән түгел генә барлыкка килгән мәшгульлекләрнең бер өлеше юкка чыга.

Белемнәр күләменең ишәюе, хезмәт нәтиҗәләренә җәмгыятьнең таләпләре арту профессияләр эчендә эшчәнлекнең «белгечлекләр» дип аталган тагын да таррак төрләре барлыкка килүгә китерде. Мәсәлән, юрист профессиясе адвокат, прокурор, судья кебек белгечлекләрне колачлый, алар эчендә, үз чиратында, тагын да таррак специальләшү бар: гражданлык, җинаять, балигъ булмаганнар эшләре буенча адвокат, икътисади җинаятьләрне тикшерү белән шөгыльләнүче прокурорлар һ.б.

Базар икътисады шартларында хезмәт базары яши. Дефицит, ягъни ихтыяҗ туган, андый белемле, үз эшләрен яхшы белүче осталар табу шактый читен булган катлаулы профессияләрнең бәясе бик югары. Шуның белән бергә хезмәтләренә бик үк югары түләнми, ә җәмгыять аларга мохтаҗ профессияләр дә бар. Андый профессияләргә сорау һәрвакыт күп, ә бу бик мөһим, чөнки эшкә урнашу гарантияләнгән диярлек. Безнең җәмгыятьтә гуманитар профессияләргә сорау зур, әмма җитәрлек дәрәҗәдә түләнми торган профессияләр — укытучылар, китапханәче, балалар бакчалары тәрбиячеләре һ.б.

«Вазыйфаи урын» төшенчәсе «профессия» һәм хәтта «белгеч» төшенчәсеннән дә таррак. Вазыйфаи урын — кеше оешмада, учреждениедә һ.б. биләп торган хезмәт урыны. Мәсәлән, профессиясе — укытучы, белгечлеге — тарих һәм җәмгыять белеме, вазыйфаи урыны — мәктәп директоры. Хәер, бу очракта вазыйфасы «төп һәм өлкәннәр мәктәбе укытучысы» да булырга мөмкин.

Бүген социологлар Россия тормышындагы яңа күренеш — «артык белем» турында сөйлиләр. Аның төп асылы шунда: бер яктан, эшсезләрнең гомуми санында югары белемле кешеләр саны арта, ә икенче яктан, вуз тәмамлап, үз белгечлеге буенча гына да түгел, югары белем гомумән таләп ителми торган эшләрдә эшләүчеләр саны күбәя. Мәсәлән, бүген менеджер, юристлар саны җәмгыять ихтыяҗыннан ике тапкырдан күбрәк-

кә, икътисадчылар өчтән бергә кирәгеннән артык. Бу исемлектә актерлар, режиссерлар, эстрада җырчылары һ.б. бар.

ПРОФЕССИОНАЛЬ ТАЛӘПЛӘР ҺӘМ ХЕЗМӘТ БАЗАРЫНДАГЫ КӨНДӘШЛЕК

Бүгенге дөньяда белем иң мөһим социаль кыйммәтләрнең берсе булып тора. Билгеле бер шартларда ул башка иҗтимагый уңайлыкларга: социаль статуска, матди муллыкка, социаль тотрыклылыкка юл ача.

Бүген безнең илдә уку йортын тәмамлаган яшьләр, әле моннан ике дистә еллар элек булганча, гарантияле төстә эшкә урнаша алмыйлар. Яшь белгеч эшкә үзе урнашырга тиеш. Вуз тәмамлаучыларның хезмәт базарында барысының да уңышка ирешә алмавын статистика дәлилли: барлык эшсезләрнең 40% ын 30 яшькә кадәрге кешеләр тәшкил итә.

Шулай итеп, хезмәт базарында уңышлы көндәшлек итү мөмкинлеге бирүче беренче нәрсә — белемнең сыйфаты. Әлбәттә, МДУ, МДХМИ һәм тагын ике-өч дистә абруйлы уку йорты дипломы яхшы рекомендация булып тора, ләкин ул эшкә урнашу өчен тулы гарантия бирә алмый. Практик күнекмәләргә ия булу, кайбер профессияләр өчен беренче көндә эш бирүчеләр югары бәяли торган коммуникатив осталыкка һ.б. ия булу кирәк. Даими эшкә урнашыр алдыннан еш кына сынау срогы үтелә, аны үткәндә булачак белгечнең әлеге сыйфатлары булу-булмавы ачыклана.

Уңышлы рәвештә эшкә урнашу шартларының тагын берсе — кечкенә булса да эш стажы булу. Ул кешенең, гәрчә башлангыч кына булса да, теоретик әзерлеген тулыландыручы практик күнекмәләре булуны дәлилли. Шунлыктан әле уку вакытында ук эшләү кирәк. Бу — авыр, аның каравы эш стажы бара. Әгәр студент сайланган белгечлеге буенча эшләсә, профессионализм башлангычы да барлыкка килә. Практикадан башка мөмкин булмаган осталыкны чарларга һәм алынган белемнәрдәге кимчелекләрне тиз табарга мөмкин. Бу исә укуга мәгънәлерәк характер бирәчәк.

ПРОФЕССИЯ САЙЛАУ СӘБӘПЛӘРЕ

Инде билгеләп үтелгәнчә, белем һәм осталыклардан тыш, сайлап алынган профессиональ эшчәнлеккә карата билгеле бер ярату һәм сәләт тә кирәк. Әмма, статистика мәгълүматларына караганда, яшьләр еш кына үзләрендә мондый сәләтләр булу-булмауга артык игътибар итми, сайлауларының төп сәбәбе күбрәк профессиянең абруена яки танылган булуына кайтып кала.

Безнең көннәрдә профессиянең абруе массакүләм мәгълүмат чаралары, шулай ук хәзерге әдәбият, кино йогынтысында формалаша. Тикшерүләр мәгълүматлары күрсәткәнчә, адвокат, сәясәтче, икътисадчы, финансист, эстрада артисты, телевидение журналистлары, телевидениедә тапшырулар алып баручылар телевизор экраннарында еш күренәләр, кино әсәрләренең төп геройлары булалар. Мәктәпне тәмамлаучыларның өстенлек бирү шкалалары да якынча шулай төзелә. Статистика мәгълүматларына караганда, 2004 елда абруй пирамидасында беренче урында юрист профессиясе булган. Аның артыннан бизнесмен, банк хезмәткәре, тәрҗемәче урнашкан, икътисадчыга, архитектор, тышкы сәүдә хезмәткәре, журналист, сәясәтче, югары мәктәп укытучысы, язучы, гуманитар фәннәр хезмәткәрләренә өстенлек бирелгән.

Профессия сайлауда шулай ук белем алу эшчәнлегенең, вузда укыячак дәресләрнең мавыктыргыч булуы да әһәмиятле сәбәп булып тора. Һичшиксез, уку процессы белән мавыгу бик тә мөһим фактор, ул алына торган белем һәм осталыкларның сыйфатын шактый күтәрә. Шулай да, тикшеренүләр мәгълүматлары күрсәткәнчә, андый чыгарылыш студентлары үзләренең белемнәренең киләчәктә кайда кирәк булачагын һәрчакта да бик үк күз алдына китерә алмыйлар. Моның исә киләчәктә эшкә урнашуда кыенлыклар, сайлаган профессиягә карата тискәре караш тудыруы ихтимал.

Профессия сайлаганда нәрсә белән шөгыльләнәчәгеңне, булачак бурычларың даирәсен, уңай һәм тискәре яклары, ихтимал авырлыкларны мөмкин кадәр ачыграк күз алдына китерергә тырышырга кирәк. Моны эшләргә *профессиограмма* ярдәм итә; ул профессияне тасвирлый, һөнәри эшчәнлекнең үзенчәлекләре турында мәгълүмат бирә.

Тагын бер тапкыр уйлагыз: булачак һөнәри эшчәнлегегезне билгеләгәндә барысын да исәпләдегезме, аларны иҗтимагый ихтыяҗлар һәм үзегезнең мөмкинлекләрегез белән чагыштырып карагыз. Барысын да үлчәргә, кирәкле үзгәрешләр кертергә вакыт бар әле.

СОЦИАЛЬ-ГУМАНИТАР ЮНӘЛЕШЛЕ ПРОФЕССИЯЛӘР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Социаль-гуманитар сыйныфта булуыгыздан чыгып эш иткәндә, сезнең өстенлек биргән өлкәгез күпмедер дәрәҗәдә билгеләнгән дип әйтергә мөмкин, конкрет профессия сайлаганда гына ялгышмаска кирәк, ә аларның даирәсе бик киң. Сезнең

алда зур исемлек: китапханәче һәм журналист, социолог һәм мөхәррир, урта мәктәптә һәм вузларда гуманитар фәннәр укытучысы, философ, прокурор, сәнгать белгече, театр белгече, башлангыч мәктәп укытучысы, балалар бакчасы тәрбиячесе, адвокат, тикшерүче, тел белгече, сәясәт белгече, әдәбият белгече, психолог, экскурсовод, архивариус, тәрҗемәче, археолог, гуманитар белемнәрнең төрле тармакларында галим-тикшеренүче, имиджмейкер һ.б. бик күпләр. Социаль-гуманитар юнәлешле профессияләр күптөрле булсалар да, алар кайбер гомуми характеристикаларга да ия.

Әлеге профессияләр даирәсен билгеләүче «социаль» һәм «гуманитар» сүзләреннән башлыйк. Белгәнебезчә, аларның икесе дә «иҗтимагый» һәм «кешенеке, кешечә» дигәнне аңлатучы socialis һәм humanis дигән латин сүзләреннән килеп чыккан.

Шуннан чыгып, социаль-гуманитар белемнәр — кеше һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләр, кешене чолгап алган, кеше һәм җәмгыять үсешенә тегеләйме-болаймы турыдан-туры яки читләтеп йогынты ясаучы, тәэсир итүче нәрсәләр турындагы белемнәр ул дип әйтәбез.

Бу өлкәдәге һөнәри эшчәнлек шәхесләр арасындагы мөнәсәбәтләргә чыга, аның нигезендә кешеләр белән үзара тәэсир итешү ята. Яисә, галимнәр әйткәнчә, социаль-гуманитар профессияләр «кеше — кеше» системасындагы эшчәнлек белән бәйле.

Шуннан аңлашылганча, бу өлкәдәге профессионалларга кешеләр белән аралашу, алар белән характерлары һәм дәвамлылыклары төрле булган элемтәләр урнаштыру осталыклары кирәк. Профессиональ уңыш күп яктан аңа бәйле булган аралашу сәнгатенә ирешү: әңгәмәне ничек алып бару, әңгәмәдәшеңне яки аудиторияне ничек итеп үзеңә карату, бик үк ачылып китәргә яратмаган кешенең ничек итеп «телен ачтыру», күп сөйләүче кешене, аның мин-минлегенә тимичә, үпкәләтмичә генә ничек туктату, әңгәмәне ничек итеп тиешле юнәлешкә бору һ.б. турындагы белемнәргә ия булуны таләп итә. Шуның белән бергә, әгәр кеше әлеге белемнәр белән беррәттән тиешле шәхес булу сыйфатларына, мәсәлән, кеше фикеренә хөрмәт белән карау, башка берәүнең үз карашларын, үз фикерен һәм ялгышын белдерүгә хокукын тану, әдәплелек, эшчәнлек, сыгылмалылык, һәм, аңлашыла ки, түземлелек кебек сыйфатларга ия булмаса, һөнәри эшчәнлектә бу белемнәр генә ярдәм итә алмас иде.

Гуманитариянең мөһим профессиональ сыйфатларына *эмпатия*, ягъни үзеңне башка кеше урынына куеп, әңгәмәдәшеңнең яки тулы бер төркем кешеләрнең, мәсәлән, экскур-

сантларның, аудиториядәге студентларның, театр залындагы тамашачыларның ни хис итүләрен тою осталыгы да кирә. Лекторның, артист, укытучы, журналистның уңышы күп яктан социаль гамәл юнәлдерелгән кешеләрнең халәтенә үтеп керә алу сәләтенә бәйле.

Әлеге даирә профессиясенең мөһим сыйфатларыннан тагын берсе шунда, аларда иҗат элементлары, импровизацияләү, гадәти нәрсәләрдә яңа якларны ачу, барча кешегә таныш предметны, күренешне көтелмәгән ягы белән күрсәтә алу осталыгы бар. Мондый яңача күрү булмаса, ачыш ясау, мәкалә, монография, дәреслек, повесть, роман язу, дәрес үткәрү, лекция уку, рольне уйнау мөмкин түгел.

Гуманитарий әйләнә-тирә мохитнең бертөрле генә булмавын, күптөрлелеген, һәр кеше шәхесенең уникаль һәм үзенчәлекле икәнен, үзе булып калырга, башкаларга охшамаска, үз язмышына һәм дөньяны үзенчә тануга хокукы барлыгын башкаларга караганда да яхшырак белергә тиеш.

Мәктәп дәреслегендә социаль-гуманитар өлкә профессионаллары өчен кирәкле барлык осталыклар һәм шәхси сыйфатлар турында да сөйләү мөмкин түгел. Җитмәсә, һәр профессия һәм хәтта белгечлек өстәмә рәвештә үзенә тиешле үзенчәлекле осталыклар һәм шәхси сыйфатлар таләп итә. Шулай да тагын бер гомуми сыйфатны әйтергә кирәк, ул — беркайчан да туктамый торган даими уку-өйрәнү. Бу гына да түгел, гуманитар профессияләр өлкәсе катнаш өлкәләрдән дә яхшы белемнәр булуны таләп итә. Мәсәлән, психология, философия, политология буенча белемнәр булмаса, югары классль социолог булу икеле һәм, киресенчә, политологка социология һәм, аңлашыла ки, психология һәм философия белемнәре кирәк.

Булачак профессионал-гуманитарийга җәмгыять белеме бирә торган психология, политология, социология белемнәре бик мөһим, чөнки барысы бергә алар кешеләрнең һәм кешеләр җәмгыятенең күпкырлы дөньясын ачып бирәләр. Кайбер социаль-гуманитар дисциплиналарның җыелма белемнәренә ия булмый торып, бу өлкәдә профессионал булу мөмкин түгел.

Барлык гуманитар профессияләр турында да сөйләү мөмкин булмаганлыктан, җәмгыять белеменең профильле курсында ачыла торган белемнәргә нигезләнгәннәренә тукталыйк.

ПОЛИТОЛОГ ПРОФЕССИЯСЕ

Соңгы елларда политолог иң популяр профессияләрнең берсенә әверелде. Белгәнегезчә, политологиянең фән буларак ике теоретик һәм гамәли юнәлеше бар.

«Галим шундый: ул ярлылыкка көенми, дан һәм байлык өчен сөенми. Аны дөнья хакимнәре кысрыклый, дөньядагы өлкәннәр комачаулый, эш буенча башлыклар кайгыга сала алмыйлар. Менә ни өчен галим кеше дип атыйлар аны. Хәзер исә кешеләр бер-берсен берникди нигез-нисез галим дип йөртәләр».

Конфуций — Кытай философы һәм педагогы, б.э.к. якынча 551–479 еллар.

Политолог-теоретикларның тикшеренүләре даирәсе бик тә киң һәм кызыклы. Галимнәр хакимият табигатен, аның җәмгыятьтәге урынын, хакимият ресурслары чикләрен, хакимиятнең нәрсә эшли алуын һәм нәрсә эшләргә тиешлеген, җәмгыять динамикалы үссен, нәтиҗәле булсын өчен, аның вәкаләтләре кайда бетәргә тиешлеген тикшерәләр. Тикшеренү юнәлешләренең берсе — сәяси тәгълиматлар тарихы, сәясәткә, хакимият эволюциясе тарихына караш. Сәяси партияләр, сәяси лидерлык теориясен, сәяси элиталарның формалашуы һәм аларның җәмгыятьтәге вазыйфалары, лидерлык типлары һәм табигате проблемаларын эшләүче галимнәр бар. Галимнәрнең күз уңында сәяси институтларның һәм сәяси системаларның роле һәм урыны кебек мәсьәләләр дә тора; төрле сәяси процесслар да тикшерелә. Политолог-тикшеренүче китаплар, журнал, газета, электрон ММЧ (массакүләм мәгълүмат чаралары), документлар белән эшли. Үз эшчәнлегендә ул төрле фәнни алымнардан, шул исәптән җыелма фәннәрдән дә, мәсәлән, социологиядән файдалана, хәтта аерым фәнни тармак — сәяси политология аерып алына. Политологның тикшеренү арсеналы — төрле басмаларда басылып чыккан материалларны, шулай ук сәяси программаларны гына түгел, хокукый документларны, хатларны, сәясәтчеләрнең чыгышларын да колачлаган документларны чагыштырма анализлау. Нинди дә булса күренешне үсештә тикшеренү өчен тарихи якын килү кулланыла.

Теоретик политологиянең нәтиҗәләре гамәли политологиядә файдаланыла; анысы, үз чиратында, сәясәт теориясе өчен бик тә бай материал бирә. Үзара баетышу теләсә кайсы фәннең үзенчәлеге булып тора, һәм политология монда искәрмә түгел.

Гамәли политология тикшеренүләренең нәтиҗәсе төрле сәяси проектлар яисә, мәсәлән, идарә итү карарлары булырга мөмкин. Моннан тыш гамәли политология өлкәсендә эшләүче галимнәр сәяси маркетинг, сәяси консалтинг, сәяси реклама проблемалары белән дә шөгыльләнәләр.

Сәяси рекламаның нәрсә икәнен сезнең күбегез лозунглар, бик тә зур фотопанно, телевидениедәге роликлар буенча белә.

Сәяси маркетинг — билгеле бер дәрәҗәдә сәяси идеяләрне алга этәрүдә булышучы, аларны сайлаучылар өчен мавыктыргыч итүче төрле сәяси акцияләрне эшләү һәм тормышка ашыру ул.

Сәяси консалтингка, беренче чиратта, аерым алганда, җәмәгатьчелек фикерен сорашып белешү, җәмәгатьчелек белән элемтә урнаштыру кебек эшчәнлек төрләрен күздә тотучы консультация хезмәтләре керә. Ул сәяси партияләр эшчәнлегенең стратегиясен һәм массакүләм мәгълүмат чараларын, имиджмейкерларны файдалану максатларын һәм ысулларын һ.б. эшләгәндә кулланыла.

Тулаем алганда, политологның эше кызыклы, һәм аның эшчәнлек төрләре күп. Мәсәлән, сәясәтченең идея позицияләрен яклау өчен конференцияләр чакырыла, үзе һәм аның теләктәшләре белән төрле интервьюлар бастырып чыгарыла һ.б. Моннан тыш, әгәр сәясәтче йогынтылы сәяси оешмага эшләсә, аның бурычына төрле белгечләр кергән тулы бер структура оештыру бурычы да йөкләнергә мөмкин. Болар — матбугат хезмәте дә, пропаганда эшен планлаштыру, башка партияләр һәм иҗтимагый хәрәкәтләр белән элемтә урнаштыру белән шөгыльләнүче, җәмәгатьчелек фикерен өйрәнүче һәм формалаштыручы кешеләр дә, спичрайтерлар, ягъни сәяси эшлеклеләрнең чыгышларын әзерләүче төркем дә.

Политолог профессиясен сайлаган кешене тагын нәрсә көтәргә мөмкин? Политологлар сата торган продукт — хакимияткә омтылучыга яки инде хакимият структураларына кергән кешеләргә кирәкле интеллектуаль хезмәтләр. Әлеге базар шактый тар һәм ул бүгенге көнгә тулы. Шуңа күрә дә бу өлкәгә керүче һәр кеше аңа кояш астындагы урын өчен көрәшергә туры киләчәге турында уйларга тиеш. Кагыйдә буларак, әле абруй казанмаган политологлар аз мавыктыргыч һәм авыр эш башкаралар: төрле редакцияләргә чабалар, сәясәтче-көндәшләрнең сайлаучылар белән очрашуларында катнашырга тырышалар (моңа ирешү еш кына шактый читен була), төннәрен алынган мәгълүматларны эшкәртәләр, телефоннан шалтыратуларга җавап бирәләр һ.б. Ләкин аларны телевидениедән чыгыш ясарга, сәяси бәхәсләрдә катнашырга чакырмыйлар, матбугатта аларның исемнәре искә алынмый, аларга киңәш сорап мөрәҗәгать итмиләр.

Көндәшлек гамәли политология белән шөгыльләнүчеләргә генә түгел, теоретик тикшеренүләр алып баручыларга да кагыла. «Гамәлиçеләр» «теориячеләр»нең эшләнмәләре өчен хезмәтләрне сатып алучы булган сәяси партия яки конкрет сәясәтче акчасыннан түлиләр. Аңлашыла ки, сәясәтчеләрнең игътибарын барыннан да элек абруйлы галимнәр үткәргән

тикшеренүләр нәтиҗәләре кызыксындыра, ә яшь теоретикларга әле үзләренең аналитик сәләтләрен исбатларга туры киләчәк.

Шуны да истә тотарга кирәк, күп кенә политологлар билгеле бер социаль-сәяси заказга эшли. Үзләре хезмәт күрсәтәчәк теге яки бу сәяси партияне алар сайлап алмый, ә, киресенчә, политологлар хезмәтен сәяси элита сатып ала. Моның нәрсәсе начар? Эш шунда ки, мондый очракта белемнең әлеге тармагы белгеченә кайчак үзе яратып шөгыльләнгәннәрдән баш тартып торырга, үзе хөрмәт итмәгән сәясәтчегә имидж булдырырга, үзе уртаклашмаган сәяси идеяләрне үткәрергә кирәк була.

СОЦИОЛОГ ПРОФЕССИЯСЕ

Хәзерге җәмгыять тормышы бик тә үзгәреп торучан: көн саен диярлек катлаулы һәм бик үк катлаулы булмаган, локаль һәм глобаль ниндидер проблемалар чишәргә туры килә. Күп кешеләр тормышына кагыла торган карарлар дөрес-яраклы булсын өчен социологлар ярдәме кирәк.

Күпчелек кешеләр өчен социолог ул — аларны урамда туктатып яки телефоннан чылтыратып, ниндидер анкета сорауларына җавап бирүне үтенүче. Ләкин бу социологлар эшенең кечкенә һәм күренеп торган өлеше генә.

Социолог — беренче чиратта иҗтимагый тормышның төрле өлкәләре турындагы күптөрле мәгълүматны җыючы һәм эшкәртүче белгеч. Аның тикшеренүләре тулаем җәмгыять турында да, аның аерым субъектлары, мәсәлән, фирмалар, җәмәгать оешмалары, социаль төркемнәр турында да күзаллаулар бирәләр. Социологларның игътибар үзәгендә иң мөһим сорауларның берсенә җавап бирү дә тора: конкрет җәмгыятьтә кеше кем ул, аның үз-үзен тотышының иң таралган формалары нинди, сәясәттә, икътисадта, этикада аның өстенлекләре нинди, төрле социаль катлау кешеләре үзара ничек һәм нинди формада хезмәттәшлек итәләр?

Җәмәгатьчелек фикерен сорашып белешү — социологик тикшеренүләрнең иң мөһим һәм бик тә катлаулы өлешләренең берсе. Аны үткәрү бик җиңел түгел. Тикшеренү дөрес булсын өчен нинди һәм ничә кешедән сорашып белешергә икәнлеген белергә кирәк. Аңлашыла ки, Алтай краендагы авылда һәм Мәскәү өлкәсенең шәһәр тибындагы поселогында кешеләр төрле социаль-икътисади шартларда яшиләр һәм мәдәниятләре белән аерылып торалар. Мәскәүдә һәм, мәсәлән, Тверь өлкәсенең Торжок шәһәрендә яшәүчеләр дә бер-берсеннән әлеге һәм башка күпләгән нәрсәләр белән аерылалар. XX гасырның 30 нчы елларында 7 сыйныфны тәмамлаган сиксән яшьлек кеше үзенең зәвыгы, дөньяга карашы, үзенең социаль ихтыяҗлары бе-

ләп югары белемле утыз яшьлек агрономнан аерылып торачак. Димәк, кайсы төбәкләрдә, нинди торак пунктларда күпме һәм нинди кешеләрдән сорашып белешергә икәнен билгеләргә кирәк. Социологлар телендә бу «сайлап сорау» дип атала, өстәвенә аны бер тапкыр гына эшләргә ярамый, ул, аның максатларыннан чыгып, һәр социологик тикшеренү өчен эшләнә.

Анкеталар төзү дә шулай ук катлаулы, шунлыктан аны эшләү өчен белгечләр чакырыла. Аларның төп бурычы — анкетадагы сорауларга җаваплар кирәкле һәм мөһим мәгълүматны бирерлек булсын. Алынган мәгълүматлар махсус методикалар буенча эшкәртелә, анализлана, һәм ясалган нәтиҗәләр нигезендә тәкъдимнәр эшләнә.

Социологлар кайда кирәк? Безнең заманда социологик тикшеренүләргә мохтаҗ булмаган иҗтимагый эшчәнлекнең нинди дә булса өлкәсен табу кыен. Болар — туристлык бизнесы да, коммуналь хуҗалык өлкәсе дә, сәнәгать, мәгариф, мәдәният өлкәсе дә, китап нәшер итү һәм, инде әйтелгәнчә, сәясәт һ.б. да. Социологик тикшеренүләр үткәрү өчен мөлаемлылык, җиңел аралаша, кызыксына, кешене тыңлый гына түгел, ишетә белү дә кирәк.

Барлык бу әйтелгәннәр гамәли социологиягә кагыла, ләкин әле тагын социаль төркемнәр, сыйныф, катлауларның проблемалары, шәхесара һәм төркемара үзара бәйләнешләр проблемаларын тикшеренү, төрле социаль каршылыкларның табигате һ.б. белән шөгыльләнүче теоретик социология дә бар. Политологиядәге кебек үк, социологик тикшеренүләр китапларга, журнал, газета, документларга, электрон ММЧ на мөрәҗәгать итүне сорый. Теоретик һәм гамәли политология үзара хезмәттәшлек иткән кебек үк, теоретик һәм гамәли социология дә бер-берсеннән башка яши алмый.

Билгеле ки, башка һәр эшчәнлектәге кебек үк, социолог профессиясенең дә үзенең катлаулыклары һәм проблемалары бар. Җентекле, бөртекләп анализлауны яратмаган, саннардан, кем әйтмешли, күз аллары җемелдәгән кешеләргә кеше эшчәнлегенең бу өлкәсенә, һичьюгы гамәли социологиягә барырга кирәкмидер, мөгаен. Әмма кыенлыклар болар гына түгел. Бүгенге көндә абруй казанган социология үзәкләре барлыкка килде. Абруй югары дәрәҗәдәге профессионализмга һәм компромиссларга бармауга таяна, чөнки әлеге үзәкләрнең җитәкчеләре тикшеренүләр нәтиҗәләрен бозып күрсәтүгә юл куймыйлар. Андый үзәкләргә эшкә урнашу шактый катлаулы. Нәкъ менә шуның өчен дә эшкә урнашу яшь белгеч өчен проблема булып тора. Һәм ул эшне акча түләгән өчен мәгълүматларны үзгәртеп күрсәтүче социология үзәкләрендә табарга мөмкин. Шул рәвешле үзең теләп яки ирексездән кешеләрне күпләп алдауда катнашуың ихтимал.

Күп кенә хуҗалык предприятиеләре үзләренең социология хезмәтләрен булдыралар һәм моннан тыш үз социологлары булмаган предприятиеләргә хезмәт күрсәтүче үзәкләр бар. Сәясәтчеләрдән аермалы буларак, сәнәгать өлкәсе һәрвакыт объектив тикшерену белән кызыксынганлыктан, бу очракта алдашуга баруның кирәге юктыр.

Социолог эше турында сөйләшүне тәмамлап, шуны әйтергә кирәк: бүгенге Россиядә ул — чагыштырмача яңа профессия. СССРда социология зур үсеш алмады. Хәзерге вакытта социология — тиз үсүче фән, бүген бу профессия кирәк санала, һәм эшне табарга була, тик түләү генә һәрвакытта да бик үк яхшы булмаска мөмкин.

ПСИХОЛОГ ПРОФЕССИЯСЕ

Соңгы елларда бу профессиягә сорау бик зур. Психологлар үзләре моны бүгенге заман кешеләре, аеруча мегаполисларда яшәүчеләр тормышының үтә дә киеренкеләнүе һәм кеше нерв системасының андый көчле тетрәнүләр белән һәрвакытта да идарә итә алмавы белән аңлаталар. Шунлыктан психолог-профессионаллар бурычларының берсе — кешеләргә ярдәм итү, һәм моның белән гамәли психология шөгыльләнә. Бүген психологларның белемнәре һәм осталыклары барыннан да элек гадәттән тыш хәлләрдә кирәк. Ихтимал, сез «Кызыл Хач» җәмгыятендә, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы бригадаларында эшләүче психологлар турында ишеткәнсездер. Аларның бурычы — кешеләрне психологик шок халәтеннән чыгару, аларны реабилитацияләү, нормаль психик халәтләрен торгызу. Психологлар коткарылган заложникларга, табигать бәла-казалары, террорчылык актлары һ.б. вакытында көчле психологик стресс кичергән кешеләргә ярдәм итү өчен баралар. Соңгы вакытларда гадәттән тыш хәлләр еш булганлыктан, әлеге белгечләрнең белеменә һәм осталыгына мохтаҗлык даими арта тора.

Психологлар ярдәме экстремаль шартлардан башка вакытларда да кирәк. Психологлар мәктәпләрдә эшлиләр, аларның игътибар үзәгендә — башкалардан аерылыбрак торучы, мәсәлән, һәрвакыт тәртип бозучы, укуда артта калучы, классташлары белән аралашуда кыенлыклар кичерүче яки ниндидер сәбәп белән стресс хәлендә калган балалар. Саналган барлык очракларда ярдәм күрсәтү өчен мәктәп психологы комплекслы эш алып бара, ягъни конкрет укучыга гына түгел, аның ата-анасына, укытучыларга да йогынты ясый. Ул килеп чыккан проблемаларга китерүе сәбәпләрне ачыклый, анда катнашучыларның барысы өчен дә кирәкле үз-үзләрен тоту линиясен эшли, алар белән әңгәмәләр үткәрә, реабилитация программасы эшли һ.б.

Ихтимал, сезнең теләсә кайсы кеше, әгәр ул катлаулы психологик хәлдә калса,— якыннарын югалтканнан соң тетрәнү, гаилә проблемалары, эштәге четерекләкләр, һәрвакыт борчып торучы үзеңә ышанмау һ.б., — психология хезмәтенә мөрәҗәгать итә алуы турында ишеткәнегез бардыр. Соңгы елларда мондый хезмәтләрнең саны һаман арта бара.

Медицина учреждениеләрендә, төрмә, хоспис, суд-экспертиза учреждениеләрендә һ.б. теге яки бу халәтнең эчке сәбәпләрен белү, аларны дөрес бәяләү бик тә мөһим.

Социаль психологлар эше коллективның тотрыклы һәм җитештерүчән эшләве белән кызыксынган фирма һәм предприятиеләргә дә кирәк. Мондый очракларда социаль психологларның бурычы конфликтлы хәлләрнең барлыкка килүенә юл куймаудан гыйбарәт; моны эшләп булмаса, аларның хезмәте конфликтны үз вакытында бетерү өчен кирәк. Шунлыктан социаль психологларны еш кына катлаулы, конфликтлы хәлләргә китерүче карарлар кабул ителә торган киңәшмәләргә чакыралар. Предприятиенең психология хезмәте җитештерү күрсәткечләренә уңай йогынты ясаган күп очраклар билгеле. Мәсәлән, Канаданың бер фирмасында эшчеләрнең хезмәт җитештерүчәнлеге нык кими башлый. Психологларны чакыралар. Алары, тикшерүләр үткәреп, ремонт вакытында цех стеналарының кызгылт сары һәм сары төсләргә буялуын, моның исә эмоциональ ярсыну тудыруын һәм, үз чиратында, тиз арытуын ачыклаганнар. Психологларның кисәтүләрен һәм киңәшләрен тыңлап, предприятие җитәкчеләре стеналарны яшькелтрәк төскә буятканнар, һәм проблема хәл ителгән.

Аңлашыла ки, теоретик психология тикшеренүләреннән башка гына гамәли психология өлкәсендә эш барып чыкмас иде. XX гасырның беренче яртысында Россиянең психология фәне дөнья фәненә бик тә зур өлеш кертте. Л.Выготский, С.Рубинштейн, Л.Лурия, П.Гальперин, А.Леонтьев һ.б. бик күпләрнең эшләре теоретик һәм, нәтиҗә буларак, гамәли психологияне баеттылар.

Кеше белән бәйле проблемаларны тикшерүче башка фәнни өлкәләрдәге кебек үк, теоретик психологиядә тикшеренүләрнең төп ысулларын анкета, тест үткәрү, интервью алу, күзәтү, психологик әдәбиятны өйрәнү һ.б. тәшкил итә. Табигый ки, барлык бу ысуллар башка фәннәрдә кулланыла торган охшаш ысуллардан аерыла. Мәсәлән, психология анкеталары социологиядәгеләргә охшамаган.

Бүген галим-психологларның теоретик эзләнүләре өлкәсе бик тә киң: һәм социаль, һәм шәхесләр арасындагы конфликтларның табигате, кешенең интеллектуаль эшчәнлеге, үз-үзен тотышындагы тайпылышлар, мотивлаштыру өлкәсе, кеше-

ләрнең гадәттән тыш хәлләрдә үз-үзләрен тотышы, үз бәяңне арттыру яки киметү сәбәпләрен тикшерену һ.б. Безнең көннәрдә теоретик психология еш кына политология, социология белән тыгыз элемтәдә эшли. Башка фәннәр кебек үк, гамәли һәм теоретик психология өлкәләре кисешеп кенә калмыйлар, ә бәлки бер-берсенең үсүенә булышалар да.

Психолог эшенең катлаулылыгы күп яктан социаль-гуманитар өлкәләрдәге башка профессионалларда барлыкка килүче катлаулыкларга туры килә. Мәсәлән, теоретик психологларда тикшерену базасын табу һәрвакытта да бик үк җиңел түгел: кайчак учреждениеләр галимнәрнең аларда эшләүче хезмәткәрләр белән сынау яки анкета үткәрү үтенечен кире кагалар, еш кына мондый ярдәмнән мәктәпләр, медицина учреждениеләре һ.б. да баш тарта. Лаборатория тикшеренүләре өчен үзләре теләк белдерүчеләрне табу кыен, еш кына мондый эшкә әлеге белгечлеккә укучы студентлар алына, ләкин мондый эксперимент фән күзлегеннән караганда һәрвакытта да бик үк «чиста» булмый.

Әлеге профиль белгечләренә ихтыяҗ туктаусыз артуга карамастан, кызыклы һәм яхшы түләнелә торган эш табу бик үк җиңел түгел. Күп кенә эре фирмалар психология хезмәтен кирәк дип санамыйлар. Мәгариф, медицина учреждениеләрендә психологлар эшенә ихтыяҗ зур. Белгечкә аларда эшләү кызыклы, ләкин хезмәт хакы шактый түбән.

УКЫТУЧЫ ПРОФЕССИЯСЕ

Гуманитар профессия вәкилләре фәнни яки практик эшчәнлекләрен еш кына югары яки урта уку йортында укытучылык эше белән беррәттән алып баралар. Шулай да була: философ, социолог яки политолог дипломы алганнан соң, кеше үз урынын урта мәктәптә җәмгыять белемен укытуда таба. Югары мәктәп укытучысы профессиясе вуз тәмамлаганнарның бер өлешен кызыксындыра, ә урта мәктәп укытучысы профессиясенә күпләр, кызганыч, запас вариант итеп кенә карый. Социологик тикшеренүләр мәгълүматларына караганда, урта мәктәп укытучысы профессиясе үзенең мавыктыручанлыгы буенча 27 нче урында һәм официант, тегүче һәм шахтер профессияләре белән янәшә тора. Һәм бу — күп йөзьеллыклар дәвамында укытучы профессиясенең дөньяда иң тыныч һәм гуманлы профессия булып саналуына карамастан.

Укытучы профессиясе — иң борынгыларның берсе. «Педагог» сүзе борынгы грекларда барлыкка килгән һәм сүзгә-сүз тәрҗемәдә «тәрбияче» дигәнне аңлата.

Урта мәктәп һәм югары, һәм урта махсус уку йортлары укытучылары профессиональ эшчәнлегендә уртаклыклар күп. Җәмәгатьчелек фикерендә иҗатны күбрәк артист, рәссам, язучы һөнәрләре белән бәйләүгә карамастан, укытучы эше дә иҗат эше булып санала. Аның иҗаты — бер үк вакытта актер, театр режиссеры, сценарист иҗаты да. Өстәвенә әле укытучы, бигрәк тә мәктәп укытучысы — психолог, җитмәсә, универсаль психолог: аңа укучыны, ата-аналарны белергә, тоярга, аңларга кирәк. Моннан тыш дәресне, вуз лекциясен әзерләнгәндә укытыла торган белемне кабул итү, уку материалын үзләштерү психологиясен белергә кирәк.

Сүз дә юк, мәктәп һәм вуз укытучысы арасында аерма бар. Бу аерма шуңа бәйле: аларның һәрберсе төрле яшьтәге кешеләр белән эшли. Мәктәптә укыту этабы — интенсив үсү, шәхеснең формалашуы чоры. Укытучы бу процесска булыша: уйларга һәм уку материалын аңларга өйрәтә, укучыларда заман мәдәниятенә туры килә торган фикерләү ысулларын формалаштыра. Ләкин бу процесста укучыларга бирелә торган сораулар һәм биремнәр аларның физик яктан үсә баруларына туры килергә генә түгел, ә бәлки аларның аң-белемнәре үсүгә дә тәңгәл килергә тиеш. Моннан тыш мәктәп укырга, язарга, планнар төзергә, конспектлар язарга, сүзнең нәрсә турында баруын аңларга, әдәбиятта ориентлашырга өйрәтә, фәнни белем нигезләре бирә һ.б. Шунлыктан дәрескә әзерләнгәндә укытучы дәреслек һәм фәнни әдәбиятны гына укып калмый, аның әзерлек арсеналына тагын мәҗбүри тәртиптә методик әдәбият та керә. Аның ярдәмендә ул дәреснең булачак вариантын эшли: максатын, сорауларны, биремнәрне төзи, укучылар очратуы ихтимал булган каршылыкларны күздә тота, алынган белемнәр мәгънәләр белән тулылансын һәм дөнья үзенең барлык гаҗәеп кабатланмаслыгы белән күз алдына килеп бассын өчен, иң төп нәрсәне ничегрәк итеп җиткерү турында уйлана.

1940 елда укытучының хезмәт хакы сәнәгатьтәге уртача хезмәт хакының 97% ын тәшкил иткән; 1970 тә ул — 72%, 1980 дә — 73%, 1990 да — 65%, 2001 дә 43,7% булган.

Югары уку йортына кеше инде мөстәкыйль рәвештә белем алырга әзерләнгән хәлдә килә; шунлыктан вуз укытучылары, мәктәп укытучыларыннан аермалы буларак, яңа материалны аңлатмыйлар, ә лекция укыйлар. Аларның эшчәнлек үзенчәлекләре белем нигезләрен бирү белән түгел, ә фән дөньясына алып керү белән бәйле. Вуз укытучысы да лекциясенә әзерләнә, ләкин бу әзерләнү мәктәп укытучысы әзерләнгәннән аерыла:

аңа студентларны фән ирешкән дөньяга, фәнни эзләнүләр дөньясына чумдырырга, хәл ителмәгән проблемалар белән таныштырырга кирәк. Шунлыктан ул китапханәдә утыра, соңгы тикшеренүләр турында белә, монографияләр, мәкаләләр җыентыклары, журналлар укый, үзенең фәнни дисциплинасы буенча төрле карашларны чагыштыра һ.б.

Студентлар белән семинарлар да мәктәп дәресләреннән аерыла. Аларның бурычы — аңлашылмаган нәрсәләрдә студентларга ярдәм итү. Шул ук дәресләрдә булачак профессия белән дә практик танышалар; мәсәлән, педагогика вузлары студентлары үзләренең дәрес бирүләрен күз алларына китерәләр, педагоглык осталыгы башлангычлары белән танышу максатында уеннар үткәрәләр. Семинарларда студентлар тикшеренү элементларына өйрәнәләр, курсташларын үзләренең фәнни эзләнүләре нәтиҗәләре белән таныштыралар.

Шулай итеп, семинар — лекциядәге катлаулырак мәсьәләләрне чишү дә, докладлар һәм рефератлар белән чыгыш ясау да, практик эшчәнлек тә. Шунлыктан семинар дәресләре — студентларның мөстәкыйль эшчәнлеге ул.

Мәктәп һәм вуз укытучысы профессиясе — кирәкле профессия, бүгенге көндә алар арасында эшсезләр юк. Ләкин, бу хезмәт шатлык һәм канәгатьлек алып килүгә карамастан, ул күпләгән катлаулыклар белән бәйле (хезмәтнең әһәмиятлеге белән һич тә чагыштырмаслык түбән эш хакы, өстәвенә, эшчәнлегенең зарури шарты булган гыйльми дәрәҗәсенә карамастан, вуз укытучысының эш хакы мәктәп укытучысыныкыннан күпкә югары түгел; өстәвенә эш көне дәрес яки лекция белән генә тәмамланмый: мәктәп укытучысында ул соңрак та дәвам итә, кайчак хәтта буш вакытында да гаиләсен калдырып, шәхси проблемаларын читкә ташлап, укучылары белән экскурсиягә, театрга, мәктәп кичәсенә китә; әле тагын сыйныф сәгате, көндәлекләрне тикшерү, классны җыештыру, ата-аналар җыелышлары һәм педагогик советлар һ.б. Һәм һәрвакыт әдәплелек, түземлек, белем, аңлый белү кирәк).

СОЦИАЛЬ ПЕДАГОГ ПРОФЕССИЯСЕ

Социаль педагог профессиясе елдан-ел кирәгрәк була бара, бу исә җәмгыятьнең үсә баручы буын язмышы өчен җаваплылыгы арта баруын, илнең киләчәге — яшьләрнең культурасы, тәрбиялелеге дәрәҗәсенә бәйле булуын реаль аңлавы күрсәткече булып тора.

Социаль педагогларның бурычлары даирәсе шактый киң; алар гаиләгә һәм балаларга ярдәм итү үзәкләре, социаль хезмәт

күрсәтү үзәкләре, опека һәм попечительлек органнары, балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе һәм, аңлашыла ки, балалар йортлары, балалар интернатлары кебек төрле социаль хезмәтләрдә эшлиләр. Аларның бурычына катлаулы хәлләрдә калган балаларны социаль яклауны гамәлгә ашыру керә, шунлыктан социаль педагогның игътибары өлкәсенә гаиләләрдә яшәүче балаларның да, балалар йортларында, приют, интернатта яшәүче балаларның да эләгүе ихтимал.

Эш урыннары төрле булса да, социаль педагогларның эшчәнлекләре охшаш. Барлык очракларда да балага квалификацияле ярдәм күрсәтү өчен аның тәртибе бозылу сәбәпләрен ачыклауга юнәлдерелгән чараларның тулы бер комплексын булдырырга кирәк; ә тәртип бозылуның сәбәпләре төрле, мәсәлән, гаиләдәге хәлләрнең начараюы, нәселдән килгән авырулар, психологик җәрәхәтләр һ.б. булырга мөмкин. Шуңа күрә балага ярдәм күрсәтү аның шәхесенең медико-психологик үзенчәлекләрен өйрәнүдән башлана. Мондый өйрәнү вакытында социаль педагог баланың мәнфәгатьләрен һәм ихтыяҗларын, психологик, интеллектуаль, үз-үзен тотышы характерындагы кыенлыкларны китереп чыгаручы проблемаларны ачыкларга тиеш. Шәхеснең үсүе һәм ныгуы билгеле бер социаль мохиттә барганлыктан, ул да әлеге профиль белгеченең игътибар зонасында була. Баланың социаль мохитен өйрәнү дә күпьяклы; аңа тормышның матди шартлары да, аралашу гадәте, мәнфәгатьләр даирәсе, әлеге социаль төркем әгъзаларының ихтыяҗлары, каршылыклы хәлләр дә һ.б. керә. Шундый катлаулы күпьяклы тикшеренү шуның белән бәйле: социаль педагогның эшчәнлеге газап чигүче балага юнәлдерелгән, һәм аның эшендәге хатасы үзе һәм кешеләр өчен тулы канлы һәм файдалы гомер кичерергә тиеш булган шәхеснең тулысынча бозылуына, җәмгыятьнең кешене югалтуына китерүе ихтимал. Шунлыктан, тикшеренү катлаулы хәлләрдә калган балага ярдәм итү өчен социаль педагог хәл итәргә тиешле бурычларны, шулай ук психологик-педагогик эшнең формаларын һәм алымнарын, шәхси һәм социаль проблемаларны чишү ысулларын белгеләргә булыша.

Яклауга мохтаҗ балаларга күрсәтелә торган ярдәм төрле булырга мөмкин. Аңа, мәсәлән, гаиләгә матди психологик булышлык итү, шуның белән гаилә микроклиматын яхшыртуга булышу керә. Ул шулай ук оешмалар, учреждениеләр белән арадашлык эшчәнлегендә, мәктәпнең педагоглар коллективы, опека һәм попечительлек органнары, балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе белән эшләүдә, баланы нинди дә булса клубка, түгәрәккә урнаштыруда һ.б. чагыла.

Инде әйтелгәнчә, социаль педагоглар төрле учреждениеләрдә эшлиләр. Гаиләгә һәм балага ярдәм итү үзәкләренә йә ата-аналар, йә балалар үзләре еш кына үз теләкләре белән килә; ә балалар йортына яки интернатка бала күбрәк үз ихтыярыннан башка килеп эләгә. Шуңлыктан социаль педагог эшчәнлегенә, балада һәрвакыт булган индивидуальлектән тыш, ул эшләргә мәҗбүр булган шартлар үзенчәлеге дә зур йогынты ясый. Бер үк очракта үсеп килүче шәхескә ике мохит йогынты ясый. Педагог моны да, баланың аңа ят тирәлектә, димәк, стресс хәлендә калуын да истә тотарга тиеш. Баланы көн саен күзәтеп, социаль педагог еш кына төрле проблемаларны хәл итү өчен профессиональ ярдәмчегә генә түгел, ә бәлки чын дуска, үзеңне борчыган нәрсәләр белән уртаклашырдай бердәнбер кешегә әверелә.

Бала гаиләдә булуын дәвам иттергән очракларда да мохит аның үсешенә турыдан-туры йогынты ясый. Өстәвенә әлеге йогынтының, гәрчә еш кына социаль ярдәм хезмәтенә килү үз ирекләре белән булса да, тискәре булып калуы ихтимал. Шуңа күрә ярдәм оештырганда социаль педагог үз эшен бу йогынтыны исәпкә алып корырга тиеш.

Социаль педагогтан тыш социаль эш белгечләре дә бар. Әгәр баланы балалар йортына, интернатка урнаштырырга, социаль ярдәм күрсәтергә, мәсәлән, лагерьга путевка, бушлай азык-төлек җыелмасы яисә аңа приютта бушлай ашау мөмкинлеге бирергә кирәк булганда, балигъ булмаган балалар эшләре комиссияләре, мәктәпләр, опекуннар һәм попечительлек органнары, җәмәгатьчелек, шулай ук социаль педагоглар аларга мөрәҗәгать итәләр. Шул ук белгечләр балигъ булмаган тәртип бозучыларның хокукларын җәмәгатьчелек яклавын оештыралар, судья таләп иткәндә психологик-педагогик экспертиза бирәләр, судта аларның җәмәгать яклаучысы яки өченче зат сыйфатында чыгыш ясыйлар.

Социаль эш белгечләренең бурычларына шулай ук кызыксынган барлык кешеләргә социаль яклау, ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукларын чикләү буенча материаллар туплау кебек четерекле мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы мәсьәләләрдә консультацияләр бирү дә керә.

Социаль педагоглар һәм белгечләр эшенең катлаулы һәм күпкырлы булуы сыйфатлы һәм күпьяклы белем: әлеге профессия өчен кирәкле психология, педагогика, физиология, социология, юриспруденция һәм кирәкле башка төр белемнәр таләп итә. Шуның белән бергә әлеге профессиональ эшчәнлек өчен сизгерлек, итагатьлелек, эмпатия, түземлек кебек шәхси сыйфатлар да бик мөһим.

Шулай итеп, саналып үтелгән профессияләр вәкилләре галим-тикшеренүчеләр булырга, белемнең гамәли өлкәләрендә, шулай ук вуз һәм мәктәп укытучылары булып эшләргә мөмкиннәр. Өстәвенә безнең көннәрдә шулай да була: кеше бер үк вакытта өч өлкәдә эшли, бу исә аның белемнәрен һәм, нәтиҗә буларак, эшчәнлеген баета.

Социаль-гуманитар белем белән бәйле профессия алу өчен югары уку йортына керү һәрвакытта да мәҗбүри түгел, кайбер профессияләрне махсус урта белем дә тәкъдим итә. Шунлыктан төрле уку йортларына укырга керергә әзерләнүчеләр өчен белешмә сатып алырга, аларда нинди белгечләр һәм белемнәрнең нинди тармакларында әзерләүләрен, аларның кайда урнашуын, аеруча нинди уку предметлары кирәклеген карарга киңәш ителә. Кагыйдә буларак, барлык уку йортлары да язын ачык ишекләр көннәре үткәрәләр. Гәрчә сез быелгы уку елында вузга, лицей яки көллияткә керергә җыенмасагыз да, барырга һәм уку йортлары белән якыннанрак танышырга кирәк.

Якын арада сезнең алда катлаулы һәм мөһим сайлау тора; ашыкмагыз, барысының да уңай һәм тискәре якларын, шул исәптән үзегезнең сәләтегезне, мөмкинлекләрегезне уйлагыз, сайлап алуыгызның сәбәпләрен ачыклагыз. Чөнки бәхетле кеше — бай кеше түгел, ә үзен тапкан, үз намусы белән килешеп яшәгән кеше бит.

Төп төшенчәләр: социаль-гуманитар профиль профессиясе.

Үзегезне тикшерегез

1. Нәрсә ул профессия? Профессия белгечлектән нәрсәсе белән аерыла? Бу аермаларны мисалларда күрсәтегез. 2. Фәнни хезмәткәр профессиясенең «плюс»лары һәм «минус»лары нинди? 3. Укытучы профессиясе нәрсәсе белән мавыктыргыч? 4. Социолог, политолог, психологларның гамәли эшчәнлекләре характерын нәрсә берләштерә?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Әле күптән түгел генә барлыкка килгән, ләкин бик аз яшәгән профессияләрне атагыз. Аларның иртә «үлеменә» китергән сәбәпләрне ачыклагыз.

2. Җәмгыять белеме курсы белемнәренә таянып, XX гасырда профессия сайлау проблемасының актуальләшүе сәбәпләрен ачып бирегез.

3. Белем биргән иҗтимагый уңайлыкларны тасвирлагыз. Әлеге уңайлыкларның һәркемгә әһәмиятле икәнен дәлилләгез.

4. Укытучы профессиясенең мәктәпне тәмамлаучылар

биргән профессиональ өстенлекләрдә бик түбән рейтингта булуын нәрсә белән аңлата аласыз?

5. Галимнәр, белем һәм дөрес сайланган профессия кешегә социаль мобильлек бирә, дип раслыйлар. Профессия сайлап алу белән шәхси мобильлекнең үзара бәйләнешен исбатлагыз. Мобильлек мөмкинлегенең кеше өчен нинди әһәмияткә ия булуын аңлатыгыз.

6. Параграфта аз сандагы профессияләрнең генә профессиограммасы бирелгән. Журналист, психолог, телевидение тапшыруларын алып баручы, сәнгать белгече, экскурсовод, балалар бакчасы тәрбиячесе профессияләренең теләсә кайсы икесенең профессиограммасын төзегез.

7. Профессиональ белем базасындагы конкурентлыкның сәбәпләре, сезнеңчә, нәрсәдә? Әлеге конкурентлык белем бирү хезмәтләре сыйфатына ничек йогынты ясый? Җәмгыять белеме курсы белемнәренә һәм үзегезнең тормыш тәҗрибәгезгә таянып, уку йортын сайлаганда абитуриент исәпкә алырга тиешле критерийларны формалаштырыгыз.

8. Әдәбият өлкәсендәге белемнәрегезгә таянып, тормыштагы драмаларының сәбәбе — җәмгыятькә кирәксезлек булган әдәби геройлар мисалларын китерегез.

9. Параграфта «профессиональ эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә эшләп белгеч үзенең белемнәрен арттыра һәм профессиональ эшчәнлеген камилләштерә» диелә. Болай дип раслауның дөреслеген дәлилләгез.

10. Параграфта җәмгыять белеменең гуманитарий өчен кирәкле уку предметы булуы турында әйтелә. 2–3 § материалларына таянып, философия, социология, политология, социаль психология белемнәренең сез сайлаган профессияләр өчен нәрсә бирүен дәлилләгез.

Чыганак белән эшләгез

XX гасырның 20 нче елларында кеше һәм җәмгыять тормышында философиянең роле турында кискен бәхәсләр бара. Әлеге бәхәсләр күпләгән галимнәрнең игътибарын җәлеп итә. Аларның берсе Иван Александрович Ильин була. Философиянең нәрсә икәнлеге, кешеләр тормышында аның нинди урын тотуы, философ нинди булырга тиешлеге турындагы фикерләрен ул «Рухи мәдәният һәм дини философия» дигән хезмәтендә бәян итә.

...Философия, фән буларак, предметлы тәҗрибәгә, ягъни өйрәнелә торган предметны өйрәнүче күңеле белән сыналган, дөрес, адекват кабул итүгә нигезләнә. Шундый кабул итүдән башка философның күңеле таныш-белүгә көчсез, чарасыз булып кала. Мәсәлән, саф... төшенчәне кабул итә алмаган аң логика законнарын формалаштыра алмый; намус күрсәтүләреннән йөз

чөергән җан изгелек һәм явызлык турында хөкем итәргә көчсез. Иң гадәти, читкә юнәлдерелгән фикерләү, үзенең бөтен «формальлегенә» карамастан, үзенә күрә тәҗрибә, һәм бу тәҗрибә мәдәнияткә мохтаҗ.

...Философия, предметлы тәҗрибәгә нигезләнгән фән буларак, тормышка чит-ят кына түгел, ә бәлки аның белән бик тирәнтен һәм бик кадерле элемтә аша тоташкан. Үз исеменә лаек булган һәм хак акылга илтүче чын, зур философия кеше тормышы аның аша үзенең мәгънәсен һәм урынын ала торган кыйммәтләрне предметлы кичерүдән һәм дөрес танып-белүдән гыйбарәт. Ул кешегә һәм кешелек дөньясына Җирдә яшәү өчен кирәк булган нәрсәләрне тикшерә; һәм әлеге тикшеренү тикшеренүчедән предметта чынлап яшәүне таләп итә...

Философ — шагыйрь, рәссам һәм галим, сәясәтче һәм пәйгамбәр кебек үк — аңлапмы, әллә аңламыйчамы, volens ant nolens[1], үз халкының рухи тәҗрибәсе белән туклана. Аның яраткан һәм төп предметлары, иҗади акты, аның тормыш инанулары белән бергә индивидуаль җаны ныгып урнашкан ватаны, ягъни милли рухи мәдәнияте бар; әлеге һәм уңай, һәм тискәре рухи мәдәнияттән аның шәхси тәҗрибәсе һәм шәхси танып-белү иҗаты туклана.

Философия рух яшәвендә һәм рухи тормыштан туа. Шунлыктан фәлсәфә иҗат итәргә теләгән кеше барыннан да элек рухи тормыш башларга, ул рухи булырга тиеш.

Сораулар һәм биремнәр: 1. И.А.Ильин фикеренчә чын философия нәрсәгә нигезләнә? 2. Автор фикеренчә, философиянең фән буларак тикшеренүләренең төп предметы нинди? 3. Философия фәне философка нинди таләпләр куя һәм ни өчен? 4. Автор: «Намус күрсәтүләреннән йөз чөергән җан изгелек һәм явызлык турында хөкем итәргә көчсез»,— дип раслый. Сез авторның мондый карашы белән килешәсезме? 5. Автор, философ үз халкының рухи тәҗрибәсе белән тукланырга тиеш, дип раслый. Ничек уйлыйсыз, философия фәнендә дөньякүләм рухи тәҗрибәгә нинди урын бирелергә тиеш? Философ иҗатында милли һәм дөньякүләм рухи тәҗрибә ничек кушыла ала?

I бүлеккә йомгаклаулар

1. Җәмгыять белеме — мәктәп дисциплиналарының берсе генә түгел, ә бәлки табигать турындагы фәннәрдән аерылып торучы, җәмгыять, аның үсеш формалары һәм закончалык-

[1] Ирекләме, әллә ирексезме.

лары, җәмгыятьнең бүгенге хәле, аның тарихы һәм перспективалары турындагы фәннәр системасы ул. Шуның белән бергә, ул — җәмгыятьнең үзе турындагы белемнәр җыелмасы; ул, фәннидән тыш, шулай ук белемнең фәннән читтәге (фәнниленкә кадәрге, көндәлек h.б.) формаларын да колачлый. Социаль-гуманитар белемнәр танып-белүнең ике төрен: бер яктан — структураларны, гомуми элемтәләрне һәм закончалыкларны өйрәнүгә юнәлеш тоткан социаль фәннәрне, икенче яктан — иҗтимагый тормышның, кешеләрнең, шәхесләрнең үзара хезмәттәшлеген һәм күренеш, вакыйгаларны конкрет сурәтләүгә юнәлдерелгән гуманитар танып-белү нәтиҗәләрен берләштерә.

Җәмгыять белеменең бердәмлеге кешеләр алдында аларның бергәләп һәм аерым яшәүләре вакытында булган уртак проблемалар, глобаль характердагы проблемалар һәм кешеләрнең индивидуаль үз-үзләрен гамәлгә ашырулары проблемалары бәйләнеше белән билгеләнә.

2. Философия социаль-гуманитар белемнәр системасында аерым урын алып тора. Философия — матди һәм рухи дөньяны танып-белүнең фәннән аермалы формасы ул. Анда төп проблема — тормышның мәгънәсе проблемасы. Философия кеше яшәешенең төп проблемаларын белүгә; аларның эволюциясенә; табигать, мәдәният, иҗтимагый эволюция тарафыннан эшләнгән тормыш чараларының төрле төрләре белән мөнәсәбәтләрдә кешенең үз-үзен гамәлгә ашыруы чикләрен билгеләүгә юнәлеш тота. Философия белемнәре белемнәрнең башка төрләреннән шуның белән аерылалар, алар тирәнтен шәхсән, чөнки кешене билгеле бер эшләргә юнәлтеп, аның тормыш мәнфәгатьләренә кагылалар.

Фәннән аерылып торса да, философия аның белән тыгыз бәйләнгән һәм үзара хезмәттәшлек итә. Гәрчә философия үз тикшеренүеннән фәннәрнең шәхси проблемаларын алып ташласа да, ул аларның казанышларын исәпкә ала, дөньяны рухи үзләштерүнең бөтен тәҗрибәсенә таяна.

3. Философия тарихына хәтта кыскача гына күз ташлау да кешеләрнең мең еллар дәвамында үзләре яшәгән дөньяны танып-белү турында нәтиҗә ясарга тырышуларын күрсәтә. Узган чорларның даһи фикер ияләре хезмәтләрендә кеше фикере, гасырлар акылы биеклекләре тупланган. Социаль фәннәрнең философиядән бары тик Яңа вакытта гына аерылуына һәм танып-белүнең мөстәкыйль өлкәләре булып формалашуына тарих шаһит. Хәзерге дөньядагы кеше тормышы шартларындагы тирән үзгәрешләр бүгенге җәмгыять проблемаларын фәнни өйрәнү, кешелек дөньясы очраган яңа проблемаларны фәлсәфи аңлау ихтыяҗы тудыралар.

4. Социаль-гуманитар белем бүген күплəгəн профессиялəргə юл ача. Җəмгыятькə мəктəплəрдə һəм университетларда иҗтимагый фəннəрне укытучылар да, социаль фəннəр өлкəсендə эшлəүче фəнни хезмəткəрлəр дə, социаль хезмəткəрлəр дə, социаль һəм шəхесара мөнəсəбəтлəр, сəясəт, фəн, тəрбия өлкəлəрендəге конкрет хəллəрне өйрəнергə, шулай ук бу өлкəлəрдə белеп консультация бирергə сəлəтле белгечлəр дə кирəк. Һəр профессиянең үзенең кызыктырырлык яклары бар; шуның белəн бергə аларның һəрберсендə үзлəренə генə хас кыенлыклар да юк түгел, ə кыен хезмəткə һəрвакытта да əйбəт түлəнми. Алга таба белем алу юлларын сайлаганда теге яки бу фəнне ярату-яратмавыңны да, килəчəк һөнəри эшчəнлегеңнең барлык якларын да исəпкə алу бик мөһим.

I бүлеккə сораулар һəм биремнəр

1. Социаль һəм табигать фəннəре нисбəте турындагы мəсьəлəне тикшергəндə төрле карашлар арасында мондые да əйтелə: танып-белүнең социаль һəм табигый-фəнни формалары һəм ысуллары арасында бернинди дə аерма юк. Социаль танып-белү бары тик əгəр ул табигый-фəнни формаларны һəм ысулларны кулланса гына фəнни. Проблеманы башкача аңлау да тəкъдим ителə: социаль танып-белү табигатькə түгел, ə кеше эшчəнлеге өлкəсенə юнəлдерелгəнлектəн, табигый-фəнни һəм социаль танып-белү арасында бернинди дə уртаклык юк. Проблемага тагын бер караш: табигать һəм социаль фəннəр вəкиллəре «бер үк азыкны ашыйлар, лəкин төрле яктан һəм төрле кашык белəн». Ə сезнең карашыгыз нинди? Аңа дəлиллəр китерегез.

2. Ерак һəм якын үткəндəге фикер иялəре əйткəн, бу бүлектə китерелгəн идеялəрнең кайсысы сездə күбрəк кызыксыну уятты? Ни өчен икəнен аңлатыгыз.

3. Вузга керүчелəр өчен белешмə яки Интернет кулланып, философия, социология, политология, психология буенча специальлəшү булган белем бирү учреждениелəрен язып алыгыз (үз төбəгегез белəн чиклəнергə дə мөмкин). Алар турында таблица рəвешендə мəгълүмат төзегез, анда вузларны (факультетларны), керү имтиханнары исемнəрен, вузны тəмамлаучылар алачак профессиялəрне күрсəтегез.

4. Əйтик, яшь белгечлəр — социологик тикшеренүлəр үзəгенең фəнни хезмəткəре һəм мəктəп психологы белəн очрашу булачак, һəм сезнең аларның профессиялəре турында күбрəк белəсегез килə ди. Аларга бирергə телəгəн сорауларыгызны языгыз.

Имтиханга әзерләнәбез

1. Түбәндә саналганнардан социаль фәннәргә керә:
1) анатомия;
2) этика;
3) генетика;
4) математика.
Социаль фәннәр исемлегеннән артыгын сызыгыз:
1) тарих;
2) политология;
3) генетика;
4) хокук белеме.
А. Табигать белеме һәм гуманитар фәннәр — тулаем бер фәннең тармаклары.
Б. Социаль танып-белү предметы — кешенең күптөрле формалардагы эшчәнлеге өлкәсе.
1) А гына дөрес;
2) Б гына дөрес;
3) А да, Б да дөрес;
4) әйтелгәннәрнең икесе дә дөрес түгел.
4. «Социаль-гуманитар белемнәр» төшенчәсенә туры килүче теләсә нинди мәгълүмат бирә торган өч җөмлә языгыз.

II бүлек

ҖӘМГЫЯТЬ ҺӘМ КЕШЕ

§ 7. Кешенең барлыкка килүе һәм җәмгыять оешу

Исегезгә төшерегез:

тарих курсында кешенең барлыкка килүе ничек аңлатыла? Бу процесска нинди факторлар хәлиткеч йогынты ясаганнар?

Килеп чыгу һәм борынгы ата-бабалар турындагы сорау кешене шәхсән дә, глобаль дәрәҗәдә дә кызыксындыра. Каян килгән ул кешеләр, җәмгыять ничек барлыкка килгән? Кешелек дөньясы кая таба бара?

Бүгенге көндә кешенең формалашуы процессын тикшеренүләр төп өч юнәлештә алып барыла. Беренчедән, кеше үсешенең бердәм шкаласында «уртак нәселдән төрле линияләрнең

тармаклары» дигән нәрсә ачыклана, бүгенге типтагы кешенең барлыкка килүе стадияләре аерып күрсәтелә, җитмәгән буыннар торгызыла.

Икенчедән, кешенең борынгы ата-бабаларының үзгәрүенең һәм кешенең аерым үзенчәлекләре (басып йөрү, алгы очлыкларны табигый эш коралы рәвешендә куллану, сүзнең һәм фикерләүнең, хезмәт эшчәнлегенең һәм социальлекнең катлаулы формалары үсү) формалашуның биологик алшартлары һәм генетик механизмнары тикшерелә.

Өченчедән, биологик һәм социаль факторларның үзара тыгыз йогынтысы нигезендә гамәлгә ашырылучы катлаулы, комплекслы процесс буларак, *антропогенезның* (кешенең хайваннар дөньясыннан аерылып чыгу процессының) гомуми теориясе ачыклана. Җәмгыятьнең оешуы процессы *(социогенез)* һәм кешенең һәм җәмгыятьнең ике бердәм процессы *(антропосоциогенез)* өйрәнелә.

Кешенең барлыкка килүе проблемалары белән шөгыльләнүче фәннәр арасыннан тарихны, философия, антропология, психология, генетика, культурология, демографияне атарга кирәк. Фән казанышлары булып әверелгән күп нәрсәләр — төрле-төрле факторларны һәм даһи фаразларны тирән өйрәнү нәтиҗәсе ул, чөнки әлеге процесслар фәнни тикшеренүләр барлыкка килүдән күп алда барган.

КЕШЕНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ ТУРЫНДАГЫ ФӘН

Ата-бабаларны эзләү кешенең «юктан» яки аллалар ихтыяры белән яисә табигатьтән үзе яралуы турында бәян итүче даһи фаразлар һәм гүзәл риваятьләр белән бәйле.

Кешенең барлыкка килүе процессын (антропогенезны) фәнни тикшеренүгә нигез XIX гасырда Ч.Дарвинның «Кешенең барлыкка килү һәм җенси сайлап алу» дигән китабы чыккач салына, анда беренче тапкыр бүгенге кешенең һәм кешесыман маймылларның уртак борынгы ата-бабалары килеп чыгуы идеясе формалаштырыла. Антропогенезның икенче факторын Ф.Энгельсның «Маймылның кешегә әверелү процессында хезмәтнең роле» дигән китабы ача. Анда, кешенең борынгы ата-бабасының социаль һәм мәдәният иҗат итүче затка эволюцион әверелүенең хәлиткеч факторы нәкъ менә хезмәт, дигән нигезләмә раслана. XX гасырда әлеге идеяләр *кешенең биосоциаль табигате гомуми концепциясенә* берләштерелә.

Бүген күзаллаганча, кешенең формалашу процессының башы рамапитек — коралларны системалы кулланып, саванналарда яшәү рәвешенә тотрыклы күчкән зат барлыкка килүгә

(моннан 14–20 млн ел элек) карый. 5–8 млн ел элек өлешчә эшкәртелгән яки табигатьтә табылган коралларны киң кулланучы австралопитеклар барлыкка килә. Алардан 2 млн ел чамасы элек беренче Homo — Homo habilis, яки Оста кеше вәкиле килеп чыга. Homo erectus — Туры йөрүче кеше төре 1–1,3 млн ел элек барлыкка килә. Аның миенең күләме 800–1200 $см^2$ тирәсе була (хәзерге кешенеке — 1200–1600 $см^2$), ул шактый камил ау кораллары әзерли, ут таба белә, бу аңа пешкән ашка күчү мөмкинлеге бирә, һәм, бәлки, сөйләшә дә белгәндер. Аның турыдан-туры нәселе Homo sapiens, яки Акыллы кеше була (150–200 мең ел элек). Кешенең бу нәселе кроманьон кеше стадиясендә (40–50 мең ел элек) бүгенге кешегә инде тышкы физик кыяфәте белән генә түгел, интеллект дәрәҗәсе, хезмәт эшчәнлегенең коллектив формаларын оештыру, торак төзү, кием-салым әзерләү, нык үскән сөйләмнән файдалану сәләте, шулай ук гүзәллеккә игътибар итүе, якын кешесенә карата кызгану хисе белдерү сәләте һ.б. белән дә якынлаша.

Галимнәр уйлавынча, эволюция процессына космик факторлар: Кояш активлыгы, Җирнең магнит полюсларының периодик алышынуы (алар арасындагы паузалар вакытында биосфераны саклаучы электромагнит кырлар калканы берничә мең елга шулкадәр көчсезләндерә — космик килеп чыгышлы ионлаштыручы радиация, исәпләүләр буенча, 60% ка арта) йогынты ясыйлар. Бу исә гоминидларның яралгы күзәнәкләрендәге үзгәрешләр ешлыгын арттыра.

Археологлар тагын шуңа да игътибар итәләр: борынгы кешеләрнең табылган торулык урыннары литосфера плитәләренең интенсив хәрәкәте, җир кабыгының радиация артуын китереп чыгаручы ватык һәм ярык урыннарына туры киләләр.

Ихтимал, тектоник, вулканик, сейсмик һәм радиацион катаклизмнар кешенең борынгы ватанының үсемлекләр дөньясына һәм шуның аша климат панорамасына йогынты ясаганнардыр.

Магнит полюсларының алышыну периодларының берсе нәкъ менә 40 мең ел элеккә туры килә.

Безнең элеккеге ата-бабаларыбызны чын хайваннарча яшәү кризисына китерүче этәргеч булып хезмәт иткән ихтимал вариантларның берсе — ми структурасының һәм төзелешенең үзгәрүе (минең бер-берсе белән кушылган өлешләренең берсенең — миндальсыман төш, пояс җыерчыгы яки ми җыелмасының зарарлануы, генетик юл белән ныгытылган баш миенең зур ярымшарларының медиаль ягы структурасының үзгәрүе); бу исә ярымшарларның үзләренең вазыйфалары үзгәрүгә китерә. Хайваннарда ярымшарлар, асылда, бер-берсен кабатламыйлар, организмның мөмкинлекләрен икеләтә арттыралар һәм берсе

зарарланган очракта икенчесенә аның вазыйфаларын үз өстенә алу мөмкинлеге тудыралар. Кешедә ике ярымшар да үз программалары буенча эшли. Шулай итеп, психика, аның сыгылмалылыгы шактый арта.

Психиканың мәгълүмат-яраклашу мөмкинлекләре организмның физиологик үзгәрүе мөмкинлекләреннән күп тапкырлар югары. Мохиткә яраклашу урынына кеше үз-үзен тотышының рәвешен үзгәртә.

Радиация йогынтысы астында үсемлек ашаучы югары приматлар үз-үзләрен тоту стереотипларын кискен үзгәртәләр: итне үсемлек ашамлыкларыннан өстенрәк күрә башлыйлар, аларда бөтен ел буена бала табу сәләте барлыкка килә. Тагын да мөһимрәге — хайвани инстинктларга сукырларча буйсынудан котылалар.

Гоминидларның эволюциясен тизләтүче фактор — эчке һәм тышкы сәбәпләрнең тулы бер комплексы китереп чыгарган стресс булган дигән фикер дә яши. Тышкы йогынтыларның үз-үзеңне саклауның эчке механизмнары һәм нәселдәнлек мәгълүматын тапшыру аша эш итүе мөмкин. Әлеге үзгәрешләр шулай ук эшчәнлекнең төп төрләрен үзгәртеп корганнар, аларда хезмәт эшчәнлеге һәм аралашу акрынлап үзенчәлекле кеше формалары ала башлаган.

Ләкин баш күләме үсүнең чиге була (андый «башлы» нормаль туа алмый). Югары интеллектка сайлау хатын-кызның бала табу вакытында исән калуы белән каршылыкка керә. Нәтиҗәдә өстенлек баш сөягенең ми матдәсе белән тулылану дәрәҗәсе арткан (ярымшарларның төзелеше катлаулану, аларның вазыйфалары үзгәрү, баланың чагыштырмача җитлекмәгән ми белән тууы, хайваннарныкына караганда минең балалыкта шактый озак өлгерүе) индивидлар ягында була. Нәсел турында кайгырту, яралгы йөртү, бала тудырганнан соң үз-үзеңне тотуның төп ысулларын өйрәнү — боларның барысы да гоминидлар бергәлегендәге тормышны оештыруда үзгәрешләр таләп итә.

Антропогенезларның гомуми теориясенә килгәндә исә, аның нигезен (бөтен XX гасыр дәвамында кешенең һәм кешелек җәмгыяте ныгып үсүнең әйдәп баручы факторы буларак) хезмәт эшчәнлеге идеясе тәшкил итә. Әмма бөтен бу вакыт дәвамында ул да үзгәрешсез калмый. Әлеге теориянең төп үзгәрүе шартларның тулы бер комплексын аңлау белән бәйле. Ул комплекста корал белән эш итү һәм хезмәт (иҗтимагый үсешнең мөһим факторлары буларак) фәкать тел, аң, әхлаклылык, мифология, ритуаль практика һ.б. факторлар белән үзара бәйләнештә карала. Кеше үсешенең әлеге барлык факторлары җәмгыятьтә мөмкин, һәм алар мәдәниятта гәүдәләнгән.

Башкача әйткәндә, кеше фәкать башка кешеләр белән бердәмлектә генә чын кеше була ала.

ҖӘМГЫЯТЬНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ

Җәмгыять турында җентекле сөйләшү алдарак булыр. Шулай да, кешенең барлыкка килүе проблемасы белән бәйле рәвештә, кешегә үзенең чын кешелек сыйфатларын чагылдыру һәм үстерү мөмкинлекләре тудырган җәмгыятьнең ничек барлыкка килүен кыскача гына булса да карап үтәргә кирәк.

«Нәрсә алданрак булган — кешеме яки җәмгыятьме?» — галимнәрне кызыксындырган сорау бу. Бер яктан, аңлашыла ки, кешедә табигатьтәге нәрсәләр бик күп; ә икенче яктан, философ Н.А.Бердяев сүзләренә караганда, «кеше — табигатьтәге принципиаль яңалык». Бу тәгъбирдә, кеше табигатьтә табигать законнары буенча гына яшәми, табигать программалаштырган тәртип кысаларыннан чыга да, дип басым ясап әйтелә. Кешене табигатьнең иреккә җибәрелгәне дип, бу фикерне немец мәгърифәтчесе Иоганн Гердер да кабатлый.

Эволюция процессында үз-үзеңне тоту ысулы гына түгел, кешелек бергәлеген оештыру формалары да үзгәрә. Башта кешеләр «кешеләр көтүе» дип йөртелгән тотрыксыз коллективларда яшәгәннәр. Андый коллективта мөнәсәбәтләр күп яктан югары социаль хайваннарның үз-үзләрен тотышына охшаш булган: бергәләп ауга йөргәннәр, салкын көннәрдә җылынганнар, ана җенес өчен сугышканнар, нәселне дәвам иттергәннәр һәм токымны тәрбияләгәннәр. Әмма акрынлап кешеләр коллективы тагын да тотрыкланган. Кешеләр коллектив, күмәк тормышның яңа формасын — җәмгыять булдырганнар.

Баштагы җәмгыятьләрне кайчак «гади җәмгыятьләр» дип атыйлар. Алар кан кардәшлеккә корылганнар, милеккә уртак хуҗа булганнар, күмәкләшеп эшләгәннәр, милек бүлешүне белмәгәннәр. Акрынлап җәмгыять структурасы катлаулана барган. Моның алшартларының берсе камилләштерелгән кораллар, техника һәм технология, хезмәтне специальләштерү ярдәмендә хезмәт эшчәнлеген катлауландыру булган.

Кешеләр бергәлегенең табигать һәм башка кешеләр белән мөнәсәбәтләре урнашуда гореф-гадәт, йолалар зур роль уйнаган. Хәтта аралашу өлкәсендә йолаларның роле тышкы табигатькә карата эш коралы роленә тиң дигән фикер яши. Асылда, ата-бабалар тәҗрибәсен кабул итү чикләре һәм индивид эшчәнлегенең фарватеры әйтерсең лә эшчәнлеккә җитәкчелек итү сыйфатында кулланылган *табу* (тыю) белән билгеләнгән. Табу — билгеле бер гамәлләр кылуны тыю системасы, аларны бозу, борынгылар күзаллаганча, өске табигый көчләр тара-

фыннан җәзага дучар ителә. Кайбер тикшеренүчеләр табуның барлыкка килүен җәмгыятьнең индивидуумнарның табигый инстинктларын йөгәнләү, аларны җәмгыять мәнфәгатьләренә буйсындыру ихтыяҗы белән бәйлиләр.

Кешеләр төркемнәре һәм *тотемнар* — хайваннар һәм үсемлекләр (сирәгрәк — җансыз әйберләр) арасындагы фантастик туганлык турындагы күзаллаулар белән бәйле ышанулар, миф, гореф-гадәтләр комплексы тотемизм дип аталган билгеле бер системага тоташтырылган. Тикшеренүчеләр арасында тотемизмның табигате турында бәхәсләр бара. Берәүләр, ул диннең башлангыч формасы булган, диләр; икенчеләре, тирә-яктагы әйберләрне һәм күренешләрне классификацияләүнең иң гади формасы, дип раслыйлар.

Үзләштерүче хуҗалык итүдән җитештерүче хуҗалык итүгә, аннары утрак тормышка күчү нәтиҗәсендә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр акрынлап киңәя һәм катлаулана. Бер үк вакытта кешеләрнең аерымлана баруы һәм аларның Җирдә таралуы үзгәреп торучы шартлар белән тыгыз бәйләнгән.

Азыкның җитәрлек булуы һәм чагыштырмача имин-тыныч яшәү кешеләргә нәсел турында күбрәк кайгырту мөмкинлеге биргән.

Әгъзалары арасындагы бәйләнешләр кан кардәшлеккә генә түгел, ә уртак эшчәнлеккә, алмашуга, буйсынуга да корылган кешеләр коллективы тормышы белән идарә итү күп баскычлы мөнәсәбәтләр таләп иткән. Шулай итеп, акрынлап башка җан ияләрендә булмаган күпьяклы бергәлек, төрле-төрле элемтәләр һәм мөнәсәбәтләрнең катлаулы бәйләнеше — җәмгыять оеша башлаган. Индивид булдыра алмаган кыйммәтләрне нәкъ менә җәмгыять булдырган. Шундый кыйммәтләргә тел, сәнгать, әхлак, техника, фән, дин һ.б. керә.

Җәмгыятьнең уңышлы продуктив эшчәнлеге мускул көче һәм осталык белән генә түгел, күбрәк белемнәр, ата-бабаларның тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итү белән бәйләнә башлый.

Кешелек дөньясы гомуми үткәннәр, гомуми тарих нигезендә формалаша.

КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫ — БИОЛОГИК ҺӘМ СОЦИОМӘДӘНИ РЕВОЛЮЦИЯ НӘТИҖӘСЕ

Нәрсә соң ул кешелек дөньясы? Сүзлек бу төшенчәне *Җирдә яшәүче кешеләрнең акыллы Кешенең барлык вәкилләрен берләштерүче бергәлеге* дип аңлата.

Кешелек дөньясы башлангычын әле тарихка кадәрге дәверләрдән үк алучы гомуми язмыш дип аңлау философия тарихында иң борынгысы булгандыр, мөгаен. Кешелек дөньясының

бердәм булуы универсаль дөнья диннәре (буддачылык, христианлык, ислам һ.б.) кануннарында чагылыш таба.

Кешелек дөньясын башкача аңлау аны теге яки бу мәдәни ареал (таралу өлкәсе) белән тәңгәлләштерә. Мәсәлән, антик мәдәнияттә «эллин»нарга һәм «варвар»ларга бүлү була.

Ниһаять, кешелек дөньясының бердәмлек буларак акрынлап билгеле бер тарихи чорда барлыкка килүен тарихи таныган караш та яши. Әлеге карашны яклаучылар халыклар кешелек дөньясына акрынлап керәләр дип исәплиләр. Андый караш философ-мәгърифәтчеләргә хас була.

Философ-мәгърифәтчеләр хезмәтләреннән кешелек дөньясын «үсә баручы бергәлек» дип карау традициясе урнашкан. Ж.- Ж.Руссо үсеш факторы итеп кешенең әхлакый сәләтләре камилләшүне саный. И.Кант конкрет кешенең һәр гамәлен кешелек дөньясының үзеннән-үзе максаты идеясе белән тәңгәлләштерергә тәкъдим итә. Кешелек дөньясы аерым бер кешегә караганда күбрәк потенциалга, «күбрәк камиллек яралгыларына» ия. Ә рус философы В.Соловьев (1853–1900) фикеренчә, кешелек дөньясы бердәмлегенең нигезе дин була.

> **«Кешелек дөньясы әлеге бергәлек танылганда барлыкка килә. Нәкъ менә язмышларның бердәйлеген тану кешелек дөньясы кебек универсаль бергәлек туугa булышлык итә».**
>
> **Г.Лессинг**

Шуның белән бергә, кайбер фикер ияләре «кешелек дөньясы» дигән төшенчә гомумән дә эчтәлексез, бернинди чынбарлыкны да чагылдырмый дип исәплиләр. Киресенчә, кешелек ыругы күпсанлы социаль-мәдәни киртәләр белән бүленгән. Мәсәлән, рус философы Н.Я.Данилевский (1822–1885), эчке бердәмлекне тоючы һәм якын телләрдә сөйләшүче кабиләләр бергәлеге — *тарихи тип*, ягъни уникаль үзенчәлекле билгеле бер аерылган мәдәният, дип раслый. Бу мәдәни-тарихи типта Н.Я.Данилевский социаль бердәмлекнең иң югары һәм ахыргы чагылышын күрә.

Немец философы О.Шпенглер (1880–1936) кешелек дөньясы төшенчәсе турында шактый кискен әйтә. Кешеләр Җирдә яшиләр, ләкин төрле вакыт киңлегендә, дип раслый ул. Бу шуның белән бәйле, мәдәниятләр төрле урыннарда барлыкка киләләр һәм үләләр. Нинди дә булса күбәләк яки орхидей кебек үк, кешелек дөньясының «бернинди идеясе дә, бернинди планы да юк». Линиягә сузылган бөтендөнья тарихының монотонлы образы урынына ул һәрберсе «...үз материалына — кешелек дөньясына үз формасын бирүче» күпләгән көчле мәдәниятләрне

тикшерергә тәкъдим итә. «Аларның һәрберсенең үз идеясе, үз ашкынуы, ихтыяры, иреге, хисе һәм үлеме бар»,— ди ул.

Кешелек дөньясына рус философы Н.Н.Трубниковның үзенчәлекле карашы бар. Ул аерым кешенең тормышның мәгънәсен эзләвен гомумкешелек тарихы белән бәйли. Аерым индивидның ахыргылык һәм үлемлелек өстеннән җиңүе кешелек дөньясының үлемсезлеге, һәр кешенең әлеге категориягә мәдәнияткә реаль өлеш кертү аша кагылышлылыгы булып әверелә.

Шулай итеп, кешелек дөньясы турындагы күп яңгырашлы барлык фикерләрне гомумиләштерсәк, бүгенге фәнни әдәбиятта «кешелек дөньясы» терминын ике төрле аңлау барлыкка килә. Беренче очракта Җир шарында яшәүче *халыкларның бердәм язмышы* күздә тотыла. Этносларның, раса, мәдәниятләрнең нинди булуына карамастан, гомумкешелекнең тормыш мәнфәгатьләре һәм кыйммәтләре турында сөйләргә була, дип билгеләп үтелә. Җир — бердәм корабль, кешелек дөньясы «җирдә яшәүчеләр коллективы»на туплана (К.Э.Циолковский (1857–1935), В.И.Вернадский (1863–1945). Мәдәниятләр арасындагы элемтәләр бердәм гомумпланетар мәдәнияткә китерәчәк, дип фаразлана.

Икенче очракта сүз абстракциянең югары дәрәҗәсен гәүдәләндерүче *җыелма төшенчә* турында бара. Бердәм глобаль мәдәният идеясе кире кагыла. Гомумкешелек бердәмлеге күренмәс җепләр белән бәйләнгән мәдәниятләр мозаикасы буларак күз алдына китерелә.

Шулай да барлык тикшеренүчеләр, кешелек дөньясы төшенчәсе организмы яшәүнең билгеле бер шартлары йогынтысы астында формалашкан кешенең биологик табигате белән генә бәйләнмәгән, дигән фикердә торалар. Социальлеге һәм мәдәният белән бәйләнеше дә кешелек дөньясының әһәмиятле характеристикасы булып тора.

МӘДӘНИЯТ БАРЛЫККА КИЛҮ — КЕШЕ ҺӘМ КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫНЫҢ АЕРЫЛМАС ӨЛЕШЕ

Кешенең аңа гына хас үзенчәлеге — үзенең практик һәм рухи эшчәнлеге белән әйләнә-тирә дөньяны үзгәртеп, «икенче табигать» иҗат итү сәләте. Дөньяны мәдәни үзгәртү процессында кеше һәм җәмгыять үзләре дә үзгәрә. Борынгы заман «кеше көтүе»нең социаль коллективка әверелүе кешегә генә хас, социаль хәтер формалаштыруга китергән.

Генетик хәтердән аермалы буларак, *социаль хәтер* мирас итеп биологик билгеләрне түгел, ә белемнәр, кыйммәтләр һәм идеаллар, иҗтимагый кеше эшчәнлеге формалары җыелмасын ала.

Югарыда искә алынган кешедә кешелек сыйфатлары барлыкка килүнең хезмәт теориясе кешелек мәдәнияте кебек феномен барлыкка килүнең тулы һәм ачык картинасын бирми. Җирдә башка җан ияләре дә яши. Бал кортлары һәм кырмыскаларның эш сөючәнлеге мәкальләргә юкка гына күчмәгән. Әмма икенче табигатьне — мәдәниятне бары тик кеше генә уйлап иҗат итә.

Кешенең мәдәни иҗатының тарихи яктан беренче формасы магия булган дигән караш яши. Әле уттан файдаланырга өйрәнгәнче үк, кеше аңа культ практикаларында баш игән. Моның чынлыкта ничек булганын фаразларга гына кала, ләкин учактагы ут та, төнге күктәге йолдызлар да хәтта бүгенге кешене дә гаҗәпләндерәләр. Кыялардагы беренче рәсемнәр ау күренешләрен, хайваннарның образларын дөрес чагылдырып кына калмый, ә бәлки, ихтимал, магия көчләренә дә хезмәт иткәннәрдер. Шулай да этимологик яктан мәдәният-культура сүзе «культ» сүзеннән түгел, ә CULTURA (лат.) — эшкәртү, үстерү, тәрбияләү сүзеннән килеп чыккан.

Мәдәниятнең барлыкка килүенә икенче караш мәдәни иҗатның нигезендә кешенең әле киләчәктә булачак практик гамәлләрнең символларын, уйдагы модельләрен булдыра алу сәләте яту белән бәйле. Образларның аерым дөньясын иҗат итеп, бу яктан кеше барлык «осталардан» да өстен тора. Эшкә тотыныр алдыннан кеше үз эшләренең образын тудыра. Образ — мәдәниятнең иң мөһим чараларының берсе.

Ничек кенә булмасын, кеше чын практицизмны беренче карашка бөтенләй файдасыз, ләкин аның үзенә һәм башка кешеләргә кирәкле күтәренке рухи иҗат белән берләштерергә сәләтле. Кешелек дөньясы бер үк дәрәҗәдә техника һәм технология казанышларын гына түгел, ә бәлки үзе ирешкән рухи биеклекләрне дә үзенең гомуми казанышы дип саный ала. Һәм, ихтимал, бары тик кеше генә нәрсә дә булса эшләр алдыннан уйлый, газапланып, матурлыкны эзли, саклый һәм хакыйкатьне мирас итеп калдыра, яхшылыкны һәм гаделлекне кадерли.

Теге яки бу галим антропогенез процессын нинди генә факторлар белән аңлатмасын, кешелек дөньясының мәдәнияттән башка яши алмавын беркем дә инкарь итми.

Төп төшенчәләр: кешелек дөньясы.

Терминнар: антропогенез, социаль хәтер, гоминидлар.

Үзегезне тикшерегез

1. Кешенең биосоциаль җан иясе буларак барлыкка килүен аңлатучы төп теорияләр нинди? 2. Кешенең барлыкка килүе турындагы сорауга җавапта алар бер-берсенә нәрсәдә туры

киләләр? 3. «Кешелек дөньясы» төшенчәсенең төп билгеләрен күрсәтегез. 4. Кешелек дөньясының социаль хәтеренең үзенчәлекләре нидән гыйбарәт? Аерым кеше хәтереннән ул нәрсәсе белән аерыла? 5. Кеше һәм җәмгыятьнең ныгып урнашуында мәдәният нинди роль уйнаган?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Кешелек дөньясы элек яшәгән, хәзер яшәүче һәм әле тумаган кешеләрнең барысыннан тора, дип әйткән француз фикер иясе Ж.П.Сартрның фикерен раслагыз яки кире кагыгыз.

2. Түбәндәге бәхәстә үз фикерегезне әйтегез:

а) сакланып калган таш коралларга таянып, кайбер антропологлар Акыллы кешенең барлыкка килүен эш кораллары булдыру һәм куллану белән бәйлиләр;

б) икенче бер галимнәр таштан яки агачтан элементар эш коралларын җитештерү өчен кирәкле мотор-сенсор координацияләр нинди дә булса фикер үткенлеге таләп итмиләр дип исәплиләр.

3*. Хәзерге фәннәрне кулланып, кешенең килеп чыгуын аңлатучы гипотезаларның берсе белән килешегез яки аны инкарь итегез. Кеше кеше булган: 1) суда яшәве аркасында; 2) өр-яңа йолдызның катгый нурланышлары яисә геомагнит кыр инверсияләре тарафыннан гоминидлар (приматлар отряды семьялыгына казылма кеше дә, бүгенге кешеләр дә керә) мие күзәнәкләрендә китереп чыгарылган мутацияләр нәтиҗәсендә; 3) җылылык стрессы нәтиҗәсендә гоминидлар арасында мутант барлыкка килгән.

4. И.Мечниковның түбәндә әйткәннәренең фәлсәфи мәгънәсен ачып бирегез: «Бакчачы яки көтүче табигать биргән үсемлекләр яки хайваннар алдында туктап калмый, аларны үзенә кирәкле рәвештә үзгәртә. Галим-философ та әнә шулай ук хәзерге кешелек табигатенә үзгәрмәс бернәрсә итеп карамаска, аны кешеләр файдасына үзгәртергә тиеш». Әлеге карашка сезнең мөнәсәбәтегез нинди?

Чыганак белән эшләгез

Россия философы А.Г.Спиркин (1919–2004) китабыннан өзек белән танышыгыз.

Кеше һәм кешелек дөньясы

Теге яки бу кешенең рухи тормышы ничек кенә гениаль бай булмасын, аның акылы тышка нинди генә фонтан булып атылмасын, әгәр ул кешелек дөньясының рухи кыйммәтләрен, башка халыклар һәм тарихның акыл капчыгыннан үзләштер-

мәсә, ул барыбер үз-үзен тәэмин итә алмый һәм чикләнгән була. Кешелек дөньясы байлыгы аерым җәмгыять байлыгыннан, бигрәк тә аерым бер кеше байлыгыннан һәрвакыт югарырак һәм киңрәк. Үзләренең асылы буенча халыклар Җирдә бөтен дөньяда «урнашырга» мәҗбүр ителгән. Кешелек дөньясын бердәм җыелма җан иясенә тиңнәргә (әлбәттә, шартлыча) мөмкин: ул, аерым кеше үз яше алышынган саен үсә барган кебек, буыннан-буынга үсә барган. Ә үзенең үсешендә, прогрессив үсешнең гомумкешелек принципларына буйсынып, һәр җәмгыять һәм һәр милләт, теге яки бу дәрәҗәдә гомуми дөньякүләм элемтәгә кереп, мөстәкыйль рәвештә мәдәниятнең аерым үз юлын үтәргә тиеш.

Җәмгыять тормышының асылын һәм кешелек дөньясы тарихын бербөтен итеп уйлап, без шуны таныргa тиеш: безнең тормышыбызда исәннәр генә түгел, ә бәлки үлгәннәр дә, ягъни кешелек дөньясы агымында искә алынырга лаеклылар да зур роль уйный. Алар, В.Соловьев[1] сүзләре белән әйткәндә, исәннәр өстеннән икеләтә югарырак: «аларның күренеп торган урнәкләре дә, яшерен яклаучылары да — мәдәни массивның тирән механизмы кебек, ул механизм аша «вафат булган акыл» күренеп торган, Җирдә яшәүче һәм алгарышка юнәлгән кешелек дөньясының шәхси һәм гомуми тарихында эш итә».

Сораулар һәм биремнәр: 1. Әлеге текст авторының карашы «кешелек дөньясы» төшенчәсен ничек аңлатуга якынрак тора? 2. «Кешелек дөньясының байлыгы аерым җәмгыять байлыгыннан, бигрәк тә аерым бер кеше байлыгыннан һәрвакыт югарырак һәм киңрәк»,— дигән җөмләнең мәгънәсен аңлатыгыз. 3. Әлеге караш белән килешәсезме? 4. Сезнеңчә, кешелек дөньясының яшәп киткән буыннарының хәзер яшәүчеләр өлешеннән өстенлеге нәрсәдә? Үз карашыгызны раслау өчен мисаллар китерегез.

Бу хакта бәхәсләшәләр

Антропологлар арасында Акыллы кешенең һәм аның расасының килеп чыгуы турында ике концепция яши — моноцентризм һәм полицентризм. Беренчеләре фикеренчә (ул бүгенге көндә өстенлек итә), Акыллы кеше билгеле бер урында (якынча, Көнчыгыш Африкада) бер тапкыр яки эзлекле рәвештә берничә тапкыр кинәт үзгәрү (мутация) вакытында барлыкка килгән, аннары әйләнә-тирә мохиткә яраклашу процессында хәзерге раса аерымлыклары алып, башка континентларга таралып урнашкан.

---

[1] *Соловьев В.С.* — рус философы, шагыйрь, публицист.

Полицентризм яклылар карашынча, Акыллы кеше күп тапкырлар һәм Иске Дөньяның төрле урыннарында барлыкка килгән, шулай булгач, бүгенге күпләгән раса аерымлыклары Акыллы кешенең шушы ата-бабаларыннан мирас итеп алынган. Яшәп килүче фрагментар мәгълүматлар, күрәсең, антропологларга әлеге мәсьәлә буенча гомум кабул ителгән фикергә килергә комачаулый. Һәм аларның күбесе альтернативага — йә моноцентризмга, яисә полицентризмга китерү өчен Акыллы кешенең барлыкка килүе артык катлаулы эволюцион процесс булган дип саный.

§ 8. Философия проблемасы буларак кешенең асылы

Исегезгә төшерегез:

астроногенезның һәм социогенезның үзенчәлекләре нинди? Борынгы Көнчыгыш һәм борынгы грек философлары барлык тереклек ияләре арасында кешегә нинди урын биргәннәр? Яңа чорда кешенең роленә һәм урынына караш ничек һәм ни өчен үзгәргән?

Кешегә бирелгән билгеләмәләр арасында фәлсәфи фикер тарихында тулы бер дәверләргә хас булганнары аз түгел: «кеше — акылга ия хайван», «кеше — сәяси хайван», «кеше — эш коралы ясаган хайван», «дини кеше», «акыллы кеше» һ.б. Немец философы *Макс Шелер* (1874–1928) болай дип яза: «Кеше шулкадәр дә киң, күптөрле бер нәрсә ки, аның барлык билгеләмәләрен дә уңышлы дип әйтеп булмыйдыр».

Кеше күп фәннәрнең өйрәнү объекты булып тора. Алар арасында — биология, физиология, психология, генетика, антропология, этнология. Мәсәлән, *антропология*нең (кеше турында тәгълиматларның) үзәгендә — кешенең килеп чыгуы, ныгып урнашуы проблемалары, *психология* үзәгендә — тормыш эшчәнлегенең аерым формасы буларак психиканың үсү һәм эш итү закончалыклары, *генетика* үзәгендә — нәселдәнлек һәм организмнарның үзгәрүчәнлек законнары. Шуның белән бергә, кеше философия белемнәренең төп предметы булып тора.

«Кеше барлык нәрсәләрнең үлчәме», — дигән борынгы грек философы *Протагор*. Нинди үлчәм соң ул? Ул кайда һәм ничек чагыла? Бу сораулар 2,5 мең чамасы ел тикшеренүләр һәм кайнар бәхәсләр тудыралар. Кешене өйрәнүдә фәлсәфи якын килү шуннан гыйбарәт — кеше тиренең эволюцион биеклеге, табигать һәм кешенең потенциалын ачу, рухи иҗатны иҗат итүче буларак карала. Үсемлек, хайван һәм кеше җанын аерып караганда, *Аристотель* табигать иерархиясендә кешенең

урынын һәм аның түбәнрәк матди хәлләргә бәйлелеген күрсәтә.

Шундый сораулар туа. Кешенең асылы турындагы характеристикалар ни өчен шулай күп? Гәрчә бер үк объектны — кешене күздә тотсалар да, ни өчен алар шулай күптөрле? Әлеге сорауларга җавап табарга тырышыйк.

БӨЕК СЕР — КЕШЕ

Кеше — катлаулы система, ул күп үлчәмле. Белгәнегезчә, фән күзлегеннән караганда, кеше — тере табигатьнең озак үсешенең уникаль продукты һәм бер үк вакытта табигатьнең үзенең космик эволюциясе нәтиҗәсе. Шуның белән бергә, кеше җәмгыятьтә, социаль мохиттә туа һәм яши. Ул уникаль сәләткә — фикер йөртү сәләтенә ия, шуның нәтиҗәсендә кешенең рухи дөньясы, аның рухи тормышы бар. Җәмгыять кешенең табигатькә мөнәсәбәтендә арадашлык итә, шуңа күрә кеше булып туган зат социаль мөнәсәбәтләргә кушылганда гына чын кеше булып әверелә. Әлеге хакыйкатьләр кеше асылының *табигый һәм социаль бердәмлеге* турында сөйләү мөмкинлеге бирә.

Кешедән дә аңлаешлырак һәм, шуның белән бергә, катлаулырак башка бернәрсә дә юк. Бүгенге кешене аның ерак бабаларыннан йөзләрчә меңьеллыклар аерып тора. Шунлыктан, барлыкка килү таңындагы кешелек ыруы тормышыннан күп нәрсәләрнең танып-беленмәве, серле, ябык булып калуы гаҗәп түгел. Безнең замандашыбыз да аны эш-хәрәкәтләрен алдан әйтерлек һәм ачык зат итеп кабул итәргә нигез бирми. Хәтта тормыш тәҗрибәсе туплаган кешеләр дә еш кына үзләренең «акыл буенча туганнарын» җитәрлек белмәүләрен таныйлар, чөнки таныш һәм таныш түгел кешеләр һәр көн үз-үзләрен тотышларында һәм фикер образларында нинди дер аңлашылмаган, көтелмәгән нәрсәләр эшләп ташлыйлар.

> «Кешеләр бер-берсенә бик үк охшамыйча туалар, аларның табигате төрле була, теге яки бу эшкә сәләтләре дә шулай ук».
>
> **Платон**

Кешенең асылын тикшерү белән белемнең аерым тармагы — *фәлсәфи антропология* шөгыльләнә. Аны кеше тәненең аның генезисындагы (килеп чыгышындагы) һәм бүгенге халәтендәге төзелеше закончалыкларын һәм механизмнарын өйрәнүче гомуми, биологик антропологиядән аерырга кирәк. Гомуми антропологияне белү Homo sapiensның биологик мөмкинлекләрен күз алдына китерү ни өчен ул үзен башкача, хәтта югары оешкан хайваннар — кеше кыяфәтле маймыллар-

дан — башкача тотарга сәләтле икәнен аңлау өчен дә мәҗбүри. Алар һәм Homo sapiens арасында күзгә күренми торган, ләкин үтә алмаслык чик ята. Фәкать Homo sapiens кына эш коралы ясау өчен корал әзерләү сәләтенә ия. Бу, кайбер тикшеренүчеләр фикеренчә, аның ырудан килгән төп аермасы булып тора.

Икенче аерма шунда: кеше абстракт фикерләү сәләтенә (хезмәт эшчәнлегенең ахыргы максаты белән арадаш операцияләр арасындагы бәйләнешне аңлавы) һәм үзенең фикерләвенең эшчәнлеген, юнәлешен, нәтиҗәләре мәгънәсен аңлаешлы телдә белдерү сәләтенә ия. Практик эшчәнлекнең гомуми формалары нигезендә мәгънәләрнең киңәйтелгән системасы барлыкка килә. Бүген ул күпләгән төрле-төрле текстларда, сүзлек, әсбап, фәнни һәм матур әдәбият, сәнгать, дин, философия, хокукта һ.б. да теркәлгән.

Мәгънәләрнең шундый гомуми системасы нәтиҗәсендә һәр яңа буын туктаусыз рәвештә мәдәниятне үзләштерә, ягъни кеше социальләшә.

Кант философиясендә кеше үзенең барлык чагылышларында: танып-белүче, әхлаклы, тәрбия ярдәмендә камиллеккә омтылучы кеше буларак карала. Нәкъ менә Кант кешене башка кеше өчен чара итеп түгел, ә максат итеп игълан итә.

Фәлсәфи антропологиянең мөстәкыйль дисциплина булып әверелүенә немец философы *Людвиг Фейербах* (1804–1872) тәгълиматы зур йогынты ясый. XIX гасырның 30–40 нчы елларында Фейербах, кеше — философиянең универсаль һәм иң югары предметы, дип белдерә. Галәм төзелешенең, дин, фән һәм сәнгатьнең калган барлык мәсьәләләре кешенең асылын нәрсә дип исәпләүгә бәйле рәвештә хәл ителә. Философ үзе кешенең асылы — барыннан да элек хиссилек, эмоция һәм кичерешләр дөньясы, мәхәббәт, газапланулар, бәхеткә омтылу, акыл һәм йөрәк дөньясы, тән һәм җан бердәмлеге дип саный. Чынбарлыкны кешедән дип аңлатучы, философиянең нигезен тәшкил итүче *«антропологизм»* төшенчәсенең барлыкка килүе дә аның исеме белән бәйле. Үз тәгълиматын Л.Фейербах «кеше философиясе», «антропология» дип атый. К.Маркс Фейербахның кешене абстракт, тарихтан тыш аңлавын тәнкыйтьли һәм, үз чиратында, кешенең асылын «иҗтимагый мөнәсәбәтләр кушылмасы» дип билгели.

Фәлсәфи антропология XIX гасырда кешенең асылы проблемасын (аның акыллылыгын, корал белән эш итүен, символлар булдыру сәләтен һ.б.) тикшеренүләрнең мөстәкыйль юнәлеше буларак барлыкка килә. Ул кешенең тормыш эшчәнлегендә (иң элек үз-үзен тотышында) нәрсә хәлиткеч булган — элеккеге философия тулы җавап бирә алмаган табигатьме, әллә социуммы дигән сорауга үзенчәлекле реакция булып тора.

Фәлсәфи антропология — белемнең кешене конкрет-фәнни, фәлсәфи һәм дини аңлауны берләштерергә тырышкан дисциплинаара өлкәсе. Аның нигезе төп мәгънәләре түбәндәгеләр тәшкил иткән концепцияләргә кайтып кала: кешенең баштагы биологик якланусызлыгы аның актив эшчәнлеген, дөнья белән, үзе кебекләр белән элемтәсен, рухилыгын, мәдәниятен барлыкка китерә; үзенең дөньяга ачыклыгы, тотрыксызлыгы (эксцентриклыгы) һәм үзенең үзеннән тыш яшәвенең таяну ноктасын даими эзләве нәтиҗәсендә кеше мәңгелек эзләнүгә, сәяхәт кылуга, үз-үзен камилләштерергә омтылуга дучар; кеше — күп үлчәмле, танып-белеп булмаслык, күпләгән «башкалар»га, «мин түгел»гә мохтаҗ зат; кеше ике башлангычның — «*ашкыну*»ның (мавыгуны, биологик ихтыяҗларны, ярсуны гәүдәләндерүче табигый төшнең) һәм «*рух*»ның (акыл һәм хисләр өлкәсенең) кисешe үзәге булып тора, аларның бердәмлеге кешенең асылын барлыкка китерә. Фәлсәфи антропологиягә нигез салучы танылган М.Шелер фикеренчә, кешенең асылы — кешенең үсешнең прогрессив кына түгел, ә бәлки регрессив линиясен дә күздә тотучы кешелеклеккә ирешүенең катлаулы процессы ул.

Фәлсәфи антропологиягә *тормыш философиясе* — XIX гасыр ахыры — XX гасыр башындагы фәлсәфи агым, аерым алганда, аның «кеше реаль тормышта акыллы омтылышлар белән түгел, инстинктлар белән эш итә» дигән идеясе сизелерлек йогынты ясый. Үз чиратында, фәлсәфи антропология кеше тормышындагы аңсыз эшләнгәннәрнең ролен аңлатучы гипотезалар һәм теорияләр комплексы — *психоанализга* һәм кешене аерып торган сыйфат итеп ирекне санаган *экзистенциализмга* (яшәү философиясенә) шактый йогынты ясый.

Фәлсәфи антропология М.Шелерның меңнәрчә вак кисәкләргә вакланган кеше образын бергә җыю турындагы хыялын тормышка ашыра алмый. Ул үзе күпләгән антропологиягә: биологик, мәдәни, дини, социологик, психологик һ.б. антропологияләргә бүленә. Алар, кешене өйрәнүгә булган берләштерү омтылышларына карамастан, тикшеренү ысулларында да, фәлсәфи антропологиянең үзенең урынын аңлауда да шактый аерымлыкларын күрсәттеләр.

Бу хакта бәхәсләшәләр

Электән дә, хәзер дә фәлсәфи антропология вәкилләренең аның белемнең мөстәкыйль өлкәсе буларак статусын шик астына алучы оппонентлары бар. Кайбер бүгенге философлар исәпләгәнчә, антропологик проблематиканың кешегә формалаштыру һәм конструкцияләү принцибы буларак беркетелүе

үзеннән-үзе генә аны философия белеменең мөстәкыйль өлкәсе итеп аеру өчен нигез булып тора алмый, чөнки философиянең барлык проблематикасы диярлек, тегеләйме-болаймы, кешегә кагыла.

КЕШЕ — БИОСОЦИАЛЬ СИСТЕМА

Инде билгеләп үтелгәнчә, кеше — катлаулы һәм күп дәрәҗәдәге система. Монда биологик, социаль һәм рухи башлангычлар, аң һәм «аң асты» өлкәсе үзара бәйләнгән. «Кеше системасының табигый һәм социаль дәрәҗәләренең (элементларының) кушылуы кешене характерлаучы башка: «индивид», «шәхес», «индивидуальлек» төшенчәләрен дә тотрыклы тәшкил итүче булып тора. Әлеге төшенчәләр — беррәттәгеләр, ләкин аларны тәңгәлләштерергә ярамый. Алардагы аерма алдагы параграфларда каралачак.

Философиядә иң төп җыелма терминнарның берсе — *субъект* төшенчәсе бар. Ул югарыда саналган төшенчәләрне колачлый, чөнки кешенең танып-белү һәм практик эшчәнлеген характерлый. *Субъект* — иҗтимагый әһәмиятле эшчәнлеге процессында үз яшәешенең предметлы хезмәтен һәм үз-үзен (үз сыйфатларын) үзенең белемнәре, тәҗрибәсе белән үзгәртү өчен актив эш итүче кеше ул. *«Субъектлык»* — кешенең шәхси яшәешенең, аның социаль көнкүреш белән элемтәсенең мөһим аспекты. Бу терминны кешегә хас булган фикерләр, ихтыяр, хисләр дөньясы булып аңлашылган *«кешенең субъективлыгы»* төшенчәсе белән бутарга ярамый.

«Субъект» төшенчәсенең эчтәлегенә кешенең, беренче чиратта тарихны иҗат итүче кешенең барлык характеристикалары керә. Кеше ихтыяҗлары, мәнфәгатьләре, сәләтләре иҗтимагый-тарихи эшчәнлекнең алга этәрүче көче булып торалар һәм барысы бергә кеше табигатенең эчтәлеген тәшкил итәләр. Башкача әйткәндә, «субъект» төшенчәсенең эчтәлеге кешенең барлык социаль әһәмиятле сыйфатларын: акылын, әхлаклылыгын, намусын, рухилыгын һ.б. колачлый.

Кеше — иҗтимагый-тарихи эшчәнлек һәм мәдәният субъекты; аңга, аңлаешлы сөйләмгә, әхлак сыйфатларына һәм эш коралы ясау сәләтенә ия булган биосоциаль зат. Монда тагын шунысын да өстәргә кирәк, кеше — биологик һәм социальнең югары оешкан бердәмлеге. Социаль биологикка кайтып калмый, ә биологик исә тормышта үзенең Homo sapiens төре әһәмиятен югалтмый. Кеше үзенең үсүе, социальләшүе, асыл ыруг сыйфатларын алуы процессында табигый зат үзенчәлекләрен саклый.

ЭШЧӘНЛЕКНЕҢ СОЦИАЛЬ НИГЕЗЕ

Кеше табигать һәм социаль дөнья белән универсаль элемтәдә тора, ул бу элемтәдән Аристотель, гәүдәдән киселгән кул бары әйтелгәнгә генә шулай булып кала, дигән кебек, бары «шулай әйтелгәнгә» генә читтә кала. Табигать, башка кешеләр, иҗтимагый структуралар һәм институтлар белән барлык төр элемтәләрен кеше *эшчәнлек* аша тормышка ашыра. Кеше нәкъ менә практик-предметлы һәм танып-белүле эшчәнлектә үз яшәешенең бөтен тулылыгы белән чагыла, анда, аның конкрет формаларында, тәннең һәм рухның, матдинең һәм идеальның, идеалларның һәм чынбарлыкның бердәмлеге тормышка ашырыла.

Эшчәнлек кешенең әйләнә-тирә дөньяга актив мөнәсәбәтенең, аны максатка ярашлы үзгәртү һәм яңартуының үзенчәлекле формасы булып тора. Бу дөньяның объектив, ягъни кеше аңына бәйле булмаган мөнәсәбәтләре һәм закончалыклары эшләүче кеше ихтыярына каршы торырга, нейтраль булырга, ә билгеле бер шартларда кеше башлангычларының уңышына булышлык итәргә мөмкин. Шунлыктан кешенең теләсә нинди эшчәнлегендә (икътисади, сәяси, мәдәни) *субъектив*, ягъни кешегә бәйле, һәм *объектив* аспектлар аерылып тора.

Югарыда кешене җәмгыять белән элемтәдән башка күз алдына китереп булмавы, шунлыктан кешенең теләсә нинди эшчәнлегенең иҗтимагый (социаль) характерда булуы турында әйтелде инде. Бу аның максатларында, чараларында һәм нигезләрендә чагыла: кеше теге яки бу (шул исәптән — җәмгыять өчен әһәмиятле) бурычлар куя, аларны тормышка ашыру өчен социум хуплаган чаралар сайлый. Аңлашыла ки, теге яки бу максатларны кую һәм аларны тормышка ашыру объектив хәлләр белән яраклаштырылырга тиеш.

Инде билгеләп үтелгәнчә, эшчәнлек һәрвакыт объектив һәм субъектив моментларны бербөтенгә берләштерү булып тора. Шул ук вакытта аларны белдерү формасы төрле хәлләрдә төрлечә була. Мәсәлән, иҗтимагый тормышны үзгәртеп кору һәм кешенең аның шартларына күнегүе бу өлкәдә белемнәргә ия булуны да, үзләренең иҗтимагый-сәяси, мәдәни һәм башка программаларын уңышлы тормышка ашырсыннар өчен теге яки бу төркем кешеләргә мөмкинлекләр тудыруны да күздә тота. Аерым бер кешенең уңышы конкрет программаны тулаем уңышлы башкару дәрәҗәсе белән билгеләнәчәк. Нәкъ менә кешенең аңы, үз эшчәнлегенең образын төрле социаль үзара эш итү образлары белән кушу сәләте буларак, эшчәнлекне тормышка ашыру процессында куелган максатка ирешүнең зарури шарты булып тора.

ФИКЕРЛӘҮ ҺӘМ ЭШЧӘНЛЕК

Фикерләүдә хисси-конкрет әйберләр һәм процесслар чагылышларыннан аерылу бара, һәм төшенчәләр системасы төзелә. Аларда фикерләүнең һәр моментында аның предметы «туктал-ган», үзенең «агышын» югалткан, билгесезлек булып карала.

Чынбарлыкны төрлечә: иң гади тормыш хәлләреннән кешелекнең бүгенге хәлен глобаль гомумиләштерүләргә һәм аның киләчәген фаразлауга кадәр, кеше күңеленең иң кечкенә хәрәкәтләрен теркәүдән алып (әдәбиятта, психологик прозада) иҗтимагый-сәяси тормышның, фәннең һәм мәдәниятнең универсаль теорияләренә кадәр фикерләргә мөмкин.

Эшчәнлекнең нигезен табигатьне, җәмгыятьне, кешенең үзен үзгәртеп кору тәшкил итсә, фикерләү әлеге үзгәртеп коруның рухи нәселдәнлеген һәм кешенең эзлекле, максатка юнәлдерелгән эшчәнлеккә субъектив әзер булуын тәэмин итә. Шул рәвешле, фикерләү кешенең һәм кешелек дөньясының бөтен эшчәнлегенә үтеп керә, аның тырышлыкларына килешенгәнлек, тәртиплелек, оешканлык бирә.

Фикерләүнең (рациональ танып-белүнең) формаларын һәм үзенчәлекләрен җентекләбрәк кешенең танып-белү эшчәнлеге мәсьәләләренә мөрәҗәгать иткәч тикшерербез.

ФИКЕРЛӘҮ ҺӘМ ТЕЛ

Чынбарлык зиһенгә алу, аның турында уйлану һәм аны танып-белү сөйләм эшчәнлеге белән чагылдырыла. Әле борынгы фикер ияләре үк, кеше хайваннан үзенең эчке халәтен вербаль (сүз белән) формалаштыра алу сәләте белән аерыла, дип билгеләп үткәннәр.

Фикер үзен эш-гамәлләрдә, музыкада да табарга мөмкин, ләкин аны белдерүнең төп чарасы — тел. Кешенең формалашуы үзе үк сүзгә ия булуны күздә тота. Без барыбыз да сөйләм ярдәмендә аралашабыз, сүзләрне җөмләләргә берләштерәбез. Җөмләләр системасын җәелдерү нигезендә һәр сүз безнең игътибарыбыздагы предметларның гаять күп сыйфатларыннан нинди дә булса бер үзенчәлеген аерып ала һәм ныгыта. Шушы сыйфатында сүз чынбарлык әйберләренең күптөрле байлыгын аларның тавыш *(сөйләм теле)*, яисә график *(язма тел)* билгеләмәләре белән алыштыра. Мимика һәм хәрәкәтләр тел аркасында символик әһәмият алалар, мәсәлән, актерның пантомимасы, мимансны яки катлаулы психологик халәттәге балетны сурәтләве. Сүз чынбарлыкның конкрет чагылышларына гына күрсәтеп калмый, ул бер үк вакытта гомумиләштерә дә. Мәсәлән, без «роза» сүзен әйткәндә, бихисап розаларның санап бетергесез

барлык сыйфатларыннан нindидер аерым сыйфаты — билгеле бер формадагы, төстәге һәм истәге чәчәк булу сыйфаты аерып алына.

Сүзләр нигезендә сөйләм яки язма тел аша буыннан буынга тапшырыла торган тотрыклы мәгънә һәм төшенчәләрнең әһәмиятлеләре ныгытып калдырыла. Уйланылган һәр эшчәнлек нигезендә фикер яки кешенең диалог алып бару осталыгын күздә тотучы «сорау һәм җавап» тел структурасы ята.

Сүзләр үзләре каян килеп чыккан соң? Алар кешелек дөньясының чынбарлыкны үзләштерү буенча иҗтимагыйтарихи эшчәнлеге процессында барлыкка килгәннәр һәм ныгып калганнар. Аларның күбесендә эшчәнлекнең билгеле бер ысулына юнәлдерелгән төп билгеләү мәгънәсе бар. Мәсәлән, без «пычак» дип әйткәндә, монда эш-гамәлнең билгеле бер тибы — кисү мәгънәсе аерып алынуын аңлыйбыз. Ләкин бит пычак белән кадарга, чәнчергә дә була, ләкин бу әлеге предметны куллануның мөмкин булган ысуллары гына.

Билгеле булганча, тел тормыш эшчәнлекләре төрле табигый һәм иҗтимагый шартларда үткән халыкларның бер-берсен алыштырган буыннары тарафыннан үстерелгән. Кабиләләр, халыклар һәм милләтләр телләренең үзенчәлеге кешелек дөньясы аларның кешелек тарихындагы хәленең һәм эшчәнлегенең төп моментларын чагылдырган. Тел аркасында анда беркетелгән һәм анда язылган эшчәнлек төрләре бер халык кысаларында буыннан буынга тапшырылып кына калмый, бер халыктан икенчесенә дә күчә.

Тел ярдәмендә аралашу — социаль коммуникациянең катлаулы төре. Аларда фонетик һәм сүзлек-синтаксик аспектлар аерыла; алар, бергә кушылып, тулы яңгырашлы сөйләм һәм тәэсирле язма телне тәэмин итәләр, шул нигездә бер халык вәкилләрен икенче халык вәкилләре аңлый алырга мөмкин. Мондый аралашу *(коммуникация)* үзара аңлашу һәм эшчәнлек тәҗрибәсе алмашу нигезе булып тора.

Хәзер инде параграф башында китерелгән «ни өчен кешенең асылын билгеләүләр шулай бик күп» дигән сорауга җавап бирергә тырышып карыйк.

Беренчедән, кеше эшчәнлегенең чагылышлары күптөрле. Ул эшли һәм сәясәт белән шөгыльләнә, уйный һәм уйлый һ.б.

Икенчедән, абстракт кеше, «гомумән кеше» юк. Кеше һәрвакыт үзенең яшәеше кысаларында калырга тиеш. Яшәү өчен кешегә вакытта үзгәрергә, иҗтимагый үсеш чакыруларына җавап бирергә туры килә. Башкача әйткәндә, социомәдәни үзенчәлегенә карап, кешене «камилләшкән», «катып калган» дип санарга ярамый. Нәкъ менә шул кеше проблемасына фәлсәфи карашның төрле булуын билгели дә инде.

Төп төшенчәләр: кеше, субъект, эшчәнлек, фикерләү, тел.

Терминнар: фәлсәфи антропология, субъектлык, субъектлылык.

Үзегезне тикшерегез

1. Кешене нинди фәннәр өйрәнә? 2. Кешене аңлау-белүгә фәлсәфи антропология нинди өлеш кертә? 3. Антропологлар кешенең нинди үзенчәлекләрен аерып күрсәтәләр? 4. Кеше субъектлыгы субъектлылыктан нәрсәсе белән аерыла? 5. Кешенең социаль асылы нәрсәдә чагыла? 6. Фикерләү һәм эшчәнлек үзара ничек яраша? 7. Тел һәм фикерләүнең башлангычын ачып бирегез.

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Борынгы грек философы Протагорның кешене барлык әйберләрнең үлчәме буларак билгеләвенең мәгънәсен ачып бирегез. «Кеше» төшенчәсенең асылын ачамы ул? Үз җавабыгызны аңлатыгыз.

2. Биология, тарих, җәмгыять белеме курсларыннан алган белемнәрегездән файдаланып, кешенең табигатьнең таҗы булуы турындагы шактый таралган фикерне нигезләргә яки кире кагарга тырышыгыз.

3. Христиан дине белгечләре кеше үзенең табигате буенча ярым җанвар-ярым фәрештә дип санаганнар. Рус шагыйре Г.Р.Державин бу темага үзенең танылган «Мин патша, мин кол, мин суалчан» дигән шигырен багышлаган. Кешене мондый югары күтәргән һәм юкка чыгарган билгеләмәләр белән килешәсезме? Үз нәтиҗәләрегезне мисаллар белән ныгытыгыз.

4. Билгеле булганча, Homo sapiens — Акыллы кеше. Сезнеңчә, мондый билгеләмәнең күп кешеләрнең чынлыкта үз-үзләрен тотышларына туры килмәве нәрсә белән аңлатыла?

5. Кешенең «эчке» сөйләменең «тышкы» сөйләменнән нәрсәсе белән аерылуын аңлатыгыз.

6. Бүгенге тормыш чынбарлыкларын исәпкә алып, кешенең асылына үзегез биргән билгеләмәне тәкъдим итегез.

Чыганак белән эшләгез

Рус философы Н.А.Бердяев хезмәтеннән өзек укыгыз.

<...> **Фәлсәфи антропология** — рух фәлсәфәсенең үзәк өлеше ул. Ул кешене фәнни — биологик, социологик, психологик өйрәнүдән принципиаль аерылып тора. Һәм бу аерымлык шунда: философия кешене кешедән тикшерә, рух патшалыгына караган итеп тикшерә; фән исә кешене табигать патшалыгына караган итеп, ягъни кешедән тыш, объект итеп тикшерә. Ике

дөньяга караган һәм үзен җиңәргә сәләтле зат буларак, кеше — үзендә поляр капма-каршылыклар туплаган каршылыклы һәм парадоксаль зат. Кеше турында бердәм хокук белән, ул югары һәм түбән, көчсез һәм көчле, ирекле һәм кол зат дип әйтергә була. <...> Кеше фәкать табигать дөньясы һәм табигый процесслар тудырган зат кына түгел, шуның белән бергә, ул табигать дөньясында яши һәм табигый процессларда катнаша. Ул табигать мохитенә бәйле һәм, шуның белән бергә, әлеге мохитне гуманлылаштыра, аңа принципиаль яңа башлангыч кертә. Кешенең табигатьтәге иҗади эше космогоник әһәмияткә ия һәм космик тормышның яңа стадиясен белдерә. Кеше — табигатьтәге принципиаль яңалык. Әгәр аны табигатьтән һәм фәкать табигать белән нисбәттә генә карасаң, кеше проблемасы бөтенләй дә чишәрлек түгел. Кешене бары тик аның Аллага мөнәсәбәтендә генә карарга мөмкин. Кешене аннан түбәннән аңлап булмый, аны аннан югарыдан гына аңларга мөмкин.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Кешенең әлеге философ тарафыннан билгеләнгән «эшчәнлекнең субъекты һәм объекты була алуы»ның уникаль үзенчәлеген сез ничек аңлыйсыз? Үз фикерегезне мисаллар белән аңлатыгыз. 2. Философның кешенең «парадоксаль» һәм «каршылыклы» зат булуы турындагы фикерен уртаклашасызмы? Үз җавабыгызны дәлилләр белән ныгытыгыз. 3. Н.А.Бердяевның «Кеше — табигатьтәге принципиаль яңалык» дигән фикеренә аңлатма бирегез.

§ 9. Җәмгыять һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләр

Исегезгә төшерегез:

«табигатьнең объектив законы» нәрсә ул? Табигый-географик мохит җәмгыять үсешендә нинди роль уйнаган һәм, вакытлар үтү белән, бу роль үзгәргәнме? Экология кризисының сәбәпләре һәм чагылышлары нинди? Ни өчен аерым бер халыкларның мәдәниятен үзенчәлекле дибез?

Кешеләр җәмгыятьне кеше яшәвенең аерым бер һәм кирәкле мохите итеп башта ук аңламыйлар. Дәүләтнең, гаиләнең булуы ачыграк аңлана. Борынгы грек фикер ияләре дәүләт һәм җәмгыятьне тәңгәлләштерәләр. Сәясәтчеләргә хас «хакимлек итү — буйсыну» мөнәсәбәтләре җәмгыятькә дә күчерелә. Иҗтимагый хәл табигатьнеке белән чагыштырганда сыйфат ягыннан яңа итеп каралганга кадәр йөз еллар уза. Акрынлап сәяси булмаган мөнәсәбәтләргә нигезләнгән гражданлык җәмгыяте турындагы күзаллаулар барлыкка килә. Хезмәт, үзара хезмәттәшлек итү аның мөһим состав өлеше буларак карала башлый.

XIX гасырда беренче тапкыр җәмгыятьне аның барлык үлчәмнәрендә бербөтен итеп анализларга тырышулар була.

Җәмгыятьне аңлауда философия һәм фән зур юл үттеләр. Ләкин монда проблемалар әле бүген дә кала. Аларның берсе — иҗтимагый «бирелгән»нең һәм «ирекле»нең нисбәте, фән теле белән әйткәндә, объектив закончалыкларның һәм кешеләрнең аңлы максатлары тарафыннан юнәлдерелгән эшчәнлекләре нисбәте.

ҖӘМГЫЯТЬНЕ СОЦИУМНАН НӘРСӘ АЕРА?

Шундый сорау бирик: нәрсә ул җәмгыять? Беренче карашка, аңа җавап бирү кыен түгел. Бу сүз көндәлек сөйләмгә дә, фәнни лексиконга да күптән һәм ныклы кереп урнашкан. Ләкин аңа билгеләмә бирергә тырышып карасак, андый билгеләмәләрнең күп булу ихтималына ышанабыз. Менә тотрыклы сүэтезмәләрнең берничәсе: «һәвәскәр бакчачылар җәмгыяте», «марка җыючылар җәмгыяте», «педагоглар җәмгыяте». Җәмгыять дигәндә, күмәк эшчәнлек, аралашу, үзара ярдәм итү һәм бер-береңә булышу өчен берләшкән кешеләр төркеме аңлашыла. «Көнбатыш Европа җәмгыяте», «Россия җәмгыяте» дигәндә без билгеле бер илләрне яки тулаем дәүләтләр бергәлеген күздә тотабыз. Гәрчә алар турында сүз барган илләр бик тә реаль булсалар да, бу — абстракциянең шактый югары дәрәҗәсе. «Архаик җәмгыять», «феодаль җәмгыять», «индустриаль җәмгыять» дип, без гомумиләштерүнең югарырак баскычына күтәреләбез. Бу очракларда җәмгыятьләрнең билгеле бер тарихи типлары күздә тотыла. Бу рәттә иң ахыргы гомумиләштерү җәмгыятьне оешуның нинди дә булса конкрет формасына кертмичә аңлау булыр.

Җәмгыятьне философлар сүзнең иң киң мәгънәсендә **кешеләрнең үзара бәйләнешләренең һәм берләшү формаларының барлык ысуллары җыелмасы** итеп аңлыйлар. Башкача әйткәндә, кешеләрнең бер-берсенә һәрьяклы бәйлелеге, аларның тормыш эшчәнлегенең аерым формасы буларак, җәмгыятьне барлыкка китерә.

«Социум» төшенчәсен күп кенә тикшеренүчеләр «җәмгыять» төшенчәсенең синонимы итеп карыйлар. Әмма башка караш та бар. Аның буенча социум дигәндә социальлек, тере һәм тере булмаган табигатьтән аерылып торучы табигый булмаган чынбарлык аңлашыла. Бу мәгънәдә «социаль» тулаем дөньяның ассистемаларының берсе булып тора. Табигый һәм социаль — кеше яшәешенең ике мохите генә түгел, ә бәлки, инде югарыда аңлатуыбызча, аның үзенә хас ике нигезе дә. Аерым һәр кеше социаль, ләкин аны җәмгыять дип санау мәгънәсезлек. Илебезнең бер философы бик зирәк әйткәнчә,

социальне ачыклау — Робинзон белән Җомганы алар ияләштергән кәҗәдән нәрсә аерып торуын аңлау дигән сүз. Социальне болай аңлатканда, җәмгыять аның яшәү формасы, кешеләр арасындагы элемтәләрнең биологиктан тыш ысулы булып чыга.

ҖӘМГЫЯТЬНЕ СОЦИАЛЬ-ФӘЛСӘФИ АНАЛИЗЛАУ ДӘРӘҖӘЛӘРЕ

«Җәмгыять» төшенчәсен билгеләүгә төрлечә якын килүләрне тикшереп, без инде гомумиләштерүнең берничә дәрәҗәсен аерып күрсәттек. Аларны җентеклэбрәк карыйк.

Тарих дәресләрендә сез аларга хас икътисади, сәяси, рухи тормыш аермалары, социаль структура үзенчәлекләре булган күпләгән конкрет җәмгыятьне өйрәндегез. Сезнең алдыгыздан борынгы, урта гасыр, яңа һәм өр яңа чорлар халыклары һәм илләре тарихы үтте. Әлбәттә, монда аерым фактларны (сәяси вакыйгаларны, сугышларны, монархларның идарә итү даталарын һ.б.) сурәтләү белән бергә, гомумиләштерүче төшенчәләр һәм фикерләр дә булды (вакыйгаларны җәмгыять тормышының өлкәләре буенча төркемләү үзе үк инде безнең «иҗтимагый өлкә» төшенчәсен куллануыбыз турында сөйли) — алардан башка гына вакыйгаларның бөтенлекле картинасын сурәтләү, төрле фактларны ниндидер системага китерү мөмкин түгел. Шулай да тагын бер тапкыр басым ясап әйтәбез: бу дәрәҗәдә без конкрет вакыйгалар, халыклар һәм дәүләтләр белән эш итәбез. Җәмгыятьне тикшеренүнең бу дәрәҗәсен *конкрет-тарихи* дип атарга мөмкин.

Төп мәктәптә тарих курсында, шулай ук җәмгыять белеме дәресләрендә сез «Көнчыгыш цивилизациясе», «Көнбатыш цивилизациясе», «феодолизм», «традицион җәмгыять», «индустриаль җәмгыять», «постиндустриаль җәмгыять» төшенчәләре белән очраштыгыз. Аларда инде бердәнбер түгел, ә үзенчәлекле күренешләрнең һәм процессларның киң классына хас сыйфатлар теркәлә. Бу — җәмгыятьнең типологиясе белән бәйле тагын да югарырак дәрәҗәдәге гомумиләштерү. Әлеге дәрәҗәне тикшеренүчеләр *тарихи-типологик* дип атыйлар.

Һәм, ниһаять, җәмгыятьне тикшерү, аның гомуми үзенчәлекләрен аерып күрсәтү һәм анализлау безне өченче — *социаль-фәлсәфи* дәрәҗәгә алып килә. Әлбәттә, «гомумән җәмгыять» юк, бу — абстракция. Һәр реаль җәмгыятьнең үзенең тарихи үсеш юлы, үзенең уникаль, кабатланмас сыйфатлары бар. Шулай да шундый югары дәрәҗәдәге абстракцияләр файдалы. Алар иҗтимагый үсештәге охшаш, кабатлана торган, тотрыклы нәрсәләрне күрү, тышкы яктан бер-берсеннән бик тә ерак күренешләрне чагыштырып карау мөмкинлеге бирә.

Безнең курста җәмгыятьне тикшерүнең күрсәтелгән барлык өч төре дә китерелгән. Шул ук вакытта конкрет-тарихи дәрәҗә үткәннең гомуми нигезләмәләрне иллюстрацияләүче аерым мисалларына мөрәҗәгать итү белән чикләнмәгән. Курста мөһим урын бүгенге Россия җәмгыятен — без яши торган җәмгыятьне анализлауга бирелгән.

ҖӘМГЫЯТЬ ҺӘМ ТАБИГАТЬ

«Табигать» төшенчәсе, «җәмгыять» төшенчәсе кебек үк, берничә эчтәлеккә ия. Киңрәк мәгънәдә табигать, кешеләрнең рухи тормышыннан тыш (фәнни белемнең озак вакытлар «табигать турындагы фәннәр»гә һәм «рух турындагы фәннәр»гә бүленүе очраклы түгел), барлык чын нәрсәләрнең җыелмасы итеп аңлатыла. Бу күзлектән караганда, җәмгыять тормышының матди ягы да табигатьнең бер өлеше булып тора һәм күп яктан аның белән уртак законнар буенча үсә. XIX гасыр фикер ияләренең җәмгыятьне өйрәнгәндә тере табигать белән туры охшашлык үткәрергә тырышуы да шуннан килеп чыга: җәмгыять тере организм кебек үк, аның һәр өлеше (һәр институты) билгеле бер вазыйфа башкара, яшәү өчен көрәш бара, анда көчлерәк җиңә һ.б. Ләкин, вакытлар үткәч, **җәмгыять белемендә табигать дигәндә кешене чолгап алган, социаль мохит белән бергә яшәүче табигый мохитне аңлый башладылар.** Болай аңлатканда, җәмгыять тә, табигать тә кеше яши торган, чагыштырмача мөстәкыйль ике «яшәү дөньясы» булып торалар. Җәмгыятьнең аерымлылыгы, аерым алганда, анда табигатькә хас булмаган закончалыклар (мәсәлән, иҗтимагый үсешне тизләтү законы) булуда чагыла.

Табигый һәм социаль мохит кеше аңында озак вакытлар аерылгысыз була. Социаль мөнәсәбәтләр кешеләр тарафыннан аларның яшәвенең табигый шартлары буларак аңланыла. Урнашкан гореф-гадәтләр бирелгән үзгәртелмәс нәрсәләр, әйберләрнең табигый чагылышы итеп кабул ителә. Урта гасырлар чорында социаль (кешеләрнең аларның аңы һәм ихтыяры тарафыннан юнәлтелгән эшчәнлеге), табигый (табигый зарурилык) һәм Илаһи (өстән билгеләп кую) нәрсәләр аерыла. Әлеге дөньялар катгый иерархиядә урнаша: иң биектә — Илаһи дөнья, аннан соң — социаль һәм, ниһаять, «катып калган табигать».

Яңа чорда, индустрияләштерү башлангач, кешеләрнең табигатькә кулланучылык мөнәсәбәте раслана. Әйләнә-тирә мохитне пычратуның кеше тормышы өчен куркыныч тудыруы, табигый ресурсларның акрынлап бетүе экология кризисы китереп чыгаралар, кешенең үзенең яшәвенә яныйлар.

Социаль мохит кеше тарафыннан бүген дә бик әһәмиятле итеп кабул ителә. Ләкин табигатькә һәм аның җәмгыять үсешендә тоткан роленә ваемсыз технократик якын килүдән акрынлап арына барыла. Табигать кешедән аның ритмына яраклашуны, аңа сак мөнәсәбәтне таләп итүче, катлаулы һәм төрле булып кала бирә. Беренче планга табигать һәм кеше арасындагы постиндустриаль җәмгыять шартларында да саклануы өзлексез элемтә чыга.

«ИКЕНЧЕ ТАБИГАТЬ»

Шулай да кеше бүген дә хәзерге дөньяны үзгәртеп коручы, яңаны булдыручы, иҗат итүче булып кала бирә. Әлеге булдырылган, «мәдәният» исеме алган дөнья табигый факторлар йогынтысына бирешми, шунлыктан мәдәниятне әле тагын «икенче табигать» дип йөртәләр. **Мәдәниятне кешенең һәм тышкы мохиткә, һәм үзенә юнәлдерелгән үзгәртеп кору эшчәнлегенең барлык төрләре һәм нәтиҗәләре җыелмасы** итеп аңлау бу төшенчәне киңрәк мәгънәдә ача һәм «мәдәният» сүзенең башлангыч мәгънәсенә тулырак туры килә.

Бу төшенчәнең таррак мәгънәсе дә бар. Аерым алганда, мәдәният дигәндә еш кына кешенең җәмгыять тормышының рухи өлкәсендә ирешкән казанышларын: әдәби-нәфис иҗатны, фәнни ачышларны, шулай ук аерым бер кешенең рухи ихтыяҗлары дәрәҗәсен аңлыйлар. Белемле, тәрбияле, яхшы манераларга һәм зәвыкка, әдәби телгә ия булган, сәнгать әсәрләре белән кызыксынучы кеше мәдәниятле булып санала.

«Мәдәният» төшенчәсенең киң мәгънәсенә әйләнеп кайтыйк. Кеше булдырган, эшкәрткәннәргә без нәрсәләрне кертәбез? Болар — төзелгән йортлар, чәчелгән кырлар, кеше яшәешенең гомум кабул ителгән нормалары, язылган җырлар һ.б. күп, бик күп нәрсәләр. Болар барысы да — кешеләрнең катлаулы мөнәсәбәтләр системасы белән бәйләнгән эшчәнлеге җимешләре. Мәдәният җәмгыятьтән башка булдырыла һәм яши алмый. Шул ук вакытта җәмгыять тә мәдәнияттән башка мөмкин түгел. Аннан башка без кешеләр була алмас, аерым төр затлар бергәлеге генә булып калыр идек. Кешеләр мәдәни нормалар (әхлак, хокук, традицияләр) нигезендә эш итәләр, мәдәни кыйммәтләр (мәдәният төшенчәсенең «тәрбияләү» мәгънәсен искә төшерик) йогынтысы нәтиҗәсендә үзгәрәләр, мәдәният казанышларын туплыйлар һәм буыннарга тапшыралар (шуның нәтиҗәсендә иҗтимагый үсештә буыннан буынга күчү мөмкин), аның яңа формаларын булдыралар. (Монда иҗтимагый прогресс чагыла.)

Мәдәният йогынтысында безнең тормышыбызның хәтта табигый яклары да үзгәрә. Мәсәлән, азыкка ихтыяҗны без нәкъ менә бүгенге җәмгыятьтә кабул ителгән ысуллар белән канә-

гатьләндерәбез: күпчелек очракта азык-төлекне кибеттән сатып алабыз (кемнәрдер шәхси хуҗалыгы мөмкинлекләреннән файдалана), ул әзер азык булмаса, плитәдә эшкәртәбез. Әзерләнгән азыкны тәлинкәләрдә бирәбез һәм махсус приборлар кулланып ашыйбыз.

Мәдәният тарихилыгы һәм гаять тә күптөрлелеге белән характерлана. Мәдәният дөньясын тагын да тирәнрәк өйрәнү өчен тикшеренүчеләр аның типларын, формаларын, компонентларын аералар һәм төрле классификацияләрен булдыралар.

Мәдәниятне *матдига* (көнкүреш әйберләре, элемтә чаралары, приборлар, җиһазлар һ.б.) һәм *рухига* (белемнәр, тел, кыйммәтләр, символлар, кагыйдәләр, нормалар һ.б.) бүлү гомум кабул ителгән. Бу бүлү шактый шартлы. Аңлашыла ки, һәр матди әйбер артында эшне оештыруның билгеле бер формалары, иҗатчыларның уй-фикерләре, еш кына катлаулы исәпләүләр, ягъни рухи мәдәнияткә кагылышлы күренешләр тора. Шул ук вакытта рухи мәдәният җимешләре еш кына җанландырылалар: нәфис образлар китап битләрендә яки сынлы сәнгать полотноларында җанланалар, дини идея храм төзегәндә гәүдәләндерелә.

Безнең планетада элек яшәгән һәм хәзерге кешеләр берберсеннән иң элек үзенчәлекле мәдәниятләре белән аерылганнар һәм аерылалар. Һәм бу тел аерымлыгына, дини карашларга яки әдәби-нәфис иҗатка гына да кагылып калмый. Үзенчәлек традицияләрдә һәм гореф-гадәтләрдә, гаилә укладында һәм балаларга мөнәсәбәттә, нинди азыкка өстенлек бирүдә һ.б. бик күп нәрсәләрдә чагыла. Өстәвенә җәмгыять мәдәниятенең аерым элементларын бары тик аның бөтен мәдәнияте кысаларында гына аңларга була. Американың бер социологы мондый мисал китерә: Көнбатыш илләрендә яшәүчеләр авыз куышлыгы гигиенасына аеруча җентекле карашлары белән аерылып торалар. Башка мәдәният вәкилләре карашынча, тешләрне даими, җентекләп чистарту йоласы, кайбер кабиләләрдә очрый торган матурлык өчен үзләренең алгы тешләрен суыртып алу яки шул ук максатта иреннәрен махсус пластиннар ярдәмендә кабарту гадәте белән чагыштырганда, гаҗәеп булып тоела.

Шуның белән бергә, төрле халыкларның мәдәниятләрен өйрәнүче тикшеренүчеләр барлык мәдәниятләргә дә уртак сыйфатлар яисә формалар хас дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Аларны *мәдәни универсалияләр* дип атаганнар. Аларга, аерым алганда, билгеле бер грамматик төзелешле тел булу, никах һәм гаилә институты, дини йолалар керә. Барлык мәдәниятләрдә балалар турында кайгырту белән бәйле нормалар бар. Барча халыкларда инцестны — якын туганнар белән сексуаль мөнәсәбәтләргә керүне тыю яши. Ләкин хәтта шушы аз санлы универсалияләр

дә төрле җәмгыятьләр мәдәниятләрендә үзләренчә чагылыш табалар. Мәсәлән, аларның күпчелеге берничә хатынга өйләнүне кире кага, ә шул ук вакытта мөселман илләрендә бу — законлаштырылган норма.

Төрле тип җәмгыятьләрнең мәдәни үзенчәлекләре, милли мәдәният эчендәге күпләгән мәдәниятләр турында сез дәреслекнең алдагы параграфларыннан белерсез.

ИҖТИМАГЫЙ МӨНӘСӘБӘТЛӘР

«Җәмгыять» төшенчәсен билгеләүгә әйләнеп кайтыйк. Әгәр индивидлар арасында чагыштырмача тотрыклы мөнәсәбәтләр урнашса гына, аларның бергәлеген җәмгыять дип санарга була. Монда «тотрыклы» сүзенә басым ясыйк. Шундый хәлне күз алдына китерегез: сез тулы автобуста барасыз ди. Кемдер сездән «фәлән тукталыш кайчан була?» дип сорый, кемдер машина йөртүчегә билет өчен акчасын җибәрүне үтенә. Бу очракларда барлыкка килгән контактлар очраклы, эпизодик. Аларны иҗтимагый мөнәсәбәтләргә кертмиләр.

Икенче бер хәлгә мөрәҗәгать итик. Сез эшкә урнашырга килдегез ди. Сезгә кайбер документлар күрсәтергә, ихтимал, әңгәмә үтәргә, эшнең барлык төп килешү бәян ителгән шартнамә төзергә туры киләчәк. Мондый процедураны шундый ук мәсьәләне хәл итүче һәркем үтә. **Чагыштырмача тотрыклы, күп яктан үзенчәлексез (формаль), кешеләр тормышының мөһим якларына кагылган мондый мөнәсәбәтләр «иҗтимагый мөнәсәбәтләр» дип атала.** Шул ук вакытта индивидлар арасындагы гына түгел, җәмгыятьтәге социаль төркемнәр арасындагы мөнәсәбәтләр дә күздә тотыла.

Күпләгән иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең үзенчәлекле булмавы аларны ачыклауны кыенлаштыра. Мәсәлән, традицион җәмгыятьтә, бер түбә астында яшәүчеләрнең барысының да шәхси сыйфатларына карамастан, гаилә башлыгы белән аның башка әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрне билгеле бер алгоритм буенча оештырылуын тиз генә билгеләп булмас иде. Әлеге элементләрнең тотрыклы сыйфатлары — теләктәшлек һәм көндәшлек, җитәкчелек итү һәм буйсыну һ.б. тиз генә ачыкланмаган.

Иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең катлаулы һәм тармакланган системасына кереп, кешеләр бер-берләренә бәйле булалар. «Беркемгә дә бәйле түгелмен» дип уйласа, кеше ялгыша. Чөнки мондый мәгънәдәге бәйсезлек — үз ихтыяҗларыңны башка кешеләрнең арадашлыгыннан һәм ярдәменнән тыш, үзең канәгатьләндерү дигән сүз. Мөмкинме соң бу? Бу бит, мәсәлән, бер кисәк ипи турында кайгыртып, сез мөстәкыйль рәвештә бөртек үстерергә, аны тарттырырга, күмәч пешерергә тиеш-

легезне аңлата. Хәтта Робинзон Крузо да үз утравында абсолют бәйсез булмаган, чөнки яшәр өчен ул баткан корабльдән калган, ягъни башкалар ясаган күп әйберләрдән файдаланган.

Табигый-фәнни дисциплиналар дәресләрендә сез вакыйгалар, күренешләр яки объектларның эчке халәтләре арасында кабатланып торучы объектив, зарури, тотрыклы элемтәләрнең «закон» яки «объектив закончалык» дип аталганын беләсез. Иҗтимагый мөнәсәбәтләрне шундый элемтәләр чагылышы дип буламы? Аларның кайбер характеристикалары «объектив закончалык» төшенчәсенә туры килә бит.

Җәмгыятьне фәнни өйрәнү башланганнан соң бу сорауга җавап ачыклана кебек. Чөнки кайбер тикшеренүчеләр җәмгыятьне тере организмга тиңли, димәк, анда да шундый ук катгый, кешеләр ихтыярына бәйсез элемтәләр булырга тиеш. Шул закончалыкларны ачу фәнни җәмгыять белеменең төп бурычы булып тора, чөнки ул җәмгыятьнең алга таба үсешен фаразлау, бүген кылынган гамәлләрнең булачак нәтиҗәләрен ачык билгеләү мөкинлеге бирәчәк дип уйланыла.

Ләкин болай якын килү, кешеләрнең иҗтимагый үсеш барышына һәм нәтиҗәләренә зур йогынты ясаучы аңлы-ихтыяри эшчәнлеген тәшкил итүче өлешен читтә калдырып, җәмгыять тормышының күп үлчәмле картинасын гадиләштерә. XX гасырда иҗтимагый тормышның кайбер объектив процессларын чагылдыручы *закон-тенденцияләр* турында күзаллау формалаша башлый; җәмгыять үсешендәге социаль күренешләр үзенчәлегенә, рухи факторларның (мәнфәгатьләр, кәеф, кешеләрнең кыйммәти билгеләмәләре) ролен исәпкә алуга күбрәк игътибар бирелә.

Төп төшенчәләр: җәмгыять, социум, иҗтимагый мөнәсәбәтләр, мәдәният, иҗтимагый үсеш закончалыклары.

Терминнар: законнар, тенденцияләр.

Үзегезне тикшерегез

1. «Җәмгыять» төшенчәсенең төп мәгънәләре нинди? Бу сүзнең киңрәк мәгънәсендә җәмгыять ничек билгеләнә? 2. «Социум» һәм «җәмгыять» төшенчәләре арасындагы аерма нәрсәдә? 3. Җәмгыятьне тикшеренүнең төп дәрәҗәләре нинди? 4. Кешеләрнең җәмгыять һәм табигать арасындагы үзара бәйләнешләр турында күзаллаулары ничек үзгәргән? Бу үзгәрешләр нәрсә белән бәйле булган? 5. «Мәдәният» төшенчәсенең күпмәгънәлелеген күрсәтегез. 6. Җәмгыять тормышында мәдәниятнең роле нинди? 7. Мәдәниятне «матди»гә һәм «рухи»га бүлүнең шартлылыгы турындагы тезисны мисаллар белән күрсәтегез. 8. Философлар нинди мөнәсәбәтләрне иҗтимагый дип

саныйлар? 9. Иҗтимагый үсеш закончалыклары табигать законнарыннан нәрсәсе белән аерыла?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Түбәндә китерелгән фикерләрнең һәрберсендә «җәмгыять» төшенчәсе нинди мәгънәдә кулланылган?

• Кагыйдә буларак, зур белемле, әйберләргә акыл белән һәм тәнкыйть күзлегеннән караучы кешеләрне берләштереп, дворяннар җәмгыяте XX гасырда да үзенә бикләнгән төркем, читләрне кабул итмәүче үзенә күрә бер каста булып калган.

• Индустриаль җәмгыять үсешнең элеккеге этабында булган кайбер каршылыкларны хәл итте, әмма шул ук вакытта яңаларын тудырды.

• Кайбер тикшеренүчеләр җәмгыять барлыкка килүне табигатьтәге эволюцион процессларның турыдан-туры дәвамы итеп карыйлар.

2. Түбәндә саналганнарның кайсысын, сезнеңчә, социаль күренешләргә кертеп була?

Кеше күзәткән кояш тотылуны, фермер эшкәрткән сөрүлек җирен, тайфунның яр буендагы торулыкларны юкка чыгаруын, куллану алдыннан азыкны кулинар эшкәртүне.

3. XIX гасырда кайбер илләрдә булган сәнәгать переворотына конкрет-тарихи, тарихи-типологик һәм социаль-фәлсәфи позициядән карарга тырышыгыз. Җәмгыятьне тикшеренүнең күрсәтелгән һәр дәрәҗәсендә әлеге күренешнең кайсы яклары кызыксындыру тудырыр иде?

4. Америка культурологлары мәдәниятне төрлечә аңлаган ике кеше арасындагы хыялдагы әңгәмәсен китергәннәр.

А н т р о п о л о г. Гадәти котелок антрополог өчен Бетховен сонатасы кебек үк мәдәният продукты.

Б и з н е с м е н. Минем өчен һәм хатыным өчен мәдәниятле кеше Дебюсси, Пикассо турында сөйли алучы гына.

Сезнеңчә, әңгәмәдәшләрнең кайсысы «мәдәният» төшенчәсен тулырак куллана?

5. Борынгы аучылар мамонт үтергәннәр һәм табышны үзара бүлешә башлаганнар. Бу очракта иҗтимагый мөнәсәбәтләр халәте барлыкка килгәнме? Үз нәтиҗәгезне дәлилләгез.

6. «Кешеләр, ягъни кеше психикасы ихтыяҗлары, өметләре, куркулары, көтүләре, аерым кеше индивидларының мотивлары һәм омтылышлары, әгәр алар гомумән нинди дә булса әһәмияткә ия булсалар, үзләренең социаль тормышларын иҗат итүдән бигрәк аның продукты булалар... Хәтта кешенең аңлы һәм алдан уйланылган гамәлләре нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән институтлар да, кагыйдә буларак, андый гамәлләрнең турыдан-туры булмаган, алдан уйланылмаган һәм кирәксез өстәмә

нәтиҗәләре булалар икән», — дип яза инглиз философы һәм социологы К.Поппер. Әлеге фикерне ачыклагыз, аны конкретлаштырыгыз.

Чыганак белән эшләгез

Илебез философы С.Л.Франкның (беренче текст) һәм француз философы А.Мольның (икенче текст) хезмәтләреннән өзекләр укыгыз.

«Техника... үзеннән-үзе генә мәдәният түгел»

Мәдәният — кешелек дөньясы тарафыннан булдырылган һәм эшләнгән, аның рухи-иҗтимагый яшәешен тәшкил итүче абсолют кыйммәтләр җыелмасы ул. Кешелек дөньясы аңында кайбер мәңгелек идеаллар — аны фәнни, нәфис, әхлакый һәм дини иҗатка этәрүче хакыйкать, игелек, матурлык, мөкатдәслек яши...

Гадәттә «матди мәдәният» дип аталган нәрсә чын мәдәнияткә карата бары тик әзерлек, хезмәт итү әһәмиятенә генә ия. Кёльн соборы, Акрополь, «Сикстин мадоннасы», Шекспир, Пушкин һәм гомумән бөтен сәнгать — мәдәниятнең үзе. Ләкин тимер юллар, телеграф һәм телефоннар, гомумән барлык техника, фәнни мәдәният тудырганнар буларак һәм мәдәниятнең үсүенә ярдәм итеп, үзләреннән-үзләре мәдәният түгелләр. Чын, рухи мәдәният кебек, алар да — кешелек дөньясының тырышлыгы, хезмәте, аңлы ихтыяры продукты... Чын мәгънәсендә мәдәният булмаса да, алар мәдәният «мөһере» белән билгеләнгән. Бу аларның рухи мәдәнияткә символик һәм реаль якынлыгы. Соңгысының үсүенә матди мәдәният күрсәткән хезмәтләр кебек үк, психологик яктан аңа без цивилизациягә һәм мәгърифәткә күрсәткән хөрмәт тарала. Әмма берсен икенчесе белән бутарга ярамый. Рухи мәдәният мәнфәгатьләрен истә тотып, «матди мәдәният» дигәннең саф утилитар, ярдәмче әһәмиятен күз уңыннан чыгармау мөһим.

Кешене рухи баетучы буларак мәдәният

Кешенең зур үзенчәлеге шунда: ул яши торган тирәлегеген үзе булдырган. Шул ясалма чагылдыру белән аерым шәхес аңында калдырыла торган эз — без мәдәният дип йөртә торган нәрсә үзе ул. «Мәдәният» — бик күп мәгънәле атама. Төрле авторлар аны төрлечә аңлый, һәм аның 250 дән артык билгеләмәсе бар. Моннан тыш вакытына һәм урынына, өйрәнелә торган җәмгыятьнең характерына бәйле рәвештә бу сүз төрле эчтәлек ала...

Без Альберт Швейцер билгеләмәсе белән килешә торган позициядән торып эш итәбез. Ул болай ди: «Мәдәният ул — аерым затларның һәм бөтен кешелек дөньясының барлык өлкәләрдә һәм барлык аспектларда шәхеснең һәм гомуми прогрессның рухи камилләшүенә ярдәм итүче казанышлары нәтиҗәсе...».

Кеше мәдәниятне өлешчә анда үзе тәрбияләгән, өлешчә аны аның белән сугарган социаль тирәлектән үзләштерә. Соңгысы — массакүләм коммуникация чаралары эше.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Мәдәният дигәндә Франк нәрсәне аңлый? 2. «Матди мәдәният» дип аталган нәрсәгә философ ничек карый? Сез мондый мөнәсәбәтне уртаклашасызмы? 3. Моль мәдәниятне ничек аңлата? 4. Мәдәниятнең асылы турындагы мәсьәләләрдә Франк һәм Моль карашларын чагыштырыгыз. Нинди уртаклыклар һәм аерымлыклар күрәсез?

§ 10. Үсә баручы система буларак җәмгыять

Исегезгә төшерегез:

теләсә кайсы механик система нәрсә белән характерлана? Тере организмнарның бөтенлеге нәрсәдә чагыла? Тере табигатькә кулланганда «үсү» төшенчәсенең мәгънәсе нинди? Җәмгыятьнең үсүе нәрсәдә чагыла? Җәмгыять үсешендә социаль революцияләрнең роле нинди?

«Система» төшенчәсе — бүгенге фәндә һәм философиядә төп төшенчәләрнең берсе. Системалылыкның бербөтен, бердәмлек кебек чагылышлары турында борынгы грек философлары ук язганнар. Йөз еллар үткәч, инде Яңа вакыт дәверендә, системалылыкның үзенә күрә бер эталоны итеп фәнни, беренче чиратта теоретик белемне саный башлаганнар. Озакламый системалы якын килү табигый-фәнни белемнең төрле өлкәләрендә: физика, биология, геологиядә һ.б. кулланыла башлый. Җәмгыять турындагы фәнгә дә үтеп керә ул. Тулаем җәмгыять һәм аның аерым яклары үзара бәйләнгән элементлар җыелмасы буларак карала башлый. Шуның белән бергә кайбер сораулар (система буларак, җәмгыятьнең төп компонентлары нинди; әлеге компонентларның элемтәләре характеры нинди; бербөтен буларак, җәмгыятьнең интеграль сыйфатлары нәрсәдә чагыла) бәхәсле булып кала бирә. Аларның кайберләренә без бу параграфта тукталырбыз.

ҖӘМГЫЯТЬКӘ СИСТЕМАЛЫ ЯКЫН КИЛҮ

Без җәмгыятьне социаль мөнәсәбәтләр белән бәйле кешеләр җыелмасы, реаль дөньяның табигатьтән аермалыклы, ләкин аның белән аерылмас бәйләнгән бер өлеше буларак карадык. Социаль-фәлсәфи дәрәҗәдә җәмгыять турындагы белемнәребезне тирәнәйтүче тагын бер мөһим караш — *җәмгыятьне бербөтен система буларак* анализлау бар.

«Система» сүзе (грекчадан) «бөтен», «өлешләрдән төзелгән», «җыелмалык» дигәнне аңлата. Реаль дөньяда күп нәрсәләрнең

система буларак каралуы мөмкин. Дөньяда системалы объектның классик мисалы булып сәгать хезмәт итә ала. Ул һичшиксез бербөтен булып тора, әмма шул ук вакытта күпләгән элементлардан — билгеле бер тәртиптә бер-берсе белән тоташкан һәм әлеге әйбер эшендә үзенең билгеле бер вазыйфасын башкаручы детальләрдән тора. Әлеге бик тә гади модель мисалында без системалы бербөтеннең кайбер үзенчәлекләрен ачыклый алабыз. Беренчедән, аның детальләре бар; икенчедән, бу детальләр фәкать бөтенлек кысаларында гына әһәмияткә ияләр (сәгать механизмының аерым бер детале ватылган шундый ук детальне алыштыру өчен генә ярый); өченчедән, барлык компонентлар билгеле бер ысул белән тоташтырылган; дүртенчедән, бербөтен аның өлешләре суммасыннан зуррак. Соңгы нигезләмәне ачыклыйк. Күз алдына китерик: сәгатьне сүттек тә, барлык детальләрне бергә өеп куйдык ди. Детальләрнең берсе дә югалмаган (бербөтеннең суммасы сакланган), әмма бербөтен — сәгать — юк.

Тагын да катлаулырак системалар табигатьтә очрый. Монда без тагын бер мөһим үзенчәлекне — әлеге системаларның ачыклыгын күрәбез. Алар тышкы мохит белән үзара эш итәләр, шуның йогынтысы астында үзләренең сыйфатларын үзгәртәләр, ләкин үзләренең бөтенлекләрен саклыйлар. Монда мисал булып тере организм гына түгел, ә бербөтен экосистема (океан, урман һ.б.) хезмәт итә ала.

Җәмгыять тә катлаулы ачык система булып тора. Аның яшәвенең табигый шарты — табигый мохит. Иҗтимагый җитештерү вакытында кешеләр, үзләре булдырган эш коралларын кулланып, табигать белән даими үзара бәйләнештә торалар. Мондый бәйләнеш кыска вакытка гына булса да өзелде дип күз алдына китерик. Нәтиҗәдә материаль байлыклар җитештерүгә сәләтсез җәмгыять яшәүдән туктар иде.

Система буларак җәмгыять үзендә күпләгән компонентларны туплый. Философлар һәм галимнәр аларны бергәлекләре дәрәҗәләре, башкарган вазыйфалары һәм башка критерийлары буенча аерырга һәм классификацияләргә тырышалар.

ҖӘМГЫЯТЬНЕҢ СИСТЕМАЛЫ ТӨЗЕЛЕШЕ

Җәмгыятьнең иң мөһим элементлары инде аның билгеләмәсендә үк ачык күренә; болар — *кешеләр* һәм аларны бәйләп торучы иҗтимагый мөнәсәбәтләр. Кайбер тикшеренүчеләр *әйберләр* һәм *билгеләр* (картиналар, китаплар, ягъни аларның матди рәвешләрендә рухи мәдәният җимешләре булып торучылар) кебек элементларны аерып күрсәтәләр. Мәкаләне укып, герб сурәтен карап, карашыбызны юл билгесенә юнәлдереп, без

социаль мохитне аңлау, анда дөрес юнәлеш алу өчен кирәкле билгеле бер мәгълүматны «укыйбыз».

Җәмгыятьнең иң төп компонентларының берсе — социаль *институт*. Әлеге төшенчәне җәмгыятьнең гаилә институты мисалында карыйк. Гаилә кору — кешенең төп ихтыяҗларының берсе. Гаилә җәмгыятьтә мөһим вазыйфа башкара: балалар табу һәм тәрбияләү, кече яшьтәгеләр һәм хезмәткә яраксызларга икътисади яктан булышу һ.б. Гаиләнең һәр әгъзасының анда тоткан үз урыны була. Ата-аналар (яки аларның берсе) яшәү өчен средстволар белән тәэмин итәләр, йорт хуҗалыгын алып баралар, балалар белән шөгыльләнәләр. Балалар укый, өйдә булыша. Мондый тәртип гаилә эчендәге кагыйдәләр белән генә түгел, ә иҗтимагый нормалар, традицияләр, хокук, әхлак белән җайга салына. Мәсәлән, иҗтимагый әхлак гаиләдәге өлкән кешеләрнең кечкенәләр турында кайгыртмавын гаепли. Законда ир белән хатынның бер-берсенә, балаларга, балигъ булган балаларның өлкән яшьтәге ата-аналарына карата җаваплылыгы һәм бурычлары беркетелә. Гаилә кору, гаилә тормышының төп этаплары җәмгыятьтә урнашкан йолалар белән бергә бара. Мәсәлән, күп кенә илләрдә никах йоласына өйләнешүчеләрнең никах балдагы алышуы кирә.

Шулай итеп, социаль институтны эшчәнлекләре конкрет иҗтимагый вазыйфаларны үтәүгә юнәлдерелгән һәм билгеле бер норма, кагыйдә, үз-үзеңне тоту стандартлары нигезендә корылган кешеләр, төркемнәр, оешмаларның тотрыклы җыелмасы итеп карап була.

Гаиләдән тыш җәмгыятьнең төп институтларына дәүләт, мәктәп керә.

Иҗтимагый институтлар сәясәттә, икътисадта, мәдәнияттә дә бар. Алар җәмгыятьне тагын да тотрыклырак итәләр.

Шул рәвешле, җәмгыять төзелешендәге элементлар белән бергә, катлаулы составка ия тагын да эрерәк компонентларны — иҗтимагый институтларны, шулай ук җәмгыятьнең тормыш өлкәләрен аерып күрсәтергә була. Институтлар турында сүз алдарак булды. Җәмгыятьне тәшкил итүче системалар буларак, аның төп өлкәләре характеристикаларына тукталыйк.

ҖӘМГЫЯТЬНЕҢ АССИСТЕМАЛАРЫ БУЛАРАК ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШ ӨЛКӘЛӘРЕ

Иҗтимагый тормышның кайсы өлкәләрен аерып карау мәсьәләсендә тикшеренүчеләрдә бердәмлек юк. Кайберәүләр җәмгыятьне бары тик ике өлкәгә — матдигә һәм рухига гына аералар; беренчесенә — икътисадны һәм җитештерүне, икенчесенә фәнне һәм мәдәниятне кертәләр. Җәмгыять тормышын икътисади, рухи, социаль һәм сәяси өлкәләргә аеру киңрәк

таралган. Кайбер авторларның бу рәтне гаилә-көнкүреш өлкәсе белән тулыландырырга тырышуы каршылыклар тудыра: тормышта бу өлкәнең зур әһәмияткә ия булуына карамастан, җәмгыятьнең нигез структураларын чагылдыручы башка ассистемалары белән чагыштырганда, ул җәмгыятьнең конкретрак кисемен гәүдәләндерә.

Өлкәләрнең һәрберсе иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең һәм социаль институтларның билгеле бер даирәсен колачлый, җәмгыять башкарырга тиешле теге яки бу функцияләргә туры килә.

Икътисади өлкә матди байлыкларны җитештерү, бүлү, алмашу һәм куллану белән бәйле мөнәсәбәтләрне колачлый. Монда мөһим функция — җәмгыятьнең система буларак тышкы табигый мохит белән үзара эш итүе, аңа яраклашуы (адаптациясе) һәм аны үзгәртүе.

Социаль өлкәгә төрле социаль бергәлекләр һәм төркемнәр арасындагы мөнәсәбәтләр керә. Ул төрле төркемнәрнең мәнфәгатьләрен үзара бәйләү һәм исәпкә алу нигезендә җәмгыятьне берләштерергә, интеграцияләргә тиеш.

Сәяси өлкәне гражданлык җәмгыяте, сәяси төркемнәр һәм дәүләт мөнәсәбәтләре барлыкка китерә. Сәяси өлкәнең бурычы — җитәкчелекне һәм идарә итүне тормышка ашыру.

Рухи өлкә рухи кыйммәтләрне булдыру, тарату, саклау һәм үзләштерү процессында барлыкка килгән мөнәсәбәтләрне колачлый. Аның аша җәмгыятьнең билгеле бер кыйммәтләрне, кеше яшәеше нормаларын саклау кебек мөһим бурычлары тормышка ашырыла.

Җәмгыять тормышы өлкәләре, бердәм системаның өлешләре буларак, үзара нык бәйләнгән; берсендәге үзгәрешләр, кагыйдә буларак, икенчесендә үзгәрешләр китереп чыгара.

Иҗтимагый өлкәләрнең үзара йогынтысын аерым мисалларда карыйк. Бүгенге дөньяда массакүләм мәдәнияттә бик тә киң таралган күренешкә мөрәҗәгать итик. Аның продуктлары — реклама, поп-музыка, телевидениедәге мавыктыргыч тапшырулар һ.б. белән бүген һәркем диярлек таныш. Ләкин җәмгыять массакүләм мәдәниятне белмәгән вакытлар да булган. XIX—XX гасыр чикләрендә, бу феномен барлыкка килсен өчен, тормышның төрле өлкәләрендә (мәдәниятнең үзен дә кертеп) үзгәрешләр булырга тиеш булган. Икътисад өлкәсендә — массакүләм җитештерүгә, аны стандартлаштыруга күчү; эшче һәм хезмәткәрләрнең түләү сәләте булган ихтыяҗын күтәрү; алга таба — сәнгать әсәрләрен тиражлау мөмкинлеге тудыручы техник чараларның барлыкка килүе. Социаль өлкәдә — шәһәр халкының нык артуы, хезмәткәрләрнең күпчелек өлешендә ял (эштән буш вакыт) барлыкка килү. Алга киткән илләр мәдәният өлкәсендә белем бирүгә, барыннан да

әлек башлангыч белем бирүгә юнәлдерелгән мөһим адымнар ясыйлар. Мәсәлән, XIX гасырның 70 нче елларында Бөекбританиядә 5–12 яшьтәге балаларны мәҗбүри укыту кертелә, гасыр ахырында башлангыч мәктәпләрдә укыган өчен түләү бетерелә. Түбән сыйныфларда ял, минималь кирәктән күбрәк кайбер средстволар барлыкка килүгә, укымышлыларның саны артуга, бертөрле эштән соң бушану, ял итү теләгенә базар «типовой» мәдәни продукт: китаплар, фильмнар, граммофон пластинкалары һ.б. тәкъдим итеп җавап бирә.

Җәмгыять тормышы өлкәләре арасында өстенлекле, булачак трансформацияләргә үзенчә беренче этәргеч бирүче бармы? Бу сорау бәхәсле булып кала бирә. Җәмгыятьне үстерүдә икътисадның, җитештерү мөнәсәбәтләренең өстенлеге турындагы идея җентекләбрәк К.Маркс тарафыннан эшләнә. Инде белгәнегезчә, аның тәгълиматлары буенча, җитештерүдәге милеккә мөнәсәбәтләрдәге үзгәрешләр тормышның башка өлкәләрендә зур үзгәрешләр китереп чыгара: «Матди тормышны җитештерү ысулы җәмгыять тормышындагы социаль, сәяси һәм рухи процессларның нигезе булып тора».

Әлеге тезис күп яктан дөрес. Массакүләм мәдәниятнең барлыкка килүе мисалында ук инде без матди җитештерүдәге үзгәрешләрнең, техник казанышларның һәм җәмгыятьтәге базар мөнәсәбәтләренең бу процесска сизелерлек йогынты ясавын күрдек. Шуның белән бергә, әлеге мисал безгә башка: социаль, рухи, сәяси (хакимиятләрнең белем бирү сәясәте) факторларның да ролен күрсәтә.

Шунлыктан тикшеренүчеләрнең күпчелеге бүген иҗтимагый күренешләрне тикшергәндә күп кенә факторларны исәпкә алырга кирәк, һәм алар арасында хәлиткече һәрвакытта да икътисади булмас дип саныйлар. Үз чиратында, икътисади процесслар җәмгыятьтәге сәяси, социаль һәм рухи үзгәрешләрне тоймый кала алмыйлар. Моны узган гасыр башында немец социологы М.Вебер яхшы күрсәткән. Капитализмның икътисади система буларак тууын тикшереп, ул җәмгыятьнең билгеле бер өлешендә — протестантлык карашларына күчкән кешеләрдә — рухи кыйммәтләрнең үзгәрүе уйнаган рольгә игътибар иткән. Аның фикеренчә, нәкъ менә байлыкка, эшлекле уңышка әхлакый аклану биргән протестантизм эшмәкәрлек эшчәнлегенең — капиталистик икътисад «моторы»ның киң үсеш алуы өчен мөмкинлекләр ачкан.

ҮЗГӘРҮЧӘНЛЕК ҺӘМ ТОТРЫКЛЫЛЫК

Галимнәр җәмгыятьне *үзлегеннән үсүче системаларга* кертәләр.

Тарих дәресләрендә сез вакытлар үтү белән социаль институтларның, кешеләрнең яшәү образы үзгәрүенә, технологияләрнең камилләшүенә, иҗтимагый төзелеш формаларының катлаулануына, боларның исә чыганаклары үзендә булган җәмгыятьнең үсүен дәлилләвенә күп тапкырлар ышандыгыз.

Үзгәрешләрнең тизлеге, тирәнлеге төрлечә бәяләнә. Күпләгән философлар, социолог, тарихчылар *эволюцион үсеш* идеясен яклыйлар. Тере табигатькә кулланылышта ул Ч.Дарвин хезмәтләрендә нигезләнү тапты, аннары җәмгыятьнең үсеше турындагы өйрәтүләрдә ныгытылды. Эволюционизм яклылар үзгәрешләрнең даимилегенә, җәмгыятьнең төрле яклары үсешендәге күчүчәнлеккә басым ясап күрсәттеләр, традицияләрнең әһәмиятенә игътибар иттеләр. Биологиядәге кебек үк, үсү кирегә кайтмый торган булып исәпләнде.

Җәмгыятьтәге күпләгән үзгәрешләрнең күчүчәнлек, эволюцион характерда икәнен инкарь итәргә туры килми. Шуның белән бергә, җәмгыять белән табигать арасында туры охшашлыклар үткәрү иҗтимагый күренешләрнең үзенчәлеген аңлау мөмкинлеге бирми. Мәсәлән, үзгәрешләрнең кирегә кайтмаслыгы турындагы нигезләмәне җәмгыятькә карата тулы килеш үк кулланып булмыйдыр. Тарих түбәнгә тәгәрәү, төшү, оештыруның тагын да гадирәк формаларына кайту мисалларын белә (шундый фактларны исегезгә төшерегез). Кайбер очракларда гадирәк структураларга кайту яшәп калу өчен гарантия булып хезмәт итә: авыр сугыш елларында кешеләргә яшәп калырга җылысыз һәм утсыз шәһәр квартиралары түгел, ә нәкъ менә мич, кое һәм үз бакчалары ярдәм итте.

Марксизм тарафдарлары проблемага башкача карашны якладылар. Әлеге тәгълимат өйрәткәнчә, җәмгыятьне яңартып коруда төп рольне социаль революцияләр уйный. Нәкъ менә шуларны Маркс «тарих локомотивлары» дип атый. Аның фикеренчә, революциянең чыганаклары үтеп баручы икътисади стройны гәүдәләндерүче социаль көчләрнең яңа тәртипләр булдыру белән кызыксынган сыйныфлар белән килештерелә алмаслык каршы торуында ята. Революция барышында алдынгы сыйныф реакцион сыйныфны бәреп төшерә, хакимиятне үз кулына ала һәм җәмгыять тормышының барлык өлкәләрендә өлгергән үзгәрешләрне гамәлгә ашыра.

Теория шактый абстракт, ләкин революцияләр үзләре, тарих курсыннан белгәнегезчә, бик тә чын вакыйгалар; алар күп кенә илләрдә булды һәм еш кына урнашкан тәртипләрне тамырдан үзгәрттеләр. Кайбер революцияләрне «бөек» дип атаулары очраклы түгел (кайсыларын икәнен исегезгә төшерегез). Шулай да, гәрчә үзгәрешләр зур булса да, алар җәмгыятьнең киң кат-

лаулары мәнфәгатьләренә һәрвакытта да җавап бирә алмады, еш кына революционерларның үз карашларына да каршы килделәр. Революцион гамәлләр һәм яңа хакимиятләр сәясәте кайчак җәмгыятьтә инде булган күп кенә кыенлыкларны көчәйтәләр.

Тарих курсыннан белгәнегезчә, революцияләрнең иң биек ноктасы (кульминациясе) еш кына үзенең рәхимсезлеге белән элеккеге режимнарны да арттырып җибәргән диктатуралар урнаштыру булды. Социаль революциянең бу сыйфатлары тарихчыларны һәм социологларны — аларның тарихтагы ролен уңай бәяләүгә саграк килергә, ә сәясәтчеләрне, революцияләргә өндәсәләр дә, «бәрхетле», гражданнар сугышы һәм лидерларның диктаторлык кыланулары булмаганнарына гына өндәргә мәҗбүр иттеләр.

Иҗтимагый үзгәрешләрнең күренеп торган закончалыкларының берсе соңгы ике-өч гасырда аларның темпы арту булды. Бүгенге инглиз тарихчысы сүзләре белән әйткәндә, XVIII гасыр уртасында яшәгән инглиз кешесе матди яктан үз оныкларына караганда Цезарь легионерларына якынрак торган.

Социологлар социаль үзгәрешләрнең тизләнү тенденциясен түбәндәге исәп-хисап белән күрсәтәләр: әгәр кешелек дөньясы яшәвенең соңгы 50 мең елын һәрберсенең тормыш озынлыгы якынча 62 яшь булган буыннар саны белән санасаң, андый буын 800 килеп чыга. Шуларның 650 се гомерләрен мәгарәләрдә яшәп үткәргән. Язуны соңгы 70 е куллана. Соңгы буыннарның 6 сы гына басма сүз куллану мөмкинлеге алды. Фәкать соңгы дүрт буын гомерендә генә кешеләр вакытны шактый дөрес үлчи башладылар. Сез бүген көндәлек тормышта куллана торган әйберләрнең иң зур күпчелеге узган гасыр уртасыннан да элегрәк эшләнмәгән.

Үзгәрешләр яшәү рәвешен генә түгел, кешеләрнең фикерләү рәвешен: аларның карашларын, нәрсәләргә өстенлек бирүен, тиешле булганнар турындагы күзаллауларын да колачлый. Шуның белән бергә, кайбер кыйммәтләр үз әһәмиятләрен бүгенге дөньяда да саклый. Мәсәлән, гаиләне, аның формалары үзгәрүгә карамастан, дөньядагы миллионнарча кешеләр элеккечә үк үз тормышларындагы иң мөһим кыйммәт дип саныйлар. Күпләгән кешеләр меңнәрчә еллар элек барлыкка килгән динне тоталар.

Шулай да иҗтимагый тормышның күп яклары бик тиз үзгәрә. Әлеге үзгәрешләрнең билгеле бер юнәлеше бармы? Бу сорауга җавап бирүгә алдагы параграф багышлана.

Төп төшенчәләр: система буларак җәмгыять; иҗтимагый институт, җәмгыять тормышы өлкәсе.

Үзегезне тикшерегез

1. Җәмгыять система булып тора дип расларга нәрсә мөмкинлек бирә? 2. Система буларак җәмгыятьнең иң мөһим компонентлары нинди? 3. Нәрсә ул иҗтимагый институт? Җәмгыятьнең төп институтларын атагыз. 4. Җәмгыять тормышының төп өлкәләрен атагыз һәм тасвирлагыз. 5. Иҗтимагый мөнәсәбәтләр, институтлар һәм җәмгыять тормышы өлкәләре үзара ничек бәйләнгән? Бу бәйләнешне мисаллар белән сурәтләп күрсәтегез. 6. Җәмгыять тормышының төрле өлкәләре элемтәсен чагылдыручы мисаллар китерегез. 7. Эволюцион якын килү яклылар җәмгыять үсешенең кайсы сыйфатларын аерып күрсәтәләр? 8. Иҗтимагый үсешнең сикерешлелеге нинди формада чагылдырыла? 9. Җәмгыять үсешендә революцияләрнең ролен бәяләүләр ничек һәм ни өчен үзгәргән? 10. Соңгы вакытта иҗтимагый үсеш темпының тизләнүен нәрсә дәлилли?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Бу параграфта китерелгән нигезләмәләргә, шулай ук башка предметлардан алган белемнәрегезгә таянып, түбәндә китерелгән характеристикалардан теләсә кайсы системаның сыйфатларын чагылдыручыларын сайлап алыгыз: вакытлар үтү белән үз халәтен үзгәрешсез саклау; хәзерге халәт аннан соңгысын төгәл билгеләү мөмкинлеге бирә; тышкы мохит белән даими рәвештә әйберләр алмашу; үзара бәйләнешле элементлар булу; бербөтеннең өлешләр суммасына туры килмәве, бербөтендә аерым компонентларда булмаган сыйфатлар барлыкка килү.

2. Иҗтимагый институтларны һәм җәмгыять тормышы өлкәләрен чагыштырыгыз.

Институтлар

а) дәүләт
б) гаилә
в) мәктәп
г) чиркәү
д) финанс системасы
е) массакүләм мәгълүмат

Өлкәләр

а) икътисади даирә
б) сәяси даирә
в) социаль даирә
г) рухи даирә

Саналган институтлар арасында сез иҗтимагый тормышның берничә даирәсенә кертергә теләгәннәре бармы? Аларны атагыз. Җәмгыять даирәләренең һәм институтларның катгый тәңгәллеге булмауны нәрсә белән аңлатырга мөмкин?

3. Таблицаны тутырыгыз.

Җәмгыятьнең төп ассистемалары

Җәмгыять өлкәләре	Кешеләрнең эшчәнлеге һәм үзара мөнәсәбәтләре	Төп учреждениеләр (оешмалар)
Сәяси даирә		
Икътисади даирә		
Социаль даирә		

4. Тарихчы һәм публицист М.И.Туган-Барановский болай дип яза: «Мәскәүнең сәяси өстенлеге шуңа нигезләнә: Мәскәү сәнәгате турыдан-туры күпчелек Мәскәүдә тупланган сәүдә капиталына буйсынган гаять зур крайның сәүдә үзәге була. Сәүдә сыйныфы җир дворяннарыннан соң борынгы Русьның иң йогынтылы сыйныфы була».

Бу характеристикада җәмгыять тормышының кайсы даирәләре бәйләнешен күреп була?

5. Социологларның берсенең фикеренчә, җәмгыять таралудан — бөтенлеккә, бертөрлелелектән күптөрлелеккә бара, эзлекле төстә үсешнең билгеле бер стадияләрен үтә. Аларның һәрберсе аннан алдагысы үз мөмкинлекләрен бетергәч кенә ныгып урнаша.

Китерелгән раслауларга таянып, сез «автор иҗтимагый үсешнең эволюцион моделе яклы» дигән нәтиҗә ясый аласызмы? Юк икән, сезгә нинди белемнәр җитми?

Чыганак белән эшләгез

Илебезнең бүгенге философы К.Х.Момджян китабыннан өзек укыгыз.

Җәмгыять, сыйфат аныклыгын саклап, үзгәрергә сәләтле.

... Җәмгыять бер-берсеннән сыйфат ягыннан аерылып торган күпләгән күренешләрне колачлый һәм шул ук вакытта икътисади, сәяси, хокукый яки эстетик тормышның аерым алынган суммасына китерелә алмый торган законнарга ия.

Бу исә политологиягә, сәнгать белеменә һәм башка махсус даирәләргә билгеле булган мәгълүматны механик кушу безгә җәмгыять турында җитәрлек мәгълүматлар бирми дигәнне аңлата. Әгәр кешеләрнең бергә яшәвен бөтен чын катлаулылыгында аңларга теләсәк, безгә аны билгеле бер өлешләрдән торучы, әмма аларга кайтып калмаучы системалыербөтен итеп карарга кирәк.

Җәмгыять ... үзенең сыйфат билгелелеген саклап, иң нык сизелерлек дәрәҗәдә аның хәлен үзгәртергә сәләтле үзеннән-үзе үсүче системалар исәбенә керә. XVI гасырдагы Японияне XX гасыр Япониясе белән чагыштырып, без кешеләрнең яшәү

рәвешендәге колачы буенча искитмәле аермалы төрле планеталарда булдык дип күзаллый алабыз.

Шуңа да карамастан, сүз ... үзенең тарихи үсешенең төрле, бүгенгесе үткәннән килеп чыккан һәм бүгенгесендә киләчәкнең мөһим яралгылары булган этапларындагы халык турында бара.

Әлбәттә, кайбер теоретиклар кебек, урта гасыр Япониясе дөньякүләм бергәлек лидерларының берсе булган бүгенге Кояш Чыгышы Иленә караганда феодаль Франциягә күбрәк охшаган дип расларга була. Ләкин бу илнең атамасы, географик урнашуы һәм аралашу теле белән генә түгел, ә бәлки мәдәниятнең милли менталитеты үзенчәлекләре кабатланган (аерым алганда, коллективизм, японнарның хәзерге уңышка ирешүләрендә төп сәбәпләрнең берсе булган бурыч һәм тәртип) тотрыклы стереотиплары белән дә бәйле бербөтен тарихын бүлгәләргә җирлек бирми.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Иҗтимагый фәннәрнең төрлесеннән алынган белемнәр нишләп җәмгыятьне аңлау өчен җитми? Мондый аңлауга нинди шартларда ирешеп була? 2. Автор карашынча, кешеләрнең яшәү рәвешендә бик тә зур үзгәрешләр булганда да халыкка бөтенлеген сакларга нәрсә ярдәм итә? 3. Бөтенлекне юкка чыгаручы үзгәрешләрнең булуы мөмкинме? Үз фикерегезне әйтегез. Аны мисаллар белән ныгытыгыз.

§ 11–12. Җәмгыятьләр типологиясе

Исегезгә төшерегез:

җәмгыятьне тикшерүнең төп дәрәҗәләре нинди? Тарихи-типологик дәрәҗә нәрсәсе белән характерлана? Иҗтимагый үсешкә цивилизацияле якын килүнең асылы нәрсәдә? Индустриаль җәмгыять кайчан барлыкка килгән? Үзенең үсешендә ул нинди этаплар узган?

Бүгенге тикшеренүчеләр җәмгыятьнең төп өч тарихи тибын аерып күрсәтәләр: традицион (аграр), индустриаль (капиталистик) һәм постиндустриаль (мәгълүмати) җәмгыять. Беренче икесе акрынлап барлыкка килгән, озак тарихи чорлар дәвамында яшәгән һәм төрле илләрдә үзенчәлекле мәдәни сыйфатлар алган. Шулай да җәмгыятьнең һәр тарихи тибының гомуми (типологик) характеристикалары бар, алар буенча кешеләрнең теге яки бу социомәдәни бергәлеген җәмгыятьнең билгеле бер тарихи тибына кертәләр. Галимнәр теге яки бу җәмгыятьне билгеле бер типтагы цивилизациягә кертү мөмкинлеге бирә торган нинди сыйфатларны төп билгеләр итеп алырга

кирәклеге мәсьәләсен тикшерәләр. Күпчелек тикшеренүчеләр хәлиткеч роль уйнаучыларга түбәндәгеләрне кертәләр:

— кешеләрнең табигатькә (шулай ук кеше тарафыннан үзгәртелгән табигый мохиткә) мөнәсәбәте;

— кешеләрнең бер-берсенә мөнәсәбәте (социаль элемтә тибы);

— яшәеш кыйммәтләре һәм тормыш мәгънәләре системасы (бу — мөнәсәбәтләрнең җәмгыятьнең рухи тормышында гомумиләштерелгән чагылышы).

ТРАДИЦИОН ҖӘМГЫЯТЬ

Традицион җәмгыять төшенчәсе Ерак Көнчыгышның аграр цивилизацияләрен (Борынгы Һиндстан һәм Борынгы Кытай, Борынгы Мисыр һәм мөселман Шәрыгының Урта гасырлар дәүләтләре), Урта гасырлардагы Европа дәүләтләрен үз эченә ала. Азия һәм Африканың кайбер илләрендә традицион җәмгыять бүген дә саклана, ләкин хәзерге Көнбатыш цивилизациясе белән очрашуы аның цивилизацион характеристикаларын сизелерлек үзгәртте.

Кешенең тормыш эшчәнлегенең нигезе — хезмәт, аның ярдәмендә кеше табигать әйберләрен һәм энергиясен үзе куллана торган предметларга әверелдерә. Традицион җәмгыятьтә тормыш эшчәнлегенең нигезен җир эшкәртү хезмәте тәшкил итә, аның нәтиҗәләре кешегә яшәү өчен кирәкле бар нәрсәне бирә. Ләкин гади кораллар ярдәмендә һәм кулдан башкарылган авыл хуҗалыгы хезмәте кешене иң кирәкле нәрсәләр белән генә тәэмин итә, анысы да әле һава шартлары әйбәт булганда гына. Урта гасырлар Европасының өч «кара җайдак» котын ала — ачлык, сугыш һәм чума. Ачлык — иң рәхимсезе, аннан качу урыны юк. Ул Европа халыкларының мәдәни йөзендә тирән яралар калдыра. Аның кайтавазлары фольклор һәм эпосларда, халык җырларының ыңгырашулы сузынкылыгында ишетелә. Халык сынамышларының күпчелеге — һава торышы һәм булачак уңыш турында. Традицион җәмгыять кешесенең табигатькә бәйлелеге «җир-туендыручы», «җир-ана» кебек табигатькә аннан кирәгеннән артыгын алырга ярамаган яшәү чыганагы итеп, яратып, сак карауны белдергән чагыштыруларда әйтелә.

Җир эшкәртүче кеше табигатьне үзенә әхлаклы мөнәсәбәт таләп итүче җанлы зат итеп кабул иткән. Шуңа күрә дә традицион җәмгыять кешесе — табигатьнең әфәндесе дә, буйсындыручысы да, патшасы да түгел. Ул бөек космик бөтенлекнең, галәмнең кечкенә генә бер бөртеге (микрокосмы). Аның хезмәт эшчәнлеге табигатьнең мәңгелек ритмына (һаваның сезонлы үзгәреп торуына, көн яктылыгының озынлыгына) буйсын-

дырыла — табигыйлек һәм социальлелек чигендә яшәү таләпләре шундый. Борынгы кытай мәсәле табигать ритмнарына нигезләнгән традицион агримәдәният белән бәхәскә керергә җөрьәт иткән игенчедән көлә: башакларның үсүен тизләтергә тырышып, ул аларның башларыннан тарта һәм тамырлары белән үк тартып чыгара.

Кешенең эш коралына мөнәсәбәте аның башка берәүгә мөнәсәбәтен чагылдыра. Эшләгәндә яки кулланганда әлеге предметны үзләштереп, кеше милекчелекнең һәм бүлүнең иҗтимагый мөнәсәбәтләре системасына кушыла. Урта гасырлар Европасы феодаль җәмгыятендә җиргә шәхси милек — аграр цивилизацияләрнең төп байлыгы өстенлек итә. «Шәхси бәйлелек» дип аталган социаль буйсыну тибы да аңа туры килә. Шәхси бәйлелек төшенчәсе феодаль җәмгыятьнең төрле социаль сыйфатларына — «феодаль баскыч» басмаларына кергән кешеләрнең социаль элемтәсе тибын характерлый. Европадагы феодаль сеньор һәм Азия деспоты үзләренә буйсынган кешеләрнең җаннарының да, тәннәренең дә тулы хокуклы хуҗалары булганнар, хәтта аларны милек итеп тотканнар. Крепостнойлык хокукын бетергәнгә кадәр Россиядә дә шулай булган. Шәхси бәйлелек, көчләүгә нигезләнгән шәхси хакимият аша *хезмәткә икътисадтан тыш мәҗбүр итү* тудыра.

Традицион җәмгыять тышкы икътисади мәҗбүр итү нигезендә хезмәтне эксплуатацияләүгә каршы тору формаларын: әфәндегә эшләүдән (барщина), натуралата (оброк) яки акчалата салым түләүдән баш тартуны, әфәндедән качып китүне (бу исә традицион җәмгыятьнең нигезен — шәхси бәйлелеккә мөнәсәбәтне җимерә) уйлап таба.

Бер социаль сыйныф яки катлау кешеләре (территориаль-күрше община, герман маркасы крестьяннары, дворяннар җыелышы әгъзалары һ.б.) теләктәшлек, ышаныч һәм коллектив җаваплылык мөнәсәбәтләре белән бәйләналар. Крестьяннар общинасы, шәһәр һөнәрчеләре феодаль йөкләмәләрне бергәләп үтиләр. Община крестьяннары игеннәр уңмаган елларны бергәләп кичерәләр: күршеңә бер телем ипи белән ярдәм итү тормыш нормасы булып санала. Народниклар, үзләренең «халыкка баруларын» сурәтләп, халык характерының кайгы уртаклашу, кумәклек һәм үз-үзеңне корбан итәргә әзер тору кебек сыйфатларын күрсәтәләр. Традицион җәмгыять кешелек дөньясының цивилизацияле казанышлары хәзинәсенә кергән кумәклек, үзара ярдәмләшү һәм социаль җаваплылык кебек югары әхлакый сыйфатлар барлыкка китерә.

Традицион җәмгыять кешесе үзен башкаларга каршы торучы яки көндәш шәхес итеп тоймый. Киресенчә, ул үзен үз авылы, общинасы, полисының (шәһәр-дәүләтенең) аерылмас бер

өлеше итеп саный. Немец социологы М.Вебер шәһәргә килеп урнашкан кытай крестьянының авыл чиркәү общинасы белән элемтәләрен өзмәвен, ә Борынгы Грециядә полистан куылуны гомумән дә үлем җәзасына тиңләүләрен билгеләп үтә. Борынгы Шәрык кешесе үзен тулысынча социаль төркем тормышы стандартларына багышлый, аларда «эри». Традицияләрне саклау элек-электән борынгы кытай гуманизмының төп кыйммәте булып саналган.

Традицион җәмгыятьтә кешенең социаль статусы шәхси уңышлары белән түгел, ә социаль чыгышы белән билгеләнгән. Традицион җәмгыятьтәге сыйныф-катлау киртәләренең катгыйлыгы аны бөтен гомере буена үзгәрешсез итеп саклаган. Халыкта хәзер дә «маңгаена язылган» диләр. Традиционлык аңына хас булган, язмыштан узмыш юк дигән күзаллау иҗади тырышлыклары тормышны үзгәртүгә түгел, ә рухи чистарынуга юнәлтелгән читтән торып күзәтүче шәхес тибын барлыкка китерә. И.А.Гончаров И.И.Обломов образында шундый психологик типны искитмәле алдан күрүчәнлек белән тасвирлый. «Язмыш», ягъни социаль тәкъдир — алдан билгеләнеп куелган — борынгы грек традицияләренең төп метафорасы булып тора. Софоклның «Эдип патша» трагедиясендә геройның үзенә билгеләнгән коточкыч язмыш-тәкъдирдән качу өчен титаникча көч куюы, ләкин, шуңа да карамастан, явыз язмышның тантанасы турында бәян ителә.

Традицион җәмгыятьнең көндәлек тормышы искитмәле тотрыклылыгы белән аерылып торган. Тормыш законнар белән түгел, күбрәк *традицияләр* — эшчәнлекнең, үз-үзеңне тотуның һәм аралашуның ата-бабалар тәҗрибәсен гәүдәләндерүче язылмаган кагыйдәләре һәм үрнәкләре белән җайга салынган. Традиональлек аңында «алтын гасыр» инде артта калды, ә аллалар һәм геройлар без кабатларга тиешле эшләр һәм батырлыклар үрнәкләре калдырдылар дип исәпләнелә. Кешеләрнең социаль гадәтләре күп буыннар дәвамында үзгәрми диярлек. Көнкүрешне оештыру, хуҗалыкны алып бару ысуллары һәм аралашу нормалары, бәйрәм йолалары, авыру һәм үлү турында күзаллаулар, кыскасы, без «көндәлек тормыш» дип атаган бар нәрсә гаиләдә тәрбияләнә һәм буыннан буынга тапшырыла. Кешеләрнең күп буыннары шул ук социаль структураларны, эшчәнлек ысулларын һәм социаль күнекмәләрне очраталар. Торгынлыклы-патриархаль тормышлы, иҗтимагый үсеш темплары бик тә акрын булган традицион җәмгыятьләрнең югары тотрыклылыгы традицияләргә буйсыну белән аңлатыла.

Күпләре (бигрәк тә Борынгы Шәрыкта) гасырлар дәвамында үзгәрешсез диярлек калган традицион җәмгыятьләр тотрык-

лылыгына югары хакимиятнең халык алдындагы абруе да ярдәм иткән. Еш кына ул турыдан-туры король шәхесе белән тиңләштерелгән («Дәүләт ул — мин»). Гәрчә тарихка дәүләт башлыгының чиркәү башлыгы да булу очрагы аз билгеле булса да (Англия чиркәве), җир хакименең мондый абруен аның хакимиятенең күктән иңдерелүе турындагы дини күзаллаулар да арттыра («Дәүләт — Ходайның җирдәге вәкиле»). Сәяси һәм дини хакимиятнең бер кешедә гәүдәләнүе (теократия) кешенең дәүләткә дә, чиркәүгә дә икеләтә буйсынуын тәэмин итә, бу исә традицион җәмгыятькә тагын да зуррак тотрыклылык бирә.

ИНДУСТРИАЛЬ ҖӘМГЫЯТЬНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ

Соңгырак чор Урта гасырлар икътисади, сәяси һәм мәдәни тормышындагы тирән үзгәрешләр яңа типтагы цивилизацияле үсеш — индустриаль (капиталистик) җәмгыять өчен алшартлар тудыралар. Алар исәбенә Ходай образында һәм аңа охшатып яратылган кешене актив һәм эшлекле җан иясе итеп аңлауны, шулай ук Мәгърифәт дәверендә формалашкан галәмнең иң тирән серләренә үтеп керергә сәләтле кеше акылы культын кертергә була. Галимнәр индустриаль җәмгыятьнең барлыкка килүендә нинди сәбәпләрнең хәлиткеч роль уйнавы турында бәхәсләшүләрен дәвам иттерәләр. К.Маркс капитализмның барлыкка килүенең төп сәбәбе итеп *житештерүче көчләрнең* үсүен күрә. «Кул тегермәне безгә — башында сюзерен[1] торган җәмгыять, пар тегермәне — капиталистлы җәмгыять бирә» дип раслый ул. Белгәнегезчә, марксистик тәгълимат буенча, даими үсә баручы иҗтимагый житештерүче көчләр *житештерү мөнәсәбәтләренең*, ягъни шәхси милек һәм бүлү мөнәсәбәтләренең урнашкан формалары белән каршылыкка киләләр. Шул чакта иске житештерү мөнәсәбәтләрен җимерүче һәм яңа, житештерү көчләренең үсеш дәрәҗәсенең житештерү мөнәсәбәтләре характерына тарихи үзгәрүчән туры килүен урнаштыручы социаль революция дәвере башлана.

М.Вебер «капитализм рухының» мәдәни чыганакларын *Реформациядә*, ягъни традицион христианлыкны реформалауда күрә. Католицизмнан аермалы буларак, христиан диненең яңа тармагы — протестантизм яклылар, фәкать профессиональ эшчәнлектәге уңышлар гына кешенең котылуга, үлгәннән соң мәңгелек рәхәтлеккә сайлануына шаһит була ала дип уйлыйлар. М.Вебер фикеренчә, комсыз булмау һәм намуслы ярлылык яклы, традиционалистик идеалларга кискен каршы килүче житештерүчән хезмәт культы хас булган протестант этика-

---

[1] *Сюзерен* — иң югары хаким (тәрҗ. иск).

сының киң таралуы Европада капитализм барлыкка килүдә хәлиткеч роль уйный.

Капитализмның мәдәни чыганаклары турында сөйләп, М.Вебер табыш китерә торган җитештерүчән хезмәт белән котылгысыз комсызлык, теләсә нинди юл белән баерга омтылу арасында мөһим фәнни аерма үткәрә. Продуктив капитализм спекуляциягә, ростовщиклыкка (процентка акча биреп торуга), ришвәтләргә, комарлы уеннарда отуга, сугышларга, диңгездә һәм колонияләрне талауга корылган иррациональ омтылышны кире кага, дип басым ясап әйтә ул. Цивилизацияле капитализм профессиональ намуслылыкка, катгый бухгалтерия исәп-хисабына, капитал белән шәхси милекне аеруга нигезләнә.

Француз тарихчысы Ф.Бродель капитализмның алшартларын ерак араларда сәүдә итүдә күрә. Андый сәүдә итү Урта диңгез буе шәһәрләрендә әле XI–XII гасырларда ук барлыкка килә. Диңгез сәүдәсенең беренче зур үзәкләре, чиратлашып, Урта диңгез буе шәһәрләре Амальфи, Генуя һәм Венеция булалар. Ерак араларга барып сәүдә итү авыл хуҗалыгына караганда шактый табышлырак була. Зур акча средстволары диңгез буе шәһәрләрендә кала. Кул хезмәтенең беренчел продуктларын эшкәртү буенча (тупас постауны эшкәртү, тире иләү, шәраб ясау) беренче сәнәгать предприятиеләре шуларда барлыкка килә дә. Ф.Бродель, эре диңгез сәүдәсе үзәкләренең (Греция, Венеция, Антверпен, Амстердам, Лондон, Нью-Йорк) алышынуы белән бергә, яңа индустриаль цивилизация үзәгенең туктаусыз рәвештә көньяктан төньякка күчә баруын күрсәтә. Индустриаль җәмгыять — шәһәрләшкән, зур шәһәрләр чәчәк аткан җәмгыять ул.

Санап үтелгән барлык социаль процесслар (иҗтимагый җитештерү көчләре үсү, җитештерүче хезмәт культы, протестант этикасы таралу, ерак араларга барып сәүдә итү) капитализмның барлыкка килүенә һәм үсүенә үз өлешләрен кертәләр. Шунлыктан, китерелгән аңлатмаларның һәрберсе, әлеге бик тә катлаулы цивилизацияле үзгәрешнең — индустриаль җәмгыять барлыкка килүнең аерым якларын чагылдырып, «хакыйкать мизгеле»нә ия.

ТЕХНОГЕН ЦИВИЛИЗАЦИЯ БУЛАРАК ИНДУСТРИАЛЬ ҖӘМГЫЯТЬ

Индустриаль җәмгыять — табигать мохитен, иҗтимагый мөнәсәбәтләр формаларын һәм кешенең үзен тизләтеп үзгәртүгә нигезләнгән иҗтимагый үсеш тибы. Индустриаль җәмгыятьнең туктаусыз үсүе кеше эшчәнлеге даирәләренең киңәюенә, *сәнәгать җитештерүе* барлыкка килүгә генә түгел, аның нигезләрен үзгәртеп коруга, традицион яшәеш кыйммәтләренең

һәм тормыш мәгънәләренең төптән үзгәрүенә дә бәйле. Традицион җәмгыятьтә теләсә нинди яңалык традицияләр артына яшеренсә, индустриаль җәмгыять регламентлаучы традицияләр белән «бәйләп куелмаган» яңаны кыйммәт буларак игълан итә. Бу исә иҗтимагый җитештерүче көчләрнең тарихта күрелмәгәнчә үсүенә булыша.

Индустриаль җәмгыятькә иҗтимагый җитештерүгә фәнни идеяләр кертү нигезендә техниканың туктаусыз үсүе хас. Традицион җәмгыять төп предметка аерым өлешләрне (блок, рычаг, арба) геометрик беркетү принцибында ясалган гади эш кораллары белән канәгатьләнсә, индустриаль җәмгыятькә көчләрнең үзара эшләвенә нигезләнгән техник җайланмалар (пар машиналары, станоклар, эчке янулы двигательләр һ.б.) хас. Катлаулы техника белән җиһазланган эре сәнәгать предприятиеләре барлыкка килү белемле хезмәткәргә социаль сорау тудыра, димәк, белем бирүнең массакүләм системасын үстерүгә булышлык итә. Тимер юллар челтәренең үсүе иҗтимагый һәм мәдәни алмашуларны шактый көчәйтеп кенә калмый, бердәм декрет вакыты кертүне дә таләп итә. Техниканың индустриаль җәмгыять тормышының барлык якларына йогынтысы шундый зур була ки, аны еш кына *техноген цивилизация* дип атыйлар.

Техниканың үсүе кешенең табигать өстеннән хакимлек итүе даирәсен киңәйтеп кенә калмый, иҗтимагый җитештерү системасында кешенең урынын да үзгәртә. Җанлы хезмәт акрынлап көч һәм хәрәкәт вазыйфаларын югалта, контроль-мәгълүматны көчәйтә. XX гасыр ахырында шундый техник системалар (автоматлаштырылган предприятиеләр, космик корабльләр белән идарә итү системалары, атом электр станцияләре) барлыкка килә ки, аларны эшләтү зур осталыкка ия җитештерү күнекмәләре генә түгел, ә фәннең өр-яңа казанышлары нигезендә фундаменталь профессиональ әзерлек таләп итә. Фән рухи мәдәниятнең мөһим өлкәсе генә түгел, ә турыдан-туры җитештерүче көч булып әверелә.

Техникадагы алгарыш җәмгыятьнең җитештерүче көчләрен күтәрүгә һәм кеше тормышының сыйфатын элек күрелмәгән дәрәҗәдә арттыруга булышлык итә. Товар җитештерүнең үсүе базарны иң кирәкле продуктлар белән тутырып кына калмый, элек традицион җәмгыять күрмәгән яңа ихтыяҗлар да барлыкка китерә (синтетик дарулар, компьютерлар, элемтә һәм транспортның заманча средстволары һ.б.). Торак, туклану һәм медицина хезмәте күрсәтү хезмәте сизелерлек яхшыра, уртача гомер озынлыгы арта.

Техниканың көчле үсүе кеше яшәешенең предметлы мохитен генә түгел, аның бөтен көндәлек тормышын да үзгәртә. Традиционалистик аңда тормышның патриархаль-торгынлык-

лы әйләнеше «вакытлар тәгәрмәче»н, ягъни үз күчәрең тирәсендә мәңге әйләнүне символлаштырса, техноген цивилизация динамизмы немец философы К.Ясперс язган утрак тарихи вакыт образын тудыра. «Вакыт-ук» техник прогрессның гына түгел, ә бәлки *иҗтимагый прогрессның* да, ягъни җәмгыятьнең вәхшилектән һәм кыргыйлыктан цивилизациягә һәм цивилизацияле казанышларны тагын да арттыруга таба алгарышлы үсеше турындагы күзаллауларның да символы булып әверелә.

Техник прогресс табигатьнең, җәмгыять һәм кешенең үзенең мәдәни мәгънәләрен тирән үзгәртте, иҗтимагый аңга яңа яшәеш кыйммәтләре һәм тормыш мәгънәләре өстәде. Көч бирүче табигать турындагы традиционалистик күзаллаулар индустриаль җәмгыятьнең иҗтимагый аңында табигый законнар белән идарә ителә торган тәртипкә салынган «табигать системасы» турындагы күзаллаулар белән алыштырыла. Мондый күзаллаулар дөньяны аерым өлешләре катгый сәбәп-нәтиҗәле үзара эш итү белән бәйле сәгать механизмына тиңләүдә чагылдырылган. Дөньяны танып-белү аны кеше эшчәнлеге формаларында кабул итү белән тәңгәлләштерелә. Дөньяны дини сихерләүгә (М.Вебер) алмашка *иҗтимагый аңны* киң колачлы *секулярлаштыру*, ягъни дини карашларны һәм тәрбияне дөньяви белән алыштыру килә. К.Марксның табигатьне «кешенең органик булмаган тәне» дип билгеләве кеше һәм табигатьнең бердәйлеге турындагы традиционалистик күзаллауларның җимерелүен күрсәтә: тормышның илаһилаштырылган чыганагы дип кабул итү урынына табигатьне яшәү мохитен сәнәгать чималының бетмәс запасы келәте буларак аңлау килә. Яңа европалы кешенең Прометей ихтыяры пафосы, аның көчен һәм хакимиятен раслау табигатькә мөнәсәбәттә иксез-чиксез үзгәртеп кору мөмкинлекләрен раслауны аңлата. Буйсындыру, яулау, үзгәртеп кору яңа индустриаль мәдәниятнең төп метафоралары булып әверелә. «Без табигатьтән рәхимлекләр көтеп тора алмыйбыз» — инженер-технологның гына түгел, ботаник-селекционерның да девизы әнә шундый.

Традицион җәмгыятьтән аермалы буларак, индустриаль җәмгыятьтә социаль элемтәнең хакимлек итүче тибы хезмәткә икътисадтан тыш түгел, ә *икътисади мәҗбүр итүгә* нигезләнгән. Капиталистик ялланган хезмәткә юридик яктан тигез хокуклы ике якның: җитештерү средстволарына (биналар, җиһазлар, чимал) ия булган эшмәкәр белән бары тик үзенең эшче көче (эшкә физик сәләте, җитештерү күнекмәләре, белеме) генә булган ялланган эшченең социаль партнерлыгы хас. Җитештерү средстволарына хуҗа кешедән аермалы буларак, кечкенә крестьянның, җиреннән михнәт тарафыннан куылган, ялланган эшченең яшәү өчен средстволары юк. Шуилыктан,

якларның формаль (юридик) тигезлеге практикада аларның фактик тигезсезлеге, хезмәткә эш бирүче куйган шартларда икътисади мәҗбүр итү булып чыга. Ләкин цивилизация ягыннан караганда, шәхси бәйлелекне бетерү һәм хокукый шартнамә нигезендә *социаль контрактка* күчү — кешенең хокукларын раслауда, гражданлык җәмгыяте булдыруда мөһим алга китү. Шәхси бәйлелек һәм клан-ыруг мөнәсәбәтләрен өзү *социаль мобильлек*, ягъни кешенең бер социаль төркемнән (сыйныфтан) икенчесенә күчүе өчен мөмкинлекләр тудыра. Индустриаль җәмгыять кешегә иң югары цивилизацияле кыйммәтләрнең берсен — *шәхси ирек* бүләк итә. Ирекле кеше үз язмышының хуҗасы булып әверелә.

Социаль мөнәсәбәтләр — социаль тукыманың күренмәс җепләре — индустриаль җәмгыятьтә товар-акча алмашу (эшчәнлек, хезмәт продуктлары, хезмәт күрсәтүләр белән һ.б.) формасы ала. Бу исә иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең тарихи билгеле бер тибы белән бәйләнгән кешеләр берсе өстеннән берсе хакимлек итеп, «дөнья белән акча хакимлек итә» дигән иллюзия тудыра. Бары тик җәмгыятьне тирәнтен өйрәнү генә әлеге иллюзияне таратырга һәм хезмәтне эксплуатацияләүнең теге яки бу формасы нигезендә иҗтимагый җитештерүнең билгеле бер тибы һәм аңа хас милекчелек һәм бүлү мөнәсәбәтләре ятуын ачыклый ала.

Әгәр традицион җәмгыятьтә социаль мөнәсәбәтләрне турыдан-туры «иҗтимагый» дип атасалар, индустриаль заман өчен бер-берсе белән шәхсән таныш булмаган кешеләрнең — социаль партнерларның берәр нәрсә аркылы (акча, товар, институтлар) социаль элемтәләре хас. Урта гасырлар шәһәрләрен тасвирлап, М.Вебер шәһәр торакларының авыл җирләрендәгеләргә караганда шактый тыгыз урнашуын, әмма, бер авылда яшәүчеләрдән аермалы буларак, шәһәрдәге күршеләрнең бер-берсе белән таныш булмау ихтималын билгеләп үтә. Индустриаль җәмгыятьтә кешеләр мөнәсәбәтләрендә арадашчылар социаль институтлар һәм, беренче чиратта, дәүләт исеменнән эш йөртүче хокук тәртибен саклау, суд, прокуратура, шулай ук социальләштерү (мәктәпләр, вузлар һ.б.) һәм индивидларны эшкә урнаштыру (дәүләт предприятиеләре) органнары була. Институциональ-читтән торып социаль элемтәләр кешеләрнең үзара *социаль роль* уйнаучылар (судьялар, башлык, укытучы, табиб, сатучы, автобус йөртүчеләр һ.б.) буларак мөнәсәбәтләрен тудыралар. Һәм һәр кеше үз тормышының актеры да, авторы да буларак чыгыш ясап, бер генә түгел, ә күпләгән социаль роль уйный.

Индустриальләшү чорына авыл халкының югарырак тормыш дәрәҗәсе тәэмин итүче шәһәрләргә күпләп күчеп китүе

хас. Урта гасырлар Көнбатыш Европа шәһәрләренең характерлы сыйфатлары XVI–XVII гасырларда ук урнаша башлый. Авыл торулыкларыннан шәһәрне ныгытылган территория («бург»), шулай ук шәһәр үзидарәсенең сайлап куелган органнары аерып тора. Әфәнделәргә һәм буйсынганнарга катгый бүленгән авыл халкыннан аермалы буларак, шәһәр кешеләре, аларның социаль чыгышларына, шәхси хезмәтләренә һәм байлыкларына бәйсез рәвештә, формаль яктан тигез хокуклылар. Сәнәгать корпорацияләре үз әгъзаларының хокукларын судта, шул исәптән элеккеге хуҗасы алдында да яклыйлар. Күп илләрдә шәһәр суды карары ахыргысы була, һәм король суды тарафыннан дәгъва белдерелә алмый. «Шәһәр һавасы иректә итә» дигән әйтем безнең көннәргә кадәр ук килеп җиткән. Әмма үзәкләштерелгән дәүләтләрнең көчәюе нәтиҗәсендә суд эшчәнлеге һаман саен югары хакимият кулында туплана бара. Дәүләтнең монопольләшүе һәм көчләүне регламентлаштыруы җәмгыятьтә рөхсәт ителмәгән көчләрнең гомуми дәрәҗәсе төшүгә булышлык итә. Көчле һәм көчсезне, танылган һәм танылмаган кешеләрне, байларны һәм ярлыны закон алдында тигезләүче хокук институтларының һәм хокук белемнәренең артуы, ягъни *хокукый дәүләтнең* ныгып урнашуы — сәнәгать капитализмы үсешенең аерылгысыз шарты гына түгел, ә бәлки кешелек дөньясының бик тә мөһим цивилизацион казанышы да.

БҮГЕНГЕ ҖӘМГЫЯТЬ КОНТУРЛАРЫ

Сәнәгать җитештерүен һаман саен арттыра баруга юнәлдерелгән техноген цивилизация һәм техниканың кеше өстеннән хакимлеге, вакытлар үтү белән, әйләнә-тирә мохитне дә, шулай ук кешенең үзенең тән һәм психик сәламәтлеген дә җимерә. Әйләнә-тирә мохитнең гомуми пычрануы һәм гаять зур психик йөкләр шуңа китерде ки, бүгенге кеше инде синтетик дарулар, биологик өстәмәләр, ясалма имплантантлардан башка яши алмый. Әйләнә-тирә мохиткә туктаусыз техноген йогынты ясау планетабызның биологик күптөрлелегенә төзәтә алмаслык зыян сала. Анда ел саен күпләре әле биологлар тарафыннан өйрәнелмәгән берничә мең төр үсемлек һәм хайван үлә. Бүген галимнәр сәнәгать җитештерүе калдыкларыннан һава һәм су бассейннарының пычрануы турында гына түгел, табигатьтә экологик тигезлекне саклау механизмнарының җимерелү куркынычы, ягъни аның үз-үзен чистартуга һәм үз-үзен торгызуга булган табигый сәләтен югалтуы турында сөйлиләр. Ниһаять, Җирнең биосферасына контрольсез йогынты ясау бөтен кешелек дөньясының биологик яшәвен сорау астына куя. Галимнәр «кешелек дөньясына *экологик кризис* яный» дип кисәтәләр.

Узган гасыр ахырында сәнәгать нык үскән кайбер илләрдә шәйләнә башлаган индустриаль җәмгыять алшартлары барлыкка килү иҗтимагый үсешнең цивилизацияле өстенлекләренең сизелерлек үзгәрүен, техноген цивилизация нигезләрен үзгәртеп коруны аңлата. Бүгенге заман кешесе күзлегеннән караганда, уникаль табигый һәм мәдәни ландшафтларны саклау кешелек дөньясы өчен аларны индустриаль үзләштерүгә караганда мөһимрәк. Бу исә сәнәгатьне үстерү стратегиясеннән тулаем баш тартуны аңлатмый. Шулай да бүгенге сәнәгатьтә өстенлек ресурсларны һәм энергияне саклаучы технологияләргә, шулай ук молекуляр дәрәҗәдәге фән технологияләренә бирелә. Ләкин бу гына җитми. Постиндустриаль җәмгыятьнең иҗтимагый аңы куллануны (азыкны, ягулыкны һ.б.) акыллы чикләү зарурлыгын аңлады. Сәнәгать нык үскән илләрдә кече формаларга сорау арту кечкенә декоратив үсемлекләрдән һәм йорт хайваннарыннан алып аз литражлы автомобильләргә кадәр тулы бер индустриясен барлыкка китерде. Постиндустриаль җәмгыять кешесе табигатьнең бөтен кешелек дөньясы өчен универсаль йорт буларак зур кыйммәтен аңлый. Шунлыктан, цивилизацияле үсешнең киләчәккә стратегиясе табигатьне буйсындыруга, җәмгыятьне үзгәртеп коруга һәм яңа кеше булдыруга түгел, ә табигатьне һәм мәдәниятне гармонияле үстерүгә — *геннар-мәдәният коэволюциясенә* юнәлдерелгән.

Индустриаль цивилизация социаль элемтәләрне гомумпланетар масштабларга кадәр озынайту мөмкинлеге бирүче мәгълүмати технологияләрне үстерә. Ләкин шунысын да онытырга ярамый: компьютер белән аралашу, кешене мәгълүмат белән баетып, аны эмоциональ ярлыландырырга, социаль җаваплылык хисләрен томаларга мөмкин. Виртуаль аралашу кешедә түземлелек, кайгы уртаклашу, якын кешең турында кайгырту кебек кыйммәтле әхлакый сыйфатларны тиешле дәрәҗәдә үстерү сәләтенә ия түгел. Шунлыктан җанлы кеше аралашуы, кешене аның акылына (интеллектына) гына кайтарып калдыру мөмкин түгеллеген аңлау постиндустриаль җәмгыятьнең аерылгысыз кыйммәте булып тора.

Цивилизацияле үсешнең алдагы перспективалары нинди соң? Бу сорауга галимнәр төрлечә җавап бирә. Мәсәлән, Америка галиме Ф.Фукуяма кешелек дөньясының цивилизацияле үсүе тәмамлана, тарихның ахыры якын дип исәпли. «Тарихның ахыры» дигәндә ул бөтен дөньяда, гарәп-мөселман төбәге илләрен дә кертеп, американча демократия принципларының урнашуын аңлый. Әмма цивилизацияле үсеш юнәлеше проблемасы алай ук гади түгел. Безнең планетадагы төрле илләр цивилизацияле үсешнең төрле баскычларында торалар, аларның үткәне һәм мәдәни традицияләре төрле. Дөнья бергәлеге сәнәгать

үскән илләр юлыннан барырмы, әллә цивилизация үсеше күпполярлы дөнья булдыруга — кешелек дөньясының гомуми мәдәни генофондында төрле халыкларның мәдәниятләре һәм традицияләре чиратлашуына китерерме — анысы инде сезнең белән безгә дә бәйле.

ХӘЗЕРГЕ ДӨНЬЯ — ЦИВИЛИЗАЦИЯ ТӘҖРИБӘСЕ КӨЗГЕСЕНДӘ

Индустриаль цивилизация XVII гасырда барлыкка килә. Шул чордан бирле ул, аның йогынтысы орбитасына эләккән традицион илләрне үзгәртеп, дөнья буйлап триумфаль адымнар белән атлый. Техноген цивилизация белән очрашу традицион мәдәниятләрнең төптән үзгәрүенә, аларның цивилизацияле нигезләрен бик тә катлаулы үзгәртеп коруга китерә. Ләкин индустриаль үсеш рельсларына күчүнең озак вакытларга сузылуы, аның барышында җәмгыятьнең төрле тарихи типларының бер социаль организмда янәшә яшәүләре ихтимал. Шунлыктан цивилизацион үзгәрешләр чорында һәр конкрет җәмгыять җәмгыятьләрнең төрле тарихи типлары кушылмасын, традицион, индустриаль, ә кайчак постиндустриаль җәмгыятьләрнең «бергә кушылуы»н гәүдәләндерә. Кайчак җәмгыятьнең бер тарихи тибының цивилизацион характеристикалары икенчеләрендә аңлы рәвештәге мәдәни күчерү төсен ала. (Мәсәлән, Бөек француз революциясе вакытында Рим патрицийларының киеме, совет чоры Россиясендәге дворяннар җыелышлары, бүгенге яшьләр арасындагы кельт мәдәни йолалары.) Әгәр алар искергән социаль структураларны өлешчә яңарту, элеккене бүгенгедән кыйммәтрәк дип тану белән бергә барса, ул очракта галимнәр әле тулысынча өйрәнелмәгән күренеш — *архаизация* турында сөйлиләр.

Төрле цивилизацион катламнарның «калынлыгы» һәм аларның үзара йогынтысы характеристикасы һәр конкрет җәмгыятьтә кеше бармаклары эзләре кебек үк индивидуаль. Тарихы 200 елдан аз гына артык исәпләнгән АКШта, мәсәлән, индустриаль җәмгыять «чиста кәгазьдә» башлана. Шунлыктан традицион җәмгыятьнең мирас булып калган сыйфатлары («карт» Европаның цивилизацион картинасы шулар белән чуарланган) анда бик аз. Индустриаль үсеш рельсларына соңрак баскан илләрдә исә (Италия, Испания, Португалия, билгеле бер дәрәҗәдә Россиядә) традицион җәмгыять сыйфатлары тормышның гомуми укладында әле хәзер дә сизелә. Тарих өйрәткәнчә, ул сыйфатлардан көч кулланып котылу омтылышы («кулакларны сыйныф буларак бетерү», «крестьянлыктан азат итү», «казаклыктан азат итү» һ.б.) кешеләрне һәм мәдәниятне куплап

югалтуга китерүе ихтимал. Азия-Тын океан төбәгендәге илләрне индустрияләштерү тәҗрибәсе күрсәткәнчә, традицион җәмгыять туплаган рухи кыйммәтләрнең (күмәклек һәм үзара ярдәм итешү, әчкерсезлек һәм үзеңне корбан итү сәләте), алар ярдәмендә традицион җәмгыятьтән индустриаль җәмгыятькә йомшак кына, көч кулланмыйча гына уңышлы күчү кешелек дөньясы цивилизациясенең кыйммәтле байлыгы була. Өстәвенә традициягә акыл белән таяну яңа җәмгыять төзүгә комачауламый, киресенчә ярдәм итә.

Төрле цивилизацион характеристикаларның бергә кушылуы бүгенге Россиягә дә хас. Базар икътисады таләп иткән социаль-психологик сыйфатлар (индивидуальлек, көндәшлеккә сәләтлелек, тигезсезлек) традицион җәмгыятьнең бүгенге Россия гражданнарының өлкән буыны тәрбияләнгән социаль гадәтләр белән начар сыеша. Шунлыктан бүгенге Россиядә «аталар һәм балалар» проблемасы — буыннарның мәңгелек каршылыгы гына түгел, ә бәлки башка типтагы цивилизация кыйммәтләренә һәм яшәү мәгънәләренә мөнәсәбәттә тирән социаль-психологик проблема да.

Бүгенге Россия җәмгыятенең бик тә кискен проблемасы — төрле катлауларның һәм социаль төркемнәрнең керемнәре дәрәҗәсендә һәм тормыш максатларында зур аерма булу. Бүгенге Россия җәмгыятенең яхшы тәэмин ителгән катлауларында һәм традицион, һәм индустриаль җәмгыять күрсәтмәләренә кискен каршы килүче «куллану җәмгыяте» һәм гедонизм (тормыш белән ләззәтләнү) этикасы сыйфатлары бик тә ачык күренә. Бүгенге Россиядә социаль гадәтләрнең һәм төрле катлауларның керем дәрәҗәсенең артык аерылып торуы җәмгыятьтә социаль киеренкелек үсү куркынычы тудыра.

XX гасырның 80–90 нчы елларында Россиядә цивилизацион трансформацияләр тәҗрибәсен тикшерү «реформалар бәясе» турында фикер йөртү мөмкинлеге бирә. Зур социаль үзгәртеп коруларның уңышы реформаларның объектив бурычларын кешеләрнең үзләренең яшәү рәвешләрен, социаль гадәтләрен тиз арада кискен үзгәртү, цивилизацион яңа яшәеш кыйммәтләре һәм мәгънәләре алу мөмкинлекләре белән ни дәрәҗәдә берләштерә алуларына бәйле. Шулай булмаганда, кеше өчен реформаларның «бәясе» ифрат та югары.

КӨНЧЫГЫШ ҺӘМ КӨНБАТЫШ — МӘДӘНИЯТЛӘР ДИАЛОГЫНДА

Традицион, индустриаль һәм постиндустриаль җәмгыятьләрне чагыштырып, без бөтендөнья тарихының «вертикаль кисемен» карадык. Цивилизацияләрнең вакыт дәвамында

яшәүләрен характерлаучы иң мөһим төшенчәләр булып Көнчыгыш һәм Көнбатыш төшенчәләре тора. Без географик төшенчә белән «Көнчыгыш» дип атарга күнеккән нәрсә — нигездә (техноген цивилизациягә көчле ыргылыш ясаган кайбер Көньяк-Көнчыгыш Азия илләрен кертмичә) күпчелек җир эшкәртү хезмәтенә нигезләнгән, җиргә общиналы яки дәүләт-общиналы милекле, социаль элемтәләрне община-кланлы корган, кешене тулысынча диярлек социаль-этик стандартларга буйсындырган, шулай ук тормыш тәҗрибәсен традицияләр формасында социаль мирас итеп алган традицион җәмгыятьтән гыйбарәт. «Көнбатыш» төшенчәсен, кагыйдә буларак, икътисады, фәне һәм техникасы югары темпларда үсүче, иҗтимагый тормышы демократик төзелешле, хокукый дәүләтле һәм үскән гражданлык җәмгыятьле, социаль мобильлеге һәм шәхси иреге югары дәрәҗәдәге, сәнәгате нык үскән җәмгыятьләрне атау өчен кулланалар. Шунлыктан Тайвань турында интенсив үсүче, ләкин әле һаман да традицион Кытайдагы «эчке Көнбатыш» буларак һәм «Көнчыгыш йогынтысы» турында XX гасыр башы Европа илләрендә традициональ кыйммәтләргә мода буларак сөйләргә мөмкин. Көнчыгыш белән Көнбатыш арасында урнашкан Россия, үз тарихының төрле чорларында цивилизацион ориентлашуга бәйле рәвештә, әле берсенә, әле икенчесенә таба тартылды.

Билгеле булганча, теләсә кайсы цивилизациянең «төш»ен яшәеш кыйммәтләре һәм яшәү мәгънәләре системасы тәшкил итә. Көнчыгыш цивилизацияләрнең төп рухи кыйммәтләре даосизм, буддизм һәм конфуцианлык дини-фәлсәфи өйрәтүләрендә чагылган. (Ул өйрәтүләрнең төп нигезләмәләрен исегезгә төшерегез.)

Борынгы Көнчыгыш дөньясы картинасы әлеге кыйммәтләр нигезендә формалашкан. Бер яктан, Кытай, Һиндстан, Япония мәдәниятләрен, икенче яктан, антик Греция мәдәниятен чагыштырмача анализлау Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәдәниятләренең уртаклыклары һәм аерымлыклары, аларга хас фикерләү стильләре үзенчәлекләре турында сөйләү мөмкинлеге бирә.

XX гасыр философы Э.Гуссерль көнбатыш мәдәниятенең аерылып торган үзенчәлеген «идеяләрнең тормыштан өстен» булуында күрә. Көнбатыш философлары гомуми башлангычны, беренче сәбәпне, логосны (ягъни яшәеш законын) табарга тырышканнар. Көнчыгыш зирәклеге яшәеш асылын эзләүгә түгел, ә аның мизгелле халәтләрен, әйберләр һәм вакыйгалар тоташуын теркәп калырга омтылганнар. Борынгы Көнчыгыш мәдәниятләрен тикшерүче К.Г.Юнг борынгы кытайларның дөньяны ничек күзаллаулары турында болай дип яза: «Без

очраклылык дип атаган нәрсә әлеге үзенчәлекле фикерләү өчен, барысыннан да күренгәнчә, төп принцип булып тора, ә без сәбәп дип әйткән нәрсә берничди әһәмияткә дә ия түгел... Аларны, күрәсең, янәсе очраклылыкны китереп чыгарган гипотетик сәбәпләр түгел, ә күзәткән мизгелдәге очраклы вакыйгалар күренеше кызыктырадыр. Көнбатыш фикере кайгыртучанлык белән анализлый, үлчи, сайлап ала, классларга бүлә, «кытай картинасы» барысын да бик үк әһәмиятле булмаган бер детальгә кайтарып калдыра... Әлеге кызык принципны мин синхронлык дип атадым, ә ул безнең сәбәплеккә диаметраль капма-каршы». Европа миссионерларына, көнбатыш мәдәниятен пропагандалаучыларга табигать законнары тарафыннан идарә ителә торган дөнья турында «көнбатыш» күзаллаулары асылын Кытай акыл ияләренә аңлату кыен була. Әмма законнарны император чыгаруы турындагы «көнчыгыш» күзаллауларда да күпмедер хаклык бар, чөнки «көч» һәм «закон» төшенчәләре (кулның мускул көче турындагы күзаллаулар, юридик законнар) табигать фәннәренә кеше дөньясы турындагы белемнәрдән килгән.

Дөньяның «көнбатыш» һәм «көнчыгыш» картиналарының аерымлыклары чыганагын социаль тормышны оештыру ысулларының һәм шуңа бәйле рәвештә кешенең дөньяда тоткан урыны турында күзаллаулар төрлелегеннән эзләргә кирәк. Көнбатыш кешесе образы аллаларга каршы килергә җөрьәт иткән Прометейны гәүдәләндерсә, Көнчыгыш кешесен хыялга бирелгән дип исәпләү гадәткә кергән. Кешедән әйберләрнең табигый тәртибенә ияреүне («зыян салма») таләп итүче минималь хәрәкәт принцибы чынлап та борынгы Кытай зирәклегеннән алынган. Әмма хыялга бирелү — традицион җәмгыять кешесе кайда гына яшәсә дә, аңа хас сыйфат. Эшлекле кеше идеалы исә Көнбатышка барча вакытларда хас булмый. Алшартлары антик мәдәнияткә барып тоташкан актив-эшлекле кеше пафосы, ягъни табигатьне һәм кешене актив үзгәртеп коруга күрсәтмә, бары Яңарыш дәверендә генә барлыкка килә, һәм Яңа вакыт Европа мәдәниятендә — индустриаль җәмгыять барлыкка килгән чорда — тәмам ныгып урнаша.

Бүгенге цивилизация картасында Көнчыгыш белән Көнбатышны географик урнашудан бигрәк социаль-мәдәни үсеш сыйфатларының үзенчәлекле кушылуы характерлый. Шунлыктан Көнчыгыш-Көнбатыш аерымлыгы табигый шартларның (ландшафт, климат, туфрак һ.б.) төрлелегенә түгел, ә халыкларның цивилизацияле үсеше характерына һәм дәрәҗәсенә бәйле.

Көнбатыш мәдәниятенең мөһим социаль табышы — рациональ, ягъни оешкан һәм дәлилләнгән фикерләү һәм аңа нигез-

ләнгән социаль практика. «Тормыш һәм дөньяның барлыкка килүе проблемалары турында уйланулар, тормышның фәлсәфи, шулай ук теологик зирәклеге, танып-белү һәм искитмәле нечкәлектәге күзәтүләр — боларның барысы да башка илләрдә дә, барыннан да элек — Һиндстанда, Кытай, Вавилон һәм Мисырда булган. Шулай да Вавилон мәдәнияте дә, нинди дә булса башкасы да астрономияне математик раслауны белмәгәннәр, аны фәкать эллиннар биргән (бу, аерым алганда, Вавилон астрономиясе үсешен тагын да гаҗәпләндерерлек итә). Һиндстан геометриясендә рациональ дәлилләү юк — ул да, механика һәм физика кебек үк, эллин рухы продукты булып тора. Эмпирик белем күзлегеннән караганда, Һиндстанның бик тә нык үскән табигать фәннәренә рациональ эксперимент та (аның башлангычлары — антиклыкка, ә тулысынча үсүе Яңарыш чорына карый), бүгенге лабораторияләр дә билгеле түгел, шунлыктан Һиндстанның үзенең эмпирик күзәтүләре һәм техник ысуллары буенча нык үскән медицинасында биологик һәм барыннан да бигрәк биохимик нигезләр юк. Көнбатышныкыннан тыш бер генә мәдәният тә рациональ химияне белми. Күпчелек кече Азиядә һәм Һиндстанда булдырылган күп кенә киң колачлы кодификацияләргә карамастан, монда... хокукның рациональ теориясе юк. Канун хокукы кебек феномен да Көнбатышта туган», — дип раслый М.Вебер. Аңа хас булган белемне рациональ нигезләүче фән фәкать Көнбатышта гына туа ала, ди ул. Нишләп шулай? Бу сорауга җавапны да иҗтимагый тормышны оештыру формаларыннан эзләргә кирәк. Борынгы Греция колбиләүчелек демократиясе шартларында һәр ирекле кеше бөтен полис өчен әһәмиятле карарлар кабул итү хокукына ия булган. Өстәвенә аның байлыгы да, танылганлыгы да, үткәндәге хезмәтләре дә хәлиткеч әһәмияткә ия булмаган. Сугыш игълан итү, солых яки сәүдә турында килешү төзү турында карар кабул итүдә төп рольне оратор фикерләренең дәлилле, төпле булуы уйный. Борынгы Грециядә фән социаль тормышны оештыруның төп сыйфатларын үз эченә ала. Җир кишәрлекләрен үлчәүдән гамәли бурычлар практикасында барлыкка килеп, Борынгы Греция геометриясе Евклид геометриясендә белемнәрнең исбатланган, логик төзелешле системасын ала. Көнчыгышта географиядән белемнәргә практик мохтаҗлык Грециядәгедән ким булмый. Мисырда, мәсәлән, Нилның сезонында ташып агуы җир кишәрлекләре чикләрен һаман саен торгызуны, ягъни күппочмаклар төзү буенча практик мәсьәләләрне чишүне таләп итә. Әмма, Борынгы Грециядән аермалы буларак, Борынгы Көнчыгышта геометрия буенча белемнәр буыннан-буынга гамәли мәсьәләләрне чишүнең практик рецептлары буларак тапшырылалар һәм алар дәлилләнгән, системага салынган

белем буларак формалаштырылмыйлар. Мондый аермаларның сәбәбе шунда ки, карарлар төрле катлау социаль төркемнәр көрәшендә һәм үзара каршы торуында кабул ителгән демократик Греция полисыннан аермалы буларак, Көнчыгышта бер кулга тупланган хакимият авторитар характерда була. Ә авторитар фикер йөртүдә белемнәр чыганагына мөрәҗәгать итү дәлилләү абруен алыштыра. Индустриаль Көнбатыш җәмгыятендә фәннең мәдәни абруе иҗат итүче, дөньяны үзгәртеп коручы кешенең урынын һәм ролен аңлау белән бәйле була. Табигатьне, җәмгыятьне һәм кешенең үзен фәнни танып-белү аларны үзгәртеп коруның зарури алшарты булып санала.

Танылган инглиз язучысы һәм шагыйре Р.Киплинг Көнчыгыш белән Көнбатыштагы цивилизацияле аерымлыкларның сәбәбен халыкларның тарихи язмышында күрә, аларны урнашкан тәртипләрне җимерү бәрабәренә генә үзгәртеп була дип уйлый:

Көнбатыш ул Көнбатыш,
Көнчыгыш ул Көнчыгыш,
Очрашмаслар һичкайчан.
Булыр Ходай каршында
Тик Кыямәт көнендә.

Шулаймы бу? Инде белгәнебезчә, XX гасыр уртасында индустриаль Көнбатыш җәмгыятенең үсеше критик, техноген цивилизация үсешенең ахыр чикләренә килеп җитә. Техника прогрессы үзеннән-үзе генә кайчак үзен машинага өстәмә, компьютерга биологик кушымта, яки «пычрак» социаль технологияләр объекты итеп тойган кешенең социаль хәлен яхшырта алмый. Сәнәгате үскән илләрдә гедонистик, ягъни канәгатьләнү алуга юнәлдерелгән омтылышлар басымы астында хезмәт этикасы сизелерлек кими. Экология кризисы, кешелек дөньясының халыкара террорчылык каршында яшәп кала алуы һәм, ниһаять, яшәү тирәлегенең һәлакәтле, ә кайчак кире кайтарып булмаслык үзгәрүе шартларында көн күрүе Көнбатышны цивилизацияле үсүнең яңа, гуманлы юнәлешләрен эзләргә мәҗбүр итә.

Күпләгән галимнәр, Көнчыгыш мәдәниятләрдә сакланган яшәеш кыйммәтләренә һәм тормыш мәгънәләренә: табигатькә, җәмгыятькә һәм кешегә сак карауга, табигый һәм мәдәни мохиткә техноген басымны чикләүгә мөрәҗәгать итмичә, акыллы җиткелек кыйммәтләрен торгызмыйча, Көнбатыштагы хәзерге индустриаль җәмгыятьнең үзенең цивилизацияле нигезләрен үзгәртеп кора алуы икеле дип уйлыйлар. Һәм аның язмышы күп яктан кешелек дөньясының Көнбатыш һәм Көнчыгыш кыйммәтләренең гармонияле синтезына ни дәрәҗәдә ирешә алуына бәйле.

Төп төшенчәләр: традицион җәмгыять, индустриальләштерү, техноген цивилизация, постиндустриаль җәмгыять, Көнбатыш җәмгыяте, Көнчыгыш тибындагы цивилизация.

Терминнар: икътисадтан тыш мәҗбүр итү, теократия, секулярлаштыру, социаль контракт.

Үзегезне тикшерегез

1. «Язмыш», «тәкъдир» метафораларында традицион фикер йөртүнең нинди сыйфатлары чагылган? Борынгы грек трагедияләрендә аларның әһәмияте ни өчен шулай зур? 2. Табигатькә традицион мөнәсәбәтнең индустриаль мөнәсәбәттән аермасы нәрсәдә? 3. Ни өчен традицион җәмгыять кешесе вакытны — кабатланучы вакыйгалар чираты («вакытлар тәгәрмәче») дип, ә индустриаль җәмгыять кешесе прогресс («вакыт угы») дип кабул иткән? 4. Ж.-Ж.Руссоның: «Фәннәр һәм сәнгать богауланган кешенең чылбырын чәчәкләр белән каплыйлар гына» дип раславы белән килешәсезме? 5. Цивилизацияле капитализмны теләсә ничек баю белән тиңләштереп буламы? Цивилизацияле капитализм авантюралы эшмәкәрлектән нәрсәсе белән аерыла? 6. Революцияләр бүген дә «тарихның локомотивлары» булып тора дигән белән килешәсезме? 7. Гиннессның Рекордлар китабын җәмгыятьнең кайсы тарихи тибы символы дип исәпләргә була? 8. Көнчыгыш кыйммәтләрен уникаль, Көнбатышка ят дип буламы?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Ч.Айтматовның «Гасырдан да озын көн» романында кыргый казакъ далалары карты Буранлы белән яңа космодром инженер-проектлаучысы арасындагы капма-каршы тору турында бәян ителә. Беренчесе космодромны иске зират урынында төзүгә каршы килә, йолдызларга ата-бабалар сөяген изеп очарга ярамый, ди; икенчесен төзелеш өчен уңайлы урын гына кызыксындыра. Сезнеңчә, бу нинди типтагы конфликт:

— профессиональ (чабан һәм проектлаучы арасындагы каршылык);

— социаль-психологик (дала кешесе мегаполис кешесен аңлый алмый);

— цивилизацияле (традицион һәм индустриаль җәмгыятьләрнең яшәеш кыйммәтләре һәм тормыш мәгънәләре бәрелеше?

2. «Язмыштан узмыш юк» һәм «Шәһәр һавасы ирекле итә» дигән ике әйтемне чагыштырыгыз. Аларның һәркайсы җәмгыятьләрнең нинди тарихи типлары фикер юнәлешләрен чагылдыра?

3. Кайбер галимнәр кешелек дөньясының киләчәге — бөтен дөньяга Америка демократиясе принципларын тарату дип исәпли. Башка галимнәр, киресенчә, исән калу өчен техноген цивилизация Көнчыгыш мәдәнияте кыйммәтләре белән баерга тиеш дип раслыйлар. Сез кайсы караш яклы? Үз карашыгызны дәлилләгез.

§ 13. Кешелек дөньясының тарихи үсеше: социаль макротеорияләр эзләү

Исегезгә төшерегез:

тарихи чыганакларга нәрсәләр кирә? Тарихны өйрәнү ысуллары нинди? Борынгы заманда һәм Урта гасырлар дәверендә нинди цивилизацияләр булган? Тарихка марксистик караш нәрсәсе белән характерлы? Ни өчен җәмгыятьне үсүче система дип атыйлар?

Җәмгыятьне система буларак карап, без аның үзгәрүгә, үсүгә сәләте кебек сыйфатларын билгеләп үттек инде. Иҗтимагый тормыш халәтенең, аны оештыру формаларының, кешеләрнең яшәү рәвешенең даими үзгәреп торуын кешелек дөньясының үткәне дәлилли. Күптәннән инде тарихны тасвирлау гына түгел, үткәндәге вакыйгаларны һәм күренешләрне фикерләргә, аңлатырга, «үзенчәлекле» артында «гомуми»не, кабатлануны күрергә омтылулар була.

Үткән белән кызыксыну очраклы түгел: ул безгә бүгенге көнне аңларга һәм киләчәккә карарга ярдәм итә. Әмма, белгәнегезчә, тарихны аңлау җиңел эш түгел. Тарихчы инде юк дөньяга мөрәҗәгать итә. Ул аны безнең көннәргә кадәр килеп җиткән мәгълүматларга, эзләргә таянып торгызырга тиеш. Мәгълүматлар, кагыйдә буларак, тулы булмаганлыктан, ә вакыйгалар еш кына вакыт ягыннан бик тә еракта калганлыктан, тарихны тасвирлау бик үк төгәл булмаска мөмкин. Ләкин испан язучысына бу, ярымшаярту рәвешендә, тарихның асылын болайрак билгеләү өчен нигез бирә: бу — анда беркайчан да булмаган кеше тарафыннан язылган беркайчан да булмаган нәрсә.

Үткәннәр турында фикер йөртүнең кыенлыклары болар гына да түгел. Тарихчы вакыйгаларны торгызу һәм тасвирлау белән генә чикләнми. Ул моның ни сәбәпле булуын, нинди нәтиҗәләргә китерүен, анда катнашучыларның нинди максатлар куюын һ.б. ачыкларга тырыша. Өстәвенә тикшеренүче ирексездән үткәнгә үзе яшәгән чор сыйфатларын күчерә. Тарихчыларга вакыйгаларны аңлатуга һәм аларга бәя бирүгә башка

вакыт, башка чор гына йогынты ясап калмый, аның шәхси карашлары, кыйммәти өстенлекләр, дөньяны танып-белү юнәлешләре дә тәэсир итә. Тарих ул — булганнар турында уйлап чыгарылган вакыйгалар дип раслап, француз философы Ш.Монтескье, ихтимал, тарихи белемнең нәкъ менә шушы үзенчәлегеп истә тоткандыр.

Үткәндәге төрле якларны торгызучы конкрет-тарихи белем белән бергә, әлеге белемнәрне анализлау һәм гомумиләштерү нигезендә ясалган нәтиҗәләрнең дә әһәмияте зур. Кайбер тарихчылар һәм философлар бөтен дөньякүләм тарихи процессларны фикри колачларга, кешелек дөньясының гомуми юнәлгәнлеген табарга, иҗтимагый-тарихи үсешнең макротеориясен булдырырга тырышалар.

Дөнья тарихын анализлауга төрлечә якын килүләр бар. Аларның һәрберсе дөньяның үз социаль картинасын бирә. Аларның күбрәк таралу алганнарына тукталыйк.

ЛОКАЛЬ ЦИВИЛИЗАЦИЯЛӘР ТЕОРИЯСЕ

Инде белгәнегезчә, әлеге теориянең төп категориясе — «цивилизация» яки «мәдәни-тарихи тип» төшенчәсе. XIX гасыр рус тарихчысы *Н.Я.Данилевский* (1822 – 1885) җәмгыятьнең андый типларын аеру — тикшеренүченең төп бурычларының берсе дип исәпли. Шул ук вакытта дини, социаль, көнкүреш, сәнәгый, фәнни, әдәби-нәфис үсеш үзенчәлекләренә дә игътибар итәргә кирәк. Автор һәр мәдәни-тарихи типның тормыш эшчәнлеге нигезләре башка мәдәни бергәлекләргә тапшырылмый, алар мөстәкыйль рәвештә барлыкка китереләләр һәм халыкларның шул төркеме кысаларында гына әһәмияткә ия дип исәпли. Үзенең бөтенлеге кысаларында мәдәни-тарихи тип үсешнең өч этабын уза: үсү, мәдәни һәм сәяси үзбилгеләнү; «чәчәк ату һәм җимеш бирү»; көч бетү, чишелмәс каршылыклар туплану, ышаныч югалу. «Мәдәни-тарихи типларның берсенә дә гомерлек прогресс өстенлеге бирелмәгән»,— дип басым ясап әйтә Данилевский.

Инглиз тарихчысы *А.Тойнби* (1889 – 1975) *цивилизацияне* «аерым милләтләрдән киңрәк, әмма бөтен кешелек дөньясыннан таррак» бергәлек буларак билгели. Автор тулысынча мөстәкыйль ун цивилизацияне саный. Алардан ул «тереләргә» Көнбатыш, православие-христиан, ислам, һинд, Ерак Көнчыгыш цивилизацияләрен кертә.

Тойнби фикеренчә, цивилизациянең кабатланмас йөзе күп факторлар, шул исәптән табигый-географик мохит үзенчәлекләре йогынтысы астында барлыкка килә. Цивилизациянең үсеше кешеләрнең җәмгыять очрашкан күпсанлы каршы-

лыкларга (хәзер без аларны «проблемалар» дип атар идек) лаеклы «җавап» таба алуларына бәйле. Алар: табигый ресурсларның җитмәве, хезмәткә яраксызларның артуы һ.б. Андый җавапларны барлык кешеләрне сайлап алган юлдан барырга әйдәргә сәләтле «иҗади азчылык» кына таба ала. Һәр цивилизация — үзенең кыйммәтләр системасы (иң югарысы — дини) булган бердәм организм ул.

Тойнби фикеренчә, цивилизацияләргә тарихи яшәүнең ябык циклы хас: алар «яшәү омтылышы» энергиясе исәбенә барлыкка киләләр, үсәләр, аннары түбән тәгәрәүгә һәм таркалуга китерүче «сыну» була. Сыну беренче чиратта «иҗади азчылыкның» яңа проблемаларны чишү юлларын таба алмаучы, үз-үзен җитештерүче кастага әверелүе белән бәйле. Бер үк вакытта «эчке пролетариат» катлавы — эшләргә дә, ватанны сакларга да сәләтсез, әмма җәмгыятьтәге «ипи һәм тамашалар»дан үз өлешен таләп итүче кешеләр үсә. Хәл тагын шуның белән дә катлаулана: цивилизациянең тышкы чикләрендә «вәхши халыклар» яный, алар басымы астында ул, эчке каршылыклар белән хәлсезләнгән хәлдә, аварга мөмкин.

Немец философы *О.Шпенглер* (1880–1936) үзенең цивилизацияне үзенчәлекле аңлавын тәкъдим итә. Ул кешелек тарихында сигез мәдәният булган, аларның һәрберсе үзләре яшәгән вакытта берничә стадия үткән һәм, үлеп, цивилизациягә әверелгән дип исәпли. Мәдәнияттән цивилизациягә күчү иҗатның, героик эшләрнең сүнүен аңлата; чын сәнгать кирәкмәс булып кала, механик эш тантана итә.

Шул рәвешле, *локаль-цивилизацион якын килүгә* нигез салучылар иҗтимагый-тарихи процессның төп «берәмлеге» — *мөстәкыйль, шактый ябык (локаль) бергәлекләр* — цивилизацияләр дигәннән чыгып эш итәләр. Төрле халыкларны цивилизацияле җәмгыятьләргә күп факторлар, әмма барыннан да элек рухи мәдәният, дини кыйммәтләр уртаклыгы туплый. Һәр цивилизация үзенең тарихи юлын үтә: туа, чәчәк ата, җимерелүгә таба авыша һәм югала (монда без теләсә кайсы тере организмның үсеш фазалары белән туры бердәйлекне күрә алабыз).

Бүгенге күпләгән тикшеренүчеләр үз эшләрендә локаль-цивилизацион якын килү принцибын кулланалар. Мәсәлән, Америка философы *С.Хантингтон* (үзенең элгәреләре артыннан) цивилизацияләрне бер-берсеннән тарих, тел, традицияләр, әмма барыннан да бигрәк дин белән аерылып торучы мәдәни бергәлекләр дип билгели. Автор бүгенге дөньядагы сигез төп цивилизацияне аерып күрсәтә: Көнбатыш, конфуцианлык, япон, славян-православие, ислам, һинд, Африка, Латин Америкасы. Цивилизацияләр арасындагы мөнәсәбәтләр потенциаль кар-

шылыклы, чөнки кыйммәтләрне һәм инануларны татуландыру икътисади һәм сәяси мәнфәгатьләргә караганда шактый катлаулырак. Автор киләчәктә зур цивилизацияара бәрелешләр («цивилизацияләр сугышы») булу ихтималын инкарь итми.

Локаль-цивилизацион якын килүнең көчле якларына (реаль мәдәни-тарихи бергәлекләрне аларның уникаль кабатланмас чагылышларында өйрәнүгә туплануга) таянып, бүгенге тикшеренүчеләр аның йомшак якларын да җиңәргә тырышалар. Аларга, беренче чиратта, цивилизацияләрнең дөньякүләм-тарихи процессның бөтенлеген җимерүче үзара аерымлану моментын күпертеп күрсәтүне кертергә кирәк. Тойнби, тарихка мондый карашның йомшаклыгын тоеп, цивилизацияләр арасында үтә алмаслык пәрдәләр беркайчан да булмаган, дип күрсәтә. Ул шулай ук киләчәктә бердәм бөтендөнья диненә күчеп, аерым цивилизацияләрнең бикләнгәнлеген җиңеп булыр дип уйлый.

Локаль-цивилизацион якын килүнең икенче бер җитешсезлеге цивилизацияләр үсеше фазаларын биологияләштерү белән бәйле. Бүгенге авторлар, мондый төзек түгәрәкле структура юк, диләр. Барыннан да элек цивилизацияле «күтәрелешләр» (чәчәк атулар) һәм «чигенүләр» (кризислар, түбән тәгәрәүләр) турында сөйләргә мөмкин; ләкин мондый алышыну катгый даимилеккә ия түгел.

ИҖТИМАГЫЙ-ИКЪТИСАДИ ФОРМАЦИЯЛӘР ТЕОРИЯСЕ

К.Маркс һәм *Ф.Энгельс*, инде белгәнегезчә, иҗтимагый *формацияләрне* җәмгыятьнең тарихи үсеш баскычлары итеп карыйлар. Аларның һәрберсенә үзенең җитештерү ысулы, икътисади мөнәсәбәтләрнең билгеле бер системасы — җәмгыятьнең *базисы*, шулай ук иҗтимагый аңның җәмгыятьнең *өскормасын* барлыкка китерүче сәяси, хокукый, идеологик, этик һәм башка мөнәсәбәтләр һәм формаларның аерым комплексы хас. Базис өскорманы билгели, ләкин соңгысы базисны чагылдырып кына калмый, аның үсүе өчен шартлар да тудыра (идеологик кыйммәтләрне, иҗтимагый нормаларны ныгыта).

Марксизмга нигез салучылар иҗтимагый-икътисади формацияләрнең берничә тибын аерып карыйлар һәм тикшерәләр. Типологияләрнең берсендә капитализмга кадәрге, капиталистик һәм коммунистик формацияләр атала. Алга таба борынгы община, колбиләүчелек, феодаль, капиталистик формаларны колачлаучы схема ныгытыла. Ул формацияләрнең һәрберсе кешелек дөньясының иҗтимагый прогресс юлыннан хәрәкәт итү баскычы буларак карала.

Бер формациядән икенчесенә күчүне җитештерү ысулында барлыкка килгән каршылыклар китереп чыгара: үскән җитештерү көчләре икътисади мөнәсәбәтләрдә, ә аннары бөтен өскормада үзгәрешләр таләп итә. Хосусый милекчелеккә корылган җәмгыятьтәге бу каршылыклар сыйнфый көрәш формасы ала, анда бер сыйныфлар элеккеге тәртипләрне сакларга тырыша, икенчеләре катгый үзгәртеп коруларны максат итеп куя. Сыйнфый көрәшнең иң югары формасы — социаль революция.

Шул рәвешле, иҗтимагый-тарихи үсешнең соңыннан аңа ияргән күпләр тарафыннан кулланылган стадияле моделе тәкъдим ителә. Маркс тарафдары *В.И.Ленин* формацияләр турында тәгълимат булдыруны иҗтимагый фикернең зур җиңүе дип атый: «Тарихка һәм сәясәткә карашларда моңарчы хөкем сөргән хаос һәм башбаштаклар, җитештерү көчләре үсү сәбәпле, иҗтимагый тормышның бер укладыннан икенчесенә, тагын да югарырагына күчүне күрсәтүче искитмәле тулы һәм төзек фәнни теория белән алышындылар».

Әле чагыштырмача күптән түгел генә Ватаныбыз җәмгыять белемендә бердәнбер дөрес дип танылган формацияле якын килүгә бүген күпләр тәнкыйть күзлегеннән карый. Барыннан да элек аның универсальлеге, барлык илләргә һәм чорларга кулланырга яраклы булуы шик астына алына. Формацияле схемага барлык тарихи фактлар да «сыеп» бетми. Мәсәлән, Урта диңгез буендагы колбиләүчелек дәүләтләре белән бер үк вакытта борынгы, архаик строй стадиясендәге кабиләләр, шулай ук Көнчыгыш тибындагы җәмгыятьләр яшәгән. Теоретик яктан караганда, колбиләүчелек ыруглык строе артыннан килергә тиеш. Ә чын тарихта исә алар икесе дә бер үк тарихи дәвердә яшәгән. Өстәвенә колбиләүчелек дәүләтләренә һәлакәтне үсешнең түбәнрәк баскычында торган халыклар һәм кабиләләр китергән.

Формацияләр теориясе диләр аны тәнкыйтьләүчеләр, тарихи процесс турында фаталистик, альтернативасыз күзаллау барлыкка китерә, кеше эшчәнлеге һәм аңы ролен киметә. Күпләгән бүгенге күренешләр дә формацияле якын килү кысаларына сыймый. Киләчәктә үсешнең коммунистик фазасына ирешә алу турындагы күзаллауларны бүген күпчелек тикшеренүчеләр фәнни нигезләнгән фаразлауга кертмиләр, әлеге өметләргә чынга ашмаслык дип карыйлар.

Шуның белән бергә, иҗтимагый үсештәге стадиялелек идеясе үзе, барыннан да элек технологик һәм икътисади факторларны исәпкә алып, «үсеш» баскычларын аерып күрсәтү иҗтимагый үсешнең башка модельләрен эшләгәндә кирәк булып чыга.

ПОСТИНДУСТРИАЛЬ ҖӘМГЫЯТЬ ТЕОРИЯСЕ

Узган гасырның 70 нче елларында Америка социологы *Д.Белльның* «Киләчәк постиндустриаль җәмгыять» дигән китабы чыкты. Автор үзе билгеләп үткәнчә, марксистик формацион анализның милекчелекнең феодализм — капитализм — социализм формалары алышу нигезенә корылган «күчәр линиясенә» ул башка: индустриальгә кадәрге — индустриаль — постиндустриаль җәмгыять линиясен каршы куя. Соңгысын, автор фикеренчә, алпавыт җире яки крестьян хуҗалыгы, сәнәгать корпорациясе түгел, ә университет гәүдәләндерә. Постиндустриаль җәмгыятькә фәннең роле күтәрелү хас, анда матди җитештерү үзенең җәмгыятьтә тоткан төп урынын хезмәт күрсәтүләр өлкәсенә бирә; дәүләтнең фаразлау роле арта.

Көнбатышның икенче бер тикшеренүчесе — *О.Тоффлер* — кешелек дөньясы үсешендәге өч дулкынны аерып күрсәтә. Якынча 10 мең ел элек зур үзгәрешләрнең беренче дулкыны башланган. Ул күченеп йөрүче кабиләләрне утрак крестьяннарга әверелдергән. Әлеге аграр революция кешелек дөньясының цивилизация кысаларында үсүенә башлангыч биргән. Аның нәтиҗәсе күп йөзьеллыкларга аграр яки традицион җәмгыять туу һәм урнашу булган. 300 ел чамасы элек Көнбатыш Европада сәнәгать революциясе башланган, аның нәтиҗәсендә аграр җәмгыять индустриаль җәмгыятькә әверелгән. Кешеләрнең яшәү рәвеше бүген дә сизелерлек үзгәрә. Үзгәрешләрнең өченче дулкыны индустриаль революциянекеннән ким түгел, әмма үзгәрешләр тизлеге сизелерлек югары. Дөнья ашкынулы төстә постиндустриаль җәмгыятькә кереп бара.

Американың тагын бер социологы — У.Ростоу җәмгыять үсешенең биш стадиясен аерып күрсәтә. Аларның икесе арадаш, үсешнең яңа фазасына күчүне тәэмин итүче булып санала.

— Традицион җәмгыять. Ул — шактый примитив техникалы, икътисадта авыл хуҗалыгы өстенлек иткән, катлау-сыйныф системалы һәм эре җирбиләүчеләр хакимлек иткән җәмгыять.

— Күчеш җәмгыяте. Бу этапта үсешнең яңа фазасына күчү өчен алшартлар булдырыла: эшмәкәрлек барлыкка килә, үзәкләштерелгән дәүләтләр урнаша, милли үзаң үсә.

— Сәнәгать революцияләре белән «үзгәрү» стадиясе һәм аның артыннан килгән эре социаль-икътисади һәм сәяси үзгәртеп корулары.

— Фәнни-техник революциянең үсүе, шәһәрләрнең артуы белән бәйле «өлгерү» стадиясе.

— «Югары массакүләм куллану» дәвере. Аның иң мөһим сыйфаты — хезмәт күрсәтү өлкәләренең шактый үсүе, куллану товарлары җитештерүнең икътисадның төп секторына әверелүе.

Бүгенге индустриаль җәмгыятьне характерлаганда, илебез һәм чит илләр авторлары аның «ясалма интеллектуаль тармакларының — микроэлектроника, биотехнология, телекоммуникацияләрнең кинәт үсүе, хуҗалыкны глобальләштерүнең кочәюе кебек сыйфатларын аерып күрсәтәләр. Барыннан да элек Көнбатышның күпчелек илләрендәге уңайсыз демографик хәл китереп чыгарган яңа проблемалар билгеләп үтелә.

Постиндустриаль җәмгыятьтә техник прогресс, икътисадтагы казанышлар ничек кенә мөһим булсалар да, танылган тикшеренүчеләр фикеренчә, аның үсеш характерын төп билгеләүчеләр — кешенең рухи потенциалы, өстенлекләре. XXI гасырда нәкъ менә шул үзәк ресурс була бара.

ТАРИХКА СТАДИЯЛЕ ЯКЫН КИЛҮНЕҢ ИКЕ ТАРМАГЫ: УРТАКЛЫК ҺӘМ АЕРМАЛЫКЛАР

Иҗтимагый-икътисади формацияләр теориясе белән индустриаль җәмгыять теориясен чагыштырып, без аларда күп кенә уртаклыкларны күрәбез.

Беренчедән, һәр ике теориядә кешелек җәмгыятенең үсеше алар аша узган билгеле бер эре этаплар аерып күрсәтелә һәм нигезләнә. Икенчедән, һәр ике теория иҗтимагый прогресс чыганагы итеп матди җитештерү өлкәсендәге үзгәрешләрне һәм шуңа бәйле социаль өлкәдәге алга китүләрне (үзләштерүче хуҗалыктан — җитештерүчегә, күчмә терлекчелектән — утрак җир эшкәртүгә, цех җитештерүеннән эре масштаблы сәнәгатькә һәм эшмәкәрлеккә күчү, шәһәр тормышын үстерү, массакүләм җитештерү булдыру һ.б.) тануга таяна. Өченчедән, марксизм классиклары да, постиндустриаль җәмгыять теориясен булдыручылар да җәмгыятьнең бер халәттән икенчесенә мондый күчүләре революцион характерда була дип билгеләп үттеләр (искә төшерик: аграр революция, сәнәгать революциясе һ.б.).

Шуның белән бергә, тарихка ике төрле караш арасында шактый аермалыклар да бар. Иң ачык күренеп торганы — кешелек дөньясының үзенең иҗтимагый-тарихи үсешендә нинди төп фазаларны үткәнлеге турындагы карашларның туры килмәве. Ләкин әһәмиятлеләрәге башкада. Җәмгыять үсешендә социаль-икътисади факторларның әһәмиятен исәпкә алып, постиндустриаль җәмгыять теориясе яклылар иҗтимагый тормышның рухи ягының: кешеләрнең белемнәренең, аларның кыйммәти ориентларының, яшәү омтылышларының аерым һәм һаман үсә баручы ролен басым ясап күрсәтәләр. Грамоталылык, белем үзләре белән «мин техник прогрессның теләсә кайсы продуктыннан күпкә мөһимрәк дип санаган нәрсәләр» алып килделәр дип исәпли *Дж.Гэлбрейт.*

Әлеге карашта постиндустриаль җәмгыять теориясе яклылар локаль цивилизация теориясе идеяләрен яклаучылар белән якынаялар.

Төп төшенчәләр: цивилизация, иҗтимагый-икътисади формация, тарихка стадияле якын килү.

Терминнар: мәдәни-тарихи тип, иҗади азчылык, базис, өскорма.

Үзегезне тикшерегез

1. «Тарих» төшенчәсенең төп мәгънәләре нинди? 2. Үткәннәрне аңлаудагы кыенлыклар нәрсәдә? 3. Н. Данилевский «мәдәни-тарихи тип» дигәндә нәрсәне аңлаган? 4. А.Тойнби цивилизацияне ничек билгеләгән? Аныңча, цивилизацияле үсүгә нинди факторлар йогынты ясый? 5. Тарихка А.Тойнби һәм Н.Данилевскийча якын килү ни өчен «локаль-цивилизацияле» дигән исем алган? Болай якын килүнең уңай һәм тискәре яклары нинди? 6. Иҗтимагый-икътисади формацияләр турында марксистик тәгълиматның төп нигезләмәләрен ачып бирегез. 7. Формацион якын килүнең көчле һәм йомшак яклары нинди? 8. Д.Белл, О.Тоффлер, У.Ростоуның тарихка стадияле якын килүләрен чагыштырыгыз. Сезнең карашыгызча, тикшеренүчеләрнең һәркайсы тарихи үсешнең төп фазаларын аерып күрсәтү нигезенә нәрсәне сала? 9. Тарихка стадияле якын килүдә ике юнәлешнең төп аермалыклары нәрсәдә?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Философ-мәгърифәтчеләр җәмгыять үсешен аның төрле якларының камилләшүе, мәгърифәтчелек, гадилек биеклекләренә менү буларак аңлатканнар.

Тарихи үсешнең алга таба барышы бу фаразны аклаганмы? Үз нәтиҗәгезне аңлатыгыз.

2. В.Засуличка язган хатында К.Маркс архаик, икътисади һәм коммунистик формацияләрне искә ала. Беренчесе — шәхси бәйлелек мөнәсәбәтләренә, икенчесе әйберләргә бәйлелеккә корылган. Коммунизмның принцибы исә — бербөтеннең үсешенең аерым индивидлар үсеше белән үзара бәйлелеге — «һәркемнең үсүе барысының да үсүенең шарты булып тора».

Сезнеңчә, җәмгыять үсешенең постиндустриаль җәмгыять теориясе кысаларында аерылып торучы өч фазасына әлеге «дөньякүләм схематика» туры киләме?

3. Иҗтимагый тарихи үсешкә формацион һәм локаль-цивилизацияле якын килүләрне чагыштырып карагыз. Таблицаны тутырыгыз.

Чагыштыру линияләре	Формацион якын килү	Локаль-цивилизацияле якын килү
Җәмгыять үсешендә матди һәм рухи факторларның нисбәте		
Тарихи үсешнең юнәлгәнлеге		
«Прогресс» төшенчәсенә аңлатма		
Бүгенге дөньяны күрү		

4. Формация турында тәгълимат яклылар һәм постиндустриаль җәмгыять теориясе тарафдарларының дөнья тарихын аңлатудагы уртак сыйфатларын һәм аермалыкларын күрсәтегез.

5. Формацион якын килү кысаларында «җитештерү ысулы», «базис», «өскорма» төшенчәләре кулланыла. Ә локаль-цивилизацияле якын килү яклылар тарихи процессны нинди төшенчәләр белән тасвирлый?

6. Укытучы укучыларга ике бурыч куйды: Урта гасырлардагы Европа цивилизациясенә характеристика бирергә һәм феодаль иҗтимагый-икътисади формациянең төп сыйфатларын күрсәтергә. Укучыларның җаваплары нәрсәләрдә үзара туры килер, ә нәрсәләрдә аерымланыр?

7. «Бөтендөнья тарихында мин органик формаларның мәңге барлыкка килүе һәм үзгәрүе, искитмәле күтәрелеше һәм үлүе күренешен күрәм. Ә присяжный тарихчы анда дәвер арты дәвер үстерә барган тасмалы суалчан кебегрәк бернәрсәне күрә».

Әлеге юлларның авторы тарихка стадиялеме, әллә локаль-цивилизацияле якын килү яклымы?

Үз җавабыгызны аңлатыгыз.

Чыганак белән эшләгез

Сезгә социолог П.Сорокинның 1941 елда язылган «Безнең заман кризисы» дигән китабыннан өзек укырга тәкъдим итәбез.

...Чын кризис — көнбатыш мәдәнияте һәм җәмгыятенең үлем алды тартышуы түгел, ягъни аларның тарихи яшәешенең җимерелүен дә, ахырын да аңлатмый. Фәкать биологик тән-

гәлләштерүгә генә корылган барлык мондый теорияләр нигезсез. Һәр мәдәният балалык, үсмерлек һәм үлем стадияләрен үтәргә тиеш дигән бер генә закон да юк. Әлеге бик тә карт теорияләр яклы беркемнең дә җәмгыятьнең балачагы яки мәдәниятнең картаюы астында нәрсә күздә тотылганын; һәр яшьнең типик характеристикалары нинди икәнен; әлеге җәмгыятьнең кайчан һәм ничек үлүен һәм, гомумән, җәмгыятьнең һәм мәдәниятнең үлеме нәрсә аңлатканын күрсәтә алганы юк.

Барча мөнәсәбәтләрдә дә, югарыда сүз барган теорияләр — билгесез терминнардан, юк универсалияләрдән, мәгънәсез белдерүләрдән торган гади аналогияләр алар. Көнбатыш мәдәнияте картаюның соңгы стадиясенә җитте һәм хәзер үлем алды тартышуы белән тартыша дип раслау — тагын да ышандырмый торганрак. Шуның өстенә көнбатыш мәдәнияте «үлеме»нең мәгънәсе дә ачыкланмаган, нинди дә булса дәлилләр дә китерелмәгән.

...Кешедә бер төрле яшәү рәвешенең икенчесенә авышуы аның үлүен аңлатмаган кебек, мәдәниятнең бер фундаменталь формасының икенчесенә алышынуы да үзгәртелүгә дучар булган җәмгыятьнең дә, аның мәдәниятенең дә һәлакәтенә китерми. Урта гасырлар ахыры Көнбатыш мәдәниятендә шул ук рәвештә бер фундаменталь социаль-мәдәни форма икенчесенә алышына... Шуңа да карамастан, мондый үзгәреш җәмгыятьнең яшәвенә нокта куймаган. Урта гасырлар ахырындагы көчеш чоры мәхшәрләреннән соң көнбатыш мәдәнияте һәм җәмгыяте биш гасыр дәвамында үзләренең иҗади мөмкинлекләренең бөтен гүзәллекләрен күрсәтте һәм дөнья мәдәнияте тарихына иң матур сәхифәләрнең берсен яздылар.

Сораулар һәм биремнәр: 1. П.Сорокин нинди «иске теорияләрне» тәнкыйтьли? Нинди теорияләр турында сүз бара? Аларны булдыручыларның исемнәрен атагыз. 2. Әлеге теорияләрне тәнкыйтьләп автор нинди дәлилләр китерә? Аларның көчле яклары бармы? Аларны атагыз.

§ 14. Тарихи процесс

Исегезгә төшерегез:

иҗтимагый үсешнең мәгънәсе һәм юнәлгәнлеге мәсьәләсен философлар ничек хәл итә? Җәмгыять үсеше проблемасына формацион һәм цивилизацион якын килүнең аермалыклары нәрсәдә?

Тарихи процесс — кешеләрнең күпләгән буыннарының эшчәнлеге чагылган бер-берсен алыштыручы вакыйгаларның

үзлекле чиратлашуы ул. Тарихи процесс — универсаль, ул кешенең тормыш эшчәнлегенең «тәмле ипикәй» табудан алып планеталардагы күренешләрне өйрәнүгә кадәр барлык чагылышларын колачлый.

Җир йөзендә кешеләр, аларның бергәлекләре яши, шунлыктан тарихи процессны яктырту, Н.Карамзин билгеләгәнчә, «халыкларның яшәеше һәм эшчәнлегенең көзгесе» булырга тиеш. Тарихи процессның нигезен, «җанлы тукымасын» вакыйгалар, ягъни иҗтимагый тормышның теге яки бу үткән яки үтүче күренешләре, фактлары тәшкил итә. Вакыйгаларның барлык бу чиксез алышынуларын аларның һәрберсенә хас булган, кабатланмас кыяфәтендә *тарих фәне* өйрәнә.

> **«Үз эшчәнлегебезнең бурычларын һәм юнәлешләрен билгеләп, аңлы һәм намуслы эш итүче гражданин булу өчен, безнең һәркайсыбыз аз гына булса да тарихчы булырга тиеш».**
>
> **В.О.Ключевский**

Җәмгыять белеменең тарихи процессны өйрәнүче тагын бер тармагы — *тарих философиясе* бар. Ул тарихи процессның гомуми табигатен, иң гомуми законнарын, тарихтагы иң әһәмиятле үзара бәйләнешләрне ачарга тырыша. Тарих философиясе — җәмгыять үсешенең борылышлардан һәм очраклылыклардан арындырылган эчке логикасын эзләүче өлкәсе ул. Тарих философиясенең кайбер мәсьәләләре (иҗтимагый үсешнең мәгънәсе һәм юнәлгәнлеге) үткән параграфта яктыртылды, башкалары (прогресс проблемалары) алдагысында ачылачак. Бу параграфта тарихи үсешнең социаль динамикасы типлары, факторлары һәм хәрәкәтләндерүче көчләре каралачак.

СОЦИАЛЬ ДИНАМИКА ТИПЛАРЫ

Тарихи процесс — динамикадагы, ягъни хәрәкәттәге, үсештәге җәмгыять ул. Соңгы өч сүз синонимнар түгел. Теләсә кайсы җәмгыятьтә кешеләрнең күптөрле эшчәнлеге тормышка ашырыла, дәүләт органнары, төрле учреждениеләр һәм берләшмәләр үз вазыйфаларын башкаралар, башкача әйткәндә, җәмгыять яши, хәрәкәт итә. Урнашкан иҗтимагый мөнәсәбәтләр көндәлек эшчәнлектә үзләренең сыйфат билгеләрен саклый, җәмгыять тулаем үз характерын югалтмый. Процессның мондый чагылышын җәмгыятьнең *эшләве* дип атарга була.

Социаль *үзгәрешләр* — теге яки бу социаль объектларның бер халәттән икенчесенә күчүе, аларда яңа үзлекләр, функция-

ләр, мөнәсәбәтләр барлыкка килү, ягъни социаль оешмалардагы, социаль институтлардагы, социаль структурадагы, җәмгыятьтә урнаштырылган үз-үзеңне тоту үрнәкләрендәге модификацияләр (яңарыш-үзгәрешләр) ул.

Җәмгыятьтә тирән, яңа сыйфат күчешләренә, социаль элементларне яңартып коруга, бөтен социаль системаның яңа халәткә күчүенә китерүче үзгәрешләр *социаль үсеш* дип атала.

Философлар һәм социологлар *социаль динамиканың төрле типларын* тикшерәләр. Киң таралган тип булып, иҗтимагый үсешнең күтәрелә яки төшә барган линиясе буларак, *линияле хәрәкәт* санала. Андый тип алдагы дәресләрдә каралачак прогресс (тәрәккыят) һәм регресс (түбән тәгәрәү) төшенчәләре белән бәйле. *Циклы тип* социаль системаларның вакыт эчендә билгеле бер дәвамлылыгы булган, ул беткәч яшәүдән туктаучы барлыкка килү, чәчәк ату һәм таркалу процессларын берләштерә. Социаль динамиканың бу тибы белән сез үткән дәресләрдә таныштыгыз. Өченче, *спиральсыман тип*, тарихның барышы теге яки бу җәмгыятьне элек үткән халәтенә, әмма турыдан-туры элгәреге этапка түгел, ә тагын да элгәресенә хас халәткә кире кайтарырга мөмкин дип тану белән бәйле. Бу вакытта күптән артта калган халәткә хас сыйфатлар кире кайта кебек, ләкин алар иҗтимагый үсешнең югарырак тармагында, сыйфат ягыннан яңа дәрәҗәдә кайта. Спиральсыман тип тарихи процессның озын чорларын күзәткәндә, тарихка зур колач белән якын килгәндә табыла дип исәпләнелә. Мисалга мөрәҗәгать итик. Сез, мөгаен, тарих курсыннан хәтерлисездер: мануфактура җитештерүнең таралган формасы «чәчелгән мануфактура» булган. Индустриаль үсеш эшчеләрне эре фабрикаларга туплый. Ә мәгълүмати җәмгыять шартларында, ничектер, яңадан өйдә эшләү формасына кайткан кебек була: һаман саен күбрәк хезмәткәрләр үз вазыйфаларын өйдән чыкмыйча, персональ компьютерларда башкаралар.

Фәндә тарихи үсешнең аталган теге яки бу вариантын тану яклылар була. Ләкин тарихта линияле дә, циклы да, спиральсыман да процесслар була дигән караш та бар. Алар параллель рәвештә яки бер-берсен алыштырып килмиләр, ә бербөтен тарихи процессның үзара бәйләнештәге аспектлары буларак эш итәләр.

Социаль үзгәрешләр төрле *формаларда* булырга мөмкин. «Эволюция» һәм «революция» сүзләре сезгә таныш. Аларның фәлсәфи мәгънәләрен ачыклыйк.

Эволюция ул — берсеннән икенчесенә сикерүләрсез һәм тәнәфесләрсез күчүче даими, өзлексез үзгәрешләр. Эволюция сикерешле сыйфат үзгәрешләрен характерлаучы «революция» төшенчәсенә капма-каршы куела.

Социаль революция ул — җәмгыятьнең барлык социаль структурасында икътисадны, сәясәтне, рухи өлкәне колачлаучы тирән, сыйфат ягыннан тамырдан үзгәртүләр. Эволюциядән аермалы буларак, революциягә җәмгыятьнең сыйфат ягыннан яңа халәтенә давыллы, сикерешле күчү, социаль системаның структураларын тиз үзгәртү хас. Революция иске иҗтимагый стройны яңасына алыштыра. Яңа стройга күчү чагыштырмача тыныч та, көчләү формаларында да булырга мөмкин. Аларның нисбәте конкрет тарихи шартларга бәйле. Еш кына революцияләр җимергеч, рәхимсез гамәлләр, канлы корбаннар белән бара. Кайбер галимнәр һәм сәясәт эшлеклеләре аларның кешегә карата көчләү кулланулары белән дә, социаль тормышның «тукымасын» — иҗтимагый мөнәсәбәтләрне көч кулланып өзү белән дә бәйле тискәре сыйфатларын һәм куркынычлыкларын күрсәтәләр. Башка берәүләр революцияне «тарих локомотивлары» дип атыйлар. (Тарих курсыннан алынган белемнәрегезгә таянып, социаль үзгәрешләрнең бу формасына үз бәяләмәгезне бирегез.)

Социаль үзгәрешләрнең формаларын тикшергәндә реформаларның роле турында да искә алырга кирәк. «Реформа» төшенчәсе белән сез тарих курсында таныштыгыз. **Ешрак социаль реформа дип ялпә килгән иҗтимагый стройны саклап, иҗтимагый тормышның кайсы да булса ягын (институтларны, учреждениеләрне, тәртипләрне һ.б.) үзгәртеп коруны атыйлар.** Эволюцион үзгәрешләрнең строй нигезләрен алыштырмый торган бер төрләре алар. Реформалар гадәттә «өстән», ягъни хакимлек итүче көчләр тарафыннан үткәрелә. Реформаларның колачы һәм тирәнлеге җәмгыятькә хас динамиканы характерлый.

Шуның белән бергә бүгенге фән революциягә альтернатива булырдай, аны кисәтерлек яки алыштырырлык тирән реформалар системасын гамәлгә ашыру мөмкинлеген дә таный. Үзләренең колачы һәм нәтиҗәләре белән андый революцион реформалар, социаль революцияләргә хас стихияле көчләүләр белән бәйле тетрәнүләргә бармыйча, җәмгыятьне тамырдан үзгәртә алалар.

СОЦИУМНЫҢ ҮЗГӘРҮЕ ФАКТОРЛАРЫ

«Фактор» сүзе тарихи процессның характерын яки аерым сыйфатларын билгеләүче сәбәбен, хәрәкәткә китерүче көчен аңлата. Җәмгыять үсешенә йогынты ясаучы факторлар төрлечә була. Аларның кайберләрендә табигый, технологик һәм рухи факторлар аерып алына.

XVIII гасыр француз мәгърифәтчесе Ш.Монтескье *табигый факторлары* — төп билгеләүче факторлар, климат шартлары кешенең шәхси үзенчәлекләрен, аның характерын һәм һәвәсләрен билгели дип исәпли. Уңдырышлы туфраклы илләрдә үзара бәйлелек хисе җиңелрәк урнаша, чөнки җир эшләре белән мәшгуль кешеләрнең ирек турында уйларга вакытлары юк. Ә салкын климатлы илләрдә кешеләр уңышка караганда күбрәк үзләренең иреге турында уйлый. Шундый фикер йөртүләрдән сәяси хакимиятнең характеры, законнар, сәүдә һ.б. турында нәтиҗәләр ясалган.

Башка фикер йөртүчеләр җәмгыятьнең хәрәкәт итүен *рухи фактор* белән аңлатканнар: «Дөнья белән идеяләр идарә итә». Аларның кайберләре болар — иҗтимагый төзелешнең идеаль проектларын төзүче тәнкыйди фикер йөртүче шәхесләр идеяләре дип санаганнар. Ә немец философы Г.Гегель, дөнья белән «дөнья акылы» хакимлек итә, дип язган.

Тагын бер караш кешеләрнең эшчәнлеген *матди факторларның* ролен өйрәнеп фәнни аңлатып була дигәннән тора. Җәмгыять үсешендә матди җитештерүнең әһәмиятен К.Маркс нигезли. Ул шуңа игътибар итә: фәлсәфә, сәясәт, сәнгать белән шөгыльләнүгә кадәр кешеләр ашарга, эчәргә, киенергә, тораклы булырга, димәк, боларның барысын җитештерергә тиеш. Маркс өйрәткәнчә, җитештерүдәге үзгәрешләр тормышның башка өлкәләрендә дә үзгәрешләр китереп чыгара. Җәмгыять үсеше, ахыр чиктә, кешеләрнең матди, икътисади мәнфәгатьләре белән билгеләнә.

Күп кенә галимнәр бүген дә җәмгыять хәрәкәтенең билгеләүче факторын (аны башкалардан аерып) табарга була дип исәплиләр. XX гасырдагы фәнни-техник революция шартларында андый фактор итеп алар *техника* һәм *технологияне* таный. Җәмгыятьнең яңа сыйфатка күчүен алар нәтиҗәләре икътисадта, сәясәттә, мәдәнияттә чагылган «компьютер революциясе», мәгълүмати технологияләр үсеше белән бәйлиләр.

Тарихи үзгәрешләрне нинди дә булса бер фактор белән аңлату мөмкинлеген кире кагучы галимнәр карашлары югарыда китерелгән карашларга каршы килә. Алар үсешнең бик тә төрле сәбәпләре һәм шартларының үзара бәйләнешен тикшерәләр. Мәсәлән, немец галиме М.Вебер, рухи фактор икътисади фактордан кимрәк роль уйнамый, мөһим тарихи үзгәрешләр тегесенең дә, монысының да йогынтысы астында үткәннәр, дип дәлилли. (Тарих курсында өйрәнгәннәрегезгә таянып, социаль үзгәрешләр факторларына карата югарыда китерелгән карашларга үз мөнәсәбәтегезне белдерегез. Сезнеңчә, кайсы аңлату ышандырырлык?)

Аталган факторлар *кешеләрнең эшчәнлегенә* актив йогынты ясый. Әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашырган барчасы: индивидлар, төрле социаль бергәлекләр, аларның оешмалары, бөек шәхесләр тарихи процесс субъектлары булып торалар. Башка караш та бар: тарихның аерым индивидлар һәм аларның бергәлекләре эшчәнлеге нәтиҗәсе икәнлеген инкарь итмәстән, кайбер галимнәр тарихи процесс субъекты дәрәҗәсенә бары тик җәмгыятьтә үз урынын тойган, иҗтимагый әһәмиятле максатларны гына кулланган һәм аларны тормышка ашыру өчен көрәшкән кешеләр генә күтәрелә дип уйлыйлар.

ТАРИХИ ПРОЦЕССТА ХАЛЫКНЫҢ РОЛЕ

Бу рольне галимнәр төрлечә аңлата. Марксистик философиядә беренче чиратта хезмәт ияләре кергән *халык массалары* — тарихны иҗат итүчеләр, алар матди һәм рухи кыйммәтләрне булдыруда, иҗтимагый-сәяси тормышның төрле өлкәләрендә, Ватанны саклауда хәлиткеч роль уйныйлар дип раслана.

Тикшеренүчеләрнең бер өлеше, халык массаларының ролен характерлап, беренче урынга иҗтимагый мөнәсәбәтләрне камилләштерүгә омтылучы социаль көчләрне куялар. Алар, «халык» төшенчәсе төрле тарихи чорда төрле эчтәлеккә ия, «халык — тарихны иҗат итүче» формуласы бары тик җәмгыятьнең алгарышлы үсүе белән кызыксынучы катлауларын һәм сыйныфларын гына берләштерүче киң бергәлекне аңлата, диләр. Алар фикеренчә, «халык» төшенчәсе белән җәмгыятьнең прогрессив көчләре реакцион көчләрдән аерыла. Халык ул — барыннан да бигрәк хезмәт ияләре, алар һәрвакыт аның төп массасын тәшкил итәләр. Шуның белән бергә, «халык» төшенчәсе, хезмәт ияләре булмасалар да, тарихи үсешнең әлеге баскычында алгарышлы хәрәкәт мәнфәгатьләрен чагылдыручы катлауларны да үз эченә ала. Мисал итеп гадәттә XVII – XIX гасырларда феодализмга каршы революцияләрне җитәкләгән буржуазияне китерәләр.

Рус тарихчысы *В.О.Ключевский* (1841–1911) «халык» төшенчәсенә социаль эчтәлек бирми, аңа этник һәм этик эчтәлек кертә. «Халыкка,— дип яза В.О.Ключевский, — этнографик һәм әхлакый элемтәләр, уртак тормыш һәм уртак эшчәнлек, тарихи язмышлар һәм мәнфәгатьләр тарафыннан тәрбияләнгән рухи бердәмлекне тою хас». «Эшләрендә бөтен халык катнашкан һәм шуның аркасында үзен бербөтен, гомуми эшне эшләүче итеп тойган» тарихи дәверләр аеруча әһәмиятле, ди В.О.Ключевский.

Халыкны югары күтәрүче раслауларга кайбер башка фикер ияләре каршы килә. *А.И.Герцен* (1812–1870), халык — инстинкты буенча консерватор, «ул үзен кайгыга салган көнкүрешкә, кереп кысылган тар кысаларга мәҗбүр ителгән... Тарих агышыннан никадәр ераграк булса, халык үзләштерелгәнгә, таныш нәрсәләргә шулкадәр ябышыбрак ята. Ул хәтта яңаны да иске киемнәрдә аңлый... Тәҗрибә халыкка артык ирекка караганда көчләү авырлыгына түзү җиңелрәк икәнен күрсәтте».

Рус философы *Н.А.Бердяев* (1874–1948) халыкның демократик инанулары булмаска мөмкин дип исәпли. «Халык бөтенләй дә демократик фикер йөртә алмаска, бөтенләй дә демократик халәттә булмаска мөмкин... Әгәр халыкның ихтыяры явыз стихияләргә буйсындырылган икән, ул — изелгән һәм изүче ихтыяр».

Кайбер хезмәтләрдә «халык» һәм «масса» төшенчәләрендәге аермага басым ясала. Немец галиме *К.Ясперс* (1883–1969), массаны халыктан аерып карарга кирәк, ди. Халык структурлашкан, ул үзен тормыш нигезләрендә, үзенең фикер йөртүендә, традицияләрендә аңлый. Масса, киресенчә, структурлашмаган, үзаңга ия түгел, ул нинди дә булса аерым сыйфатлардан, традицияләрдән нигездә мәхрүм, ул — буш. «Кешеләр массалар арасында башларын бик җиңел югалтырга, «башкалар булу»ның исерткеч мөмкинлегенә бирелергә, аларны тәмуг упкынына төшерүче күсе капкынына ияреpгә мөмкиннәр. Акылсыз массалар аларны алдаучы тираннар белән үзара эш итәргә мөмкиннәр».

Шулай итеп, фикер ияләренең халыкның роленә карашлары нык аерыла. (Уйлагыз: алда бәян ителгән карашларның кайсысы халык массаларының ролен төгәлрәк чагылдыра? Бәлкем, бу мәсьәләдә сезнең үз карашыгыз бардыр? Сез аны ничек дәлилли алыр идегез? Халыкның эш-гамәлләре вакыйгалар агышына йогынты ясаган мисаллар китерегез.)

Халыкның нормаль тормыш эшчәнлеге өчен *элиталар* дип аталган аерым катлауларның булуы да мөһим. Алар — җәмгыятьнең сәяси, икътисади, мәдәни тормышында төп урынны алып торучы чагыштырмача аз санлы кешеләр, яхшырак квалификацияле белгечләр. Ул кешеләр массалардан интеллектуальлекләре һәм әхлаклылыклары, югары җаваплылык хисләре белән өстен торалар дип уйланыла. (Һәрвакытта да шулаймы?) Кайбер философлар фикеренчә, элиталар җәмгыятьне идарә итүдә, мәдәниятне үстерүдә аерым роль уйныйлар. (Уйлагыз: җәмгыять тормышының төрле даирәләре: икътисад, сәясәт, хәрби өлкә һ.б. белән идарә итүчеләр нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?)

СОЦИАЛЬ ТӨРКЕМНӘР ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ БЕРЛӘШМӘЛӘР

Һәр индивид нинди дә булса бергәлектә тора. Тарихи процессларда катнашучылар турында сөйләгәндә, без *социаль төркемнәр* кебек бергәлекләргә мөрәҗәгать итәбез. Инглиз философы *Т.Гоббс* болай дип яза: «Кешеләр төркеме дигәндә мин уртак мәнфәгатьләр яки уртак эшләр белән берләшкән кешеләрнең билгеле бер санын күздә тотам». Мәнфәгатьләр үзләренең юнәлешләре (дәүләти, сәяси, икътисади, рухи) белән аерылырга; чын һәм ялган, прогрессив һәм регрессив яисә консерватив характерда булырга мөмкин.

Кешеләрнең тарихи яктан тотрыклы һәм озак вакыт яшәүче төркемнәре була. Сезгә сыйныфлар (коллар — колбиләүчеләр, феодаллар — крестьяннар һ.б.); кабиләләр, халыклар, милләтләр; катлаулар; дини (протестантлар, католиклар һ.б.), профессиональ (шахтерлар, укытучылар һ.б.), территориаль (кайсы да булса өлкә кешеләре) билгеләр, яшь (яшьләр, өлкән кешеләр һ.б.) буенча аерыла торган төркемнәр билгеле. Һәр төркемгә хас гомуми мәнфәгатьләр әгъзаларының җитештерүдә, иҗтимагый һәм дини тормышта һ.б. тоткан урыны белән билгеләнә. Тарихның төрле чорларында без теге яки бу төркемне вакыйгаларда актив катнашучы итеп күрәбез. (Колларның баш күтәрүен, «өченче сыйныф»ның монархиягә каршы көрәшен, милли-азатлык хәрәкәтләрен, диннәр сугышларын һәм җәмгыятьнең төрле төркемнәренең тарихи вакыйгаларда актив ролен дәлилләүче башка фактларны исегезгә төшерегез.)

Үз мәнфәгатьләрен яклау өчен социаль төркемнәр *иҗтимагый берләшмәләр* оештыралар, аларга төркемнең активрак әгъзалары керә. **Иҗтимагый берләшмәләр дигәндә гражданнарның ирекле катнашуга, карашлар һәм мәнфәгатьләр уртаклыгына, үзидарәгә нигезләнгән, үз хокукларын һәм мәнфәгатьләрен уртак тормышка ашыру максатын куйган оешмалар аңлашыла.** (Урта гасырлар гильдияләрен, Франциядәге революция чорындагы сәяси клубларны исегезгә төшерегез.) Яңа вакытта исә ялланган эшчеләрнең *профессиональ союзлары* барлыкка килә. Аларның бурычы — хезмәтияләренең икътисади мәнфәгатьләрен яклау. Эшмәкәрләр эшләрен җайга салучы *эшмәкәрлек оешмалары* да булдырыла. Шулай ук җир эшкәртүчеләрнең мәнфәгатьләрен чагылдыручы *авыл хуҗалыгы оешмалары* барлыкка килә. *Чиркәү* кебек йогынтылы оешма турында да онытырга ярамый. Хакимиятне кулга алу өчен Яңа вакытта *сәяси партияләр* оештырыла. (Уйлагыз: иҗтимагый оешмаларның тарихи процесска сизелерлек йогынты ясавын нинди мисаллар күрсәтә ала?)

ТАРИХИ ШӘХЕСЛӘР

Параграф башында тарихи процессның универсаль булуы әйтелде. Ул кеше эшчәнлегенең барлык чагылышларын колачлаганга күрә, тарихи шәхесләр даирәсенә иҗтимагый тормышның төрле өлкәләре эшлеклеләре: сәясәтчеләр һәм галимнәр, сәнгать эшлеклеләре һәм дин лидерлары, хәрби башлыклар һәм төзүчеләр — тарих барышына шәхси йогынты ясаган барча кешеләр керә. Тарихчылар һәм философлар теге яки бу шәхеснең тарихта тоткан ролен бәяләүче төрле сүзләр кулланалар: тарихи шәхес, бөек кеше, герой. Билгеле бер эшлекленең тарихка сизелерлек өлеш кертүен чагылдыру белән бергә, әлеге бәяләмәләр тикшеренүченең дөньяга карашына, сәяси карашларына бәйле һәм шактый дәрәҗәдә субъектив характерда була. «Бөек» дигән төшенчә — чагыштырмача төшенчә», — дип яза рус философы Г.В.Белинский.

Тарихи шәхеснең эшчәнлеге шул кеше яшәгән чорның үзенчәлекләрен, аның нинди әхлакны сайлавын, эш-гамәлләрендәге җаваплылыгын исәпкә алып бәяләнергә мөмкин. Бәя уңай яки тискәре, ләкин ешрак күп мәгънәле була, бу эшлекленең уңай яки тискәре якларын исәпкә алып бирелә. «Бөек шәхес» төшенчәсе, кагыйдә буларак, тамырдан прогрессив үзгәртеп коруны гәүдәләндерүче кешеләр эшчәнлеген характерлый. «Бөек кеше шуның белән бөек,— дип яза Г.В.Плеханов,— анда үз заманының бөек иҗтимагый бурычларына хезмәт итү өчен кирәкле сыйфатлар бар... Бөек кеше нәкъ менә башлаучы булып тора, чөнки ул башкалардан ераграк күрә һәм башкалардан көчлерәк тели. Ул чиратка җәмгыятьнең алдагырак акыл үсеше тарафыннан куелган фәнни бурычларны чишә; ул иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең алдагы үсеше булдырган яңа иҗтимагый бурычларны күрсәтә; ул бу бурычларны канәгатьләндерүдә башлап йөри».

> **«Бөек кеше турында аның хаталары буенча түгел, фәкать аның төп эшләре буенча гына фикер йөртәләр».**
>
> **Ф.Вольтер**

В.О.Ключевский үз лекцияләрендә тарихи эшлеклеләрнең истә калырлык образларын бирә. Гәрчә сүз чагыштырмача ерак гасырлар кешеләре турында барса да, әлеге шәхесләрнең ул ачкан сыйфатлары хәзер дә шактый кызыксыну тудыра, чөнки, ул язганча, кыен минутларда яхшы кешеләр үрнәге дәртләндереп кенә калмый, ничек эшләргә дә өйрәтә. В.О.Ключевский фикеренчә, тарихи шәхесләргә дәүләт һәм халыкның гомуми бәхетенә хезмәт итәргә омтылыш; мондый хезмәт итү өчен

кирәкле батырлык; кичергән бәлаләрнең сәбәбен табу өчен рус тормышы шартларына, урнашкан иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең иң төбенә төшү өчен теләк һәм осталык, милли чикләнгәнлектән ваз кичү; барлык эшләрдә, шул исәптән дипломатиядә дә, вөҗданлык; үзгәртеп кору омтылышларына һәм уйларына, зирәклелегенә һәм башкарып чыгу мөмкинлегенә ышанып булган, файдасы һәркемгә күренеп торган гади, ачык һәм ышандырырлык планнар җиткерү омтылышы хас.

Төп төшенчәләр: тарихи процесс, социаль динамика типлары, социаль үзгәрешләр факторлары, тарихи процесс субъектлары.

Терминнар: тарих философиясе, эволюция, революция, реформа, халык массалары, тарихи шәхес.

Үзегезне тикшерегез

1. «Тарихи процесс» төшенчәсенең мәгънәсе нәрсәдә? 2. Фәндәге социаль динамика типлары турындагы күзаллаулар нәрсә белән аерылалар? 3. Җәмгыятьне тамырдан, сыйфат ягыннан яңартуның мөмкин булган вариантлары нинди? 4. Тарихи процесс характерына нинди факторлар тәэсир итә? 5. Тарихи процесста катнашучыларның кайсылары тарихны алга этәрүче көчләр булып тора? 6. Тарихи процессларда халык массаларының һәм даһи кешеләрнең нисбәте нинди?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Борынгы грек философы Фукидидның (б.э.к. 460 – 400 еллар) «Тарих — мисаллардагы философия ул» дигән фикере тарих фәне белән философия арасындагы нисбәтне чагылдырамы? Үз карашыгызны дәлилләгез.

2. 1999 елда социологлар, барлык вакытларның иң күренекле кешеләрен атауларын сорап, сорап белешү үткәргәннәр. Нәтиҗәдә барыннан да бигрәк түбәндәгеләрне атаганнар: Петр I — 46 %, Ленин — 42 %, Пушкин — 42 %, Сталин — 35%, Гагарин — 26 %, Жуков — 20 %, Наполеон — 19 %, Суворов — 18 %, Ломоносов — 18 %, Менделеев — 12 %. Күренекле ун кешедән торган үз исемлегегезне төзегез һәм аны югарыда күрсәтелгәннәр белән чагыштырыгыз. Үзегез сайлаганны дәлилләгез һәм аның социологлар тикшеренүләре нәтиҗәләреннән аермалыклары ихтималын аңлатыгыз.

3. Параграфта бәян ителгән карашлардан чыгып, сезгә билгеле иң нык танылган тарихи шәхесне анализлагыз.

4. Н.А.Бердяевның: «Кечкенә башлангыч дәверләрдән башлап тарихның иң югары түбәсенә, бүгенге дәвергә кадәрге барлык тарихи дәверләр — барысы да минем тарихи язмышым,

барысы да минеке»,— дип әйтүенә ничек карыйсыз? Үз карашыгызны дәлилләгез.

5. Җәмгыять белеменең бу темасы белән бер үк вакытта сез тарихның кайсы чорын өйрәнәсез? Җәмгыятьтә ул чорда булган үзгәрешләрне анализлагыз. Түбәндәге сорауларга җавап табарга тырышыгыз; ул үзгәрешләрнең характеры нинди? Социаль динамиканың кайсы тибы булган? Иҗтимагый үсешнең кайсы факторлары ни рәвешле эш иткән? Тарихи процесс субъектлары үзләрен ничек чагылдырган?

Чыганак белән эшләгез

Рус тарихчысы һәм философы Л.П.Карсавин тарих философиясе турында.

Тарих философиясе үзенең төп өч бурычы белән аерылып тора. *Беренчедән*, ул бер үк вакытта тарихи белемнәрнең, фән буларак тарихның төп башлангычлары булган тарихи яшәешнең беренче башлангычын тикшерә. *Икенчедән*, ул башлангычларны яшәеш һәм белемнең бердәмлегендә тикшерә, ягъни тарихилыкның тулаем дөньядагы һәм абсолют Яшәешкә мөнәсәбәттәге әһәмиятен һәм урынын күрсәтә. *Өченчедән*, аның бурычы конкрет тарихи процессны тулы килеш танып-белүдән һәм сурәтләүдән, әлеге процессның мәгънәсен ачудан гыйбарәт. Тарих философиясе үзен беренче бурыч белән чикләгәнлектән, ул *тарих «теориясе»*, ягъни тарихи яшәеш теориясе һәм тарихи белем теориясе булып тора. Ул икенче бурычны чишүне күздә тота, шуңа күрә — «философия» атамасының тар һәм махсус мәгънәсендәге *тарих философиясе*. Ниһаять, өченче бурыч билгеләгән өлкәдә ул безнең алга *тарих метафизикасы* буларак килеп баса; өстәвенә, әлбәттә, *«метафизика»* атамасында мин конкрет эмпириядән читкә китүне түгел, ә тарихи процессны иң югары метафизик идеяләр яктылыгында конкрет танып-белүне күздә тотам.

Тарих теориясе һәм тарих философиясе проблемаларының тирән органик, аерылмас бәйләнешләре беренче карауга ук ачык күренә. Тарихның нигез башлангычларын аларның яшәеш һәм гомумән белем нигез башлангычларына мөнәсәбәтеннән башка, шулай булгач, аларның абсолют Яшәеш белән элемтәләрен ачыкламыйча билгеләү мөмкин түгел. Тарих теоретигының һәрберсе, әгәр ул үзен ясалма рәвештә техник методология дип аталган мәсьәләләр эченә ябып куймаса, котылгысыз рәвештә түбәндәгеләрне ачыкларга тиеш: тарихи яшәешнең үзенчәлеге нәрсәдә һәм ул үзенчәлек бармы; тарихи танып-белүнең төп категорияләре, төп тарихи төшенчәләре нинди, алар табигатьне танып-белү өлкәсендәге кебекме, әллә башкачамы һ.б. Болар-

ның барысы да теоретик-тарихи һәм фәлсәфи-тарихи проблемаларны үзара бәйләнештә карау зарурлыгын тудыра.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Автор фикеренчә, тарих философиясенең бурычы нидән гыйбарәт? Һәр бурычның мәгънәсен сез ничек аңлыйсыз? 2. Тарихи яшәеш һәм тарихи белем ничек ярашалар? 3. Тар мәгънәдә тарих философиясе нинди бурычны хәл итәргә тиеш? 4. Тарихның теоретик һәм фәлсәфи проблемаларын карауны автор ни өчен берләштерә? 5. Конкрет тарихи процессны һәм тарих философиясен өйрәнүнең бәйләнешләре нинди? 6. Бу параграфта каралган кайсы сорауларны философиянең кайсы бурычларына кертергә була?

§ 15. Иҗтимагый прогресс проблемасы

Исегезгә төшерегез:

«җәмгыять төшенчәсенә фән нинди мәгънә сала? Җәмгыятьне аңлауга линияле-стадияле якын килү локаль-цивилизацияле якын килүдән нәрсәсе белән аерыла?

Борынгы грек шагыйре *Гесиод* (б.э.к. VIII–VII гасырлар) кеше тормышындагы биш стадия турында яза. Беренче стадия — кешеләр җиңел, артык уйламыйча яшәгән «алтын гасыр», икенчесе — әхлак һәм намуслылык кими башлаган «көмеш гасыр». Шулай һаман саен түбәнгә төшеп, кешеләр һәркайда явызлык, көчләү хөкем сөргән, гаделлек санга сугылмаган «тимер гасыр»га килеп җитәләр.

Гесиодтан аермалы буларак, борынгы грек философы Платон һәм Аристотель тарихка бер үк стадияләрне кабатлаучы цикллы өзлексез хәрәкәт буларак карыйлар.

XVIII гасырда француз философ-мәгърифәтчесе *Жан Антуан Кондорсе* (1743–1794), тарих өзлексез кабатлаулар күренешен гәүдәләндерә, дип яза. «Кешенең нәрсә булганын һәм ул хәзер нәрсә булып әверелгәнен күзәтүләр табигать аңа өметләнергә мөмкинлек биргән яңа уңышларны тәэмин итү һәм тизләтү чараларын табарга ярдәм итәчәк»,— дип яза Кондорсе.

ПРОГРЕСС ҺӘМ РЕГРЕСС

Үсешнең түбәннән — югарыга, камил булмаганнан камилрәккә күчү хас булган юнәлеше фәндә *прогресс* дип атала; ул латинчадан алынган, туры мәгънәсендә «алга таба хәрәкәт» дигәнне аңлата. Прогресска *регресс* каршы куела. Регресска югарыдан түбәнгә хәрәкәт, таркалу процесслары, искергән форма һәм структураларга кире кайту хас.

1500 елга кадәр Европада елына 1 мең чамасы исемдәге китап басылган. 1950 елда 120 меңнән артык китап нәшер ителгән. 1960 еллар уртасына дөньякүләм (Европаны да кертеп) китап җитештерү көненә 1 мең исемгә кадәр җиткән.

Кондорсе нигезләгән прогресс идеясен күпләгән фикер ияләре алга таба да үстергәннәр. Өстәвенә алар аның яңа аспектларын ачканнар. Прогресска мондый ышануны К.Маркс та кабул иткән, ул кешелек дөньясы җитештерүнең һәм кешенең үзенең тагын да зуррак үсешенә бара дип исәпләгән.

XIX–XX гасырлар җәмгыять тормышында прогресс һәм регресс турында фикер йөртү өчен яңа мәгълүмат биргән давыллы вакыйгалар белән үзенчәлекле. XX гасырда җәмгыять үсешенә оптимистик караштa торган, якты киләчәк иртәме-соңмы булачак ул дигәннән баш тарткан фәлсәфи һәм социологик теорияләр барлыкка килгән. Испания философы *Х. Ортега-и-Гассет* (1883–1955) прогресс идеясе турында болай дип яза: «Бу идеягә үз акылларын капларга ирек куйганлыктан, кешеләр тарих тезгенен үз кулларыннан ычкындырдылар, сизгерлекләрен һәм осталыкларын югалттылар, һәм тормыш алар кулыннан ычкынды, аларга буйсынмый башлады. Прогресс идеясе урынына төрле философлар циклы өзлексез хәрәкәт теорияләре, «тарихның ахыры» турындагы пессимистик идеяләр, глобаль экологик, энергетик һәм атом-төш фаҗигаләре тәкъдим итәләр.

Шулай итеп, җәмгыять кайсы юлдан бара — прогресс юлынынмы, әллә регресскамы? Кешеләрнең киләчәк турында ул яхшы тормыш алып киләме яисә бернинди дә яхшылык вәгъдә итмиме дип күзаллаулары шушы сорауга җавапның нинди булуына бәйле.

ПРОГРЕССНЫҢ КАРШЫЛЫКЛЫЛЫГЫ

XIX–XX гасырлар тарихыннан фактларны искә төшерик: революцияләр артыннан еш кына контрреволюцияләр, реформалар артыннан контрреформалар, сәяси төзелештәге тамырдан үзгәртеп корулар артыннан иске тәртипләрне яңадан торгызу булган. (Уйлагыз: бу фикерне илебездәге яки гомуми тарихтагы нинди мисаллар белән күрсәтеп була?) Әгәр без кешелек дөньясының прогрессын график рәвештә сурәтләргә тырышсак, безнең алда югарыга үрләгән туры сызык түгел, ә иҗтимагый көчләр көрәшендәге күтәрелешләрне һәм түбән төшүләрне, ташу һәм чигенүләрне, алга тиз баруларны

һәм искитмәле артка чигенүләрне чагылдыручы сынык линияне күрер идек. Төрле илләр тарихында реакция тантана иткән, җәмгыятьнең прогрессив көчләре эзәрлекләнгән, акыл карагруһчылык тарафыннан басылган чорлар булган. Мәсәлән, сез фашизмның Европага нинди бәла-казалар китерүен: миллионнарча кешеләрне үтерүен, күпләгән халыкларны бөлгенлеккә төшерүен, мәдәният үзәкләрен җимерүен, даһи фикер ияләре һәм рәссамнарның иң яхшы китапларын учакка ташлауларын, кешене мыскыл иткән әхлак, тупас көч культы урнаштыруын беләсез.

Ләкин эш тарихның мондый сыныкларында гына да түгел. Җәмгыять ул — катлаулы механизм, анда төрле «әгъзалар» (предприятиеләр, кешеләр берләшмәләре, дәүләт учреждениеләре һ.б.) эшли, бер үк вакытта төрле (икътисади, сәяси, рухи һ.б.) процесслар бара, кешеләрнең төрле эшчәнлеге җәелдерелә. Бер иҗтимагый организмның бу өлешләре, бу процесслар, эшчәнлекнең төрле төрләре үзара бәйләнештә булалар һәм, шуның белән бергә, үз үсешләрендә туры килмәскә мөмкиннәр. Ул гына да түгел, тормышның төрле өлкәләрендә бара торган аерым процессларның, үзгәрешләрнең төрле юнәлештә булулары, ягъни бер өлкәдәге прогрессның икенче өлкәдәге регрессы белән бергә баруы ихтимал.

Мәсәлән, тарих дәвамында техниканың прогрессы: таш коралларданн — тимерләренә, кул коралларыннан — машиналарга, кеше һәм йөк хайваннары көченнән — пар двигательләренә, электр генераторларына, атом электр станцияләренә, йөк хайваннарында ташудан — автомобильләргә, тиз йөрешле поездларга, самолетларга, космик корабльләргә, сөякле агач счетлардан куәтле компьютерларга ирешү күзәтелә.

Ләкин техника прогрессы, индустриянең үсүе, химияләштерү һәм җитештерү өлкәсендәге башка үзгәрешләр табигатьне бозуга, кешене чолгап алган мохиткә төзәтеп булмаслык зыян салуга, җәмгыять яшәешенең табигый нигезләрен җимерүгә китерде. Шулай итеп, бер өлкәдәге прогресс икенчесендәге регресс белән бергә барды. **Җәмгыятьнең тарихи үсеш процессы каршылыклы: анда прогрессив үзгәрешләрне дә, регрессивларны да табарга була.**

Фән һәм техника прогрессының нәтиҗәләре бертөрле генә булмый. Атом-төш физикасы өлкәсендәге ачышлар энергиянең яңа чыганагын алу гына түгел, куәтле атом коралы булдыру мөмкинлеге дә бирде. Компьютер техникасын куллану иҗади хезмәт мөмкинлекләрен гадәттән тыш киңәйтеп кенә калмады, ә бәлки дисплей янында озак, туктаусыз эшләү белән бәйле авырулар: күрү начарлануулар, психик тайпылышлар да китереп чыгарды; боларга өстәмә психик авырлыклар сәбәп булды.

Эре шәһәрләр барлыкка килү, производствоның катлаулануы, тормыш ритмы үзгәрү — боларның барысы да кеше организмына йөкне арттырды, стресслар һәм шуның нәтиҗәсе буларак нерв системасы патологияләре, кан тамырлары авырулары китереп чыгарды. Кеше рухының бик тә бөек казанышлары белән бергә, дөньяда рухи һәм мәдәни кыйммәтләрнең кимүе күзәтелә, наркомания, эчкечелек, җинаятьчелек тарала.

Кешелек дөньясына прогресс өчен зур бәя түләргә туры килә. Шәһәр тормышы уңайлыкларына шәһәрләшү авырулары: транспортта ару, пычранган һава, урам шау-шуы һәм аларның нәтиҗәләре — стресслар, сулыш әгъзалары авырулары һ.б. белән түләргә кирәк була; автомобильдә йөрү уңайлы булса, шәһәр магистрале тыгызлана, транспорт «бөке»ләре барлыкка килә.

Прогрессны тизләтергә тырышу кайчак искитмәле югары бәягә төшә. Безнең ил XX гасырның 20–30 нчы елларында сәнәгатьнең кайбер мөһим продуктларын җитештерү күләме буенча Европада беренче урынга чыкты. Тизләтелгән темпларда индустриальләштерү гамәлгә ашырылды, авыл хуҗалыгын механикалаштыру башланды, халыкның белем дәрәҗәсе күтәрелде. Әлеге казанышларның кире ягы да булды: миллионнарча кеше рәхимсез ачлык корбанына әверелде, йөзләрчә мең кеше үзе күнеккән яшәү урыныннан кузгатылды, миллионнар репрессияләнде, кешеләрнең тормышы тоталь «көйләү»гә һәм контрольгә буйсындырылды.

Әлеге каршылыклы прогрессларны ничек бәяләргә соң? Шундый югары бәяләр белән түләнгән уңай үзгәрешләрне прогрессив дип бәяләп буламы? Төрлечә бәяләнә торган мондый үзгәрешләр булганда, тулаем иҗтимагый прогресс турында сөйләү мөмкинме? Моның өчен прогрессның гомуми критерие нәрсә икәнен, җәмгыятьтәге нинди үзгәрешләрне — прогрессив, ә кайсыларын регрессив дип бәяләргә мөмкин икәнен белергә кирәк.

ПРОГРЕСС КРИТЕРИЙЛАРЫ

Башка француз мәгърифәтчеләре кебек үк, А.Кондорсе да прогресс критерие итеп акыл үсешен саный. Социалист-утопистлар прогрессның әхлакый критерийларын тәкъдим итәләр. Мәсәлән, Сен-Симон җәмгыятьне оештыру шундый форма алырга тиеш ки, ул барлык кешеләр бер-берсенә туганлык мөнәсәбәтләрендә булырлык әхлакый принципларны тормышка ашырырга тиеш дип исәпли. Социалист-утопистларның замандашы, немец философы *Фридрих Вильгельм Шеллинг* (1775–1854), тарихи прогресс турындагы мәсьәләләр

шуның белән катлауланды ки, кешелек дөньясының камилләшүенә ышану яклылар һәм аларга каршы торучылар прогресс критерийлары турындагы бәхәсләрдә тулысынча буталып беттеләр, дип яза. Берәүләр — кешелек дөньясының әхлак өлкәсендәге прогрессы турында, икенчеләр, Шеллинг язганча, тарихи күзлектән караганда, күбрәк регрессив булган фән һәм техника прогрессы турында баш ваталар. Проблеманы хәл итүгә ул үз тәкъдимен бирә: кешелек ыругының тарихи прогрессын раслауда критерий булып фәкать хокукый төзелешкә акрынлап якынаю гына хезмәт итә ала.

Иҗтимагый прогресска тагын бер карашка немец философы *Г.Гегель* (1770–1831) ия. Прогресс критерием ул иреклe аңлауда күрә. Ирекле аңлау үскән саен, җәмгыять тә эзлекле үсә.

Күргәнебезчә, прогресс турындагы мәсьәлә Яңа вакытның бөек акылларын җәлеп итә, ләкин чишелеш тапмый. Әлеге бурычны хәл итәргә бөтен тырышуларның кимчелеге шунда: барлык очракларда да критерий сыйфатында иҗтимагый үсешнең фәкать бер линиясе (яки бер ягы, бер өлкәсе) тикшерелә. Акыл, әхлак, фән, техника, хокукый тәртип, ирекле аңлау — боларның барысы да бик мөһим күрсәткечләр, ләкин универсаль, кеше һәм җәмгыять тормышын тулаем колачлый торган түгел.

Безнең заманда да философлар иҗтимагый прогресс критерийларына төрле караштa торалар.

Карашларның берсендә иҗтимагый прогрессның югары һәм гомуми объектив критерие җитештерүче көчләрне (кешенең үзенең үсешен дә кертеп) үстерүдән гыйбарәт дип санала. Ул шуның белән дәлилләнә: тарихи процессның юнәлгәнлеге, хезмәт чараларын, кешенең табигать көчләренә ия булу дәрәҗәсен, алардан кешенең тормыш эшчәнлегенең нигезе сыйфатында файдалану мөмкинлекләрен дә кертеп, җәмгыятьнең җитештерүче көчләренең үсүенә һәм камилләшүенә бәйле. Иҗтимагый җитештерүдә кешеләрнең бөтен тормыш эшчәнлеге башлангычлары ята. Шушы критерийга туры килгәнчә, иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең җитештерүче көчләр дәрәҗәсенә туры килгәннәре һәм аларны үстерү, хезмәт җитештерүчәнлегенең кешенең үсүе өчен киңрәк мөмкинлекләр ачканнары прогрессивлар дип танылa. Кеше җитештерүче көчләрдә иң мөһиме дип санала, шунлыктан аларның үсүе бу караштан да кеше табигатенең байлыклары үсү буларак карала.

Бу позиция башкача караш тарафыннан тәнкыйтьләнә. Гомуми прогресс критерием бары тик иҗтимагый аңда гына (акыл, әхлак, ирекне аңлау үсешендә) табу мөмкин булмаган кебек, аны матди җитештерү өлкәсендә дә (техникада, икътисади мөнәсәбәтләрдә) табу мөмкин түгел. Тарих матди җи-

тештерүнең югары дәрәҗәсе рухи мәдәниятнең таркалуы белән туры килгән илләр мисалларын бирде. Җәмгыятьнең бары тик бер өлкәсенең торышын гына чагылдыручы критерийларның берьяклылыгыннан котылу өчен кеше тормышы һәм эшчәнлегенең асылын характерлаучы төшенчәне табарга кирәк. Философлар шул сыйфатта ирек төшенчәсен тәкъдим итәләр.

Ирек, инде белгәнегезчә, белем белән генә түгел,— ул булмаса, кеше субъектив яктан ирекле була алмый,— аны гамәлгә ашыру өчен шартлар булу белән дә характерлана. Шулай ук ирекле сайлау нигезендә кабул ителгән карар да кирәк. Ниһаять, тагын әле кабул ителгән карарны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чаралар һәм эшләр дә таләп ителә. Шунысын да искә төшерик, бер кешенең ирегә икенче берәүнең иреген кысу бәрабәренә ирешелмәскә тиеш. Ирекне алай чикләү социаль-әхлакый характер ала.

Ирек шәхеснең үз-үзен тормышка ашыруының кирәкле шарты булып тора. Ул (ирек) кешенең үзенә җәмгыять биргән сәләтләре, мөмкинлекләре, ул үзен күрсәтә ала торган эшчәнлеге мөмкинлекләре турындагы белемнәре булганда гына барлыкка килә. Җәмгыять булдыра торган мөмкинлекләр киңрәк булган саен, кеше шулкадәр ирекләрәк, эшчәнлекнең вариантлары шулкадәр күбрәк була. Күпкырлы эшчәнлек процессында кеше үзе дә күпкырлы үсеш кичерә, шәхеснең рухи байлыгы арта.

Шулай итеп, әлеге карашча, социаль прогрессның критериен җәмгыять индивидка бирә ала торган ирек үлчәме, җәмгыять тарафыннан гарантияләнгән шәхси ирек дәрәҗәсе тәшкил итә. Ирекле җәмгыятьтә кешенең ирекле үсүе шулай ук аның чын кешелек сыйфатларының — интеллектуаль, иҗади, әхлакый сыйфатларының ачылуын да аңлата. Болай дип раслау безне социаль прогресска тагын бер карашны карауга китерә.

Күргәнебезчә, кешене эшлекле җан иясе буларак характерлау белән генә чикләнергә ярамый. Ул шулай ук акыллы һәм иҗтимагый җан иясе дә. Фәкать шуны исәпкә алып кына без кешедәге кешелек турында, *кешелеклелек* турында сөйли алабыз. Ләкин кешелек сыйфатларының үсүе кешеләрнең тормыш шартларына бәйле. Кешенең азыкка, киемгә, торакка, транспорт хезмәтләренә, рухи ихтыяҗлары тулырак канәгатьләндерелгән саен, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр шулкадәр әхлаклырак, икътисади һәм сәяси, рухи һәм матди эшчәнлекнең күп төрләре кеше үзләштерә алырдайрак була. Кешенең физик, интеллектуаль, психик көчләрен, аның әхлакый сыйфатларын үстерү өчен шартлар уңайрак булган саен, һәр аерым кешегә хас шәхси сыйфатларны үстерү өчен мәйдан

шулкадәр киңрәк була. **Тормыш шартлары кешелеклерәк булган саен, кешедәге кешелеклекне: акыл, әхлак, иҗади көчләрне үстерү өчен мөмкинлекләр шулкадәр күбрәк була.**

> **«Прогресс акылның хайвани көрәш законыннан һаман саен өстенрәк булуыннан гыйбарәт».**
>
> **Л.Н.Толстой**

Кешелеклелек, кешене иң югары кыйммәт дип тану «гуманизм» сүзе белән белдерелә. Югарыда әйтелгәннәрдән социаль прогрессның универсаль критерие турында нәтиҗә ясарга була: гуманизмны югары күтәрүгә булышлык итүче нәрсә прогрессив була.

Хәзер, без тарихи процесс критерийларына төрле карашларны бәян иткәч, уйлагыз: җәмгыятьтә барган үзгәрешләрне бәяләү өчен кайсы караш сезгә ышанычлырак ысул бирә?

ИҖТИМАГЫЙ ҮСЕШ ЮЛЛАРЫНЫҢ ҺӘМ ФОРМАЛАРНЫҢ КҮПТӨРЛЕЛЕГЕ

XVIII–XIX гасырларда Ж.Кондорсе, Г.Гегель, К.Маркс һәм башка философлар хезмәтләрендә иҗтимагый прогресс бөтен кешелек дөньясы өчен бердәнбер магистраль юлдан законлы хәрәкәт итү буларак аңлатыла. Киресенчә, локаль цивилизация концепциясендә прогресс төрле цивилизацияләрдә төрле юллар белән бару итеп күзаллана.

Әгәр сез уегызда дөнья тарихы барышына күз ташласагыз, төрле илләр һәм халыклар үсешендәге күп уртаклыклар күрерсез. Беренче борынгы җәмгыять һәркайда дәүләт белән идарә ителә торган җәмгыятькә алышынган. Феодаль таркалганлыкка алмашка үзәкләштерелгән монархияләр килгән. Күп илләрдә буржуаз революцияләр булган. Колониаль империяләр җимерелгән, һәм алар урынында дистәләрчә бәйсез дәүләтләр барлыкка килгән. Төрле илләрдә, төрле континентларда булган вакыйгаларны һәм процессларны санауны сез үзегез дә дәвам итә аласыз. Бу охшашлыкта тарихи процессның бердәмлеге, бер-берсен алыштыручы тәртипләрнең билгеле бер тәңгәллеге, төрле илләр һәм халыклар язмышларының гомумилеге чагыла.

Шуның белән бергә, аерым илләр һәм халыкларның конкрет үсеш юлы күптөрле. Бер үк төрле тарихлы халыклар, илләр, дәүләтләр юк. Конкрет-тарихи процессларның табигать шартларының төрлелеге, хуҗалык спецификасы, рухи мәдәниятнең, яшәү рәвешенең үзенчәлекләре һәм күпләгән башка факторлар белән бәйле. Һәр илгә үсешнең үз варианты алдан билгеләнгән, һәм ул — мөмкин булганның бердәнбере дигәнне

аңлатамы бу? Тарихи тәҗрибә билгеле бер шартларда өлгергән мәсьәләләрне хәл итүнең төрле вариантлары мөмкин икәнен, алга таба үсү ысулларын, формаларын һәм юлларын сайлау, ягъни тарихи альтернатива мөмкин икәнен күрсәтә. Альтернатив вариантларны еш кына җәмгыятьнең теге яки бу төркемнәре, төрле сәяси көчләр тәкъдим итә.

Искә төшерик: Россиядә 1861 елда уткәреләчәк Крестьяннар реформасын әзерләгәндә төрле иҗтимагый көчләр ил тормышындагы үзгәрешләрне тормышка ашыруның төрле формаларын тәкъдим итәләр. Берәүләр — революцион юлны, икенчеләре реформалар юлын яклый. Реформаларның берничә варианты тәкъдим ителә.

Ә 1917–1918 елларда Россия алдына яңа альтернатива килеп баса: йә символларының берсе бөтен халык тарафыннан сайланган Учредитель җыены булган демократик республика, йә башында большевиклар торган Советлар республикасы.

Һәр очракта сайлап алу эшләнә. Мондый сайлау (көчләр нисбәтенә һәм тарих субъектларының һәрберсенең йогынтысына бәйле рәвештә) дәүләт эшлеклеләре, хакимлек итүче элиталар, халык массалары тарафыннан тормышка ашырыла.

Теләсә кайсы ил, теләсә кайсы халык тарихның билгеле бер мизгелләрендә язмышны хәл итүче сайлау алдында кала, һәм аның тарихы әлеге сайлауны гамәлгә ашыру процессында тормышка ашырыла.

Иҗтимагый үсеш юллары һәм формаларының күп вариантлылыгы чиксез түгел. Ул тарихи үсешнең билгеле бер тенденцияләре кысаларына кертелгән.

Мәсәлән, без үз гомерен инде яшәгән крепостнойлык хокукын бетерүнең революция формасында да, дәүләт гамәлгә ашыра торган реформалар формасында да ихтимал булуын күрдек. Ә икътисади үсешне тизләтүгә бүген өлгергән ихтыяҗ төрле илләрдә йә яңадан-яңа табигый ресурсларны җәлеп итү юлы, ягъни экстенсив юл белән, йә яңа техника һәм технологияләрне кертү, эшләүчеләрнең квалификациясен күтәрү юлы белән, хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү нигезендә, ягъни интенсив юл белән тормышка ашырыла. Төрле илләрдә яки бер үк илдә бер типтагы үзгәрешләрне тормышка ашыруның төрле вариантлары кулланылырга мөмкин.

Шул рәвешле, гомуми тенденцияләр — күптөрле үсеш бердәйлеге чагылган тарихи процесс әлеге илнең алга таба хәрәкәтенең юллары һәм формалары үзенчәлеге бәйле булган сайлап алу мөмкинлеген тудыра.

Төп төшенчәләр: иҗтимагый процесс, регресс, иҗтимагый үсешнең күп вариантлылыгы.

Терминнар: тарихи альтернатива, прогресс критерие.

Үзегезне тикшерегез

1. «Прогресс» сүзе нәрсәне белдерә? 2. Прогресска карашлар төрлелеген нәрсә белән аңлатырга? 3. Иҗтимагый прогрессның каршылыклылыгы нәрсәдә чагыла? 4. Элеккеге чорларда прогрессның нинди критерийлары алга сөрелгән? Аларның чикләнгәнлеге нәрсәдә? 5. Прогрессның кайсы критериен универсаль дип санап була? Аның өстенлекләре нәрсәдә? 6. Иҗтимагый үсеш юллары һәм формалары ни өчен күптөрле? 7. «Күптөрле иҗтимагый үсеш бердәмлеге» дигәннең мәгънәсе нәрсәдә?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Россиядәге XIX гасырның 60–70 нче елларындагы реформаларны прогрессның универсаль критериеннан чыгып бәяләргә тырышыгыз. Аларны прогрессив дип буламы? Ә 80 нче еллар сәясәтен? Үз карашыгызны дәлилләгез.

2. Уйлагыз: Петр I, Наполеон Бонапарт, П.А.Столыпиннарның эшчәнлеге прогрессивмы? Үз карашыгызны дәлилләгез.

3. Флоренция тарихчысы Ф.Гвиччардининың (1483–1540) карашы прогресска карата параграфта китерелгән карашларның кайсысына туры килә: «Үткәндәге эшләр киләчәкне яктырта, чөнки дөнья һәрвакыт бер үк: нәрсә булган һәм булачак, инде башка вакытта да булган, булганнар кире кайта, тик башка исемнәр һәм башка буяулар астында; әмма аны һәркем түгел, ә бары тик аны җентекләп тикшергән һәм уйлаган акыл иясе генә таный».

4. Уйлагыз: ике рус философының прогресс идеясенә түбәндә китерелгән мөнәсәбәтләрендә аерма бармы?

А.И.Герцен (1812–1870): «Безнең барлык бөек мәгънәбез... шунда ки, исән вакытта без... һәрвакыт үзебез, прогресска түзәргә яки нинди дә булса акылсыз идеяне гәүдәләндерергә мәҗбүр ителгән курчаклар түгел. Шуның белән горурланырга тиешбез ки, без тарихның чуар тукымасын тегүче тәкъдир кулындагы җепләр яки энәләр түгел».

Г.В.Плеханов (1856–1918): «Кешеләр үз тарихларын прогрессның алдан сызып куелган юлыннан тантаналы төстә атлау өчен дә, ниндидер абстракт эволюция законнарына буйсыну өчен дә эшләмиләр. Алар аны үз ихтыяҗларын канәгатьләндерергә омтылып эшлиләр».

Бу әйтелгәннәрне параграф текстында бәян ителгән материал белән чагыштырыгыз һәм, тарихтан белемнәрегезгә таянып, үз карашыгызны әйтегез.

5. Бүгенге социаль үсешне өйрәнүче кайбер галимнәр үз

игътибарларын алар җәмгыятьне «вәхшиләндерү» дип атаган күренешләргә юнәлттеләр. Алар аңа мәдәният, аерым алганда, тел дәрәҗәсенең кимүен, әхлакый җайга салучыларның йомшаруын, хокукый нигилизмны, җинаятьчелек, наркомания үсүне һәм башка шундый процессларны керттеләр. Сез бу күренешләрне ничек бәялəр идегез? Аларның җәмгыятькә йогынтысы нинди? Әлеге тенденцияләр якындагы перспективада җәмгыять үсеше характерын билгелиләрме? Үз җавабыгызны дәлилләгез.

6. Совет чоры философы *М.Мамардашвили* (1930–1990) болай дип яза: «Дөньяның ахыр мәгънәсе яки тарихның ахыр мәгънәсе кеше язмышының бер өлеше булып тора. Кеше язмышы мондый: Кеше сыйфатында башкарылу. Кеше булу». Философның бу фикере прогресс идеясе белән ни дәрәҗәдә бәйләнгән?

Чыганак белән эшләгез

Рус философы Н.А.Бердяев прогресс турында.

Прогресс кешелекнең һәр буынын, һәр кешене, тарихның һәр дәверен ахыр максат өчен — безнең беребезнең дә үзенә тигән өлеше булмаган киләчәк кешелек дөньясының камиллеге, куәте һәм рәхәт тормышы өчен чара һәм коралга әверелдерә. Прогрессның уңай идеясе эчтән кабул ителмәслек, дини һәм әхлакый яктан ярамый торган; чөнки әлеге идеянең табигате шундый ки, ул тормыш михнәтләрен хәл итүне, бөтен кешелек ыругы өчен, барлык кешелек буыннары өчен, барлык заманнар өчен, үзләренең газаплы язмышлары белән кайчан да булса яшәгән кешеләр өчен фаҗигале каршылыкларны һәм конфликтларны хәл кылуны мөмкин түгел итә. Галимнәр генә ул, күрә торып һәм аңлаган килеш, гаять тә зур масса өчен, кешелек буыннарының чиксез массасы, дәверләрнең һәм чорларның бетмәс сафлары өчен фәкать үлем һәм кабер генә бар, дип раслыйлар. Алар камил булмаган, михнәтле, каршылыклар тулы хәлдә яшәгәннәр. Һәм бары тик тарихи яшәешнең түбәсендә генә, ниһаять, барлык элгәре буыннарның череп беткән сөякләренә басып бәхетлеләрнең югарыга менәчәк һәм аңа тормышның иң югары тулылыгы, рәхәтлеге һәм камиллеге мөмкин булачак буын пәйда була. Барлык буыннар нindидер безгә караңгы һәм ят киләчәктә пәйда булачак әлеге бәхетле буыннарның рәхәт яшәвен тәэмин итүче чаралар гына булып тора.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Прогресска әлеге документта китерелгән карашларның параграфта китерелгән карашлардан аермасы нәрсәдә? 2. Н.А.Бердяевның фикер йөртүләренә сезнең мөнәсәбәтегез нинди? 3. Прогресска карата параграф

материалларында китерелгән барлык карашлар арасында сезнең өчен күбрәк җәлеп итәрдәе кайсысы? 4. Бу параграфның исеме ни өчен «проблема» сүзе белән башлана?

Бу хакта бәхәсләшәләр

Җәмгыять тормышының барлык өлкәләрендә дә берьюлы прогресска ирешеп буламы? Кайчак кайбер үзгәрешләрнең берберсенә ярашмавын әйтәләр, аларның һәрберсе прогрессив дип танылса. Мәсәлән, халыкның матди яхшы яшәве бәйле булган җитештерүнең үсүе һәм шул ук вакытта кешеләрнең сәламәтлеге бәйле булган экологиянең яхшыруы. Яки кешене аның эшен һәм көнкүрешен җиңеләйтүче төрле техник җайланмалар белән һаман саен күбрәк чолгап алу һәм бер үк вакытта гуманитар мәдәниятне күтәрүне таләп итүче рухи тормышны баету.

Үткән йөзьеллык тәҗрибәсе күрсәткәнчә, фән, техника, икътисад, социаль мөнәсәбәтләр, тәрбия һ.б. өлкәләрдәге югарыда аталган һәм күпләгән башка прогрессив үзгәрешләрнең барысын да берьюлы тормышка ашырып булмый. Нишләргә?

§ 16. Кеше эшчәнлегендә ирек

Исегезгә төшерегез:

табигатьтәге зарурилык нәрсәдә чагыла? Бөек француз революциясе елларында ирек лозунгы нәрсәне аңлаткан?

Шәхес иреге үзенең барлык чагылышларында хәзерге цивилизацияле кешенең иң мөһим кыйммәте булып тора. Кешенең үз-үзен гамәлгә ашыруы өчен ирекнең әһәмиятен әле борынгы заманнардан ук аңлаганнар. Ирекка омтылу, деспотлык һәм башбаштаклык богауларыннан котылырга тырышу кешелек дөньясының бөтен тарихына хас булган. Бу хәл Яңа һәм Өр яңа вакытларда бигрәк тә нык чагылган. Барлык революцияләр «ирек» сүзен үз байракларына язганнар. Сәяси лидерларның һәм революция юлбашчыларының һәрберсе диярлек үзләре җитәкләгән массаларны чын ирекка чыгарырга ант иткән. Гәрчә аларның күпчелеге үзләрен шәхес ирегеп һичшиксез яклаучылар һәм саклаучылар дип белдерсәләр дә, әлеге төшенчәгә салынган мәгънә төрлечә булган.

«Ирек» төшенчәсе кешелек дөньясының фәлсәфи эзләнүләрендә дә үзәк категорияләрнең берсе булып тора. Еш кына үзләренең конкрет сәяси максатларына буйсындырып, сәясәтчеләр бу төшенчәне төрле төсләргә буяган кебек, философлар да аны аңлауга төрле позицияләрдән якын киләләр.

Әлеге төрле аңлатмаларны тикшереп карыйк.

АБСОЛЮТ ИРЕК НИ ӨЧЕН МӨМКИН ТҮГЕЛ?

Кешеләр ирекка ничек кенә омтылсалар да, алар абсолют, чиксез ирекнең була алмавын аңлыйлар. Барыннан да элек — бер кешенең тулысынча иреге икенче берәүгә карата башбаштаклыкны аңлатыр иде. Әйтик, кемнеңдер төн уртасында көчле музыка тыңлыйсы килде ди. Үз магнитофонын бөтен көченә куеп, кеше үз теләген тормышка ашырды, иреге кушканны эшләде. Ләкин бу очракта аның иреге күпләгән башкаларның төнлә рәхәтләнеп йоклау ирегенә киметте.

Нәкъ менә шуңа күрә дә барлык маддәләре шәхес хокукларына һәм ирекләренә багышланган Кеше хокукларының гомуми декларациясенең бурычлар турында искә төшергән соңгы маддәсендә үз хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашырганда һәр кеше фәкать максаты башкаларның хокукларын тану һәм хөрмәт итү өчен булган чикләүләргә генә дучар ителергә тиешлеге турында әйтелә.

Абсолют ирекнең мөмкин түгеллеге турысында фикер йөртеп, игътибарны мәсьәләнең тагын бер ягына юнәлтик. Андый ирек кешегә берни белән дә чикләнмәгән сайлауны аңлатыр һәм бу аны карарлар кабул иткәндә бик тә читен хәлгә куяр иде. «Буридан ишәге» дигән әйтем киң таралган. Француз философы Буридан бер үк төрле ике печән өеме уртасына куелган һәм кайсы өемгә өстенлек бирергә белмичә ачтан үлгән ишәк турында сөйләгән. Аннан алдарак шундый ук хәлне Данте сурәтләгән, ләкин ул ишәк турында түгел, кешеләр турында сөйләгән: «Бер үк ераклыкта торган, бер үк дәрәҗәдә кызыктырган ике ашамлык арасындагы кеше, ул абсолют ирекка ия булса, аларның берсен авызына капканнан бигрәк ачтан үләчәк».

Кеше абсолют ирекле була алмый. Һәм монда чикләүчеләрнең берсе — башка кешеләрнең хокуклары һәм ирекләре.

ТАНЫП БЕЛЕНГӘН ИХТЫЯҖ БУЛАРАК ИРЕК

Күпләгән философлар — Б.Спиноза, Г.Гегель, Ф.Энгельс ирекне шулай аңлатканнар. Афоризмга диярлек әйләнгән бу формула артында нәрсә ята соң? Дөньяда үзгәртеп, кире кайтарып булмый торган рәвештә хәрәкәт итүче көчләр бар. Әлеге көчләр кеше эшчәнлегенә дә йогынты ясый. Әгәр бу зарурилык кеше тарафыннан танып беленми, сизелми икән, ул — аның колы; әгәр инде танып беленсә, кеше «эшне белеп карар кабул итү сәләте» ала. Аның ихтыяр иреге шунда чагыла да инде.

«Кешеләр үз теләкләрен аңлыйлар, ләкин аларның бәйләнешләренең сәбәпләрен белмиләр».

Б.Спиноза

Нинди көчләр соң алар, заруриликның табигате нинди? Бу сорауга җаваплар төрле. Берәүләр монда Ходай эшен күрә. Бар нәрсә аның тарафыннан алдан язып куелган. Ул чакта кешенең иреге нидән гыйбарәт соң? Ул юк. «Ходайның алдан билгеләп куюы һәм бөтенесеннән дә куәтлерәк булуы безнең ирекле ихтыярыбызга диаметраль капма-каршы. Барысы да котылгысыз нәтиҗәне кабул итәргә мәҗбүр: без бернәрсәне дә үз ихтыярыбыз белән эшләмибез, барысы да заруриликтан килеп чыга. Шул рәвешле, без ирекле ихтыяр белән берни дә эшләмибез, барысы да Ходайның алдан билгеләп куюына бәйле»,— дип раслый дини реформатор Лютер. Абсолют алдан билгеләнү тарафдарлары шундый карашны яклыйлар. Әлеге карашка каршы булган башка дин әһелләре Ходайның алдан билгеләп куюы белән кеше иреге нисбәтен шундый аңлатуны тәкъдим итәләр: «Ходай Галәмне барлык яратылганнарның бөек бүләге — иреге булырлык итеп яраткан». Ирек барыннан да элек изгелек белән явызлык арасында сайлау, мөстәкыйль рәвештә, үз карарың нигезендә бирелгән сайлау мөмкинлеген аңлата. Әлбәттә, Ходай бер мизгелдә үлемне дә, явызлыкны да юк итә ала. Ләкин бу вакытта Ул бер үк вакытта дөньяны да һәм ирекне дә юкка чыгарыр иде. Дөнья үзе Ходайга кире кайтырга тиеш, чөнки ул Аннан үзе читләшкән».

«Заруриликь» төшенчәсенең башка мәгънәсе дә булырга мөмкин. Заруриликь табигатьтә һәм кешедә объектив, ягъни кеше аңына бәйле булмаган законнар рәвешендә яши дип исәплиләр кайбер философлар. Башкача әйткәндә, заруриликь — вакыйгалар үсешенең закончалыклы, объектив нигезләнгән чагылышы ул. Ул карашны яклаучылар, фаталистлардан аермалы буларак, әлбәттә, дөньяда (аеруча иҗтимагый тормышта) барысы да катгый һәм һичшиксез алдан билгеләнгән дип исәпләмиләр, очраклылыклар булуын инкарь итмиләр. Әмма үсешнең очраклылыклар тарафыннан теге яки бу якка авыштырылучы гомуми закончалыклы линиясе барыбер үзенә юл табачак. Мисалларга мөрәҗәгать итик. Билгеле булганча, сейсмокуркыныч зоналарда даими рәвештә җир тетрәүләр була. Бу хәлне белүче яки аны инкарь итүче кешеләр, мондый урыннарда үз торакларын төзеп, куркыныч стихияләр корбаннары булырга мөмкиннәр. Бу факт төзелеш вакытында (мәсәлән, сейсмик тотрыклы биналар салганда) исәпкә алынса, куркыныч ихтималы нык кимиячәк.

Бәян ителгән карашны (гомумиләштерелгән формада) Ф.Энгельс сүзләре белән белдерергә мөмкин: «Ирек табигать законнарыннан бәйсезлектән түгел, ә бәлки әлеге законнарны танып-белүдән һәм шул белемнәргә нигезләнгән мөмкинлекләрне планлы рәвештә табигать законнарын билгеле бер максатлар өчен эшләргә мәҗбүр итүдән гыйбарәт».

Шул рәвешле, **ирекне танып беленгән заруриллык дип аңлату кешенең үз эшчәнлегенең объектив чикләренә җитүен һәм аларны исәпкә алуын, шулай ук әлеге чикләрне киңәйтүнең белемнәр үсешенә нигезләнгән тәҗрибәсен баетуны күздә тота.**

ИРЕК ҺӘМ ҖАВАПЛЫЛЫК

Тагын бер хәлне карап үтик. Хәзерге җәмгыять кешегә изелгәнлеккә, төшенкелеккә бирелгәнлек халәтеннән чыгарга булышучы төрле чаралар бирә. Алар арасында кеше организмын туктаусыз җимерә торганнары да (алкоголь, наркотиклар) бар. Андый куркыныч булуын белсә дә, кеше аңа кул селтәп кенә карарга мөмкин, ул чакта аны котылгысыз җәза көтә, өстәвенә иң кадерле нәрсә — үз сәламәтлегең, ә кайчак тормышың белән түләргә туры килә.

Башкача әйткәндә, чын иректе кеше үзенең бер минутлык кәефе һәм гадәтләренең колы булмаячак. Ул сәламәт яшәү рәвешен сайлаячак. Бу очракта, аңланган куркынычтан тыш, кешене теге яки бу рәвешле түгел, ә болай эш итәргә билгеле иҗтимагый шартлар да мәҗбүр итә. Әхлак һәм хокук нормалары, традицияләр һәм җәмәгатьчелек фикере бар. «Үз-үзеңне тиешенчә тоту» моделе шулар йогынтысы астында урнаша. Кеше шул кагыйдәләрне истә тотып эш итә, теге яки бу карарлар кабул итә.

Кешенең билгеләнгән социаль нормалардан читкә китүе, белгәнегезчә, җәмгыятьтә билгеле бер реакция тудыра. Тискәре тайпылышлар социаль санкцияләр, ягъни хупланмаган гамәлләр өчен җәза барлыкка китерә. Мондый җәзаны әле тагын кешенең үз эшчәнлеге һәм аның нәтиҗәләре өчен җаваплылыгы дип тә атыйлар. (Исегезгә төшерегез: нинди очракларда җинаять, административ, матди һәм башка төр җаваплылыклар барлыкка килә?)

Ләкин «җаваплылык» төшенчәсе кешегә йогынты ясауның тышкы формалары белән генә бәйле түгел. Җаваплылык аның эшчәнлегенең бик тә мөһим эчке җайга салучысы да булып тора. Ул чакта без җаваплылык хисе, бурыч турында сөйлибез. Ул барыннан да элек кешенең куелган тәртипләрне үтәргә, үз гамәлләренең тирә-юньдәгеләр өчен нинди нәтиҗәләргә китерүе ихтималын бәяли белергә, кылган тәртипсезлекләрең булган очракта җәзалар кабул итәргә аңлы рәвештә әзер булуында чагыла.

Психологлар тикшеренүләре күрсәткәнчә, күпчелек кешеләр үз эшләре өчен үзләренә җаваплылык алырга әзер. Ләкин җаваплылык хисе югалган хәлләр дә була. Мәсәлән, кеше күп кеше арасында башка хәлләрдә беркайчан да эшли алмаган нәрсәләргә — мыскыллап кычкыруга, тәртип сагында торучыларга каршылык күрсәтүгә, рәхимсезлек һәм агрессивлыкның төрле чагылышларына сәләтле. Бу очракта чыгышларның массовыйлыгы гына түгел, беренче чиратта кешеләр эшчәнлегенең аноним характерда булуы да йогынты ясый. Мондый мизгелләрдә кешенең эчке чикләүләре йомшара, җәмәгатьчелек бәяләвен уйлау кими. Үзендә җаваплылык хисе барлыкка китереп, кеше үзен индивид булуын югалтудан, ягъни түбән үзаңлы төссез җан иясенә әверелүдән саклый.

«ШУННАН ИРЕК» ЯКИ «ШУНЫҢ ӨЧЕН ИРЕК»

Без нинди кешене ирекле дип исәплибез — шул турыда уйланыйк. Иң беренче аңга шул килә: ул нәрсәгә дә булса мәҗбүр ителми, ул теләмәгән эшне башкарырга көчләп кушмыйлар, аны төрле хәлләр изеп тормый. «Мин бүген ирекле, чөнки миңа репетитор янына чабарга кирәкми», «Ата-ана опекасыннан котылу һәм үземне, ниһаять, ирекле итеп тою өчен мин квартира алып торырга телим»,— ирекне нәкъ менә шулай аңлау чагылган тагын күп сүзләр китерергә мөмкин.

Ләкин философлар бу бары тик ирекнең башлангыч пункты гына дип исәплиләр. Чын ирекле булу үз-үзеңне чикләүдән башлана. «Шуннан ирекле» — әхлакый законга буйсындырылган яхшы ихтыяр ул. Кеше ирекле тырышлык белән явызлыктан котыла һәм яхшылыкка борыла. И.Кант мондый ирекле сайлау табигый зарурлыктан өстен тора дип исәпли.

Шулай итеп, без ирекне тышкы чикләүләрне караудан кеше үзе өчен урнаштыра торган эчке чикләүләргә күчтек. «Әгәр җан омтылуга һәм каршы торуга сәләтле, кимчелек нигезле булмаса, мактаулар да, битәрләүләр, хөрмәтләүләр, җәзалаулар да гадел булмаячак»,— дип раслый III гасыр христиан дине белгече.

> **«Ихтыяр үзенең табигате буенча шундый дәрәҗәдә ирекле ки, аны беркайчан да мәҗбүр итеп булмый».**
>
> **Р.Декарт**

Кеше тормышының тышкы хәлләре нинди булуы мөһим түгел. Башкасы мөһим: аның аңы аларны ничек аңлый, кеше дөньяга үзен ничек итеп күрсәтә, үз алдына нинди максатлар куя, әйләнә-тирә чынбарлыкка нинди мәгънә һәм әһәмият бирә. Нәкъ менә шул үз-үзеңне тотуның мөмкин булган күптөрле

вариантларыннан сайлап алуны билгели. Моннан кайбер бүгенге философлар шундый нәтиҗә ясый: кеше эшчәнлеге үз максатын читтән ала алмый, читтәге бернәрсә дә аны дәлилли алмый, үзенең эчке тормышында кеше бөтенләй дә ирекле.

Чын-чынлап ирекле кеше үзенең кылган гамәлләрен генә түгел, аның нигезләрен, үз эшләренең инану рәвешен алучы гомуми принципларын да үзе сайлый. Андый кеше хәтта кешелек ыругы бетә барган яки үз илендә деспотик яисә тоталитар режим тотрыклы сакланган шартларда да рухи төшенкелек хәленә җитмәячәк һәм ул яклый торган принципларның киләчәктә, һичшиксез, тантана итәчәгенә ышанып эш итәчәк.

Мондый карашны тәнкыйтьләүчеләр: әгәр һәркем үз-үзен тотышының нигезләрен, гомуми кабул ителгән чикләүләрне һәм тыюларны исәпкә алмыйча, бары тик үз инануларына таянып кына эзләсә, җәмгыять үзенең бөтенлеген югалтачак, һәм кешеләрне хаос көтә: теләгән ирек урынына алар тулы башбаштаклык алачаклар дип исәплиләр.

Ә сезнең карашыгыз нинди? Сезгә бу карашларның кайсысы һәм ни өчен дөрес булып тоела?

ИРЕКЛЕ ҖӘМГЫЯТЬ НӘРСӘ УЛ?

Шулай итеп, сез «ирек» төшенчәсенең төрлечә, ә кайчак диаметраль капма-каршы аңлатылуын күрдегез. Төрлечә якын килүләр турында уйланып, нәрсәнедер кабул итеп, нәрсәдәндер катгый ваз кичеп сайлау булмаган шартларда чын ирекле эшчәнлекнең була алмавы белән килешик. Ирек барлык мөһим эшләрдә сайлап алу нигезендә эш итәргә сәләтле кешенең халәтен аңлата.

Мондый сайлауны нинди җәмгыять тәэмин итә ала соң?

Аңлашыла ки, аерым шәхесләр яки төркемнәр башбаштаклыгы һәм тиранлыгы хөкем сөргән, законлылык санга сугылмаган, дәүләт үз гражданнары өстеннән тулы контроль урнаштырган җәмгыятьне ирекләгә берничек тә кертеп булмый.

Дәүләтнең аерым кеше тормышына тыкшынуы бик аз булган җәмгыять кенә ирекле була ала дигәнне аңлатамы бу? Мондый караш яклылар аз түгел.

Андый җәмгыятьтә икътисад өлкәсендә көндәшлек башлангычларына нигезләнгән ирекле эшмәкәрлек, сәясәт өлкәсендә сәяси партияләр төрлелеге, сәяси плюрализм, дәүләт төзелешенең демократик принциплары хөкем сөрә. Ул — ирекле фикерләү җәмгыяте. Һәм моның төп асылы бөтенләй һәркемнең ни теләсә шуны сөйләвендә яки язуында түгел, ә теләсә нинди идеянең тикшерелә алу ихтималында. Төрле белемнәргә ия булган һәм төрле карашларда торган кешеләрнең үзара эш итүенең бу процессы фикерне үстерү нигезе булып тора да инде. Кешеләр-

нең тормышы фәкать демократик кабул ителгән законнар һәм гомумтанылган әхлак нормалары белән генә җайга салына.

«Җәмгыять һәм дәүләт эшли ала торган бар нәрсә — тормышның бер генә өлкәсендә дә монополиялеккә юл куймыйча, ирекне яклау ул. Дәүләт тыкшынуыннан азат, үзләре теләгәнчә эшләргә ирекле индивидлар уңышларга ирешә башлаячак һәм алар бәхетле булачак»,— дип язды Американың сәясәт эшлеклеләренең берсе.

Ләкин ирекле җәмгыятьнең бу моделен һәркем дә кабул итми. Кайбер галимнәр, сәясәтчеләр, халыкның билгеле бер өлеше карашын чагылдырып, андый чикләнмәгән индивидуальлек кешеләр файдасына түгел дип исәплиләр. Чын ирек дәүләтнең кешеләр тормышына тыкшынмавыннан да күбрәк нәрсәне күздә тота. Кешенең үзен тормышта раславы индивидуаль тәҗрибәгә генә түгел, ә бәлки уртак тәҗрибәгә, карарларны бергәләп эзләүгә, гомуми уңайлыклар булдыруга нигезләнә. Шунлыктан кооперация, җаваплылык, гаделлек, ягъни җәмгыять тәэмин итәргә тиешле бар нәрсә ирекккә өстәмә булып торалар.

Шулай итеп, дип исәплиләр әлеге концепция яклылар, җәмгыятьнең роле аны күз алдына китерергә тырышуларга караганда күпкә әһәмиятлерәк. Бергәлекләргә берләшеп, кешеләр яңа кыйммәтләр генә алып калмыйлар, кайчак аларга бик тә кирәкле коллектив яклану да алалар.

Дәүләт тә билгеле күләмдә җайга салучы ролен үтәргә тиеш. Ул, гражданнар ирекен гарантияләүче институтлар оештырып һәм аларга ярдәм итеп кенә калмыйча, керемнәрне тигезрәк булу турында кайгыртырга, ярлылар һәм байлар арасындагы упкынның тагын да тирәнәюен булдырмаска тиеш. Ирек идеалы социаль гаделлек идеалы белән тулыландырылырга тиеш.

Шунысы да мөһим: үзләренең гражданлык бурычларын намуслы үтәп, гражданнар бер-берсенең ирекен дә гарантияләсен.

Шулай итеп, сайлау халәте һәр кешенең шәхси тормышы «киңлегенә» генә сыеп бетә алмый. Инде белгәнегезчә, ул тулаем җәмгыять дәрәҗәсендә дә барлыкка килә. Аеруча ул «күчеш» дип йөртелгән чорларда чагыла. Кайбер тикшеренүчеләр фикеренчә, андый чорлар алга таба үсүнең тулы спектр юнәлешләренә — альтернативаларына ия була. Аларның кайсысының, әйтик, ил җитәкчелеге тарафыннан яклануы бөтен җәмгыять тормышына сизелерлек йогынты ясарга мөмкин. Шунлыктан сайлау бу очракта бик тә югары җаваплылык белән бергә була. Мондый хәлләр һәм кабул ителгән карарларның нәтиҗәләре мисалларын безгә ерак һәм бик үк ерак булмаган үткәндәге тарих саклаган.

Төп төшенчәләр: ирек, сайлау ирекe, зарурилык, җаваплылык, ирекле җәмгыять.

Терминнар: индивидуальләшүне бетерү, алдан билгеләп кую.

Үзегезне тикшерегез

1. «Ирек» төшенчәсе Яңа һәм Өр-яңа вакытлардагы сәяси көрәш белән ничек бәйләнгән? 2. Чикләнмәгән сайлау ирегенең нәрсәгә китерүе ихтимал? 3. Христиан дине өйрәтүендә ирек ничек аңлатыла? 4. Табигый зарурилыкның кешеләрнең иректле эшчәнлегенә йогынтысын күрсәтегез. 5. Иҗтимагый зарурилык нәрсәдә чагыла? 6. «Ирек», «сайлау», «җаваплылык» төшенчәләренең үзара бәйләнеше нинди? 7. «Ирекле җәмгыять» төшенчәсен аңлатуга төрлечә якын килүләрне ачып бирегез. 8. Җәмгыятьтә шәхеснең ирекләрен һәм хокукларын яклауда дәүләтнең ролен күрсәтегез. 9. Гражданнар бер-берсенең иреген ничек гарантияли ала?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Кешенең җәмгыятьтә абсолют, берни белән дә чикләнмәгән иреге була алмавы турындагы нәтиҗәне нинди дәлилләр белән раслап була?

2. Түбәндә китерелгән ике фикернең кайсысы сезгә дөресрәк булып тоела?

«Безнең тормыш — табигать кушуы буенча Җир шары өслегенә, аннан бер генә мизгелгә дә китү мөмкинлегебез булмыйча, язарга тиешле линия ул». «Вакыйгалар агышы үз ышанычларын саткан кешегә генә кире кайтармаслык булып күренә. Тарих үзеннән-үзе генә кешене мәҗбүр итә дә, аны пычрак эшкә кертә дә алмый. Кеше дөньяның бөтен авырлыгын үз өстендә алып бара: ул дөнья һәм үзе өчен җаваплы».

3. «Ирек — сайлау ул» дигән әйтемне сез ничек аңлыйсыз?

4. Түбәндәге раслауны сез конкрет фактлар белән ныгыта аласызмы: «Европаның яңа тарихы чорында үсешнең генераль юнәлеше индивидны аның көндәлек тормыш эшчәнлеген богаулап торучы төрле норма һәм күрсәтмәләрдән азат итү була».

5. «Ирек» төшенчәсенең түбәндә китерелгән билгеләмәләреннән кайсысы сезгә төгәлрәк булып тоела:

а) ирек — төрле киртәләрнең һәм комачаулыкларның булмавы ул;

б) ирек — зарурилыкка аңлы рәвештә ияру ул;

в) ирек (ирекле ихтыяр) — теләсә нинди эшләргә китерүе ихтимал булган үзбелдекле лек түгел, кешенең әхлак таләпләрен тормышка ашыргандагы даимилеге, тотрыклылыгы, үз дигәнендә нык торуы ул;

г) ирек — тарихи иҗатның аңланган мөмкинлегеме ул?

6. Ирекле җәмгыятьнең төрле модельләрен тасвирлагыз. Андый җәмгыять турында сезнең күзаллауларыгыз нинди?

7. «Җәмгыятьтә яшәп, җәмгыятьтән азат булып булмый» дигән әйтем белән килешәсезме? Үз карашыгызны дәлилләгез.

8. XIX гасырның танылган фикер иясе «юридик яктан танылган ирек дәүләттә закон рәвешендә яши... Законнар — теоретик, аерым индивид башбаштаклыгына бәйсез яшәүне уңай, ачык, гомуми нормалар ул. Законнар җыелмасы халыкларның азатлык тәүраты ул» дип раслаган. Әлеге әйтемгә аңлатма бирегез.

9. Кайчак ирек теләсә нәрсә эшләргә хаклы булу итеп кабул ителә. Социаль мәгънәдә ул нинди дә булса норма яки чикләүләргә тулысынча бәйсез булу дигәнне аңлата.

XX гасыр башында рус авылларында мондый такмак җырладылар:

Алла юк, патша кирәкми,
Губернаторга — үлем;
Ясаклар да түләмибез,
Солдатка бармыйм үзем.

Ирекне болай аңлату нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин? Үз фикерегезне мисаллар белән аңлатыгыз.

Чыганак белән эшләгез

Американың бүгенге социаль психологы Э.Аронсон хезмәтеннән өзек укыгыз.

Ирек хисебезне без ничек яклыйбыз?

Әгәр ышандыручы хәбәрләр «бәйләнчек» булса, алар индивидуаль сайлау иреге өлкәсенә «басып керү» буларак кабул ителергә һәм шуның белән алардан саклану чараларын эзләүне активлаштырырга мөмкин. Әйтик, үҗәт бер сатучы мине аның товарын сатып алырга үгетли башласа, минем беренче реакциям үземнең бәйсезлегемне саклау булачак: мин кибеттән тизрәк чыгып китүне өстен күрәчәкмен...

Мондый каршы тору төрле һәм кызыклы формаларда булырга мөмкин. Әйтик, мин урамнан барам, һәм миннән әдәпле төстә генә ниндидер петициягә кул куюымны үтенәләр. Мин исә кул куярга тәкъдим ителгән нәрсәнең мәгънәсен бик үк аңлап бетермим. Әмма миңа нәрсәнең нәрсә икәнен аңлаткан бер вакытта ниндидер бер кеше янәшәбездә туктый да ачыктан-ачык төстә миңа «басым ясый», бернәрсәгә дә кул куймавымны таләп итә башлый. Басым ясауга каршы тору һәм үземнең ирегемне саклап калу максатыннан, мин тәкъдим ителгән петициягә кул куячакмындыр...

Әлбәттә, кешеләр йогынтыга бирелергә мөмкиннәр (һәм биреләләр дә) социаль басымга буйсыналар... Ләкин әлеге басым шулкадәр дә ачыктан-ачык була ки ул, безнең ирегебез

хисенә яный башлагач, без басымга каршы торып кына калмыйбыз, капма-каршы юнәлештә эш итәргә тырышабыз.

Ирекке һәм автономиягә ихтыяҗның тагын бер сәбәбе бар. Башка барлык тигезлек шартларында, аларның инануларына каршы килә торган мәгълүмат белән очрашып, кешеләр, әгәр бу мөмкин булса, каршы дәлилләр табарга тырышалар. Шулай итеп алар үз фикерләрен башкаларның артык йогынтысыннан сакларга һәм үзләренең автономлык хисләрен якларга мөмкиннәр.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Психолог фикеренчә, кешеләр үзләренең эчке ирекләрен һәм автономияләрен ничек яклыйлар? 2. Фрагментта бәян ителгәннәргә охшаш хәлләр сезнең белән дә булмадымы? Андый очракларда сез ничек эш иттегез?

II бүлеккә йомгаклаулар

1. Җәмгыятьне һәм кешенең социаль асылын төшенүдә фән һәм философлар зур юл үттеләр. Элеккеге берьяклы якын килүләрдән арынып, бүгенге тикшеренүчеләр кешенең асылын табигатьнең, социальнең һәм рухиның бердәмлеге буларак билгелиләр, аны иҗтимагый-тарихи эшчәнлек субъекты, мәдәниятне иҗат итүче итеп карыйлар.

2. Философлар һәм социологлар җәмгыятьне тикшерүдә өч дәрәҗәне аерып күрсәтәләр: социаль-фәлсәфи, тарихи-типологик, конкрет-тарихи. Социаль-фәлсәфи дәрәҗәдә күптәннән инде иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең барча төрләрен һәм формаларын колачларга сәләтле социаль макротеорияне эзлиләр. Җәмгыятьнең стадияле һәм циклы, формацияле һәм цивилизацияле, локаль һәм глобаль модельләре эшләнде.

3. Тикшеренүләрнең тарихи-типологик дәрәҗәсендә традицион (аграр), индустриаль (капиталистик), постиндустриаль (цивилизацияле) җәмгыятьләрне аерып күрсәтәләр.

4. Бүгенге җәмгыять белемендә иҗтимагый процесс төшенчәсе элеккегә караганда тирәнрәк фикерләнә. Прогрессның каршылыклылыгы, аерым өлкәләрдәге каршылыклар өчен җәмгыятьнең еш кына «кыйммәт түләве» билгеләп үтелә. Прогрессның критерийлары турындагы бәхәсләр дәвам итә. Шул ук вакытта күп кенә тикшеренүчеләр чын прогресс гуманизмны күтәрүдә, шәхеснең ирекле үсеше өчен шартлар тудыруда чагыла дип исәплиләр.

II бүлеккә сораулар һәм биремнәр

1. «Борынгы көтүнең кан кардәшлек общинасына эволюциясе кешенең тирән үзгәрешләренә, анда аралашу сәләтләренең үсүенә, әхлак башлангычлары күренә башлауга китерә».

«Кешедә акрынлап үзе кебекләр белән аралашу күнекмәләре үсү иҗтимагый оешманың тагын да югарырак баскычына — кан кардәшлек общинасына күчүгә булышлык итә».

Төрле чишелешләре әлеге җөмләләрдә чагылдырылган проблеманы формалаштырыгыз. Ике төрле карашның сезгә кайсысы ныграк ышандырырлык булып тоела? Әгәр аларның берсе белән дә килешмәсәгез, әлеге проблеманы чишүнең үз вариантыгызны тәкъдим итегез.

2. Җәмгыятьне классификацияләүнең ике вариантын анализлагыз. Җәмгыятьләрнең төрле типларын аерып күрсәтү критерийларын билгеләгез. Таблицаны тутырыгыз.

Җәмгыятьнең типлары	Аеру критерийлары
Көнбатыш һәм Көнчыгыш тибындагы цивилизацияләр	
Традицион, индустриаль, постиндустриаль җәмгыятьләр	

3. Немец философы И.Фихте болай дип раслый: «Тарих белән философ сыйфатында шөгыльләнүче философ бу вакытта кулланма итеп дөнья планының аның өчен бернинди тарихсыз да ачык булган априор (тәҗрибәдән бәйсез) җебе белән эш итә һәм ул тарихны... җанлы тормыштагы тарихсыз да ачык нәрсәне аңлату һәм күрсәтү өчен файдалана».

«Дөнья планының априор җебе» дигән сүзләрне сез ничек аңлыйсыз? Дөнья тарихының шундый планы булган сезгә таныш фәлсәфи тәгълиматларны атагыз. Сезнеңчә, философ билгеләп үткән тарихка карашның өстенлекләре һәм кимчелекләре нәрсәдә?

4. Иҗтимагый прогресс белән кешенең арта барган иреге арасындагы бәйләнешне ачып бирегез. Бүгенге җәмгыятьтә кеше ирегенең арта баруы нәрсәдә чагыла?

Имтиханга әзерләнәбез

1. Түбәндә саналганнарның кайсысы җәмгыятьне система буларак характерлый:

1) яшәвенең мәңгеллык тарихы;

2) иҗтимагый тормышның үзара бәйләнеше;

3) формаларның үзгәрүчәнлеге?

2. Саналган үзенчәлекләрнең кайсылары кешегә хас һәм кайсылары хайваннарда юк:

1) нәселдәнлек механизмнарының эшләве;

2) сизү органнары эше;
3) төрләргә махсуслашу;
4) аңлашыла торган итеп сөйләү.
3. Артыгын исемлектән сызыгыз.
Бары тик кешегә генә хас:
1) туры басып йөрү;
2) әхлаклылык хисләре;
3) аңлашыла торган итеп сөйләү.
4. Индустриаль җәмгыятькә күчү характерлана:
1) сәнәгать перевороты белән;
2) авыл хуҗалыгының хезмәт күрсәтү өлкәләреннән өстенлеге белән;
3) яңа мәгълүмати технологияләр барлыкка килү белән;
4) социаль мобильлек кимү белән.
5. Җәмгыять һәм табигатьнең үзара йогынтысы турында түбәндәгечә фикер йөртү дөресме?
А. Мәдәниятне иҗат итүче буларак җәмгыять табигатькә бәйсез рәвештә үсә.
Б. Тарих җәмгыятьнең табигатькә карата уңай йогынтысы мисалларын белми.
1) А гына дөрес;
2) Б гына дөрес;
3) икесе дә дөрес;
4) икесе дә дөрес түгел.
6. Җәмгыять белеме һәм тарих курсларында алган белемнәрегезгә таянып, реформа һәм революцияне түбәндәге критерийлар буенча чагыштырыгыз: 1) иҗтимагый тормышка йогынты ясау тирәнлеге һәм колачы; 2) халык массаларының роле; 3) нәтиҗәләренең фаразлана алуы.
7. Түбәндә әйтелгәннәргә таянып, эссе (кыска хикәя) языгыз: «Тарих үзе генә кешене мәҗбүр итә дә, аны пычрак эшкә җәлеп итә дә алмый» (Ж.-П.-Сартр).

III бүлек

ЭШЧӘНЛЕК — КЕШЕЛӘРНЕҢ ЯШӘҮ ЫСУЛЫ

§ 17. Кешеләрнең эшчәнлеге һәм аның күптөрлелеге

Исегезгә төшерегез:

эшчәнлек кеше һәм җәмгыять тормышында нинди әһәмияткә ия?

Ике билгеләмәне чагыштырыгыз. Беренчесе — философия сүзлегеннән: «Эшчәнлек — кешелек җәмгыятенең яшәеш формасы; субъектның әйләнә-тирә дөньяны максатчан үзгәртүдә, шулай ук кешенең үз-үзен үзгәртүендә чагылучы активлыгы күренеше». Икенчесе — психология сүзлегеннән: «Эшчәнлек — субъектның объектны танып-белүнең яки үзгәртеп коруның аңлы рәвештә куелган максатына мотивлаштырылган ирешүдән гыйбарәт булган психик активлыгы формасы».

Һәр ике билгеләмәдә әйләнә-тирә дөньяны максатчан үзгәртүдә (үзгәртеп коруда) кешенең активлыгы турында сүз бара. Шулай да фәлсәфи билгеләмә эшчәнлекне җәмгыятьнең яшәү формасы кебек үк аңлата, ә психология игътибарны психик, ягъни кешенең субъектив кичерешләрендә, аның хисләрендә, фикерләвендә, ихтыярында чагылучы активлыгына юнәлтә. Күргәнегезчә, эшчәнлекне төрлечә карау аны тулырак аңларга ярдәм итә.

ЭШЧӘНЛЕКНЕҢ АСЫЛЫ ҺӘМ СТРУКТУРАСЫ

Эшчәнлекне билгеләүнең югарыда китерелгәннәрдән беренчесенә мөрәҗәгать итик. Кеше яшәеше аспектларының берсе буларак, эшчәнлек социаль элемтәләр барлыкка китерә. Анда кешенең эшчәнлек продуктларында тупланган көч һәм сәләтләре тормышка ашырыла. Элемтәләрнең бу чылбырында *эшчәнлекнең социаль асылы* ачыла.

Эшчәнлек структурасында аның субъекты һәм объекты аерылып тора. Эшчәнлек субъекты — эшчәнлекне тормышка ашыручы, *объект* ул — юнәлдерелгән нәрсә. Мәсәлән, игенче (эшчәнлек субъекты) җирдә эшли һәм анда төрле авыл хуҗалыгы культуралары (эшчәнлек объекты) үстерә. Субъект буларак Мәгариф министрлыгы өчен илнең барлык уку йортлары — аларга карата идарә итү эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган объектлар.

Шулай итеп, эшчәнлек субъекты кеше, кешеләр төркеме, оешма, дәүләт органы булырга мөмкин. Объект табигый материаллар, төрле әйберләр, кеше тормышы өлкәләре була ала. Субъектның эшчәнлеге шулай ук башка кешегә дә юнәлдерелергә мөмкин. Мәсәлән, тренер спортчыга йогынты ясый (аңа тренерлык итә). Артист эшчәнлегенең объекты — залдагы тамашачы. Ниһаять, субъектның эшчәнлеге аның үзенә юнәлдерелергә мөмкин (кеше аңлы рәвештә үз гәүдәсен күнектерә, аны чыныктыра, ихтыяр көче тәрбияли, үз белемен күтәрү белән шөгыльләнә һ.б.).

«Тормыш һәм эшчәнлек үзара ялкын һәм яктылык кебек үк тыгыз кушылганнар».

Ф.Н.Глинка (рус шагыйре)

Эшчәнлек структурасында эшнең максатын, максатка ирешү чараларын аерып күрсәтергә мөмкин. Югарыда инде билгеләп үтелде: кеше теләсә кайсы эшчәнлекне үз алдына максат куюдан башлый.

Максат — эшчәнлек юнәлдерелгән көтелгән нәтиҗәнең аңланган образы. Мәсәлән, йортны төзи башлаганга кадәр архитектор башында аның образы туа. Чынлап та, аның нинди буласын күз алдына китерми торып (күп фатирлы йортмы ул, административ бинамы, агач өйме, әллә храммы, казарма яки сараймы) бинаны төзи башлап буламы соң? Аның образы рәсемдә, сызымда, күләмле модельдә күрсәтелергә мөмкин, ләкин ул иң элек архитекторның аңында барлыкка килә.

Шулай итеп, максат — аңда күзалланган һәм билгеле бер рәвештә юнәлдерелгән эшчәнлек нәтиҗәсендә көтелгән нәрсә ул.

Уйга килгән теләсә нинди максатны тормышка ашырып була дип исәпләргә мөмкинме? Кремниең булса, ук очлыгы ясау максаты куярга мөмкин, ләкин аннан җәя ясап булмый. XIX–XX гасыр чикләрендә космоска очу турында бары тик хыялланып кына була иде, ләкин күп кешеләр эшчәнлегенең практик максатына ул фәкать берничә дистә ел үткәч, моның өчен фәнни-техник шартлар тугач кына әверелде. Димәк, теләгән теләсә нинди образ түгел, ә бәлки әйләнә-тирә дөньяның һәм эшчәнлек субъектының үзенең чын мөмкинлекләренә туры килгәне генә эшчәнлекнең ирешә алырлык максаты була ала. Өстәвенә кеше үз мөмкинлекләрен, әйләнә-тирә дөньядагы әйберләрнең үзенчәлекләрен белергә яки белә алмаска мөмкин. Эшчәнлек субъекты чын чараларны һәм аларга ирешү шартларын никадәр яхшырак белсә, максат шулкадәр төгәлрәк билгеләнә һәм ачыграк була. «Кемне акыллырак дип исәпләргә?» — дип сорый XIII гасырның сүрияле фикер иясе Әбелфараҗ һәм: «Фәкать ирешеләчәк максатка омтылган кешене»,— дип җавап бирә.

Эшчәнлек структурасында төрле эш-хәрәкәтне аерып күрсәтергә була. Мәсәлән, уку эшчәнлеге үзендә лекцияләр тыңлап язып баруны, китаплар укуны, мәсьәләләр чишүне һ.б. колачлый. Космонавт эшчәнлеге дә төрле эш-хәрәкәтләрдән: Җирне күзәтүдән, приборларны җайлаудан, тәҗрибәләр үткәрүдән, ремонт эшләреннән, тренировкалардан тора. Игенченең эшчәнлеге сөрү, чәчү, чүпләрдән арындыру, игенне урып-җыю кебек эшләрне күздә тота. Аерым эш-хәрәкәтләрдә дә максатны,

чараларны, нәтиҗәне күреп була. Мәсәлән, чүпләрдән арындыруның максаты — культуралы үсемлекләргә үсү өчен шартлар тудыру.

Максат билгеләнгәч, аларга ирешү яки эшчәнлекнең уңышсызлыгы *средство-чараларга* бәйле. Йорт төзү өчен төзелеш материаллары, механизмнар, эш кораллары һәм башка җитештерү средстволары кирәк. Ашлык үстерү өчен орлыклар, эш кораллары, агротехника алымнары системасы һ.б. кирәк. Укучыларны укырга-язарга өйрәтү өчен дәреслекләр, дәфтәрләр, укыту эшенең нәтиҗәле алымнары һ.б. кирәк. Средство-чаралар максатка ярашлы булырга тиеш. «Чыпчыкларга туптан атмыйлар» дигәндә, бу средстволарның максатка туры килмәвен аңлата.

Ә соң алга изге максатлар куеп, намуссыз чаралар кулланып буламы? Бу сорауга Яңарыш чоры фикер иясе Никколо Макиавелли менә нәрсә дип җавап бирә: «Барча кешеләрнең, аеруча судта сорап булмаган патшаларның эшләре турында аларның нәтиҗәләре буенча фикер йөртәләр, шунлыктан патшалар хакимиятне сакларга һәм җиңү яуларга тырышсыннар. Моның өчен нинди генә чаралар кулланса да, аларны һәрвакыт лаек дип санаячаклар һәм хуплаячаклар, чөнки кара халыкны күренеп торган нәрсәләр һәм уңыш кызыктыра». Ул куелган максатка ирешү өчен алдарга да ярый, «кирәк булганда, явызлыктан да чирканмаска» дип исәпли.

Димәк, җиңүчеләрне хөкем итмиләрме? Максат чараларны аклыймы? Башка төрле караш та бар: игелекле максатлар өчен теләсә нинди чаралар түгел, ә игелеклеләре генә ярый. Игелекле максатка игелексез чаралар белән ирешергә ярамый. Игелексез чаралар кулланганда, нәтиҗә куелган максаттан аерыла: ул да игелексезгә әверелә. Моның дөреслегенә кешелек дөньясының күп гасырлык тәҗрибәсе ышандыра. (Бу фикерне раслаучы тарихи мисаллар китерегез.)

ИХТЫЯҖЛАР ҺӘМ МӘНФӘГАТЬЛӘР

Галим-психологлар кешенең аны эшчәнлеккә әйдәүче кичерешләрен өйрәнәләр. Кешенең мондый кичерешләрен сәбәп (мотив) дип атыйлар. Психологиядә «сәбәп» дигәндә кеше эшчәнлеген уятучы, шуның өчен эшләнгән нәрсәне аңлыйлар. Сәбәп ролен ихтыяҗлар, социаль күрсәтмәләр, инанулар, мәнфәгатьләр, мавыгулар һәм эмоцияләр, кешеләрнең идеаллары уйнарга мөмкин.

Эшчәнлек сәбәпләрендә кешенең ихтыяҗлары чагыла. Ә ихтыяҗ — кеше тарафыннан аның организмын яшәтү һәм шәхесен үстерү өчен кирәкле нәрсә турында кичерелгән һәм аңланган мохтаҗлык ул.

Ихтыяҗ гадәттә нинди дә булса бер әйбергә юнәлтелә. Мәсәлән, ачлык — ашамлыкка мохтаҗлык, ә ашамлык куллану әйбере булып тора. Нинди дә булса бер мәсьәләне чишә алмау аны чишү өчен кирәкле белемнәргә ихтыяҗ тудыра. Бу очракта ихтыяҗның сәбәбе булып белем тора.

Кеше ихтыяҗларын өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

1. *Биологик ихтыяҗлар* (һавага, азыкка, суга, нормаль җылылык алмашуга, хәрәкәткә, үз-үзеңне саклауга, ыругны саклауга мохтаҗлык кичерү һәм кешенең биологик төзелешенә, аның табигатькә бәйлелегенә караган башка ихтыяҗлар).

2. *Социаль ихтыяҗлар.* Аларны җәмгыять тудыра. Аларда шәхеснең, мәсәлән, башка кешеләр белән күптөрле үзара мөнәсәбәтләренә, үзен булдыруга, үзен раслауга, аның хезмәтләрен җәмгыятьнең тануына булган ихтыяҗлары тупланган.

3. *Идеаль ихтыяҗлар:* әйләнә-тирә дөньяны тулаем яки аның өлешләрен танып-белүгә, анда үз урыныңны, яшәвең мәгънәсен аңлауга ихтыяҗлар. Белемгә мохтаҗлык турында әле борынгы заманнарда ук әйтелгән. Философ Аристотель: «Табигатьләре буенча барлык кешеләр дә белемгә омтыла»,— дип язган. Күп кенә кешеләр үзләренең ялларын укуга, музейларда, концерт залларында һәм театрларда булуга багышлыйлар. Кайберәүләрдә идеаль ихтыяҗлар күңел ачуларга кайтып кала. Әмма бу очракта да алар күптөрле: кемнедер — кино, кемнедер — бию, кемнедер футбол кызыктыра.

Биологик, социаль һәм идеаль ихтыяҗлар үзара бәйләнгән. Нигездә кешедәге биологик ихтыяҗлар, хайваннардан аермалы буларак, социаль ихтыяҗларга әверелә. Чынлап та, эссе көннәрдә күпләрне су эчәсе килү интектерә, ләкин берәү дә (әгәр ул соң чиктә булмаса) юлдагы чокырдан су эчми. Кеше үзенең сусавын басардай су эзли һәм су салып эчәсе савытының чиста булуы турында да кайгырта. Ашау да кеше өчен аны канәгатьләндерүнең күпләгән социаль яклары булган ихтыяҗга әверелә: кулинария нечкәлекләре дә, өйне җиһазлау, өстәл әзерләү, савыт-сабаның сыйфаты, ризыкларны тезү, ашка килгәннәр белән күңелле утыру — барысы да әһәмияткә ия.

Күпчелек кешеләрдә социаль ихтыяҗлар идеаль ихтыяҗлардан өстенрәк була. Белемгә булган ихтыяҗ еш кына профессия, җәмгыятьтә лаеклы урын алу чарасы булып тора.

Кайбер очракларда биологикны, социальне, идеальне гомумән дә аеру читен. Мисал булып аралашуга мохтаҗлык хезмәт итә ала.

Ихтыяҗларның китерелгән классификациясе фәнни әдәбиятта берденбере түгел. Күп кенә башкалары да бар. Аларның берсе Америка психологы А.Маслоу тарафыннан эшләнгән. Ул түбәндәге базис ихтыяҗларны аерып күрсәтә:

физиологик: ыругны дәвам иттерүгә, азыкка, сулауга, киемсалымга, торакка, физик хәрәкәтләргә, ялга һ.б.;

экзистенциаль (туры мәгънәсендә «яшәү»не аңлаткан латин сүзеннән): яшәвеңнең иминлегенә, комфортка, тормыш эшчәнлеге шартларының даими булуына, мәшгульлеккә гарантиягә, бәхетсезлек очракларына иминиятләштерүгә, иртәгәсе көнгә ышануга һ.б.;

социаль: социаль элемтәләргә, аралашуга, ияләшүгә, башкалар турында кайгыртуга һәм үзеңә карата игътибарга, башкалар белән уртак эшчәнлектә катнашуга;

абруйлы: үз-үзеңне хөрмәт итүгә, башкаларның сине хөрмәт итүенә, танылуга, уңышка ирешүгә һәм югары бәягә, хезмәт буенча үсүгә;

рухи: үзеңне актуальләштерүгә, үзеңне күрсәтүгә.

Маслоу теориясе буенча, ихтыяҗларның беренче ике тибы — беренчеләр (тумыштан), ә калган өчесе — икенчел (алынган). Алдагы ихтыяҗлар канәгатьләндерелгәч, киләсе ихтыяҗның һәрберсе бик тә әһәмиятлегә әверелә.

Ихтыяҗлар белән бергә *социаль күрсәтмәләр* дә эшчәнлекнең мөһим сәбәпләре булып тора. Аларда кешенең әлеге объектка карата билгеле бер рәвештә эш итәргә омтылышын чагылдыручы гомуми юнәлеш алуы күздә тотыла. Андый объект, мәсәлән, гаилә булырга мөмкин.

Үзе өчен гаилә тормышының әһәмиятен һәм файдасын бәяләүгә карап, индивид гаилә кору һәм аны саклау яклы булырга, яисә, киресенчә, гаилә булдырырга һәм гаилә җепләрен сакларга теләмәскә мөмкин. Аның эш-гамәлләре һәм үз-үзен тотышы шуңа бәйле.

Эшчәнлек сәбәпләрендә *инанулар* — дөньяга, идеалларга һәм принципларга тотрыклы карашлар, шулай ук аларны үз эш-гамәлләрең аша тормышка ашыруга омтылыш мөһим роль уйный.

Эшчәнлек сәбәпләрен формалаштыруда *мәнфәгатьләр* аеруча әһәмиятле. Кешеләр мәнфәгатьләре нигезендә аларның ихтыяҗлары ята, ләкин алар (ихтыяҗ предметларына караганда) күбрәк әлеге предметларны, барыннан да элек — ихтыяҗларны канәгатьләндерүне тәэмин итүче матди һәм рухи уңайлыкларны кулланырлык итүче иҗтимагый шартларга юнәлдерелгән. Кешеләрнең мәнфәгатьләре уңайлык-байлыкларны бүлүдән, аларга бәйле булган шартларны (учреждениеләрне, нормаларны, тәртипләрне һ.б.) саклаудан яки үзгәртеп корудан тора. Бу мәнфәгатьләр теге яки бу төркемнең җәмгыятьтә тоткан урынына бәйле. Һәр кеше берничә социаль төркемгә керә. Мәсәлән, яшь кеше, башка төркемнәрдән аермалы буларак, үз мәнфәгатьләре булган (белем, профессия алу, гаилә кору өчен

матди шартларга ия булу һ.б.) яшькә кирә. Ул шулай ук нинди дә булса этник төркемгә дә кирә, һәм аның әлеге төркемнең башка гаиләләре белән уртак мәнфәгатьләре була (милли мәдәниятне, телне үстерү мөмкинлекләре). Башка төркемнәр әгъзасы буларак, кешенең шуңа ярашлы социаль мәнфәгатьләре була. Димәк, мәнфәгатьләр төрле социаль төркемнәрнең һәм индивидларның җәмгыятьтә тоткан урыннары белән билгеләнә. Алар күпмедер дәрәҗәдә кешеләр тарафыннан аңлана һәм эшчәнлекнең төрле төрләренә мөһим этәргеч (стимуллар) булып торалар. Җәмгыятьтә төрле: индивидуаль, төркем, тулаем җәмгыять мәнфәгатьләре үзара эш итә. Юнәлгәнлекләре буенча мәнфәгатьләр икътисади, социаль, сәяси, рухига бүленә.

Кешеләрнең мәнфәгатьләре белән аларның идеаллары бәйле. *Иҗтимагый идеал* — билгеле бер социаль төркемнең мәнфәгатьләре һәм омтылышлары, аның югары гаделлек һәм җәмгыятьтә яхшы урын алуы турындагы күзаллавы чагылган камил иҗтимагый образы ул. *Әхлакый идеал* — үрнәк алырга лаеклы кеше, аның шәхси, кешеләр белән мөнәсәбәттә үзен тотышының үзенчәлекләре турында күзаллау. Әхлакый идеал, гадәттә, иҗтимагый идеал белән тыгыз бәйләнгән.

Ихтыяҗлар, мәнфәгатьләр идеаллар тарафыннан аңлана, ягъни аңлы эшчәнлекне характерлыйлар. Кешеләр эшчәнлекне уйлыйлар, үз эш-гамәлләренә контрольлек итәләр. Ләкин эшчәнлектә аңсызы да була, ул аңнан башка гына эшләнгән психик тормышны аңлата. Мисал булып мәсьәләләрне чишү процессындагы автоматлаштырылган эш *стереотиплары* яки түбәндә әйтеләчәк *интуиция* хезмәт итә ала.

Кеше эшчәнлегендә *ихтыяр*, ягъни юнәлгәнлекләре белән капма-каршы булган теләк-омтылышларын җиңеп, куелган максатка таба аңлы рәвештә эш итү сәләте зур әһәмияткә ия.

ЭШЧӘНЛЕК ТӨРЛӘРЕ

Эшчәнлек төрләрен төрлечә классификациялиләр. Барыннан да элек эшчәнлекнең практик һәм рухи эшчәнлеккә бүленүен билгеләп үтик.

Практик эшчәнлек табигатьтәге һәм җәмгыятьтәге реаль объектларны үзгәртеп коруга юнәлдерелә. Ул матди-җитештерү эшчәнлеген (табигатьне үзгәртеп коруны) һәм социаль-үзгәртеп кору эшчәнлеген (җәмгыятьне үзгәртеп коруны) колачлый.

Рухи эшчәнлек кешеләрнең аңын үзгәртү белән бәйле. Аңа танып-белү эшчәнлеге (чынбарлыкны әдәби-нәфис һәм фәнни формада, мифларда һәм дин өйрәтүләрендә чагылдыру); кыйммәти-юнәлешле эшчәнлек (кешеләрнең әйләнә-тирә дөнья күренешләренә уңай яки тискәре мөнәсәбәте, аларның дөньяга

карашын формалаштыру); фаразлау эшчәнлеге (чынбарлыкның ихтимал булган үзгәрешләрен планлаштыру яки күзаллау) кирә.

Эшчәнлекнең барлык төрләре үзара бәйләнгән. Мәсәлән, реформалар үткәрү алдыннан (социаль-үзгәртеп кору эшчәнлеге) аларның ихтимал булган нәтиҗәләре анализланырга тиеш (фаразлау эшчәнлеге). Франция мәгърифәтчеләре Вольтер, Ш.Монтескье, Ж.-Ж.Руссо, Д. Дидро идеяләре (кыйммәти-юнәлешле эшчәнлек) XVIII гасырдагы Франциядә революцияне әзерләүдә зур роль уйнаган (социаль-үзгәртеп кору эшчәнлеге). Матди-җитештерү эшчәнлеге табигатьне танып-белүгә, фәнне үстерүгә (ягъни танып-белү эшчәнлегенә) ярдәм итә, танып-белү эшчәнлеге нәтиҗәләре (фәнни ачышлар) җитештерү эшчәнлеген камилләштерүгә булыша.

> **«Хайван аның бөтен эше — яшәү дип уйлый, ә кеше тормышны нәрсә дә булса эшләү мөмкинлеге итеп кабул итә».**
>
> **А.И.Герцен**

Кеше эшчәнлегенең күп төрләре арасында *иҗади* һәм *җимергеч* эшчәнлекләрне күрергә була. Беренчесенең нәтиҗәләре — шәһәрләр һәм авыллар, чәчәк атып утыручы бакчалар һәм эшкәртелгән кыр-басулар, һөнәрчеләр эшләгән әйберләр, машина, китап, кинофильмнар, дәваланган авырулар һәм тәрбияләнгән балалар. Җимергеч эшчәнлек — барыннан да элек сугышлар ул. Һәлак булган һәм гарипләнгән кешеләр, җимерелгән тораклар һәм храмнар, ялангач кыр-басулар, яндырылган кулъязмалар һәм китаплар — болар барысы да аерым (җирле) һәм дөньякүләм, гражданнар һәм колониаль сугышлар нәтиҗәләре.

Ләкин кулында хакимият булган кешеләрнең административ эшчәнлеге дә җимергеч булырга мөмкин. Рус язучысы М.Е.Салтыков-Щедрин сатирик рәвештә «соңыннан аннан файда чыксын өчен» үзенә ышанып тапшырылган бер өлкәдә мөмкин кадәр күбрәк зыян эшләргә карар иткән бер түрәне сурәтли. Аның программасы: «Башта ул фәнне бетерәчәк, аннары шәһәрне яндырачак, ниһаять, халыкны куркытачак». Һәм өстәвенә һәрвакыт яшь коячак һәм: «Ходай күреп тора, мин бу зыянны аларның үз файдалары өчен эшлим», — ди. Һәм безнең заманда да, утопик максатлар бәрабәренә яисә табыш алу, йә булмаса тарихта үз эзләрен калдыру өчен иҗтимагый тормышның үзен аклаган формаларын җимерергә, әйбәт традицияләрне ватарга, үз эшләре белән табигатькә төзәтә алмаслык зыян салырга әзер торучы эшлеклеләр бар. Җимергеч

эшчәнлек уңаеннан халыкта: «Җимерү — төзү түгел», — диләр. Ләкин еш кына җимергеч эшчәнлек явыз ихтыяр тарафыннан түгел, ә теләгән уңай нәтиҗәгә ирешү мөмкинлекләре чикләнгәнлектән туа. В.Г.Белинский: «Бөек реформалар җимерү өчен килми, җимереп, яңаны булдыру өчен килә»,— дигән.

ИҖАДИ ЭШЧӘНЛЕК

Күз алдына китерик: әйтик, конструкторлар алдына яңа модельдәге автомобиль булдыру бурычы куелган ди. Машинаны тагын да куркынычсызрак итеп ничек эшләргә? Ягулык тотуын ничек киметергә? Узел һәм детальләрнең озак эшләвенә ничек ирешергә? Атмосфераның чыккан газлардан пычрануын ничек булдырмаска? Машинаны ясаганда металл яки башка материаллар тотуны ничек киметергә? Бу сорауларга яңа җаваплар кирәк, ә аларны эзләү иҗади эшчәнлек булып тора.

Нәрсә соң ул *иҗат*? Бу сүз белән ниндидер моңарчы беркайчан да булмаган бер нәрсәне булдыру эшчәнлеген аңлату кабул ителгән. Ул яңа максат, яңа нәтиҗә яки яңа чаралар, аларга ирешүнең яңа ысуллары булырга мөмкин. Иҗат галимнәр, уйлап табучылар, язучылар, рәссамнар эшчәнлегендә аеруча ачык күренә. Кайчак алар турында «профессиональ иҗат кешеләре» диләр. Чынлыкта исә фән белән шөгыльләнгән барча кеше дә ачыш ясамый. Шул ук вакытта эшчәнлекнең башка бик күп төрләрендә (укытучы яки эшмәкәр, бакчачы яки пешекченекендә) иҗат элементлары була. Киң мәгънәдә әйткәндә, кешеләрнең табигать дөньясын һәм социаль чынбарлыкны үз максатларына һәм ихтыяҗларына туры китереп яңартып коручы бөтен эшчәнлеге иҗади була.

Иҗат тулысынча кагыйдәләр белән чикләнгән эшчәнлектә түгел, ә алдан чикләнгәннәр эчендә күпмедер дәрәҗәдә билгесезлек булган эшчәнлектә ята. Иҗат яңа мәгълүмат булдыруны һәм үзоештыруны күздә тоткан эшчәнлектән гыйбарәт. Яңа кагыйдәләр, стандарт булмаган алымнар булдыру зарурлыгы элеккеге шундый ук хәлләрдән аерылып торучы яңа хәлләр белән очрашканда барлыкка килә.

Иҗади эшчәнлектә моңа кадәр булган белемнәрне, билгеле эш ысулларын башкача куллану, сайлап алу мөһим урын алып тора. Эшчәнлеккә этәрүче ихтыяҗ *күзаллау, фантазия* чыганагы, ягъни чынбарлык күренешләрен кеше аңында яңа, гадәти булмаган, көтелмәгән кушылмаларда һәм бәйләнешләрдә чагылдыру чыганагы булырга мөмкин. Күзаллау (фаразлау) практиканы узып китү, ихтимал булганнарны алдан күрү мөмкинлекләре бирә. Мәсәлән, «үлем элмәге» (ягъни иң югары пилотажның беренче фигурасы) очучы П.Нестеров тарафыннан баш-

та күзаллау-фантазиядә, аннары самолетта һавада башкарыла. Фантазия — кешенең иҗади эшчәнлегенең кирәкле бер өлеше, ул максатка ирешү шартлары һәм чаралары турында мәгълүмат җитмәгән очракларда аның нәтиҗәләренең образын яки күргәзмә моделен төзүдә чагыла. Мондый очракта кеше: «Мин үземнең хаклыгымны исбатлый алмыйм, ләкин сизәм: нидер эшләргә кирәк»,— дип әйтә ала. Шул рәвешле, интуициядә кеше эшчәнлегенең аңсыз бернәрсәсе чагыла. Кайчак тикшеренүче еллар буе баш ваткан катлаулы фәнни проблеманың чишелеше еш кына ничектер кинәт кенә, көтмәгәндә, хәтта кайчак кешенең мие бөтенләй дә башка мәсьәләне чишү белән мәшгуль вакытта килә.

Әмма иҗаттагы аңсызлык, кагыйдә буларак, килеп туган проблемаларны чишүгә юнәлдерелгән аңлы тырышлыклар белән бәйле. Бәхетле фикер галим яки полководецны, уйлап табучы яки шагыйрьне «яктыртканга» кадәр чишелешне эзләү, аның төрле вариантларын анализлау, кирәкле материалны әзерләү өчен күп хезмәт куелган була. Психологлар, дөрес чишелеш юлында проблеманы аңлы өйрәнү һәм образларның аңсыз туплануы, мәсьәләне ачык аңлау һәм аның чишелешен аңсыз табу була дип исәплиләр. Ачыш буш урында була алмый, ул үткән тәҗрибәгә һәм тупланган белемнәргә таяна. Әмма чишелешкә ачкыч элеккеге тәҗрибәнең аңланмаган өлеше, аның «өстәмә продукты» булырга мөмкин.

Иҗатның табигатенә башкача карашлар да бар. Мәсәлән, рус философы Н.А.Бердяев иҗатны өстәлү, дөньяда булмаган яңаны булдыру дип исәпли. Ул иҗат серен дөньяны юктан бар иткән Алла белән бәйли.

Бүген фән теләсә кайсы кешедә күпмедер дәрәҗәдә иҗат эшчәнлеге сәләтләре бар дип исәпли. Ләкин сәләтләр ачылырга яки ябылырга мөмкин. Үзеңдәге иҗади сәләтләрне үстерү өчен яшь кеше нәрсә эшләргә тиеш? Әлбәттә, мәдәнияткә, телгә, белемнәргә, эшчәнлек ысулларына ия булырга. Элеккеге буыннарның мәдәнияттә сеңдерелеп калган тәҗрибәсендә иҗади эшчәнлек тәҗрибәсе дә бар. Ләкин аны андый эшчәнлеккә үзеңнең кушылуың белән генә үзләштерергә мөмкин. Сораулар бирергә, стандарт булмаган, авыр мәсьәләләрне чишәргә өйрәнергә, чишелешнең төрле вариантларын уйларга, туры килмәгән карашларны чагыштырып карарга, сәнгать белән аралашырга; күзаллауны, фантазияне үстерергә, теләсә нинди дәлилләүгә ышанмаска, проблеманы чишкәндә төрле чаралар кулланып карарга, аларның иң яхшы комбинацияләрен эзләргә һәм бөек рус композиторы П.И.Чайковскийның «Илһам шундый кунак ки, ул ялкауларда булырга яратмый» дигән сүзләрен истә тотарга кирәк.

Төп төшенчәләр: эшчәнлек, эшчәнлекнең сәбәпләре, ихтыяҗлар, иҗат.

Терминнар: максат, максатка ирешү чаралары, эш-гамәл, аңсыз килеш.

Үзегезне тикшерегез

1. Эшчәнлекнең социаль асылы нидән гыйбарәт? 2. Эшчәнлекнең структурасы нинди? 3. Эшчәнлекнең субъекты һәм объекты нәрсәләр алар? 4. Эшчәнлекнең максаты, чаралары һәм нәтиҗәсе үзара ничек бәйләнгән? 5. Эшчәнлекнең сәбәпләре нинди? 6. Ихтыяҗлар һәм мәнфәгатьләр ничек яраша? 7. Иҗади эшчәнлекнең үзенчәлекләре нәрсәдә?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Архитектор фикерендә максат уйланган корылма образы рәвешендә килеп баса. Ә дәүләт эшлеклесенең, укытучы, полководецның нинди максаты булырга мөмкин? Җавабыгызны дәлилләгез.

2. Америка язучысы Э.Хемингуэй (1899–1961): «Һәрбер кеше нинди дә булса эш өчен туа», — дигән. Ничек уйлыйсыз, «эш» сүзе астында эш-гамәлме, әллә эшчәнлек күздә тотыламы? Үз карашыгызны дәлилләгез.

3. Күпләргә таныш гыйбрәтле хикәятнең мәгънәсе турында уйланыгыз.

Узып баручы кирпеч төялгән тачкалар этеп баручы өч эшчене очраткан да аларның нәрсә эшләүләрен сораган. «Күрмисеңмени, — дигән беренчесе, — кирпеч ташыйм». «Гаиләгә ипилек эшлим», — дигән икенчесе. Ә өченчесе: «Сарай төзим», — дип җавап биргән. Аларның эшчәнлеге бер үк төрле булганмы? Әллә эшчәнлекнең төрле төрләрендә бер үк эш-гамәлме?

4. «Талантны җиргә күмәргә» дигән сүзләрне сез ничек аңлыйсыз?

5. Уйлагыз: иҗади эшчәнлекнең В.И.Вернадский аерып күрсәткән шартларын сез башкара аласызмы:

җентекле анализ үткәрергә;

аерымда гомумине күрергә;

күренешне сурәтләп кенә калмыйча, аның асылын һәм башка күренешләр белән бәйләнешен тирәнтен тикшерергә;

«ни өчен» дигән сораудан качмаска;

идеяләр тарихын күзәтергә;

тикшерелә торган нәрсә турында әдәби чыганаклардан мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат җыярга;

фәнни танып-белүнең гомуми закончалыкларын өйрәнергә (кешенең әйләнә-тирә дөньяны ничек өйрәнүе турында уйларга);

фәнне белемнең башка өлкәләре, иҗтимагый тормыш белән бәйләргә;

проблеманы хәл итеп кенә калмаска, ә яңаларын, хәл ителмәгәннәрен табарга.

Әлеге шартларны үтәп, «Мәктәптә иҗади эшчәнлеккә әзерләнүне ничек итеп яхшыртырга?» дигән проблеманы әзерләп, аның турында фикер алышыгыз.

Чыганак белән эшләгез

Совет философы А.Л.Никифоров эшчәнлекнең һәм үз-үзеңне тотуның нисбәте турында.

Кешенең активлыгы бик тә мөһим ике функция башкара: беренчедән, әйләнә-тирә дөньяга йогынты ясап һәм аны үзгәртеп, ул индивидның матди һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү чарасы булып хезмәт итә; икенчедән, ул шәхеснең белемнәрен, булдыклылыкларын, осталыкларын чагылдыручы һәм үстерүче булып тора. Һәр ике функция кеше активлыгының һәр гамәлендә бергә берләшкән. Без йортлар төзибез, икмәк үстерәбез, кием-салым әзерлибез һәм космоска ракета җибәрәбез. Үз ихтыяҗларыбызны канәгатьләндерү өчен тышкы дөньяны үзгәртеп һәм яраклаштырып, без әйләнә-тирәлекне үзгәртү процессында бер үк вакытта үз зәвыгыбызны, һәвәслегебезне, дөньяны кабул итүебезне һәм аңа мөнәсәбәтебезне белдерәбез. Шунлыктан безнең активлыгыбызның барлык продуктларында билгеле бер тарихи чор кешесенең, билгеле бер мәдәният вәкиленең шәхси эзе ята. Атап үтелгән активлык функцияләренең беренчесен — эшчәнлек, икенчесен үзеңне тоту башкара. Эшчәнлек һәм үзеңне тоту — аерымланган гамәлләр түгел, ә кешенең бердәм активлыгының ике ягы.

Индивид активлыгында үз-үзеңне тоту һәм эшчәнлек бердәмлегенең яхшы үрнәге — телдән файдалану. Лингвистлар, билгеле булганча, билгеле бер законнар буенча эш итүче һәм үсүче үзара бәйләнгән төшенчәләр (символлар) системасын тәшкил итүче *телне* һәм *сөйләмне* телне аерым индивидларның конкрет хәлләрдә куллануын аерып күрсәтәләр. Аңлаешлы булсын өчен, сөйләм телнең гомум әһәмиятле законнары буенча төзелергә тиеш; ләкин, шуның белән бергә ул һәрвакыт индивидуаль характерда була һәм сөйләүче субъектның үзенчәлекләрен чагылдыра. Шунлыктан гәрчә без бер телдә сөйләшсәк тә, төрлечә сөйлибез. Телне һәм аның кагыйдәләрен куллану — сөйләүче кешенең үзен тотышы йөкләнгән эшчәнлек ул; сөйләм шулай барлыкка килә.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Галим фикеренчә, эшчәнлек һәм үз-үзеңне тоту арасында аерма нәрсәдә? Ни өчен аларны

кешенең бердәм активлыгының ике ягы итеп карарга кирәк? 2. Түбәндәге сүзләрнең һәркайсы әлеге ике төшенчәнең кайсысына туры килә: максат, гамәл, эш, чаралар, операцияләр, нәтиҗәләр, җинаять? 3. Эшчәнлек һәм үзеңне тоту нисбәтен азык-төлек кибетендә эшләүче өч сатучы үрнәгендә (яисә үз мисалыгызда) күрсәтегез.

§ 18. Рухи эшчәнлекнең эчтәлеге һәм формалары

Исегезгә төшерегез:

теләсә нинди эшчәнлекнең структурасы нинди? Җәмгыятьнең рухи мәдәниятенә нәрсәләрне кертәләр? Рухи һәм матди мәдәниятләр үзара ничек бәйләнгән?

Мөстәкыйль төстә зур булмаган социологик тикшеренү үткәреп карагыз. Төрле кешеләрдән «рух», «рухи» сүзләренең нәрсә аңлатуын сорагыз. Әңгәмәдәшләрегезнең бу сүзләргә төрле мәгънә бирүенә шаккатырсыз. Кайбер кешеләрдә алар дин, чиркәү сүзләре белән охшашлык табар (мәсәлән, «рухи музыка»). Профессиональ мәдәният эшлекләре барыннан да бигрәк рухилыкның алар өчен «иҗат» сүзенең синонимы булуын билгеләп үтәрләр. Күпчелек «рух», «рухилык» төшенчәләрен югары максатлар һәм кеше тормышының мәгънәсе, шәхеснең әхлакый йөзе турындагы күзаллаулар белән бәйли.

Төрлечә аңлату, бер яктан, әлеге төшенчәләрнең мөһимлеген күрсәтә; икенче яктан, аларны фәнни билгеләүне кыенлаштыра. Бу параграфта без «рухи эшчәнлек», «рухи кыйммәтләр», «кешенең рухи дөньясы» төшенчәләренең социаль мәгънәләрен ачыкларга тырышачакбыз. Безгә рухи эшчәнлекнең гомуми структурасында нинди урын алып торуын, галимнәрнең җәмгыятьнең рухи тормышының төрле якларын ничек тикшерүләрен, рухи кыйммәтләрнең шәхеснең үсүенә ничек ярдәм итүен ачыкларга кирәк булачак.

РУХИ КЫЙММӘТЛӘРНЕ БУЛДЫРУ ҺӘМ ҮЗЛӘШТЕРҮ

Сезгә инде билгеле булган эшчәнлекнең кешеләрнең табигатьне һәм җәмгыятьне үзгәртүгә юнәлдерелгән аңлы максатчан активлыгы буларак билгеләмәсеннән чыгып эш итәрбез. Иҗтимагый активлык нәтиҗәсендә, кешеләрнең төрле ихтыяҗларын канәгатьләндерүче объектлар: эш кораллары, азык-төлек һәм кием-салым, дәүләт һәм мәдәният учреж-

дениеләре, сәнгать әсәрләре, архитектура ансамбльләре, фәнни хезмәтләр барлыкка килә. **Кешенең иҗади эшчәнлегенең «табигать матдәсен» түгел, ә «кешеләрнең кешеләрне» эшкәртүенә, ягъни ахыр чиктә социаль субъектларның үзләренең сыйфатларының үзгәртүгә юнәлдерелгән ягы — рухи эшчәнлек, ә аның продуктлары рухи кыйммәтләр дип атала.** Педагог, шулай ук артист, рухани, журналист хезмәте рухи эшчәнлекнең ачык мисалы булып тора.

Рухи кыйммәтләр барлык башкаларыннан нәрсәләре белән аерылып тора соң? Мисал итеп китапны алыйк. Ул матди, хисси нәрсәләрнең барлык сыйфатларына ия: аны күреп һәм тоеп, бер урыннан икенче урынга күчереп, хәтта юк итеп була (ләкин моны эшләргә ярамый). Китапны булдыруга кыйммәтле табигый материаллар һәм җанлы, тере кешеләр хезмәте кергән. Ниһаять, китапның, башка күпләгән товарлар кебек үк, базар бәясе бар. Милли халык киеме картина, скульптура һәм башка бик күп нәрсәләр кебек үк, китапны тышкы дөнья объектларына түгел, ә иң элек рухи кыйммәтләргә кертү өчен безгә аның нинди үзенчәлекләре хокук бирә?

Күренеп торган образ һәм утилитар практик функцияләр аталган әйберләрнең тирән асылын ачып бетермиләр. Америка социологы Р.Мертон ачыкны һәм латентны, ягъни мәдәни объектларның ачык булмаган, турыдан-туры күзәтүдән яшеренгән функцияләрен аерырга куша.

Философлар рухи күренешләрнең төп аермалары аларның *идеальлегендә* дип раслый. Рухи кыйммәтләр «төрелгән» матди материал бары тик бик тә хисле эчтәлекнең формасы гына була. Борынгы грек философы Платон идеяләр турында үзенчәлекле тәгълимат булдыра. Анда бәхет, хакыйкать, матурлык кебек рухи кыйммәтләр реаль әйберләр дөньясы белән янәшә яшәүче һәм соңгыларының асылын билгеләүче автоном идеаль дөнья рәвешендә күзаллана. XIX гасыр немец философы Г.Гегель рухның төп сыйфаты — рефлексия, ягъни үз-үзеңне танып-белү сәләте дип раслый. Аның «Рух феноменологиясе» дигән гомумиләштерүче хезмәтендә дөнья мәдәниятенең бөтен тарихын кешенең асыл, рухи көчләре үсеше көзгесе итеп карарга тырышыла. Әдәбият һәм сәнгать әсәрләре иҗат итеп, кешеләр үз белемнәрен, хисләрен, тормыш тәҗрибәләрен, үз идеалларын, омтылышларын һәм өметләрен *предметлаштыралар.* Уку һәм белемнәрен күтәрү вакытында кешеләр, киресенчә, аларда булган рухи кыйммәтләрне *предметсызландыралар*, шул ук вакытта үзләренең интеллектуаль белемнәрен киңәйтәләр, шәхси иҗади сәләтләрен үстерәләр һәм арттыралар. Рухи тормыш күренешләре арасыннан Гегель бигрәк тә телне, фән, дин, әхлак, сәнгатьне, философия һәм хокукны аерып күрсәтә.

Гегель заманыннан соң кешеләрнең яшәү рәвеше нык үзгәрә. Эшчәнлекнең рухи өлкәсе мода һәм реклама, массакүләм мәгълүмат чаралары, Интернет кебек яңа күренешләр белән баеый. Иҗтимагый практиканың һәм социаль таныпбелүнең үсә барган ихтыяҗларына җавап итеп, XX йөзьеллыкта кыйммәтләр турындагы аерым фәлсәфи фән — *аксиология* барлыкка килә.

Әлеге юнәлешне үстерүче философлар билгеләп үткән беренче нәрсә — рухи кыйммәтләрнең иҗтимагый характеры. Мәсәлән, без үз фикерләребезне белдерү өчен куллана торган тел, асылда,— милли мәдәният байлыгы ул. Рухи байлыклар аралашу процессында булдырыла, коммуникация ярдәмендә тарала һәм барыннан да элек социаль үзара бәйләнешләрнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә хезмәт итәләр. Рухи кыйммәтләр алмашу нәтиҗәсендә кешеләрнең үзара аңлашуын тәэмин итүче идеяләрнең, образлы күзаллауларның, социаль хисләр һәм кичерешләрнең «күмәк зонасы» булдырыла. Рухи кыйммәтләрне кулланган вакытта аларның бердәм фондлары кимеми, ә арта. Бу закончалыкны күрсәтү өчен түбәндәге парадоксны китерергә була: «Минем алмам булып, аны сиңа бирсәм, миндә алма калмый. Минем идеям булып, аны синең белән уртаклашсам, икебезнең дә уртак идеясе булачак». Моңа тагын шунысын да өстәргә кирәк: рухи кыйммәтләр алмашу замандашлар арасында гына түгел, төрле буын, хәтта төрле тарихи чорлар вәкилләре арасында да була ала. Киңлек һәм вакыт киртәләреннән үтеп, рухи алмашу мисалларын үзегез дә китерә аласызмы?

Философлар ясаган икенче бер мөһим нәтиҗә шуннан гыйбарәт. Гәрчә рухи кыйммәтләрне куллану («үзләштерү» дисәк дөресрәк булыр) индивидуаль, шәхси характерда булса да, рухи кыйммәтләрнең эчтәлеге объектив, ягъни аерым кешенең ихтыярына һәм аңына бәйле түгел.

Математика теорияләр, грамматика һәм синтаксис законнары, кайбер иҗтимагый әхлак нормалары (мәсәлән, үтерүне тыю) күздә тотылганда, рухи кыйммәтләрнең объектив характеры бик тә ачык кебек. Дөньяга караш, эстетик, сәяси кыйммәтләрнең объективлыгын нигезләү исә шактый кыенрак. Гәрчә дөньядагы барлык телләрдә дә изгелек һәм явызлыкны, матурлык, гаделлек, бурыч һәм ирекне белдерүче сүзләр булса да, бу төшенчәләргә төрле цивилизацияләр һәм мәдәниятләр биргән конкрет мәгънә шактый аерыла. Бу исә немец философы Ф.Ницшены һәм аның тарафдарлары — нигилистларны (латин сүзе nihil «кире кагам» дигәнне аңлата) барлык рухи кыйммәтләрнең чагыштырмалылыгы турындагы тезис белән чыгарга этәрә.

Барлык кешеләр барлык чорларда бер үк төрле аңлаган абсолют рухи кыйммәтләр бармы? Бу мәсьәлә бүгенге көнгәчә бәхәсләшү өчен ачык булып кала бирә. Сез үзегезнең фикерегезне әйтә һәм аны дәрестә тикшерә аласыз.

Чагыштырмача күптән түгел ясалган тагын бер ачыш рухи кыйммәтләрне булдыру, трансляцияләү, тиражлау, үзләштерү процессларында *билгеләр* һәм *символлар*ның үзенчәлекле ролен ачыклау белән бәйле. Франция тикшеренүчеләре белән бергә, белемнең бу өлкәсенә Россия культурологы Ю.М.Лотман мөһим өлеш кертте. Билгеләр ярдәмендә чагылдырылмаган кыйммәтне күз алдына китерүе читен. Кешеләрнең бик күп эш-гамәлләре — көндәлек гадәтләр һәм тантаналы йолалар, әдәби тел һәм сөйләм жаргоны, кием һәм чәч стиле, мимика һәм ишарә, һичсүзсез, билгеләр характерында була. Яшәлә торган һәр мәйдан, киңлек, мәсәлән, шәһәр мәйданы, храм, хәрби часть яки йорт эче мәйданы билгеләр ярдәмендә билгеләнә һәм оештырыла. Билгеләр һәм символлар (хәтта без аларны күрмәгәндә дә) безне һәркайда чолгап алганнар.

Бер үк төрле рухи кыйммәтләр төрле билгеләр системалары ярдәмендә чагылдырылырга (кодланырга) мөмкиннәр. Күрәсең, гомеребезнең шактый өлешендә без (белепме, белмичәме) билгеләрне кодлаштыру һәм кодтан чыгару белән шөгыльләнәбез. Шәхеснең мәдәни белеменең гомуми дәрәҗәсе моны ни дәрәҗәдә тиз һәм төгәл эшләвебезгә, билге «хәбәрләре»нең мәгънәсен ни дәрәҗәдә дөрес һәм тирән аңлавыбызга бәйле. Боларның барысы да немец философы һәм культурологы Э.Кассирерга кешене «символик хайван» дип атарга, француз социологы П.Бурдьега «рухи кыйммәтләр» белән «символик кыйммәтләр» төшенчәләре арасында фактта тигезлек билгесе куярга нигез була.

ҖӘМГЫЯТЬНЕҢ РУХИ ТОРМЫШЫ

Хәзерге җәмгыятьнең рухи тормышы бик тә тиз хәрәкәтле. Һәр көнне символик кыйммәтләр базарына төрле-төрле сәнгать әсәрләре, яңа сәяси лозунглар, газета һәм журналлар, телесериаллар чыгарылып тора. Бүгенге мәдәният белән аралашырга әзер булмаган кешегә боларның бөтенесе анда бик тиз адашырга мөмкин булган хаос тәэсире тудырырга мөмкин. Чынлыкта исә рухи кыйммәтләр булдыру һәм үзләштерү процесслары тәртипкә салынган була һәм билгеле бер иҗтимагый законнарга буйсыналар.

Кешеләрнең рухи эшчәнлегенең төп тарихи формаларының — дин, әхлак, сәнгать, фән, философия, хокук, сәяси идеологиясенең бурычларын аңлау аеруча мөһим. Тарихи дип

алар шуңа аталалар: чөнки кешелек дөньясының рухи аякка басуының билгеле бер даимилеген чагылдыралар. Әлеге формаларның һәрберсе кешеләрнең үзенчәлекле рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә һәм сурәтләүнең үзенчәлекле символик билге-чараларын куллана. Мәсәлән, сәнгать, кешенең гүзәллек белән аралашуга булган ихтыяҗын канәгатьләндереп, эстетик фикерләүнең һәм дөньяны үзгәртеп коруның күп гасырлык тәҗрибәсен туплый. Сәнгатьнең символик теле — нәфис һәм хисләргә тулы образлар. Фән исә белемнәргә булган социаль ихтыяҗларны канәгатьләндерә һәм символик код сыйфатында фәнни төшенчәләр, теорема, теорияләрнең катгый телен файдалана. Сез, аларның үзенчәлекләрен һәм иҗтимагый бурычларын яхшырак аңлау өчен, мәсәлән, хокук һәм әхлакны, дин һәм сәяси идеологияне чагыштырып, бу анализлауны үзегез дәвам иттерә аласыз.

Югарыда каралган күренешләр җәмгыятьтәге рухи тормышның «югары катлавын» барлыкка китерәләр кебек. Аларның барысы да үзләренчә мөһим һәм кирәкле. Рухи эшчәнлекнең теләсә кайсы формасының эшен бүтәннәре башкара алмый. Шуның белән бергә төрле тарихи дәверләрдә аларның әле берсе, әле икенчесе алгы планга чыккан. Мәсәлән, Урта гасырларда төп рольне дин уйнаган, чөнки рухи эшчәнлек өлкәсендә төп заказчы, оештыручы һәм иҗтимагый эксперт сыйфатында чиркәү эш иткән. Яңа вакытта, якынча XVII йөзьеллыктан башлап, әлеге роль акрынлап дәүләткә күчә барган, шул уңайдан *секуляризация* — диннең йогынтысы чагыштырмача кимү процессы күзәтелгән. Алгы планга рухи эшчәнлекнең фән, философия, сәяси идеология кебек формалары чыгарыла башлаган. Ләкин бу процесс гомумкүләм булмаган һәм барлык илләргә дә бер үк дәрәҗәдә кагылмаган.

Тарихта җәмгыять тормышыннан бер рухи кыйммәтне көчләп «кысрыклап чыгарырга» һәм аны икенчесе белән алыштырырга, мәсәлән, динне фән белән, әхлакны идеология белән алыштырырга тырышулар булган (мәктәптәге тарих курсыннан моның кайда һәм кайчан булганын исегезгә төшерегез), ләкин алар күпчелек очракта уңышсыз тәгаълләнгән.

Бүгенге җәмгыятьтә рухи эшчәнлекнең кайсы формасы төп рольне уйный? Күпләгән галимнәр фикеренчә, бу урынга һаман саен күбрәк *массакүләм мәгълүмат чаралары* (ММЧ) дәгъва итә, ә рухи кыйммәтләрне булдыручылар һәм кулланучыларның мәнфәгатьләрен бәйләп торучы төп арадашчы сыйфатында базар мөнәсәбәтләренең үзенчәлексез (шәхси үзенчәлекләргә битараф) механизмы тора. Җәмгыять һаман күбрәк дәрәҗәдә идеяләр ярдәмендә түгел, ә коммуникация каналлары ярдәмендә оеша һәм идарә ителә. Бу үзгәрешләр күпләгән яңа

социаль проблемалар, аерым алганда, кайбер традицион интеллигентлы профессияләрнең образлары кимүен һәм кайбер яңаларының — мәгълүмат агентлыгы яки медиа-холдинг хезмәткәре, мәдәният менеджеры, продюсер, реклама агенты, телевидениедә тапшырулар алып баручының һ.б. популярлыгы күтәрелүен китереп чыгарды. Әсәрләрне күпләп бастыру турында карар кабул итү өчен иң саллы дәлилләрнең берсе — күбрәк табыш алу мөмкинлеге. Мәдәният эшлеклеләренең кайберләре мондый хәлне «җәмгыятьнең рухи кризисы» яисә «рухи түбәнлек» дип бәялиләр.

Җәмгыять өчен рухи эшчәнлекнең төп тарихи формаларының мөһимлеге тагын шуның белән раслана: алар күпчелек профессионаллар тарафыннан мәктәп һәм университет, музей, китапханә, театр һ.б. кебек махсус мәдәният учреждениеләрендә үстерелә һәм камилләштереләләр. Бу өлкәләрдә уңышка ирешү өчен иң аз дигәндә югары белем чикләрендә киң махсус белемнәргә ия булырга кирәк. Шуңа күрә дә иҗтимагый тормышның әлеге өлкәсен тагын *махсуслашкан рухи эшчәнлек* дип атыйлар.

Ләкин махсуслашканнан тыш *махсуслашмаган рухи эшчәнлек* тә бар. Тел, халык гореф-гадәтләре һәм традицияләре, мода, этикет кебек күренешләргә игътибар итегез. Алар канәгатьләндерә торган иҗтимагый ихтыяҗларны бертөрле генә билгеләп буламы? Бүгенге җәмгыятьтә эшчәнлекнең бу төрләре өчен «җаваплы» махсус оешмалар һәм учреждениеләр бармы? Билгеле ки, профессионалларның гына түгел, ә җәмгыятьнең барлык әгъзаларының да мәнфәгатьләренә кагылып, алар күпләгән мәдәни вазыйфаларны башкаралар. Рухи тормышның бу өлкәсенә кагылышлы булу өчен махсус белем алу мәҗбүри түгел. Рухи мөнәсәбәтләрнең эш, көнкүреш, ял, гаиләдә яки шәхси аралашу культурасы белән бәйле барлык өлкәләре махсуслашмаган эшчәнлек була. Гәрчә фәндә аңа кайчак җәмгыятьнең рухи тормышының «түбән катлавы» дип карасалар да, бу барыннан да бигрәк «югары» (белемле азчылык өчен булдырылган) һәм «түбән» (гади халыкныкы) мәдәниятләрне капма-каршы кую гадәтеннән генәдер.

Бүгенге заманда махсуслашмаган эшчәнлекнең әһәмиятен һич кенә дә төшерергә ярамый, чөнки кешенең рухи мәдәният кыйммәтләре белән очрашуы нәкъ менә шул дәрәҗәдә була.

КЕШЕНЕҢ РУХИ ДӨНЬЯСЫ

Кешенең шәхси тормышында рухи кыйммәтләр юл күрсәтү һәм юнәлеш бирү ролен үтиләр. Алар — диңгездә йөзүчеләргә юл күрсәтүче йолдызлар яки маяклар кебек. Кыйммәт-

ләр аркасында кешеләр әһәмиятлене әһәмиятсездән аера алалар. Фикер йөртү яки бәя бирү сәләтен немец философы И.Кант кешенең иң югары сәләтләренең берсе дип исәпли. Ул, бер яктан, сайлау иреге белән, икенче яктан, максатка юнәлтелгән эшчәнлек һәм шәхеснең *рухи яктан үзен билгеләве* белән бәйле.

Кешеләр «кыйммәтләр» дип алар минутлык шатлык һәм рәхәтлекләрдән өстен күргән, аларның яшәвенә мәгънә биргән нәрсәләрне саныйлар. Америка психологы Э.Фромм, кешеләр яшәү мәгънәсен кыйммәтләр белән чагыштыруда күрәләр, дип яза. Берәүләр өчен төп рухи кыйммәтләр — танып-белү, икенчеләр өчен мәхәббәт, иҗат, дин, ирек, Ватанның имин-бай яшәве өчен кайгырту булырга мөмкин. Әлеге кыйммәтләр хакына кешеләр яшәү кыенлыклары һәм мәхрүмлекләренә түзәргә, аңлы төстә үз-үзләрен чикләүгә яки корбан итүгә сәләтлеләр. Аңлашыла ки, чын, практик тормышта рухи кыйммәтләр абстракт идеяләр рәвешендә түгел, ә конкрет, хисси сизелә торган символлар, мәсәлән, яраткан әдәби геройлар, шигъри юллар яки картиналар, даһи уйлап табулар һәм фәнни ачышлар образларында килеп басалар. Символлар белән аралашып, кешеләр кыйммәтләр белән аралашалар.

Шуның белән бергә, Э.Фромм эгоистлык һәм үз-үзенә соклану, чикләнмәгән байлыкка, данга һәм хакимлеккә омтылу, җимерү теләге, наркотик кәеф күтәренкелеге, расачылык һәм фашизм кебек ялган аңланган бозык кыйммәтләргә — «антикыйммәтләргә» күрсәтә. Алар күп кенә кешеләр баш игән символ — фетишлар белән гәүдәләндерелгән. Әлеге күренешләрнең бүгенге рухи тормышта киң таралуы борчылу тудыра, чөнки алар җәмгыятькә һәм шәхескә җимергеч йогынты ясыйлар.

Рухи кыйммәтләргә мөрәҗәгать итү кешене үз эш-гамәлләрендә мөстәкыйль һәм эзлекле, очраклы бәяләмәләрдән һәм ялгыш фикерләрдән бәйсез итә. Мөгаен, сезгә андый кешеләр белән очрашырга туры килгәндер. Алар күп укып, сәнгать, фән, сәясәт белән мавыгып кына калмыйлар, ә бәлки боларның барысын да кызыксынып, шәхси кабул итәләр. Андый кешеләр турында аларның *рухи дөньялары* бай диләр. Икенче яктан, бернинди рухи кыйммәтләр белән дә аралашмаган кеше бүгенге көн белән генә яши. Аның язмышы очраклыклар һәм төрле фикерләр капризына бәйле, һәм тулаем аның тормышы мәгънәсез булып күренә. Ә сез үзегезнең киләчәк тормышыгызны нәрсәгә багышларга теләвегез турында уйландыгызмы инде? Ул хакта бөтен кеше алдында әйтмәскә дә мөмкин. Әлегә бу сезнең үз серегез булып калсын. Әмма бу хакта уйланырга кирәк, әлбәттә.

Төп төшенчәләр: рухи эшчәнлек, рухи кыйммәтләр, махсуслаштырылган һәм махсуслаштырылмаган рухи эшчәнлек, рухи дөнья, шәхеснең рухи үзбилгеләнүе.

Терминнар: аксиология, кыйммәтләрне «предметлаштыру», кыйммәтләрне «предметлаштырмау», секуляризация, билге, символ.

Үзегезне тикшерегез

1. «Рухи эшчәнлек» төшенчәсенә билгеләмә бирегез. 2. Рухи эшчәнлек һәм рухи кыйммәтләр үзара ничек бәйләнгән? 3. Рухи эшчәнлектә предметлаштыру һәм предметлаштырмау процессларының үзенчәлекләрен ачып бирегез. 4. Рухи кыйммәтләрнең иҗтимагый характеры нәрсәдә ачыла? 5. Рухи кыйммәтләр объектив характерда, дип раслап буламы? Үз нәтиҗәгезне нигезләгез. 6. Кешеләрнең тарихи эшчәнлегенең төп тарихи формаларын санагыз. 7. «Махсуслаштырылган» рухи эшчәнлеккә нәрсәләр кирә? 8. «Махсуслаштырылмаган» иҗтимагый эшчәнлек иҗтимагый тормышның кайсы өлкәләрендә чагыла? 9. Кеше тормышында рухи кыйммәтләрнең роле нинди?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Эшчәнлекнең төп компонентларын белүегезне «рухи эшчәнлек» төшенчәсенә карата кулланыгыз һәм рухи эшчәнлек объекты кем, кем аның субъекты, кешеләрне бу төр эшчәнлеккә нәрсә мәҗбүр итә, аның төп нәтиҗәләре һәм аларга ирешү чаралары нинди — шуларны билгеләгез.

2. XXI гасыр башында «Бүгенге яшьләр кем булырга тиеш?» дигән темага үткәрелгән социологик сорап белешүләр мәгълүматлары буенча түбәндәге җаваплар алынган; җавап бирүчеләрнең 32% ы — бизнесмен, 17% ы — икътисадчы, 13 % ы — банкир, 11% ы — бандит, 5% ы — менеджер, 1% ы космонавт булырга теләгән, 21% ы башка профессия һәм шөгыльләрне әйткән. Ата-аналардан «Балаларыгыз мәсьәләсендә барыннан да бигрәк сезне нәрсә борчый?» дигән темага үткәрелгән сорап белешүләргә җаваплар шуны күрсәтә: 26% — агрессивлык һәм рәхимсезлек, 25% — әхлаксызлыкны; 24% — наркоманияне, 15% — ялкаулыкны. («Аргументы и факты».— 2002.— № 28, 29; «Комсомольская правда».— 2002.— 26 декабря.)

Әлеге мәгълүматлардан чыгып бүгенге яшьләрнең кыйммәти юнәлешләре турында нәтиҗә ясап буламы? Булса, ниндиләрне?

3. Түбәндәге таблицаны анализлагыз. Кешенең социаль хәле (статусы) белән аның мәдәни ихтыяҗлары арасында бәйлелек бармы? Үз нәтиҗәгезне конкретлаштырыгыз.

Ә сезнең мәдәни өстенлекләрегез нинди?

Яшь мәскәүлеләрнең буш вакытларын үткәрүе

Ялны үткәрү формасы	Социаль статус (% ларда)							
	Уртачадан югары		Уртача		Уртачадан түбән		Түбән	
	1999	2001	1999	2001	1999	2001	1999	2001
Телевидение	56,3	71,7	67,7	77,0	70,6	76,4	70,1	74,9
Китап, журнал, газеталар уку	41,2	55,7	44,7	57,6	46,4	56,1	46,5	51,1
Дуслар белән аралашу	43,8	52,4	41,9	45,0	38,5	43,4	33,1	37,3
Радио, музыка	39,6	38,9	32,3	40,5	33,3	33,6	32,4	29,7
Концерт, театр, музейлар	39,6	39,2	28,6	29,1	19,8	18,1	18,1	14,2
Спорт, түгәрәкләр, занятиеләр	31,2	38,6	14,8	24,5	11,8	15,0	14,2	4,4
Хобби, мавыгулар	11,4	16,9	12,1	17,7	14,4	22,1	15,5	21,6

Дәвамы

Ялны үткәрү формасы	Социаль статус (% ларда)							
	Уртачадан югары		Уртача		Уртачадан түбән		Түбән	
	1999	2001	1999	2001	1999	2001	1999	2001
Дискотека, ресторан, төнге клублар	16,7	47,6	15,0	27,6	7,4	10,2	3,9	2,2
Компьютер, Интернет, уеннар	15,6	20,5	10,6	15,2	8,1	8,0	4,5	2,7
Дини чараларда катнашу	2,1	4,8	2,1	5,9	3,2	9,3	3,9	8,7
Иҗтимагый-сәяси эшчәнлек	6,2	3,6	2,0	4,7	1,7	1,7	1,3	3,4

4. Түбәндәге схема рухи эшчәнлек структурасы вариантларының берсе булып хезмәт итә ала.

Сезнеңчә, бүгенге җәмгыятьтә рухи эшчәнлекнең схемадагы ике өлкәсе арасында арадашчы ролен кем үти ала?

Чыганак белән эшләгез

Илебезнең бүгенге тикшеренүчесе Ю.Лотман хезмәтеннән өзек укыгыз.

Мәдәниятнең символик табигате

Социаль аралашу өлкәсенә хезмәт күрсәтүче теләсә кайсы структура — тел ул. Бу исә ул коллектив әгъзаларына таныш кагыйдәләр нигезендә кулланыла торган билгеләр системасын барлыкка китерә дигәнне аңлата. «Билгеләр» дип без *әһәмияткә ия* булган һәм шул рәвешле *мәгънәне тапшыру* чарасы булып хезмәт итүче теләсә нинди матди тәгъбирне (сүзләр, рәсемнәр, әйберләр һ.б.) әйтәбез.

Димәк, мәдәниятнең, беренчедән, коммуникацион һәм, икенчедән, символик табигате бар. Соңгысына тукталыйк. Гади һәм күнегелгән әйбер — икмәк турында уйланыйк. Икмәкне тотып һәм күреп була. Аның авырлыгы һәм формасы бар. Аны кисеп, ашап була. Ашалган икмәк кеше белән физиологик элемтәгә керә. Бу функциясендә аның турында «ул нәрсәне аңлата» дип сорап булмый. Ул аңлатмый, аны кулланып була. «Икмәк безгә көн дә кирәк» дигәндә, «икмәк» сүзе әйберне генә аңлатмый, ул зуррак мәгънә ала: «яшәү өчен кирәкле азык». «Икмәк булса, ач булмассың» дигәндә, безнең алга предметның үзенең дә, аны белдерүче сүзнең дә катлаулы символик мәгънәсе килеп баса.

Кылыч та предмет кына кебек. Әйбер буларак аны ясап һәм сындырып, музей витринасына куеп, аның белән кеше үтереп була. Болар барысы да — аны әйбер буларак куллану: әмма билгә кыстырып яки җилкәгә асып куйсаң, кылыч ирекле кешене символлаштыра һәм «ирек билгесе» була, ул инде символга әверелә һәм мәдәнияткә керә.

XVIII гасырда рус һәм Европа дворяны кылыч йөртми, аның бер ягында шпага асылынып тора (кайчак бөтенләй дә корал булмаган, кечкенә, уенчык диярлек парад шпагасы). Бу очракта шпага — символның символы: ул — кылычны, ә кылыч — өстен катлауга карауны аңлата...

Шпага корал буларак, шпага киемнең бер өлеше буларак, шпага символ, дворянин билгесе буларак — болар барысы да предметның мәдәниятнең гомуми контекстындагы төрле вазыйфалары.

Үзенең барлык гәүдәләнешләрендә символ бер үк вакытта турыдан-туры практик кулланышка яраклы корал булырга да, яисә үз вазыйфасыннан аерылырга да мөмкин. Мәсәлән, кечкенә, парадлар өчен эшләнгән шпага фактта коралны түгел, ә коралның сурәтен белдерә, практик кулланылышын югалта. Парад өлкәсе сугыш өлкәсеннән хисләр, ишарә һәм вазыйфалар теле белән аерыла. Чацкийның: «Үлемгә парадка барган кебек барыйм»,— дигән сүзләрен искә төшерик. Шуның белән бергә, Л.Толстойның «Сугыш һәм тынычлык» романында сугышны сурәтләгәндә без үз солдатларын сугышка кулына парад шпагасы тоткан (ягъни файдасыз шпага) офицерның алып баруы белән очрашабыз. «Сугыш — сугыш уены» икеполюслы хәле корал-символ белән чын корал арасында катлаулы мөнәсәбәтләр тудыра. Шул рәвешле шпага (кылыч) дәвернең символик системасына кертелә һәм аның мәдәният фактына әверелә.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Мәдәният әйберләренең чын вазыйфасы һәм символик мәгънәсе ничек бәйләнгән? 2. Көндәлек тормышта киң кулланылучы, шул ук вакытта символик мәгънәгә ия булган әйберләр мисалларын китерегез.

Бу хакта бәхәсләшәләр

Е.Н.Шапинская, С.Я.Кагарлицкая китабыннан өзек белән танышыгыз.

Икътисади байлык буларак түгел, ә символик «байлык» буларак сәнгать әсәре аны «кабул итү — үзләштерү», ягъни шифрны ачу мөмкинлеге булган кеше өчен генә яши...

Сәнгать әсәренең шифрын ачу акты, аны бердәй «аңлау» бары тик шифрны ахыргача ачып бетерүне мөмкин иткән «мәдәни код» күзәтүче тарафыннан тулысынча үзләштерелгән,

әлеге әсәрне мөмкин иткән мәдәни код белән кушылган очракта гына мөмкин һәм нәтиҗәле. Авторның мәдәни коды кабул итүченең мәдәни кодына туры килергә тиеш. Үзенчәлекле бу шартлар мөмкин булмаса, аңламау килеп туа... Әсәрләрнең кодлаштырылуын һәм ниндидер билгеле код белән кодлаштырылуын танымый торып, без кодны аңсыз рәвештә көндәлек кабул итү, таныш объектларны башка традицияләр шифрын ачу өчен кулланабыз. «Зәвыксызлык» һәм «күрә алмаучылык» бүләк иткән игелек дип саналучы саф караш турындагы мифтан баш тарту мөһим. Җәмгыятьләребездәге укымышлылыгы азрак кайбер укучыларның һәм тамашачыларның чынбарлыкны сурәтләүне таләп итүләренең сәбәпләреннән берсе шуннан гыйбарәт ки, зиһенгә алуның үзенчәлекле категорияләренә ия булмаганлыктан, алар югары дәрәҗәдә мәдәни әсәрләргә карата «көндәлек тирәлектәге объектларны әһәмиятле дип кабул итү»дән башканы куллана алмыйлар. Иң гади күзәтүчегә мөмкин булган һәм аңа «йорт»ны яки «агач»ны тану мөмкинлеге бирүче иң аз һәм турыдан-туры аңлау барыбер дә рәссам белән тамашачы арасында теге яки бу тарихи дәверне чын дип килешүне (әлбәттә инде, аңсыз рәвештә) күздә тота.

§ 19. Хезмәт эшчәнлеге

Исегезгә төшерегез:

кешелек дөньясы тарихында хезмәт нинди роль уйнаган? Хезмәт хокукы мөнәсәбәтләре нидән гыйбарәт? Квалификацияле хезмәт квалификациясездән нәрсәсе белән аерыла? Хезмәткәрнең профессиональлеге нәрсә ул?

Хезмәт эшчәнлеге — күпкырлы күренеш. Хезмәтнең төрле якларын берничә иҗтимагый фән өйрәнә.

Икътисад фәне күзлегеннән хезмәт табигать биргән нәрсәләрне куллану әйберләренә әверелдерү максатында планлы, аңлы эшчәнлек буларак карала. Икътисад хезмәтне җитештерү факторларының берсе буларак өйрәнә, икътисад законнарының хезмәт өлкәсендә эш итү механизмын, җитештерү циклының барлык стадияләрендәге хезмәт чыгымнарын, хезмәткә түләүнең аның нәтиҗәләре белән нисбәтен тикшерә. *Психология* хезмәткәрнең психикасын, хезмәткәрләрнең аерым шәхси сыйфатларын, эшкә мөнәсәбәтләрен һәм үз-үзләрен тоту сәбәпләрен, хезмәт эшчәнлегенең төрле төрләренең психо-физиологик үзенчәлекләрен өйрәнә. *Хокук белеме галимнәре* хезмәткәр-

ләрнең хокукый хәле, хезмәткәрләр белән эш бирүчеләр арасындагы хезмәт мөнәсәбәтләре, хезмәтне саклауны юридик яктан әзерләү белән бәйле проблемаларны өйрәнәләр. *Социология* хезмәт эшчәнлеген җитештерү оешмаларында берләшкән кешеләр тарафыннан башкарыла торган эш һәм вазыйфаларның вакыт һәм киңлектә чагыштырмача катгый теркәлгән максатка ярашлы рәте итеп карый. Социология социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре структурасын һәм механизмын, шулай ук хезмәт өлкәсендәге социаль процессларны тикшерә. *Философия* хезмәтне кешеләр тарафыннан яшәү өчен шартлар һәм средстволар тудыру процессы итеп карый, анда кеше көче, осталыгы һәм белеме гәүдәләнеш таба. Философия өчен үзен хезмәттә тапкан кешенең бу процесста ничек чагылуын билгеләү мөһим.

Хезмәтне өйрәнүче фәннәр күп очракта тыгыз бәйләнә, еш кына кисешәләр. Хезмәт кебек күренеш турында һәрьяклы белемне төрле фәннәр көчләре берләшкән комплекслы тикшеренүләр генә бирә ала. Бу параграфның эчтәлеге иҗтимагый фәннәрнең (күбрәк — социологиянең) хезмәт эшчәнлеген тикшерүләренең кайбер нәтиҗәләрен берләштерә.

КЕШЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТӨРЕ БУЛАРАК ХЕЗМӘТ

Кешеләрнең ихтыяҗлары һәм мәнфәгатьләре хезмәт эшчәнлегенең максатын билгеләүче нигез булып тора. Чын мәгънәсендә хезмәт кеше эшчәнлеге аңлы булганда, анда аңлы рәвештә куелган максат — кешеләрнең яшәве өчен кирәкле матди һәм рухи кыйммәтләр булдыру максаты гамәлгә ашырылганда барлыкка килә. Бу яктан хезмәт эшчәнлеге белем алуга һәм осталыкка ирешүгә юнәлдерелгән уку эшчәнлегеннән һәм нәтиҗәсеннән бигрәк уйнау үзе мөһим булган уен эшчәнлегеннән аерылып тора.

Социологлар хезмәт эшчәнлеген, ысул, чара һәм нәтиҗәләрдән бәйсез рәвештә, *гомуми сыйфатлар* белән характерлыйлар.

Беренчедән — билгеле эш урыннарында башкару өчен билгеләнгән *эш төрләре җыелмасы* белән. Хезмәт эшчәнлегенең һәр конкрет төрендә төрле эш алымнары, хәрәкәтләре башкарыла. (Сезгә хезмәтнең нинди төрләре билгеле? Аларда нинди хәрәкәтләр һәм алымнар кулланыла?) Эш процессы эчтәлегенә яңа техника һәм заманча технологияләр кертү нәтиҗәсендә физик һәм акыл, бертөсле (монотонлы) һәм иҗади, кул һәм механикалаштырылган һ.б. хезмәт арасында нисбәт үзгәрә.

Икенчедән, хезмәт эшчәнлеге профессиональ, квалификацияле һәм вазыйфаи характеристикаларда теркәлгән *хезмәт эшчәнлеге субъектларының тиешле сыйфатлары* җыелмасы

белән характерлана. Шунысын исегезгә төшерик: квалификацияне профессионализмга тиңләргә ярамый. Ул — нәтиҗәле хезмәтнең кирәкле, әмма җитәрлек булмаган шарты. Профессионал булу өчен кеше тәҗрибә тупларга, аңа үз бурычын аңлау, үздисциплина, эшлекле намуслылык, җаваплылык хас булырга тиеш.

Өченчедән, хезмәт эшчәнлеге *хезмәтнең матди-техник шартлары* белән характерлана. Хезмәт эшчәнлегендә, һәрбер эшчәнлек төрендәге кебек, максатка ирешү өчен төрле средстволар кулланыла. Алар — барыннан да элек, җитештерү өчен кирәкле төрле техник җайланмалар, энергетика һәм транспорт линияләре, эш процессы алардан башка була алмый торган башка матди объектлар. Алар барысы бергә *хезмәт средстволарын* тәшкил итә. Җитештерү процессында *хезмәт предметына*, ягъни үзгәртеләчәк материалларга йогынты ясала. Моның өчен *технологияләр* дип аталган төрле алымнар кулланыла. Мәсәлән, заготовкадан артык металлны алу өчен металлны кисүче җиһаз кулланып була. Әмма электр импульслы ысул куллану шул ук нәтиҗәгә ун тапкыр тизрәк ирешү мөмкинлеге бирә. Бу — *хезмәт җитештерүчәнлеге* ун тапкыр арта дигән сүз. (Уйлагыз: хезмәт җитештерүчәнлеге нәрсәгә бәйле һәм ул һәрвакытта да кеше теләгәнә генә карыймы?)

Предприятиеләрнең хәзерге техник базасы төрле типтагы хезмәт средстволарының катлаулы кушылмасыннан тора, шунлыктан хезмәтне техника белән тәэмин итү дәрәҗәсе шактый аерымлана, бу исә аның шактый төрлеләнүенә китерә. Эшләүчеләрнең күбесе бер төрле, иҗади булмаган эш белән мәшгуль. Шул ук вакытта күпләр актив акыл эшчәнлеген, катлаулы производство бурычларын хәл итүне таләп итүче эш башкара.

Дүртенчедән, хезмәт эшчәнлеге хезмәт субъектларының аларны башкару чаралары һәм шартларының оештыру-технологик һәм икътисади бәйләнеше ысулы белән характерлана. Хезмәт эшчәнлегенең мөһим үзенчәлеге шунда: ул, кагыйдә буларак, куелган максатларга ирешү өчен *уртак тырышлык* таләп итә. Ләкин коллектив эшчәнлеге ниңди дә булса продукт җитештерүче коллективтагы барлык әгъзаларның да бер үк эшне эшләвен аңлатмый. Киресенчә, *хезмәтне* бүлү зарурлыгы туа, шуның аша аның нәтиҗәлелеге арта.

Аңлашыла ки, югары дәрәҗәдә мөстәкыйльлек һәм кабул иткән карарлары өчен матди җаваплылыгы белән характерлана торган эшмәкәр хезмәте килешү шартлары буенча производство белән идарә итүчеләрнең кушканнарын үтәргә тиешле ялланган эшче хезмәтеннән аерыла. (Моннан чыгып, уйлагыз: шәхси хезмәт эшчәнлеге нәрсә белән характерлана?)

2001 елда Россиядә ялланып эшләүчеләр барлык эшләүчеләрнең 93% ын, эш бирүчеләр — 1,4% ын, шәхси хезмәт эшчәнлеге белән шөгыльләнүчеләр 5% ын тәшкил иткән.

Бишенчедән, хезмәт эшчәнлеге эш процессын оештыру һәм идарә итүнең структурасы, анда катнашучыларның үз-үзләрен тотуын билгеләүче нормалар һәм алгоритмнар белән характерлана. Аерым алганда, *дисциплина* төшенчәсе бик мөһим. Нормаль хезмәт эшчәнлеге һәр хезмәткәрнең коллективта аның барлык әгъзалары өчен мәҗбүри булган кагыйдәләрне һәм тәртипләрне ирекле, аңлы рәвештә үтәвеннән башка мөмкин түгел. Хезмәт турында законнар, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре эш вакытын җитештерүчән файдалануны, үз вазыйфаларыңны намуслы үтәүне, эшнең югары сыйфатын таләп итәләр. Бу таләпләрне үтәү — *хезмәт дисциплинасы* ул.

Бүгенге производство җитештерүнең максатына ирешүне, ягъни тиешле сыйфат күрсәткечләре булган продукт алуны тәэмин итүче билгеле бер технологик режимны үтәүне (материалны эшкәртү ысулларын, тизлекне, температураны, басымны һ.б.) таләп итә. Һәркем белә: мәсәлән, плитәдәге утның көчен көйләмәсәң, табадагы әйбер янарга мөмкин. Технология нормаларын катгый үтәү *технология дисциплинасы* дип атала.

Предприятиеләр, мәсәлән, продукт җитештерү өчен чимал, ярымфабрикатлар, детальләр бирүне күздә тоткан үзара шартнамә төзесәләр, шартнамә шартларын катгый үтәү *шартнамәле дисциплина* дип атала. Аны үтәмәү предприятиенең эш ритмын, куплаган кешеләрнең көйләнгән производство эшчәнлеген боза.

Кагыйдәләрне, норма, шартнамәләрне, производство җитәкчеләренең әмерләрен, күрсәтмәләрен үтәүне «башкаручанлык» дип тә атыйлар. Әмма башкаручанлык инициативадан башка була алмый. Чынлап та, күрсәтмә алгач, кеше аны ничек итеп яхшырак үтәү турында уйларга тиеш. Кагыйдә, приказ, инструкцияләрдә эш процессында барлыкка килүче барча хәлләрне дә алдан күреп булмый. Хезмәткәр конкрет шартларда үзенә бирелгән күрсәтмәне сыйфатлы һәм вакытында башкаруны тәэмин итүче әйбәт чишелеш табарга тиеш. *Инициатива* һәм *башкаручанлык* үзара бәйләнгән. Уйламыйча башкаручы — начар хезмәткәр. Киресенчә, инициатива — югары профессионализм дәлиле.

Социологиядә хезмәт «хезмәтнең эчтәлеге» һәм «хезмәтнең характеры» төшенчәләрен файдаланып карала. *Хезмәт эчтә-*

леге теге яки бу хезмәт төренең хезмәткәр башкарган эш-хәрәкәтләр җыелмасына, аларның үзара мөнәсәбәте һәм үзара бәйләнешенә, хезмәт предметы һәм хезмәт средстволары белән бәйле үзенчәлекләренә; башкару һәм идарә итү функцияләре нисбәтенә, шулай ук җиһазларга контрольлек итү, күзәтү һәм мәҗбүр итү функцияләренә; эшләрнең алдан билгеләнеп куелуына, мөстәкыйльлеккә, иҗади мөмкинлекләр дәрәҗәсенә һ.б. бәйле. Кирәкле операцияләрнең составын һәм хезмәт функцияләренең нисбәтен үзгәртү хезмәтнең эчтәлеген үзгәртүне аңлата. Мондый үзгәрешнең төп факторы — фәнни-техник алгарыш.

Бүгенге технологик процесслар хезмәтне мөмкин кадәр интеллектуальләштерүне (АЭС операторы яки заманча лайнер очучысы хезмәтен күз алдыгызга китерегез), аны шәхес аерым операцияләрне гади башкаручы хәленә калмаслык итеп оештыруны күздә тоталар. Башкача әйткәндә, сүз хезмәтнең эчтәлеген фәнни-техник прогрессның бүгенге этабында тагын да күптөрлерәк, тагын да иҗадирак итү турында бара.

Хезмәт характеры эш процессында катнашучы хезмәткәрләрнең эшкә мөнәсәбәтен һәм аның җитештерүчәнлегенә йогынты ясаучы мөнәсәбәтләре күрсәтә.

Эш шартлары зур әһәмияткә ия. Аларга эш предметлары һәм средстволарының куркынычлык яки куркынычсызлык дәрәҗәсе, аларның кешенең сәламәтлегенә, кәефенә һәм эшкә сәләтенә тәэсире керә. Физик (тавыш, вибрация, температураның күтәрелүе яки төшүе, ионлаштыручы яки башка нурланышлар), химик (газлар, парлар, аэрозольләр), биологик (вируслар, бактерияләр, гөмбәчекләр) факторлар потенциаль куркыныч булып тора.

Аеруча зарарлы, экстремаль эш шартлары (мәсәлән, шахтада күмер чыгару) авыр профессиональ авырулар, җитди җәрәхәтләр, зур аварияләр китереп чыгарырга, кешенең үлеменә китерергә мөмкин.

Хезмәт культурасы зур роль уйный. Тикшеренүчеләр анда өч нәрсәне аерып күрсәтә. Беренчедән, бу — хезмәт мохитен, ягъни эш процессы бара торган шартларны камилләштерү. Икенчедән, — эштә катнашучылар арасындагы үзара мөнәсәбәтләр культурасы, хезмәт коллективындагы әхлакый-психологик климат. Өченчедән, хезмәт эшчәнлегендә катнашучыларның эш процессының эчтәлеген, аның үзенчәлекләрен аңлавы, шулай ук анда салынган инженерлык фикерен иҗади гәүдәләндерү.

Хезмәт эшчәнлеге — теләсә кайсы кеше тормышында аның үзен табуы-танытуы өчен бик тә мөһим кыр. Нәкъ менә шунда

кешенең сәләтләре ачыла һәм камилләшә, нәкъ менә шушы өлкәдә ул үзен шәхес буларак раслый ала.

ҖИТЕШТЕРҮДӘ КЕШЕ ФАКТОРЫ

Кеше факторы — хезмәткәр сыйфатларының барлык җыелмасының (квалификациясе, үз-үзен тоту сәбәпләре, мәнфәгатьләре, аңы, мәдәнияте һ.б.) иң киң атамасы. Ул техник һәм икътисади факторлар белән чагыштырып кулланыла, «Персонал», «эшче көче», «хезмәткәр» төшенчәләренә якын.

Фәнни-техник прогресс кешенең (хезмәт субъектының) җитештерү процессындагы хәлен нык үзгәртә: ул турыдан-туры әзер продукт булдыру процессыннан читкә чыга, аның янәшәсенә баса һәм аңа карата контролер, көйләүче, төзәтүче ролен үти. Аннан элегрәк кеше машинага башкару (хезмәт предметына инструмент ярдәмендә йогынты ясау), аннары хәрәкәт итү, энергетика вазыйфасы биргән. Хәзер, кешенең җитештерүдә турыдан-туры катнашуы кимегәч, хезмәтнең тагын да югарырак дәрәҗәдәге контроль-идарә итү һәм логик вазыйфаларын башкару, җаваплы карарлар кабул итү белән бәйле, турыдан-туры булмаган төрләре арта.

Фән-техника прогрессы кешенең җитештерү процессындагы ролен үзгәртә, аның хезмәт эшчәнлегенең эчтәлегенә йогынты ясый.

Физик һәм акыл хезмәте, физик һәм интеллектуаль сәләтләр **арасындагы нисбәт сизелерлек үзгәрә**. Әгәр элек эшче хезмәт процессы вакытында күпчелек физик сәләтләрен (чыдамлык, мускул көче, профессиональ күнегү) кулланса, логик операцияләр кулланучы машиналар булдыру, математик исәпләүләр һ.б. беренче планга кешенең хәлне анализлый белү, мәгълүматларны чагыштыру, максатлар кую һ.б. кебек сәләтләрен чыгара. Акыл һәм физик хезмәт арасында төгәл чик кую читен. Компьютерны ремонтлау кул хезмәте (физик) белән дә, акыл хезмәте белән дә бәйле. Ә менә, әйтик, хирург эшчәнлегендә хезмәтнең ике төрен аерып буламы?

Ләкин бездә дә, бөтен дөньяда да фәнни-техник революция хезмәтнең акыл вазыйфаларын арттыра. Өстәвенә иҗади башлангыч — хәлгә бәя бирү һәм мөстәкыйль карарлар кабул итү сәләте үсә.

Өр-яңа техника һәм технологияләр кешенең сәләтләре үсүен стимуллаштыра, шул ук вакытта хезмәткәр шәхесенә югары таләпләр дә куя. Станокта эшләүченең хатасы бозылган бер деталь булса, автомат линия операторының хатасы йөзләрчә детальне бракка чыгаруы мөмкин. АЭС операторының яки

авиалайнер очучысының хатасы бик тә авыр нәтиҗәләргә китерүе ихтимал. Бер караганда, монда эш приборларны күзәтүдән һәм төймәләргә басудан гына гыйбарәт кебек, ә чынлыкта исә эмоциональ киеренкелек, психик басым, шәхеснең җаваплылыгы, үздисциплинасы, үзконтроле кебек әхлак сыйфатларының роле арта.

Шулай итеп, җитештерүнең техник факторы үзгәрү белән бергә, кеше факторының әһәмияте дә шактый арта. Моны кеше кушылачак бик тә катлаулы инженерлык системаларын эшләүчеләр исәпкә алырга тиешләр. Кешенең үзен тотышы социотехник системаларда тәвәкәллек факторы булу ихтималын күздә тотып, алдан күрелмәгән хәлләрдә хезмәткәрнең ышанычлылыгын арттырырга кирәк.

Тикшеренүчеләр югары технологияле җиһазлар белән эш итүче бүгенге заман профессияләренә яңа квалификацияле таләпләргә куялар. Алар арасында түбәндәгеләр бар:

— абстракт фикер йөртү сәләте һәм информатика теленнән иркен файдалана белү;

— статистик һәм географик мәгълүматны анализлый белү, җитештерүдәге теләсә нинди үзгәрешләрне оста һәм тиз тотып алып, логик фикерләү;

— кайбер гомуми урта белем предметларын (математиканы, физиканы, программлаштыруны) урта мәктәп дәрәҗәсеннән югарырак күләмдә белү.

Хезмәт эшчәнлегендә мәгълүмати компонент кеше эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә иске мәгълүматның һаман саен тизрәк «картаюы» белән бәйле рәвештә дә үсә. Моннан хезмәткәргә үзенең бөтен хезмәт гомерендә туктаусыз рәвештә белемнәрен яңарту һәм арттыру таләбе килеп туа.

Бүгенге дөньяда кеше факторы сыйфатлары җәмгыять тормышындагы шактый үзгәрешләр (барыннан да элек мәдәни-техник базаның яңаруы, ә безнең илдә әле тагын базар икътисадына күчү белән бәйле рәвештә), шулай ук аның үзенең (белемнәрнең, гомуми культурасының, тормыш сыйфатының үсүе) йогынтысы астында үзгәрәләр.

Шунысын әйтик, фәндә «кеше факторы» төшенчәсенең чикләнгәнлеге билгеләп үтелә. Кешене бары тик җитештерү факторы итеп кенә карарга ярамый. Кеше, аның һәрьяклы үсүе — үзмаксат ул; аның тормышы, хокуклары һәм иреге — иң югары кыйммәт.

СОЦИАЛЬ ПАРТНЕРЛЫК

Хезмәт эшчәнлеге вакытында бер яктан — хезмәткәрләр, икенче яктан эш бирүчеләр (предприятие, оешмалар җитәк-

чeләре яки аларның вәкилләре) белән социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килә. Яклар арасында килеп туган каршылыклар көч ысуллары белән (забастовка һәм локаутлар аша) чишелсә, алар капма-каршы тору характеры алырга мөмкин. Ләкин узган гасырның икенче яртысында дөнья тәҗрибәсе мөнәсәбәтләрнең башка бер моделен — социаль партнерлыкны күрсәтте. XX гасырның 90 нчы елларында бу модель Россиядә дә танылу алды.

Киң мәгънәдә социаль партнерлык ул — социаль төркемнәр, катлаулар, сыйныфлар, аларның иҗтимагый берләшмәләре, хакимият органнары һәм бизнес арасындагы иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең билгеле бер тибы, аның нигезен социаль-икътисади һәм сәяси үсешнең мөһим юнәлешләре буенча килешүгә ирешү тәшкил итә. Таррак мәгънәдә ул — дәүләт хакимияте органнары, хезмәт ияләре вәкилләре һәм эш бирүчеләр, эшмәкәрләр арасындагы тигез хокуклы хезмәттәшлеккә нигезләнгән үзара мөнәсәбәтләр системасы. Бу параграфта сүз хезмәт турында барганлыктан, социаль партнерлыкны без аның икенче мәгънәсендә карарбыз.

Белгәнегезчә, ялланган хезмәткәрләр һәм эш бирүчеләр мәнфәгатьләре күп яктан туры килми. Алар арасында хезмәт эшчәнлегенең кайчак теләсә нинди мәсьәләсенә: аны нормалаштыруга һәм түләүгә, эш вакытына һәм хезмәтне саклауга, социаль гарантияләргә һәм берләшүгә хокукка кагылырга мөмкин булган конфликтлар тудыручы каршылыклар барлыкка килә. Социаль партнерлык механизмы бәхәсле мәсьәләләрне капма-каршы тору нигезендә түгел, ә сөйләшүләр, мәнфәгатьләрне килештерү юлы белән, акыллы уртак тел табу нигезендә хәл итү мөмкинлеге бирә.

Социологлар социаль партнерлыкның түбәндәге аерым сыйфатларын күрсәтәләр:

— ялланган хезмәткәрләрнең (профсоюзларны да кертеп) төрле оештыру формаларында предприятие белән идарә итүдә катнашуы;

— яклар (хезмәт мөнәсәбәтләре субъектлары) арасында барлыкка килгән каршылыкларны җайга салуның сөйләшүләр юлы;

— партнерларның мәнфәгатьләрен төрле дәрәҗәләрдә килештерү механизмнары һәм хокук институтлары булу;

— партнерлар арасында (социаль гаделлекнең төп критерийларын һәм күрсәткечләрен) хезмәт мөнәсәбәтләре субъектларын яклау чараларын да кертеп, керемнәрне бүлүне һәм тулаем социаль-икътисади сәясәтне югары (гомуммилли) дәрәҗәдә килештерү;

— забастовка һәм локаутлар формасындагы хезмәт конфликтларын киметү һәм йомшарту.

Россиядә хезмәт өлкәсендә социаль партнерлык хәзерге вакытта РФ Хезмәт кодексы, РФ нең «Профсоюзлар, аларның хокуклары һәм эшчәнлекләре гарантияләре турында»гы (1996), «Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча Россиянең өч яклы комиссиясе турында»гы (1999) кануннары белән җайга салына.

2000 елда социаль партнерлыкның өстенлекләре билгеләнүче Генераль килешүләрне төзүдә һәм гамәлгә кертүдә 30 профсоюз, 30 эш бирүчеләр берләшмәсе вәкилләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 30 вәкиле катнашты.

Социаль партнерлыкның берничә формасы бар. Аларның берсе — коллектив шартнамәләр проектлары әзерләү һәм аларны төзү буенча *коллектив сөйләшүләр.* Андый шартнамәләр — оешмаларда социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салучы хокук актлары. Аларны хезмәткәрләр һәм эш бирүчеләр исеменнән аларның вәкилләре әзерли һәм төзи. Шартнамәгә якларның түбәндәге мәсьәләләр буенча үзара йөкләмәләре кертелергә мөмкин: хезмәткә түләү формалары, системасы һәм күләме; эш вакыты һәм ял вакыты; хезмәткәрләрнең эш шартлары һәм аларны саклауны яхшырту; производствода экология иминлеге, хезмәткәрләрнең сәламәтлеген саклау; укып эшләүче хезмәткәрләргә гарантияләр һәм ташламалар һ.б.

Социаль партнерлык формаларына хезмәткәрләрнең, аларның вәкилләренең оешма белән идарә итүдә катнашуы да керә. Андый катнашу формалары арасында: эш бирүчедән хезмәткәрләр мәнфәгатьләренә турыдан-туры кагыла торган мәсьәләләр буенча мәгълүмат алу; эш бирүче белән оешманың эше турындагы мәсьәләләрне тикшерү, аны камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертү; коллектив шартнамәләр эшләүдә, кабул итүдә катнашу һ.б.

Хезмәткәрләр вәкилләренең шәхси хезмәт бәхәсләрен судка кадәрге хәл итүдә катнашулары да социаль партнерлык формасы булып тора. Шул максатта хезмәткәрләр һәм эш бирүчеләр вәкилләреннән комиссияләр төзелә.

Россиядә социаль партнерлык урнашу процессын анализлап, экспертлар, ул тигез генә бармады, дип билгеләп үттеләр. Бу юлдагы кыенлыклар халыкның төрле төркемнәренең керемнәрендәге артык зур аерма, социаль партнерлык идеяләрен кабул итүгә социаль-психологик яктан әзер булмау, гражданлык

җәмгыятенең җитәрлек үсмәве, бизнес вәкилләренең бер өлешенең цивилизацияле «уен кагыйдәләрен» сакламавы, профсоюзларның таркаулыгы, хакимият системасының камил булмавы белән аңлатыла. Ә югыйсә үзара килешеп эшләү, төрле социаль төркемнәрнең мәнфәгатьләрен саклау икътисадны үстерүнең, гражданлык җәмгыяте булдыруның, көчле дәүләт төзүнең кирәкле шартлары булып тора. Атап үтелгән барлык бурычларның үзара бәйләнеше безнең илдә социаль партнерлыкны үстерү перспективасын билгели.

Төп төшенчәләр: хезмәт, хезмәт социологиясе, социаль партнерлык.

Терминнар: хезмәтнең эчтәлеге, эш шартлары, хезмәт дисциплинасы, эш культурасы, җитештерүнең кеше факторы.

Үзегезне тикшерегез

1. Социология хезмәтнең кайсы якларын тикшерә? 2. «Хезмәт культурасы» төшенчәсенә нәрсәләр керә? 3. Бүгенге шартларда җитештерүнең кеше факторына таләпләр ни өчен үзгәрә? 4. Социаль партнерлык нәрсә ул? 5. Россиядә социаль партнерлык ничек урнаша?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Сезгә кайсы профессия яхшырак таныш? Әлеге профессиональ хезмәтне анализлагыз: аның максатын, кулланыла торган техник средстволарны, хезмәт эшчәнлеге ысулларын (технологияне), хезмәт операцияләре һәм алынмаларын билгеләгез. Кибеттә сатучы һәм автобус йөртүче эшчәнлеген чагыштырыгыз.

2. Немец шагыйре һәм галиме И.В.Гете болай дип язган: «Һәр тормышка, һәр эшчәнлеккә, һәр сәнгатькә билгеле бер специальләшү нәтиҗәсендә генә үзләштереп булган һөнәр элгәр булырга тиеш. Нинди дә булса бер предмет өлкәсендә тулы белем, тулы осталык алу йөзләрчә төрле предметларны ярымйорты үзләштерүгә караганда күбрәк белем бирә». Мондый раслау белән килешәсезме? Үз җавабыгызны дәлилләгез.

3. Дөньяның мәгълүмати җәмгыятькә аяк баскан, алга киткән илләрендә XX гасырның 90 нчы елларында эшчәнлекләрендә мәгълүмати компонентлар шактый булган хезмәткәрләр категориясе халык хуҗалыгында эшләүчеләрнең 40% тан 50% ына кадәрен тәшкил иткән. Теге яки бу дәрәҗәдә иҗади хезмәт таләп иткән профессияләр белән бергә аларның гомуми күләме барлык эшләүчеләрнең 70–80% ына җиткән. Әлеге мәгълүматлардан нәтиҗә ясагыз.

4. Көнбатыш илләре әдәбиятында җитештерүне мәгълү-

матлаштыруның тискәре нәтиҗәләре турындагы фаразлар да барлыкка килде. Алар арасында: күпләгән профессияләрнең юкка чыгуы, квалификация киму, хезмәтнең кешелексезләнүе, хезмәт ияләренең тизрәк эшләвен таләп итү, стресслар. Мәктәптә һәм башка чыганаклардан алган белемнәрегезгә таянып, әлеге фаразларга үз мөнәсәбәтегезне белдерегез.

5. Социаль партнерлык идеясе сыйнфый көрәш теориясенә каршы тору буларак туды. Тикшерегез: бүгенге шартларда иҗтимагый мөнәсәбәтләргә карата мондый ике төрле якын килүнең кайсысы җәмгыять, дәүләт һәм төрле социаль төркемнәр мәнфәгатьләренә яхшырак туры килә?

Чыганак белән эшләгез

А.И.Кравченконың «Социология: белешмә әсбап» дигән китабыннан өзек белән танышыгыз.

Социология — хезмәттән канәгатьләнү алу турында

Кешеләр үз хезмәтләренә карата төрле мөнәсәбәттә булалар. Берәүләр үзләрен артык эш белән интектермиләр, аңа җиңел генә карыйлар. Икенчеләр эштә «яна». Өйгә кайткач та алар көн буена эшләп бетерә алмаган нәрсәләре турында уйлыйлар. Икенчеләр эшкә бирелгән, беренчеләре аңа салкын карый. Нәкъ менә эштә «янган» кешеләр өчен хезмәт төп яшәү мәнфәгате булып әверелә.

«Төп яшәү мәнфәгате» төшенчәсен 1956 елда индустриаль социология өлкәсендә белгеч Роберт Дабин кертә. Идея шулкадәр уңышлы була ки, аның нигезендә тулы бер концепция барлыкка килә. Ул түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә ала:

1. Эшләүче шәхеснең тормыш үзәге — аның эше; эшендә булган бар нәрсә аның тормышындагы теләсә кайсы башка ягына кагыла.

2. Нәрсә белән генә шөгыльләнсәләр дә, кешеләр һәрвакыт канәгатьләнү алырга тырышалар; эш канәгатьлек хисе тудырмаса, аны алыштыралар.

3. Кешеләр фәкать канәгатьлек алу өчен генә эшлиләр, башка берни өчен дә түгел.

4. Канәгатьлек алган хезмәткәрләр күбрәк нәтиҗә бирә; киресенчә, эшеннән канәгатьләнү алмаган кеше азрак нәтиҗәле.

6. Канәгатьлек алган кеше эшендә дә, аннан тыш та ныграк тупланган була.

7. Канәгатьлек алган кеше күңел кайту, курку, төшенкелек, гаепле сизү, үч алу, әшәкелек һәм көнләү кебек тискәре хисләрне белми.

8. Канәгатьлек алу бәхеткә тиң; шуңа күрә барлык тырышлыклар эшченең үз эше өлкәсендә яшәвен мөмкин кадәр бәхетлерәк итүгә юнәлдерелергә тиеш.

Психологлар һәм социологлар эштән канәгатьләнү алу чынлыкта кешеләр аңа биргән әһәмияткә үк ия түгел дип исәпли. Хезмәт кеше тормышы аспектларының берсе генә, аның бөтен яшәешенең бердәнбер максаты, акланучы түгел. Әмма бу кеше эшен югалтканга кадәр генә дөрес. Бу мизгелдә без хезмәтнең кеше аннан башка яши алмый торган нәрсә икәнен аңлыйбыз... Әгәр эштән башка кешенең яшәү мәгънәсе бетә икән, димәк, хезмәт тормышның беренче ихтыяҗы, ягъни төп тормыш мәнфәгате булып әверелә.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Эштән канәгатьлек алу эшкә мөнәсәбәт булдыруда нинди урын алып тора? Канәгатьләнү алган кешенең хезмәте ни өчен нәтиҗәлерәк? 2. Сезгә эшкә бирелгән һәм аннан читләшкән кешеләр белән аралашырга туры килдеме? Тегеләре дә, болары да үзләренең эшкә мөнәсәбәтләрен ничек аңлаталар? Эштә «янучы» кешеләрнең аңлатуы документта бирелгән характеристикага туры киләме? 3. Сез бу тексттагы йомгаклау раславы белән килешәсезме? Аңа карата мөнәсәбәтегезне дәлилләгез.

§ 20. Сәяси эшчәнлек

Исегезгә төшерегез:

сәясәт даирәсе нәрсә ул? «Хакимият» төшенчәсенең мәгънәсе нидән гыйбарәт?

Сәясәт фәнендә — политологиядә — сәясәтне аңлауга төрлечә якын киләләр. *Аларның берсе* сәясәтне җәмгыять тормышының төп дүрт өлкәсенең берсе итеп караудан гыйбарәт. Сәясәт өлкәсенә сәяси аң да, сәяси оешмалар да (хөкүмәт, парламент, партияләр һ.б.), хөкүмәтне файдаланып, төрле социаль төркемнәр чишәргә тырышкан бурычлар да, җәмгыятьтә тотрыклылыкны саклау чараларын һәм реформаларны кертеп, конфликтлар һәм хезмәттәшлек аша бара торган сәяси процесслар да керә. Сәяси өлкәне характерлау белән сез төп мәктәпнең җәмгыять белеме курсында таныштыгыз. *Икенче якын килү* сәясәтне шәхесләр, кече төркемнәр һәм зур бергәлекләр арасындагы социаль мөнәсәбәтләрнең, ягъни хакимият, дәүләт, җәмгыять эшләрен идарә итү белән бәйле мөнәсәбәтләрнең аерым тибы буларак аңлауга нигезләнгән. (Бу материалны сез 11 нче сыйныфта өйрәнерсез.) Ниһаять, *өченче*

якын килү сәясәтне эшчәнлек төрләренең берсе, ягъни аның субъектларының — сәяси тормышта катнашучыларның активлыгы буларак караудан тора.

Барлык өч төрле якын килү бер объект — сәясәт турында күпләгән күзаллаулар бирә. Ә бу параграфта сәясәт өченче якын килү яктылыгында карала.

СӘЯСӘТ ЭШЧӘНЛЕК БУЛАРАК

Фән сәяси эшчәнлекнең төрле билгеләмәләрен тәкъдим итә. Шуларның икесен китерәбез.

1. Сәясәт — дәүләт органнарының, сәяси партияләрнең, иҗтимагый хәрәкәтләрнең зур социаль төркемнәр, барыннан да бигрәк сыйныфлар, милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләр өлкәсендәге сәяси хакимиятне ныгыту яисә аны үзенчәлекле ысуллар белән яулап алу максатында аларның тырышлыкларын берләштерүгә юнәлдерелгән эшчәнлеге ул.

2. Сәясәт — социаль төркемнәрнең, партияләр, хәрәкәтләр, аерым шәхесләрнең җәмгыять һәм дәүләт эшләрендә, алар белән җитәкчелек итүдә яки бу җитәкчелеккә йогынты ясауда катнашулары белән бәйле эшчәнлекләренең аерым бер төре ул.

Бу билгеләмәләр турында уйланыгыз, аларны чагыштырыгыз. Аларда сез, беренчедән, сәясәтнең эшлекле характерын, икенчедән, бу эшчәнлектә социаль төркемнәрнең, шулай ук партияләр һәм дәүләтләрнең аерым ролен, өченчедән, аларның эшчәнлегенең дәүләт хакимиятен яулап алу, тоту һәм файдалану белән бәйлелеген күрерсез.

Сәяси эшчәнлеккә дәүләт белән идарә итү, ягъни җәмгыятькә, социаль үсешнең теге яки бу ягына хакимият таләпләренең закон һәм дәүләтнең махсус, шул исәптән көч учреждениеләре (полиция, армия, дәүләт иминлеге органнары) көченә таянып йогынты ясавы керә. Ул шулай ук сәяси партияләрнең иҗтимагый процесслар агышына һәм дәүләт карарлары кабул итүгә йогынтысын да колачлый. Партияләр яки башка сәяси берләшмәләр, бер яктан, төрле социаль төркемнәр белән бәйләнгәннәр, аларның булышлыгына таяналар, икенче яктан, әлеге төркемнәрнең мәнфәгатьләрен һәм омтылышларын чагылдыралар, хөкүмәткә басым ясыйлар яки дәүләт карарларын эшләүдә катнашалар.

Сәяси эшчәнлек киң халык массаларының җәмгыятьнең сәяси тормышында катнашуында да чагыла. Сәяси эшчәнлек вакытында анда катнашучылар үзара үзенчәлекле мөнәсәбәтләргә керә. Моның хезмәттәшлек тә, берләшү, бер-берсен яклау, каршы тору, конфликт, көрәш тә булуы мөмкин.

Сәясәт *субъектлары*: беренчедән, социаль төркемнәр һәм катлаулар, сыйныфлар, милләтләр, сословиеләр һ.б. кергән зур социаль бергәлекләр; икенчедән, сәяси оешмалар һәм берләшмәләр (дәүләтләр, партияләр, массакүләм хәрәкәтләр); өченчедән, сәяси элиталар — үз кулларында хакимиятне туплаган чагыштырмача кечерәк төркемнәр; дүртенчедән, шәхесләр, беренче чиратта — сәяси лидерлар.

Сәясәт *объектлары* турындагы мәсьәләгә мөрәҗәгать итик. Белгәнегезчә, эчке сәясәт һәм тышкы сәясәт була. Аларның һәрберсенең объекты нинди соң? Эчке сәясәтнең объекты — үз илендәге җәмгыять, ә тышкыныкы — дөнья бергәлеге, халыкара мөнәсәбәтләр, ягъни башка илләр белән мөнәсәбәтләр икәнен аңлау кыен түгел. Эчке сәясәт юнәлгән объектка бәйле рәвештә, икътисади, социаль, милли, демографик, яшьләр, экология, мәдәни, кадрлар сәясәте була. Үз чиратында, икътисади сәясәттә фәнни-техник, структур, аграр, инвестицион, финанс, тышкы икътисади сәясәтне аерып күрсәтәләр. (Мөгаен, сәясәтнең саналган юнәлешләренең һәрберсенең объектларын сез үзегез дә әйтә аласыздыр.)

Сәяси эшчәнлек объектларын караганнан соң, сәясәт бөтен җәмгыятькә, тормышның барлык якларына йогынты ясый дигән нәтиҗәгә килеп була. Моннан инде сәяси эшчәнлекнең җәмгыятьне үстерүдә зур әһәмияткә ия булуын әйтергә мөмкин.

СӘЯСИ ЭШЧӘНЛЕКНЕҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ ЧАРАЛАРЫ

Сәяси эшчәнлек, башка һәрбер эшчәнлек кебек, аның максатларын билгеләүне күздә тота. Алар озак вакытлы (аларны «стратегик» дип атыйлар) һәм кыска вакытлы максатларга аера. Максатлар актуаль, өстенлекле һәм актуаль булмаган, реаль һәм реаль булмаган булырга мөмкин. Теге яки бу максатның, бер яктан, ничек актуаль, икенче яктан, ничек реаль икәненә җавапны иҗтимагый үсешнең төп тенденцияләрен, өлгергән социаль ихтыяҗларны, сәяси көчләрнең урнашуын, төрле социаль төркемнәрнең ихтыяҗларын анализлагач кына бирергә мөмкин.

Куелган максатларга нинди чаралар белән ирешү мәсьәләсе аерым әһәмияткә ия. Сәяси эшчәнлеккә кагылышлы рәвештә бу мәсьәләне Яңарыш чорының даһи фикер иясе *Никколо Макиавелли* (1469–1527) тикшергән. «Дәүләттә әйткән сүзеңә тугрылыкның, самимилекнең һәм саф намуслылыкның мактауга лаеклыгы турында сөйләп тору артык,— дип язган ул.— Ләкин без, тәҗрибәбез буенча, безнең заманда бөек эшләргә әйткән сүзендә тормаган һәм кирәк кешене төп башына утырткан ке-

шеләрнең генә ирешүен беләбез: андый патшалар ахыр чиктә намус саклаганнарга караганда күбрәккә ирешкәннәр... Шуны аңларга кирәк: патша, аеруча яңасы, кешеләр «яхшы» дип санаганнарның барысын да эшли алмый, чөнки дәүләтне саклау хакына ул еш кына әйткән сүзенә, игелеккә, намуслылыкка, тәкъвалыкка каршы барырга мәҗбүр була. Шунлыктан ул күңеленнән, вакыйгалар икенче юнәлеш алса яки бәхет җиле икенче якка иссә, үз юнәлешен үзгәртергә, ягъни, инде әйтелгәнчә, яхшылыктан мөмкин кадәр ерагаймаска, әмма кирәк чакта явызлыктан да чирканмаска һәрвакыт әзер булырга тиеш».

Шулай итеп, сәяси эшлекле («патша») Н.Макиавелли исәпләгәнчә, «дәүләтне саклау хакына әйткән сүзен бозарга һәм гомумән «явызлыктан да чирканмаска» мөмкин. Безнең заманда да, билгеләгән максатларының якты образын сурәтләп, аларга ирешү өчен ялганга баручы, оппонентларын кимсетүче һәм дөрес булмаган чаралар кулланучы сәясәт эшлеклеләре бар. Капма-каршы карашлар яклы оешмалар бу мәсьәләдә аеруча сайланып тормыйлар. Үзләренең сәяси максатларына ирешү өчен алар урамнарда тәртипсезлекләр оештырырга, административ биналарны басып алырга, сәяси дошманнары белән сугышырга мөмкин дип уйлыйлар.

«Максат чараларны аклый» формуласына «сәясәт һәм әхлак нисбәтендә сәясәтне әхлаклылыкка буйсындырырга» дигән икенче бер караш каршы тора. Ләкин, күп кенә галимнәр билгеләп үткәнчә, сәясәт эшлеклесенә еш кына сайларга туры килә: йә (куркынычны бетерү өчен) «абсолют әхлак»ка бик үк туры килеп бетми торган каты чаралар кулланырга, йә үзеңнең берни эшләмәвең белән җәмгыятькә зыян китерергә. Бозарга ярамаган әхлак чиге бүгенге көндә кеше хокуклары турындагы документларда, халыкара гуманитар хокукта чагылыш тапкан.

СӘЯСИ ЭШЛӘР

Исегезгә төшерәбез: һәртөрле эшчәнлек эшләр җыелмасыннан тора. Сәяси эшчәнлек күптөрле эшләрне: партияләр оештыруны һәм хөкүмәт карарлары кабул итүне, сайлау кампанияләрен һәм парламентта чыгышлар ясауны, сәяси митингларны һәм дипломатик сөйләшүләрне, партия съездлары үткәрүне һәм халыкка мөрәҗәгать итүне, партия программалары эшләүне һәм референдумнарны, дәүләт переворотларын һәм хөкүмәт делегацияләре визитларын үз эченә ала. Бу сәяси эшчәнлек субъектлары буларак эш итүче аерым кешеләр яки төркемнәр акцияләре булырга мөмкин.

Сәяси эшләр «нәрсәдер эшләргә» (мәсәлән, нинди дә булса закон кабул итүгә ирешүгә һ.б.) яисә «нәрсәнедер булдырмаска»

яки «нәрсәнедер туктатырга» (мәсәлән, милләтара каршы торуны туктатырга) юнәлдерелергә мөмкин. Шул уңайдан эшне генә түгел, эш кылмауны да карап үтәргә кирәк. Дәүләт лидерының дәүләт перевороты куркынычы алдыннан берникди эш күрсәтмәвен ничек бәяләргә була? Кешенең сайлауларга карата битарафлыгын (сайлауларда катнашмавын) ничек бәяләп була? Һәр ике очракта да битарафлык сәяси вакыйгаларда катнашучы башкаларга үз линиясен үткәрү мөмкинлеге бирә.

Сәясәт субъектларының эшләре рациональ һәм иррациональ булырга мөмкин. Рационале — аңлы, планлаштырылган, максатларны һәм чараларны ачык аңлап эшләнгән эшләр. Иррационале — нигездә, кешеләрнең эмоциональ хәле, мәсәлән, аларның ярсуы, куралмаучанлыгы, курку хисе, барган вакыйгалардан алган тәэсирләре сәбәпле туган эшләр. Реаль сәяси тормышта рациональ һәм иррациональ башлангычлар кушылалар, үзара тәэсир итешәләр.

Сәяси эшләр стихияле һәм оешкан була. Стихияле рәвештә барлыкка килгән митинг һәм җентекләп әзерләнгән партия конференциясе — шундый эшләрнең мисаллары.

Сәяси эшләр һәрвакытта да куелган максатка ирешүгә китерми. Мәсәлән, народоволецларның Александр II не үтерүе «Народная воля»ның көрәш максатларыннан нык аермалы нәтиҗәләр бирә. (Исегезгә төшерегез: бу оешманың максатлары нинди булган? Патшага каршы террорчылык актының нәтиҗәләре нинди?)

> **«Сәясәт — аңа керүгә караганда чыгуы кыенрак булган лабиринт ул».**
>
> **У.Гладстон (1809–1898),**
> **Бөекбритания премьер-министры**

Соңгы елларда сәяси эшчәнлекнең ышандыру, җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү, төрле сәяси көчләрнең файдалы сөйләшүләре, хокук нормаларын саклауга контрольлек итү, теге яки бу сәяси эшләрнең нәтиҗәләрен фаразлау кебек ысулларның әһәмияте артты. Боларның барысы да сәясәт субъектларыннан югары сәяси культура, әхлак ягыннан үз-үзеңә контрольлек итүне, сәяси ихтыяр таләп итә.

ХАКИМИЯТ ҺӘМ ХАКИМИЯТ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Сәяси эшчәнлек хакимияткә йогынты ясау яки хакимиятне файдалану белән бәйле булганлыктан, бу төшенчәне җентекләбрәк тикшерик. Шул ук вакытта сезнең алар белән тарих

курсында да, җәмгыять белемен өйрәнгәндә дә күп тапкырлар очрашуыгызны истә тотыйк. Тамырлары грекча «кратос» яки «архи» булган, «хакимият»не, «хакимлек итү»не аңлаткан «аристократия», «монархия» һ.б. сүзләр сезгә таныш, әлбәттә. *«Хакимият»нең* кем белән яки нәрсә белән дә булса идарә итү: абруйга, хокукка таянып, кешеләрнең үзләрен тотышына йогынты ясау, кирәк булса, үз ихтыярыңа көчләп буйсындыру сәләте һәм мөмкинлеге икәнен дә беләсездер, мөгаен. Сәясәт белемендә хакимиятнең төрле классификацияләре бар.

Икътисад өлкәсендәге хакимият югары дәүләт органнары, сәясәт һәм финанс кампанияләре, фирмалары, аларның җитәкчеләре һәм хуҗалары арасында бүленә торган *икътисади хакимият* дип атала. *Хәрби хакимият* Югары башкомандующий (Россиядә, Конституция нигезендә, ул — илнең президенты), хәрби башлыклар кулында. *Рухи хакимият*, ягъни идеяләр хакимияте — җәмгыятькә зуррак абруйлы язучыларның, галимнәр, журналистлар, чиркәү эшлеклеләренең, шулай ук кайчак *мәгълүмати хакимият* дип йөртелгән массакүләм мәгълүмат чаралары хуҗалары һәм җитәкчеләренең йогынтысы ул. *Дәүләт хакимиятен* илнең Конституциясе нигезендә югары вәкаләтләр бирелгән дәүләт органнары һәм кешеләр тормышка ашыра (дәүләт хакимиятендә *законнар чыгаручы, башкаручы* һәм *суд* хакимияте аерып күрсәтелә). Сәясәтнең төрле субъектлары җәмгыять тормышының барлык өлкәләрендә хакимияткә ирешергә тырышалар. Бөтен җәмгыятькә тулаем йогынты ясау мөмкинлеген *сәяси хакимият* бирә, аңа — дәүләт, ә сәяси партияләрдә һәм хәрәкәтләрдә аларның лидерлары ия.

Сәяси хакимият дәүләт хакимияте буларак якынча моннан 5 мең ел элек барлыкка килә. Әмма аннан алдагы меңьеллыкларда ук кешеләрнең үзара хезмәттәшлеген җайга салу, үз-үзеңне тотуның гомуми кагыйдәләренә буйсындырып, аларга оешканлык бирү ихтыяҗы туа. Кешелек тарихының элеккеге этапларында андый җайга салу халык җыены, өлкәннәр шурасы, хәрби җитәкчеләр ихтыяры белән тормышка ашырылган. Кешеләрнең эшчәнлеге күп төрлерәк, социаль тигезсезлек сизелерлек булган саен, аларның мәнфәгатьләре шулкадәр төрлерәк, ә аларны килештерүгә, җәмгыятьне тәртипкә китерүгә, берләштерүгә, хаосны, социаль элемтәләрне җимерүгә каршы юнәлдерелгән аерым эшчәнлеккә мохтаҗлык шулкадәр зуррак була. Әлеге эшчәнлек профессиональ эшчәнлеккә әверелә: төп шөгыльләре җәмгыять эшләре белән идарә итү, хакимият вазыйфаларын гамәлгә ашыру булган кешеләр катлавы, сәяси хакимиятне тормышка ашыруның төп коралы булган дәүләт барлыкка килә.

Хакимият эшчәнлеге — нигездә хакимият карарларын эшләү һәм аларны тормышка ашыру буенча эшчәнлек ул. Рус философы И.А.Ильин (1882–1954) бу эшчәнлекне болай характерлый: «Хакимлек итүче теләргә һәм хәл итәргә генә түгел, ә башкаларны да системалы төстә теләргә һәм хәл итәргә китерергә тиеш. Хакимлек итү ул ничектер үз ихтыярыңны башкаларга иңдерү, әмма бу иңдерү буйсынганнар тарафыннан ирекле кабул ителергә тиеш.

Хакимлек итү — көчлерәк ихтыярның көчсезрәк ихтыяр белән аралашуының нәзберек, нәфис процессы ул. Бу процесс периферияңең — үзәккә, күпләп таралган ихтыярларның бердәм, оешкан, төп ихтыярга тартылуының күренмәс һәм авырлыгы булмаган атмосферасын тудыра».

Төрле субъектларның һәм хакимият объектларының (хакимияткә ия булучылар һәм буйсынганнарның) үзара эш итүләре нәтиҗәсендә хакимият мөнәсәбәтләре барлыкка килә. Субъект кулланган чараларга бәйле рәвештә, әлеге мөнәсәбәтләрнең төрле форма алуы мөмкин. Көч хакимияте — субъектның хакимияткә буйсынганнар белән мөнәсәбәтләрдә теләгән нәтиҗәләргә физик көч куллану яисә психик йогынты ясау юлы белән ирешү сәләте. *Мәҗбүр итү* — буйсынганнарны нинди дә булса таләпләргә җәза бирү белән куркытып буйсындыруга исәпләнгән гамәл. *Теләк уяту* субъектның буйсынучыга карата теге яки бу уңайлык тудыру сәләтенә нигезләнә. Буйсынучыга *ышандыру* ярдәмендә йогынты ясау аларның үз-үзләрен тотышларына көчле, саллы, уйланган дәлилләргә нигезләнә. *Абруй хакимиятенә* буйсындыру хакимият субъектының аңа карата ышаныч тудыра торган югары сыйфатларын барлык кеше алдында тану белән бәйле. Ниһаять, кешеләрнең аңы һәм үз-үзләрен тотышы белән *манипуляция*, аларга ялган мәгълүмат, демагогик лозунглар һ.б. ярдәмендә яшерен йогынты ясау мөмкин.

> **«Хакимият — аның артыннан беркем дә үз теләге белән торып китми торган өстәл ул».**
>
> **Ф.Искәндәр (1929 елда туган),**
> **совет язучысы**

Сәясәт фәне хакимият эшчәнлегенең кайбер төп компонентларын аерып күрсәтә. Бу, барыннан да элек — хакимият ихтыяры, ягъни максатка ирешүгә көчле омтылыш, хакимиятне күрсәтүдә көчләрне, ирекне туплау, барча кеше үтәргә тиешле карарлар кабул итү, барысы да буйсынырга тиешле чаралар күрү. Ул — нигезе мәсьәләне өйрәнү, аны уйлау, тикшерү,

килештерү нәтиҗәсендә хакимият башында торучы (хаким, дәүләт органы) тапкан йомгаклау булган нинди дә булса мәсьәлә буенча хакимият карары, боерыгы. Бу шулай ук хакимият ихтыяры һәм хакимият карары тормышка ашырыла торган хакимият эшләре, активлыкның конкрет чагылышлары. Хакимият эшчәнлеге барлык хакимият актларында, ягъни дәүләт органнары законнарында, указ, карар, боерыкларында чагылыш таба. Хакимият эшчәнлегенең әлеге үзенчәлекләрен сез төрле тарихи чорлардагы төрле дәүләтләрнең сезгә билгеле җитәкчеләре — Иван Грозный һәм Петр I, Александр II һәм П.А.Столыпин, Наполеон һәм Рузвельт сәясәтендә күрә аласыз.

ХАКИМИЯТНЕҢ ЛЕГИТИМЛЫГЫ

Хакимият ул легитим булган шартларда гына нәтиҗәле була. Сәясәт белемендә легитимлык төшенчәсе буйсынганнарның хакимият иясенә карата халыкның хакимиятнең хокукыйлыгын тануын, аны законлы һәм гадел дип санавын, аңа ирекле төстә буйсынуын характерлау өчен киң кулланыла. Хакимлек итүнең легитимлылыгының классик типологиясен немец галиме М.Вебер (1864–1920) эшли. Ул легитимлыкның өч тибын һәм шуңа бәйле рәвештә сәяси хакимлекнең (турыдан-туры һәм һичшиксез буйсынуның) өч тибын аерып күрсәтә.

Легитимлыкның *традицион тибы* хакимияткә буйсыну гадәте буенча яши. Ул законга караганда күбрәк традицияләргә һәм гореф-гадәтләргә, күптән урнашкан тәртипләргә һәм хакимияткә изге итеп карауга таяна.

Легитимлыкның *харизматик тибы* хакимнең («харизма» сүзе грекчадан алынган, «ходай бүләге» дигәнне аңлата) гадәттән тыш, искитмәле шәхси сыйфатлары белән бәйле. Кешеләр мондый хакимиятне традиция буенча түгел, ә яңаны, ачыкны, гадәти булмаганны тою аркасында кабул итәләр. Хакимиятнең мондый тибы гадәти тәртипкә, законга түгел, хакимнең чынлыктагы яки күз алдына китерелгән гадәттән тыш сыйфатларына хисси баш июгә таяна.

Легитимлыкның *рациональ-легаль тибы* хакимиятне урнашкан тәртипләр һәм законнар нигезендә барлыкка килгән тануны аңлата. Бу тип җитәкченең даһи шәхес булуы, кешеләрнең гадәтләре белән түгел, ә хакимият эшчәнлеген регламентлаучы формаль-хокукый нормаларны төгәл үтәве белән бәйле. Бүгенге дөньяда ул, кагыйдә буларак, демократик дәүләтләрдә бар.

М.Веберның квалификацияләве күбрәк аерым шәхесләр хакимиятенең легитимлыгына кагылса, соңрак Америка политологы Д.Истон төрле сәяси режимнарга карата кулланыла

торган якын килү тәкъдим итә. *Идеология* легитимлыгы хакимият игълан иткән кыйммәтләргә һәм принципларга, аларның халык көткәннәргә туры килүенә таяна. *Структур* легитимлык кешеләрнең режим структураларына һәм нормаларына бәйләнгәнлеге нигезендә яши. *Шәхсәнлек* легитимлыгы режим структураларында хакимият вазыйфаларын башкаручы кешеләрнең әхлакый хуплавына нигезләнә.

Карап үтелгән квалификацияләрнең икесе дә хакимият мөнәсәбәтләренең «идеаль» дигән типларын гәүдәләндерәләр, ә реаль тормышта алар азмы-күпме ачыграк чагылырга мөмкин; теге яки бу аерым очракта аларның кушылуы ихтимал.

Хакимлек итү — сәяси эшчәнлек төре, аңа да сәясәтне эшчәнлек буларак характерлаучы һәм бу параграфта язылган барлык сыйфатлар хас.

Хакимият эшчәнлеге — асылда, барлык социаль бергәлекләргә, кешеләрнең тормыш эшчәнлегенең барлык өлкәләренә, тулаем җәмгыятькә йогынты ясаучы хакимият сәясәте ул.

Сәясәт һәм хакимият — политологиянең төп төшенчәләре; аларның төп нигезләмәләре белән сез 11 нче сыйныфта танышырсыз.

Төп төшенчәләр: сәясәт, хакимият, сәяси хакимият, хакимиятнең легитимлыгы.

Терминнар: сәяси эшләр, хакимлек итү, харизма.

Үзегезне тикшерегез

1. Эшчәнлекнең аерым төре буларак сәясәтнең билгеләре нинди? 2. Сәясәттә максат һәм чаралар үзара ничек бәйләнгән? 3. Сәяси эшләрне ничек квалификацияләргә мөмкин? 4. Нәрсә ул хакимият? 5. Сәяси хакимият хакимиятнең башка төрләреннән нәрсә белән аерыла? 6. Нинди хакимият легитим була? 7. Легитимлыкның төп типлары нәрсә белән характерлана? 8. Хакимият эшчәнлеге нидән гыйбарәт?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Аристотельнең: «Кеше үзенең табигате буенча сәяси зат»,— дигән сүзләрен актуаль яисә искергән дип буламы? Аларны ничек аңларга кирәк?

2. Рус философы Н.О.Лосский (1870–1965) болай дип яза: «Кайбер социаль реформаторларның җәмгыятьне «көзән җыерулы» бер сикерүдә, җәмгыятьне шундук үсешнең тагын да югарырак баскычына күтәрергә тырышулары гадәттә без элек ирешкән тыйнак уңышыбызны җимерәләр генә һәм һич тә камиллекнең яңа, югары формаларын барлыкка китермиләр». Сәясәтчеләрнең эшчәнлеге турындагы бу сүзләрне «максат —

чара — нәтиҗә» бәйләнеше карашыннан чыгып анализлагыз. Н.О.Лосский сүзләре параграф текстындагы нинди фикерне раслыйлар?

3. Петр I сәясәтенең төп юнәлешләрен атагыз. Аларга ирешүнең максат һәм чаралары һәм аларның һәрберсенең нәтиҗәләре нинди булган? Петр I сәясәте Россия җәмгыятенә ничек тәэсир иткән?

4. М.Веберның түбәндә әйткәннәрендә нинди проблема күздә тотыла: «Яхшы» максатларга ирешүнең күпчелек очракларда буйсыну зарурлыгы белән һәм әхлакый яктан шикле яисә иң аз дигәндә куркыныч чаралар кулланып эшләнелүе, әшәке нәтиҗәләр булу мөмкинлеге яки хәтта ихтималлылыгы белән бәйле булуы фактын дөньяда бер генә этика да читләтеп узмый, һәм бер генә этика да этик яктан уңай максатның этик куркыныч чараларны һәм соңгы нәтиҗәләрне нинди күләмдә «изгеләндерүен» әйтә алмый». М.Вебер карашы Н.Макиавелли карашларына туры киләме? Үз нәтиҗәгезне дәлилләгез.

5. Хакимиятнең легитимлыгы артамы яки кимиме икәнен нинди күрсәткечләр буенча билгеләргә мөмкин? Уйлагыз: хакимият эшчәнлегендә теге яки бу чараларны өстенлекле куллану нәрсәне дәлилли?

6. Әлеге параграфта өйрәнгән төшенчәләрдән файдаланып, соңгы вакытта кайсы да булса сәяси оешма эшчәнлеге турындагы матбугат материалларын җыегыз.

Чыганак белән эшләгез

Рус философы В.Ю.Сморгунова сәяси белемнәрнең һәм сәяси эшнең бәйләнеше турында уйлана.

Барлык сәяси эшләр **сәяси мәгънәгә ия,** гәрчә аларга **«аңсыз компонент»** булса да, алар уйлап эшләнелә. Ләкин сәяси эшләрнең уйланып эшләнүе аларның һәрвакытта да конструктив булуы, **хәзерге** сәяси хәлгә туры килүе, субъектның үз ихтыяҗлары һәм сәяси мәнфәгатьләренең **сәяси** эшен дөрес чагылдыруы, башка сәяси субъектларның сәяси мәнфәгатьләрен истә тотуы турында сөйләми. Сәяси эш субъекты үзенең сәяси практикасында сәяси тормышны мөстәкыйль рәвештә үзе үткәргән тикшеренүгә түгел, ә башка гносеологик чыганак сәяси мәгълүматына таянырга мөмкин. Шулай ук сәяси мотивларның чын мәгънәсен «каплап торучы» рәсми белдерелгән максатлар белән сәяси субъектлар эшчәнлеге белән чынлыкта җитәкчелек итүче сәяси идеяләр арасында туры килмәү булуы да ихтимал. Мондый хәл сәяси процесста катнашучының сәяси фикерләве җитмәгән, ул фикер йөртү белән **практика** арасындагы каршылыкны тоймаган хәлләрдә дә очрый.

Сәяси мөнәсәбәтләр, тулаем сәясәт, хакимият структуралары, иҗтимагый килешүгә ирешү максатларында, иҗтимагый тормышны рациональләштерергә тиешләр. Сәяси белем сәяси мөнәсәбәтләрдә гәүдәләнә. Интеллектуаль-иҗтимагый белем буларак, сәяси карар интеллектуаль эшчәнлекне практик эшләргә әверелдерүче, «эшләтеп җибәрүче» механизмны күрсәтә. Монда рухи дөнья реаль, практик дөнья белән кушыла. Монда без кешенең сәяси яктан белүче һәм теләүче кеше булудан куәтле, үз мәнфәгатьләрен чынлап та тормышка ашыручы кешегә әверелүен күрәбез. Мәнфәгатьләрне болай тормышка ашыру сәясәтнең төрле формаларында мөмкин.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Сәяси белемнәр сәяси эшчәнлектә нинди роль уйный? 2. Ялган мәгълүмат куллану нәрсәгә илтә? 3. Белүче кеше ничек итеп куәтле кешегә әверелә? 4. Чынбарлык турында дөрес күзаллаулар хакимият карарлары кабул итү өчен нинди әһәмияткә ия?

III бүлеккә йомгаклаулар

1. Эшчәнлек — җәмгыятьнең яшәү формасы, кеше өчен характерлы тышкы дөньяга мөнәсәбәт ысулы, субъектның әйләнә-тирә дөньяны максатчан үзгәртеп коруда, шулай ук кешенең үзен үзгәртеп коруда чагылучы активлыгы күренеше ул. Эшчәнлек процессында җәмгыять һәм кеше үзе үсә. Һәр эшчәнлектә максатка юнәлдерелгән сәбәпләр, максат, аңа ирешү чаралары, эш һәм нәтиҗә бар. Сәбәп ролендә ихтыяҗлар, мәнфәгатьләр, социаль күрсәтмәләр, инанулар, идеаллар, мавыгулар һәм хисләр булырга мөмкин.

Кеше һәм җәмгыять үсешендә иҗади процесс аерым роль уйный; ул процесста яңа, әле беркайчан да булмаган нәрсә булдырыла. Кешенең иҗади активлыгының күптөрлелеге эшчәнлекнең уен, уку, хезмәт кебек төрләрендә чагыла. Иҗади эшчәнлектә кешенең сәләтләре үсә, ә аның нәтиҗәләре — мәдәниятнең, иҗтимагый тормышның барлык якларының яңаруы.

2. Рухи эшчәнлек (танып-белү, кыйммәти-юнәлешле, фаразлаулы) кешеләрнең аңы үзгәрү белән бәйле, фән һәм белем, нәфис мәдәният һәм дин өлкәсендәге эшчәнлек ул. Аңа рухи мәдәниятләрне булдыру, тарату һәм үзләштерү керә. Мәдәниятне үзләштереп, кешеләр үз халкының, иленең һәм дөньяның рухи байлыкларына ия булалар. Рухи эшчәнлек төрле төрләрдә һәм формаларда иҗат итә, шәхеснең һәм җәмгыятьнең мәдәниятен баета. Шәхеснең рухи (эчке) дөньясы кешенең акылын, хисен, ихтыярын берләштерә, шәхесне аның тирә-

юньдәге чынбарлыкка, башка кешеләргә, үзенә мөнәсәбәте позициясеннән торып характерлый.

3. Хезмәт — хезмәт чаралары ярдәмендә кешеләрнең яшәве өчен кирәкле матди һәм рухи кыйммәтләр булдыруга юнәлдерелгән максатчан эшчәнлек ул. Ул — кеше ихтыяҗларын канәгатьләндерү ысулы; иҗтимагый байлык чыганагы; иҗтимагый процесс факторы. Хезмәт эшчәнлеге эш-хәрәкәтләр җыелмасы, хезмәт субъектының сыйфаты, хезмәтнең матди-техник шартлары, хезмәт субъектының аларны куллану чаралары һәм шартлары, эш процессын оештыру һәм аның структурасы белән характерлана. Җитештерүнең техник факторы яңару кеше факторының ролен сизелерлек арттыра.

Базар икътисадына күчкәч, социаль партнерлык — дәүләт хакимияте органнары, хезмәт иязәре һәм эш бирүчеләр, эшмәкәрләр вәкилләре арасында тигез хокуклы хезмәттәшлеккә нигезләнгән үзара мөнәсәбәтләр системасы үсеш алды.

4. Сәяси эшчәнлек зур социаль төркемнәрнең һәм тулаем җәмгыять мәнфәгатьләрен чагылдыра. Аңа кеше хокуклары турындагы документларда билгеләнгәннәрнең чикләреннән чыкмаска тиешле төрле эшләр, чаралар куллану кирә. Сәяси эшчәнлекнең юнәлеше һәм эчтәлеге күп яктан сәяси идеология белән билгеләнә.

Сәяси эшчәнлек хакимияткә йогынты ясау яки хакимиятне файдалану белән бәйле. Хакимият — абруйга, хокукка таянып һәм, кирәк икән, көчләү ярдәмендә кешеләргә йогынты ясау ысулы ул. Хакимият эшчәнлеге нигездә сәяси карарлар эшләүдә, кабул итүдә һәм аларны тормышка ашыруда чагыла. Хакимият ул легитим булганда, ягъни буйсынганнар хакимиятне «законлы» һәм «гадел» дип таныганда гына нәтиҗәле була.

III бүлеккә сораулар һәм биремнәр

1. II һәм III бүлекләр эчтәлегенә таянып, эшчәнлекнең социаль асылын тасвирлагыз.

2. Эшчәнлек һәм аның күптөрлелеге турындагы белемнәрегезне таблицада чагыштырыгыз.

Эшчәнлек һәм аның төрләре

Эшчәнлек төрләре	Сәбәпләр	Максат	Чаралар	Эшләр
Хезмәт				
Рухи				
Сәяси				

3. Философия буенча семинарда бәхәс чыкты:

Н и к о л а й. Эшчәнлектә — кешенең асылы. Ул нинди дә булса эшләрдән башка чагыла алмый.

Л е н а. Мин моның белән килешмим. Берни эшләмичә дә яшәп була. Борынгы грек философы бернинди эшчәнлек белән дә шөгыльләнмәгән, тормыш турында гына уйланган.

М а к с и м. Фәлсәфәлек итү эшчәнлек түгелмени? Ул да бит кешенең асылы. Хайваннар фәлсәфәлек итә алмый.

Сез бәхәскә кушыласыз. Тикшерелә торган мәсьәләләр буенча әйтелгән карашларга карата мөнәсәбәтегезне һәм үз карашыгызны бәян итегез.

4. Хезмәт, рухи һәм сәяси эшчәнлектәге иҗат мисалларын китерегез. Иҗади эшчәнлекнең әлеге актларында уртаклык һәм аерымлыклар нәрсәдә?

5. Иҗатның ике бәяләмәсен чагыштырыгыз. Н.Бердяев, иҗат — ирек акты аша яшәештән яшәешкә күчү ул, дигән. А.Д.Андреев иҗатны кешенең иң югары, иң кыйммәт сәләте, аның илаһи прерогативасын (гадәттән тыш хокукын. — *Ред.*) чагылдыручы буларак билгеләгән. Сез бу сүзләргә ничек карыйсыз? Аларда нинди дә булса уртаклык бармы? Кайсы билгеләмәгә өстенлек бирәсез һәм ни өчен?

Имтиханга әзерләнәбез

1. «Кеше эшчәнлеге» төшенчәсе билгеләмәсенең кирәкле элементлар рәвешендә нинди сыйфатлар өстәргә кирәк?

1) активлык чагылышы;
2) . . . . ;
3) . . . .

2. Кеше эшчәнлегенең үзенчәлекләрен санаганда нәрсә артык?

1) максат кую;
2) сәбәпләр;
3) әйләнә-тирә мохиткә яраклашу;
4) әйләнә-тирә мохитне үзгәртеп кору.

3. Кеше өчен хас, тышкы дөньяны үзгәртеп коруда гәүдәләнүче активлык чагылышлары алар:

1) уен;
2) үз-үзеңне тоту;
3) мөнәсәбәт;
4) эшчәнлек.

4. Яңаны, элек булмаганны булдыручы эшчәнлек ул:

1) танып-белү;
2) өйрәнү;

3) иҗат;

4) күчереп алу.

5. Түбәндәге фикерләр дөресме?

А. Эшчәнлек вакытында мәдәниятне иҗади булдыру тормышка ашырыла.

Б. Кырмыска оясы — яхшы оештырылган эшчәнлек үрнәге ул.

1) А гына дөрес;

2) Б гына дөрес;

3) А да, Б да дөрес;

4) икесе дә дөрес түгел.

6. Нинди дә булса эшчәнлеккә үз мисалыгызны китерегез һәм шул мисалда теләсә нинди эшчәнлекнең уртак сыйфатларын ачып бирегез.

7. «Социаль-гуманитар белемнәр» төшенчәсе булган һәм ул белемнәр турында теләсә нинди мәгълүмат бирә торган өч җөмлә языгыз.

8. «Их, эш сөючәнлеккә — белем, ә белемгә эш сөючәнлекне өстәсәң икән ул...» дигән җөмлә нигезендә эссе языгыз.

IV бүлек

АҢ ҺӘМ ТАНЫП-БЕЛҮ

§ 21. Дөньяның танып-беленүе проблемасы

Исегезгә төшерегез:

кешедә нинди сизү органнары бар? Аларның эшчәнлеге ничек җайга салына? Кешенең аңы нәрсә ул? Ул тел белән ничек бәйләнгән? Теләсә кайсы эшчәнлекнең структурасы нинди?

«Белем — көч ул». Бу сүзләрне инглиз философы *Ф.Бэкон* (1561–1626) әйткән. Аларда белемнәрнең аерым кеше һәм тулаем кешелек дөньясында тоткан гаять зур әһәмияте турындагы фикер чагылдырыла. Чынлап та, әйләнә-тирә дөнья һәм үзе турындагы белемнәр кешегә эшчәнлекнең барлык төрләре — торак төзү һәм корыч җитештерү, авыруларны дәвалау һәм дәүләт белән идарә итү өчен кирәк. Белемнәр кешеләр, әйберләр һәм табигать күренешләре дөньясында юнәлеш табу мөмкинлекләре бирәләр. Белемнәрдә кешеләрнең

матди һәм рухи эшчәнлегенең меңнәрчә гасырлык тәҗрибәсе тупланган. (Күз алдыбызга китерик: кешеләр алган белемнәрен ныгыта һәм киләсе буыннарга тапшыра алмадылар ди; бу очракта һәр яңа буын тарихны «чиста бит»тән башлар, һәм без үзебезнең борынгы ата-бабаларыбыз кебек үк яшәр идек.)

Әлбәттә инде, тупланган барча белем дә аерым кеше байлыгы була алмый. Безгә ябырылган искитмәле күп мәгълүматлар ташкынына карамастан, безнең һәрберебез аларның бер өлешен генә үзләштерә, эшкәртә һәм киләчәктә файдалана. Үзләренең составлары буенча бу белемнәр төрле. Бер очракта ул белемнәр — предметлар, аларның үзлекләре һәм кеше өчен файдалы яклары турында. Әлеге белемнәрнең нигезләре физика, химия һәм башка предметлар дәрәҗәсендә ачыла. Башка очракларда белем алу ысуллары һәм эшчәнлек кагыйдәләре үзләре кызыксыну тудыра. Белемнәрнең әлеге компонентларының әһәмияте бүгенге дөньяда арта бара. Алар күпләгән мәктәп предметлары эчтәлегенә кертелгән, ләкин махсус дисциплина — технология — дә бар.

Белемнәрнең аерым тибын безнең билгеле бер предмет даирәсендәге белемнең ничек барлыкка килүе турындагы күзаллауларыбыз һәм идеяләр түгел, ә кешелек танып-белүенең бигрәк тә гомуми принциплары ничек формалашуы, аның реаль дөнья белән нисбәте, белем һәм инану арасындагы чик, кешенең танып-белү мөмкинлекләренең чикләре тәшкил итә. Әлеге мәсьәләләр даирәсе философларның игътибар үзәгендә булды һәм шулай булып кала бирә. Башка күпләгән проблемалардагы кебек үк, монда да төрлечә якын килүләр һәм теорияләр урнашты.

ЯШӘЕШ ҺӘМ ТАНЫП-БЕЛҮ

«Яшәеш» категориясе — философиядә иң үзәк категорияләрнең берсе. Философиянең яшәешнең нигез принципларын өйрәнүче бүлеге *«онтология»* дип атала (грекча «асылы» һәм «төшенчә», «тәгълимат» сүзеннән). Бу категория дөньяның гомумиләштерелгән фәлсәфи картинасын булдыру өчен мөһим генә түгел, ә бәлки аңлау өчен дә кыен, барыннан да элек — бик тә гомумилеге аркасында. Инде белгәнегезчә, төшенчә күренешләрнең, объектларның күбрәк даирәсен колачлаган саен, аның асылын чагылдыручы характерлы сыйфатлар шулкадәр азрак була. «Яшәеш» категориясен дә бик тә киң, димәк, бик тә читен билгеләнә торган фәлсәфи терминнарга кертергә була. «Борынгы заманнардан куелган һәм хәзер дә даими куела торган һәм кыенлыклар тудыра торган мәсьәлә — нәрсә ул асыл турындагы мәсьәлә», — дип язган борынгы грек философы Аристотель.

Яшәешнең асылы, аның аң белән мөнәсәбәте мәсьәләсе фәлсәфи фикернең бөтен тарихы аша үтә. Озак вакытлар ул философиянең төп мәсьәләсе булып санала. Без аңа төрле җавапларны инде борынгы грек философларында ук табабыз. Мәсәлән, Фалес Милетский дөньяның субстанциясе — су дип исәпли, Анаксимен аны — һава, Гераклит уй белән бәйли. Демокрит яшәешнең нигезен реаль яшәүче бүленмәс атомнарда күрә, ә бушлыкны аларның хәрәкәт итүе шарты дип саный. Платон чын асылга бары аң белән генә ирешеп була торган тәнсез, матди булмаган идеяләрне кертә. Кешене чолгап алган предметлы дөнья үзгәрүчән һәм чын яшәешкә ия түгел. Аристотель яшәешне шундый нәрсә (асыл) һәм аерым әйбернең асылы дип аерып күрсәтә. Яшәеш, барлык асылларның беренчесе, фәлсәфи танып беленә, ә әйберләрнең асылын аерым фән өйрәнә.

Урта гасырлар онтологиясендә абсолют яшәеш еш кына Алла белән тәңгәлләштерелә. Ләкин кайбер фикер ияләре Алланы асыллар дөньясы өстеннән күтәрелеп торучы, яшәеш бүләк итүче (чыганак) итеп карыйлар.

Табигать белеме үскән саен, яшәешне күбрәк табигать буларак аңлый башлыйлар. Беренче планга дөньяны танып-белүнең философиянең *гносеология* дип аталган бүлегендә карала торган проблемалары чыга.

Немец философы И.Кант тышкы дөньяны һәм кешегә теләсә нинди тәҗрибәгә кадәр башта бирелгән (априор) сизеп танып-белү формаларын, шулай ук акыл категорияләрен (сәбәп һәм нәтиҗә, бердәнбер, аерым, гомуми һ.б.) аерып күрсәтә. Философ фикеренчә, аларны танып-белү аппаратына ия булган танып-белүче кушылдыра. Шул ук вакытта кешенең белеме фәкать тәҗрибә дөньясын гына колачлый, ә аннан читтә танып булмый торган «үз эчләрендәге әйберләр» ята.

Платонга барып тоташкан «идеализм линиясе»н,—ул агымны соңыннан шулай дип атаганнар,— XVIII–XIX гасыр немец философлары, немец классик идеализмы вәкилләре үткәргән. Г. Гегель «дөньяның субъстанциясе» дип үзенең үсешендә табигать стадиясен үтеп, абстракттан конкретка, ягъни гомумирәк билгеләмәләрдән бай эчтәлекле конкретракка күтәрелү процессында үзен-үзе танып-белүче «абсолют рух»ны яки «дөнья акылы»н санаган.

Ләкин күп философлар танып-белүдә яшәешнең мондый «эретелүе» белән килешмәгән яшәеш дөньясының чынбарлыгы, объективлыгы, аның танып-белүче субъекттан бәйсезлеге идеясен яклаганнар.

Философлар бүген дә, үзләренең элгәреләренең хезмәтләренә таянып һәм бүгенге фән казанышларын исәпкә алып, яшәеш

һәм танып-белү проблемалары турында уйлануларын дәвам иттерәләр.

ФӘЛСӘФИ ПРОБЛЕМА БУЛАРАК ДӨНЬЯНЫҢ ТАНЫП-БЕЛЕНҮЕ

Аек акыл күзлегеннән чыгып караганда, «дөньяны танып-белеп буламы» дигән сорауга җавап фәкать уңай гына булырга мөмкин. Чынлап та, әгәр танып-белү, аның нигезендә дөньяны үзгәртү мөмкин булмаса, кешелек дөньясы кыргыйлык халәтеннән чыга алмас иде. Хәтта белемнәр нигезләрен үзләштерү өчен генә дә бүгенге мәктәп укучысына кимендә ун ел кирәк.

Философия өчен дөньяның танып-беленүе турындагы мәсьәлә тирән мәгънәгә ия. Чөнки «дөнья чынлыкта нинди ул» дигәнне аңлату өчен кешегә үз аңы чикләреннән чыгарга кирәк,— ә бу мөмкин түгел. Шунлыктан, дип раслыйлар философлар, тышкы дөнья белән безнең аның турындагы күзаллауларыбызның ничек ярашуы турында без берни дә әйтә алмыйбыз. Димәк, чынбарлык кеше өчен принципта танып-беленмәслек. Әлеге нәтиҗә яклы философларны *агностиклар* (грекчадан — танып-белеп булмый торган) дип атыйлар.

Күпчелек философлар исә дөньяны танып-белеп булуны таныйлар. Әмма предметлы дөньяның һәм безнең аның турындагы күзаллауларыбызның нисбәтенең характеры турындагы мәсьәләдә аларның карашлары аерыла. Кайберәүләр безнең сизү әгъзаларыбыз чынбарлыкны «фотографик төгәллек» белән чагылдыра дип исәпли. Башкалар, безнең белемнәребездә һәрвакыт кешенең субъектив эшчәнлегенең бетереп булмаслык эзләре бар: безнең дөнья турындагы күзаллауларыбыздагы үткән буыннар туплаган мәдәни-тарихи тәҗрибә, үзебезнең дөньяга караш өстенлекләребез, априор (тәҗрибәгә кадәрге) идеяләр һ.б. йогынты ясый, дигән караштан чыгып эш итәләр. Шунлыктан «объектив дөньяның субъектив образы» турында сөйләү дөрес булыр.

Кайбер философлар тышкы предметларның үзләренә хас (беренчел) һәм кеше аңына фәкать предметлар аның сизү әгъзаларына тәэсир иткәч кенә барлыкка килә торган (икенчел) сыйфатларны аерырга тырышкан. Беренчел сыйфатка — авырлык, форма һ.б., икенчелгә тәм, төс, ис һ.б. кертелгән.

Философлар актив тикшерә торган икенче бер гносеологик проблема — танып-белүче субъектның урыны һәм роле турындагы мәсьәлә. Аның асылын ачарга безгә танып-белүне кеше эшчәнлегенең үзенчәлекле төре буларак тикшерү ярдәм итәчәк.

ТАНЫП-БЕЛҮ — ЭШЧӘНЛЕК УЛ

Белемнәр юктан гына барлыкка килми. Алар — аерым бер процесс — кешеләрнең танып-белү эшчәнлеге нәтиҗәсе. Мисалга мөрәҗәгать итик. Борынгы кеше, ау вакытында кыргый хайваннарның үз-үзләрен тотышларын күзәтеп, соңыннан аларны кулга ияләштерүгә ярдәм итәчәк файдалы мәгълүматлар алган. Яисә башка бер мисал: бала туп белән уйнаганда тәрәзә пыяласын вата. Бу гамәлнең икенче нәтиҗәсе (турыдан-турысы — җәза) пыяланың мөһим үзенчәлеге — уалучанлыгы белән танышу булачак. Бу хәлләр танып-белүнең ирексездән, безнең көндәлек тормышыбызга «ябышып» барлыкка килүе ихтималын күрсәтәләр. Менә башка мисаллар. Зоолог кыргый хайваннарның ябылып асралганда үрчүләре үзенчәлекләрен өйрәнү буенча махсус тикшеренүләр үткәрә. Яшүсмер физика дәресләрендә каты җисемнәрнең үзенчәлекләрен өйрәнә. Монда инде сүз махсус оештырылган танып-белү процессы турында бара. Галим, әгәр аңа уңыш юлдаш булса, яңа закончалыклар ача. Укучы да күп яңа нәрсә ача, ләкин үзе өчен. Ул аның шәхси тәҗрибәсе казанышы булачак.

Ничек кенә барса да, танып-белү процессы ике нәрсә булуны күздә тота: танып-белүче кешене (танып-белү субъектын) һәм танып-беленүче предметны (танып-белү объектын). Алар берберсе белән ничек яраша соң?

XVII гасырда танып-белүче акыл дөньяны ничектер читтән күзәтә, һәм аны шул юл белән танып-белү дигән күзаллау барлыкка килә, ул озак вакыт хакимлек итә. Танып-белүнең максаты — объектларны чынлыкта алар ничек булган шулай, кешедән бәйсез рәвештә сурәтләү. Әгәр тәҗрибә мәгълүматларын дөрес гомумиләштерсәң һәм дөрес ысул кулланcаң, моңа ирешеп була. (Без кайбер философларның максатка болай ирешү мөмкинлеген кире кагуларын әйтеп үттек инде.)

Хәзер күп кенә тарафдарлары булган мондый карашка күпләгән философлар һәм табигать белгечләре башка карашны каршы куя. Танып-белүче субъект предметлы дөньядан аерылмаган, ә аның эчендә яши. Без әйбернең асылын пассив күзәтүчеләр булып түгел, ә фәкать аны безнең актив эшчәнлегебезгә кертү аша танып белә алабыз. Танып-белүнең нәтиҗәләре өйрәнелә торган предметның сыйфатларын гына түгел, ә танып-белүне ничек оештыруыбызны да (танып-белүнең ысулларын, формаларын), шулай ук, танып-белүче субъектлар буларак, үзебезнең үзенчәлекләребезне (карашларыбызны, элек туплаган тәҗрибәбезне һ.б.) дә чагылдыра.

Немец физигы В.Гейзенберг (1901–1976) табигать танып-белү процессында безнең сорауларга җавап бирә, ләкин җавап-

лар аның ничек төзелүенә генә түгел, ә безнең сорауларны ничек куюыбызга да бәйле ди.

Болай якын килгәндә, теория тәҗрибә фактларын гомумиләштерү генә түгел, шулай ук бердәнбер дөрес, абсолют ысул да була алмый. Бер үк күренешне төрлечә аңлатучы теорияләр бар.

СИЗЕП ТАНЫП-БЕЛҮ: АНЫҢ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ ЧИКЛӘРЕ

Сизеп танып-белү һәм рациональ танып-белү (фикерләү) бар.

Бер фикер иясе безнең сизү әгъзаларыбызны «дөньяга тәрәзәләр» дип атаган. Алар ярдәмендә без тышкы дөнья, шулай ук үз организмыбызның хәле турында кирәкле мәгълүматны алабыз. Биология курсыннан белгәнегезчә, сизү әгъзалары озак эволюция процессында барлыкка килгәннәр һәм үскәннәр, һәм баш мие эшчәнлеге белән аерылгысыз бәйләнгәннәр. Төп биш сизү — күрү, ишетү, ис сизү, тән белән тою, тәм тою — Аристотель тарафыннан әле моннан 2 мең ел элек тасвирланган, әмма аларны өйрәнү, эшләү механизмнарын анализлау бүгенге көнгәчә дәвам итә.

Тикшеренүчеләргә хәзер иң күп мәгълүматны күрү һәм ишетү бирүе мәгълүм. Ә эволюциянең башлангыч этапларында тере затлар өчен ис сизү күбрәк әһәмияткә ия булган. Гәрчә хәзерге кеше әлеге тойгының үткенлеге буенча кайбер төр хайваннар белән ярыша алмаса да, безнең борыныбыз дүрт меңнән дә ким булмаган исне сизә ала. Ә безнең күзебез яктылык киеренкелегенең һәм төс билгеләренең берничә миллион үзенчәлеген аерырга сәләтле.

Шулай да, әгәр баш мие эшчәнлеге булмаса, безгә сизү әгъзаларыбыз эшләве нәтиҗәсендә килә торган күптөрле, чәчелгән, еш кына каршылыклы мәгълүматлар беркайчан да тәртипле күренеш алмас иде. Ми барча сизү әгъзаларыннан хәбәрләр кабул итеп кенә калмый, алынган мәгълүматны классификацияли һәм саклый. Мәсәлән, күрү күренешен булдырып, ми, җитмәгән фрагментларны өстәп, «ак таплар»ны тутырып, тупланган мәгълүматларны актив куллана. Шунлыктан без күрүгә караганда күбрәк хәтерлибез һәм күзаллыйбыз дип исәплиләр тикшеренүчеләр.

Сизеп танып-белүнең өч формасы бар: тою, зиһенгә кабул итү, күзаллау. *Тою* — сизү тәҗрибәсенең башлангыч элементы. Ул предметларның безнең сизү әгъзаларыбызга турыдан-туры тәэсир итүе нәтиҗәсендә барлыкка килә. Без форманы, төсне, исне, ягъни предметның аерым сыйфатларын тоябыз. Аның бөтенлекле образын безгә зиһенгә *кабул итү* бирә. Ул, пред-

метның формасын, фәзадагы (пространстводагы.— *тәрҗ.*) торышын чагылдырып, аны тирәлектәге фоннан аеру мөмкинлеге бирә. Зиһенгә кабул итү шулай ук күзаллауларны формалаштыру өчен нигез булып хезмәт итә. Предметның сизү әгъзаларына йогынтысы беткәч, аның турындагы тәэсир хәтергә сеңеп саклана. Предметлар һәм күренешләрнең аңда аларның турыдан-туры тәэсиреннән тыш саклана торган хисси образы *күзаллау* дип атала. Кеше кайчандыр күргәнне күзаллый, элек кабул иткәнне сурәтли ала. Шул ук вакытта аның асыл үзенчәлекләре сакланып, кайбер детальләре, аерым сыйфатлары югалырга мөмкин. Андый образны без «гомумиләштерү» дип атыйбыз.

Кешедә ниндидер сәбәпләр аркасында «дөньяга тәрәзәләр» ябылса, ул әйләнә-тирә чынбарлыкта юнәлеш таба алмый торган ярдәмчесез бер затка әверелә. Мондый кешеләрне тирәлек мохитендә җайлашуга тәрбиячеләрнең үз карамагындагы кешеләрне «кулга кул» (бармак әлифбасы) принцибында махсус рәвештә озак вакыт һәм җентекләп өйрәтүе генә ярдәм итә ала. Моны безнең илдә сукыр-чукрак-телсез балаларны өйрәтү тәҗрибәсе күрсәтте.

Шуның белән бергә, безнең хисләребез алар нормаль эшләгәндә һәрвакытта да чын күренешне биреп бетермиләр. Мәсәлән, чәйле стаканга төшерелгән кашык безгә кәкрәйгән кебек күренә. Социаль тормыштагы күп күренешләр һәм процесслар сизеп кабул ителәләр, (мәсәлән, барча рухи кыйммәтләр — инану, ышану, намус). Хисләр ярдәмендә социаль төркемнәрне, товар бәясен һәм башка күп нәрсәләрне чагылдырып булмый.

Бу исә кайбер философларга сизеп танып-белү мөмкинлекләрен кире кагарга яки киметеп күрсәтергә сәбәп була. Мәсәлән, Платон чын белем фәкать фикерләүгә нигезләнгән генә була ала (мәсәлән, математика) дип исәпли. Яңа вакытта барлыкка килгән фән, дөрес белем алу өчен сизеп тою тәҗрибәсе аерым шартлар барлыкка килгән экспериментта тикшерелергә, шулай ук математик эшкәртелергә тиеш дигән күзаллауга нигезләнә.

РАЦИОНАЛЬ ТАНЫП-БЕЛҮНЕҢ АСЫЛЫ ҺӘМ ФОРМАЛАРЫ

Кабул итү һәм күзаллау үзенчәлекләреннән күренгәнчә, алар билгеле бер дәрәҗәдә сизеп танып-белү кысаларыннан чыга: предметны зиһенгә кабул итү хәтеребездә саклаучы шундый ук образлар белән тиңләшүне күздә тота; күзаллауда бер сыйфатлар югала, икенчеләре башка әһәмият ала. Бу — кирәк-

ләрәкне табу, гомумиләштерү һәм ныгыту буенча фикерләү эшчәнлегенең башлангычы. Шулай итеп, танып-белү процессында хиссине һәм рациональне аеру практик яктан мөмкин түгел.

Психологлар рациональ танып-белүне — фикерләүне — проблеманы хәл итү процессы дип билгели. Аларның башлангыч шартлары безгә сизү әгъзаларыбыз аша сизелә торган чынбарлык белән биреләләр (без гадәттә тормыш яңа проблемалар куйды дибез). Ә менә проблеманы хәл итүдә кирәкле нәтиҗә алуда безгә күпчелек үз фикерләү мөмкинлекләребезгә таянырга туры килә. Без чын процесслар һәм күренешләр турында мәгълүмат алабыз, ул мәгълүматны, бездә булган тәҗрибә белән бәйләп, үзгәртәбез. Үзгәртү исә үзе төрле фикерләү эшчәнлекләрен: анализлауны, синтезлауны, чагыштыруны, абстрактлауны, гомумиләштерүне һ.б. таләп итә.

Танып-белү эшчәнлеге нәтиҗәләренең берсе һәм бер үк вакытта инструменты — *аңлау*. Философлар аны предмет өлкәсеннән аерылып чыгучы һәм объектларны аларның гомуми һәм аерым сыйфатларына карап классларга җыючы фикер дип билгелиләр.

Бу билгеләмәне «кылыч» төшенчәсе мисалында тикшереп карыйк. Аңлатмалы сүзлектән укыйбыз: «Кылыч — бер йөзе генә үткен кәкре озын пластинкадан гыйбарәт корал». Күрәбез ки, кылыч корал классына кертелгән, аның әлеге предметны шушы ук класска керүче башка әйберләрдән аеру мөмкинлеге бирә торган билгеләре (состав өлеше, коралның үзенчәлекләре) күрсәтелгән.

Мантыйк күзлегеннән караганда, һәр төшенчәнең күләме — реаль объектлар җыелмасыннан аерылып торучы һәм төшенчәдә гомумиләштерелүче объектлар классы һәм нәкъ менә шушы предметка хас булган эчтәлеге бар. Мантыйкта эчтәлек белән күләм арасындагы кире нисбәт законы билгеле: төшенчәнең күләме зуррак булган саен, аның эчтәлеге, ягъни конкрет аерым билгеләре шул кадәр ярлырак була. «Социаль төркем» һәм «урта сыйныф» төшенчәләрен чагыштырыйк. Беренчесе күләме буенча шактый киң, аңа урта сыйныф белән бергә башка төркемнәр, шул исәптән бүтән нигезләмәләр буенча аерып күрсәтелгәннәре дә керә. Ә шул ук вакытта икенче төшенчә әлеге төркемне, әйтик, элита катлавыннан яки авыл хуҗалыгы эшләре төркеменнән аеру мөмкинлеге бирүче конкрет характеристикаларга, билгеләргә баерак.

Сөйләмдә аерым сүзләр белән белдерелгән төшенчәләр, эшләрнең ниндидер бер халәттә булуын яки булмавын раслаучы *фикер йөртү* — уй барлыкка китереп, үзара берләшәләр. Үз чиратында, фикер йөртүнең билгеле бер бәйләнеше безне

нәтиҗә ясауга китерә. Кайбер фикер йөртүләрдән без, аларда булган мәгълүматларны үзгәртеп, нәтиҗә ясыйбыз. Мәсәлән, имезүчеләрнең тешләренең тамыры бар дип раслыйбыз. Болай дип фикер йөртүдә гомумилекнең төрле дәрәҗәдәге берничә төшенчәсе үзара бәйләнгән: теш тамырлары, тешләр, имезүчеләр (ул монда киңрәк төшенчә). Беренче фикер йөртүгә икенчесен өстик: эт — имезүче. Ике фикер йөртүне бәйләүче логик ахыр нәтиҗә ясау булачак: этнең тешләренең тамырлары бар.

Йомгаклап тагын шуны әйтик: сизеп һәм рациональ танып-белүнең аерым формаларының, шулай ук танып-белүнең бу ике төренең аерылгысыз бәйләнеше бар. Без инде сизеп танып-белүнең зиһенгә кабул итү һәм күзаллау кебек формаларында фикер йөртү элементлары булуын билгеләп үткән идек. Беренче яшьтәге балаларны күзәтү тою әгъзаларының акыл сәләтен үстерүен күрсәтте. Мәсәлән, вакытыннан алдан туган һәм массаж курсы үткән сабыйларның акыл һәм физик яктан үз яшьтәшләреннән күбрәк мөмкинлекләргә ия булулары расланды. Галимнәр шулай ук баланың, авызына берәр әйбер капкач, сизгеррәк тою әгъзаларын — телне һәм иреннәрне файдаланып, аның тәмен белергә генә теләмәвен ачыкладылар. Тою аркылы әйбернең формасын яки катылыгын белергә теләп, бала бер үк вакытта башка сизү әгъзаларын да (мәсәлән, күрүне) үстерә.

Төп төшенчәләр: белем, танып-белү эшчәнлеге, онтология, гносеология, сизеп танып-белү, рациональ танып-белү, тою, зиһенгә кабул итү, күзаллау, төшенчә, фикер йөртү.

Терминнар: агностицизм, априор идеяләр, фикерләү операцияләре, абстракцияләү.

Үзегезне тикшерегез

1. «Яшәеш» категориясенең фәлсәфи мәгънәсе нидән гыйбарәт? 2. Нәрсә ул онтология? 3. Философия тарихында яшәеш һәм танып-белү (аң) нисбәте мәсьәләсе ничек хәл ителгән? 4. Гносеология нәрсәне өйрәнә? 5. Дөньяның танып беленүе турындагы фәлсәфи мәсьәләнең мәгънәсе нидән гыйбарәт? 6. Эшчәнлекнең бер төре буларак, танып-белүнең структурасы нинди? 7. Танып-белү эшчәнлегендә субъектның роле турындагы күзаллаулар ничек үзгәргән? 8. Сизеп танып-белүнең төп формалары нинди? Аларны кыскача тасвирлагыз. 9. Дөньяны танып-белүдә сизеп танып-белүнең ролен һәм чикләрен ачып бирегез. 10. Рациональ танып-белүнең төп формаларын атагыз. Аларны кыскача тасвирлагыз. 11. Сизеп һәм рациональ танып-белүнең аерылгысыз бәйләнеше нәрсәдә чагыла?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Чагыштыруның түбәндәге линиясен файдаланып, танып-белү һәм хезмәт эшчәнлеген чагыштырыгыз: эшчәнлекнең максатлары, эшчәнлек объектлары, эшчәнлек субъектлары, үзенчәлекле чаралар, эшчәнлекнең турыдан-туры нәтиҗәсе.

2. Танып-белүдә субъектның ролен чагыштыручы өч позицияне карагыз, аларның һәрберсен мисал белән күрсәтергә тырышыгыз:

— тышкы дөнья процессларына һәм күренешләренә йогынты ясамаучы читтән күзәтүче;

— өйрәнелә торган әйбергә аңлы рәвештә йогынты ясаучы яңартып коручы;

— үзенең юнәлтелгән игътибары белән тышкы хәлгә йогынты ясаучы ирексездән бимазалаучы.

3. Бер философ танып-белү процессын суд белән чагыштырган: сизүнең биш әгъзасы — биш шаһит, хакыйкатьне фәкать алар гына белә ала. Әлеге фикерне дәвам иттерсәк, бу очракта кем судья була?

4. Философ болай дип раслый: «Безнең акылның барлык эш-хәрәкәтләре төрле әйберләрнең охшашлыгын һәм охшаш булмавын, туры килүен һәм туры килмәвен белә алу сәләтебездән тора. Ләкин бу сәләтләр физик сизгерлек кенә. Димәк, барысы да сизүгә кайтып кала».

Философ белән бәхәсләшегез.

5. Ике төрле фикер йөртүне чагыштырыгыз. Дөресен сайлагыз.

1) Барлык балалар да алма ярата.
Света — бала.
Димәк, Света алма ярата.

2) Барлык балалар да алма ярата.
Света алма ярата.
Димәк, Света — бала.

Чыганак белән эшләгез

Түбәндә Америка социаль психологы Р.Солсо китабыннан өзек китерелә.

БЕЗ ОБРАЗНЫ НИЧЕК ТАНЫЙБЫЗ

Без этне башта аның йонын, дүрт аягын, күзләрен, колакларын һ.б. күргәнгә таныйбызмы, әллә бу өлешләрне башта этне күргәнгә таныйбызмы? Бу проблема — тану паттерның (тулаем күренешнең) тулаемны тану өчен («астан өскә») хезмәт итүче өлешләрне танудан башланамы, әллә ул аны бердәйләштерергә

ярдәм итүче тулаем турындагы гипотеза чыгарудан башланып, соңыннан аның состав өлешен күрәбезме («өстән аска») — «аналитик парадокс» дип атала.

Кайбер теоретиклар... билгеле бер хәлләрдә өлешләрне һәм бөтенне тану бер үк вакытта астан өскә һәм өстән аска таба булырга мөмкин дип фаразлаган...

Төрле контекстларда без билгеле бер объектларны күрүне көтәбез. Табиб бүлмәсендә — стетоскоп, аш бүлмәсендә — савыт-саба, офиста — язу машинкасы, урамда янгын кранын күрәбез. Мөгаен, «дөнья турында болай белү» объектларны таныш контекстларда бердәйләштерүне җиңеләйтәдер һәм туры килмәгән контекстларда да бердәйләшүгә комачаулыйдыр...

Паттерннарның һәм формаларның ничек танылуы турындагы гипотезаларның берсе «эталон белән чагыштыру» дип атала... Тормыш тәҗрибәсе туплау процессында тану турында шулай күзаллау нәтиҗәсендә бездә һәрберсе күпмедер әһәмияткә ия булган бик тә күп сандагы эталоннар барлыкка килә. Мәсәлән, геометрик фигураны күреп тану болай була: бу фигурадан чыккан яктылык энергиясе күзнең челтәр катлавына тәэсир итә һәм мигә баручы нерв энергиясенә әверелә. Булган эталоннар арасыннан эзләү башлана. Нерв паттернныкына туры килүче эталон булса, кеше ул паттернны таный. Объектны аның эталоны белән чагыштырганнан соң мәгълүмат алга таба эшкәртелергә һәм объект аңлашылырга мөмкин.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Аналитик парадоксның асылы нәрсәдә? 2. Кеше битенең аерым өлешләрен сурәтләп карагыз. Әгәр без аларны тулаем — бит белән чагыштырсак, ул өлешләр җиңел таныламы? Бу мисал алда китерелгән фрагментның кайсы фикерен күрсәтә?

Бу хакта бәхәсләшәләр

Интеллектны үлчәп буламы?

XIX гасыр ахырында тикшеренүчеләр акыллыларны тинтәкләрдән аера торган ниндидер универсаль табигый факторны табарга тырышканнар. Француз А.Бине мәктәптәге өлгерешне тикшерә торган Франция Белем бирү академиясе өчен игътибарга, хәтергә, уйлауга, эстетик хисләргә тест-сынаулар җыелмасы эшләгән. Нәтиҗәдә бүген билгеле булган интеллектуаль үсеш күрсәткече — IQ — «интеллект коэффиценты» барлыкка килгән. Шуннан бирле миллионнарча кеше әлеге күрсәткеч ярдәмендә үзенең интеллектын тикшергән. Шундый ук әлеге күрсәткечтән күпләгән компанияләрнең кадрлар хезмәтләре файдалана.

Әмма күп кенә галимнәр тестлар интеллектның үзен түгел, ә кайбер мәсьәләләрне чишү уңышлылыгын үлчи дип исәплиләр. Шул ук вакытта тикшерү нәтиҗәсенә йогынты ясаучы күпләгән һәм озак вакытлы (тикшерелүче яхшы мәктәптә укыганмы, әллә начарындамы), һәм кыска вакытлы факторлар (тестлаган чакта кешенең нәрсәдән дә булса кәефе кырылганмы) исәпкә алынмый.

§ 22. Хакыйкать һәм аның критерийлары

Исегезгә төшерегез:

фәлсәфи фикер тарихында яшәеш һәм танып-белүнең нисбәте турындагы мәсьәлә ничек чишелгән? Сизеп һәм рациональ танып-белүнең үзара бәйләнеше нәрсәдә чагыла? Танып-белүче субъектның танып-белүдәге ролен һәм урынын бәяләү ничек үзгәргән?

«Игелек» һәм «матурлык» төшенчәләре белән бергә, «хакыйкать» категориясен җәмгыятьнең төп кыйммәтләренә кертеп була. Рус философы В.С.Соловьев язганча, кеше өчен «аның ихтыяры предметы... объектив яхшылык, аның фикеренең предметы һәм эчтәлеге объектив хакыйкать һәм аның тою предметы объектив гүзәл булуы мөһим, ягъни аның өчен генә түгел, ә бәлки, һичшиксез, барысы өчен дә».

Нинди белемне чын дип исәпләргә, танып-белүче кешегә ул ни дәрәҗәдә ирешерлек һәм нинди ысуллар белән ирешелә дигән сораулар философиядә һәм фәндә тикшеренү предметлары булды һәм шулай булып калалар да.

Кайбер философларның дөньяны принципиаль танып-белеп булмауны раслауларын сез инде беләсез. Аларны «агностиклар» дип атаганнар. Ләкин чын белем алу мөмкинлеген танучылар да «хакыйкать» категориясен төрлечә аңлый һәм аның критерийларын төрлечә күрәләр.

ХАКЫЙКАТЬНЕҢ ОБЪЕКТИВЛЫЛЫГЫ

Хакыйкатьне ике классик билгеләүне китерик. Урта гасырлар фикер иясе Фома Аквинский: «Хакыйкать ул — әйбернең һәм күзаллауның тәңгәллеге»,— дип раслаган. XVII гасыр француз философы Р.Декарт: «Хакыйкать» сүзе фикернең предметка туры килүен белдерә»,— дип язган. Шулай итеп, хакыйкать дип карала торган предметның асылын һәм үзенчәлекләрен төгәл белдерүче белемне атарга була. Шуннан чын белемнең бик тә мөһим сыйфаты — аның объективлыгы, кеше аңына, аның теләкләренә һәм мәнфәгатьләренә бәйсез булуы чагыла.

Хакыйкатьне болай аңлату Аристотельгә барып тоташа. Ул хакыйкатьнең объективлыгын инкарь иткән һәм: «Кемгә нәрсә ничек тоела, шул дөрес»,— дип язган философ Протагор карашын тәнкыйтьли. Әгәр Протагор хаклы булса, дип фикер йөртә Аристотель, димәк, «бер үк нәрсә яши дә, яшәми дә, ул начар да, яхшы да; бер-берсенә каршы торучы башка фикерләр дә дөрес». Ләкин «бер-берсе белән бәхәсләшүче кешеләр фикеренә бер үк төрле бәя бирү акылсызлык: чөнки аларның берсе ялгыш булырга тиеш бит».

Инде билгеләп үтелгәнчә, алга таба субъектның танып-белү процессындагы роле, аның чараларга гына түгел, ә бәлки танып-белү эшчәнлеге нәтиҗәсенә дә йогынтысы һаман саен ныграк ачыклана бара.

Шулай да, предмет аңа турыдан-туры булмаган формаларда — сизеп күзаллау һәм рациональ фикерләү аша бирелгәч, кеше предмет турындагы үз белемнәренең хаклыгына ничек ышана ала дигән төп сорау кала. Менә монда безгә алган белемнәребезнең чын хаклыгы турында нәтиҗә ясау мөмкинлеге бирә торган күрсәткечләр проблемасы килеп туа да инде.

Фән хакыйкать критерийларын, хакыйкатьне нигезләү ысулларын сайлап алуга һәм тикшерүгә аеруча катгый карый.

ХАКЫЙКАТЬНЕҢ КРИТЕРИЙЛАРЫ

Философия тарихында, аеруча Яңа вакытта, вәкилләре сизү һәм акылның танып-белүдә тоткан ролен төрлечә билгеләгән ике юнәлеш аерылып тора. *Эмпириклар* барлык белемнәрнең чыганагы һәм нигезе дип сизү тәҗрибәсен саныйлар. Әлеге юнәлеш үзенең чик формасында сенсуализмда (латинча sensus — сизү, тою) — тою — белемнең бердәнбер чыганагы һәм нигезе дип санаган фәлсәфи агымда чагыла. Идеалистик сенсуализм, фикерләүне тоюдан чыккан дип карап, кешенең «Мин»ен тоюлар комплексына кертә.

Эмпиризмның чикләнгәнлеге бүген шактый ачык күренә. Беренчедән, инде билгеләп үтелгәнчә, зиһенгә кабул итү һәм күзаллау дәрәҗәсендә дөньяныңербөтен күренеш алуы өчен безнең аңыбыз гомумиләштерелгән белемнәр элементларын файдалана; шулай булмаса, безнең сизү тәҗрибәбез чынбарлык турында ялгыш күзаллау бирергә мөмкин. Икенчедән, фәнни белем нигезендә туучы күп кенә теоретик постулатларны тәҗрибә юлы белән нигезләп булмый. Моннан тыш тәҗрибә үзе һиндидер башлангыч түгел, без чынбарлыкны билгеле бер чагылу почмагы аша «күрәбез», игътибарны безнең өчен теге яки бу сәбәпле әһәмиятле булган аерым объектларга туплыйбыз; кыскасы, сизү тәҗрибәсе — аңлау, ачыклау нәтиҗәсе ул.

Башка юнәлеш вәкилләре — *рационалистлар* өчен хакыйкать критерие булып акыл санала. Чын белем үрнәге итеп күренеп торган хакыйкатьләрдән башлаучы һәм бәхәссез шартлардан яңа белемнәрне логикалы чыгару ысулларын кулланучы математика алына. Шуның белән бергә, танып-белүнең әлеге фундаменталь һәм бәхәссез нигезләрен билгеләү рационализм өчен катлаулы проблема булып кала. Декарт аларны «тумыштан идеяләр» дип исәпли, немец тикшеренүчесе Лейбниц андый нигезләр булып «тумыштан дөрес сиземләү» хезмәт итә дип уйлый. Рационализмга хас булган танып-белүнең дөрес сиземләү (интуитив) турындагы күзаллаулары евклидча булмаган геометрия ачылгач какшап кала. (Евклид геометриясе озак вакытлар теоретик нигезләнгән белем идеалы булып саналган.) Евклид, Лобачевский һәм Риман аксиомалары системасының һәркайсы теоретик яктан катгый булганлыктан, аларның кайсысы чынлыкка туры килә, кайсысы хакыйкать соң дигән сорау туа.

Күпләгән тикшеренүчеләр рационализмны кеше эшчәнлегендә һәм җәмгыять үсешендә акылның һичшиксез өстенлегенә дәгъва кылулары өчен тәнкыйтьлиләр.

Кайбер галимнәр, чын фәнни белемне билгеләүнең нигезендә тикшеренүчеләр арасындагы килешү — «конвенция» ята дип исәпләргә тәкъдим итәләр. Мәсәлән, француз математигы, физигы һәм философы *А.Пуанкаре* (1854–1912) болай дип яза: «Евклидның төп нигезләмәләре дә шул килешүнең асылы; «метрик система чынмы яки ялганмы» дигән сорауны биргән кебек үк, алар чынмы яки ялганмы дип төпченү дә шулкадәр үк акылсызлык булыр иде. Әлеге килешүләр генә уңайлы».

Болай якын килгәндә, безнең белемнәребезнең дөрес яки ялган булуы турындагы сорау актуаль түгел. Ләкин төрле юнәлешләр философларының үҗәтлек белән аңа кире әйләнеп кайтулары аның бүген дә үз әһәмиятен саклавы турында сөйли.

Күрсәтелгән карашларның берьяклылыгын бетерергә тырышканда, хакыйкатьнең төп критериена тагын бер караш туа. Гади бер мисал алыйк. Әйтик, кеше ак фонда кара тап күрә. Әмма ул чынлыкта бармы соң? Әйе, диярләр кайберәүләр, әгәр аны башка кешеләр дә күрсә. Ләкин, бәлкем, эш шунда — барча кешеләрдә дә зиһенгә кабул итүнең психофизиологик механизмы берүктер? Сизү тәҗрибәсе кысаларыннан ничек чыгарга? Бу төрле юллар белән мөмкин. Беренчедән, махсус приборлар кулланып эксперимент кую. Икенчедән, күзәтелә торган күренешнең башка берсе белән практик үзара эш итүен булдыру. Көтелгән нәтиҗәгә ирешү-ирешмәвебезгә карап, беренче фикеребезнең дөресме-түгелме икәне турында әйтергә була. Әлеге һәр ике юл да хакыйкать критерие булып каралучы

«практика» төшенчәсенә карый. Өстәвенә әлеге төшенчә киң аңлатыла: аңа матди җитештерү дә, тупланган тәҗрибә дә, фәнни эксперимент та керә.

Кешеләрнең танып-белү эшчәнлегендә практиканың әһәмиятле роль уйнавын инкарь итү мөмкин түгелдер. Практик ихтыяҗлар фәнни белемнең күп тармакларын булдырды. Тарих курсыннан белгәнегезчә, җир эшкәртү һәм диңгездә йөзү ихтыяҗлары астрономия, геометриянең үсүенә этәргеч бирде. Җитештерү даирәсе фәнни тикшеренүләр өчен кешенең танып-белү мөмкинлекләрен шактый киңәйтүче приборлар һәм аппаратлар булдыра. Һәм, ниһаять, бөтен кешелек дөньясының аның тарихи үсешендәге тәҗрибәсе безнең белемнәребезнең дөреслегенең «иң югары хөкемдары» булып тора. Бу күзлектән караганда, предметлар һәм күренешләр турындагы белемнәр, әгәр алар ярдәмендә без теге яки бу реаль әйберләрне эшли, максатка ярашлы үзгәртеп коруларны гамәлгә ашыра алсак, дөрес дип санала ала.

Шуның белән бергә, күп кенә философлар практиканы хакыйкать критерие сыйфатында тану проблеманы ахыргача чишү була алмый дип исәпли.

Беренчедән, практика хакыйкатьнең универсаль критерие булып карала алмый. Мәсәлән, укучы мәсьәләләр чишкәндә алган нәтиҗәләрне турыдан-туры реаль чынбарлык белән түгел, ә үзе уку чорында алган теоретик белемнәр белән (законнар, кагыйдәләр, аксиомалар, элек исбатланган нигезләмәләр белән) чагыштырып карый. Галим үзенең фәнни эшчәнлеге вакытында тәкъдим ителгән идеяләрне раслау өчен күп очракларда экспериментка гына түгел, ә тиешле теориягә дә таяна. Математика фәннәрендә нигезләмәләрне раслау һәрвакыт теоретик дәлилләү белән тәмамлана: әлеге нигезләмәләр дөреслегенең критериен теория тәшкил итә.

Икенчедән, практик уңышны тәкъдим ителә торган теорияләрнең дөреслеген күрсәтүче итеп карасак, белемнең үсүе принцибыннан баш тартырга туры киләчәк: практик бурычны чишеп булгач, димәк, предмет турында тулы белем алуга ирешелде, тулы хакыйкать алынды. Монда инде без абсолют һәм чагыштырмача хакыйкатьләрне аеру проблемасына килеп җитәбез.

АБСОЛЮТ ҺӘМ ЧАГЫШТЫРМАЧА ХАКЫЙКАТЬ

Абсолют хакыйкать — шиксез, үзгәрешсез, мәңгелеккә билгеләнгән белем. Абсолют хакыйкать предметны тулысынча танып белә һәм белемне алга таба үстерүдә кире кагыла алмый. Мондый белемгә ирешеп буламы? Мәсәлән, өчпочмакның эчке

почмаклары суммасы һәрвакыт 180° ка тигез дип раслауны абсолют хакыйкать дип буламы? Ләкин башка геометрик системаларда ул ялгыш. Моннан тыш абсолют белемгә дәгъва итү тәнкыйдилек күрсәтмәсенә — фәнни белемнең зарури чигенә каршы килә. Чөнки белем фикерләүнең актив эшләвен күздә тота, ә уйлау, — димәк, шикләнү ул.

Философларның күпчелеге абсолют хакыйкатьне үрнәк (идеал) яки безнең белемебез омтылган чик дип карый. Бу максатка бару юлында без *чагыштырмача хакыйкать*, ягъни тулы булмаган, чикләнгән белем алабыз. Белемнәребезнең чикләнгәнлеге кайбер сәбәпләргә бәйле. Барыннан да элек дөнья үзе һәрвакыт туктаусыз үзгәреп тора. Инде билгеләп үтелгәнчә, кешенең танып-белү мөмкинлекләре дә чикләнгән. Моннан тыш танып-белү мөмкинлекләре үз вакытының реаль тарихи шартларына бәйле һәм рухи мәдәниятнең, матди җитештерүнең үсеш дәрәҗәләре, булган күзәтү һәм эксперимент чаралары белән билгеләнә.

Нәтиҗәдә танып-белү эшчәнлегенең һәр этабында без тулы булмаган, тәмамланмаган, мәңгелек булмаган белемнәр алабыз. Ләкин белемнәр туплана барган саен, бер төрле чагыштырмача хакыйкатьләр икенчеләре, тулыраклары һәм тирәнрәкләре белән алышына. Кайбер философлар танып-белү юлын ачылган һәр хакыйкатьнең алдагысына «басма» булган баскыч белән чагыштыралар.

Конкрет мисалга мөрәҗәгать итик. Кешеләрнең Галәмнең төзелеше турындагы белемнәре һәм күзаллаулары ничек үзгәрүен карыйк. Әле борынгы кешеләр үк, күк күренешләрен күзәтеп, Ай һәм Кояштан башка тагын күктә даими күчеп торучы биш яктырткыч барын белгәннәр. Аларны «планеталар» дип атаганнар. Астрономик күзәтүләр елның дәвамлылыгын билгеләү, беренче календарьлар төзү мөмкинлеге биргән. Шуның белән бергә, Җир — хәрәкәтсез яссы җисем, аның тирәсендә Кояш, Ай, планеталар әйләнә дигән күзаллау хакимлек иткән. Б.э.к. II гасырда борынгы грек астрономы Птолемей дөнья төзелеше турында үз системасының төп принцибын тәкъдим итә: шар формасындагы Җир — Галәмнең хәрәкәтсез үзәге. Бу караш мең ярым ел чамасы яши. Эш аның дөньяның дини картинасына туры килүендә генә дә түгел. Ул күзаллауда, аерым алганда, планеталар хәрәкәте траекторияләренә нисбәттә, чын белемнәр элементлары була: ул планеталарның хәрәкәтен алдан исәпләп чыгару мөмкинлеге төзү өчен кирәк була.

XVI гасырда Польша астрономы Н.Коперник күзәтүләр һәм катлаулы математик исәпләүләр нигезендә ышандырырлык итеп, Җир — планеталарның берсе, һәм барлык планеталар Кояш тирәсендә әйләнә дип күрсәтә. Шул вакытта Коперник

йолдызларны — хәрәкәтсез, ә планеталарның хәрәкәт орбиталарын түгәрәк дип исәпли. Тарих курсыннан сез әлеге яңа тәгълиматның язмышы драматик булуын, католик чиркәү тарафыннан каты җәзалануын беләсез.

Өч чирек гасыр үткәч, немец галиме И.Кеплер, планеталарның орбитасы эллипс формасында, дип дәлилли һәм планеталар хәрәкәте законын чыгара. Италия галиме Г.Галилей үз күзәтүләре белән Кеплер тәгълиматының дөреслеген раслый.

Галәмне тикшерүдә яңа сәхифә XVIII гасыр ахырында инглиз галиме И.Ньютон тарафыннан ачыла. Нәкъ менә ул, бөтендөнья тартылу законын ачкан кеше, планеталар хәрәкәтенең чын сәбәбен ачыклый. (Кеплер исә, ялгышып, Кояшны гигант магнит белән чагыштыра, планеталар орбита буенча аның магнетик йогынтысы астында хәрәкәт итәләр дип уйлый.)

Хәзерге галимнәр, тикшеренүләрнең өр-яңа ысулларын кулланып, Галәм ни өчен киңәя, галактикалар ничек барлыкка килгән дигән башка мәсьәләләрне ачыкларга тырышалар.

Шулай итеп, кайсыдыр сорауларга җавап алып кешенең танып-белүче акылы яңа проблемалар куя һәм аларны чишү юлларын эзли.

ХАКЫЙКАТЬ ҺӘМ ЯЛГЫШУ

Әгәр без танып-белүнең шундый да куәтле һәм нәтиҗәле инструменты — баш миенә иябез, хакыйкатьнең нәрсә икәнен беләбез, чын белемнәргә омтылабыз икән, ни өчен кешелек дөньясының тулаем һәм аерым алганда һәркемнең ялгышуы шулкадәр күп соң? (Монда без махсус эшләнгән ялгышны, фактларны аңлы рәвештә буташтыру очракларын күздә тотмыйбыз.)

Безнең ялгышуларыбызның сәбәпләре кайчакта кешенең кайбер танып-белү үзенчәлекләрендә ята. Чын белем юлыннан алып китүче ул үзенчәлекләр турында әле XVI гасырда ук инглиз философы Ф.Бэкон язган. Ул аларны балбаллар (ташлар) дип атаган. Аерым алганда, «балбаллар ыругын» (ягъни чыганаклары кешенең үзенең табигатендә яткан ялгышуадашуларны) ул болай тасвирлаган: «Кешенең асылы әйберләр табигатенә үз табигатен кушып, әйберләрне бозып һәм мәсхәрәләп күрсәткән кәкре көзгегә охшаш. Кешеләр өлешенә танып-беленә торган дөньяның фәкать «кәкрелегән» һәм «мәсхәрәләп күрсәтүен» генә калдыру гадел түгелдер, мөгаен. Ләкин кешенең, хәтта читтән күзәтүче булып калырга тырышып та, ирексездән танып-белү процессына һәм нәтиҗәләренә йогынты ясавын бүген, инде билгеләп үткәнебезчә, күпчелек тикшеренүчеләр таный. Бэкон заманнарыннан бирле хакыйкатьне

бозып күрсәтүче, ялгышуга этәрүче андый «аң балбаллары» исемлеге тагын да тулыландыр.

Соңрак чорда — узган гасыр башында, Австрия физигы һәм философы Э.Мах үз тикшеренүләренең берсен ялгышу проблемасына багышлый. Гәрчә аның безне чолгап алган әйберләрне безнең тоюларыбыз комплексы дип караны идеясе фәндә һәм философиядә тәнкыйтьләнсә дә, аның ялгышуга карата булган кайбер карашларын бик тә дөрес дип табып була. Мәсәлән, тикшеренүче, аларның сәбәпләрен табу өчен, фән тарихыннан һәм аерым кешеләр тәҗрибәсеннән танып-белү эшчәнлеге уңышсыз тәмамланган реаль очракларга мөрәҗәгать итәргә, шулай ук ул вакытта яңа фән булган психология казанышларын киң файдаланырга кирәк дип исәпли.

Бүгенге психология зиһенгә кабул итү һәм фикерләүнең безне ялган нәтиҗәләргә китерүе ихтимал булган кайбер механизмнарын ачыклады.

Аерым алганда, безнең гомум кабул ителгән фикерләр яклы булуыбыз яхшы билгеле (гәрчә алар чын фактларга һәм фәнни нигезләнгән нәтиҗәләргә туры килмәсәләр дә). Фикерләүнең кайберләре стихияле төстә барлыкка килә, икенчеләре пропаганда яки реклама тарафыннан көчләп тагыла. Мәсәлән, озак вакыт күпләр «симезлек, тулы тәнлелек — сәламәтлек билгесе» дип ышандылар. Мондый караш медицина белгечләре киресен раслаганда да сакланды. Социаль мифлар, мәсәлән, һәрбер хакимият — Алладан дигән ышану гасырлар дәвамында сакланып килә.

Кешеләргә шулай ук чынлыкта ул булмаган әйбер-вакыйгалар арасында элемтә урнаштыру хас. Мәсәлән, җир тетрәүләрнең (күпме генә еракта булмасын) аларның үзләрен хис итүләренә тәэсире бар дип исәпләүче кешеләр очрый. Без беренче тойгы-тәэсиргә артык ышанабыз, үзебезнең карашларны уртаклашкан кешеләр санын арттырып күрсәтергә яратабыз.

Ләкин хакыйкать урнашуга комачаулаучы төп нәрсә — фән теле белән әйткәндә, безне кызыксындырган предмет турында тулы һәм төгәл мәгълүмат, шулай ук аны эшкәртү өчен кирәкле чаралар булмау. Әлбәттә, бөтенесен колачлаучы (аеруча танып-белүнең катлаулы объекты турында) мәгълүмат туплау мөмкин түгелдер. Шунлыктан безнең белемнәребез чагыштырмача хакыйкать барлыкка китерә дибез. Әмма бик яхшы билгеле булганны да һәрберебез дә исәпкә алып бетермибез: кемгәдер ваграк нәрсә булып тоела, кайсысындыр «гомумурнашкан карашларга туры килми» дип кире кагабыз. Психологлар моны танып-белү энергиясен экономияләргә тырышуыбыз белән аңлаталар. Мәгълүматларның ташкын

рәвешле артуы сәбәпле, без котылгысыз төстә танып-белү «саранннарына» әвереләбез. Чөнки безнең мәгълүматны фикерләп бетерү сәләтебез чиксез түгел, без күп мәгълүматны кире кагабыз, катлаулысын гадиләштерәбез, еш кына хәлне анализлауга түгел, ә гадәтләнгән схема — стереотиплар куллануга нигезләнгән карар кабул итәбез.

Шуңа күрә безнең нәтиҗәләребез еш кына өстән-өстән, ә кайчак ялгыш була. Мәсәлән, кибеттә нинди дә булса ашамлык сатып алганда, без иң элек аның төргәгендәге матур рәсемгә игътибар итәбез һәм ул сурәт төргәк эчендәге әйбергә туры килә дип уйлыйбыз. Шул ук вакытта әлеге төргәктәге, кагыйдә буларак, ашамлыкның составы, аның азыклык кыйммәте, әзерләүче фирма турында шактый тулы һәм файдалы мәгълүмат бирүче текстка сирәк мөрәҗәгать итәбез. Нәтиҗәдә сатып алынган әйбер безнең өметләребезне һәрвакытта да аклап бетерми.

Дөнья һәм кеше турында объектив, чын белемнәрне беренче чиратта фән табарга тиеш. Фәнни танып-белүнең үзенчәлекләре турында сүз алдагы параграфта булыр.

Төп төшенчәләр: эмпиризм, рационализм, хакыйкать критерие буларак практика, чагыштырмача хакыйкать, абсолют хакыйкать.

Терминнар: сенсуализм, критерийлар.

Үзегезне тикшерегез

1. Фәлсәфи төшенчә буларак хакыйкатьнең классик билгеләмәсе нинди? 2. Хакыйкатьнең объективлыгы нәрсәдә чагыла? 3. Эмпириклар фикеренчә, безнең белемнәребезнең дөреслеге нәрсә белән тәэмин ителә? 4. Эмпиризмның танып-белүдәге һәм дөньяга караштагы чикләнгәнлеген күрсәтегез. 5. Рационалистлар күзлегеннән караганда, хакыйкатьнең төп критерие нинди? 6. Мондый карашның җитешсезлеге нәрсәдә? 7. Хакыйкать критерие буларак, практика нәрсәләрне үз эченә ала? 8. Танып-белү эшчәнлеге нәтиҗәләрен бәяләүдә «практика» критерием куллану мөмкинлекләрен һәм чикләрен ачып бирегез. 9. «Абсолют хакыйкать» төшенчәсенә билгеләмә бирегез. 10. Без тапкан хакыйкатьләрнең чагыштырмачалыгы нәрсәдә чагыла? 11.Философлар һәм психологлар фикеренчә, кешенең ялгышуының чыганаклары нинди?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Түбәндәге сүзләрнең авторлары эмпирикларга керәме, әллә рационалистларгамы?

«Иң югары бәхет хисләрдә түгел, ә акылда тупланган... камил акыл — кешегә хас бәхет ул, ә калган барлык хисләр хайваннар һәм үсемлекләргә дә хас».

«Хакыйкать исәп-хисаплар белән таныл-беленмә; бернигә карамастан, кешелек дөньясын күтәрелешкә алып баручы бөек Дөреслекнең кайда яшәвен фәкать йөрәк теле генә белә».

«Мантыйк, хакыйкатьне эзләүдән бигрәк, нигезләре гомум кабул ителгән төшенчәләрдә булган ялгышуларны ныгытуга һәм саклауга хезмәт итә».

2. Бер фәлсәфи бәхәстән өзек укыгыз.

«Гилас. Без аның чын табигатен яисә аның нәрсә булуын белә ала торган бернәрсә дә юк.

Филониус. Син ут яисә суның нәрсә икәнен чынлап та белмим дип әйтергә телисеңме?

Гилас. Син утның кайнар икәнен, суның акканын белә аласың, әлбәттә; ләкин бу ут белән су синең сизү әгъзаларыңа кагылгач, синең үз күңелеңдә нинди хисләр барлыкка килүне белүдән артыкны аңлатмый. Аларның эчке төзелешләренә, хакыйкый һәм чын табигатенә килгәндә исә, бу мөнәсәбәттә син бөтенләй дә караңгылыкта каласың» (Д.Беркли).

Гиласны агностикларга кертеп буламы? Үз нәтиҗәгезне дәлилләгез.

3. Узган гасыр башы рус фикер иясе А.А.Богданов абсолют хакыйкатьләрнең булуын инкарь итә. Үзенең «Ышану һәм фән» дигән мәкаләсендә ул Ф.Энгельс, аннары В.Ленин кулланган «Наполеон 1821 елның 5 маенда үлгән» дигән хакыйкать мисалын тәнкыйть итә.

Түбәндәге дәлилләрне китереп, Богданов әлеге хакыйкатьнең чагыштырмачалыгын исбатлый: а) елны исәпләү 1821 елга астрономик календарьдан 13,5 сәгатькә артта калган григориан календаре буенча алып барыла; б) үлем сулыш алу, йөрәк тибү тукталгач теркәлгән; медицина дөньясында ирешелгән килешү нәтиҗәсендә, аларны үлем билгеләре дип исәплиләр (бәлки, киләчәктә үлемне башка билгеләр буенча исәпләрләр); в) «Наполеон» төшенчәсе чагыштырмача — кешенең «Мин»е физиологик һәм психик яшәве дәвамында берничә тапкыр яңара; үлә башлаган Наполеон, асылда, мәсәлән, Аустерлиц янындагы сугыштагы Наполеон кебек булмаган инде.

Сез авторның хакыйкатьнең чагыштырмачалыгы турындагы әлеге өзектә китерелгән фикерләрен уртаклашасызмы? Китерелгән документларның ышандырырлык икәнен бәяләгез.

Чыганак белән эшләгез

В.С.Соловьевның беренче тапкыр 1879–1881 елларда басылган бер хезмәтеннән өзек укыгыз.

Ышану (инану) һәм белем

Бездән тыш һәм бездән бәйсез рәвештә нәрсә дә булса яшиме — без моны белә алмыйбыз, чөнки без белгән (реаль) бар нәрсә, ягъни без тойган һәрнәрсә бездән читтә түгел, ә бездә яши (сизү-тоюларыбыз һәм фикерләребез кебек үк); шулай ук — бездән тыш, үз эчендә, *шуның белән* безнең тәҗрибәбездән һәм, димәк, безнең чын белемебездән тыш булган һәм шул рәвешле безнең әлеге чынбарлык чикләреннән ышану дип аталган рух акты белән тотып алынуы аша гына расланырга мөмкин булган нәрсә дә.

Беләбез ки, $2 \times 2 = 4$, ут пешерә — бу, асылда, безнең аңыбыз фактлары; ләкин нәрсәнең дә булса безнең аңыбыздан тыш яшәве (мәсәлән, безгә ут эшен барлыкка китерүче төп асылның яки асылларның яшәве) аңның үзендә бирелә алмый, аның факты яки халәте була алмый, һәм, димәк ки, ул фәкать «күренми торган әйберләрне» раслаучы ышану акты гына була ала.

Ләкин әгәр тышкы чынбарлыкның *яшәве* ышану белән расланса, әлеге чынбарлыкның эчтәлеге (аның асылы, essentia) тәҗрибә белән бирелә: чынбарлыкның булуына без ышанабыз, ә *нәрсә* ул әлеге булу — без моны тоябыз һәм беләбез. Әгәр без тышкы чынбарлыкның яшәвенә ышанмасак, без тойган һәм белгән һәрнәрсә фәкать субъектив әһәмияткә генә ия булыр, фәкать безнең эчке психик дөньябыз мәгълүматларын гына күрсәтер иде. Әгәр без Кояшның бәйсез яшәвенә ышанмасак, Кояшны күзәллаудан торган барлык тәҗрибә материалы (яктылыкны һәм җылылыкны, Кояш дискы образын, аның күренүләренең периодиклыгын һ.б. тою) — боларның барысы да безнең өчен психик нигезләнгән субъектив аңыбыз халәте булыр иде...

Кояш турында без тәҗрибәбездән белгән бар нәрсә... һич тә Кояшның чынбарлыгы өчен түгел, фәкать безнең чынбарлыгыбыз өчен генә җаваплы булыр иде. Ләкин, әгәр без беренчесенә ышанабыз икән, Кояшның объектив яшәвенә ышанабыз икән, Кояш турындагы барлык тәҗрибә мәгълүматларыбыз әлеге объектив нәрсәнең безгә тәэсире булып тора һәм шул рәвешле объектив чынбарлык рәвеше ала...

Әлеге тәҗрибәләр, тышкы предметларның аларга туры килгәннәрнең булуына ышанганда, чынлап та булган нәрсә турындагы мәгълүматлар булып торалар һәм, шундый буларак, объектив белем нигезен тәшкил итәләр. Әлеге белемнең тулылыгы өчен булган нәрсәләр турында аерым мәгълүматларның үзара бәйләнгәнлеге, тәҗрибәнең тулы системага *оештырылуы* кирәк, моңа исә эмпирик материалга фәнни форма бирүче рациональ фикер йөртү белән ирешелә.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Автор фикеренчә, ни өчен без бездән тыш, бездән бәйсез рәвештә булган нәрсәне белә алмыйбыз? 2. Философ объектив чынбарлыкның булуын инкарь итәме? Тышкы дөньяның булуы турындагы сорауга билгеле бер җавап бирергә авторга нинди феномен ярдәм итә? 3. Сезнеңчә, ышанудан тыш объектив чынбарлыкның булуын раслаучы тагын нәрсә дә булса бармы?

§ 23. Дөньяны танып-белү юлларының күптөрлелеге

Исегезгә төшерегез:

> кеше тирә-юньдәге дөньяны ничек танып-белә? Нәрсә ул хакыйкать? Абсолют хакыйкать чагыштырмачасыннан нәрсәсе белән аерыла?

Белем һәм танып-белү турындагы фән тарихында белемнәрнең төрле төрләре тикшерелгән. Мәсәлән, антик вакытларда *белем* белән *фикер* арасында аерма куелган. «Фикер»нең «дөрес»леге мәҗбүри түгел, ә белем (билгеләмә буенча) — чын, дөрес. Фикер, гадәттә, аерым объектларга кагыла, белем исә берничә охшаш объектның гомуми сыйфатларын колачлый. Фикер үзгәрергә мөмкин, ул тотрыксыз, ә белемгә тотрыклылык һәм гомуми характер хас. Антик галимнәр еш кына белемне акыл хакыйкате — идеяләр белән тәңгәлләштергәннәр.

Урта гасырларда аеруча *белем* һәм *ышануның* нисбәте турындагы мәсьәлә борчыган. Алар арасындагы төп аерма дәлилләнелүдә күрелгән. Ышану моны күздә тотмаса, белем катгый, мантыйклы дәлилләүне таләп итә.

Яңа вакытта табигать фәннәре өлкәсендәге уңышлар белем һәм фәнне тәңгәлләштерүгә китерә. Фәнни белем *гносеологиянең* (танып-белү теориясенең) төп объектына әверелә. Ләкин нәкъ менә шул ук вакытта фәнне төрле: гадәти, мифологик, фәлсәфи дини, нәфис-образлы төрләргә аеру башлана.

Чынлап та, белем дөньясында рациональ һәм хисси, мантыйклы һәм мантыйксыз, фәнни һәм фәнни булмаганнар бергә килеп кушыла. Фән формалашканга кадәр дөньяны танып-белүнең башка ысуллары да була. Ләкин фән үскән бүгенге көндә, XXI гасыр башында да, күпчелек кешеләр дөнья турындагы күпчелек мәгълүматларны фәнни трактатлардан гына алып калмыйлар. Фән белән бергә, дөньяны танып-белү ысулы буларак, танып-белүнең башка юллары да бар. Бу параграфта сүз шулар турында барачак.

МИФ ҺӘМ ДӨНЬЯНЫ ТАНЫП-БЕЛҮ

Табигый һәм иҗтимагый чынбарлыкны танып-белүнең иң элекке ысулы миф булган. Борынгы халыклар мифларының шигърилегенә, сихрилегенә кайсыбыз гына сокланмаган? Миф ул һәрвакыт бәян итү; аның дөреслеге шик тудырмаган, ә эчтәлеге һәрвакыт (тегеләйме, болаймы) кешеләрнең реаль тормышы белән бәйле булган. Дөньяны аңлатырга, сәбәп һәм нәтиҗә арасында үзара бәйләнеш урнаштырырга омтылучы фәннән аермалы буларак, миф аңлатуны дөньяның яки аның аерым өлешләренең барлыкка килүе, яратылуы турында сөйләү белән алыштыра.

Мифта сурәтләнгән барлык нәрсәләр яңартып сөйләү өчен үзенчәлекле үрнәк әһәмияте ала. Ул үзендә мәҗбүри төстә үткән турында сөйләүне һәм бүгенгене, киләчәкне аңлатуны берләштерә кебек. Мәсәлән, грек мифологиясендә дөнья турындагы фәннең, белемнәрнең килеп чыгуы Прометей батырлыгы белән аңлатыла.

Мифларда, кешеләр өчен мөһим булган вакыйгалар турында сөйләү, бәян итү белән бергә, әлеге җәмгыятьтә кабул ителгән кагыйдәләр һәм кыйммәтләр системасы да раслана. Бу исә *билгеле бер шартларда кешенең үзен тотышын модельләштерү* була. Мифлар үзләре кеше фикеренең аерым «лабораториясе» булып хезмәт итә, ул «лаборатория»дә тормышның барлык очракларына үз-үзеңне тотуның социаль хупланган үрнәкләре туплана һәм билгеле бер тәртипкә, системага салына.

Мифларда әйләнә-тирә дөнья турында нинди мәгълүматлар булган соң? Барыннан да элек аларда дөньяның, хайваннарның, кешеләрнең яратылуы, табигать көчләренең барлыкка килүе, рельеф үзенчәлекләре, төрле гореф-гадәтләр һәм йолалар сурәтләнә. Сез андый мифларны хәтерлисездер, мөгаен. Аларның күбесендә барлыкка китерелү геройның мәдәният элементларын «табуы» (мәсәлән, иң беренче саклаучылардан урлау юлы белән) яки иҗатчының эше буларак гәүдәләндерелә. Мәсәлән, Борынгы Елга арасында, имештер, кешеләрне техника һәм мәдәниятнең барлык казанышларына өйрәткән беренче зирәк хаким — ярым-аллалар турында миф була.

Дөньяның яратылу процессы еш кына акрынлап тәртипкә салу юлы белән хаостан галәмгә әверелү буларак күзаллана, ул аллалар яки демоннарча көчле геройлар сугышы белән бергә бара. Күкнең җирдән аерылуы, коры җирнең беренчел океаннан бүленеп чыгуы, өч дөньяның: күкнең, җирнең һәм җир астының барлыкка килүе сурәтләнә.

Ел фасыллары алышыну турындагы белемнәр календарь мифларында чагыла һәм үлүче, һәм үлгәч терелүче аллалар,

һәм геройлар (Осирис, Деметр, Персефон һ.б.) турында бәян ителү белән бәйле була.

Кайбер халыкларда әле борынгы заманнарда ук галәмнең киләчәктәге һәлакәтен (соңыннан ул йә торгызыла, йә юк) сурәтләүче эсхатологик дип аталган мифлар була. Галәмнең яки аның аерым өлешләренең һәлакәте идеясе, кешелек ыругының аерым вәкилләренә котылу мөмкинлеге биреп, кешеләрне сынау өчен чиксез куәтле аллалар җибәргән су басу турындагы мифларда очрый.

Галәм темасы белән бергә мифларда биографик мотивлар да була: мифологик геройларның тууы, үсеп җитүе, никахы, үлеме. Барлык бу мифларда геройлар уңышлы үтә торган ниндидер сынаулар тасвирлана. Кайбер мифологик геройлар тирәсендә, аерым тарихи персонажлар кебек үк, тулы бер цикллар барлыкка килә. Беренче тип мифлар мисалы — Одиссей, Тезей, Геракл турындагы мифлар. Чын вакыйгалар турындагы мифлар мисалы — Троян сугышы турындагы мифлар. Аның турында исә безгә килеп ирешкән риваятьләр буенча гына түгел, немец археологы Г.Шлиман казынулары мәгълүматлары буенча да билгеле.

Йолалардан һәм изгелек элементларыннан арындырылган мифлар әкиятләргә башлангычлар бирә. Борынгы героик эпос, ягъни халык тормышының тулы күренешен чагылдырган үткән турындагы риваять тә мифларга барып тоташа. Мифология белән тыгыз бәйләнештәге борынгы эпосның билгеле мисаллары — «Илиада», «Одиссия», «Махабхарата», «Рамаяна», калмык эпосы «Җангар» һ.б. Рус халкының былина баһадирлары да биографик мифлар геройларын хәтерләтә.

Мифлар, әкиятләр, эпос үзләренә күрә халыкларның тормыш тәҗрибәсен саклау ысулы булып хезмәт иткән. Өстәвенә чынбарлык турындагы күзаллаулар гына түгел, әйләнә-тирә дөньяда ориентлашуга ярдәм итүче фикерләү алымнары да истә калдырылган.

Италия философы Д.Вико (1668–1744) бик зирәк төстә мифларны «кешелек дөньясы акыл сүзлегенең беренче басмасы» дип атаган.

Үз халкының мифларын үзләштереп, шәхес үзенең шәхси тәҗрибәсен коллективның, кешеләр бергәлегенең ыруг тәҗрибәсе белән чагыштыра башлый. Язу барлыкка килгәнгә кадәрге дәверләрдә мифлар социаль хәтер сандыгы булып хезмәт иткән. Ул кешеләрнең күп буыннары туплаган белем, осталык, тәҗрибә җыелмасын саклаучы үзенчәлекле «тере хәтер» булган.

XX гасырда инде мифларны тикшерүдә берничә юнәлеш барлыкка килә. Мәсәлән, Дж.Фрезер мифларны берсе дә очраклы булмаган, барысының да үз урыны һәм үз вакыты булган йола текстлары дип санаган. Әлеге текстлардан чигенеп булмый, ә аларның чын мәгънәләре азчылыкка гына мәгълүм, анысы да ачыш аша килә. Башка юнәлеш яклылар (функционалистлар) мифта бер үк вакытта һәм бер үк урында яшәүче кешеләр бергәлекләрен генә түгел, аларның борынгы ата-бабаларын да бергә бәйләүче бер тәртипне саклау ысулын күрәләр. Мифның вазыйфасы — кабилә (халык) мәдәниятенең дәвамчанлыгын тәэмин итү.

Борынгы кешеләрнең дөньяның төзелеше, аллаларның һәм геройларның эшләре турындагы мифологик күзаллаулары үткәндә калды. Ләкин мифологик аңның кайбер сыйфатлары әле хәзер дә саклана. Безнең күбебез элеккечә үк берничә гадел идея ярдәмендә дөньяның күптөрлелеген аңлатып булуына ышана.

XIX гасырда мондый рольне «раса чисталыгы», «гомуми рәхәт тормыш дәүләте», «гомуми ирек патшалыгы» һ.б. идеяләргә биргәннәр. Бүген дә җәмәгатьчелек фикере кайберәүләрдән — батыр, икенчеләреннән иблис ясый. Кешеләр элеккечә үк безнең алда яңа, моңарчы күрелмәгән мөмкинлекләр ачачак «культуралы каһарман»ны көтәләр.

«ҺӘМ ТӘҖРИБӘ, ЧИТЕН ЯЛГЫШЛАР УЛЫ...»

Яшәү практикасы, *көндәлек тормыш тәҗрибәсе* дөньяны танып-белүнең аерым ысулы булып тора. Элек-электән кешеләр дөньяны тулаем аңлатырга тырышып кына калмаган, ә бәлки гади эшләр белән дә шөгыльләнгәннәр, уңышсызлыкларда интеккәннәр, нәтиҗәгә ирешергә омтылганнар. Белем үзмаксат булган фәннән аермалы буларак, практик тәҗрибәдә алар өстәмә (икенчел) продуктны гәүдәләндерә. Мәсәлән, елга яки күл буенда яшәүче кеше суда йөзү өчен корабль яки көймә ясаган. Андый эшчәнлекнең төп нәтиҗәсе — судно, ә өстәмә продукты — нинди агач сайларга, аны нәрсә белән һәм ничек эшкәртергә, йөзеп хәрәкәт итү средствосына нинди форма бирү турындагы белем була. Ул чакта әле судно төзергә Архимед законы билгеле булмый. Шулай да, әгәр көймә уңышлы булып чыга икән, димәк, аны төзегән кагыйдәләр, гәрчә төзүчепрактикка билгеле булмасалар да, фәнни нигезләмәләргә шактый туры килгән. Һөнәрче, җир эшкәртүче, пешекче, табиб, шәраб ясаучы, төзүче һ.б. эшчәнлеге кешеләргә практик характердагы күп белемнәр бирә. Тәҗрибәле остазда өйрәнчеклек үтү практик белем формалаштыру ысулы була.

Тәҗрибә туплау вакытында барлыкка килгән практик белемгә үзенең теле дә туры килә. Хәтерләгез әле: «күз күргәнчә», «аз гына», «чеметем генә» һ.б. Моның күпме икәнен грамм, минут, сантиметрларда билгеләп карагыз. Андый практик белем иясенең һөнәри осталыгы: микрон һәм миллиграммнарны, секунд өлешләрен билгеләү осталыгын; хәтер, гадәтләр, күнекмәләр ярдәмендә күптөрле кораллар, материаллар, эш шартлары белән дә белеп эш итүне таләп итә.

Практик белемнәрнең күпчелеге теоретик нигезләүгә дәгъва кылмый һәм аннан башка да яши. Гәрчә сурәтне еракка тапшыру принципларын белмәсә дә, бүген телевизордан файдалана белмәгән баланы табу кыен. Бернинди фәнни теориясез дә һәркем ботинка бавын бәйли белә.

Тормыш тәҗрибәсе туплау процессында кеше практик белемнәр генә түгел, ә бәяләүләрне, үзеңне тоту нормаларын да үзләштерә, өстәвенә аларны болай гына, махсус тырышлык куймыйча, үрнәк буенча эш итеп кенә үзләштерә. Көндәлек тәҗрибә белән бәйле бәяләү белемнәрен кайчак «рухи-практик белемнәр» дип атыйлар. Алардан халык зирәклегенә — бер адым.

ХАЛЫК ЗИРӘКЛЕГЕ ҺӘМ СӘЛАМӘТ (САФ) АКЫЛ

Кешеләрнең үз мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән эшчәнлегенең күләме арту һәм катлауланувы белемнәрне, практика казанышларын тасвирлау рәвешендә теркәү зарурлыгына китерә. Өстәвенә андый тасвирлаулар төрле халыкларның, хәтта күп буыннарның бергә тупланган тәҗрибәсен колачлыйлар. Андый гомумиләштерелгән практик белемнәр халык зирәклегенең нигезен тәшкил итә.

Тарихның башлангыч чорларында кешенең зирәклеген барыннан да элек аллаларга кайтарып калдырганнар, алар аның белән аерым кешеләрне бүләкләгәннәр дип уйлаганнар. «Алла очкыны» кагылган кешеләр белмәгәнне белү, аллалар үзләре юнәлдергән вакыйгалар агышын алдан күрү сәләтенә ия дип исәпләгәннәр. Мифология хакимлек иткән җәмгыять нигезләре җимерелгәч, зирәклекне аңлау да үзгәрә. Ул җирдәге вакыйгаларның үзләрен, аллалар дөньясына бәйләмичә, аңлау осталыгы буларак карала башлый.

Тәҗрибәне гомумиләштерүдән практик нәтиҗәләре булган үзенчәлекле афоризмнар, әйтемнәр, фикер йөртүләр килеп чыга. «Тимерне кызуында сук» дигәнне һәркем белә. Болай дип фикер йөртү металлның йомшак вакытта җиңелрәк эшкәртелүен күзәтүләрдән чыгып туган. Ул нәрсәне дә булса үз вакытында, эшчәнлек өчен шартлар әйбәт булганда эшләргә өндәүне аңлата. Хәзер ул тимерче хезмәте белән бөтенләй дә

бәйләнмәгән гамәлне аңлатырга мөмкин. Халык зирәклегенең табышмакларда, әйтемнәрдә, мәкальләрдә теркәлгән шаһитларының күпчелеге башта практик предметлы эшчәнлек белән бәйле булган.

Табышмаклар борынгы юраучы, күрәзәчеләр сәнгате белән тыгыз бәйләнгән. Шуның белән бергә халык табышмагын табигый акылы һәм тормыш тәҗрибәсе булган һәркем чишә ала. Исегезгә төшерегез әле: Иван-тиле чынлыкта Василиса Премудраяның табышмакларына җавап эзләгәндә шактый зиһенлелек күрсәтә.

Төрле очраклар өчен үз-үзеңне тоту рецептлары җыелмасы буларак халык зирәклегенең аерылып торучы сыйфаты — аның бертөрле булмавы, каршылыклы булуы. Бу шуның белән бәйле: анда бер үк күренешләргә, гамәлләргә карата төрле кешеләр мөнәсәбәтләре туплана, шунлыктан бер үк нәрсә турында каршылыклы фикерләр очрый. Мәсәлән: «Эш бүре түгел, урманга качмас», ә янәшәдә генә: «Телең белән ашыкма, эшең белән ашык». Халык зирәклегенең мондый фикер йөртүе мисалларын сез үзегез дә дәвам иттерә аласыз.

Хәзер инде нәрсә ул *сәламәт (саф, аек) акыл* дигәнгә мөрәҗәгать итик. Сүзлек аны *көндәлек тәҗрибә басымы астында кешеләрнең әйләнә-тирә чынбарлыкка һәм үзләренә карата барлыкка килгән карашлары; шул ук вакытта бу карашлар практик эшчәнлек һәм әхлак өчен нигез булып торалар* дип билгели. Әлеге аңлатманы тикшереп карыйк. Барыннан да элек сәламәт акылга стихияле рәвештә, махсус танып-белү эшчәнлегеннән башка үзләштерелгән мәгълүматлар (аларны «белемнәр» дип атарга мөмкин) керә. Алар кешенең үз замандашларының җанлы, турыдан-туры тәҗрибәсен һәм кешелек дөньясының тормыш эшчәнлеге күнекмәләрен ни дәрәҗәдә колачлавына карап үзләштерелә. Бу мәгънәдә сәламәт акыл «табигый фикер йөртү» дигән нәрсәне тәшкил итә һәм һәр сәламәт кешегә хас. Мәсәлән, аек акыл белән караганда, нинди дә булса прибор белән эш итә белмисең икән, белгән кешедән сорау хәерлерәк, андый кеше булмаса (артык кирәге юк икән), приборга тотынма. Сәламәт акыл башкаларга һәм үзеңә зыян сала торган эшкә тотынмавың яхшырак дип күрсәтә.

Шик юк, сәламәт акыл күп тапкырлар тикшерелгән, шиксез, бәхәссез мәгълүматларны терки. Ләкин һәрвакыт һәм һәрнәрсәдә аңа гына ышанырга ярыймы соң? Башкача әйткәндә, тулы канлы эшчәнлек өчен сәламәт акыл гына җитәме?

Шунысын да әйтергә кирәк: сәламәт акыл, күпләгән кешеләр тәҗрибәсе белән тыгыз бәйләнгән хәлдә, билгеле чор кешеләре тарафыннан абсолют, какшамас хакыйкатьләр сыйфатында кабул ителгән адашулар, ялгыш инанулар, тотрыклы күзаллаулар,

стереотиплар белән чолгап алынган. Әйтик, Гомер вакытында ак төлке башлы кешеләр булырга мөмкин дип уйлаганнар. Бу гаҗәпләнү тудырган, әмма шик түгел. Сәламәт акыл — шактый консерватив күренеш, ул аз үзгәрә, яңа идеяләр искеләрен бик кыен кысрыклап чыгара, шулай да, вакытлар үткәч, үзгәрешләр була. Дөнья турында күзаллауларның туктаусыз үсүе процессында фәнгә караганда күбрәк ата-бабалар тәҗрибәсенә таянучы белемнәрнең кайбер өлкәләренең үзгәрешсез калуы бик үк начар да түгелдер, бәлкем.

СӘНГАТЬ ЧАРАЛАРЫ БЕЛӘН ТАНЫП-БЕЛҮ

Сәнгать танып-белүнең башка бер тибын бирә. Ул дөньяны сәнгати үзләштерү белән эш итә. Әлбәттә, сәнгать дөньяны танып-белү белән генә чикләнми, аның бурычы киңрәк. Сәнгатьтә кешенең чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәте чагылдырыла. (Алга таба эстетик эшчәнлекнең үзенчәлеге махсус тикшереләчәк. Монда без сәнгатьнең танып-белү ягын күрсәтү белән чикләнербез.)

Тарихи үткәнне архив документларын һәм археологик табышларны системалаштырып һәм гомумиләштереп өйрәнергә була. Ләкин үткәннәр турында әдәбият, сынлы сәнгать, театр осталары иҗат иткән нәфис әсәрләр ярдәмендә дә белергә мөмкин. Нәфис әсәр үткән заман геройларының нинди булулары турында гына түгел, нәрсә уйлаулары һәм үзләрен ничек хис итүләре, билгеле бер хәлләрдә үзләрен ничек тотулары турында да хис белән төрелгән һәм ачык күзаллау бирә, шул заман рухын тоярга ярдәм итә.

Үз вакытында әдәбият тәнкыйтьчесе В.Г.Белинский А.С.Пушкинның «Евгений Онегин» романын рус тормышы энциклопедиясе» дип атый. Чынлап та, аны укучылар XIX гасыр башы рус җәмгыяте тормышының төрле яклары белән танышалар.

Сәнгати гомумиләштерү, образ сәнгати танып-белүнең үзенчәлекле ысулы булып тора.

Чынбарлыкны чагылдыручы буларак, образ чын булган предметның билгеле бер сыйфатларына ия. Вакыйга турындагы әдәби хикәя ул вакыйганың үзе түгел, әмма ул укучы фантазиясе ярдәмендә аны күз алдына китерү мөмкинлеге бирә. Мәрмәр үзе тере гәүдә түгел, ләкин, бөек скульптор Микеланджело раслаганча, «зур кисәктән артыгын алып ташласаң», салкын ташка нәфис образ формасы бирсәң, сокланган тамашачы алдында матур атлетның мәһабәт гәүдәсе яки философның зирәклек белән балкыган йөзе пәйда була. Рәссам тарафыннан осталык, төсләр, линияләр, композиция ярдәмендә кулланылган

яссы киндер өч үлчәмле киңлек булып әверелә. Бер предметның икенчесен шундый алыштыруын үз башлангычы — борынгы заманнардагыча дөньяга караштан; аныңча, әйберләр бер-берсенә әверелә ала. Бер предмет икенчесен алыштыра, бу вакытта икесенең дә асылы һәм әһәмияте арта, ачыграк була.

Антик һәм Урта гасырлар сәнгатендә сәнгать образы урынын канун — сәнгати яки поэтик һөнәрнең гамәли кагыйдәләре җыелмасы алып тора. Аңа иярү сәнгать эшчәнлегенең зарури шарты була. Яңарыш чорында стиль турында рәссамның әсәрне үзенең иҗади инициативасы нигезендә, ягъни дөньяны үзе белгәнчә иҗат итүе буларак күзаллау барлыкка килә. XVIII гасырда, табигать турында белемнәр нык үскәч, сәнгать формасы эчке максатларга буйсынган үзенчәлекле оешма, тәртипкә салынганлык буларак кабул ителә башлый. Рәссам, дөньяны танып-белеп, аны сәнгати образларда үзгәртеп сурәтли. Сәнгатьне «образдан фикерләү» буларак аңлау Г. Гегельдән башлана.

Г.Гегель «образ турыдан-туры хислелек белән идеаль фикер өлкәсенә караган фикер арасында тора» дип яза. Башкача әйткәндә, образ идеаль фикерне реаль гәүдәләндерү аша күрсәтергә һәм ул гәүдәләндерүне «фикерне җиткерү» итеп аңларга ярдәм итә. Моны мисалда аңлатыйк.

М.Ю.Лермонтовның «Шагыйрь» дигән шигырендә образ табабыз: поэзия — «вече манарасындагы чаң». Монда бер-берсеннән ерак торган реаль яшәүче субъектлар чагыштырыла. Ләкин берсен икенчесе белән алыштыру ярдәмендә поэзиядә кешеләрне берләштерү, аларны яшәү өчен мөһим минутларга чакыру сәләте кебек сыйфатлар ачылу мөмкинлеге туа. Килешәсездер: «Нәрсә ул поэзия?» дигән темага күп китап язарга була, ә шул ук вакытта ачык образ тәкъдим итсәң, күп нәрсә ачыграк, поэзия дөньясына керү тирәнрәк була. Шуның белән бергә, сәнгатьле образның мәгънәсен сүзләр белән аңлату авыр. Өстәвенә котылгысыз рәвештә ул ярлылана, нииндидер мөһим детальләр сүзләр теленә күчерелми, яңгыравыклы поэтик образ серле кала.

Борынгы заман шагыйре Гесиод: «Музалар дөреслеккә охшаш ялганны сөйлиләр»,— дигән. Реаль түгел, ә идеаль объект буларак, образга кеше дөньяны танып-белгәндә куллана торган төшенчә, күзаллау, гипотеза һәм башка фикерләү конструкцияләренең кайбер сыйфатлары хас. Ул дөньяны гади чагылдырып кына калмый, күпләгән реаль объектларның мөһим сыйфатларын гомумиләштерә сыман. Образ бердәнбердә, күчмәдә, очраклыда асылны, үзгәрешсезне, мәңгелекне ачып бирә. Лермонтовтан китерелгән мисалыбызда чаңның конкрет характеристикалары әһәмиятле түгел, безнең өчен поэзиянең табылган образны колачлы һәм тирән белдерүе мөһим.

Художестволы образ ярдәмендә сәнгать әйләнә-тирә дөньяның һәм аның өлешләренең үзенә күрә гипотезасын булдыра. Әлеге гипотеза кабул итүчедән һәм дөньяны танып-белүчедән, һичшиксез, үз фантазиясен, иҗатын, тирән фикерләү эшчәнлеген, ниһаять, дөньяны шул ысул белән кабул итәргә әзер булуын таләп итә.

Шулай итеп, килешик: танып-белү эшчәнлеге бик тә күптөрле. Ул үз барышында һаман саен яңа хакыйкатьләр ача барган абсолют хакыйкатькә таба тантаналы атлап бару кебек кенә була алмый. Танып-белү юлында кешене ялгышулар да, күңелсезлекләр дә, хаталар да көтә. Алдынгы фәнни белемнәр юк-барга ышанулар белән дә, томаналык белән дә янәшә яши ала. Боларның берсе дә фәнни танып-белүнең әһмиятен киметми, ә бәлки кеше кызыксынуларының күптөрлелегенең һәм аның тирәсендәге дөнья байлыгының чынбарлыкны танып-белүнең күптөрлелеген дә, танып-белү эшчәнлегенең күптөрле ысуллары һәм формаларын чиратлаштыруны да таләп итүен басым ясап күрсәтә.

ФӘН БЕТКӘН УРЫНДА

Фәннән тыш белемнең яшәвенең тагын бер нәтиҗәсе — вакыт-вакыт «парафән» (латинча para — соң, янында) дигән гомумиләштерелгән исем алган, ягъни фән тирәсендәге юнәлешләрнең булуы.

Һәрвакыт ачыклыкка, бер мәгънәлеккә, дөреслеккә омтылучы сәламәт акылдан аермалы буларак, парафән үзе куллана торган мәгълүматларның томанлылыгы һәм серлелеге белән аерылып тора. Ниндидер гаҗәеп, аңлатып булмый торган күренешләр (танылмаган объектлар, медицина фәне һәм практикасы кире каккан, дәвалап булмаслык авыруларны дәвалауның фантастик очраклары) турында еш укырга яки ишетергә туры килә. Шик юк, табигатьнең, җәмгыятьнең, кешенең үзенең барлык серләре дә ачылып бетмәгән, фән дөньяны танып-белүнең барлык почмакларына да үтеп керде дип беркем дә раслый алмас. Фәннең мөмкинлекләре чикләнгәнлектән, барлык сорауларга да җавап бирү мөмкин түгел, кеше үтеп керергә омтылган тикшерелмәгән киңлек һәрвакыт бар. Еш кына эксперимент белән расланмаган, кабул ителгән теорияләргә сыешмаган яки гомум кабул ителгән һәм практикада сыналган фәнни белемнәргә каршы килә торган мәгълүматлардан файдаланып, әлеге киңлекне парафән били.

Бүгенге көндә фән аңлата алмаган һәр өлкә парафәннеке дип раслау дөрес булмастыр, мөгаен. Танып-белүнең кайбер урыннарында теория үсешен узып китүче ерымнар булуы мөмкин, әлбәттә. Урнашкан фәнни системаларга ярашмаган чын

фактлар бар. Ләкин әле андый фактлар белән эш итү аларның фәнни кыйммәтен инкарь итү хокукын бирми. Андый мәсьәләләргә уйлап һәм объектив якын килергә кирәк.

Парафән универсальлеккә дәгъва кылуы белән аерылып тора: еш кына табылган даруны яисә традицион медицинадан ерак торган дәвалау ысулын парафән тарафдарлары барлык авырулардан универсаль чара дип белдерергә ашыгалар. Еш кына парафән, үзенчәлеккә дәгъва кылып, кыен тәрҗемә ителә торган серле яки мәгънәсез ялган фәнни терминология куллана. Мәсәлән, «Кеше сферик биокыр белән туа» дип раслауда мәгълүматка караганда сораулар күбрәк. Нәрсә ул сферик биокыр? Аның сфериклыгын кем һәм ничек билгеләгән? Ул нинди ераклыкка тарала? Әгәр кеше геометрик яктан нокта булмаса, сфера булып калу өчен гәүдәнең төрле өлешендә биокыр төрле калынлыкта була дигәнне аңлатамы бу? Ләкин парафән исәпсез мондый сорауларга җавап бирергә тырышмый, ул андый формуланы каршы килә алмаслык итеп файдалана, шуның ярдәмендә авыруларның сәбәбен яисә кешенең башка проблемаларын аңлата.

Парафәнгә шулай ук үзенә карата артык зур игътибар таләп итү хас (бу болайрак була: «Мин барлык авыруларга каршы дару уйлап таптым, ләкин моны фармацевтларга аңлатып тормыйм, чөнки алар әле моңа үсеп җитмәгән. Миңа Фәннәр академиясе каршында доклад яки телевидение аша бөтен илгә чыгыш ясавымны оештырыгыз, юкса мин бер сүз дә әйтмәячәкмен»). Өстәмә экспертизалар яисә тикшерүләр үткәрергә тәкъдимнәр кимсетү яки ышанмау буларак кабул ителә. Өстәвенә парафән еш кына традицион фәнне танымаска тырыша, профессионалларга түгел, массаларга, матбугатка һ.б. мөрәҗәгать итә.

Парафән турында сөйләшүне тәмамлап, шунысын билгеләп үтик: гәрчә ул кайчак яңа фәнни проблемалар тудыруга булышлык итсә дә, аңа конкрет аңлатулардан качу, ул файдалана торган ысулларга туры килми яки каршы килә торган фактларны әйләнеп үтәргә тырышу хас.

Төп төшенчәләр: кеше белемнәренең төрләре һәм дәрәҗәләре, мифологик һәм рациональ-мантыйклы белем, тормыш тәҗрибәсе һәм сәламәт акыл.

Терминнар: гносеология, эсхатология, сәнгати образ, парафән.

Үзегезне тикшерегез

1. Кешенең дөньяны танып-белү юлларының күптөрлелеге нәрсәдә чагыла? 2. Фәнни танып-белүдән тыш, дөньяны танып-белүнең тагын нинди юллары бар? Аларны нәрсә берләштерә?

Алар нәрсәләре белән аерыла? 3. Фәнни булмаган танып-белү кешене хакыйкатькә илтә дип раслап буламы? Җавабыгызны дәлилләгез. 4. Сәнгать чаралары белән танып-белү нәтиҗәсе кешенең танып-белү эшчәнлегенең башка төрләреннән нәрсәсе белән аерыла?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Барлыкка килү (яратылу) турындагы теләсә кайсы миф мисалында шул миф туган чорда кешеләрнең дөньяның төзелеше турында нәрсә белүләрен билгеләгез.

2. Тормыш тәҗрибәсенә һәм белемнәрегезгә таянып, түбәндәге халык табышмакларын чишегез.

Кайсы тере зат ике аяклы, өч аяклы һәм дүрт аяклы, аягы күбрәк булган саен хәлсезрәк була?

Берсен белмим, икенчесен күрмим, өченчесен хәтерләмим.

3. Ни өчен куплаган табышмакларның төрле, бер үк дәрәҗәдә гадел чишелешләре була?

4. Түбәндәге фикер йөртүләр нигезендә мантыйклы нәтиҗә ясагыз:

Белемнәрнең төрле төрләре танып-белү процессы нәтиҗәсе булып торалар.

Киң мәгънәдә алганда, белем — танып-белү предметы турында алынган барлык мәгълүмат ул.

Чыганак белән эшләгез

Россия психологы Б.М.Теплов (1896–1965) хезмәтеннән өзек укыгыз.

Практик фикерләү

Теоретик һәм практик фикерләү арасындагы аерма шунда ки, алар практика белән төрлечә бәйләнгән: аларның берсе практика белән бәйле, ә икенчесе алай булмауда түгел, ә бу бәйләнешнең характеры төрле булуда.

Практик фикерләүнең эше нигездә шәхси конкрет бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән: билгеле бер заводның эшен оештыру, сугыш планын эшләү һәм гамәлгә ашыру һ.б.; ә теоретик фикерләү эше нигездә гомуми закончалыкларны: җитештерүне оештыру принципларын, тактик һәм стратегик закончалыкларны табуга юнәлдерелә. <...>

Практик акыл эше турыдан-туры практик эшчәнлеккә беркетелгән һәм практика белән туктаусыз сыналып торыла, ә теоретик акыл эше гадәттә практик тикшерелүләргә фәкать үзенең ахыр нәтиҗәләрендә генә дучар ителә... Теоретик акыл практика алдында бары тик үз эшенең ахыргы нәтиҗәсе өчен генә җавап бирә, ә практик акыл фикерләү эшчәнлеге процессында җаваплы.

Галим-теоретик төрле эш гипотезалары тәкъдим итәргә, кайчак аларны озак вакыт дәвамында сынарга, үзләрен акламаганнарын алып ташларга, аларны башкасы белән алыштырырга мөмкин һ.б. Практиканың гипотезалар куллану мөмкинлекләре чагыштыргысыз дәрәҗәдә чикләнгән, чөнки әлеге гипотезалар махсус экспериментларда түгел, ә тормышның үзендә тикшерелергә тиеш, һәм аеруча мөһиме — андый тикшерүләр өчен практик хезмәтләрнең һәрвакытта да вакыты булмый. Вакытның кырыс кагыйдәләре — практик акыл эшенең иң характерлы үзенчәлекләренең берсе.

Иң киң таралган ышануларның берсен — акылга иң югары таләпләрне теоретик эшчәнлекләр: фән, философия, сәнгать таләп итә дигән ышануны шик астына алу өчен югарыда әйтелгәннәр җитә. Кант үз вакытында «даһи сәнгатьтә генә була ала» дигән. Гегель философия белән шөгыльләнүдә акыл эшчәнлегенең иң югары баскычын күргән. XX гасыр башы психологлары акыл эшчәнлегенең югары чагылышы итеп, кагыйдә буларак, галим эшен санаганнар. Барлык бу очракларда теоретик акыл интеллект чагылышының мөмкин булган иң югары формасы буларак каралган. Практик акыл исә хәтта аның иң югары баскычларында — сәясәтче, дәүләт эшлеклесе, полководец акылы — бу күзлектән караганда элементаррак, җиңелрәк, интеллектуаль эшчәнлекнең азрак квалификацияле формасы булып бәяләнгән.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Б.М.Теплов теоретик һәм практик фикерләүнең нинди аерымлыкларын күрсәтә? 2. Фикерләүнең практик тибы эшчәнлекнең кайсы тибына күбрәк туры килә? 3. Эшчәнлек төрләренең фрагментта аталган исемлеген дәвам иттерегез. Эшчәнлекнең теге яки бу төрен әлеге исемлеккә нинди принцип буенча кертәсез? 4. Практик фикернең әһәмиятен бәяләүдә автор белән килешәсезме? Нәрсә турында бәхәсләшә алыр идегез? Үз карашыгыз файдасына нинди дәлилләр китерә алыр идегез?

§ 24. Фәнни танып-белү

Исегезгә төшерегез:

кешеләрнең танып-белү эшчәнлегендә сизү һәм рациональлек үзара ничек бәйләнгән? Нинди белемнәр чын, хакыйкать дип атала? Хакыйкатьнең объективлыгы нәрсәдә чагыла? Физика, биология дәресләрендә сез табигать үсешенең галимнәр ачкан нинди законнары белән таныштыгыз?

Чынбарлык кеше тарафыннан төрле юллар һәм ысуллар белән үзләштерелә. Аларның иң әһәмиятлесе булып инде күп гасырлар дәвамында фән санала. Ул тапкан белемнәр өр-яңа технологияләр, сәнәгать җитештерүе, медицина, мәгариф һәм эшчәнлекнең күпләгән башка өлкәләре нигезендә ята. Шундый зур уңышларга ирешергә фәнгә нәрсә ярдәм иткән икән соң? Моны аңларга фәнни танып-белү үзенчәлекләрен карау булышыр.

Шул ук вакытта бүгенге көндә белем алуның фәнни булмаган, хәтта фәнгә каршы булган ысулларына ышанучы кешеләр саны артты. Нидән килә бу? Бу сорауга мөмкин булган җавапларның кайберләре шушы параграфта китерелә.

ФӘННИ ТАНЫП-БЕЛҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Фән барыннан да элек кешелек дөньясы өчен яңа белемнәр алу, кешеләргә әле билгеле булмаганнарны ачу максатын куя. Бер үк вакытта аңа объективлыкка, дөньяны кешедән тыш һәм бәйсез рәвештә, ул ничек булса, шулай өйрәнүгә омтылу хас. Алынган нәтиҗә шәхси фикергә, гаделсезлеккә, абруйлыкка бәйле булырга тиеш түгел. Танылган физик М.Планк (1858–1947), бөтен кешелек дөньясы өчен генә түгел, ә бәлки (гомумән, ул булса) чит планетадагы акыл иясе өчен дә хакыйкать булырлык белемнәр табарга тырышам, дигән.

Гадәти аң кысаларында без үз күзаллауларыбыз һәм фикерләүләребезнең дөреслеген көндәлек практикада тикшерәбез. Әгәр алар безнең шәхси тәҗрибәбез белән генә түгел, башка кешеләр тәҗрибәсе белән дә расланса, нәтиҗәләребез һәм күзәтүләребез аеруча ышандырырлык була. Алынган белемнәрнең чынлыгын раслау өчен фәндә тикшеренүләрнең махсус ысуллары, нәтиҗәләрне тикшерүнең аерым процедуралары кулланыла. Америка сүзлекләренең берсендә фән «табигый күренешләрне күзәтү, классификацияләү, сурәтләү, эксперименталь тикшеренү һәм теоретик аңлату» дип билгеләнә. Әлбәттә, мондый билгеләмә бөтенесен колачлаучы була алмый, ләкин анда фәнни танып-белүдә кулланыла торган төп ысуллар күрсәтелгән. Без бу мәсьәләгә тукталырбыз әле. Бер үк шартларда алынган мәгълүматның яңадан җитештерелүен (мәсәлән, клонлаштыру мөмкинлеге бары тик тиешле нәтиҗәләр берничә фәнни тикшеренү үзәгендә алынгач кына фәнни факт булып танылды), тәкъдим ителә торган нигезләмәләрнең рациональ тәнкыйтькә ачыклыгын фәнни тикшеренү принципларына кертәләр.

Көндәлек тормышта без таба торган белемнәрне тасвирлау өчен гадәти сүзләр җитә, кулланыла торган төшенчәләр аерым

төгәллек таләп итми. Фәнгә исә аерым терминнар кергән махсус тел, катгый билгеләүче төшенчәләр, математик символлар кирәк.

Фәнни тикшеренүләрнең тагын бер мөһим сыйфаты — аларның хәзер генә түгел, киләчәктә дә кулланылуы ихтимал булган мәгълүматлар алуга юнәлгәнлеге. Теге яки бу фәнни ачышларны замандашларның «чиста теоретик әһәмияткә ия, практикада исә файдасыз» дип каравына күпләгән фактлар бар. Ләкин еллар, дистә еллар уза, һәм фән тапкан белемнәр кешеләр тормышына турыдан-туры йогынты ясаучы яңа техника һәм технологияләр булдыру өчен нигез булып хезмәт итә. Бер караганда, Г.Р.Герцның электр магнитлы дулкыннарны ачуыннан нинди файда алып була иде? Әмма дистә еллар үткәч, ватандашыбыз А.С.Попов аның нигезендә безгә хәзер гадәти булган радионы уйлап тапты.

ФӘННИ БЕЛЕМНЕҢ ИКЕ ДӘРӘҖӘСЕ

Фәннең нигезен төгәл билгеләнгән фактлар, шулай ук күзәтүләр һәм эксперимент, алынган мәгълүматларны гомумиләштерү һәм системалаштыру барышында ачылган алар арасындагы закончалыклы элемтәләр — *эмпирик* законнар тәшкил итәләр. Әлеге фактлар һәм законнар фәнни белемнең эмпирик (грекча empeiria — тәҗрибә) дәрәҗәсен булдыралар. Аларга сезгә физика курсыннан яхшы билгеле булган Шарль (газ басымының температурага бәйле булуы), Гей-Люссак (газ күләменең температурага бәйлелеге), Ом (ток көченең көчәнешкә һәм электр каршылыгына бәйлелеге) законнары һәм башка бик күпләр керә. Әлеге бәйлелекләр экспериментлар аша ачылды.

Фәнни белемнең икенче бер дәрәҗәсе — теоретик танып-белү. Ул күренешләрнең бик тә киң классын колачлаучы элемтәләр һәм мөнәсәбәтләр белән, шулай ук турыдан-туры күзәтеп булмый торган объектлар — идеаль объектлар (идеаль газ, абсолют кара тән, иҗтимагый-икътисади формация һ.б.) белән эш итә. Шундый объектлар белән эш итүче, теоретик танып-белү гомумиләштерүнең югары дәрәҗәсенә ирешү, законнар формалаштыру сәләтенә ия. Теоретик дәрәҗәдә ачылган һәм нигезләнгән законнар арасында — энергияне саклау һәм әзерләү законы, бөтендөнья тарту көче, нәселдәнлек законы һ.б. Андый законнар үзара тыгыз бәйләнгән башка компонентлар — типологияләр, классификацияләр һ.б. белән бергә фәнни теория төзү өчен башлангыч материал булып хезмәт итә. Әлеге нигездән тыш, теория, кагыйдә буларак, логик нәтиҗә һәм дәлилләү кагыйдәләрен, шулай ук теориядә формалаштырылган раслаулар җыелмасын — теоретик белемнең төп массивын колачлый.

(Математика, табигый-фәнни һәм тарих белемнәре өлкәсендә сезгә таныш теорияләрне исегезгә төшерегез.)

Теорияләрнең танып-белү әһәмияте бик зур. Алар өйрәнелә торган күренешләрне һәм процессларны аңлатырга, киләчәктә аларның үсешен фаразларга ярдәм итә. Мәсәлән, Ньютон теориясе яки аны атаганнарынча, бөтендөнья тарту законын, хәрәкәт итүнең өч законын колачлаучы күк механизмы дөньяның яңа физик күренешен булдырды, күк җисемнәренең хәрәкәтен исәпләү мөмкинлеге бирде, фәнни эзләнүләргә яңа юнәлеш күрсәтте. Э.Галлейның күк механикасы законнары нигезендә исәпләүләре аркасында соңыннан «Галлей кометасы» дип аталган кометаның Җиргә якынлашу датасы билгеләнде (1758). Галимнең исәпләве расланды. Ньютон теориясе яңа Уран һәм Нептун планеталарын ачарга ярдәм итте.

ФӘННИ ТАНЫП-БЕЛҮ ЫСУЛЛАРЫ

Инде билгеләп үтелгәнчә, эмпирик фәнни белемнәр күзәтүләр һәм экспериментлар барышында табыла.

Фәнни күзәтү максатка юнәлдерелгән характерда була: күзәтү алып баручы тикшеренүче үз алдына билгеле бер бурычлар куя, элек туплаган фәнни белемнәрен кулланып эш итә. Үз күзәтүләре нәтиҗәләрен теркәп, галим тасвирлау һәм классификацияләү ысулын куллана.

Эксперименталь табигать белеме XVII гасырда барлыкка килгән. Аңа кадәр тикшеренүчеләр күпчелек көндәлек тәҗрибәгә, күзәтүләргә таянганнар. Техника үскән, приборлар, инструментлар арткан саен, экспериментлар үткәрү өчен шартлар туган. Моннан тыш Яңа вакыт кешесе тормышның барлык өлкәсендә активлык күрсәтүгә юнәлгән була.

Күзәтүләрдән аермалы буларак, эксперимент вакытында тикшеренүче аны кызыксындыра торган предметны аерып күзәтергә, шулай ук аны махсус йогынтыларга дучар итәргә мөмкин. Шуның белән бергә, нәкъ менә күзәтү эксперименталь бурычны хәл итүгә булышкан. Мәсәлән, Англия патша сарае табибы У.Гилберт гәрәбәне, алмаз, пыяланы йон яки тире белән сөртә, шуннан соң аларга вак тәнчекләр тартылуын күрә. Гилберт бу күренешкә электрлык (грекчадан electron — гәрәбә) дигән исем дә таба. Бу әле эксперимент түгел, әмма шуңа бер адым. Ә менә данияле физик Х.Эрстед, бүгенге үлчәмнән караганда иң гади приборлар — гальваник батарея, үткәргеч чыбык, магнит угы кулланып, чын эксперимент ясый.

Экспериментлар акрынлап катлаулана, күп көч куллануны, тагын да камилрәк приборлар таләп итә. Заманча фәнни эксперимент — еш кына катлаулыдан-катлаулы һәм бик тә сизгер

приборлар һәм җиһазлар кулланыла торган чын техник могҗиза ул.

Ә фәнни тикшеренүләрнең теоретик дәрәҗәләрендә нинди танып-белү чаралары кулланыла соң? Беренче карашка, теоретик белемнәргә хас гомумиләштерүнең югарырак дәрәҗәсенә экспериментлар санын арттыру юлы белән ирешергә мөмкин кебек тоелуы ихтимал. Әмма бу алай түгел. Физика курсыннан белгәнегезчә, мәсәлән, энергия саклану һәм әверелү законы күзәтелә торган фактларны гомумиләштерү нигезендә экспериментал ь рәвештә (тәҗрибәләрдән) чыгарыла алмый. Аны кабул ителгән раслаулар нәтиҗәсе буларак саф мантыйк юлы белән дә чыгарып булмый иде. Хәрәкәт итү законы һәм фәннең теләсә кайсы өлкәсенең башка барлык фундаменталь теоретик законнары турында да шуны әйтергә мөмкин. Танып-белүнең бу дәрәҗәсендә гипотезалар тәкъдим итү, фәнни модельләштерү, галимнең иҗади күзаллавы гаять зур роль уйный.

Күпләгән фәнни нигезләмәләр башта гипотезалар, ягъни фаразлаулар, юраулар формасында барлыкка киләләр. Кайчак гипотезаларны уйлап чыгарылган, ясалма дип кабул итә. Ләкин фәнни эзләнү алардан башка була алмый. Тикшеренү барышында яңа фактлар элеккеге аңлатулар кысаларына сыймый башлаган этап туа. Менә шунда кайберләре соңрак раслана торган төрле гипотезалар кирәк тә инде. Мәсәлән, физик П.Дирак антиэлектронның (позитронның) булуы турында әлеге кисәкчә экспериментал ь рәвештә табылганга кадәр берничә ел элек әйткән.

Фәнни гипотеза билгеле бер дәрәҗәдә модель булып тора. Монда фикерләү «андый нәрсә булырга мөмкин» дигән формулага корыла. Күп кенә модельләр гадиләштерү принцибында төзелә: «ачыграк булсын өчен, кайбер детальләрне төшерик». Мондый модельнең мисалы идеаль газ турында күзаллау була ала: аңарда молекулалар арасында бәрелешләр булмый, шунлыктан алар тулысынча бер-берсеннән бәйсез рәвештә хәрәкәт итәләр.

Еш кына модель охшашлык буенча төзелә. Андый модельләрне әле бик борынгы заманнарда ук кулланганнар. Борынгы грек философы Эпикур сыеклыкның төзелешен сибелүче җисемнәр, барыннан да элек барыбызга да билгеле бөртек рәвешендә күзаллаган.

Бүгенге заман фәнендә математик модельләштерү киң кулланыла, анда алыштыручы объект урынын математик тигезләүләр системалары ала. Шуның белән бергә, образлы модельләр дә фәнгә хезмәт итүләрен дәвам иттерә. Әйтик, кайбер мәгълүматларга караганда, немец физигы А.Кекулега бензол формуласын ачарга аның урам буйлап маймыллар алып барган арба белән очрашуы этәргеч бирә. Маймыллар куллары белән

кайсысы — читлеккә, кайсысы бер-берсенә асылынган була.

Әйтелгәннәрне йомгаклап, модель фәндә билгеле бер нисбәттә өйрәнелә торган предметны алыштырырга сәләтле чынбарлык аналогы итеп кулланыла диярга була.

ФӘННИ БЕЛЕМНЕ ДИФФЕРЕНЦИАЦИЯЛӘҮ (АЕРУ) ҺӘМ ИНТЕГРАЦИЯЛӘҮ (КУШУ)

Әлеге ике терминның мәгънәсен исегезгә төшерик. Дифференциацияләү (латинча differentia — төрле булу) бербөтенне өлешләргә, формаларга һ.б. таркатуны, бүлүне аңлата. «Интеграцияләү» (латинча integration — торгызу) термины кире процессны — төрле өлешләрнең, процесслар, күренешләрнең якынаюын, берләшүен белдерә.

Фәнни белемнәрнең башлангычлары бик күптәннән барлыкка килгән. Борынгы Шәрекъ цивилизацияләре үк күпләгән астрономия, математика, медицина белемнәре туплаган. Борынгы грек фикер ияләре, беренчеләрдән булып, мантыйклы бәйләнгән системалар — математик, фәлсәфи, космогоник теорияләр булдыра башлаганнар. Ләкин фәнни белемнәр элементлары гомумирәк танып-белү системаларында: башта — мифологиядә, аннары философиядә таралган.

Фән турында дөньяны һәм кешене танып-белүнең мөстәкыйль һәм кыйммәтрәк формасы буларак күзаллау Яңа вакыт чорында урнаша башлый. Һәм фәнни белем шундук дифференциацияләнә башлый — үзләренең тикшеренү предметлары һәм ысуллары белән аерым фәннәр барлыкка килә. Математикадан соң фәнни табигать белеме оеша. Объектларның үзгәрүе белән законнар — табигать дөньясында хакимлек итүче универсаль һәм гомуми багланышлар идарә итә дигән фикер раслана. Әлеге багланышларны өйрәнү теоретик, фәнни ысуллар белән бергә, экспериментальләре дә барлыкка килгәч мөмкин була. Индустриаль цивилизация чорында сәнәгатьнең көчле үсүе, яңа инженерлык җайланмалары уйлап табу техник фәннәр барлыкка килү белән бәйле. XIX гасырның икенче яртысында социаль һәм гуманитар фәнни белемнәр барлыкка килә.

Иҗтимагый белемнәр барлыкка килүгә ике хәл булышлык итә: беренчедән, XIX гасырда башланган, социаль процессларны яхшырак аңлау һәм алар белән идарә итү ихтыяҗларын тудырган тирән иҗтимагый үзгәрешләр; икенчедән, табигать фәннәренең күренеп торган алгарышы. Соңгы хәл табигать фәннәре үрнәгендә фәнни социология булдыру омтылышы тудыра: яңа табигать белемен «социаль физика» дип йөртә башлыйлар. Ләкин озакламый тикшеренүчеләр социаль белем үзенчәлегенә дә игътибар итә башлыйлар.

Соңгылар булып гуманитар фәннәр, яки, бер философ билгеләмәсе буенча, «рух турындагы фәннәр» барлыкка килә. Әлеге фәннәр үз чаралары, барыннан да элек текстны анализлау ысуллары белән рухи мәдәният күренешләрен өйрәнәләр. Фәнни белемнең әлеге өлкәсендә җитди «көндәшләр» — философия һәм дин.

Фәнни белемне дифференциацияләү соңгырак дистә елларда да дәвам итә. Узган гасырда ул аеруча көчле характер ала. Классик фәннәр тикшерену предметларында һаман саен яңа «кыр»лар ачыла, тикшерену ысуллары колачы киңәя. Бу исә фәнни белемнең яңа тармаклары бүленеп чыгуга китерә. Аларның күбесе фәннең традицион өлкәләре кисешендә барлыкка килә: физик химия, математик лингвистика, социаль психология һ.б.

Фәннәрне дифференциацияләү өйрәнелә торган объектлар турында тагын да тирәнрәк белем алу, элек «яшеренгән» якларны һәм мөнәсәбәтләрне ачу мөмкинлеге бирде. Шуның белән бергә, фәнни белемне еш кына таркалган компонентларны бердәм картинага берләштерү, димәк, бербөтен үсешендәге төп элемтәләрне күзәтү мөмкинлеге бирүче интеграцияләү ихтыяҗы артты. Фәнни белемне интеграцияләүдә иң кискен җитешсезлек кешене үсүче бербөтен система буларак өйрәнгәндә сизелде. Аннан чыгу өчен безнең илдә узган гасыр ахырында төрле юнәлеш белгечләрен берләштергән махсус фәнни институт ачылды; шул тематикадагы вакытлы басмалар чыга башлады.

Белгечләр бәяләгәнчә, фәнни белемне интеграцияләүгә берләштерүче фәнни идеяләр кытлыгы, махсуслашкан фәнни белемнең көчле үсүе комачаулый; соңгысы галимнәргә күп кенә фәнни дисциплиналар буенча белгечләр булу мөмкинлеге бирми (башкача әйткәндә, энциклопедиячеләр гасыры кире кайтмаслык булып артта калды).

ФӘННИ РЕВОЛЮЦИЯЛӘР НИЧЕК БУЛА

Озак вакытлар фәннең үсеше, кирпеч өстенә кирпеч тезеләп дивар өелгән кебек, мәгълүматларны акрынлап җыю һәм инде таныл-белгәнне ачыклау булып күзалланды. Болай караганда, дөнья картинасы нигездә үзгәрми, фәкать чынбарлыкның һаман саен яңа формаларын гына колачлый, фән таба торган белемнәрнең чыганакларын исә һәрвакытта да үткәннән табып була. Шунлыктан элгәреләрнең хезмәтләрен өйрәнү бик мөһим.

Узган гасыр уртасында Америка философы Т.Кун фән үсешенең башка концепциясен тәкъдим итә. Аның буенча бу үсеш яңа белемнәрне салмак кертү юлы белән түгел, ә фәнни

белемнәр системасында периодик һәм тамырдан үзгәрешләр юлы, ягъни фәнни революцияләр аша бара. Фән үсешенең «нормаль» дигән чорында булган фәнни теорияләр проблемаларны уңышлы хәл итү мөмкинлеге бирә. Ләкин акрынлап әлеге теорияләр кысаларында гына аңлатыла алмый торган фактлар җыела. Кыю гипотезалар тәкъдим ителә, фәнни ачышлар ясала, фәнни проблемаларны хәл итүнең яңа ысуллары табыла башлагач, кризис этабы башлана. Нәтиҗәдә яңа, еш кына элеккеләре белән ярашмый торган, тупланган эмпирик мәгълүматлар җыелмасын аңлатучы фәнни теорияләр барлыкка килә. Бу — фәнни революция барлыкка килде дигән сүз.

Андый революциянең ачык мисалы — XX гасыр башында булган дөньяның фәнни картинасы алышыну. А.Эйнштейн, М.Планк һәм башка даһи галимнәрнең тикшеренүләре фәза, вакыт, материя турындагы күзаллауларны тамырдан үзгәртте. Шулай да, аларны сизелерлек баетып, узган гасыр физикасы элеккеге күзаллауларны юкка чыгармады, әмма алар хаклы булган чикләрдәге өлкәне күрсәтте.

ФӘННИ ФИКЕРЛӘҮ ҺӘМ БҮГЕНГЕ КЕШЕ

Профессиональ фәнни эшчәнлектән хәтта бик ерак торсак та, безнең һәрберебез бүгенге күп нәрсәләрдә гәүдәләнүче фән җимешләреннән файдалана. Ләкин фән безнең тормышыбызга массакүләм җитештерү, техник яңалыклар, көнкүреш уңайлыклары «ишекләре» аша гына кереп калмый.

Дөньяның төзелеше, кешенең андагы урыны һәм роле турындагы фәнни күзаллаулар (дөньяның фәнни күренеше) теге яки бу дәрәҗәдә кешеләр аңына керә. Фән тарафыннан эшләнгән принциплар һәм чынбарлыкны аңлауга якын килүләр безнең көндәлек тормышыбызда юнәлеш күрсәтеп торучыларга әверелә.

Якынча XVII гасырдан, индустриаль җәмгыять үсә башлагач, фәннең, фәнни фикерләү методологиясенең (принципларының, якын килүләренең) абруе тагын да ныгыды. Бер үк вакытта дөньяның альтернатив күренешләре, шул исәптән дини (мистик балку һ.б.) акрынлап иҗтимагый аң чикләренә кысрыклап чыгарылды.

Шулай да соңгы унъеллыкларда фәнгә традицион тотрыклы ышаныч булган кайбер илләрдә хәл үзгәрә башлады. Күп кенә тикшеренүчеләр фәнни булмаган белемнәрнең көчәюен билгеләп үтәләр. Бу уңайдан хәтта кешеләрнең ике тибы турында да сөйлиләр. Беренче тип фәнгә күз тота. Аның вәкилләренә активлык, эчке бәйсезлек, яңа идеяләргә һәм тәҗрибәгә ачык булу, эштә һәм тормышта үзгәрешләргә тиз

җайлашырга әзер тору, практицизм хас. Алар бәхәсләшүләр өчен ачык, авторитетларга битараф карыйлар.

Башка типтагы, дөньяның фәнни булмаган күренешенә ориентлашкан шәхеснең фикерләвенә практик файдага эшләү, серле һәм гаҗәеп нәрсәләр белән кызыксыну хас. Әлеге кешеләр, кагыйдә буларак, алынган нәтиҗәләрнең дәлилләрен эзләмиләр һәм аларны тикшерү белән кызыксынмыйлар. Өстенлек белемнең абстракт-теоретик түгел, хисси-конкрет формасына бирелә. Алар ачышны профессиональ тикшеренүче генә түгел, һәркем ясый ала дип исәпли. Андый кешеләр өчен төп терәк — инану, фикер, авторитет. (Ә сез үзегезне нинди типка кертер идегез?)

Альтернатив карашларның һәм күрсәтмәләрнең фәнниләренә йогынтысы ни өчен үсә соң? Моны төрлечә аңлаталар. Кайберәүләр XX гасырда фән кешелек дөньясы өчен мөһим булган күп кенә проблемаларны хәл итүдә үзенең көчсезлеген күрсәтте, ул гына да түгел, Көнбатыш, цивилизацияне түбән төшерүгә китереп, күпләгән яңа кыенлыклар чыганагы булды дип исәпли. Шундый караш та бар: кешелек дөньясы, маятник кебек, даими рәвештә рациональ фикерләүгә һәм фәнгә өстенлек бирү фазасыннан рационализмның түбән төшүе, инануга һәм ачышка тартылу көчәю фазасына керә. Әйтик, мәгарифнең беренче чәчәк атуы классик Греция чорына туры килә: нәкъ менә шул чакта мифологиктан рациональ фикерләүгә күчү тәмамлана. Периклның идарә итүе чоры ахырына маятник кире якка авыша: төп урынны төрле культлар, магик дәвалаулар, астрологик фаразлаулар ала. Мондый караш яклылар бүгенге кешелек дөньясы башлангычы Мәгърифәт гасырында салынган рационализмның чәчәк атуының соңгы фазасына керде дип исәпли.

Ихтимал, цивилизация «сайлау һәм җаваплылык йөгеннән билгеле бер дәрәҗәдә арыганлык туплады, астрологик алдан белү фәнни критицизмнан һәм даими шикләнүләрдән өстенрәк» дип уйлаучылар хаклыдыр. (Ә сез ничек уйлыйсыз?)

Төп төшенчәләр: фәнни теория, эмпирик закон, гипотеза, фәнни эксперимент, модельләштерү, фәнни революция.

Терминнар: дифференциацияләү, интеграцияләү.

Үзегезне тикшерегез

1. Фәнни танып-белүнең гадәтидән төп аермалары нәрсәдә? 2. Фәнни белемнәрнең эмпирик дәрәҗәсе нәрсә белән үзенчәлекле? 3. Фәннең теоретик дәрәҗәсенә нәрсә хас? 4. Фәнни танып-белүнең дәрәҗәләрен һәм ысулларын чагыштырыгыз. 5. Экспериментны гади күзәтүдән нәрсә аера? 6. Гипотезаның

фәнни танып-белүдәге роле нинди? 7. Фәнни модельләштерүгә мисаллар китерегез. 8. Фәнни белемне дифференциацияләү нәрсәдә чагыла? Аның сәбәпләре нинди? 9. Хәзерге шартларда фәнни белемне интеграцияләүгә нәрсә комачаулый? 10. Фәнни революция ничек үсә?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Немец философы К.Поппер астрологиянең фәнни булмавын менә ничек исбатлаган: астрологларның күрәзәчелеге билгесез, аларны тикшерү кыен, күпләгән күрәзәчелекләре тормышка ашмады, астрологлар үз уңышсызлыкларын аңлатуның канәгатьләнмәслек ысулын файдаланалар (шәхси киләчәкне алдан әйтү — катлаулы бурыч; йолдызлар һәм планеталар урнашуы даими үзгәреп тора һ.б.).

Бу мисалда фәнни һәм фәнни булмаган белем аермаларының нинди критерийларын күрсәтеп була? Башка критерийларны атагыз.

2. Пушкинның: «Фән безгә тиз узучы тормыш тәҗрибәләрен кыскарта»,— дигән юлларын үзегезчә аңлауны ачып бирегез.

3. Л.Пастер болай дип раслый: «Фән Ватанның иң югары гәүдәләнеше булырга тиеш, чөнки барча халыклар арасыннан беренче урында башкаларны фикер һәм акыл эшчәнлеге өлкәсендә узып киткәне булачак».

Әлеге нәтиҗә тарих барышы белән расланамы?

4. Түбәндәге тексттагы ялгышны табыгыз.

Катгый эмпирик белем фәкать күзәтү юлы белән генә туплана. Күзәтүгә эксперимент та якын. Ләкин ул инде катгый белем бирми, чөнки кеше монда өйрәнелә торган предметның табигатенә тыкшына: аңа хас булмаган мохит кертә, экстремаль шартларда сыный. Шулай итеп, эксперимент барышында алынган белемне өлешчә генә чын, объектив дип санарга була.

Чыганак белән эшләгез

Немец философы К.Ясперсның «Тарихның чыганаклары һәм аның максаты» дигән хезмәтеннән өзек укыгыз.

Хәзерге заман фәне

... Дөнья тарихына күз ташлап, без танып-белүнең өч этабын табабыз: беренчедән, ул теге яки бу формаларда гомумкешелек сыйфаты булган, кешедә күренә торган гомумән рациональләштерү; ... икенчедән, логик һәм методик аңланган фәннең — грек фәненең һәм параллель рәвештә Кытайда һәм Һиндстанда фәнни танып-белү яралгыларының формалашуы; өченчедән, Урта гасырлар ахырында үсә башлаган, XVII

гасырдан ныклап урнашкан һәм XIX гасырдан бөтен киңлегенә җәелгән бүгенге фәннең барлыкка килүе. Әлеге фән Европа мәдәниятен —һичьюгы XVII гасырдан — башка барлык илләр мәдәниятеннән аермалы итә...

Фәнгә зарури өч билге хас: танып-белү ысуллары, дөреслек һәм гомумәһәмиятлелек...

Бүгенге фән үзенең рухы белән *универсаль*. Озак вакытка аннан аерылып тора алган даирә юк. Дөньяда була торган һәр-нәрсә — табигать күренешләре, кешеләрнең эшләре яки әйткәннәре, аларның иҗатлары һәм язмышлары күзәтүгә, карауга, тикшерүгә дучар ителә. Дин, башка барлык авторитетлар да тикшеренү объекты булалар. Чынбарлык кына түгел, барлык фикерләү мөмкинлекләре дә өйрәнү объектына әверелә.

«Бердәнбер»гә юнәлдерелгән бүгенге фән үзенең *һәрьяклы* элемтәләрен ачарга омтыла... Барлык фәннәрнең үзара бәйләнгәнлеге идеясе «бердәнбер»не танып-белүдән канәгатьсезлек тудыра. Бүгенге фән универсаль генә түгел, ә бәлки ул фәннәрнең беркайчан да ирешә алмаслык берләшүенә омтыла.

Һәр фән ысул һәм предмет белән билгеләнгән, һәрберсе дөньяны күрү перспективасы булып тора, берсе дә дөньяны бар булганча төшенә алмый, һәрберсе чынбарлыкны түгел, ә чынбарлыкның бер буынтыгын колачлый,— бәлкем чынбарлыкның бер ягындыр, ләкин тулаем чынбарлыкны түгел, ләкин аларның һәрберсе иксез-чиксез, әмма шулай да элемтәләр калейдоскобында бердәм дөньяга керә...

Сораулар һәм биремнәр: 1. Автор танып-белүнең нинди этапларын аерып күрсәтә? 2. Бүгенге фәннең универсальлеге дигәндә философ нәрсәне күз алдында тота? 3. Белемне интеграцияләү һәм дифференциацияләү проблемасы текстта ничек аңлатыла? 4. Фәннәрнең тулысынча берләшә алмаслыгын автор нәрсә белән аңлата?

§ 25. Социаль танып-белү

Исегезгә төшерегез:

социаль фәннең табигать турындагы фәннәрдән аермасы нәрсәдә? Рухи өлкәдәге эшчәнлекнең үзенчәлекләре нинди?

Микроскоп өстендә башын игән, идарә итү пульты алдында микрокисәкчәләрне тизләтүче яки заманча телескоп терминалы белән утырган галимне күз алдыбызга китерик. Тере, микро- һәм макродөньяны өйрәнү җентекле күзәтүне, тикшерелгән исәп-хисап һәм экспериментларны, математик яки компьютер модельләре төзүне колачлый. Җәмгыятьне өйрәнгәндә дә

галимнәр күзәтәләр, чагыштыралар, исәплиләр, ә кайчак экспериментлар үткәрәләр (мәсәлән, психологик ярашлылык принцибына нигезләнеп, космик экипаж яки поляр экспедиция составын сайлаганда). Бу «җәмгыятьне өйрәнү өчен дә табигатьне өйрәнгәндә кулланган ысуллар кулланыла» дигәнне аңлатамы соң? Әлеге сорауга галимнәр төрлечә җавап бирә.

ТАБИГАТЬНЕ ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬНЕ ФӘННИ ТАНЫП-БЕЛҮ

Барлык фәннәр дә математик табигать белеме алымын кулланырга тиешлеге турындагы күзаллау әле XVIII гасырда ук замандашларны шаккатырган табигать белеме һәм аеруча математиканы механикада куллану йогынтысында барлыкка килә. Техниканың үсүе иҗтимагый җитештерү көчләренең моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә күтәрелүенә ярдәм итә, кешеләрнең көндәлек яшәешен үзгәртә. Табигать фәннәренең искиткеч мәдәни абруе механиканың ролен үрнәк буларак билгели, табигать фәннәре дә, иҗтимагый фәннәр дә шуңа яраклашып төзелергә тиеш була. Социологиягә нигез салучы француз галиме О.Конт җәмгыять турындагы фән кирәкле социаль күренешләрнең элемтәләрен табигый-фәнни ысуллар белән өйрәнергә тиеш дип саный һәм шуңа күрә ул социологияне «социаль физика» дип атый. Аның дәвамчысы Э.Дюркгейм кешегә тәэсир итүче һәм аны билгеле бер рәвештә эш итәргә этәрүче барлык иҗтимагый күренешләрне *социаль фактлар* дип исәпли. Социаль фактларга ул хокук һәм әхлак нормаларын, эшләрне алып баруның гадәти ысулларын, иҗтимагый хәрәкәтләрне һәм хәтта моданы да кертә. Э.Дюркгейм социологиядә фәнни алымның төп принцибы итеп *социаль фактларга әйберләргә кебек үк мөнәсәбәтне* саный. Бу исә, табигать күренешләренең сәбәпле үзара бәйләнешен өйрәнгән кебек үк, социаль фактлар арасындагы бәйләнешне һәм бәйлелекне ачу дигәнне аңлата.

XIX гасыр ахыры — XX гасыр башында *җәмгыять турында натуралистик күзаллауларның* киң таралуына сәнәгать капитализмы урнашуның — традицион җәмгыятьнең социаль структуралары таркалу һәм массакүләм җәмгыять барлыкка килүнең объектив иҗтимагый процесслары ярдәм итә. Нәкъ менә феодализмга хас катлаулы социаль иерархиядән мәхрүм ителгән массакүләм җәмгыятьтә иҗтимагый күренешләрне өйрәнү өчен математика алымнарын киң куллану мөмкинлеге туа да инде.

Ләкин мондый натуралистик карашларны барлык галимнәр дә уртаклашмый. Әйтик, немец философы У.Дильтей «рух турындагы фәннәр» «табигать турындагы фәннәр»дән принци-

пиаль рәвештә шуның белән аерыла, беренчеләре кеше белән — Галәмдә танып-белүгә генә түгел, ә кичерешләргә дә сәләтле бердәнбер зат белән эш итәләр дип исәпли. Бу — кеше аңының аның эчке тормышы бәйләнешләреннән килеп чыга торган аерым эшчәнлеге. Җәмгыять һәм мәдәният тормышына үзенең катнашы барлыгын аңлаган хәлдә, галим күңеленнән үткәрә, ягъни башка кешеләрне, ватандашларын һәм замандашларын, башка чорлар һәм башка мәдәниятләр текстларын һәм мәгънәләрен *аңлый*. У.Дильтей, табигать һәм иҗтимагый фәннәрнең төп аермасы ысулда: «Рух турындагы фәннәр» — *аңлаучы*, ә табигать турындагылары *аңлатучы* фәннәр, дип ышана.

Икенче бер немец философы, И.Кантның дәвамчысы Г.Риккерт та мәдәният турындагы фәннәр табигать турындагы фәннәрдән нык аерыла дип исәпли. Аның фикеренчә, аларның төп аермасы тикшеренүченең үзе тикшерә торган объектына ничек якын килүенә бәйле. Табигатьне өйрәнгәндә галим *гомумине*, ягъни өйрәнә торган предметның шул ук типтагы башка күренешләр белән охшашлыгын табарга тырыша. Ә мәдәният турындагы фәннәрдә исә галимнең игътибары иң элек *индивидуальгә*, ягъни әлеге күренеш өчен хас нәрсәгә юнәлдерелә. Нәкъ менә объектның кабатланмас индивидуальлеге аңа, *табигать объектларыннан* аермалы буларак, *мәдәният объекты* әһәмияте бирә дә дип ышана Г. Риккерт. Гәрчә кайбер социаль фәннәр (мәсәлән, икътисад) шулай ук гомумиләштерү алымнары куллана алсалар да, мәдәният өлкәсендәге тикшеренүләр барыннан да элек үткән вакыйгалардагы индивидуаль һәм кабатланмас нәрсәләр кызыктырган тарихчы эшен хәтерләтә. Өстәвенә, мәдәният материалы белән эшләп, галим аны һәрвакыт гомумәһәмиятле әхлак, сәясәт, хуҗалык, сәнгать, дин *кыйммәтләре* белән чагыштырып карый. Гомуми кыйммәтләр белән чагыштырып карау, галим фикеренчә, мәдәният турындагы фәннәргә табигать турындагы фәннәр кебек ук *объектив* булырга ярдәм итә.

Җәмгыятьне объектив фәнни танып-белүнең кыенлыклары нәрсәдә соң?

Классик табигать белемендә фәнни тикшеренүнең объективлыгы дигәндә табигатьне кешегә бәйсез рәвештә, ягъни табигатьне «үз-үзендә» тикшерү аңланган. Шунлыктан элементар кисәкчәләрнең яки хайваннарның үзләрен тотышын өйрәнүче галим үзен тикшеренү хәленнән чыгарырга тырыша. Ләкин ул, гәрчә аерым рәвештә булса да, аңа кертелгән: ул «табигатьне күзәтүче сәнгате белән кысрыклаган» һәм табигатькә юнәлдерелгән, җавап табарга теләгән сорау формалаштырган. Ләкин җәмгыятьне тикшерүче галим үзен иҗтимагый үсеш процессыннан чыгара алмый, ә аның тикшеренүләренең нәтиҗәләре

аның үз тормышына гына түгел, аның балаларының киләчәгенә дә йогынты ясаячак. Социаль танып-белү кешеләрнең *мәнфәгатьләренә* — кешеләр белән көндәлек тормышта һәм эшлекле мөнәсәбәтләрдә идарә итүче тотрыклы социаль ориентлашуга кагыла. Бүгенге галимнәр иҗтимагый тормыш күренешләрен төрлечә аңлату — *фикерләр плюрализмы (төрлелеге)* булу мөмкинлеге турында сөйлиләр. Алар шәхси мәнфәгатьләр, өстенлеккә омтылу яки тормыш тәҗрибәсе аерымлыгы белән генә түгел, ә кешеләрнең иҗтимагый мөнәсәбәтләр системасында төрле хәлдә булуларын чагылдыручы *социаль мәнфәгатьләр* туры килмәү аркасында да туа. Социаль танып-белү нәтиҗәләрен табигать белемендәге гомумәһәмиятле фикер йөртүләрдән аерып торучы караш һәм бәяләмәләр күптөрлелеге шуның белән аңлатыла. М.Вебер корпоратив мәнфәгатьләрнең социаль танып-белүгә йогынтысына мондый мисал китерә. Җинаятьләр статистикасын төзегәндә полиция, «мундир намусын» сакларга тырышып, ачылмаган теләсә кайсы үтерүне «үз-үзен үтергән» дип күрсәтергә тырыша, ә шул ук вакытта чиркәү, үз-үзеңне үтерүнең иң зур гөнаһ икәнен исәпкә алып, шикле хәлләрне «җинаять» дип күрсәтү яклы. XVII гасыр Англия философы Т.Гоббс гомумән дә, әгәр геометрия кешеләр мәнфәгатьләренә кагылса, аны инкарь итәрләр яки дәшми калырлар иде, ди. Социаль мәнфәгатьләрнең социаль танып-белүгә йогынтысы *идеологиядә* — сәяси партияләр һәм киң иҗтимагый оешмаларның социаль мәнфәгатьләрне сайлау алды декларацияләрендә, программаларында теоретик чагылдырылуында аеруча ачык күренә. Төрле сәяси партияләр яки сайлау алды берләшмәләренең идеологик күрсәтмәләрен чагыштырып, барыннан да элек аларның кайсы иҗтимагый көчләр мәнфәгатьләрен чагылдыруларын ачыкларга кирәк.

Әгәр без табигатьне сәбәп һәм нәтиҗә төшенчәләре ярдәмендә танып-белсәк, кешенең эшләрен, ниятләрен, максатларын өйрәнеп беләбез. Әгәр табигатьтә сәбәптән соң нәтиҗә килсә, бер кешенең ниятләре һәм максатлары катлаулы рәвештә башка кешеләр ниятләре һәм максатлары, шулай ук традицияләр, әхлак һәм җәмгыять законнары белән үзара эш итеп, һәрвакытта да эш-гамәлдә гәүдәләнмәскә мөмкин. Социаль нормалар һәм үз-үзеңне тотуның социаль әһәмиятле мотивлары күздә тоткан эшләрдән аңлы рәвештә баш тарту (мәсәлән, товарны билгеләнгән бәядән арттырып сату, судка бармау, җаваплылыктан качу) — кулдан ычкындырылган мөмкинлек һәм җинаятьчел эшлексезлек кебек үк, социаль эшләрдән ким булмаган объектив социаль фактлар.

Фәнни социаль белем кешенең эш-гамәлләре һәм аларның нәтиҗәләре, ягъни мәдәнияттәге һәм иҗтимагый тормыштагы

вакыйгалар белән эш итә. Ул даирә кешеләндерелгән, аңлашылган һәм фикерләнгән. *Мәгънә* төшенчәсе предметка карата үзенчәлекле, кешеләргә хас мөнәсәбәтне белдерә. М.Вебер җәмгыятьне социологик тикшерену аерым кешеләр эшләренең мәгънәсен ачуга юнәлдерелгән, ахыр чиктә алардан бөтен иҗтимагый тормыш барлыкка килә дип исәпли. Ләкин социаль нәрсәләрнең: мәгънә, мотив, ниятләрнең субъектив үлчәмнәрен ничек итеп фәнни өйрәнергә мөмкин? Чөнки, табигать фәннәре объектларыннан аермалы буларак, алар матди түгел һәм объектларның үзләрен түгел, ә теләсә нинди объектларга карата кешенең мөнәсәбәтен белдерәләр.

Күргәнебезчә, җәмгыятьне объектив фәнни танып-белү юлында кыенлыклар бик күп. Социаль белем төгәллегенең һәм объективлыгының җитәрлек дәрәҗәсенә ирешү өчен галим нәрсәне җитәкче кулланма итеп алырга тиеш?

ФӘННИ СОЦИАЛЬ ТАНЫП-БЕЛҮНЕҢ ТӨП ПРИНЦИПЛАРЫ

Әлеге кыенлыкларны җиңү өчен, иҗтимагый тормыш күренешләрен өйрәнгәндә галим *фәнни алымнар* кулланып эш итә. Җәмгыятьне өйрәнүче галим белем табуның *гомум фәнни*, ягъни һәм табигать фәннәренә, һәм иҗтимагый фәннәргә хас ысулларга һәм фәнни тикшерену нормаларына таяна. Аларга фактларга нигезләну, теоретик төшенчәләрнең катгыйлыгы һәм бертөрлелеге, фикерләүләрнең дәлиллелеге, аларның логик яктан бер-берсенә каршы килмәве, фәнни нәтиҗәләрнең объективлыгы, ягъни фәнни хакыйкатьнең шәхси теләкләрдән, фикерләрдән һәм иҗтимагый хорафатлардан бәйсезлеге керә.

Әмма җәмгыятьне танып-белүнең үз үзенчәлекләре дә бар. Тикшерелә торган предметка үзенең контрольдә тотылмаучы йогынтысын булдырмаска тырышучы һәм фәнни белемнең объективлыгына ирешүне шунда күрүче табигатьне тикшерүчедән аермалы буларак, җәмгыять белгече-галим үзе дә шуңа керә торган предметны тикшерә: ул социаль тормышны тикшеренүче дә, анда катнашучы да. Ул гына да түгел, башка кешеләрне, мәдәниятләрне һәм тарихи чорларны уңышлы танып-белүнең шарты — уртак кайгыру, хәлгә керә белү, башка кешеләр күргән һәм тойган кебек үк күрә һәм тоя белү сәләте дә икән. Галим үзе дә — ул күзәтә торган кешеләр кебек үк эш итәргә омтылган «катнашучы күзәтүче» хәлендә; бу аеруча әһәмияткә ия. Ләкин шул ук вакытта ул үз фикерләвенең анық үз тормышыннан, белеме, тәрбиясе һәм фәнни мәктәбе традицияләреннән алынган алшартларга бик тә игътибарлы булырга тиеш: аларга игътибарсызлык башка кешеләр тормышын

һәм мәдәниятләр күренешен бозып күрсәтергә мөмкин. Шунлыктан М.Вебер галимне «объектка карата дистанция сакларга» чакыра һәм, башкаларны өйрәнгәндә үзеңнең социомәдәни тәҗрибәңә тәнкыйтьсез карау көндәлек тормыштагы эгоизм кебек үк гаепләнә, дип кисәтә.

Җәмгыять белгече-галим өйрәнә торган объектының үзенчәлекләрен тулы итеп тасвирларга омтыла. Бу теләсә кайсы социаль күренешне аның тарихи үсешендә һәм башка социаль күренешләр белән үзара элемтәдә, ягъни *тарихи һәм мәдәни контекстта* карарга кирәк дигәнне аңлата. Мәсәлән, Якобинчылар терророның табигатен аңлар өчен, аны аерым вакыйга итеп түгел, ә Бөек француз революциясенең контекстында, аның үсешенең бер этабы буларак карарга кирәк. Үзенә дә *конкрет-тарихи* якын килергә, аны Европа тарихының башка вакыйгалары белән системалы бәйләнештә тикшерергә һәм бер үк вакытта — ул вакыттагы җәмгыятьнең төрле катлау вәкилләренең элеге вакыйгага ничек карауларын һәм нәрсә кичерүләрен дә күздән ычкындырмау мөһим.

Тарих фәне безгә вакытлар бәйләнешен аңларга ярдәм итә, аннан башка үткәндәге вакыйгалар аерым эпизодлар сериясенә таркалыр иде. Ул тарихи документларга — борынгы ата-бабаларыбызның тормышы турында күзаллау төзергә ярдәм итүче дәлилләргә таяна. Әмма фән факты тормыштагы вакыйга түгел. Ул үткәннәрне җентекләп тасвирлау да түгел.

Фәнни факт һәрвакыт өйрәнелә торган иҗтимагый күренештәге *әһәмиятлене* ачуны күздә тота. Аңа галимнең үткәннәрдә социаль фактның роленә бәясе, аны *интерпретацияләве* (ачып-аңлатып бирүе) керә. Бербөтен фәнни теория булдырып, галим социаль закончалыкларны аңлау өчен үзенә билгеле фактларның нәкъ менә кайсылары әһәмиятлерәк икәнен билгели. Аның теоретик күрсәтмәсе, бер яктан, булуларын аның концепциясе әйтеп торган яңа фактлар эзләү юнәлешен үзе билгели, икенче яктан, бу концепция белән ярашмаган башка фактларны табу аны ачыклауны, ә кайчак, дөрес булмаганлыктан, кире кагуны таләп итә.

ИДЕАЛЬ ТИП — ФӘННИ СОЦИАЛЬ ТАНЫП-БЕЛҮ КОРАЛЫ

Фәнни социаль танып-белүдә, табигать турындагы фәннәрдәге кебек үк, *фәнни төшенчәләр* кулланалар. Социаль гамәлләрне өйрәнгәндә галимнәр аерым төр төшенчәләргә — *идеаль типларга* мөрәҗәгать итәләр.

Идеаль тип билгеле бер социаль гамәлләр субъектының мөһим, тотрыклы кабатланучы сыйфатларын гәүдәләндерү мөм-

кинлеге бирә. Мәсәлән, капиталистик эшмәкәрнең идеаль тибын сурәтләп, М.Вебер, эшкәртә торган урынга — чимал, базарга товар ташып, көн саен авылдан шәһәргә чабучы, дәрвиш тормышы алып баручы, протестант дине тотучы яшь кеше портретын сурәтли. Әлбәттә, идеаль тип сәнгати образ тәгәллегеннән мәхрүм. Без яшь кешенең исемен, кайда яшәвен, нәкъ менә нинди товар җитештерүен белмибез. Ләкин фәнни социаль танып-белү өчен нәкъ менә характеристикаларның гомумиләштерелүе мөһим: дөньяны сәнгатьчә аңлауда конкретлыкта оттырып, идеаль тип булган хәл кысаларыннан чыгарга һәм, кайда һәм нинди хәлләрдә баруына карамастан, билгеле бер социаль гамәл субъектының конкрет, тотрыклы кабатланучы үзенчәлекләрен сурәтләргә мөмкинлек бирә. Идеаль-типиклаштыручы методология М.Веберга, төрле илләрдәге конкрет шартларның күптөрлелегенә нисбәтсез рәвештә, капитализмның Көнбатыш Европада барлыкка килүе процессы закончалыкларын теоретик чагылдырырга ярдәм итә.

Идеаль типлардан файдалану галимгә кешеләрнең зур төркемнәренең, сыйныфларның, дәүләтләрнең тотрыклы һәм системалы яңарып торучы мөнәсәбәтләре турында белем алырга булыша. Идеаль типлар ярдәмендә галим киләчәккә дә карый ала, ләкин заманның типик дип тәкъдим ителгән сыйфатлары үз әһәмиятләрен киләчәктә саклаячак кадәр генә.

Социаль анализлау коралы буларак, «идеаль тип» конкрет кешенең үз-үзен тотышын сурәтләү түгел. Ул — социаль процессның реаль тормышны аның асыл сыйфатларында гәүдәләндерүче фәнни күренеше персонажы.

ГАДӘТИ ҺӘМ ФӘННИ СОЦИАЛЬ БЕЛЕМ

Моңарчы без бары тик фәнни социаль белем турында гына сөйләдек. Ләкин социаль белем төшенчәсе шактый киң. Ул кеше һәм җәмгыять турында тупланган, халык авыз иҗаты традицияләрендә, китапларда, фәнни басмаларда, сәнгать әсәрләрендә һәм тарихи һәйкәлләрдә ныгытылган, галимнәр өчен документлар ролен уйнаучы белемнәрнең бөтен массивын колачлый.

Социаль белем фәнни генә түгел, гадәти, ягъни көндәлек тормыштан алынган булырга да мөмкин. Фәнни белем һәрвакыт аңлы, системалаштырылган була һәм фәнни алым таләпләренә җавап бирә. Гадәти белем, кагыйдә буларак, системалаштырылмаган һәм хәтта аңланып бетмәгән — ул гадәти яки йола рәвешендә булырга мөмкин. Фәнни танып-белү фәнни бергәлеккә берләшкән, профессиональ әзерлек үткән кешеләр тарафыннан гамәлгә ашырылса, гадәти танып-белү субъекты

тулаем җәмгыять була. Табигый-фәнни белем белән чагыштырганда, фәнни социаль белем үзенчәлекләренең берсе шунда: фәнни социаль белем объекты, кагыйдә буларак, гадәти фикерләү тарафыннан тегеләйме-болаймы инде үзләштерелгән була. Табигатьнең фәнни картинасы физик кырлар һәм кисәкчәләр өчен бернинди әһәмияткә дә ия булмаса, җәмгыятьнең фәнни картинасы кешеләр тарафыннан инде көндәлек тормышта аңланган чынбарлыкны чагылдыра. Һәм гадәти белем дәрәҗәсендә үзләштерелгән шушы социаль дөньяны галим, үз чиратында, фәнни алым кагыйдәләре белән үзләштерергә тиеш. Ләкин бу гадәти белем — ялгыш, ә фәнни — дөрес дигәнне аңлатмый. Хәзерге галимнәр социаль белемнең ике төре дә иҗтимагый тормыш өчен бер үк дәрәҗәдә мөһим дип саный. Фән кешеләрнең гадәти, шул исәптән ялгыш күзаллауларын да исәпкә алырга, җәмгыятьнең барлык катлаулары фикерен өйрәнергә тиеш.

Бүгенге җәмгыять көндәлек тормышка катлаулы техник җайланмаларны гына түгел, икътисади, сәяси, юридик һәм башка өлкәләрдә хәбәрдарлыкны таләп итүче социаль үзара мөнәсәбәтләрнең катлаулы формаларын да кертә. Шунлыктан бүгенге кеше гадәти тормышта фәнни белем элементларына мөрәҗәгать итми кала алмый. Хәзерге җәмгыятьтә гадәти белем үзенә фәнни белем элементларын да ала. Әлбәттә, телефон трубкасын күтәргән кешегә аның тавышын йөзләрчә километрга нинди техник җайланмалар ишеттерүен белү мәҗбүри түгел, әмма ул телефон аппаратының тавыш тирбәлешләрен электр тирбәлешләренә әверелдереп җиткерүен күзаллый. Бүгенге кешедә мондый хәбәрдарлык фәнни социаль белемгә карата да бар. Банкта счет ачкан кешегә кәгазь акчаларның әйләнү законнарын белү мәҗбүри түгел. Ләкин ул акча турында үзенең эш бирүче белән иҗтимагый мөнәсәбәтләрен көйләү ысулы булуы, инфляция, банк проценты турында белә. Гадәти социаль танып-белүгә массакүләм матбугат чаралары бик зур йогынты ясый. Бүгенге кеше дөнья хәлләрен газета, радио һәм телевидение аша белә. Тормышыбызга үтеп кереп, массакүләм матбугат чаралары тамашачыга, укучыга, тыңлаучыга җәмгыятьтә бара торган хәлләр турында журналистлар җәмәгатьчелегенең килештерелгән фикерен җиткерә. Чөнки журналист вакыйга турында еш кына очраклы, әмма тәэсир итәрдәй нәтиҗәле детальләр роленә игътибар биреп хәбәр итә. Галимне исә, киресенчә, өйрәнелә торган күренешнең асылы очраклылыклардан арындырылган хәлдә кызыксындыра. Моннан тыш бара торган вакыйгаларны яктырту массакүләм матбугат чараларының хакимияткә һәм финанс корпорацияләренә ни дәрәҗәдә бәйле булуларына, ягъни җәмгыятьтә сүз

ирегенең ирешелгән дәрәҗәсенә бәйле. Шунлыктан һәр кеше, җәмгыятьтә бара торган вакыйгаларга бәя бирә алсын өчен, социаль белем запасына ия булырга, төрле чыганаклардан алынган хәбәрләрне чагыштыра, анализлый белергә тиеш.

СОЦИАЛЬ ФӘННӘР ҺӘМ ГУМАНИТАР БЕЛЕМ

Социаль белемгә социаль фәннәр һәм көндәлек күзаллаулар гына түгел, гуманитар белемнәрнең гаять зур өлкәсе дә керә. Социаль фәннәргә җәмгыятьне фәнни танып-белүнең фәнни алымы кагыйдәләрен тотучы барлык төрләрен кертәләр. Болар, белгәнегезчә, социология, икътисад, сәясәт белеме, хокук белеме, этнография һ.б. Социаль фәннәр халыклар, сыйныфлар һәм профессиональ төркемнәр арасындагы чагыштырмача тотрыклы һәм системалы төстә яңартылып торыла торган элемтәләр турында белемнәр җитештерәләр. Социаль фәннәр үз предметларын кешеләрнең эш-гамәлләрендә, җәмгыятьтә һәм мәдәнияттә тотрыклыны һәм кабатланучыны теркәү мөмкинлеге бирә торган идеаль типлар ярдәмендә өйрәнәләр.

Гуманитар танып-белү кешенең рухи дөньясына юнәлдерелгән. Гуманитар белемнәр көндәлекләрдә, рецензия, танылган кешеләрнең тормыш юлларын тасвирлауда, ясалган чыгышларда, программ белдерүләрдә, әдәби тәнкыйть, сәнгать белеме, лингвистика, әдәбият белемендә сакланалар. Социаль фәннәр һәм гуманитар белем арасындагы чик катгый түгел. Социаль фәннәр, кешенең тормыш итү дөньясы белән элемтәне саклап, гуманитар белем элементларын колачлый. Тарихи закончалыкларны һәм идеаль-типик үзенчәлекләрне тикшергәндә тарихчы социаль галим буларак эш итә. Катнашучы кешеләрнең мотивларына мөрәҗәгать итеп һәм көндәлекләрне, хатларны, чыгыш текстларын өйрәнеп, ул галим-гуманитар ролен үти. Әмма гуманитар белемдә дә социаль белем элементлары бар. Галимнәр бүгенге иҗтимагый фәннәрдә һаман саен күбрәк кулланыла торган биографияләр төзү һәм аерым очракларны тасвирлау кагыйдәләре турында сөйлиләр. Әдәби әсәрләрне бәяләү дә, үз чиратында, тәнкыйтьченең субъектив фикерен генә белдерү түгел, ул әдәби композициянең художестволы образларын, сәнгатьчә тәэсирлек чараларын һ.б. анализлауга таяна.

Кешенең рухи дөньясына, аның кичерешләренә, куркуы һәм өметләренә юнәлдерелгән гуманитар белем аңлауны таләп итә. Текстны аңлау, — димәк, аңа мәгънә бирү. Ләкин ул аны иҗат итүче күздә тотканча булмаска мөмкин. Без аның фикерләре һәм хисләре турында дөресен белә алмыйбыз, алар турында теге яки бу дәрәҗәдәге ихтималлылык белән хөкем

йөртәбез. Ләкин без һәрвакыт текстны *үзебезчә аңлыйбыз*, ягъни аңа үзебез аңлаганча автор күздә тоткан мәгънәне бирәбез. Ә инде автор биргән мәгънәгә якын килү өчен әсәрнең кем һәм нинди хәлләрдә язуын, авторның аралашу даирәсе нинди булуын, аның үз алдына нинди бурыч куюын белү файдалы. Кеше текстка үзенең социаль белем запасына карап мәгънә сала. Шунлыктан сәнгатьнең бөек әсәрләре миллионнарча кеше йөрәгендә төрлечә аңлау таба һәм үз әһәмиятен күпләгән буыннар өчен саклый.

Табигый-фәнни белемнең катгыйлыгына һәм универсальлегенә ия булмастан, гуманитар белем мәдәнияттә мөһим урын тота. Кешенең рухи дөньясына юнәлдерелеп, гуманитар белем анда рух күтәренкелегенә һәм гүзәллеккә омтылыш уята, аның омтылышларын сафландыра, әхлакый һәм дөньяга караш эзләнүләре барлыкка китерә. Ул эзләнүләр тулырак рәвештә философиядә тупланган, ләкин һәр кеше яшәү һәм танып-белү, әхлакый камиллек һәм җәмгыятьнең акыллы төзелеше мәсьәләләре турында үзе уйланган дәрәҗәдә — философ. Гуманитар белем дөньясына кереп, кеше иң якын шәхси аралашу вакытында мөмкин булмаган тирәнлектә үзенең танып-белү офыкларын киңәйтә, башкаларның һәм үзенең эчке дөньясын белергә өйрәнә. Гуманитар мәдәнияттә кеше социаль күзаллау сәләте ала, җәмгыятьтә бергә яшәү мөмкинлеге бирә торган уртак кичереш сәнгатенә, башкаларны аңлау сәләтенә ия була.

Төп төшенчәләр: фәнни социаль белем, гадәти белем, социаль танып-белү алымнары, социаль факт, мәгънә, кыйммәтләр, үзебезчә аңлау.

Терминнар: мәдәни контекст, конкрет-тарихи якын килү, идеаль тип.

Үзегезне тикшерегез

1. Табигый-фәнни белән чагыштырганда социаль белемнең үзенчәлеге нәрсәдә? Табигый-фәнни, социаль һәм гуманитар белемнәрнең объективлыгы нәрсә белән аерыла? 2. Социаль фактны вакыйга, тормышта булган белән тәңгәлләштерү мөмкинме? 3. Текстны, эш-гамәлне, тарихи документны үзеңчә аңлау нидән гыйбарәт? Дөрес аңлау нәрсә ул? Бердәнбер дөрес аңлауга ирешеп буламы? 4. Идеаль тип художестволы образдан нәрсә белән аерыла? Идеаль типны конкрет кешене фәнни сурәтләү дип буламы? 5. Гадәти белем — ялгыш, ә фәнни белем дөрес дип раслау белән килешәсезме? Иҗтимагый фикерне өйрәнү ни өчен кирәк?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Матбугатның иҗтимагый көчләр ничек урнашуга бәйле

булуын күздә тотып, бүгенге философ П.Бергер болай дип яза: «Кемнең таягы озынрак, шуның җәмгыятькә үз карашларын көчләп тагу мөмкинлеге күбрәк». Сез моның белән килешәсезме?

2. Тарихның килештеру төркемчәсе юк дигән фикер яши. «Булырга мөмкин иде» дигәнне тикшерергә кирәкме? Кулдан ычкындырылган шанс һәм югалган мөмкинлек социаль факт-лар була аламы? Үз җавабыгызны аңлатыгыз.

3. Социаль белемне социаль фәннәргә һәм гуманитар белемгә бүлү кабул ителгән. Протагорның: «Кеше — барча нәрсәләрнең үлчәме»,— дигәнен аларның кайсысына кертеп була?

4. Ике эшче турында мондый сүз йөри. «Нәрсә эшлисез?» дигән сорауга берсе: «Таш ташыйм»,— дип, икенчесе: «Сарай төзим»,— дип җавап биргән. Бер җавап дөрес, икенчесе ялган дип буламы? Үз җавабыгызны дәлилләгез.

5. Немец философы У.Дильтей: «Аңлау, — димәк, шәхсән кичерү»,— дигән. Сез моның белән килешәсезме? Кеше үзе кичермәгәнне аңлый аламы? Шәхсән кичерелгән нәрсә һәрвакытта да аңлашыламы?

6. А.С.Пушкинның «Борис Годунов» трагедиясендә елъязмачы Пимен Григорий Отрепьевны өйрәтә: «Тормышта шаһит булганнарыңның барысын да хәйлә кормыйча яз»,— ди. Тарихи вакыйгаларны үзеңчә күрү-аңлаудан тыш сурәтләү мөмкинме? Тарих курсыннан алган белемнәрегездән файдаланып, үз нәтиҗәгезне конкретлаштырыгыз.

7. Күз алдыгызга китерегез: янәсе, сез, Миклухо-Маклай кебек, туземец кабиләләре тормышын өйрәнергә киттегез ди. Барыннан да элек сез нәрсәгә игътибар итәр идегез:

— күзгә күбрәк ташланганга;

— туземецлар тормышында безнекеннән аерым булган нәрсәләргә;

— практик эшчәнлекнең тотрыклы һәм кабатлана торган формаларына?

Чыганак белән эшләгез

А.Шюц китабыннан өзек белән танышыгыз.

Табигать фәннәре һәм социаль фәннәр турында

Социаль фәннәрдә төшенчәләр һәм теорияләр формалашу мантыйкны өйрәнүчеләрне һәм методологларны гына түгел, социаль галимнәрнең үзләрен дә ярты гасырдан артык вакытка ике лагерьга бүлә. Берәүләре табигать фәннәренең шундый искитмәле нәтиҗәләргә китергән алымнары гына фәнни, димәк ки, кеше гамәлләрен өйрәнү өчен фәкать алар гына кулланылырга тиеш дигән караштә тора. Раслауларынча, аларны кул-

ланудан баш тарту социаль фәннәргә тәгәллек буенча табигый-фәнниләре белән чагыштырыла торган аңлатучы теорияләрне үстерү мөмкинлеге бирми...

Икенче мәктәп вәкилләре социаль фәннәр һәм табигать фәннәре дөньялары структурасында фундаменталь аерма күрә. Мондый тою икенче бер чиккә — социаль фәннәр табигать фәннәреннән бөтенләй аерыла дип раслауга китерә. Бу карашларны яклауга күпләгән дәлилләр китерелде. Табигать фәннәре гомумиләштерүче фәннәр булып тора, аларга гомуми дөрес фикер йөртүләр хас булган бер вакытта, социаль фәннәргә индивидуальләштерелгән якын килү һәм бердәнбер раслаучы фикерләүләр хас дип раслана. Кыскасы, әлеге мәктәп яклылар, табигать фәннәре — матди объектлар һәм процесслар белән, ә социаль фәннәр психологик һәм интеллектуальләре белән эш итәргә тиеш; шулай булгач, беренчеләренең алымы — аңлату, икенчеләренеке — аңлау, дип раслыйлар.

Сораулар һәм биремнәр: Табигать турындагы фәннәрдә аңлауга ирешү мөмкин түгел, ә кеше турындагы фәннәр берни дә аңлатмыйлар дигән белән килешәсезме?

§ 26. Белем һәм аң

Исегезгә төшерегез:

нәрсә ул фикерләү? Нәрсә ул белем? Социаль танып-белүнең үзенчәлекләре нинди?

Галимнәр аңның асылы, килеп чыгышы һәм вазыйфалары турында бәхәсләшәләр. Бу төшенчә «белем» төшенчәсеннән нәрсәсе белән аерыла?

Күп еллар мәктәптә укыган кешегә «белем» сүзенең нәрсә белдерүен аңлату кирәкми. Белү, хәбәрдар булу, төшенү — чынбарлыкның теге яки бу өлкәләрендә мәгълүмат җыелмасына ия булу дигән сүз. Белемгә белмәү, наданлык каршы куела.

Аңны өйрәнү белән психология, философия шөгыльләнә.

НӘРСӘ УЛ АҢ?

Аңның асылын аңлау рух һәм табигатьнең, материя һәм аңның үзара бәйләнеше мәсьәләләрен хәл итүгә турыдан-туры бәйле. Идеальнең беренчелеген тану аңны дөньяны иҗат итүче мөстәкыйль «асыл» дип аңлауга китерә. Мондый караш Антик дәвердә Платон философиясендә чагылдырылган. Урта гасырда мондый якын килү христиан фәлсәфәсендә китерелгән (иң

югары аң иясе — Алла). Яңа вакытта немец классик философиясендә ул Г.Гегель карашларында үстерелгән.

Материалистик философия аңны югары дәрәҗәдә оештырылган материя, объектив дөньяның субъектив образы, идеаль, ягъни субъектив чынбарлык, аңланган яшәеш сыйфаты итеп карый.

Аң проблемасын хәл итү аның барлыкка килүе алшартларын ачыклауны да күздә тота. Материализм аларны материянең нигезендә ятучы чагылдыру үзенчәлегендә күрә. Аң хезмәт процессында барлыкка килә, социомәдәни чынбарлык йогынтысы астында үсә һәм байый. Практика әһәмиятле роль уйный. Аңның үзәк өлешен белем тәшкил итә. Шуңа күрә материализм аңны объектив дөньяның субъектив образы дип бик хаклы билгели. Бу — белемгә ия булган кешенең үзен әйләнә-тирә дөньядан аерылып тору сәләтенә һәм үзен субъект буларак объектка каршы тора алу белеменә ия икәнлеге билгесе. Аң — эшчәнлек образын һәм аның барышында алына торган нәтиҗәне алдан фикерләп төзү дә ул. Аңның үзенчәлекләре — активлык һәм сайлап алучанлык, субъективлык һәм иҗади башлангыч. Әлеге үзенчәлекләрнең берсе шунда: аң компонентлары — чынбарлык образлары һәм күзаллау образлары, сүзләр, хисләр, ихтыярлык импульслары һәм башкалар — ул компонентларның нәрсә тирәсендә туплануына бәйле рәвештә, бербөтен картина барлыкка китерәләр. Аң, әйтик, көзгегә яки тирәлек чынбарлыгын чагылдыручы су өсте тигезлегенә һич тә охшамаган. Әлеге чынбарлык гаҗәеп рәвештә сынып күрсәтелә, төрле өлешләрдән җыела.

Аң нәтиҗәсендә барлыкка килгән идеаль чынбарлык төрле кешеләр өчен төрлечә булырга мөмкин. Берәүне дулкынландырган бер нәрсәнең башкаларны битараф калдыруы ихтимал. Аң безгә мәгънәле булган образларны саклый. Мондый сайлап алучанлык шәхсән дәрәҗәдә дә, иҗтимагый дәрәҗәдә дә чагыла.

«Кеше — табигатьтәге иң кечкенә булмыш, ләкин аңлы булмыш».

Блез Паскаль

Аңның иң мөһим компонентлары — ихтыяҗлар һәм ихтыяр. Дөнья белән үзара эш итү аң иясе буларак кешедә дөньяда карата билгеле бер мөнәсәбәт тудыра. Бу исә фикерләү бәяләмәләрендә генә түгел, ә хисләрдә, кичерешләрдә дә чагыла. Танып-белү процессы кешенең эчке дөньясының барлык якларына — ихтыяр, ихтыяҗ, мәнфәгать, хисләренә кагыла. Тәҗрибәне саклау, үткән белән хәзерге, шулай ук хәзерге, үткән һәм киләчәк арасында күперчек салу мөмкинлеге тудыручы

хәтер мөһим роль уйный. Аңның предметы тышкы дөнья гына түгел, ә субъект үзе дә, аң иясе булганлыктан, үзаң аңның мөһим моменты булып тора. Үзаң — кешенең үз эшчәнлеген, хисләрен, кичерешләрен, мәнфәгатьләрен, ихтыяҗларын аңлавы ул. Аның турында сүз алдагы параграфта булачак.

Эчке «аңлы» аңа еш кына каршы куелучы «аңсыз» белән бәйле, өстәвенә «аңсыз»га кеше тормышында хәлиткеч роль бирелә. Ләкин «аңлы»ның өстенлегеннән килеп чыгучы башкача караш та бар. «Аңсыз»ны аңлы эшчәнлек продукты дип карарга мөмкин. Элек «аңлы» өлкәсендә булган нәрсә «аңсыз»га күчә. Үз чиратында, кешенең тирән психикасында яшәүче «аңсыз» яңадан аң өлкәсенә күчәргә сәләтле.

Шуның белән бергә, бүгенге психология белемгә караган һәр нәрсә дә аңланып бетми дигән каршылыкка очрады.

Белем ул — кеше белгән нәрсә генә түгел, ә бәлки ул хәзерге вакытта уйламаган, шунлыктан аңламаган, ләкин җиңел генә аның байлыгы итәргә мөмкин булган нәрсә дә (мәсәлән, укучының суның химик формуласын, геометрик теоремаларны яки үз биографиясе фактларын белүе һ.б.). Ул шулай ук кеше белгән, куллана торган, ләкин зур кыенлык белән аңлана торган, — әгәр гомумән дә шулай була алса, — нәрсә дә. Ул, мәсәлән, экспертлар куллана торган «ябык» белем. Фәннең билгеле бер өлкәсендәге нинди дә булса әһәмиятлене белә торып та, эксперт (үз белемнәрен аңа бирелгән объект яки теория белән чагыштырып карау һәм әлеге объектның аңа билгеле булганга ни дәрәҗәдә туры килүен билгеләү таләп ителгән очракка кадәр) моны үз белемнәренең гомуми суммасыннан аерып алмый торырга мөмкин. Фәнни теорияләрнең барлык алшартларын һәм нәтиҗәләрен аңлау бары тик билгеле бер шартларда гына мөмкин һәм беркайчан да тулы булмый. Моннан тыш кайбер кичерешләр һәм теләкләр, шәхеснең кайбер тирән инанулары аңлауга бирелми (алар турында сүз шәхеснең юнәлгәнлеге турындагы параграфта булачак). Әйтелгәннәрдән белем аңның кирәкле, әмма җитеп үк бетмәгән шарты булып тора дигән нәтиҗә ясарга була.

Кайбер философлар аңның төп билгесе сыйфатында белемне түгел, ә билгеле бер предметка, объектка юнәлгәнлекне аерып күрсәтәләр. Кеше нинди дә булса объект турында берни дә белмәскә мөмкин, әмма ул аны аерып алса, аңа үз мәнфәгатен юнәлтсә, әлеге объект аңлау объектына әверелә.

Дж.Локк белемнең ике чыганагы: тышкы дөнья белән бәйле тоюлар һәм, акылның үз эшчәнлеген күзәтүче буларак, рефлексияләр турында теорияләр әйтә. Соңгысы, Локк фикеренчә, аң була да инде. Болай аңлаганда, аң субъект аңлый торган үзенчәлекле чынбарлык, аерым эчке дөнья ролендә була.

Танып-белү ысулы үзкүзәтү формасында чагылырга мөмкин булган үзләштерү була.

Аңның асылына карата тагын бер караш — аны шәхси һәм коллектив идеяләр җыелмасы итеп аңлау. Иҗтимагый аң, сыйнфый аң турында сөйләп, Г.Гегель һәм К.Маркс «аң» терминын нәкъ менә шул мәгънәдә кулланганнар. Иҗтимагый аң төшенчәсе марксизм философиясендә киң кулланылыш таба.

ШӘХСИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ АҢ

Иҗтимагый аң аерым шәхесләр аңыннан башка була алмый. Шәхсән яшәү чикләреннән чыгып, уртак байлык, уртак кагыйдә яки инануга әверелгәч, уртак аңга, әхлак, сәнгать, фән, хокукка, үзеңне тоту кагыйдәләренә кергәч, шәхси идеяләр һәм инанулар иҗтимагый кыйммәт характеры ала. Бу вакытта инде теге яки бу идея авторының шәхси биографиясе төп рольне уйнамый. Мәсәлән, конкрет шартларда тәкъдим ителгән иҗтимагый шартнамә яки хакимиятне бүлү идеясе авторлыкларын югалтмыйлар, ләкин иҗтимагый аңның мөһим өлешенә әвереләләр.

Ләкин җәмгыять шәхси аң эшчәнлеге нәтиҗәләрен сайлый: ул нәрсәнедер ала, ә нәрсәнедер кире кага. Шәхси аңның һәр казанышы да иҗтимагый аңның гомуми массивына керми. Бу әлеге шәхеснең рухи эшчәнлегенең тирәнлегенә һәм социаль әһәмиятенә, вакыт рухының аның иҗатына булган ихтыяҗына бәйле.

Үз чиратында, шәхси аң да шул рәвешле эш итә. Ул иҗтимагый аңның барлык элементларын да кабул итеп алмый. Җәмгыять тарафыннан тарихи эшләнгән аң нормалары шәхесне рухи баета, әхлакый нормалар, инанулар, эстетик хисләр һәм күзаллаулар чыганагына әвереләләр. Ләкин иҗтимагый аңда булган элементларны һәр кеше, шәхси үзенчәлекләренә бәйле рәвештә, төрлечә кабул итә.

Дж.Бруно, Г.Галилей, Жанна д'Арк кебек тарихи шәхесләр, күпләгән замандашларыбыз язмышы шәхси һәм иҗтимагый аң арасындагы, җәмгыятьтә кабул ителгән рухи принциплар системасы һәм теге яки бу җәмгыятьнең аерым гражданнары идеяләре арасындагы каршылыкларны дәлилли. Үз заманыннан алга узган шәхесләр иҗтимагый аңны үстерүгә үз өлешләрен кертәләр.

Иҗтимагый аң шәхси аңнар күләме суммасына туры килмәгән, ә үзенчәлекле оешкан идеаль-объектив чынбарлык рәвешендә чагылган кебек үк, шәхси аң да иҗтимагый аңнан төгәл күчермәсе була алмый. Кеше чынбарлыкта булган, аның белән исәпләшергә туры килгән иҗтимагый аң белән диалогка

кирә. Шәхси аң тарихның аккумуляштырылган тәҗрибәсе булып тора. Кеше, шәхес үз гаиләсе, иле, үз халкы тарихы белән үзенең бәйләнешен тоя ала. Һәрбер шәхси аңның үзенең үсү чыганагы була, шунлыктан, аны кызыктыручы мәдәниятнең бербөтенлегенә карамастан, һәр шәхес үзенчәлекле.

ИҖТИМАГЫЙ АҢНЫҢ АСЫЛЫ ҺӘМ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Җәмгыятьнең рухи тормышы процессында төрле белемнәр һәм табигатькә, объектив чынбарлыкка, җәмгыятьтә булган һәр нәрсәгә мөнәсәбәт барлыкка килә. Моннан тыш җәмгыятьтә кәефләр, гадәтләр, халыкларның традицияләре, шулай ук төрле социаль төркемнәрнең психик төзелеш үзенчәлекләре тамырлана. Әйтик, американыларның эшлеклелеге яки немецларның төгәллеге һәм педантлыгы турында сөйләү гадәткә кергән. Шул ук вакытта әлеге төркемнәрнең барлык вәкилләре дә һәрвакытта әлеге сыйфатлар белән аерылып тормыйлар. Шулай да билгеле бер сыйфатлар характеристикасы бөтен социаль-мәдәни бергәлеккә берегеп калган.

Иҗтимагый аң барлыкка килү — катлаулы процесс. Иҗтимагый аңда кешеләрнең үз ихтыяҗларын җәмгыятьнең рухи тормышында яңа идеяләрдә, фәнни белемнәрдә, әхлакый камилләшүдә, гүзәллектә, илһамлыкта канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән мәнфәгатьләре һәм эшчәнлеге чагыла. Бер үк вакытта идеяләрнең, теория, караш, әхлак нормалары, фәнни белемнәрнең киң таралуы, бөтен җәмгыятькә йогынты ясавы кирәк. Бу вазыйфаны мәктәп, вуз, массакүләм матбугат чаралары, сәяси партияләр, иҗтимагый хәрәкәтләр һәм оешмалар башкара.

Галимнәр иҗтимагый аңның чагыштырмача мөстәкыйль булуын таныйлар. Эш шунда: күпләгән идеяләр, кешеләрнең карашлары, аларның әхлакый инанулары шактый тотрыклы була һәм алар хәтта шулар нигезендә барлыкка килгән объектив шартлар, иҗтимагый мөнәсәбәтләр инде булмаганда да кешеләр аңында шактый озак саклана алар. Бу шуннан килә: кешеләрнең карашларында, инануларында үзгәрешләр тиз генә булмый (әйтик, икътисади строй алышынган очракта да). Кешеләрнең аңы, аларның идеяләре, карашлары иҗтимагый яшәештән артта калырга һәм билгеле бер вакыт дәвамында аңа туры килмәскә мөмкин. Бу очракта сүз йә кешеләр аңындагы искелек калдыклары, яисә традицияләр саклану турында бара. Мисал өчен, крепостной хокук бетерелгәннән соң, крестьяннарның бер өлеше яңа икътисади һәм социаль чынбарлыкларга шактый авыр иялә шә. А.П.Чеховның «Чия бакчасы»

дигән пьесасы герое Фирсның бу вакыйганы бәхетсезлеккә санаган сүзләрен исегезгә төшерегез. Кешеләрнең идеяләре һәм карашлары реаль шартларны узып китәргә мөмкин, ул чакта андый идеяләрнең социаль хыялларны, фаразлауны, алдан күрүне чагылдыруы турында сөйлиләр. Тарих курсыннан сезгә социалист-утопистларның фаразлары билгеле.

Иҗтимагый аң җәмгыятьнең рухи тормышында булган яхшылыкны, файдалы һәм кирәклене буыннан-буынга күчерү нигезендә яши. Бу хәл фәндә, әхлакта, халыкларның традицияләрендә бик ачык күренә. Иҗтимагый аңның күп кенә чагылышлары үзара эш итәләр, бер-берсенә көчле йогынты ясыйлар. Мәсәлән, кешеләрнең эстетик зәвыклары һәм омтылышлары аларның әхлакый идеаллары белән тыгыз бәйләнгән. Еш кына матурлык идеалы кешеләр өчен бер үк вакытта игелеклелек идеалы булып тора, һәм, киресенчә, әхлакый идеал белән бәйле нәрсә гүзәллек булып кабул ителә.

Иҗтимагый аң бөтен җәмгыять тормышына актив йогынты ясый. Әмма бу йогынты үзеннән-үзе генә түгел, ә кешеләрнең җәмгыять тормышына прогрессив яки тоткарлаучы йогынты ясавы мөмкин булган эшчәнлегендә чагыла.

ТЕОРЕТИК ҺӘМ ГАДӘТИ АҢ

Иҗтимагый аң структурасы иҗтимагый аңның социаль чынбарлыкны чагылдыру тирәнлеге ноктасыннан карала ала. Ул чакта төп структур элементлар сыйфатында иҗтимагый психология һәм идеология аерылып чыга.

Иҗтимагый психология — тулаем әлеге җәмгыять һәм зур социаль төркемнәрнең һәрберсе өчен хас булган хисләр, кәефләр, гореф-гадәтләр, омтылышлар җыелмасы ул. Иҗтимагый психология социаль яшәешнең конкрет-тарихи шартлары йогынтысында урнаша. Әлеге шартлар зур социаль төркемнәр өчен төрле булган кебек, аларның социаль-психологик комплекслары да (Урта гасырларда «затлы сыйныф»ларның «гади халык»тан өстенлеге комплексы) үзара котылгысыз төстә аерылалар. Төрле социаль төркемнәрнең социаль-психологик комплексларының конкрет җәмгыятьнең тарихи үзенчәлекләре, милли традицияләре, мәдәният дәрәҗәсе белән бәйле уртак сыйфатлары да бар.

Идеология — җәмгыятьнең дөньяны тулаем һәм аның аерым якларын танып-белү дәрәҗәсен чагылдыручы теоретик карашлар системасы ул. Ул иҗтимагый аңның иҗтимагый психология белән чагыштырганда югарырак дәрәҗәсен — дөньяны теоретик чагылдыру дәрәҗәсен гәүдәләндерә. Әгәр социаль төркемнәр психологиясен анализлаганда ешрак «иҗ-

тимагый» эпитетын кулланасалар, «идеология» төшенчәсенә андый эпитет кирәк түгел, чөнки индивидуаль идеология юк, ул һәрвакыт иҗтимагый гына була.

Шуны истә тотарга кирәк, «идеология» төшенчәсе социаль философиядә тагын бер, таррак мәгънәдә — **зур бер социаль төркемнең төп мәнфәгатьләрен турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган рәвештә чагылдыручы теоретик карашлар системасы буларак кулланыла.**

Иҗтимагый психология стихияле рәвештә иҗтимагый төркем, сыйныф яшәгән тормыш хәлләренең турыдан-туры йогынтысында формалашса, идеология күпчелек очракта әлеге сыйныф вәкилләренең — аның идеологларының теоретик эшчәнлеге продукты булып тора.

Теоретик танып-белү күзлегеннән караганда, иҗтимагый психология белән идеология арасындагы нисбәт иҗтимагый аңның тәэсирле, хисле һәм рациональ дәрәҗәсе арасындагы нисбәтлекне хәтерләтә. Билгеле булганча, хис белән танып-белү гомумән дә аңның җитәрлек булмаган, ләкин зарури «катламы» булып тора, чөнки безнең бала мие фәкать шуның аркасында гына дөнья турында беренчел мәгълүматны ала ала, ләкин мәдәниятле кешенең хисләре һәрвакыт рациональ «тутырылган» (музыкаль ишетү, форма матурлыгын сизүче күрү). Иҗтимагый психология социаль чынбарлыкның тышкы гәүдәләнешләрен турыдан-туры чагылдыру булып тора, ул тиешле идеология барлыкка килү өчен тормыш практикасы нигезен тәшкил итә. Идеология психология җитәрлек дәрәҗәдә аңлап бетермәгәнне ачыклый, күренешләрнең асылына тирән үтеп керә.

Фәлсәфи һәм тарихи әдәбиятта *«гадәти аң»* дигән төшенчә бик еш очрый. Бу төшенчә кешеләрнең көндәлек практик тормышына турыдан-туры кушылган аңын характерлау өчен кулланыла.

Массакүләм аң иҗтимагый аң төрләренең берсе булып тора.

Массакүләм аң үзенең эчтәлеге, чынбарлыкны чагылдыру дәрәҗәсе һәм сыйфаты белән түгел, барыннан да элек аның иясенең, субъектның специфик үзенчәлеге белән аерылып тора. Массакүләм аңның субъекты буларак, масса индивидларның аерым җыелмасын (күпчеллекне, гомумилекне) тәшкил итә. Массаның мисаллары — киң сәяси, социомәдәни һәм башка хәрәкәтләрдә катнашучылар, төрле чаралар һәм массакүләм мәгълүмат каналлары аудиторияләре, теге яки бу социаль «буялган» (абруйлы, модалы) товарларны һәм хезмәтләрне кулланучылар, төрле үзешчән (мәнфәгатьләр буенча) ассоциацияләр һәм клублар әгъзалары, футбол яки башка спорт төрләрен яратучылар һ.б. була ала.

Аң субъекты буларак, массаларга түбәндәге сыйфатлар хас. Беренчедән, әлеге берлекнең, мөстәкыйль, тулылыклы, аның төп элементларыннан аермалы булмаган хәлдә, күпләгән аерым «берәмлекләр» белән катнашуында чагылган статистик характеры. Икенчедән, аңа индивидларның керүе тәртипсез, очраклы рәвештә була, нәтиҗәдә мондый берлек һәрвакыт катгый билгеләнмәгән, ачык чикләре, билгесез күләме һәм сыйфаты белән аерылып тора. Масса өчен яшәүнең ситуативлыгы хас, ул теге яки бу конкрет эшчәнлек базасында һәм аның чикләрендә яши, аннан башка була алмый. Шуның нәтиҗәсендә масса һәрвакыт бер очрактан икенчесенә, бер конкрет хәлдән икенчесенә үзгәртеп торучы тотрыксыз берлек булып кала. Массага әлеге берлек составының ачык билгеле төрле кешеләрдән туплануы, катнаш булуы, аның төркемнән тыш (яки төркемара) табигате хас; ул җәмгыятьтә яшәүче барлык социаль (демографик, сәяси, төбәк һ.б.) төркемнәр арасында чикләрнең «юылуында» чагыла.

Массаның атап үтелгән сыйфатлары аңа хас аң тибын, аның эчтәлеге һәм структурасы үзенчәлекләрен, формалашуы һәм эшләве ысулларын тулысынча билгели.

Эчтәлеге буенча массаның аңы теге яки бу рәвешле җәмгыять тормышының төрле якларын чагылдыручы идеяләр, фикерләү, күзаллау, иллюзия, хис итү, кәефләр җыелмасыннан гыйбарәт. Шуның белән бергә, үзенең эчтәлеге буенча масса тулаем җәмгыять аңыннан күпкә таррак, чөнки массалар аңлап җиткерми һәм (яки) аларның мәнфәгатьләренә кагылмый торган (мәсәлән, фән, философия эчтәлеге һ.б.) бик тә күп сюжет аның чикләреннән тыш кала.

Масса аңының структурасы иҗтимагый аңның билгеле булган барлык типлары — иҗтимагый психология һәм идеология, гадәти һәм теоретик, абстракт һәм художестволы, читтән күзәтү һәм ихтыярый эшләр белән бәйле һ.б. типлары «чат»ында барлыкка килүче гадәттән тыш катлаулы конгломерат (бербөтен булып та, үз сыйфатларын һәм үзенчәлекләрен саклап калу. — *Тәрҗ.*) бергәлектән гыйбарәт.

Бу уңайдан масса аңы структурасы таркаулыгы, каршылыклы булуы, тиз, көтелмәгән үзгәрешләргә сәләтлелеге белән аерылып тора.

Бүгенге типтагы җәмгыятьләрдә масса аңы кешеләрнең тормыш эшчәнлегенең төп шартларын һәм формаларын (җитештерү, куллану, аралашу, социаль-сәяси катнашу, ял итү өлкәләрендә) бер үк төрле омтылышлар, мәнфәгать, ихтыяҗ, күнекмә, һәвәслекләр һ.б. китереп чыгаручы стандартлаштыру процессында барлыкка килә. Яшәешнең әлеге шартлары һәм формаларының эш-гамәле производствода һәм барыннан да

элек массакүләм матбугат чаралары белән бәйле массакүләм мәдәниятнең тиешле төрләрендә ныгый һәм үз ахырын таба. Алар ярдәмендә халыкның киң массалары мәнфәгатьләре, ихтыяҗ, омтылышлары чынбарлыкның стандарт формалары, аны танып-белү ысуллары һәм үз-үзеңне тоту модельләре рәвешендә формалаша.

Кеше эшчәнлеген стандартлаштыру объектив процессларының рухи азыгы буларак, масса аңы үзе дә җәмгыять тормышының күп якларына бик тә актив йогынты ясый. Ул кешеләрнең үз-үзләрен тотышының массакүләм формаларын куәтле җайга салучы ролен үти. Бу вакытта иҗтимагый фикер һәм иҗтимагый кәеф масса аңын чагылдыруның төп формалары булып торалар.

Төп төшенчәләр: иҗтимагый аң, шәхси аң, иҗтимагый психология, идеология.

Терминнар: аң, гадәти аң, масса аңы, иҗтимагый фикер.

Үзегезне тикшерегез

1. Төрле караш яклылар аңның асылын ничек аңлаганнар? 2. Иҗтимагый аң һәм рухи мәдәният үзара ничек бәйләнгән? 3. Иҗтимагый аңның төп сыйфатларын тасвирлагыз. 4. Иҗтимагый аңның төрле формаларына тасвирлама бирегез. 5. Иҗтимагый аңда нинди дәрәҗәләрне аерып күрсәтү кабул ителгән? 6. Иҗтимагый психология һәм идеология нәрсә белән аерыла? 7. Иҗтимагый һәм шәхси аң үзара ничек бәйләнгән?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Алма турында күзаллауның авырлыгы да, төсе дә, исе дә, тәме дә юк дигәндә И.Кант аңның нинди үзенчәлеген күрсәткән? Җир тетрәү турында күзаллау шәһәрне җимерә алмый, ә кесәдәге тәңкә белән уйдагы тәңкә бер үк нәрсә түгелме? Бу үзенчәлекне үз сүзләрегез белән формалаштырыгыз.

2. Г.Гегель гадәти аң турында, кайсы да булса чорның шул заманның барлык хорафатлары булган фикерләү ысулы ул, дигән. Философ әйткәннәрне үз мисалыгыз белән тасвирлап күрсәтегез.

3. Түбәндәге фрагментка аңлатма бирегез:

«Социаль психология — бары тик шәхси хәлләр белән генә түгел, халыкның зур төркемнәренең тормыш мәнфәгатьләренә кагылучы иҗтимагый үсеш, тарихи вакыйгалар тудырган хәлләр нәтиҗәсендә килеп чыккан тәэсирләр, кичерешләр һәм кәефләр өлкәсе ул».

Шундый тәэсирләр, кәефләр һәм кичерешләр мисалларын китерегез.

4. Төрле сүзлекләрдән файдаланып, «идеология» төшенчәсенең мәгънәсен табыгыз. Әлеге аңлатмалар нәрсә белән аерыла?

Чыганак белән эшләгез

Психолог Г.Лебонның «Халыклар һәм массалар психологиясе» дигән китабыннан өзек укыгыз.

Кешеләр төркеменең[1] күңеле

... Хәтта төрле белгечлек өлкәсендә танылган кешеләр җыелышында кабул ителгән, уртак мәнфәгатьләргә кагылган карарлар да аңгыралар җыелышы кабул иткән карарлардан аз аерыла. Чөнки теге очракта да, монысында да нинди дә булса даһи сыйфатлар түгел, ә һәркемдә очрый торган әйбәт сыйфатлар гына бергә кушыла. Төркемдә акыл түгел, фәкать акылсызлыклар гына туплана ала.

Төркемгә хас, шул ук вакытта аның составына кергән шәхесләрдә очрамый торган әлеге яңа социаль сыйфатлар төрле сәбәпләр аркасында барлыкка килә. Аларның беренчесе шуннан гыйбарәт: шәхес төркемдә аның саны аркасында гына көчле аң ала һәм ул аң аңа ялгызы гына булганда беркайчан да ирек бирми торган инстинктка бирелдерә. Төркемдә исә ул әлеге инстинктларны бигүк йөгәнли алмый, чөнки төркем үзендә җаваплылык тоймый. Аерым шәхесләрне һәрвакыт тотып торучы җаваплылык хисе төркемдә бөтенләй югала.

Икенче сәбәп — йогышлылык яки йогыш — шулай ук төркемдә махсус сыйфатлар барлыкка килүгә ярдәм итә һәм аның юнәлешен билгели. <...> Төркемдә һәр хис, һәр гамәл «йогышлы» һәм шундый дәрәҗәдә ки, шәхес үзенең шәхси мәнфәгатьләрен коллектив мәнфәгатенә бик җиңел корбан итә. Хәлбуки мондый хәл кеше табигатенә каршы килә, шунлыктан кеше моңа ул төркемнең бер кисәкчәсен тәшкил иткәндә генә сәләтле.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Кешенең үз-үзен тотышының кайсы үзенчәлекләре нәкъ менә төркемдә күренә? 2. Автор шәхеснең үзен төркемдә үзенчәлекле тотуының нинди сәбәпләрен атый? 3. Сез әлеге сәбәпләрнең асылын ничек аңлыйсыз? 4. Авторның төркемдәге аерым шәхесләрдә була алмый торган сыйфатлар турындагы фикерен раслаучы яки кире кагучы үз мисалларыгызны китерегез. 5. Төркемдә иҗтимагый аң, иҗтимагый фикер барлыкка килә дип раслап буламы?

---

[1] Бу юлы төркем (русча «толпа») — аңлап ук эш итмәүче төркем мәгънәсендә кулланыла. — *Тәрҗ.*

§ 27. Үз-үзеңне танып-белү һәм шәхеснең үсеше

Исегезгә төшерегез:

кешенең дөньяны танып-белү баскычлары нинди? Танып-белү эшчәнлегенең субъекты һәм объекты нәрсә ул?

Кешенең эчке дөньясы һәм аның үзаңы философларның, психолог, лингвист, этнограф, социолог, педагог, рәссамнарның игътибарын күптәннән җәлеп итә. Әйтик, философлар XVII–XVIII гасырлардан башлап шәхеснең кыйммәте нидән гыйбарәт һәм ул үзен ничек чагылдыра, ул үзен ничек танып-белә һәм ул танып-белүнең чикләре кайда икәнен белергә тырышканнар. Р.Декартның: «Мин фикер йөртәм, димәк, мин яшим»,— дигән танылган формуласында ук инде фикерләүгә ия булу факты шәхеснең яшәвенең дәлиле булып тора.

Дж.Локк, кеше үзен еллар үткән саен киңәя барган тормыш тәҗрибәсен рефлексияләү (фикерләү) нигезендә интуитив танып-белә, дип раслаган. Аның карашынча, үзеңә карата рефлексив мөнәсәбәт өлгергән шәхескә хас, ләкин һәрберсенә дә түгел.

И.Кант «Мин»не аңлауга кыйммәти-шәхси үлчәм бирә. Ул фәнни әйләнешкә кешенең аңын һәм үзаңын бүлүне кертә. «Кеше үзенең «Мин»е турында күзаллауга ия булуы аны Җирдә яшәүче барлык башка затлардан югары күтәрә. Шуның аркасында ул шәхес...» Кант исәпләвенчә, үзаң — әхлаклылык һәм әхлакый җаваплылыкның зарури алшарты.

Г.Гегель үзаңны үсештә карый; үзаңны өйрәнгәндә ул кеше эшчәнлеге үсеше фаразларына туры килүче баскычларны аерып күрсәтә.

Психологлар, үз чиратында, кешенең «Мин»е структурасын һәм аны танып-белү ысулларын өйрәнәләр.

НӘРСӘ УЛ ҮЗАҢ

Проблеманың катлаулыгы шунда: бу очракта танып-белү объекты һәм субъекты тәңгәл килә, шунлыктан кешенең үзе турындагы белемнәрнең дөреслеге дәрәҗәсен билгеләү кыен. Шулай да үзең турында белү, үзеңнең сыйфатларыңны, үзаңыңны бәяләү шәхеснең үсеп җыгуының мөһим өлеше булып тора.

Гадәттә *үзаң* дигәндә кешенең үзен *мөстәкыйль карарлар кабул итәргә*, башка кешеләр һәм табигать белән билгеле бер мөнәсәбәтләргә керергә сәләтле шәхес итеп билгеләвен аңлыйлар. Үзаңның иң мөһим билгеләреннән берсе — кешенең ка-

бул иткән карарлары һәм кылган гамәлләре өчен җаваплылык тоюы.

Үзаң барыннан да элек шәхси дәрәҗәдә була. Асылда, кеше гомере буе үзаң белән шөгыльләнә, әмма эшчәнлекнең мондый төрен алып баруы турында һәрвакытта да уйланмый. Галимнәр раславынча, үзаң сабый чакта ук башлана һәм еш кына соңгы сулышны алганда бетә. Шик юк, шәхеснең үсүе процессында үзеңне аңлау ысуллары, үзеңә карата мөнәсәбәт үзгәрә, үзаң үсә.

Шәхес үзен үзаң аша гына түгел, *үзен гамәлгә ашыру* процессында да күрсәтә. Әлеге термин белән шәхеснең үз мөмкинлекләрен тулырак ачуы һәм гамәлгә ашыруы, шәхеснең иҗади потенциалын мөмкин кадәр тулырак тормышка ашыру мөмкинлеге бирүче шәхсән әһәмиятле проблемаларны хәл итүдә күздә тотылган максатларга ирешүе процессы билгеләнә.

Ләкин үзен гамәлгә ашырсын өчен, кеше үз үзенчәлекләрен белергә тиеш.

> **«Кеше — үз-үзен танып-белүче белем ул».**
>
> **Е.Евтушенко**

ТАНЫШ ТҮГЕЛ ТАНЫШ

Үзеңне танып-белү үзеңне белүдән, үзеңне һәм тышкы дөньяны аерудан башлана. Галимнәр мондый аеру инде өч — сигез айлык сабыйларда очрый дип уйлыйлар.

> **Уртача ике яшькә кадәр балалар, башкаларны бик яхшы белеп тә, үзләрен фоторәсемнәрдә, кинокадрларда һәм хәтта көзгедә дә танымыйлар. Көзгедә чагылган үз йөзен күрү балада гаҗәпләнү һәм соклану тудыра.**

Көзгегә караган һәр кеше үзен, үз образын күрүгә, үзенең тышкы кыяфәтен үзгәртергә яки «төзәтергә» тырыша. Бу — үзеңне пассив кабул итүдән «Мин» образын актив булдыруга күчү башлангычы, әлегә бары тик тышкы якка гына кагылучы үзеңне камилләштерүгә юл.

Катгый әйткәндә, кеше, үз тавышын ишетмәгән кебек үк, көзгедә үзенең чын йөзен күрми. (Үз тавышын магнитофон тасмасыннан тыңлаган һәр кеше гаҗәеп, күнекмәгән яңгырашка гаҗәпләнгәндер, мөгаен.) Эш шунда: үзебезне көзгедән карарга җыенып, без ирексездән билгеле бер позага басабыз. Нәтиҗәдә безнең йөзебез үзгәрә, аның табигыйлеге һәм үзен иркен тотуы

югала. Үзебез дә аңламыйча, үзебезнең «Мин» образыбызны барлыкка китерәбез. Шундый очрак А.Моравианың «Трельяж» хикәясендә сурәтләнгән. Яшь адвокат, әле генә кибеттән алып кайткан көзгегә карап, анда гадәти булган үзен түгел, ә үзенең нindидер икенче кыяфәтен күрә, аңа бөтенләй дә таныш булмаган кешегә карата булган яратмау хисе кичерә. Бу яратмауга әле тагын нindидер читләшү килеп кушыла. Хикәя герое көзгегә нindидер предмет итеп карый, ул анда үз кыяфәтен күрергә әзерләнмәгән була. Нәтиҗәдә анда күргән нәрсә аның өчен көтелмәгән, моңа кадәр күнегелгән, үзе турында әһәмиятлерәк дип күзаллаудан сәер төстә аерылган нәрсә булып чыга.

Фотосурәт тә еш кына модельнең чын йөзеннән аерыла, чөнки персонажга тормышта хас булган мимика җанлылыгын бирми.

Танылган кинорежиссер С.Эйзенштейн һәр йөздә күпйөзлелек бар, һәм һәр кеше икейөзле дип исәпләгән. Беренче очракта ул кеше йөзенең хәрәкәтчәнлегенә һәм үзгәрүчәнлегенә, ә икенчесендә битнең сул һәм уң яклары арасындагы аермага әһәмият бирә. Әгәр конкрет кешенең портретын битнең бер үк фоторәсемнән йә уң, йә сул яртысыннан гына беркетеп ясасаң, алар бер-берсеннән нык аерылачак. Әйтик, «уң» битләр (уң яртылардан торучы) оригиналның чын йөзеннән картрак күренәчәк. «Сул» битләр азрак билгеләнгән, типиграк булалар, тере битнең индивидуальлеген азрак саклыйлар.

Кешенең тышкы кыяфәте, аның үзе өчен генә әһәмияткә ия булып калмыйча, ул кешене башка кешеләрнең ничек кабул итүенә дә тәэсир итә. Сез, ихтимал, игътибар иткәндерсез: берәүләр үзләренә карата хәтта таныш түгел кешеләрнең дә ышанычлы мөнәсәбәтен тудыралар, ә икенчеләренә танышлары да еш мөрәҗәгать итәргә тырышмый. Психологик экспертлар тышкы кыяфәтләре күңелгә ятышлы кешеләргә аларда булмаган өстенлекләрне дә бирергә әзерләр дип күрсәтәләр.

Әле борынгы заманнарда ук кешеләр сыйфатларының аларның тышкы кыяфәтләренә, гәүдә, бит төзелеше үзенчәлекләренә нигезләнгән типик характеристикасын булдырырга тырышканнар. «Аның битендә язылган» дигәндә кешенең кыяфәте белән эчке сыйфатлары арасындагы билгеле бер бәйләнешне күздә тотканнар.

Үз-үзеңне кабул итү турында әйтелгәннәр кешегә үзе турында дөрес күзаллау мөмкинлеге бирелмәгән дигәнне аңлатмый. Кешенең тышкы кыяфәтендә бар нәрсә дә гәүдәләнмәгән. Йөзендә акыл чагылышы барлык гасырларда да фикер чагылышы булмаганга караганда мөлаемлырак булып күренгән. Монда инде киемгә карап каршылыйлар, акылга карап озаталар, дигән әйтемне искә төшерми булмый.

БӘЯ БИРГӘНДӘ НИЧЕК ЯЛГЫШМАСКА

Үзеңне танып-белүдә үзеңә бәя бирү дә мөһим роль уйный.

Үзеңнең тышкы кыяфәтеңә мөнәсәбәт үзеңнең сәләтләрең, үзеңә карата башка кешеләрнең мөнәсәбәте турындагы күзаллаулар белән бергә, үзбәяне барлыкка китерәләр. Үзбәя күпчелек үз образыңа: «Мин талантлы», «Мин бөтенләй дә булдыксыз», «Мин башкалардан ким түгел» һ.б. кебек эмоциональ мөнәсәбәттән тора. Үзбәя күпчелек очракта субъектив, ләкин аның нигезендә үз фикерләүләрең генә түгел, сезнең хакта башкаларның фикере дә ята. Кыскасы, кеше үзен ике юл белән бәяли: беренчедән, үзенең теләк-өметләре дәрәҗәсен үз эшчәнлегенең объектив нәтиҗәләре белән; икенчедән, үзен башка кешеләр белән чагыштырып.

Үзбәяне аңлау өчен өч төп момент мөһим. Беренчедән, аны формалаштыруда реаль «Мин» образын үзебез шундый булырга теләгән идеаль образ белән чагыштырып карау мөһим. Үзбәяне мондый формула белән күрсәтеп була:

$$\text{үзбәя} = \frac{\text{уңыш}}{\text{дәгъва (ымсыну)}}$$

Үзбәяне нәрсәгә дә булса, мәсәлән, уңышка ирешеп яисә ымсынуны киметеп күтәрергә була.

Икенчедән, кайбер кешеләр үзләренә бәяне башкалар биргәнчә бирергә тырыша. Балага яшьли үк «син матур» дип тукып торырга мөмкин. Әмма кемдер малайга «син әрекмән колак» дип әйтсә, еллар үткәч, кыз белән очрашуга барганда егет бүреген батырыбрак киярга яисә чәчен башкачарак тарарга мөмкин. Кешенең аңы — үзе турында яңа белемнәргә ачылучы үзенчәлекле кабырчык кебек ул.

Өченчедән, үзбәя безнең үз уңышларыбызга яки уңышсызлыкларыбызга мөнәсәбәтебезгә, тормыш тарихыбыздан нәрсә алуыбызга бәйле.

«Мин» образы гомер буе үзгәрешсез калмый. Тышкы кыяфәт кенә түгел, аңа мөнәсәбәт тә үзгәрә, үзбәя акланганрак була бара, аны арттыру чаралары күрелә. Хөрмәт казанырга омтылу кешене үзенә карата башкаларның мөнәсәбәтен дә үзгәртергә мәҗбүр итә. Дөресрәк итеп әйткәндә, бер «Мин» образы берәү генә түгел; үзаң сәхнәсенә чыгучы яисә күләгәгә китүче андый образлар бик күп.

«Мин»нең катлаулылыгы һәм комплекслылыгы галимнәргә яшәү процессында барлыкка килүче һәм шәхесләрнең үзүзләрен тотышына йогынты ясаучы күп кенә компонентларны аерып күрсәтү мөмкинлеге бирде.

ҮЗАҢНЫҢ ҮСҮЕ ҺӘМ ШӘХЕСНЕҢ ФОРМАЛАШУЫ

Үзаң гадидән катлаулыга таба: тыштан килгән тоюларны һәм эчтән булдырылган тоюларны аерудан үсә. Билгеле бер вакытка кадәр бала үз аягы белән уйнарга, авырттырырга һәм авырту тойгыларының сәбәпчесе үзе икәнен аңламаска мөмкин. Бу бик тә мөһим казаныш, чөнки кешенең гәүдәсе — координатлар системасы, аңа мөнәсәбәттә ул өсне, асны, уң яки сул якны һ.б. кабул итә. Үз гәүдәсенең чикләрен аерып күрсәтү сәләтен югалтса (мәсәлән, махсус камерага япкач, кеше гадәти тоюларын югалтканда), анда галлюцинацияләр башлана, һәм барган вакыйгаларның чын түгеллеге хисе барлыкка килә.

Үзаң үсүнең шуннан соңгы этабы балада предметлар белән мөстәкыйль рәвештә эшләү сәләте барлыкка килү белән бәйле; шуның нәтиҗәсендә бала үзен актив субъект итеп кабул итә башлый. Өч яшенә аның лексиконына «мин» алмашлыгы керә һәм үз шәхесенең тәңгәллеген аңлау ныгый. Шуннан соң үзбәя үсү чоры башлана. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үзбәясе чит кешеләрнең, күбрәк аларны даими бәяләүче ата-аналар һәм тәрбиячеләр фикеренә нигезләнә. Монда балаларның үзбәяләрендәге уңай һәм тискәре чикләр арасындагы балանска күп нәрсә бәйле. Мәктәп балаларында үзләре турында күзаллаулар шактый шартлы, тотрыксыз һәм хисси. Бала нәрсә беләндер башкалардан өстен булса, ул үзен иң яхшы дип саный, ә беренче үк уңышсызлык үзбәяне киметүгә китерә. Мәктәп елларында балада мантыйклы фикерләү барлыкка килә, бу вакытта дусларының роле һәм аларның фикере арта башлый, аралашу даирәсе киңәя. Бу факторлар үсмернең үзе турындагы төрле фикерләрне чагыштырып каравына китерә. Алар нигезендә ул, үз интеллектына таянып, үз фикерен булдыра башлый. Бәяләр тагын да гомумиләштерелгәнрәк, тотрыклырак була бара, ярсулы компонентлар белән бергә рациональләре дә барлыкка килә. Алдагы этап әхлакый үзбәя үсү белән бәйле, ул үсмернең чит кешеләрнең һәм үзенең эш-гамәлләре турында әхлакый фикерләүләре нигезендә корыла.

Үзаң үсү нәтиҗәсендә кешедә үз шәхесенең һәм организмының төрле яклары турында аның барлык күзаллауларының җыелмасы булган *Мин-концепция* барлыкка килә. Мин-концепция аерымрак үзенчәлекләрне күрсәтүче күпсанлы «Мин»-образлардан тора. Аларны классификацияләү өчен төрле критерийлар бар.

Кайсы вакытка караулары буенча түбәндәге образларны аерып күрсәтергә була: Мин-хәзерге, Мин-үткәндәге, Мин-киләчәктәге яки тагын да ваклабрак, Мин 15 яшьтә, Мин 30 яшьтә һ.б.

Эчтәлек буенча түбәндәге образларны аерып күрсәтергә мөмкин: Мин-физик, Мин-акыл, Мин-эмоциональ, Мин-социаль.

Мәгълүмат чыганаклары буенча төрле «көзге» Миннәр бар: Мин әни күргәнчә, Мин дустым күргәнчә һ.б.

Барлык бу образлар кешенең үз-үзен тотышын һәм башка кешеләр белән үзара эш итүен җайга салучылар булып хезмәт итә. Шунлыктан, үз-үзең турындагы мәгълүматны чагылдыру белән бергә, үзаң әле тагын үзеңне җайга салу вазыйфасын да башкара. Кешенең Мин-концепциясе күпме тәңгәлрәк булса, аңа үз-үзен тотышын идарә итү шулкадәр җиңелрәк. Әгәр кеше үз сыйфатларына мөнәсәбәттә ялгышса, ул дөрес төзелмәгән карта белән эш иткән юлчыга охшап кала.

Үзеңне танып-белү процессының чикләре юк, чөнки объект үзе үзгәреп тора. Кеше социаль рольләрен даими үзгәртә, бер яшь категориясеннән икенчесенә күчә, һәм аның үзаңы чынбарлыкка туры килсен өчен аңа үзе турындагы күзаллауларны гел җайга салып торырга кирәк. Кем мин? Бу сорау кешене гомере буе борчып тора. Аның Мин-концепцияне формалаштыруы шуңа ничек җавап бирүенә бәйле.

Психологлар фикеренчә, үзеңнең үсеш процессыңны аңлауда төп урынны *тәңгәллек* төшенчәсе били. Ул төп аспектны колачлый. Беренчедән, тәңгәллек үзеңнең яшәвеңнең вакыт дәвамлылыгын аңлауга таяна: кеше элек ул нәрсә эшләгән, бүген нәрсә эшли һәм киләчәктә нәрсә эшләргә җыенуы арасында нәселдәнлек күрә. Икенчедән, тәңгәллек үзеңнең бербөтенлегеңне, бердәмлегеңне, үзеңә туры килүне күздә тота. Өченчедән, тәңгәллек кешегә, бер үк вакытта үзенең уникальлеген һәм кабатланмаслыгын күргән хәлдә, үзенең төрле кешеләр белән охшашлыгы дәрәҗәсен билгеләү мөмкинлеге бирә.

Һәр кеше үз гомерендә үзен төрле социаль төркемнәр белән тәңгәлләштерү (социаль тәңгәллек), билгеле бер шәхси үзенчәлекләре хас булган кешеләр белән тәңгәлләшү аша уза, нәтиҗәдә үзең турында белем туа. Башта бала үзенең нинди җенескә, аннары нинди милләткә каравын белә. Бераз соңрак ул үзен ата-аналары кергән социаль катлау, үзе яшәгән шәһәр һәм ил белән тәңгәлләштерә башлый. Өлгереп җиткән кеше үзен үз профессиясе, партиясе, дине, социаль катлавы һ.б. вәкилләре белән тәңгәлләштерә.

Шәхеснең һәм социаль тәңгәлләшүнең өлгереп җитүендә үсмерчак аерым әһәмияткә ия, бу вакытта булган бала белән булачак өлкән кеше арасында күперчек салына.

Кызыклы тикшеренү үсмерлек тәңгәллегенең нидән гыйбарәт икәнлеген ачыклау мөмкинлеге биргән. Әлеге тикшеренүнең нигезенә «Кем Мин?» дигән атаклы методика

салынган. Һәр тикшеренүчегә «Кем Мин?» дигән сорауга 20 тапкыр җавап бирергә тәкъдим ителде. Алынган мәгълүматлар нигезендә психологлар үсмерлек тәңгәллегенең өч үлчәмен аерып алдылар.

Беренче үлчәмгә үзеңне кешеләрнең билгеле бер категориясенә керүең һәм эшчәнлекнең, һәм зәвыкның өстенлекле төрләре аша тасвирлау керә (мин — укучы, мин — бүгенге музыканы яратучы һ.б.).

Тәңгәллекнең икенче үлчәме, бер яктан, рәсми социаль статусны, икенче яктан, шәхси сыйфатларны тасвирлау нигезендә төзелә (мин россияле, мин кыю, мин тәвәккәл).

Өченче үлчәм бәялерәк булып санала һәм шәхеснең социаль хуплана һәм хупланмый торган үзенчәлекләреннән тора (мин хәшәрәтләрне яратмыйм, мин намуслы булырга тырышам).

Шул рәвешле, шәхсәнлек һәм социаль тәңгәллек алу һәр кешенең үзаңы үсүенең төп линиясе булып тора.

Эмпирик тикшеренүләр нигезендә фәндә үсмерләрдә тәңгәллек булдыруның дүрт варианты тасвирланган. Аларның берсе, *диффуз тәңгәллеге* дип аталганына, үсмердә үзенең киләчәгенең нинди дә булса профессиональ һәм идеологик модельләре булмау һәм сайлап алу проблемасы белән аз кызыксынуы хас.

Икенчесе — хәл ителгән тәңгәллек; бу вакытта үсмер сайлап алуны эчке конфликт нәтиҗәсендә түгел, ә тирә-яктагылар йогынтысы нәтиҗәсендә ясый.

Өченче вариант — үсмер кризис кичерә, ләкин үзе өчен мөһим сайлап алуны эшли алмый, аны киләчәккә калдыра.

Гамәлгә ашырылган тәңгәллек — иң оптималь вариант; бу вакытта үсмер үзенең сайлап алуын аңлы рәвештә, тәңгәллек кризисын кичерү стадиясе аша үтү нигезендә эшли.

Тәңгәллек алуның җиңеллеге күп яктан үсмер яшәгән җәмгыятькә бәйле. Ничек кенә көлке тоелмасын, җәмгыять үсмергә ирекне күбрәк биргән саен, аңа үзен табу шулкадәр үк катлаулана бара.

Шулай итеп, кайбер нәтиҗәләр ясыйк.

Эшчәнлек процессында кеше гел үзгәреп тора. Аның танып-белү объекты сыйфатында булган «Мин»е — катлаулы һәм динамикалы.

«Мин» образы кергән «Мин-концепция» кешенең үз-үзе турында чагыштырмача тотрыклы, сөйләм формасында зуррак яки кечерәк дәрәҗәдә аңланган һәм теркәлгән күзаллавын гәүдәләндерә. Бу концепция — иң күптөрле чын һәм фантастик хәлләрдә үзеңне аерым образлар аша, шулай ук башка кешеләр фикерләре һәм үзеңне башкалар белән чагыштыру аша үз-үзеңне танып-белү һәм бәяләү нәтиҗәсе.

Төп терминнар: үзаң, үзеңне танып-белү, үзбәя.

Терминнар: Мин-концепция, образ-Мин, тәңгәллек.

Үзегезне тикшерегез

1. Үзеңне танып-белүнең нинди этапларын аерып күрсәтергә мөмкин? Алар бер-берсеннән нәрсә белән аерыла? 2. Үзеңнең тышкы кыяфәтең турындагы күзаллауларны чын дип буламы? Җавабыгызны дәлилләгез. 3. Шәхеснең үзен бәяләвен нинди факторлар йогынты ясый? Үзбәяне ничек күтәрергә?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Шагыйрь Н.Заболоцкий түбәндәге шигырь юлларында үзенең танып-белү процессының нинди үзенчәлекләрен чагылдыра алган?

> Дөнья ничек үзгәрә!
> Мин дә ничек үзгәрәм!
> Мин бер исем белән аталам.
> Чынлыкта мин дип атаганнар,—
> Мин генә түгел. Без күп. Мин — тере.

2. Үзкүзаллауга күнегү. Көзге каршына басып, үзегезгә кимендә ун минут карап торыгыз. Нәрсә күрдегез? Сезгә иң яхшысы нәрсә? Мәсәлән, сезне вокзалда каршыларга тиешле таныш булмаган кешегә үзегезне ничегрәк тасвирлар идегез? Үзегезне беренче тапкыр күрәсез дип күз алдыгызга китерегез. Тәэсирләрегез нинди? Тәэсирләрегез яхшы булсын өчен нәрсә эшләргә кирәк? Иң яратмаган тышкы үзенчәлегегез нинди? Бу сыйфатыгыз бигрәк тә сөйкемсез дип күз алдыгызга китерегез. Ә хәзер алынган образдан кыек көзгедәге чагылыш буларак көлегез.

3. Параграфта тасвирланган «Мин кем?» тестын кулланып, үзегезнең сыйныфыгызда зур булмаган тикшеренү үткәрегез.

Чыганак белән эшләгез

Психолог һәм социолог В.Б.Ольшанскийның «Практикларга, укытучыларга, ата-аналарга һәм җитәкчеләргә — психология» дигән китабыннан өзек укыгыз.

Мин-концепция

Кешенең үзе турында күзаллавы һәм аны башка кешеләр нинди дип белүләре беркайчан да тулысынча туры килми. Һәркем үз кичерешләреннән үз карашынча нindидер мөһим

нәрсәне ала һәм аннан күзаллаганча, үзенчәлекле кеше образын, аның (яки үзенең) шәхес моделен тудыра. Һәркем белә: кеше үзе яраткан объектны идеаллаштыра («уйлап чыгара») һәм дошманның капма-каршы образын барлыкка китерә. Үз-үзеңне күзаллау да шул принципта эшләнә...

Үзеңнең «Мин»еңдәге үз кичерешләреңнән алынган когнитив (таныш-белүле. — *Ред.*) структура «Мин-концепция» дип атала. Бер тапкыр барлыкка килеп, ул әлеге концептуаль категориягә яңа кичерешләрне яки яңа мәгълүматларны бик тә сайлап кабул итә. Шунлыктан аңа «үз-үзен беркетеп калдыру» концепциясен тагалар. Бу төшенчәне эшләүгә Манфред Кун җитди өлеш керткән. Ул Мин-концепцияне шәхесне оештыру, аны социаль уртак эшләр процессына кертү өчен нигез дип карый. Кун үз тәртибеңне җайга салуда әлеге берәмлекнең биш вазыйфасын аерып күрсәтә:

а) үзеңнең тәңгәллегеңне билгеләү;
б) үз мәнфәгатьләрең, симпатия һәм антипатияләрең;
в) үз максатларың һәм уңышка атлауларың;
г) үзәгендә әһәмиятле объектлар чолганышындагы шәхес булган үзара бәйләнеш системасын;
д) үз-үзеңне бәяләү.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Үзегез турында күзаллау һәм башка кешеләрнең сезнең турында күзаллаулары туры килмәү турындагы нигезләмәне сез ничек аңлыйсыз? Шундый туры килмәүнең сезгә әдәбияттан билгеле булган мисалларын китерегез. 2. Мин-концепциягә нинди элементлар керә? Сез аларның асылын ничек аңлыйсыз? 3. Кешеләргә үзләре яраткан предметларны идеаллаштыру хас дигәннән үзеңне таныш-белү өчен нинди мөһим нәтиҗә ясарга мөмкин? 4. Мин-концепция иҗтимагый багланышлардан мәхрүм булган кешедә барлыкка килә аламы? Җавабыгызны дәлилләгез.

IV бүлеккә йомгаклаулар

1. Белемнәр — кешенең таныш-белү эшчәнлеге нәтиҗәсе ул. Үзләренең предметы, составы, характеры, юнәлгәнлекләре буенча безнең белемнәребез бик тә күптөрле. Кешенең таныш-белүенең иң гомуми принципларының ничек формалашуы, дөнья турында таныш-беленгәннәрнең аның белән нинди нисбәттә булуы, белем һәм инану арасындагы чикнең кайда ятуы, кешенең таныш-белү мөмкинлекләренең чикләре нинди булуы турындагы күзаллауларыбыз һәм идеяләребез аерым бер өлкәне барлыкка китерә. Бу проблемалар философиянең «гносеология» дип аталган бүлегендә карала.

2. Бүген күпчелек философлар, дөньяны танып-белеп, кеше үз аңында чынбарлыкны гәүдәләндереп кенә калмый, аңа мәгънә сала, идеаль образлар, объектлар, модельләр тудыра дип исәпли. Танып-белү эшчәнлегенең һәр этабында сизеп һәм рациональ танып-белү аерылгысыз бердәмлектә эш итәләр. Сизү, зиһенгә кабул итү һәм күзаллау предметның хисси образын барлыкка китерәләр. Рациональ фикерләү исә, төшенчә, фикер йөртү, нәтиҗә ясаудан файдаланып, аның асылын төшенергә ярдәм итә.

3. Танып-белүнең максаты — чынбарлык турында дөрес белемнәр алу. Әлеге белемнең мөһим сыйфаты — объективлык. Объектив хакыйкать — чагыштырмача. Бу әйләнә-тирә дөньяның катлаулыгы, бик тә күптөрлелеге, үзгәрүчәнлеге, шулай ук кешенең танып-белү мөмкинлекләренең чикләнгәнлеге белән бәйле. «Абсолют хакыйкать» төшенчәсен философлар төрлечә аңлата. Хакыйкатьнең критерийлары турындагы мәсьәлә дә бәхәсле булып кала. Практиканың хакыйкать критерие буларак әһәмиятен инкарь итмәгән хәлдә, тикшеренүчеләр аны куллану мөмкин булмаган өлкәләр бар дип раслый.

4. Кешегә дөньяны тулысынча танып-белергә омтылу хас. Ул белемнәрне төрле юллар белән: көндәлек тәҗрибәдә, философиядә, дин кысаларында, сәнгать чаралары белән туплый. Борынгы заманда дөньяны танып-белүнең төп ысулы миф булган. Мифологик аңның кайбер сыйфатлары хәзерге дөньяда да саклана.

5. Чынбарлыкны танып-белүнең бик тә мөһим юлларының берсе — фәнни эзләнү. Фән дөнья һәм кеше турында объектив, ышанычлы, тикшерелә торган, системалы белем тупларга тырыша һәм моның өчен социаль чаралар комплексын һәм танып-белү эшчәнлеге алымнарын куллана. Җәмгыятьне фәнни танып-белүдә, барлык танып-белү эшчәнлеге өчен уртак сыйфатлар белән бергә, шактый аерым сыйфатлар да бар. Алар күп кенә факторларга бәйле. Алар арасында өйрәнү объектының — җәмгыятьнең катлаулыгы, кешенең иҗтимагый тормышка кушылуы һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, аның билгеле булган «һәвәслеге», табигатьне өйрәнгәндә файдаланыла торган кайбер танып-белү чаралары һәм алымнарының чикләнгәнлеге.

6. Кеше өчен танып-белү объекты — ул үзе. Үзенең «Мин» образының барлыкка килүе бары тик тел ярдәмендә, коммуникатив аралашу кысаларында, үзеңне башкалар белән чагыштырып караганда гына мөмкин. Үзеңне танып-белү үзеңне гамәлгә ашыруга — эшчәнлектә үзеңнең «Мин»ең барлыкка килүгә юл ача.

IV бүлеккә сораулар һәм биремнәр

1. Түбәндә китерелгән ике фикер турында уйланыгыз:

«Дөнья — тукталышсыз үзгәрешләр процессы, шунлыктан аны танып-белеп булмый».

«Нигездә, дөнья — какшамас, тыныч һәм танып-белүгә бирелүчән».

Әлеге фикерләр арасында дөресе бармы? Үз җавабыгызны дәлилләгез.

2. Фәнни һәм гадәти танып-белүне түбәндәге критерийлар буенча чагыштырыгыз: танып-белү объекты, танып-белү субъекты, танып-белү эшчәнлегенең алымнары һәм чаралары, танып-белүнең нәтиҗәләре. Танып-белүнең әлеге төрләренең гомуми сыйфатлары һәм аермалары турында нәтиҗәләр ясагыз. Әлеге исемлеккә сез тагын нинди критерийларны кертер идегез?

3. Җәмгыять белеме дәреслегеннән түбәндәгеләр булган өзекләрне китерегез: а) фактлар; б) интерпретация; в) бәяләүләр.

4. Үзеңне танып-белүнең үз тәҗрибәгезгә мөрәҗәгать итегез. Сездә, яшь арган саен, үзегезнең «Мин»егез үзгәрдеме? Ә ничек үзгәрде?

Имтиханга әзерләнәбез

1. Абсолюттан аермалы буларак чагыштырмача хакыйкать:
1) анда предмет турында объектив белем бар;
2) ул һәрвакытта да сәламәт акылга таяна;
3) вакыты җиткәч, кире кагыла ала;
4) сизеп танып-белү нәтиҗәсе булып тора.

2. Хакыйкать критерие буларак практикага керә:
1) фәнни эксперимент;
2) фәнни төшенчәләр;
3) теоретик гомумиләштерүләр;
4) статистик алымнар.

3. Социаль танып-белү турында түбәндәгечә фикер йөртү дөресме?

А. Социаль танып-белү үзенчәлеге фактик материалның теоретик гомумиләштерүдән өстенлекле булуыннан гыйбарәт.

Б. Социаль танып-белүдә модельләштерү алымы кулланылмый.

1) А гына дөрес;
2) Б гына дөрес;
3) икесе дә дөрес;
4) икесе дә дөрес түгел.

4. Үзеңне танып-белү турындагы түбәндәге фикерләүләр дөресме?

А. Кеше үз бәясен үзен башкалар белән чагыштырып барлыкка китерә.

Б. «Мин-образ» — кеше турында тирә-юньдәгеләрдән туган күзаллау ул.

1) А гына дөрес;

2) Б гына дөрес;

3) икесе дә дөрес;

4) икесе дә дөрес түгел.

5. Түбәндә китерелгән исемлектә бары тик фәнни танып-белүгә генә хас сыйфатларны табыгыз:

1) төшенчәләрне куллану;

2) мантыйклы нәтиҗәләр чыгару;

3) нәтиҗәләрне экспериментта раслау;

4) теләсә нинди рациональ тәнкыйтьнең ачыклыгы;

5) көндәлек тәҗрибә мәгълүматларын йомгаклау.

6. Философлар «танып-белү» төшенчәсенә нинди мәгънә сала? Җәмгыять белеменә туры китереп, әлеге төшенчәне кулланып, ике җөмлә төзегез.

7. Җөмләне тутырып языгыз: «Реаль дөнья күренешләре һәм процесслары турында фәндә урнашкан тотрыклы күзаллауларның алышынуы, яңа теорияләр барлыкка килү ... процессында бара».

8. Түбәндә әйтелгәннәр нигезендә кыска хикәя языгыз: «Кеше аңламый торган мәгълүмат сораусыз җавап биргән кебек — аның мәгънәсе юк» (А.Маслоу).

V бүлек

ШӘХЕС. ШӘХЕСЛӘР АРАСЫНДАГЫ МӨНӘСӘБӘТЛӘР

§ 28. Индивид, индивидуальлек, шәхес

Исегезгә төшерегез:

кешедәге биологик һәм социаль сыйфатлар нинди нисбәттә була? Кеше сыйфатлары үсүгә тумыштан ук җайлашу нәрсәдә чагыла? Нәрсә ул социаль роль? Җәмгыятьтә нинди социаль нормалар бар?

Бу параграф шәхескә, аның якындагы тирә-як белән эш итүенә, әйләнә-тирә социум белән аралашуына багышлана.

Шәхес турында фәнни бәхәсләрдә *аны аңлатуга төп өч төрле якын килүне* аерып күрсәтергә була. Шартлы рәвештә аларны болай билгеләргә мөмкин: 1) *антропологик;* 2) *социологик;* 3) *персоналистик.*

Шәхси антропологик якын килүгә аның турында гомумкешелек сыйфатларына ия булу дип карау хас. Шәхес кешелекнең Homo sapiens ыругы вәкилен аңлатучы ыруг төшенчәсе буларак карала һәм индивид төшенчәсенә тәңгәлләштерелә. Үз вакытында кешегә антропологик якын килү үзенең классик чагылышын Л.Фейербах (1804–1872) хезмәтләрендә таба. Ул аны барыннан да элек табигать продукты итеп карый һәм шәхеснең формалашуында социаль мөнәсәбәтләргә чагыштырмача зур булмаган игътибар бирә.

Социологистик якын килүдә шәхес күпчелек социаль мөнәсәбәтләр объекты һәм продукты буларак карала. Француз галимнәре — социолог Э.Дюркгейм (1858–1917), этнолог һәм философ Л.Леви-Брюль (1857–1939), психолог Ж.Пиаже (1896–1980) һ.б. хезмәтләрендә үз вакытында А. Сен-Симон (1760–1825) тарафыннан тәкъдим ителгән психиканың социаль бәйлелеге принцибы эшләнә.

Шәхеснең башта — «маска»ны, аннары «актер»ны һәм, ниһаять, аның «ролен» аңлатучы төшенчәсе эволюциясенең шәхес турында (социаль теләкләр йогынтысында «рольдәге тотышы» системасы буларак үсеше өчен этәргеч була Бу, үз чиратында, Америка психологлары Т.Парсонс (1902–1979), Д.Г.Мид (1863–1931) һ.б. эшләгән «шәхеснең роль теориясе» дигән нәрсәдә чагылыш таба. Әле аталган ике төрле якын килүгә күпмедер дәрәҗәдә каршы буларак, шәхесне абсолют мөстәкыйль һәм индивидуаль-кабатланмас бербөтен итеп аңларга һәм аңлатырга тырышу да бар.

Шәхесне персоналистик аңлатуның тулырак чагылышы шәхеснең асылы — аның абсолют рухи мөстәкыйльлегендә һәм кабатланмаслыгында дип караучы экзистенциализм концепциясендә. Бүгенге индустриаль дөньясында кеше үзенең индивидуальлеген югалта, «Мин»не массалар арасында эретә. Әлеге идеяләр М.Хайдеггер (1889–1976), Ж.П.Сартр (1905–1980), К.Ясперс (1883–1969) һәм экзистенциализмның башка вәкилләре хезмәтләрендә үстерелә.

Югарыда барлык әйтелгәннәр шәхесне өйрәнүгә һәм тасвирлауга төрлечә якын килү мөмкинлеген һәм хакыйкыйлыгын инкарь итми.

Бүгенге социаль психология шәхесне өйрәнүне актуаль фәнни проблема дип саный. Галимнәр шәхеснең асылы һәм аның структурасы турында бәхәсләшәләр.

КЕМНЕ ШӘХЕС ДИП САНАРГА

«Шәхес» төшенчәсе фәндә иң билгеләнмәгәннәр һәм бәхәсләләр исәбенә керә.

Шәхес кешелек тарафыннан эшләнгән кыйммәтлелек юнәлешләре традицияләре һәм системалары үзләштерә торган индивидны социальләштерү нәтиҗәсе дип карала. Социальләштерү процессында кеше күпме кабул итә һәм үзләштерә ала, ул шулкадәр өлгергәнрәк шәхес була.

«Шәхес» төшенчәсен аңлату күптөрле булуга карамастан, аларның авторлары: шәхес булып тумыйлар, моның өчен кеше күп тырышлык куярга: телгә, төрле моторлы, интеллектуаль һәм социомәдәни күнекмәләргә ия булырга тиеш дигән белән килешәләр.

Әле 1937 елда ук тикшеренүче Г.Олпорт, философиядән, теология, юриспруденция, социология һәм психологиядән алып, шәхеснең 50 билгеләмәсен санап чыгара.

Әйтелгәннәр уңаеннан: кеше шәхес була аламы? Бер яшьлек бала, психик яктан тулы кыйммәтле булмаган кеше яки остарып беткән җинаятьче шәхес була аламы дигән сораулар бик тә урынлы.

Әлеге сорауларга бертөрле генә җавап юк, чөнки һәр очрак конкрет карауны таләп итә. Шулай да галимнәренең күпчелеге, гәрчә билгеле бер искәрмәләр белән булса да, һәр кешенең «шәхес» дип аталырга хокуклы булуы яклы. Баланы, үсмерне һәм яшь егет-кызны «формалышып килүче шәхес» дип атау дөресрәк, чөнки бу үсеш чорларында аларның сыйфатларының тулы системасы үсә һәм формалаша.

Психик яктан тулы булмаган кешеләргә килгәндә исә, аларның шәхесләре саклану дәрәҗәсе төрле булырга мөмкин: норма белән чагыштырганда, зур булмаган тайпылышлардан алып төрле дәрәҗәдәге авырулар вакытында шәхеснең шактый зарарлануларына кадәр. Аларның дөньяны кабул итүләре, үз-үзләрен тотышларын аңлатулары, фикерләү үзенчәлекләре сәламәт кешенең шундый ук характеристикаларыннан сыйфат ягыннан аерыла, шунлыктан мондый очракларда «патологик» яки «аномаль» шәхес төшенчәсен куллану дөресрәк.

«Психик яктан сәламәт» дип табылган җинаятьчеләр социаль булмаган шәхесләр булып санала, чөнки алар туплаган барлык белемнәр, осталыклар һәм күнекмәләр аларны формалаштырган җәмгыятькә каршы юнәлдерелгән. Шәхес каты авыру нәтиҗәсендә дә югалырга мөмкин, бу исә үзеңне эшчәнлек субъекты дип таный, киңлекне һәм вакытны аера

алмауда һ.б. чагыла. Мондый очракта шәхеснең бетүе, таркалуы турында сөйләргә мөмкин.

Өлгергән шәхес бөтенлеге һәм иерархиялеге (түбән дәрәҗәнең югары дәрәҗәгә буйсынуы.— *Тәрҗ.*) белән үзенчәлекле. Бөтенлек кеше үзен төрле шартларда аңлаешлы итеп тота дигәнне аңлата. Ә иерархиялек дигәндә кешенең үзенең биологик ихтыяҗлары белән идарә итә алу сәләте күздә тотыла. Башкача әйткәндә, өлгергән шәхес бер минутлык шартлар йогынтысы астында түгел, ә еллар дәвамында урнашкан кыйммәтләр системасы нигезендә эш итә.

Өлгергән шәхеснең тагын бер ягы шунда: кеше үзе шөгыльләнә торган теләсә нинди эшчәнлектә актив яшәү позициясе тота. Шәхес үзе өчен эшчәнлекнең мәгънәсен, максатын һәм бурычларын билгеләү сәләтенә ия һәм аларны башкаруның оптималь юлларын эзли. Әгәр бу эш аңа канәгатьләнү китерсә, кайчак ул бу эше өчен бүләк тә көтми. Өлгергән шәхес үз эшчәнлеген хәтта эзәрлекләү (мәсәлән, хакимиятләр ягыннан) һәм күп тормыш уңайлыкларын югалту куркынычы янаганда да тормышка ашырырга сәләтле. Мисал итеп академик А.Д.Сахаровның (1921–1989) иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген искә төшерергә мөмкин.

Шәхеснең өлгергәнлеге аның башка кешеләр белән үзара мөнәсәбәтләрендә дә чагыла. Өлгергән шәхескә башка кешеләрнең үсүенә һәм өлгерүенә йогынты ясау хас. Бу йогынты турыдан-туры булмаска да мөмкин. Чын-чынлап өлгергән шәхесләр үз замандашларына гына түгел, ә киләсе буыннарга да йогынты ясый. Андый шәхесләрнең исемнәре бөтен кешелек дөньясының горурлыгы булып тора. Аларны «милләтнең намусы», «халыкларның горурлыгы» дип йөртәләр. Үткәндәге һәм бүгенге көндәге андый кешеләрне сез үзегез дә атый аласыз.

ИНДИВИД ҺӘМ ИНДИВИДУАЛЬЛЕК

Бәлкем, өлгергән шәхесне билгеләү өчен «индивидуальлек» дигән атама белән чикләргә мөмкиндер? Күпчелек сүзлекләрдә һәм психология буенча дәреслекләрдә индивидуальлекне әлеге кешене башка кешеләрдән аерып торучы һәм аның психикасын һәм шәхесен билгеләүче сыйфатлар җыелмасы буларак билгелиләр.

Ләкин бу билгеләмә кайбер сораулар тудыра. Мәсәлән, аның сәләтләре чагылу ясисә психик процесслары бару (тою, зиһенгә кабул итү, хәтер, хис, ихтыяр, фикер йөртү) үзенчәлекләрен индивидуальлек сыйфатларына кертеп буламы?

Туганда кешенең индивидуальлеге аның организмының үзенчәлекләре белән генә (чәч төсе, тавыш тембры, бармаклар тиресе рәсеме һ.б.) чикләнә. Әмма анда темперамент үзенчәлекләре чагыла, шәхес сыйфатлары барлыкка килә барган саен, аның индивидуальлеге киңәя һәм тагын да югарырак дәрәҗәләргә тарала. Яңа тәҗрибә алу, башка социаль рольләр үтәү индивидуальлекнең алга таба үзгәрүенә китерә.

Индивидуальлек кабатланмас сыйфатлар белән генә түгел, алар арасындагы үзара бәйләнешләр үзенчәлеге белән дә характерлана. Мәсәлән, сыйфатлары бер үк төрле булган ике кеше (бу хәтта игезәкләр өчен дә бик аз ихтимал) барыбер үз-үзләрен тотышлары буенча бер-берсенә охшамаячак, чөнки сыйфатлар арасындагы элемтә төрле булачак.

Шулай да фәндә «индивид булып туалар, шәхес булып әвереләләр, индивидуальлекне яклыйлар» дигән фикер яши.



«Шәхес» һәм «индивидуальлек» төшенчәләренең график нисбәтен бер-берсенә алар тулысынча туры килмәслек, ләкин ниндидер уртак мәйдан алырлык итеп өлешчә терәлгән ике түгәрәк итеп сурәтләргә була. Туры килгән мәйдан — шәхеснең аның индивидуальлеге нигезен тәшкил итүче сыйфатлары. Түгәрәкнең шәхесне символлаштыручы калган мәйданы аның социаль типик булган сыйфатларына туры килә, һәм аны күпләгән зур һәм кечкенә төркемнәр вәкиле буларак характерлыйлар. Индивидуальлекнең «калдыклары» кешене биологик организм буларак характерлаучы биохимик, гомумсоматик (бу атама белән психикага капма-каршы буларак организмдагы тән белән бәйләнешле төрле күренешләрне билгелиләр) сыйфатлар тәшкил итә. Шәхескә керми торган индивидуаль билгеләргә физик конституция (тән төзелеше), нерв системасы тибы, темперамент, табигый сәләтләр керә.

ШӘХЕС СТРУКТУРАСЫ

Шәхесне өйрәнү тарихын анализласак, шуны күрәбез: әлеге катлаулы психик күренешнең асылына төшенергә һәм аның эшләве механизмын аңларга тырышучы барлык галимнәр диярлек шәхес структурасындагы аерым элементларны аерып күрсәтү һәм алар арасындагы үзара бәйләнешне анализлау зарурлыгы турында фикергә киләләр.

Философия энциклопедик сүзлегендә «структура» объектның бөтенлеген һәм тәңгәллеген, ягъни төрле эчке һәм тышкы үзгәрешләр вакытында аның төп сыйфатларын саклауны тәэмин итүче тотрыклы элемтәләр җыелмасы буларак билгеләнә.

Шулай итеп, нинди дә булса катлаулы образны структур анализлау үткәрү өчен түбәндәгеләрне эшләргә кирәк: 1) аны тәшкил иткән элементларны аерып күрсәтергә; 2) әлеге элементлар арасындагы бәйләнешләр характерын өйрәнергә; 3) структураның мохит үзгәргәндә бөтенлекне саклау мөмкинлеге бирүче бөтенлек механизмын ачыкларга. Элементларны ачыклаганда түбәндәгеләрне исәпкә алу мөһим: алар бөтеннең төп үзенчәлекләре булырга, аның гади өлешләре генә булмаска тиеш; аларның саны шәхесне тулысынча сурәтләү өчен җитәрлек булырга, әмма бик артык та булмаска тиеш.

Шәхес структурасы — әлеге индивидка хас булган, төрле үз чагылышларда әлеге кабатланмас шәхесне барлыкка китерүче сыйфатларның, сәләт, мотив, кыйммәтләрнең үзенчәлекле оешмасы ул.

Шәхес структурасын төзүнең һәм тасвирлауның берничә варианты бар. Шәхеснең күп дәрәҗәле моделе вариантларының берсе социальнең һәм биологикның үзара нисбәтенә корылган (1 нче схема). Бу вакытта беренче дәрәҗә шәхеснең биологик сыйфатлары: җенес һәм яшь белән бәйле темперамент, үзенчәлекләр белән билгеләнүче компонентлар белән күрсәтелә. Икенче дәрәҗә, үзенә психик процесслар агышының шәхеслек үзенчәлекләрен (зиһенгә кабул итү, фикерләү һ.б.) ала. Ул биологик һәм социаль факторлар белән бәйле. Күпчелек социаль факторлар белән бәйле өченче дәрәҗә шәхеснең гадәтләре, осталыгы һәм белемнәреннән тора. Ниһаять, дүртенче дәрәҗә фәкать социаль бәйлелеккә генә ия һәм шәхеснең инанулары, дөньяга карашы, идеаллары, омтылышлары, мәнфәгатьләре, теләкләре кебек характеристикалар белән тасвирлана.

1 нче схема

Шәхес структурасы

Инанулар, дөньяга караш, идеаллар, омтылышлар, мәнфәгатьләр
Шәхеснең гадәтләре, осталыклары, күнекмәләре һәм белемнәре
Психик процессларның үзенчәлекләре: зиһенгә кабул итү, фикерләү, хәтер һ.б.
Җенес, яшь, темперамент белән бәйле биологик сыйфатлар

Модельнең башка варианты 2 нче схемада күрсәтелә. Әлеге модель шәхеслекне карауның һәм чагыштыруның өч вариантын аерып күрсәтә.

2 нче схема

Интроиндивид: шәхес башка кешеләрдән индивидуаль аерымлыклары күзлегеннән карала, кешегә тумыштан бирелгән сыйфатлар күрсәтелә
Интериндивид: шәхес фәкать башка кешеләр белән үзара эш иткәндә генә күренә торган сыйфатлар күзлегеннән карала
Метаиндивид: шәхеснең башка кешеләргә йогынтысын аның эшчәнлеге аша билгели

Психоанализга нигез салучы З.Фрейд (1856–1939) шәхес структурасының үзенчәлекле схемасын тәкъдим итә.

Аның структур моделенә өч структур компонент керә: Ид, Эго һәм супер-Эго.

Ид (латинчадан тәрҗемәсе «ул»), Фрейдча, шәхеснең фәкать примитив, инстинктлы, тумыштан булган аспектларын, ниндидер караңгы, биологик, хаотик, законнарны белмәүче, кагыйдәләргә буйсынмаучы нәрсәне аңлата. Ул бөтен кешелек тормышының беренчел принцибын — биологик нигезләнгән омтылышларын (аеруча сексуаль һәм агрессив) китереп чыгара торган психик энергияне кичекмәстән бушату. Киеренкелекне кичекмәстән бушату «рәхәтлек принцибы» дигән исем алган. Үзен импульсив, иррациональ һәм үз-үзенә соклану рәвешендә чагылдырып, башкалар өчен нинди нәтиҗәләргә китерүенә карамастан һәм үз-үзеңне саклау турында уйламастан, Ид шул принципка буйсына. Куркуны һәм борчылуны белмәгәнлектән, Ид үз максатына ирешүдә сакланып тормый. Бу фактның индивидка һәм җәмгыятькә куркыныч тудыруы ихтимал.

Эго (латинчадан «мин») — психиканың карарлар кабул итү өчен җаваплы өлеше. Эго тышкы дөнья куйган чикләүләр нигезендә Идның теләкләрен чагылдырырга һәм канәгатьләндерергә омтыла. Яшәү өчен көрәштә (һәм тышкы социаль дөньяга, һәм Идның инстинктив таләпләренә каршы) Эго психик пландагы вакыйгалар белән тышкы дөньядагы реаль вакыйгалар арасында даими аерымлык эшләргә тиеш.

Эго исә, максаты инстинктны канәгатьләндерүне бушануга ирешү мөмкинлеге тиешле ысул белән табылганга кадәр кичектереп торып, организмның бөтенлеген саклау булган чынбарлык принцибына буйсына. Чынбарлык принцибы индивидуумга Идның тупас энергиясен социаль чикләүләр һәм индивидуум намусы кысаларында тоткарлау, башка адреска күчерү яки аның акрынлап чыгуы мөмкинлеге бирә. Мәсәлән, сексуаль ихтыяҗны канәгатьләндерү кирәкле объект һәм тиешле шартлар табылганга кадәр кичектерелеп тора. Ә инде объект һәм шартлар идеаль булгач, үзеңне тоту канәгатьлек принцибына буйсына. Чынбарлык принцибы кешенең үзен тотышына акыллылык үлчәме бирә. Шулай итеп, Эго шәхеснең «башкару органы» — интеллектуаль процесслар агышы һәм проблемаларны чишү өлкәсе булып тора.

Кеше җәмгыятьтә нәтиҗәле яшәсен өчен, анда аның тирәсендә кабул ителгәннәргә акылга ярашлы кыйммәтләр, нормалар системасы булырга тиеш. Боларның барысына да супер-Эгоны (латинчадан — «югары-Мин») формалаштыру юлы белән ирешелә.

Фрейд супер-Эгоны ике ассистемага — намуска һәм үз-үзеңә тәнкыйди бәя бирү, әхлакый тыюлар булу, балада ул эшләргә тиешле нәрсәне эшләмәгәннән үзен гаепле тою хисе керә. Супер-Эгоның «бүләкләү» аспекты — Эго-идеал. Ул тирә-яктагыларның кешедә булганны хуплауларыннан яки югары бәяләүләреннән барлыкка килә; ул индивидуумны үзе өчен тиешенчә туры килерлек югары стандартлар эзләүгә илтә. Әгәр максатка ирешелсә, бу үзеңә карата хөрмәт һәм горурлык хисе уята. Мәсәлән, мәктәптәге уңышлары өчен макталган бала һәрвакыт үзенең академик казанышлары белән горурланачак.

Ата-ана контролен үзконтроль алыштыргач, супер-Эго тулысынча формалашкан булып санала. Ләкин үзконтрольнең бу принцибы чынбарлык принцибы максатларына хезмәт итми. Ид ягыннан теләсә нинди иҗтимагый гаепләнә торган импульсларны тулысынча тоткарларга тырышып, супер-Эго кешене уйда, сүздә һәм эшләнгән эшләрдә абсолют камиллеккә юнәлтергә омтыла. Кыскасы, ул Эгоны идеалистик максатларның чынбарлык максатларыннан өстен икәнлегенә ышандырырга тырыша. Супер-Эго шәхес кабул иткән мораль, әхлаклылык һәм дин өчен җавап бирә һәм ата-ананың икесе белән дә тәңгәлләшү нәтиҗәсендә формалаша.

Шәхес структурасына якын килүләр күптөрле булуга карамастан, аларның барысы да аның бөтенлеген, интегративлыгын чагылдыра, чөнки биологик, социаль һәм психик компонентлардан тора.

Шәхес структурасында чагыштырмача тотрыклы сыйфатларны да, үзгәрүчәннәрен дә аерып күрсәтергә була. Шәхеснең күп сыйфатлары үз сыйфатлары буенча тотрыклы. Темперамент, психика үзенчәлекләре гомер буе үзгәрми диярлек.

Шәхеснең тотрыклылыгы аның юнәлгәнлеге, тормыш карашлары һәм инанулары кебек сыйфатларда чагыла. *Шәхеснең үзгәрүчәнлеге* үз-үзеңне тоту модельләре үзгәрүчәнлегендә дә, кәеф, хис-тойгылар, тормыш тәҗрибәсе алышынуында да чагылырга мөмкин. Кайчак үзгәрүчәнлек чит кеше ихтыярына принципсыз буйсыну, үзеңнең «Мин»еңне югалту рәвешендә була. Мондый үзгәрүчәнлектән шәхесне тулысынча югалтуга бер адым. Шәхеслек сыйфатларыннан мәхрүм ителгән зат мисалы Р.Брэдбериның «Марс хроникалары» дигән новелласы герое була ала. Ул шәхеслек аныклылыгыннан һәм мөстәкыйльлегеннән бөтенләй мәхрүм; йогынтысына бирелгән кеше теләгенә бәйле рәвештә, ул гел үзгәреп тора.

Танылган психолог А.Н.Леонтьевның «Эшчәнлек. Аң. Шәхес» дигән китабында аңа капма-каршы герой сурәтләнә. Анда шәхеслек турында болай диелә: «Тормышның үзе кебек үк үзгәрүчән, шуның белән бергә үз даимилеген саклаучы

кешенең югары бердәмлеге» характеристикасы... «Чөнки кеше үзе туплаган тәҗрибәгә, тормыш хәлен үзгәртүче вакыйгаларга, ниһаять, үзендәге физик үзгәрешләргә бәйсез рәвештә, шәхес буларак, башкалар күз алдында һәм үзе өчен шул ук булып кала».

Төп төшенчәләр: индивид, индивидуальлек, шәхес.

Терминнар: экзистенциализм, Ид, Эго, супер-Эго.

Үзегезне тикшерегез

1. «Шәхес» төшенчәсен нинди билгеләр характерлый? 2. Шәхеснең өлгергәнлеге нәрсәдә чагыла? 3. «Индивид» һәм «индивидуальлек» төшенчәләре үзара нинди мөнәсәбәттә? 4. Шәхес структурасы нинди элементлардан тора?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Сабый-император Иван Антоновичны шәхес дип санап буламы (тарих курсыннан аның фаҗигале язмышын исегезгә төшерегез)? Җавабыгызны дәлилләгез.

2*. Үз шәхесегезнең «шәхес агачы» рәвешендәге схемасын ясагыз. Теге яки бу шәхеслек характеристикасыз ни өчен схеманың ул өлешенә урнаштыруыгызны аңлатыгыз.

Игътибарга алыгыз: туфрак — ыру башлыгы генофонды, ягъни агач тамырлары белән китә торган мирас.

Тамырлар үзләренә ата яки ананың генотипик сыйфатларын (яки бераз гына аларның һәр икесеннән дә) кеше үзен тотышы һәм чалымнары белән күпмедер охшаган башка туганнарыннан да алырга мөмкин.

Кәүсә — үсеш процессында формалашучы, база үзенчәлекләренең тирәлек белән үзара эш итүе нәтиҗәсендә билгеләнә торган психик сыйфатлар. Кәүсә өлеше символик рәвештә характерны, хис-тойгыларны, интеллектны, коммуникатив стильне (башка кешеләр белән аралашу ысулын) белдерә.

«Шәхес агачы»ның ябалдашы мәнфәгатьләрне, социаль активлыкны, әхлак сыйфатларын колачлый. Аны шактый дәрәҗәдә тирәлек, мохит формалаштыра. Әмма югары дәрәҗәдәге шәхесләр дә, мәдәни-тарихи кыйммәтләрне сәндереп, сайлап кына бер төрле тормыш күренешләренә, кешеләргә, мәнфәгать өлкәләренә, эшчәнлек төрләренә тартылалар, ә икенчеләреннән читләшәләр.

3. Язучы Ю.Трифонов (1925–1981) «Башка тормыш» хикәясендә болай ди: «Уңышсызлыклар аны елдан-ел басты, аның көчен суырды, ул бөкрәйде, хәлсезләнде, ләкин аның эчендәге ниндидер үзәк, нечкә корыч чыбык кебек, кагылмаган хәлдә калды, селкенде, ләкин ватылмады. Һәм бу аның бәласе

иде. Ул үзенең үзәгендә үзгәрергә теләмәде һәм, гәрчә ул уңышсызлыклардан интексә һәм күп газап кичерсә дә, үзенә ышанычын югалтты, аның акылы буталды дип уйларга мәҗбүр итүче мәгънәсез акылсызлыклар белән мавыкты, өметсезлеккә бирелде, һәм боларның барысы белән үзенең корычтай, беркемгә күренмәс мескен йөрәген интектерде».

Герой үз шәхесен саклаган дип раслап буламы? Параграф материалына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез.

4. Үз сыйныфыгызда зур булмаган тикшеренү уздырыгыз. Сыйныфташларыгызга өлгергән ун шәхес исемлеген төзергә тәкъдим итегез.

Сыйныфташларыгыздан сорагыз: алар өлгергән шәхескә кемнәрне кертәләр икән? Шуңа игътибар итегез: тәкъдим ителгән исемлектә замандашларыбыз бармы? Әлеге шәхесләр үзләрен эшчәнлекнең күпчелек кайсы өлкәсендә күрсәтәләр? Алынган мәгълүматлар нигезендә рейтинг төзегез һәм нәтиҗәләрне анализлагыз.

Чыганак белән эшләгез

Россиянең бүгенге социологы В.А.Ядов хезмәтеннән өзек укыгыз.

Өйрәнү предметы буларак шәхес

Табигать фәннәре өйрәнү предметы итеп кешене ала, аның сыйфатларын биологик һәм кайчак биосоциаль организм буларак тикшерә; шәхес исә, кешенең социаль сыйфаты буларак, социаль фәннәр: философия, социология һәм психологиянең тикшеренү предметы булып тора.

Философия шәхесне һәм кешене өйрәнүнең дөньяга карашның төп алшартларын, дөнья системасында кешенең урынын, аның асылын (ягъни аның тышкы дөнья белән күптөрле элемтәләрендә һәм мөнәсәбәтләрендә үзгәрешсез кала торган төп сыйфатларын) билгеләү кебек фундаменталь (методологик) проблемаларны чишү белән шөгыльләнә...

Социология шәхесне төп сыйфатлары социаль структурада билгеле бер урынга караган продукт һәм шуның белән билгеләнгән билгеле бер социаль тип сыйфатында тикшерә.

... Социологиядән аермалы буларак, гомуми психология барыннан да элек һәм нигездә шәхестәге субъектив башлангычын, әлбәттә, аның үзләреннән-үзләре өйрәнү предметы булып тормаган социаль шартлар белән билгеләнгән эчке табигатен тикшерә. Психологны тышкы социаль мохит йогынтысын зиһенгә кабул итүдә эчке психик сыйфатлар һәм процессларның читтән тәэсир итү ролен ачу, шәхеснең үз-үзен тотышында нәкъ менә аның шушы эчке сыйфатлары һәм үзенчә-

лекләренең (характер, темперамент, сәләтләренең, мотивлаштыруының) көйләү функцияләрен өйрәнү кызыксындыра.

Социаль психологиянең предметы — социаль субъектның типологиясен индивид буларак... тикшерү, социаль эшчәнлекнең эчке психик структура дәрәҗәсендә алынган тарихи һәм социаль конкрет бәйле типларын: мотивлаштыруны, кыйммәти билгеләнгәнлекне, социаль күрсәтмәләрне һәм башка... берәмлекләрне өйрәнү.

Сорулар һәм биремнәр: 1. Табигать фәнендә кешене өйрәнү предметының нәрсә булуын күрсәтегез. 2. Кешене табигать һәм социаль фәннәрдә өйрәнү нәрсә белән аерыла? 3. Философия, психология, социаль психология шәхестә нәрсәне өйрәнәләр? 4. Шәхес проблемасына предметара кызыксынуны сез нәрсә белән аңлата аласыз?

§ 29. Кешенең яше һәм шәхеснең ныгып урнашуы

Исегезгә төшерегез:

нәрсә ул «яшь»? Үсмер чак үзенчәлекләре нидән гыйбарәт? Кеше тормышының һәр чорында эшчәнлекнең нинди төрләре хәлиткеч роль уйный? А.Маслоуча, «ихтыяҗлар пирамидасы» нәрсә ул?

Барыннан да элек теләсә кайсы объектның яше аның яшәү озынлыгы буларак билгеләнә. Кешегә карата кулланганда, яшьне туудан исәпләнә башлаучы яшәү озынлыгы белән генә түгел, ә шәхеснең күп ныгу, үсү фазалары белән дә бәйлиләр.

Россиянең танылган психологы Л.С.Выготский (1832–1920) яшьне үсешнең үзенең эчтәлеге һәм динамикасы булган чагыштырмача йомык чор буларак билгели. Аның карашынча, хронологик яшь һәм психологик яшь — төрле, бер-берсенә туры килми торган ике төшенчә.

Кеше үз гомерен вакытта яши. Ләкин бу вакыт шактый катлаулы берәмлектән гыйбарәт. Бер яктан, яшәүнең шәхси вакыты үткәндәге, бүгенге һәм киләчәк вакыйгаларның үзара бәйләнешеннән тора. Тормыш вакыйгалары агышы биологик һәм социаль мөнәсәбәтләрнең вакытта объектив чагылышы. Вакытның бу агышын сәгатьләр, айлар, еллар терки. Кешенең яше рәсми документларында теркәлә. Моннан тыш һәр кеше өчен вакытның кеше тормышындагы әһәмиятле вакыйгалар масштабында субъектив чагылышы мөһим. Андый вакыт «шәхеснең психологик вакыты» дип атала. Ул — үз структу-

расы булган катлаулы берәмлек. Аңа ситуатив вакыт, биографик вакыт һәм тарихи вакыт керә.

Психологик вакытның һәр элементы нәрсәдән гыйбарәт? Ситуатив вакыт кыска вакыт аралыкларын зиһенгә кабул итүне һәм кичерүне чагылдыра. Кешегә яхшы булганда — вакытның «очуы», ә башка очракларда сузылуы һәркайсыбызга таныш.

Биографик вакыт индивид тормышын тулаем колачлый. Аңа әһәмиятле вакыйгалар да, бик үк әһәмиятле булмаганнары да керә. Бу вакыт кеше белән аның гомерендә булган бар нәрсәне терки. Гадәттә: «Сезгә ничә яшь?»— дип сораганда нәкъ менә биографик яисә паспорт вакытын күрсәтәләр.

Моннан тыш кешенең вакыт турындагы күзаллаулары өлкәсенә ул яшәгәнгә кадәр булган вакыйгалар да, ул үлгәч булачаклары да керә. Вакытның әлеге масштабы «шәхеснең тарихи вакыты» дип атала. Кайчакта шәхеснең, аерым индивидның практик эшчәнлекне, социаль тәҗрибәне үзләштерүе белән бәйле социаль вакытны да аерып күрсәтәләр. Нәкъ менә шул вакыт социальләштерүнең әһәмиятле этапларын терки.

ШӘХЕС ҮСЕШЕН ЧОРЛАШТЫРУ

Шәхеснең психик үсеше һәм аның төп эшчәнлеге үзара ни рәвешле бәйле? Психологиядә яшь үсүенең төрле чорларын өйрәнүгә тарихи принципны беренче булып Л.С.Выготский кертә. Ул, бала психикасы үсешендә анализ берәмлеге булып эш-гамәл тора, дип исбатлый. Соңрак А.Н.Леонтьев (1903–1979), психик үсешне чорлаштыруның критерие булып теләсә нинди эшчәнлек түгел, ә эчтәлеге һәм формасы бала үсешенең конкрет-тарихи шартларына бәйле булган төп эшчәнлек тора, дип күрсәтә. Бу атама белән үсешнең әлеге этабында бик тә мөһим психик яңа берәмлекләр барлыкка килү бәйле булган эшчәнлекне атау кабул ителгән.

> **Вундеркиндлар**
> Акыл үсешендә үз яшьтәшләрен узып киткән яисә искитмәле махсус сәләтләргә ия булган балалар. Гадәти сөйләмдә андый балаларны вундеркиндлар (немецчадан Wunder — гаҗәеп, Kind — бала) дип атыйлар.

Үткән гасырның 70 нче елларында яшь үсешенең төп эшчәнлек формаларын эзлекле төстә алыштыру идеясенә нигезләнгән периодлаштыру концепциясе эшләнде. Баланың туудан алып үсмерлек яшенә кадәр булган төп эшчәнлегенең

барлык теорияләрен анализлау нигезендә ике зур төркем аерып алына. Беренче төркем эшчәнлекнең «бала — ижтимагый өлкән кеше» системасында (шартлы рәвештә, балага теге яки бу эшчәнлекне үзләштерергә булышучы «өлкән» була) кешеләр арасындагы ысулларны, мотивларны һәм мөнәсәбәтләр нормаларын үзләштерү барган эшчәнлекнең барлык төрләреннән тора. Бу төркемгә сабыйның турыдан-туры эмоциональ аралашуы, үсмерләрнең рольле уены һәм интим-шәхси аралашуы керә. Икенче төркемне эшчәнлекнең «бала — ижтимагый предмет» системасында (бу очракта кешене аның тормышында чолгап алган предметлар күздә тотыла) үзләштерелә торган эшчәнлек төрләре тәшкил итә. Эшчәнлекнең әлеге төрләре предметлар белән эшләүнең ижтимагый эшләнгән ысулларын үзләштерүгә һәм предметларда төрле әһәмиятле якларны аерып күрсәтүче эталоннарга юнәлдерелгән. Бу төркемдәге эшчәнлек төрләре бер-берсеннән нык аерыла. Мәсәлән, кече яшьтәге баланың төрле предметлар белән уйнавы — мәктәп укучысының уку эшчәнлегеннән, ә 1 нче сыйныф укучысының уку эшчәнлеге өлкәнрәк яшьтәге үсмерләрнең мөстәкыйль танып-белү эшчәнлегеннән аерыла. Шул ук вакытта эшчәнлекнең бу төрләре кеше мәдәниятенең элементлары булып тора. Бала акрынлап мәдәниятнең күптөрле предметлары белән эш итүнең тагын да катлаулырак ысулларын үзләштерә, нәтиҗәдә баланың предметлы дөньяда тагын да тулырак ориентлашуы һәм аның интеллекты формалаша. Шулай итеп, төрле предметлар белән һәм төрле социаль хәлләрдә эш итү ысуллары үсеп кенә калмый, эшчәнлекнең индивидуаль стиле, кешенең тәҗрибәсе һәм характеры да формалаша.

Балаларның төп эшчәнлекләренең барлык төрләрен алар туганнан алып үскәнгә кадәр яшь үсешенең төрле чорларында төп эзлеклелегенә урнаштырсак, түбәндәге рәт барлыкка килә:

1. Турыдан-туры эмоциональ аралашу 0–1 ел I төркем	2. Предметлы-манипулятив эшчәнлек 1–3 ел II төркем	3. Рольле уен 3–7 яшь I төркем	4. Уку эшчәнлеге 7–10 яшь II төркем	5. Интим-шәхеслек аралашуы 11–14 яшь I төркем	6. Уку-профессиональ эшчәнлек 14–17 яшь II төркем

Схема бала үсешендә чорларның эзлекле рәвештә үзгәрүен, аларда бурычларны, мотивларны һәм *кешеләр арасындагы*

мөнәсәбәтләр нормаларын үзләштерү баруын (алар нигезендә шәхеснең мотивлары һәм ихтыяҗлары өлкәсе үсә), *предметлар белән эш итүнең* иҗтимагый эшләнгән ысулларын үзләштерү барган чорларын (алар нигезендә балаларның интеллектуаль танып-белү потенциалы формалаша) күрсәтә. Бер төркемдәге эзлекле төстә катлаулана баручы эшчәнлек төрләре һәрвакыт икенче төркемгә караган эшчәнлек төрләре белән алышына. Мотивлаштыру-ихтыяҗ өлкәсе өстенлеге үскән чордан соң закончалыклы рәвештә балаларның эш итү-техник мөмкинлекләре өстенлекле формалашкан чорлар килә һәм киресенчә.

Шулай итеп, шәхеснең үсеш процессы мотивлаштыру-ихтыяҗ өлкәсенең акрынлап катлауланауы һәм үзенең ныгып урнашуы процессында кеше үзләштерергә тиешле предметлы эшчәнлекнең төрле төрләренең акрынлап катлауланауы рәвешендә бара.

Шәхес үсешен башкача чорлаштыру исә индивид эшчәнлеге шәхес булу ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен ысуллар һәм чаралар эзләүгә юнәлдерелгән дип фаразлауга нигезләнә. Кешенең үсү чыганагы булып шәхес булу һәм үзеңне раслау ихтыяҗы белән төркем бурычларын хәл итүгә, төркем нормаларын һәм кагыйдәләрен кабул итүгә юнәлдерелгән активлык арасындагы каршылык ята. Бу теория буенча, кеше шәхесенең үсешен аның яңа социаль мохиткә керүе һәм анда тулы кыйммәтле урнашуы итеп күрсәтергә була. Әгәр кеше үзе өчен яңа, әмма чагыштырмача тотрыклы социаль бергәлеккә керсә, ул анда үзенең шәхес булып ныгып урнашуының өч фазасын үтә. Беренче фаза — *җайлашу* — бергәлектә яшәп килүче нормаларны үзләштерүне һәм эшчәнлекнең тиешле формаларына һәм чараларына ия булуны күздә тота. Әлеге бергәлеккә кабул ителсен өчен, индивид объектив рәвештә «башкалар кебек үк булырга» тиешле шартларга эләгә. Икенче фаза — *индивидуальләшү* — индивид төркемдә башкаларныкы кебек үк булган белән аның индивидуаль үзенчәлекләрендәге ихтыяҗлары арасындагы каршылык нәтиҗәсендә барлыкка килә. Бу вакытта индивидның үзен тотышы үз индивидуальлеген билгеләү өчен чаралар һәм ысуллар эзләүгә юнәлдерелгән. Өченче фаза — шәхеснең җәмгыятьтәге *интеграциясе* — шәхес булырга омтылу белән кешенең фәкать конкрет бергәлек кыйммәтләренә туры килгән һәм уртак эшчәнлек уңышына хезмәт итүче индивидуаль үзенчәлекләрен генә хуплау арасындагы каршылыклар тарафыннан тудырыла. Индивид белән төркем арасындагы каршылык бетерелмәсә, шәхесне бу бергәлектән йә «этеп чыгару», яисә ят итеп күрү, читләштерү белән тәмамланачак дезинтеграция барлыкка килә.

Шәхеснең үсеш процессын югарыда күрсәтелгәнчә аңлау ул кергән төркемнең үсеш дәрәҗәсе нигезендә периодлаштыру белән тулыландырылырга мөмкин. Шушы нигездә шәхес формалашуның яшь этапларын аерып күрсәтәләр: иртә балалык (балалар бакчасына кадәрге) чоры (0–3 яшь), балалар бакчасы чоры (3–7 яшь), кече мәктәп чоры (7–11 яшь), урта мәктәп чоры (11–15 яшь), өлкән мәктәп яше (15–18 яшь).

ЯШЬ ҺӘМ ЭЧКЕ ДӨНЬЯНЫҢ НЫГЫП УРНАШУЫ

Кайбер белгечләр яшь үсешен периодлаштыру турындагы мәсьәләне караганда аны шәхеснең эчке дөньясы ныгып урнашуы этаплары белән бәйли, туган бала фәкать шуның эчендә генә кеше була алган үзенчәлекле «киңлекне» аерып күрсәтәләр. Тикшеренүчеләр бу киңлекне баланың әнисе белән «тере бергәлеге», аларның уртак яшәве дип атыйлар. Уртак яшәү эчендә баланың индивидуаль сәләтләре, шул исәптән кешегә генә хас, иң югары сәләт — рефлекциягә сәләт үсә. Ул кешенең үз хисләрен, фикерләрен, эш-гамәлләрен анализлауда һәм бәяләүдә чагыла. Бу үзенчәлектән башка өлгергән шәхес була алмый. Югарыда күрсәтелгән периодлаштырудан аермалы буларак, шәхеснең ныгып урнашуы балачак һәм яшүсмерчак белән генә чикләнми.

Әлеге нигезләмәләргә таянып, шәхеснең эчке дөньясы үсешенең түбәндәге баскычлары аерып күрсәтелә.

Индивидның яшәвенең ана тормышы белән бергәлектә барлыкка килгән «җанлану» баскычы (туганнан алып бер яшькә кадәр), ягъни бергә яшәү. «Җанлану»ны гамәлгә ашыру билгесе булып «җанлану комплексы» хезмәт итә, шәхеслек аралашуы һәм мөнәсәбәте шуннан башлана да инде. Бу дәрәҗәдә бала кабул ителә торган әйләнә-тирә дөньяны һәм үзенең тоюларын аера башлый. Сабый бала әнисен күргәч үзен тотышын үзгәртә, ачык канәгатьлек хисләре белдерә.

«Рухлану» баскычы (бер яшьтән алты яшькә кадәр) башында ике мөһим вакыйга тора — туры басып йөрүне һәм сөйләмне үзләштерү. Туры басып йөрү аркасында бала беренче тапкыр координатларның өлкән кеше белән бердәм киңлек системасына эләгә. Ул дөньяны шул ук сурәттә күрә һәм кабул итә. Сөйләм исә балага үз-үзен «Мин үзем» формуласында аңлау мөмкинлеге бирә. Бу яшьтә бала беренче тапкыр өлкән кеше белән «уртаклыктан» котыла; аның мөстәкыйльлеге барлыкка килә.

Персональләшү баскычы (7 яшьтән 18 яшькә кадәр) кешенең үзе турында эчтәлекле күзаллаулар формалашу белән үзенчәлекле (үзбәя, «образ-Мин» һ.б.). Аңа шәхеснең үзенең

ныгып урнашуы туры килә. Үзеңне танып-белү баскычлары сезгә билгеле инде.

Индивидуальләшү баскычында (20 яшьтән 40 яшькә кадәр) кешенең рухи үзүсеше процессы башлана. Кеше үз тормышының авторына әверелә, үз гамәлләре һәм карашлары өчен җаваплылык тоя.

Күп кенә чит ил авторлары фикеренчә, шәхеснең акыл үсеше әхлакый үсеше белән тыгыз бәйләнгән. Бу фикер игътибар шәхеснең әхлакый аңы үсешен периодлаштыруга караган кайбер концепцияләрдә чагылган. Мәсәлән, шактый яхшы билгеле концепцияләрнең берсендә әхлакый үсеш үз-үзеңне тотуның эгоистик мотивларыннан намус һәм гаделлек турында күзаллаулар кушкан үз-үзеңне тотуга эволюция итеп карала.

Кайбер тикшеренүчеләр мәсьәләне шәхес үсешенең югары дәрәҗәсе дип исәпләргә мөмкин дип карый. Шик юк, кешенең яше белән шәхес үсеше арасында бәйләнеш бар, ләкин бу бәйләнеш турыдан-туры һәм бер мәгънәдә генә түгел. Американың гуманистик психология лидерларының берсе — К.Роджерс «Мин-концепция» формалашуны үзеңне хөрмәт итүгә ихтыяҗ арту белән бәйли. Әлеге ихтыяҗны тормышка ашыру еш кына шәхескә тирә-яктагылар куйган таләпләр белән каршы килә, нәтиҗәдә кеше үзе турында идеаль күзаллау белән үзенең реаль «Мин»е арасында бозылыш сизә башлый, бу исә кешенең үзенең чын асылыннан читләшүен барлыкка китерә. К.Роджерс фикеренчә, шәхес аның реаль «Мин»е үзенең тирәяктагылардан яшерергә кирәк булмаган фикерләренә, хисләренә, кичерешләренә һәм үз-үзен тотуына тәңгәл булганда гына гармонияле үсә ала.

Шәхес үсешенең гуманлы ориентлашкан теорияләренә шәхес үсүенең Көнбатышта киң таралган «интенциональлек» дип аталган теориясе дә керә. Аның нигезендә шәхескә салынган интенцияләрне (ниятләрне, максатларны) үстерү идеясе ята. Интенциональлек шәхеснең тормыш өчен әһәмиятле максатлар кую һәм мөстәкыйль рәвештә сайлау осталыгында чагыла. Әлеге нигезләмәләргә таянып, шәхес үсешенең периодлашуы эшләнгән, анда яшәү циклының биш фазасы аерып күрсәтелгән.

Беренче фаза 15 яшькә кадәр сузыла һәм мөстәкыйль максатлар булмау белән характерлана. Бу чорда акыл һәм физик сәләтләр үсә. Кагыйдә буларак, максатлар читтән бирелә, шәхес тарафыннан мәҗбүри һәм тиешле итеп кабул ителә.

Икенче фаза 25 яшькә кадәр сузыла. Бу чорда кеше үз ихтыяҗларын һәм сәләтләрен, шулай ук профессия һәм тормыш иптәшен сайлауны аңлый.

Өченче фаза — 25 яшьтән 45 яшькә кадәр — өлгерү фазасы дип исәпләнә. Бу чорда интенциональ мөмкинлекләр чәчәк ата,

профессиональ эшчәнлек һәм гаилә мөнәсәбәтләре тотрыклылана.

Дүртенче фазада (45–65 яшь) кеше үз тормышына йомгак ясый, уңышларын һәм уңышсызлыкларын башыннан кичерә.

Һәм, ниһаять, соңгы бишенче фазада (65–75 яшь) максатлар кую туктала, кеше үзенең яшәлгән гомеренә тулаем бәя бирергә тырыша.

Шәхес үсеше этапларын тагын бер сурәтләү яшь үсүе кризисын кичергәндә эшләнә торган шәхсән сайлау буларак гәүдәләнә. Бу кризис нәтиҗәсендә яңа берәмлек барлыкка килә. Әлеге яңа берәмлек кайбер потенциал каршылыкларны хәл итү белән бәйле, һәм берсе — шәхеснең прогрессына, ә икенчесе аның регрессына илтүче ике мөмкинлектән берсен сайлау буларак формалаша (таблицаны кара).

Э.Эриксон буенча шәхеснең үсү стадияләре

Этап	Нинди сайлау тормышка ашырыла
I	Дөньяга ышану — аңа ышанмау
II	Автономия урнашу — оялу белән бергә баручы үзенә шикләнеп карау
III	Инициатива — оялу хисе
IV	Эшкә ниятләү — тулы кыйммәтле булмау хисе туу
V	Идентификация — рольләрнең буталуы
VI	Якынлык эзләү — читләшү
VII	Нәселне саклау хисе, балалар тәрбияләү белән кызыксыну — үзеңә генә нният тоту
VIII	Шәхеснең бөтенлеккә ирешүе — үлемнән куркудан һәм кабат яшәү мөмкин булмаудан төшенкелеккә бирелү

Сезгә билгеле булган «яшь кризисы»ның балачактан үсмерчакка күчү чорының аерылгысыз үзенчәлеге икәнен аңлаудан аермалы буларак, әлеге таблица яшь кризисы тормышның башка чорларында да булу ихтималын күрсәтә. Ул кризисны

җиңү һәм аннан чыгу — шәхеснең ныгып урнашуының мөһим өлеше.

Шул рәвешле, кешенең яшен чорлаштыру теорияләренә йомгак ясап, кешенең паспорт һәм психологик яшьләренең туры килмәү ихтималын билгеләп үтик. Мәсәлән, җаваплы һәм мөстәкыйль кешеләр, гадәттә, үзләренең психологик яшьләре буенча җитлекмәгән яшьтәшләрен узып китәләр. Һәр яшь чоры — кабатланмас, үзенчәлекле, һәм ул шәхеснең ныгып урнашуы өчен мөһим. Кешенең тормыштагы уңышы һәм яшәвеннән канәгатьлек алу дәрәҗәсе билгеле бер яшьтәге кешенең үзен ни дәрәҗәдә тулы кыйммәтле итеп күрсәтә алуына бәйле.

Төп төшенчәләр: шәхес үсешен чорлаштыру.

Терминнар: персональләштерү, җайлашу, индивидуальләшү, интеграция, рефлексия, универсальләшү, интенциальлек.

Үзегезне тикшерегез

1. Кешенең биографик, социаль һәм тарихи вакытлары нәрсә белән аерыла? 2. А.Н.Леонтьев буенча, шәхес үсешен чорлаштыру нигезенә нинди критерийлар салынган? 3. Нәрсә ул төп эшчәнлек? Шәхес үсеше процессында ул ничек үзгәрә? 4. Шәхеснең үсүендә яшь кризислары нинди роль уйный?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Шәхеснең үсешен чорлаштыруга төрлечә якын килүне чагылдырган систематик таблица төзегез. «Чорлаштыру» төшенчәсен аерым авторлар каршында нәрсә белән аерылуын телдән аңлатып бирегез.

2. Балачак — тарихи күренеш, чөнки аның дәвамлылыгы да, эчтәлеге дә гасырлар дәвамында шактый үзгәрде дигән фикер яши. Борынгы җәмгыятьтә балачак Урта гасырларга караганда (безнең көннәр белән чагыштырганда бигрәк тә) шактый кыскарак булган. Безнең заманда балачакның кайчан тәмамлануы турындагы бәхәсләрдә үз карашыгызны булдырыгыз.

3. Бүгенге психологиядә психологик яшьнең аерым өлешләрен диагностикалауның кайбер алымнары һәм ысуллары эшләнгән. Уегызда гына кечкенә эксперимент үткәрегез: «Шундый хәлне күз алдыгызга китерегез: янәсе, сезнең паспортта, туу турында таныклыкта яки нindидер башка документларда теркәлгән яшегез дөрес түгел; өстәвенә әле сез ялгышның кайсы якка ясалганын — сез чынлыкта яшьрәкме, әллә өлкәнрәкме икәнен дә белмисез».

Үзегезне шундый хәлдә күзаллап, «Чынлыкта сезгә ничә

яшь?» дигән сорауга (үз яшегезне эчке сиземләүгә таянып) җавап бирергә тырышыгыз.

Сезнең чын календарь яшегез эчке сиземләвегез әйткән бәя белән туры киләме?

4. Календарь яшьне үзгәртмичә, психологик яшьне ничек итеп үзгәртеп була:

2–3 яшьтә балада сөйләм теле тиз үсә, 5–6 яшь — иң «артистлык» яше, 5–7 яшьтә бала укуны үзләштерүгә һәвәсрәк һ.б. Шул ук вакытта, бөтендөнья тәҗрибәсе күрсәткәнчә, 12–14 яшьтә туры басып йөрергә һәм сөйләшергә өйрәнү бик кыен.

Үз нәтиҗәгезне тәкъдим итегез, аны афоризм рәвешендә формалаштырыгыз яки бу очракка ярашлы мәкаль табыгыз.

Чыганак белән эшләгез

Бүгенге психолог Я.Л.Коломинский хезмәтеннән өзек укыгыз.

Балачакның тарихи характеры

Кеше тормышын бүгенгәчә дәверләр һәм чорларга бүлү шулкадәр табигый күренә ки, нинди дә булса башка вариантны күз алдына китерүе дә кыен. Гадәти өчлек: балалык, үсмерлек һәм яшьлек — әйтерсең лә яз, җәй, көз, кыш кебек үк какшамаслык... Ә чынлыкта исә монда барысы да алай ук гади түгел.

Беренче карашка гына гади булып күренергә мөмкин булган сорау бирик: нәрсәгә кирәк ул балачак? Өскә мәгълүмат ташкындай агылып торган безнең заманда аны үзләштерергә һәм, ул гына да түгел, аны күбәйтергә һәм практик кулланырга вакыт һич тә җитмәгәндә, беренче дистә елны (иң яхшыларын түгелме?) уеннарга, доктор Айболитка һ.б. әрәм итү дөресме? «Уйнагыз, балалар, уйнагыз, күңел ачыгыз иркенләп, шуңа бит сез әле бала!» дигән поэтик лозунг, бәлкем, кирәкмәс дәрәҗәдә искергәндер?

Махсус тикшеренүләр һәм чагыштырып караулар күрсәткәнчә, тере затларның яшәвенең аерым, сыйфат ягыннан үзенчәлекле чоры буларак, балачак ул — эволюция продукты, ә кешенең бала чагы әле тагын җәмгыятьнең тарихи үсеше нәтиҗәсе дә. Төр эволюция баскычында никадәр биектәрәк торса, балалык чоры шулкадәр озынрак икән. Түбән төзелешле хайваннарда балачак гомумән юк — алар үткәрергә тиешле примитив яшәү һәр заттан яшәү алды әзерлегенең махсус дәверен таләп итми. Нәселдәнлек яраклашу реакцияләре (инстинктлары) фонды җитә...

Кешенең бала чагы эволюция продукты гына түгел, ә тарихи үсеш нәтиҗәсе дә... Д.Б.Эльконин, балачак һәм аның аерылгысыз юлдашы — рольле уен — җәмгыятьнең җитештерү көч-

ләре үсү дәрәҗәсе белән бәйле, ди. Кешелек дөньясының үзенең бала чагы борынгы бергәлекнең һәр кешесенең индивидуаль бала чагы өчен урын калдырмый. Ул вакыттагы ерак тарихи дәвердә балалар, безнең көннәрдә күнеккән кебек, тормышы үз законнары белән аерымланган махсус төркемне тәшкил итми. Иҗтимагый җитештерүнең гадилеге балаларга ул процесска тулы хокуклы катнашучылар булып кушылу мөмкинлеге бирә. Үсешнең түбәнрәк баскычында торган җәмгыятьләрдә балалар бик тиз мөстәкыйль булып әвереләләр. Мәсәлән, корякларны[1] тикшеренүче Р.Н.Стебницкий узган йөзьеллыкның 20 нче елларында үткәргән күзәтүләре нигезендә, аларда балаларга һәм өлкәннәргә катгый билгеләү юк, дип билгеләп үтә. Балалар — җәмгыятьнең тулы хокуклы, тигез хөрмәт ителүче әгъзалары. Уртак әңгәмә вакытында аларның сүзләрен олыларныкы кебек үк игътибар белән тыңлыйлар. Некрасовның «бармак башы кадәрге» малаен хәтерлисезме?: «Ә сиңа ничә яшь?» — «Алты тулып үтте». Аның хәзерге яшьтәше, горурланып: «Гаилә зурын-зур да, ир-ат икәү генә шул — әти дә мин»,— дип әйтә алыр иде микән? Күптән түгел үткәндәге бу крестьян балаларының үзаңнарының «өлкәнлек» дәрәҗәсе аларда (А.П.Чехов сүзләре белән әйткәндә) балачакта балачак булмау белән бәйле: алар төп эшчәнлек уен түгел, ә хезмәт булган өлгерүлек чорына бик иртә аяк басканнар.

Кешенең нәкъ менә төп эшчәнлеге аның шәхси тарихы стадиясен билгели. Монда чор аша сикереп чыгу да, аны ясалма тоткарлау да бер үк дәрәҗәдә зарарлы.

Сораулар һәм биремнәр: 1. «Балачак — тарихи үсеш продукты»,— дип әйтү нәрсәне аңлата? 2. Җәмгыять үсешенең элеккеге тарихи этапларында иртә өлгерүгә нинди сәбәпләр булышлык иткән? 3. «Балачак» төшенчәсенең тарихи характерын раслау өчен автор нинди дәлилләр китерә? 4. Балачактан өлгерү яшенә күчкәндә төп эшчәнлек ничек үзгәрә?

§ 30. Шәхеснең юнәлгәнлеге

Исегезгә төшерегез:

кыйммәтләр кеше тормышында нинди роль уйный? Кешенең ихтыяҗлары һәм мәнфәгатьләре үзара ничек бәйләнгән?

---

[1] *Коряк* — төньяк халыкларының берсе.

Кеше эшчәнлеген аның активлыгы формасы буларак өйрәнеп, сез әлеге эшчәнлекнең төп аермалыклары белән хайваннарның үз-үзләрен тотышлары аша таныштыгыз. Кешенең әйләнә-тирә дөнья белән үзара эш итүендә шәхеснең дәлилләү өлкәсе структурасы әһәмиятле роль уйный.

Бу параграфта сүз дәлилләр системасы, аларның нисбәте һәм социаль үз-үзеңне тотуга йогынтысы турында барачак. Шәхеснең кыйммәтлекле юнәлеш тотуын һәм аның үз-үзен тотышының төп линиясен нәкъ менә дәлилләү өлкәсенең һәм эшчәнлекнең барлык башкалары аларга буйсынган төп дәлилләр төзелеше билгели.

Шәхеснең юнәлгәнлеге социаль психология һәм педагогика өчен кызыксындыру тудыра, чөнки шәхеснең бу үзенчәлеге һәрвакыт социаль нигезләнгән һәм җәмгыятьнең турыдан-туры йогынтысы астында формалаша. Дәлилләү өлкәсенең тиешенчә формалашып җитмәве яки шәхеснең ныгып урнашуының уңайсыз шартлары нәтиҗәсендә барлыкка килгән ялгыш карашлар социаль нормаларны бозуга һәм үз-үзеңне дөрес тотмауга китерә.

СОЦИАЛЬ ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТОТУ

Фәндә «социаль эш итү», «социаль үзара эш итү» һәм «социаль үз-үзеңне тоту» төшенчәләре еш кына синонимнар буларак кулланыла.

«Социаль эш итү» атамасын немец социологы, икътисадчысы һәм юристы М.Вебер (1864–1920) еш куллана. Ул болай дип яза: «Эш итү дип кешенең үз-үзен тотышы эш итүче индивид яки эш итүче индивидлар аның белән субъектив мәгънәне бәйләгән очракта атала». Гадиләштереп әйткәндә, эш итү ул — кешенең уйланылган үз-үзен тотышы.

Социаль эш итү — кешенең яки социаль системаның объекты башка социаль субъектлар булган эш итүе ул.

Социаль эш итү, бер яктан, кешенең үз ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүгә, икенче яктан, читләтеп яки турыдан-туры башка кешеләргә юнәлдерелгән. Эш итү яки гамәл тирә-яктагыларның мәнфәгатьләренә кагылган очракларда алар тегеләре ягыннан нинди дә булса җавап тудыра.

Социаль эш итү ике төргә: рациональгә һәм иррациональгә бүленергә мөмкин.

Рациональ социаль эш итү вакытында субъект максатны, шулай ук аңа тиешле чараларны һәм аңа ирешү ысулларын алдан уйлап куя.

Иррациональ социаль эш итү ул — аффектив-импульсив эш итү; бу вакытта субъект максатлар, аңа ирешүнең чарала-

ры һәм ысуллары турында үзенә ачык исәп-хисап бирми.

Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: реаль тормышта еш кына кушылган тип — өлешчә рациональ, өлешчә иррациональ очрый. Бу өч компонентның (максат, чаралар, ысуллар) берсе яки икесе уйланмаган яки начар уйланган очраклар да була. Шулай ук хәтта иррациональ эш итү дә һәрвакытта да тулысынча мәгънәсез, ягъни акылга сыймаслык һәм зарарлы булмый.

Социаль эш итүнең аталган төрләрен аерып күрсәтү, социаль әһәмиятлелеге күзлегеннән караганда, теләсә кайсы конкрет кешенең үз-үзен характерлавы өчен мөһим. Әгәр кешенең гадәттә рациональ эш итүе билгеле булса, ул исәп белән, уйлап эш итүче, тотнаклы икәнен, эшләгәндә ышанычлы булуын, типик хәлләрдә аның гамәлләрен алдан күреп була. Һәм бу аның белән хезмәттәшлек итүне күпкә җиңеләйтә. Әгәр кеше ешрак иррациональ эш итсә, бу аның үзен начар контрольдә тотуын, аны хис-тәэсирләр (кайчак идарә итеплә алмаслыклары да) мавыктыруын, аның алдагы минутта ни эшләячәген үзе дә белмәвен аңлатуы мөмкин.

Эш итүләрне җаваплыга һәм җавапсызга (волюнтарчылыкка) аерырга була.

Җаваплы эш итү — ул шундый инициативалы социаль эш итү ки, бу вакытта эш итүче субъект башка кешеләр һәм әйләнә-тирә социаль һәм табигый мохиттә ихтимал булган нәтиҗәләр өчен җаваплылыкны үз өстенә ала. Социаль эш итүнең бу төре кешене теләсә нинди инициативага юл биргән, әмма җаваплылык белән тулыландырылмаган ирекнең акылсыз — дәгъвалы волюнтаризмга илтәчәген аңлаган цивилизацияле социаль затка әверелдерә.

Җавапсыз эш итү ул шундый инициативалы социаль эш итү ки, бу вакытта эш итүче, үз мәнфәгатьләрен генә күздә тотып, башка кешеләр мәнфәгатьләрен санга сукмый, җәмгыять һәм табигать өчен тискәре нәтиҗәләр булу ихтималы өчен үзенә җаваплылык алырга теләми, максатка илтергә сәләтле теләсә нинди чараны сайлый. Андый кеше — һәрвакытта «Мин шулай телим һәм вәссәлам, аннары теләсә нишләгез» дигән принцип белән эш итүче волюнтарист. Үз файдасы турында гына уйлаучы кешенең индивидуальлек әхлагы әнә шулай барлыкка килә. Андый әхлакның төп принцибын гомуми талану һәм хәерчелек уртасында байлыкта-муллыкта яшәүче Людовик XV: «Бездән соң су басса да ярый»,— дип белдерә.

Социумда үз-үзеңне тоту үзенчәлеге күп яктан шәхеснең кыйммәти юнәлгәнлеге белән билгеләнә.

ШӘХЕСНЕҢ ЮНӘЛГӘНЛЕГЕ СТРУКТУРАСЫ

Юнәлгәнлек иерархия тәртибендә күрсәтелгән мотивларның: һәвәслек, теләк, омтылыш, кызыксыну, идеал, дөньяга караш һәм инануларның тулы бер гаммасында чагыла.

Һәвәслек — индивидның нәрсәгә дә булса, кемгә дә булса аңсыз ихтыяҗын чагылдыручы аерым бер халәт ул.

Теләк нәрсә дә булса булдыру яисә нәрсә дә булса эшләү мөмкинлеге турындагы уйлардан гыйбарәт. Һәвәслектән аермалы буларак, теләк — билгеле бернәрсәгә аңлы ихтыяҗ һәм һәвәслек, шул ук вакытта кешенең нәрсә теләве генә түгел, ә аңа ничек ирешүе дә аңланыла. Үз теләкләре нигезендә кеше максатлар билгели, планнар кора.

Омтылыш, максатка ирешү яки ирешмәүгә бәйле рәвештә, кешедә канәгатьлек яки канәгатьсезлек китереп чыгаручы хискичерешләр белән тыгыз бәйләнгән.

Шәхеснең кызыксыну юнәлгәнлеге формасы галимнәр тарафыннан ныграк өйрәнелгән. Кешене аның ихтыяҗын канәгатьләндерә ала торган нәрсә кызыктыра. Кызыксыну арта баруга сәләтле. Кызыксынган бернәрсәне канәгатьләндерү, гадәттә, яңаларын тудыра.

Кызыксынуларның нинди дә булса ихтыяҗ белән турыдантуры бәйләнгәннәре һәм ихтыяҗ бик үк ачык сизелмәгән турыдан-туры түгелләре була. Бер кешене сәясәт хакимият алу максатында кызыксындыра, ә икенче берәү сәясәттә үзен нәрсә кызыксындыруын төгәл генә әйтә алмый.

Саклау дәвамлылыгына карап, кызыксынулар тотрыклы һәм тотрыксыз була. Тотрыклы кызыксынган кешеләр тотрыксыз кызыксынганнарга караганда уңышка ешрак ирешәләр. Гәрчә хаклык өчен танырга кирәк: тотрыксыз кызыксынулар хискичереш ягыннан мавыктыргыч булырга мөмкин.

Кызыксынулар шулай ук киң һәм тар була. Тар кызыксыну бөтенләй төгәл бер объектка юнәлдерелергә мөмкин.

Кайчак кызыксынуларны «вак» дип атыйлар. Бу вакытта кешеләрнең, нигездә, табигый: ашауга, эчүгә, йокыга, башка тою-сизү рәхәтлекләренә булган ихтыяҗлары белән кызыксынуын күздә тоталар. «Иске карашлы алпавытлар» повестендагы Афанасий Иванович белән Пульхерия Ивановнаның мәнфәгатьләре, мәсәлән, әнә шундый. Н.В.Гоголь геройлары, һичшиксез, игелекле, ләкин аларның мәнфәгатьләре бүгенге көн турында вак кайгыртулардан читкә чыкмый.

Кызыксыну ихтыяр белән кушылса, ул *һәвәслеккә* әверелә. Әгәр кеше музыка дәресләрендә ихтыяри тырышлык куйса, музыка белән кызыксыну һәвәслеккә үсеп җитә. Һәвәслек барлыкка килү гадәттә сәләтләрнең үсүе белән бергә бара.

Шунлыктан күпләгән бөек рәссамнар, музыкантлар тиешле һәвәслекләрен әле бала вакытта ук күрсәткән. Шунысын да әйтик: уңай һәвәслектән тыш тискәре, хәтта куркыныч һәвәслекләр дә очрый.

Социаль үз-үзеңне тотуга карата кулланганда, *идеал* дип максатны бик тә яхшы гәүдәләндерү турындагы күзаллауны, үрнәкне атыйлар. Идеаллар аркасында кеше әйләнә-тирә дөньяны чагылдырырга гына түгел, ә аны идеалларга туры китереп үзгәртергә дә сәләтле.

Конкрет бер кешенең идеалы аның кыйммәтләре системасы белән тыгыз бәйләнгән.

Инануларны шәхеснең юнәлгәнлегенең иң югары формасы дип атыйлар. Сүзлектә **инану** атамасы **берәр нәрсәнең дөреслегенә, раслыгына чын күңелдән ышану** дип билгеләнә. Инануның нигезен көчле хисләр һәм чынбарлыкка карата аерым бер мөнәсәбәт белән бизәлгән тирән белемнәр тәшкил итә. Инануларның чын табигате барыннан да бигрәк үз-үзеңне тотуда чагыла. Нәкъ менә инанулар үз-үзеңне тотуны максатка омтылучан һәм эзлекле итә. Инанулар хакына кешеләргә җитди корбаннарга барырга туры килгән мисалларны тарих күп белә.

Урнашкан инануларлы кеше аларга катгый туры китереп кенә эш итеп калмый, аларны башка кешеләргә дә тапшырырга тырыша. Бербөтен, тәртипкә салынган инанулар кешенең *дөньяга карашы* булып әверелә.

Дөньяга караш — кешенең әйләнә-тирә дөньяга һәм анда үзенең урынына карашлары системасы. Дөньяга караш булу — шәхеснең өлгергәнлегенең әһәмиятле күрсәткече. «Җитлеккән кеше» дигәндә барыннан да элек дөньяга карашның формалашып бетүен күздә тоталар. Дөньяга караш һәркайда — көнкүрештә, эштә, кешеләр мөнәсәбәтендә чагыла. Эчтәлеге буенча кешенең дөньяга карашы фәнни һәм фәнни түгел, материалистик яки идеалистик, дини яки атеистик булырга мөмкин. Ул эшчәнлекнең төрле өлкәләреннән белемнәрне гомумиләштерүгә нигезләнеп кенә калмый, буыннан буынга тапшырыла торган карашларга һәм инануларга да таяна. Дөньяга караш турында тулырак сүз алдарак, җәмгыятьнең рухи тормышын һәм рухи мәдәниятне өйрәнгәндә булыр.

Шулай итеп, шәхеснең юнәлгәнлеге сәбәпләрнең (мотивларның) төрле кушылмалардагы катлаулы иерархиясен колачлый; әлеге иерархиянең түбәсендә эчтәлекләре буенча төрле мотивлар булырга мөмкин. Шулай да психологлар юнәлгәнлекне кешенең үзенә һәм җәмгыятькә, башка кешеләргә мөнәсәбәте күзлегеннән характеристикалау тирәнрәк, нигезлерәк дигән уртак фикердә тора.

Кешене нәрсә этәрә — шәхсән кызыксыну сәбәпләреме (аларны шулай ук шәхси, эгоистик дип тә атыйлар), әллә башка кешеләр мәнфәгатьләре белән бәйлеләреме (аларны шулай ук альтруистик, коллективистлык, просоциаль дип атыйлар) — шәхеснең барлык башка үзенчәлекләре: мәнфәгатьләре, характеристикалары, омтылышлары, кичерешләре шуңа бәйле рәвештә төзелә.

Исегезгә төшерик, альтруизм — үз мәнфәгатьләрең белән исәпләшмичә, башкалар файдасына эчкерсез эш итүгә әзер тору ул. Шунлыктан шәхеснең альтруистик юнәлгәнлеге кешеләргә ярдәм итүгә, аларның максатларын, мәнфәгатьләрен исәпкә алуга, гамәлләрне алга этәрүче дәлилләрне аңлауга юнәлдерелгән сәбәпләрдә төзелә.

Иҗтимагый (просоциаль) юнәлгәнлек өстенлек иткән шәхесләрдә кешеләргә ярдәм итү һәм ярату күбрәк була. Андый юнәлгәнлек булмаса, җәмгыять бербөтен бердәмлек булып яши алмас, ә кеше хәзергедәй зат була алмас иде.

Альтруистик юнәлгәнлекнең капма-каршысы — *эгоистик юнәлгәнлек;* бу вакытта кешегә шәхсән кызыксынучанлык, үзен ярату, үз мәнфәгатьләрен башка кешеләрнекеннән, җәмгыятьнекеннән өстен кую сәбәпләре этәргеч бирә.

Юнәлгәнлекнең атап үтелгән ике төре белән бергә тикшеренүчеләр шәхеснең юнәлгәнлегенең өченче төрен — шулай ук мөһим булган, ләкин шәхси һәм иҗтимагый юнәлгәнлеккә карамаган *эшлекле юнәлгәнлек* дигәнен дә аерып күрсәтәләр.

Эшлекле юнәлгәнлектә (аны шулай ук «бурычка юнәлгәнлек» дип тә атыйлар) этәрүче сәбәпләр эшчәнлекнең үз процесслары белән бәйле.

Картинасын рәсем ясау процессы кызыксындырган өчен ясаучы рәссамны әнә шундый сәбәп мавыктыра.

Эшлекле сәбәпләрнең гомумән тормыштагы һәм, аерым алганда, фәндәге роле турында бөек рус педагогы Константин Дмитриевич Ушинский (1824–1870) менә нәрсә дип яза: «Фәннең максаты фәннән файда алу гына булса, ул бер адым да алга бара алмас һәм файда китерүдән туктар иде. Чын галим исә фән белән фән өчен шөгыльләнә һәм, болай гына әйткәндә, юл уңаеннан анда газапларны бетерү яисә яңа ләззәтләр табу өчен, әлбәттә, үзе өчен түгел, чаралар ача».

Юнәлгәнлекнең бу өч төре саф рәвештә еш очрамый. Билгеле бер хәлләрдә кешенең үз-үзен тотышының теге яки бу сәбәбе өстенлек итү турында сөйләү дөресрәк.

ТОРМЫШ МАКСАТЛАРЫ

Шәхеснең юнәлгәнлеге анық тормыш максатлары формалаша торган нигез булып тора.

Яшәве дәверендә һәр кеше эшчәнлекнең төрле төрләрен башкара. Һәр эшчәнлек билгеле бер максатны гамәлгә ашыра. Ләкин аерым эшчәнлек максаты шәхеснең юнәлгәнлегенең тормышта шушы мизгелдә чагыла торган нинди дә булса бер ягын гына ача. Эшчәнлек максатын һәм тормыш максатын аерып карау кабул ителгән. Тормыш максаты эшчәнлекнең аерым төрләре белән бәйле аерым максатларны берләштерә, куша. Шуның белән бергә, арадаш һәр максатка ирешү — гомуми тормыш максатына баруда яңа адым ул. Мәсәлән, әгәр кешенең тормыш максаты игелек идеалларына хезмәт итү буларак билгеләнергә мөмкин булса, яшәү дәвамында әлеге максат аерым максатларга: үз эшеңне яхшы итеп башкаруга, аралашкан партнерларыңны хөрмәт итүгә, социумда кабул ителгән нормалардан читләшмәүгә, үз Ватаныңа хезмәт итүгә һ.б. әверелергә мөмкин.

Шәхеснең казанышлары дәрәҗәсе тормыш максатлары белән бәйле. Шәхеснең тормыш максатларына анық үз киләчәгенә карашлары кергән. Кешенең максатның үзен генә түгел, ә аны гамәлгә ашыру юлларын да аңлавы шәхеснең перспективасы итеп карала. Әгәр кеше максатка бару юлында уңышларга ирешсә, ул дулкынлану, рух күтәренкелеге, иҗади күтәрелеш тоя. Максатка ирешүдә очравы ихтимал булган үтә алмаслык каршылыклар, киресенчә, тирән кичерешләр, борчылулар тудырырга мөмкин. Бу халәтне фрустрация (латинчадан frustratio — алдау, борчылу, планнарның җимерелүе) дип атыйлар.

Үзләре алдында барлыкка килгән каршылыкларга кешеләр төрле мөнәсәбәт күрсәтә. Психологлар кешеләрнең үз-үзләрен тотышларының берничә типик төрен аерып күрсәтәләр. Берәүләр фрустрация вакытында төшенкелеккә бирелә, бөтенесенә кул селти, икенчеләре, киресенчә, тагын да активрак, дәртлерәк була. Кемдер агрессиягә бирелә, җимерергә омтыла, кемдер сукырларча, бернинди уңышка ирешмичә, һаман саен максатына ирешергә тырыша. Башкалар, үз-үзеңне тотуның тормышның элеккерәк чараларына хас булган формаларына әйләнеп кайткандай, «кечкенә» булып калалар. Шунысына игътибар итик: мондый хәлләрдә үз-үзеңне тоту шәхеснең үзенчәлекләренә дә, бу тотыш чагылган социаль шартларга да бәйле.

Фрустрация барлыкка килүнең зарури билгеләре — ачык чагылган максатка ирешү (ихтыяҗны канәгатьләндерү) теләге һәм аны гамәлгә ашыру юлында каршылыклар барлыкка килү.

Мондый очракларда кеше шактый кыенлыкларны фрустрация халәтенә төшмичә җиңә ала. Ләкин критик мизгелләрдә, кыенлыкларны җиңеп булмаганда, фрустрация халәте туарга мөмкин. Бер яктан, ул кеше аның үз-үзен тотышын үзгәртә, боза, икенче яктан, аны яхшырак белергә ярдәм итә. Кеше бәла килгәндә беленә, дип юкка гына әйтмиләр.

СОЦИАЛЬ ОМТЫЛЫШ

Кешенең социумда үз-үзен тотышы һәрвакыт билгеле бер кичерешләр белән бергә бара.

Социаль психологиядә «омтылыш» төшенчәсе шәхеснең социаль объектның әһәмиятен күңеленнән кичерүе буларак аңлашыла.

Бүгенге фәндә социаль омтылышның төрле билгеләмәсе бар. Еш кына мондый билгеләмәне кулланалар: социаль омтылыш ул — шәхеснең объектка карата үзен билгеле бер рәвештә тотуының алдан билгеләнгән, үткәндәге тәҗрибәсенә нигезләнгән психологик әзерлеге.

Әле үткән гасыр уртасында ук омтылыш структурасында үзара бәйләнгән өч компонентны аеру традициясе урнаша: когнитив, эмоциональ, үзеңне тоту.

Когнитив (танып-белүче) компонент объектка карата фикерләр һәм раслаулар рәвешендә табыла.

Эмоциональ (аффектив) компонент объектка хисләр һәм кичерешләр телендә әйтелгән мөнәсәбәт аша чагыла.

Үзеңне тоту компоненты индивидның объект белән конкрет эшчәнлек алып барырга әзерлегеннән тора.

Кеше социаль омтылышларның әзер җыелмасы белән тумый, аларны яше арта барган саен үстерә. Омтылыш кешенең үз тәҗрибәсе нигезендә генә түгел, башка кешеләрдән алган тәҗрибә нигезендә дә формалаша.

Омтылышның төп сыйфатлары — тотрыклылык һәм үзгәрүчәнлек.

Әгәр кеше барлык төрле хәлләрдә объектка карата үзен тотуның гадәти һәм табигый булган ысулын тормышка ашырса, бу аның омтылышлары тотрыклылыгын дәлилли. Омтылыш объекты турында алынган яңа мәгълүмат булган белемнәр белән билгеле бер рәвештә яраштырыла. Омтылышта мәгълүмат каршылыклары («когнитив диссонанс») булса, яңа мәгълүмат алыну һәм акыллы дәлилләр йогынтысында анда үзгәрешләр булырга мөмкин.

Омтылышның үзгәрүе объект кешенең мәнфәгатьләренә һәм ихтыяҗларына ул элек фаразлаганнан да күбрәк туры килүен ачучы мәгълүматлар йогынтысы нәтиҗәсендә дә булыр-

га мөмкин. Тагын да якыннанрак танышу нәтиҗәсендә кешенең бәяләмәсе тискәредән уңай якка үзгәрүе ихтимал, шуннан соң әлеге объектка карата үзеңне тоту да үзгәрә.

Омтылышның төп вазыйфасы — кешенең социаль тотышын җайга салу. Уңай (объект яклы), тискәре (объектка каршы) һәм нейтраль омтылышлар була. Кешенең индивидуаль омтылышлары системасы аның әйләнә-тирә чынбарлыкта ориентлашу мөмкинлеген тәэмин итә.

Моннан тыш омтылышларның саклау вазыйфасы да бар. Аңа якындагы социаль тирәлек омтылышлары бертөрлелегенә ярашу нәтиҗәсендә ирешелә. Мәсәлән, бер гаилә әгъзалары, кагыйдә буларак, охшаш омтылышлар тоталар. Әгәр алар нык аерылса, моның каршылыкларга һәм бер-береңне аңламауга китерүе ихтимал.

Шунысын да әйтергә була: әгәр кеше башкалар белән охшаш рәвештә уйласа һәм эш итсә, үзен башкача тотмаса, социаль омтылыш кешенең төркемдәге үзбәясен саклый.

Әгәр социаль омтылышлар озак вакыт тотрыклы һәм яңа тәҗрибә йогынтысына ябык булса, алар стереотипка (бертөрлелеккә) әвереләләр. Стереотип структурасында төп рольне аның эмоциялеккә корылуы уйный, ул теләсә кайсы объектка карата нәрсәнең кабул ителгәнен, гомумән, нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнен бер үк рәвештә күрсәтә.

> **«Хәлне үзгәртә алмасаң, аңа карата үз мөнәсәбәтеңне үзгәрт».**
>
> **Станислав Ежи Лец**

Төп төшенчәләр: социаль күрсәтмә, шәхеснең юнәлгәнлеге.

Терминнар: социаль эш итү, мавыгу, теләк, омтылыш, мәнфәгатьләр, идеаллар, ышанулар, дөньяга караш, альтруизм, фрустрация.

Үзегезне тикшерегез

1. Нәрсә ул социаль үзеңне тоту? 2. Шәхеснең юнәлгәнлеген нинди сәбәпләр тәшкил итә? 3. Шәхеснең юнәлгәнлегенең төп төрләрен тасвирлагыз. 4. Кешенең тормыш максатларының үзенчәлекләре нидән гыйбарәт? 5. Социаль омтылыш нәрсә белән характерлана? Шәхес структурасында аның роле нинди?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Түбәндәге фикер белән килешегез яки аны кире кагыгыз: «Шәхеснең юнәлгәнлеге — кешенең эшчәнлегенә йогынты

ясаучы, ул үзе эш итә торган конкрет хәлләрдән чагыштырмача бәйсез булган тотрыклы сәбәпләр җыелмасы».

2. Сальериның шәхес юнәлгәнлегенең А.С.Пушкин язган чагылышларын тасвирлагыз:

Отверг я рано праздные забавы;
Науки, чуждые музыке, были
Постылы мне; упрямо и надменно
От них отрекся я и предался
Одной музыке.

Якынча тәрҗемәсе:

Иртә ташладым буш күңел ачуларны,
Музыкага ят фәннәр файдасыз миңа,
Алдан тырышып һәм үҗәтләнеп
Баш тарттым һәм биреддем
Фәкать музыкага.

3. Мәнфәгатьләре киң булган тарихи шәхесләрнең исемлеген дәвам иттерегез. Леонардо да Винчи...

4*. Теләсә кайсы әдәби геройның (Онегинның, Печоринның һ.б.), сезнең карашча, аның шәхес юнәлгәнлеген төгәлрәк чагылдыручы социаль үзен тотышының сәбәпләрен схематик төстә күз алдыгызга китерегез. Сез сайлаган персонажның шәхес юнәлгәнлеген билгеләүче төп сәбәпләрен күрсәтеп, күз алдыгызга китергән схеманы телдән аңлатыгыз.

Чыганак белән эшләгез

Америка психологы Д.Майерс хезмәтеннән өзек укыгыз.

Үзеңне тоту һәм омтылышлар

Безнең гамәлләребезнең ни өчен омтылышларыбызны чагылдыручы раслауларга йогынты ясавын үзара көндәшлектәге өч теория аңлата. Үзең белән таныштыру теориясе: кешеләр, аеруча үзләрен яхшы тәэсир калдыру нияте белән контрольдә тотучылар, аларның эш-гамәлләренә туры килсен өчен, үз әйткәннәрен яраклаштыралар дип исәпли. Булган мәгълүматлар кешеләрнең омтылышларын чагылдыручы раслауларны яраклаштыруын дәлилли...

Башка ике теория безнең гамәлләребез башка омтылышларны үзгәртүгә китерә дип исәпли. Когнитив диссонанс[1]

[1] Cognitio — белем, танып-белү һәм dissonans — гармония булмау, нәрсәгә дә булса туры килмәү, каршылык, аерымлык.

моны омтылышларыбызга каршы килүче эшләрдән яки авыр карар кабул иткәннән соң безнең киеренкелек хис итүебез белән аңлата. Аны киметү өчен без үз гамәлләребезгә эчке аклану эзли башлыйбыз. Аннары диссонанс теориясе шуннан чыгып эш итә: без кылган ярамаган эшләр өчен эчке акланулар күпме азрак булса, без аның өчен шулкадәр зуррак җаваплылык тоябыз, һәм, димәк ки, шулкадәр зуррак диссонанс барлыкка килә, һәм омтылышлар шулкадәр күбрәк үзгәрә.

Үзеңне аңлау, кабул итү теориясе омтылышларыбыз тотрыклы булмаганда без үзебезнең тотышыбызны һәм тышкы хәлләрне күзәтәбез генә дип исәпли. Үзеңне кабул итү теориясенең кызыклы якларының берсе — «артык аклану нәтиҗәсе». Кешеләрне алар яратканны эшләгәннәре өчен бүләкләүнең эштән алган канәгатьләнү хисен эч пошуга әйләндерүе ихтимал (әгәр бүләк үзеңне тотуны бүләкләү зарурлыгына кайтарып калдырса). Әгәр һәр икесе дә билгеле бер шартларда булганнарны тасвирласа, фактлар ике теорияне дә яклый.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Үзең белән таныштыру теориясе үзеңне тоту һәм омтылышлар нисбәтен ничек аңлата? 2. Когнитив диссонанс теориясе күзлегеннән караганда, үзеңне тоту һәм омтылышлар нисбәтен сез ничек аңлыйсыз? 3. Үзеңне кабул итү теориясенең үзеңне тоту һәм омтылышлар нисбәтен аңлатуы белән килешәсезме? 4. Текстта китерелгән теорияләрне конкретлаштыручы мисаллар китерегез.

§ 31. Аралашу — мәгълүмат алмашу

Исегезгә төшерегез:

нәрсә ул аралашу? Шәхеснең ныгып урнашуында ул нинди роль уйный? Мәгълүмат тапшыруда аралашу нинди роль уйный? Аралашуның нинди чаралары бар? Нәтиҗәле аралашуга нинди каршылыклар комачаулый?

Төп мәктәп курсыннан белгәнегезчә, аралашу ул — кешеләр арасындагы уртак эшчәнлек ихтыяҗы тарафыннан тудырыла торган, мәгълүмат алмашуны үзара эш итүнең бердәм стратегиясен булдыруны, башка кешене кабул итүне һәм аңлауны үз эченә алган элемтәләр урнаштыру һәм үстерүнең катлаулы һәм күппланлы процессы. Аралашу билге (знак) чараларын (һәм сөйләм, һәм невербаль) куллануны күздә тота.

Аралашу проблемасы социаль психологиянең төп проблемаларының берсе булып тора. Ул, социологларның, социаль

психологларның һәм мәгълүмат теориясе белгечләренең тикшеренү предметын тәшкил итеп, дисциплинара характерда була. Бер яктан, башлангыч төшенчәнең күп мәгънәле булуы аралашу проблемаларын тикшеренүне кыенлаштыра; икенче яктан, әлеге феноменны аңлау өчен өстәмә ресурслар бирә. Бүгенге тикшеренүләрнең иң актуаль юнәлешләреннән түбәндәгеләрне атарга була: техник чаралар (телефон, Интернет һ.б.) кулланып, коммуникатив йогынтыларны гамәлгә ашыру, невербаль аралашуны үзенчә аңлатуның читенлеге, коммуникатив компетентлыкның асылы. Шулай ук диалоглы, ягъни ышанулы аралашу проблемасы да актуаль. Белгечләрне профессиональ өлкәләрдә (идарә итү, маркетинг, сәяси җәмәгатьчелек белән элемтә һ.б.) нәтиҗәле аралашу технологияләре булдыру һәм кешенең манипуляцияләү объектына әверелү куркынычын бетерү проблемалары да кызыксындыра.

Бу параграфта сүз, мәгълүмат алмашу буларак, аралашу турында яки мәгълүмат алмашуның коммуникатив вазыйфасы турында барачак.

Аралашу, мәгълүмати ягы белән бергә, әле тагын интерактив һәм перцептив яклары белән дә үзенчәлекле. Хәзер сүз алар турында барачак.

КОММУНИКАЦИЯ ЯКИ АРАЛАШУ

Аралашуның коммуникатив ягы турында сөйләгәндә, барыннан да элек белемнәрне, күзаллау, идея, хисләрне һәм психологик эшчәнлекнең башка нәтиҗәләрен күздә тоталар.

Ләкин кешеләрнең аралашуында коммуникация бары тик мәгълүмати процесска гына кайтып калмый. Аралашуда мәгълүмат тапшырылып кына калмый, ул формалаша, төгәлләшә, үсә дә. Шунлыктан аралашуның коммуникатив ягын тасвирлаганда кешеләр арасында мәгълүмат алмашуның үзенчәлеген дә төгәл аңларга кирәк.

Беренчедән, аралашуны ниндидер тапшыру системасы белән мәгълүмат җибәрү һәм аны икенче якның кабул итүе генә итеп карарга ярамый. Мондый һәр очракта һәр икесе дә актив субъект булган ике индивид мөнәсәбәте барлыкка килә. Кешеләрнең бер-берсен мәгълүматлаштыруы уртак эшчәнлек урнаштыруны күздә тота. Бу — коммуникатив процесста катнашучы һәр кеше партнеры ягыннан да активлык көтә дигәнне аңлата. Аралашу процессында катнашучы башка як шулай ук субъект сыйфатында була, шунлыктан мәгълүмат тапшырганда аның теләкләрен, максатларын, омтылышларын исәпкә алырга кирәк (шул ук вакытта үзеңнең теләк, максат, омтылышларыңны да күз уңыннан ычкындырмыйча). Әмма бу

очракта тапшырылган мәгълүматка алмашка партнердан чыккан яңа мәгълүмат алыныр дип фаразларга кирәк. Шунлыктан коммуникатив процесста гади «мәгълүмат хәрәкәте» генә түгел, аның белән актив алмашу да бара. Белгечләр фикеренчә, кешеләрчә алмашуда төп «өстәмә» шунда: монда һәр кеше өчен мәгълүматның мәгънәсе зур роль уйный. Мәгълүмат шуның өчен әһәмият ала: кешеләр мәгънәләр белән алмашып кына калмый, ә бәлки бу вакытта гомуми мәгънә чыгарырга да онытмыйлар. Ә бу исә мәгълүмат кабул ителеп кенә калмаган, ә аңланган, фикерләнгән очракта гына мөмкин. Шунлыктан, һәр коммуникатив процесста эшчәнлек, аралашу һәм танып-белү — реаль бердәмлектә.

Икенчедән, кибернетика җайланмаларыннан аермалы буларак, кешеләр арасында мәгълүмат алмашуның характеры шуның белән билгеләнә: билгеләр системасы ярдәмендә партнерлар бер-берсенә йогынты ясарга мөмкиннәр. Процессның нәтиҗәлелеге нәкъ менә аралашу буенча партнерга ни дәрәҗәдә йогынты ясау белән үлчәнә. Бу билгеле бер мәгънәдә коммуникациядә катнашучылар арасында урнашкан мөнәсәбәтләр тибының үзгәрүен аңлата. «Саф» коммуникатив мәгълүмат процессларында, мәсәлән, мәгълүмат бер компьютердан икенчесенә тапшырылганда, моңа охшаш берни дә булмый.

Өченчедән, коммуникатив йогынты, мәгълүмат алмашу нәтиҗәсе буларак, бары тик мәгълүмат тапшыручы кеше (коммуникатор) һәм аны алучы кеше (реципиент) бердәм яки охшаш кодлаштыру (тапшыру) һәм декодлаштыру (кабул итү) системасына ия булганда гына мөмкин. Гадәти телдә бу кагыйдә «уртак тел табу мөһим» дигән сүзләр белән белдерелә. Бу аеруча шуның өчен мөһим: аралашуда катнашучылар коммуникатив процесста даими рәвештә урыннары белән алмашалар. Алар арасында һәртөрле мәгълүмат алмашу фәкать билгеләр һәм, иң мөһиме, аларга куелган мәгънәләр коммуникация процессында катнашучыларның барысына да билгеле булганда гына мөмкин. Бары тик мәгънәләрнең бердәм системасын кабул итү генә партнерларның бер-берсен аңлавы мөмкинлеге бирә. Бу хәлне тасвирлау өчен социаль психология лингвистикадан төркемнең барлык әгъзалары кабул итә торган мәгънәләрнең гомуми системасын белдерүче «тезаурус» атамасын куллана. Ләкин бөтен эш шунда: хәтта бер үк сүзләрнең мәгънәләрен белеп тә, кешеләр аларны бер үк төрле аңламаска мөмкин: моңа сәбәп социаль, сәяси, яшь үзенчәлекләре булырга мөмкин. Аралашу өчен бердәм лексик һәм синтаксик системалар гына түгел, ә аралашу халәтен бер үк төрле аңлау да кирәк. Ә бу исә коммуникацияне эшчәнлекнең кайбер гомуми системасына керткән очракта гына мөмкин.

Моны көнкүреш мисалында аңлатыйк. Хатын ирен ишек ачып каршылый һәм әйтә: «Мин бүген берничә электр лампочкасы сатып алдым»,— ди. Бу җөмлә турыдан-туры мәгънәдә генә түгел. Сатып алынган лампочкалар турындагы хәбәрдән тыш ир аңа аш бүлмәсендәге янган лампочкаларны алыштырырга кирәклеген дә аңларга тиеш. Яисә, ихтимал, гаиләгә лампочкалар запаска кирәк, хатын аларны берничә данә алган һәм хәзер иренең үзенең аннан алдагы хәлне белгәндә генә аңлап була.

Дүртенчедән, кешеләр коммуникациясе шартларында аралашуда бөтенләй көтелмәгән каршылыклар туарга мөмкин (алар турында сүз төп мәктәп курсында булды). Исегезгә төшерик: каршылыкларның психологик кына түгел, социаль, сәяси, дини, профессиональ дә булулары һәм коммуникация процессында кулланылучы шул ук сүзләрнең төрлечә куллануын китереп чыгаруы ихтимал. Мәгълүмат алмашуда каршылык дөньяны төрлечә аңлау, тою, дөньяга караш белән дә бәйле була. Табигый ки, коммуникация процессы каршылыклар булганда да эшләнә, чөнки хәтта хәрби дошманнар да сөйләшүләр алып баралар, ләкин бу вакытта аралашу шактый катлаулана.

Аралашудагы каршылыклар турыдан-туры аралашучыларның психологик үзенчәлекләре аркасында да туарга мөмкин. Мәсәлән, аралашуга партнерларның берсенең артык оялчанлыгы, икенчесенең ачылып китәргә теләмәве, өченчесенең моңа әзер булмавы комачаулый. Каршылыклар аралашучылар арасындагы аерым бер психологик мөнәсәбәтләр: бер-берсен өнәмәү, ышанып җитмәү һ.б. сәбәпле дә барлыкка килергә мөмкин.

Аралашу вакытында әлеге процесста катнашучылар арасында мәгълүмат әйләнеше бара. Кайбер очракларда мәгълүмат бер кешедән турыдан-туры икенчесенә тарала. Барыннан да бигрәк мондый мәгълүмат бары тик шәхси характерда гына була. Җәмгыятьтә мәгълүмат сигналлары күпчелек очракта ихтимал булган адресатка юнәлдерелә. Бу очракта сүз челтәрле коммуникатив процесс турында бара.

АРАЛАШУ ЧАРАЛАРЫ

Теләсә нинди мәгълүматны тапшыру бары тик билгеләр, тәгәлрәге — билгеләр системасы ярдәмендә генә була ала. Вербаль аралашу билге системасы сыйфатында кеше сөйләмен, табигый тавыш телен, ягъни ике: лексик һәм синтаксик принциптан торган фонетик билгеләр системасын куллана. Сөйләм коммуникациянең иң универсаль чарасы булып тора, чөнки аның ярдәмендә хәбәрнең мәгънәсе аз бозыла. Сөйләм

ярдәмендә мәгълүмат кодлаштырыла һәм кодтан чыгарыла: коммуникатор сөйләм барышында кодлаштыра, ә реципиент тыңлау барышында бу мәгълүматны декодлаштыра.

Хәбәрнең мәгънәсен тапшыру һәм кабул итү күзлегеннән караганда, К — Х — Р ның (коммуникатор — хәбәр — реципиент) гомуми схемасы асимметрик.

Коммуникатор өчен мәгълүматның мәгънәсе кодлаштыру (әйтү) процессыннан алда була. Ул нәрсәне булса да хәбәр итү алдыннан билгеле бер мәгълүматка ия була, ә аннары аны билгеләр системасына кертә. Тыңлаучы өчен алынган хәбәрнең мәгънәсе декодлаштыру белән бер үк вакытта ачыла. Тыңлаучының әйтелгәннәрнең мәгънәсен төгәл аңлавы коммуникаторга «коммуникатив рольләр» («сөйләүченеке» һәм «тыңлаучыныкы») алышынгач кына ачык була. Диалог яки диалог сөйләме «сөйләшүнең» үзенчәлекле төре буларак коммуникатив рольләрнең эзлекле алышынуыннан гыйбарәт; аның барышында сөйләм хәбәренең мәгънәсе ачыла, ягъни «мәгълүматны баету, үстерү» буларак билгеләнгән күренеш бара.

Сөйләм аралашуында мөмкин булган модельләренең берсе биш элементтан тора:

1) кем? (хәбәрне тапшыра) — коммуникатор;

2) нәрсә? (тапшырыла) — хәбәр;

3) ничек? (тапшыру тормышка ашырыла) — турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган;

4) кемгә? (хәбәр җибәрелгән) — адресат;

5) нинди нәтиҗә белән? (хәбәр итү булды) — нәтиҗәле яки нәтиҗәсез аралашу.

Гәрчә сөйләм аралашуның универсаль чарасы булса да, ул бары тик эшчәнлек системасына кертелгәндә генә мәгънәгә ия була, ә бу кертелү мәҗбүри төстә башка — сөйләм булмаган билгеләр системалары белән тулыландырыла. Сүз экспрессив реакцияләр белән генә түгел, кылган гамәлләрнең мәгънәсе белән дә тулыландырыла. Шулай итеп, әгәр без вербаль булмаган чараларга тиешле игътибар бирмәсәк, коммуникатив процесс тулы булмый.

ВЕРБАЛЬ БУЛМАГАН АРАЛАШУ

Вербаль булмаган аралашу чаралары арасында ишарәне (куллар белән ишарәләрне), мимиканы (битнең төрле элементлары хәрәкәтен), пантомиманы (поза, гәүдә торышын) — оптик-кинетик билгеләр системасын аерып күрсәтергә була.

Гәүдәнең төрле өлешләре хәрәкәтенең күпчелеге кешенең тәэсирле реакцияләрен чагылдыра, шунлыктан вербаль бул-

маган сигналларны аралашу халәтенә кертү аңа аерым тәэсирле төсмерләү бирә. Шул ук вакытта вербаль булмаган аралашу төсмерләре бер үк ишарәне кулланганда, мәсәлән, төрле милли мәдәниятләрдә бер үк мәгънәгә ия булмыйлар.

Баш иеп уңай яки тискәре мәгънәне белдергәндә кайчак рус белән болгар аралашканда килеп туган аңлашылмаучылыклар һәркемгә билгеле. Чөнки русның башын өстән аска таба июе ризалык билгесе булып кабул ителсә, болгар «сөйләме» өчен бу — кире кагу һәм киресенчә.

Паралингвистик система — тавышның сыйфаты, аның колачы, тоны — вербаль коммуникациягә билгеле «өстәмәләр» бирә. Әле тагын экстралингвистик система — сөйләмгә паузалар, башка кушылмалар, мәсәлән, ютәлләү, елау, көлү кертү — һәм, ниһаять, сөйләмнең үзенең темпы бар. Боларның бөтенесе «сөйләм яны» алымнары белән мәгънәле мәгълүматка өстәмә төс бирә.

Коммуникатив процессны оештыруның фәзасы һәм вакыты шулай ук аерым мәгънә системасы булып тора, коммуникатив хәлләр компонентлары буларак, мәгънәви йөккә ия. Мәсәлән, партнерларны йөзгә-йөз урнаштыру аралашу барлыкка килүгә ярдәм итә, шул ук вакытта арка яктан кычкыру да билгеле бер тискәре мәгънәгә ия була ала. Аралашуны оештыруның кайбер фәза формаларының коммуникатив процесс буенча ике партнер өчен дә, күп кешелек аудитория өчен дә өстенлеге экспериментта расланды.

Бу өлкәдәге кайбер тикшеренүләр коммуникатив хәлләрнең фәзалы һәм вакытлы характеристикаларының үзенчәлекле җыелмаларын өйрәнү белән бәйле. Әлеге күпмедер дәрәҗәдә ачык аерып алынган җыелмалар «хронотоплар» дигән исем алды.

Мәсәлән, «сырхауханә палатасы» хронотобы, «вагондагы юлдаш» хронотобы һ.б. сурәтләнгән. Аралашу халәтенең үзенчәлеге монда кайчак тәэмин итүнең көтелмәгән нәтиҗәләрен бирә. Мәсәлән, әгәр ул «вагондагы юлдаш» булса, беренче очраган кешегә карата һәрвакытта да аңлатып бетереп булмый торган үз серләрен чишеп ташлауны.

Шулай итеп, вербаль булмаган аралашу чараларына мөрәҗәгать итү, аларның коммуникатив процесста, һичшиксез, зур ярдәмче (ә кайчак — мөстәкыйль) роль уйнауларын күрсәтә. Вербаль йогынты ясауны көчәйтү яки киметү сәләтенә генә ия булмыйча, вербаль булмаган коммуникациянең барлык системалары коммуникатив процессның анда катнашучыларның

ниятләрен белдерү кебек әһәмиятле параметрларын ачуда да ярдәм итә. Коммуникациянең вербаль системасы белән бергә, бу системалар кешеләргә уртак эшчәнлек оештыру өчен кирәкле мәгълүмат алмашуны да тәэмин итәләр.

БҮГЕНГЕ ДӨНЬЯДА АРАЛАШУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Аралашу проблемасының мәгълүмати аспектлары социаль психологларны, социологларны, тел белгечләрен генә түгел, фантастларны һәм футурологларны, киләчәкне өйрәнүче, аның ихтимал булган сценарийларын сурәтләүче галимнәрне дә кызыктырды һәм кызыктыра. Соңгыларының барлык көткәннәре акланмаса да, шунысын танырга кирәк: алар аралашу өлкәсендә булачак үзгәрешләр һәм мәгълүмат алмашу турында беренчеләрдән булып уйландылар.

Практикада шунысы ачыкланды: формалашып килә торган мәгълүмати җәмгыять мәгълүматны туплау һәм эшкәртү мөмкинлекләренең киңәюе белән генә түгел, аралашуның яңа формалары белән дә характерлана. Мәгълүмати җәмгыятькә күчү шартларында мәгълүмат алмашу үзенчәлеген өйрәнү әле башлана гына, шулай да тикшеренүчеләрнең мәгълүматлары аралашу турындагы классик күзаллауларны үзгәртү мөмкинлеге бирә.

Әле компьютерлар күпләп таралганга кадәр үк кешеләр язышуны алыштырган, шәхси визитларны һәм очрашуларны киметкән техник чаралар (телефон, телеграф) ярдәмендә аралаша башладылар. Техника аралашканда мәгълүмат тапшыруны җиңеләйтә (мәгълүматны тапшыру вакыты кими, аның күләме арта, һәм аралашуда катнашучылар арасында ераклык кыскара). Күз алдыгызга китереп карагыз: хәбәрләшүчеләр арасында берничә мең километр булса, хат җибәрүче белән аны алучыны күпме вакыт аерып тора? Хәзер факс ярдәмендә язманы берничә минут эчендә төп нөсхәдә тапшырып кына түгел, Интернет челтәрендә онлайн режимында аралашып та була.

Заманча техника ярдәмендә аралашу даирәсе киңәюгә бәйле рәвештә аның ысулы, стиле, характеры гына үзгәреп калмый. Кешенең коммуникатив тәҗрибәсе структурасы да үзгәрә. Мәсәлән, яңа мәгълүмат технологияләре арасында коммуникация буенча партнер образын да, аның белән үзара эш итүне дә «өстәп төзү», конструкцияләү зарурлыгы коммуникациянең үзенчәлегенә әверелеп бара. Аралашу буенча виртуаль партнер күп яктан хәбәр ителә торган мәгълүматтан билгеле булганнарның да, аны турыдан-туры күрмичә, аның турында аралашуда катнашучы башка берәү өстәп уйлаганнарның да синтезы булып тора.

Глобаль мәгълүмат чараларында аралашу, бер яктан, катгый формалардан азат (челтәрдән файдаланучылар аралашу формасын һәм эчтәлеген үзләре сайлый). Әмма, икенче яктан, мәгълүмат алышуның ачыклыгы эмоциональ тулылык һәм кайчак социаль җаваплылык җитеп бетмәгән виртуаль коммуникатив процессның фрагментарлыгы белән бергә бара.

Галимнәр мәгълүмат ташкынының тыгызлыгы аны фикерләү һәм үзләштерү мөмкинлекләреннән күпкә артып китә дип исәпли. Мондый «мәгълүмат ташкыны»ның кеше психикасына тискәре йогынты ясавы мөмкин.

1992 — 1998 елга кадәрге чорда Россиядә мәгълүмат челтәреннән файдаланучыларда юмор, хобби һәм ялны үткәрү чыганаклары белән кызыксыну арту белән бер үк вакытта, фәнни мәгълүмат белән кызыксыну (күпчелек табигый-фәнни, аеруча программлы тәэмин итү белән) тотрыклы рәвештә артты.

Мәгълүматның зур күләмнәрдә тупланувы үзе үк инде аны субъектларның үзләренчә кабатлауларына зур таләпләр куя. Бүгенге коммуникация парадоксларының берсен кинорежиссер А.Кончаловский, образлы итеп: «Мәгълүмат күп булган саен, аның мәгънәсе аз»,— дип белдерде. Мәгълүмат бирү формаларының төрлелегенә аның мәгънәви тулылыгы һәрвакытта да туры килеп бетми.

Мәгълүматлаштыру чараларын глобальләштерү үзенчәлекле «дөньякүләм мәгълүмат тәртибе» кертә, аның асылын Көнбатыш, Төньяк Америка мәдәнияте стандартларын бөтен дөньяга тарату тәшкил итә. Шул ук вакытта реципиент (мәгълүматны кабул итүче) әлеге мәгълүматның эчтәлегенә аз йогынты ясый.

Төп төшенчәләр: мәгълүмат — алмашу буларак аралашу, мәгълүмати җәмгыятьтәге аралашу үзенчәлекләре.

Терминнар: коммуникация, вербаль булмаган аралашу.

Үзегезне тикшерегез

1. Аралашу коммуникациядән нәрсә белән аерыла? 2. Мәгълүмат алышу процессында сөйләм нинди роль уйный? 3. Аралашу процессында мәгълүматны төгәл аңлауга нәрсә комачаулый? 4. Аралашуның вербаль булмаган чаралары нәрсә ул? 5. Мәгълүмат дөньясында аралашу нәрсәсе белән аерылып тора?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. «Аралашу һәм коммуникация» дигән чагыштырма таблица төзегез. Шундый чагыштырудан телдән нәтиҗә ясагыз.

2. «Фикер бер, ә сүз күп» күнегүен башкарыгыз. «Тел ярдәмендә аралашу башка кешене аңлау мөмкинлеге бирә»,— дигән фикерне башка сүзләр белән тапшыруның мөмкин кадәр күбрәк вариантын тәкъдим итегез. Түбәндәге шартларны үтәргә тырышыгыз:

1) әйтелгәннең мәгънәсен бозмаска;

2) җөмлә шартында бирелгән бер генә сүз дә сезнең вариантларда кабатланмаска тиеш.

3. Түбәндәге раслау белән килешегез яки аны кире кагыгыз: «Сөйләмдә өч нәрсә мөһим: кем сөйли, ул ничек сөйли һәм нәрсә сөйли; монда соңгысының әһәмияте азрак» (Джон Морли, инглиз нәшире, биографы һәм сәясәтчесе).

4. «Минем танышларым — Интернеттан файдаланучылар» дигән темага мөстәкыйль рәвештә зур булмаган социологик тикшеренү үткәрегез; сезгә таныш бөтендөнья «үрмәкүч оясын» кулланучыларны классификацияләгәндә түбәндәге мәгълүматтан файдаланыгыз.

Гамәли тикшеренүләренең кайберләрендә: интернет-коммуникациянең шәхескә йогынтысы виртуаль аралашу тәҗрибәсе белән түгел, ә компьютерда турыдан-туры аралашу канәгатьләндергән шәхси максатларны аңлау үзенчәлеге белән бәйле, дип билгеләп үтелә. Интернеттан файдаланучыларны бу принцип нигезендә «хакерларга», «мавыгучыларга» һәм «прагматикларга» бүләргә була. «Прагматиклар» — челтәр белән сирәк, конкрет бурычка бәйле рәвештә кулланучылар; шәхесара коммуникация, актив катнашу, челтәр бергәлекләре белән кушылу алар өчен икенчел роль уйный. «Мавыгучылар» челтәрдән файдаланучылар яисә аның конкрет бергәлекләре белән тулаем кушылмый, ләкин аны тар прагматик максатларда да файдаланмый. «Хакерлар» исә Интернеттан файдаланучылар белән социаль категория буларак нык кушылалар.

5*. Соңгы вакытта вербаль булмаган аралашу турында күп китап чыкты. Алар ярдәмендә ишарәләрнең, күрсәтүләрнең, кайсы ишарәләрнең нинди мәгълүмат бирүен чагылдырган сүзлек төзегез.

Чыганак белән эшләгез

Хәзерге заман психологы Е.И.Роговның «Аралашу психологиясе» дигән китабыннан өзек белән танышыгыз.

Коммуникатив каршылыклар (киртәләр)

Аңлауга каршылык психологик һәм башка күп сәбәпләр аркасында туарга мөмкин. Ул мәгълүматны тапшыру процессындагы хаталар нәтиҗәсендә дә була ала. [...] Фонетик аңлап җиткермәү феномены коммуникаторның тәэсирсез, тиз сөйлә-

ве, ашыгуы яки паразит сүзләр күп кушылган сөйләме аркасында барлыкка килә. [...] Шулай ук аралашуда катнашучыларның төрле мәгънәдәге сүзләр кулланувы белән бәйле семантик киртәләр дә була. Әйтик, очучы яки танкист театрда «Экипаж бирегез!» дигән сүзләр ишетсә, моның аларда җиңелчә аптыраш тудыруы ихтимал, чөнки пьесада сүз карета турында бара, ә алар исә күз алдына машина белән эш итүчеләрне китерәләр. [...]

Ниһаять, аңламауның логик каршылыгы булу турында да әйтергә мөмкин. Ул сөйләүченең фикерләү логикасы тыңлаучы аңлар өчен йә артык катлаулы булганда, яисә аңа хас дәлилләү манерасына каршы килгәндә туа. Мәсәлән, баладан: «Таздагы кечкенә корабль ни өчен йөзә?» — дип сорасаң, аның: «Чөнки ул кызыл», яисә: «Чөнки ул минеке»,— дип җавап бирүе мөмкин. Бу очракта «бала логикасы» белән очрашабыз. Хатын-кызлар һәм ир-атлардагы психологик логика һ.б. турында да сөйләргә була.

Еш кына аңлау өчен каршылык тууга аралашучылар арасындагы социаль-мәдәни аермалар да сәбәп булырга мөмкин. Алар теге яки бу төшенчәләрне төрлечә аңлатуга китерүче социаль, сәяси, дини һәм профессиональ аермалар була ала. Социаль аермалар турында сөйләгәндә: «Ачның хәлен тук белми»,— дигән әйтемне искә төшерергә мөмкин. Сәяси аңламауны барыннан да яхшырак итеп Дәүләт Думасы күрсәтә: анда һәр закон озаклап төрле партия вәкилләре тарафыннан тикшерелә һәм кайчак кабул ителми дә кала. Ирландия, Төркия, Әфганстанда һ.б. бара торган дини сугышлар төрле дин тотучы кешеләрнең дә бер-берсе белән аралашуда кыенлыклар тоюы турында сөйли.

[...] Күз алдыгызга китерегез: әйтик, сез бер үк мәгълүматны дустыгыздан, әтиегездән яисә мәктәп директорыннан ишеттегез ди. Кайсы очракта сезгә тәкъдим ителгәнне тизрәк эшләр идегез? Психологлар сөйләүченең тыңлаучы алдындагы абруе зуррак булган саен, аралашу киртәсе шулкадәр азрак булуын әйтә. Абруй югарырак булган саен, тәкъдим ителгән мәгълүматны үзләштерү җиңелрәк. Кайбер очракларда мөнәсәбәт каршылыклары турында сөйлиләр. Сүз сөйләүчегә карата яратмау, ышанмау хисе барлыкка килү, бу хиснең ул тапшыра торган мәгълүматка да таралуы турында бара.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Текстта аралашудагы каршылыкларның нинди төрләре күрсәтелгән? 2. Аларның кайсылары күпчелек очракта — мәгълүматны тапшыру, ә кайсылары кабул итү белән бәйле? 3. Күрсәтелгән киртәләрнең кайсылары мәгълүмат алмашканда аңлашу өчен күбрәк хезмәт

итә дип уйлыйсыз? 4. Мөстәкыйль рәвештә коммуникацион киртәләрне үтәргә булышлык итүче аралашу кагыйдәләрен языгыз.

§ 32. Үзара аралашу — үзара хезмәттәшлек

Исегезгә төшерегез:

шәхесара мөнәсәбәтләр нәрсә ул? Шәхесара мөнәсәбәтләрнең нинди төрләре бар? Шәхесара мөнәсәбәтләрнең үзенчәлеген нәрсә тәшкил итә? Шәхесара үзара эш иткәндә эмоцияләр нинди роль уйный?

Аралашу мәгълүмат алмашу белән генә чикләнми. Берничә кеше бергәләп нинди дә булса эшчәнлек белән шөгыльләнгәндә нәрсә булуын күз алдына китерергә мөмкин. Мәсәлән, берничә укучыга бергәләп сыйныф бүлмәсен җыештырырга кушылган ди. Кемдер ялкаулана, кемдер идәнне юу өчен су алып килә, кемдер тузан сөртә, кемдер бүлмә гөлләрен карый. Бу очракта уртак эшчәнлек процессында катнашучылар арасындагы аралашу шәхесара үзара эш итү яисә интеракция (inter — үзара һәм action —эш итү) булып тора.

Фәндә шәхесара үзара тәэсир итүнең асылын төрлечә аңлатучы берничә теория яши. Мәсәлән, «алмашу» теориясе яклылар кешеләр бер-берсе белән үзара, ихтимал булган бүләкләрне һәм чыгымнарны үлчәп, үз тәҗрибәләре нигезендә тәэсир итәләр дип уйлыйлар. Бу вакытта бүләкләү — бары тик матди, ә чыгымнар физик яки ресурслы дип кенә уйланылмый. Икенче теория кешеләрнең бер-берсенә һәм әйләнә-тирә дөнья предметларына карата үзләрен тотышын кешеләр аларга бирә торган әһәмияткә бәйле рәвештә карый. Социаль үзара тәэсир итү хәлен актерлар үзләре турында уңай тәэсир тудырырга һәм шуны сакларга тырышкан драма театры кебегрәк итеп караучы теория дә бар. Психоанализ теориясе буенча, шәхесара үзара тәэсир итүгә иртә балалык чорында үзләштерелгән күзаллаулар һәм яшәүнең шул чагында кичергән конфликтлар көчле йогынты ясый.

ҮЗАРА ТӘЭСИР ИТҮНЕҢ ИКЕ ЯГЫ

Үзара тәэсир итү процессы яки аралашуның интерактив ягы ике — тышкы һәм эчке компонентны колачлый. Тышкы компонент конкрет хәлләрдә тәэсир итүнең үзенчәлекле регламентланган тәртибе булып тора. Бу очракта аралашу этикасы турында да сөйләргә мөмкин.

Икенче компонент үзара тәэсир итүнең психологик ягына кагыла. Эш шунда: үзара тәэсир итешеп, кешеләр үзләренең психологик тотрыклылыгын саклау белән бәйле кайбер ихтыяҗларын канәгатьләндерәләр. Бары тик бергәләп һәм башка кешеләр ярдәмендә генә канәгатьләндерелә алырлык ихтыяҗлар бар. Бу ихтыяҗлар еш кына аңлап бетерелми, чөнки алар бик тә табигый булып тоела. Шулай да аларны канәгатьләндерү психик энергия тотуны таләп итә.

Андый ихтыяҗлар исәбенә, мәсәлән, үзеңнең социаль хәлеңне һәм статусыңны билгеләүгә булган ихтыяҗ керә. Кешеләр бергә җыелгач ук, алар төрле ысуллар белән үз статусларын һәм теге яки бу төркемгә керүләрен билгелиләр. Сезгә, мөгаен, теләсә нинди компаниядә кешеләрнең бер-берсенә карата билгеле бер образда урнашуларын, мәнфәгатьләр һәм позицияләр уртаклыгын карашлары, ишарәләре белән чагылдырылуларын, үзләренең бер-берсенә якынлыгын яки ераклыгын билгеләүләрен күзәтергә туры килгәндер. Г.-Х.Андерсенның балалар өчен язылган шыксыз үрдәк баласы турындагы акыллы экиятен исегезгә төшерегез. Беренче тапкыр кошлар келәтенә килеп эләккәч, үрдәк балалары шундук аягына кызыл чүпрәк бәйләнгән үрдәкнең монда башлык булуын күрәләр. Барысы да нәкъ менә шуңа ялагайланалар. Нәкъ менә шул, бәбкәләрнең артык зур һәм килбәтсез булуын күреп, моны үзгәртергә куша. Үзең кебекләр рәтенә керүне билгеләү ихтыяҗы нәкъ менә үзара тәэсир итешүдә гамәлгә ашырыла.

Үзара тәэсир итү белән бәйле икенче ихтыяҗ — яхшы мөнәсәбәтләр булдыру ихтыяҗы. Андый мөнәсәбәтләр урнашмаса, кеше психологик уңайсызлык тоя. Менә шуңа күрә үзара тәэсир итү кешенең башка кешеләргә карата игелекле ниятләре булып хезмәт итүче ритуаль эшләр сериясе итеп карала.

Аралашу процессында кешеләр үзара тәэсир итүнең күп төрләренә керәләр.

Тикшеренүчеләрнең берсе фикеренчә, үзара тәэсир итү партнер ягыннан җавап реакциясе тудыруга юнәлдерелгән эшләрне системалы, тотрыклы тормышка ашырудан гыйбарәт; бу вакытта тудырылган реакция, үз чиратында, тәэсир итүченең реакциясен китереп чыгара.

Үзара тәэсир итүне, бер яктан, физик аралашудан, фәзада бергәләп күчүдән, бергәләп төркем яки күпләгән кеше белән эш итүдән һәм, икенче яктан, вербаль яки вербаль булмаган формада чагылдырылган рухи аралашудан барлыкка килүче процесс дип күзалларга була.

Шуның белән бергә, аралашу вакытындагы уртак эшчәнлек кешеләр арасындагы мәгълүмати, ә билгеле бер мәгънәдә — рухи аралашу дәрәҗәсенә турыдан-туры бәйле. Кешеләр бер-

берсен аңласа, бер кешедәй бердәм булып эшләсә, эшләр гөрләп бара, дип юкка гына әйтмиләр бит.

Кешеләрнең аралашу процессында үзара тәэсир итүнең күптөрле чагылышларын *кооперация* яки *көндәшлек* итеп күзалларга була. Беренче очракта аралашу процессында катнашучыларның бердәм көчен җайга салу (бу көчләрне тәртипкә китерү, комбинацияләү) бара. Кооперациясез үзара уңышлы тәэсир итү булмый. Чынлап та, һәрберсе дәшмәгән, активлык күрсәтмәгән партнерларның тулы кыйммәтле аралашуын күз алдына китерү мөмкин түгел. Бер кул белән алкышлау мөмкин булмаган кебек, реаль индивидларның аралашуында һәр ике якның эш итүе кирәк.

Сез, ихтимал, икътисадтагы көндәшлек төшенчәсе белән таныштыр. Икътисадтагы көндәшлектән аермалы буларак, аралашудагы көндәшлек уртак эшчәнлекне какшата, үзара тәэсир итү өчен билгеле бер киртәләр тудыра. Үзара тәэсир итү тибы буларак, көндәшлек үзен иң чик формада — үзара низагта (конфликтта) бигрәк тә ачык күрсәтә. Үзара низаг турында тулырак сүз алдарак булачак. Әмма сез үзегез дә кешеләр берберсе белән талашкан очракта аралашу кыенлашкан яки бөтенләй беткән очракларны исегезгә җиңел төшерә аласыз.

Аралашуны үзара уңышлы тәэсир итү буларак күрсәтү өчен психологик ярашуның нәрсә икәнен карап үтәргә кирәк.

АРАЛАШУ ПРОЦЕССЫНДА ҮЗАРА ТӘЭСИР ИТҮ СТРАТЕГИЯСЕ

Уртак эшчәнлек вакытында төрле кешеләр үзләрен төрлечә тоталар. Берәүләр чагыштырмача ялгызлары уңышлы эшли — аларга башкаларның булуы комачаулый, аралашу эштән аера. Икенчеләре үз эшләрен бары тик бергә хезмәт иткәндә генә яхшы башкаралар. Кайберәүләр нәтиҗәле хезмәттәшлеккә фәкать тирә-юньдәгеләрне буйсындырып кына сәләтле — аралашу бу очракта диктат урнаштыруга булыша. Аралашу процессында башка стратегияләр дә бар. Әлеге стратегияләр аралашу буенча партнерларның психологик ярашу-туры килүенә яки башка эшчәнлеккә бәйле. «Психологик ярашу» дигәндә коммуникатив партнерларның бер-берсен тулыландыру аңлана. Психологик ярашкан партнерлар аралашканда киеренкелек йә бөтенләй бетә, яисә ул чагыштырмача җиңелчә үткәрелә.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, җәмгыятьтә югары ихтыяҗга ия булган партнерлар ныграк яраша. Бу сыйфат үзара тәэсир итүнең беренче этабында, үзара контакт башланганда бигрәк тә мөһим.

Шунысы кызык: психологик ярашу шәхесләрнең теге яки бу сыйфатлары охшаш вакытта да (аралашырга яратучы аралашырга яратучы белән, хисчән кеше хисчән кеше белән), алар капма-каршы булганда да (көчле — көчсез) барлыкка килә ала.

Психологлар кешеләрнең башка кешеләр белән үзара тәэсир итешүе вакытында ныграк беленүче һәм аралашуның нәтиҗәлелегенә йогынты ясаучы социаль сыйфатларны ачты. Аларның кайберләрен карап үтик.

Аралашуда катнашучылар *доминантлы* һәм *доминантсыз әңгәмәдәш* буларак карала ала. Доминантлы әңгәмәдәш, партнерга мөрәҗәгать итү зарурлыгы туса, моның урынлымы-түгелме, комачауламыймы, аны аңлармы икәнлеге турында артык уйлап тормый. Үзара мөгамәләгә керергәме-юкмы, мөрәҗәгать итүгә яки үтенечкә җавап бирергәме-юкмы икәнен нәкъ менә үзе хәл итәргә тиеш дип уйлый ул. Гадәттә андый кеше үҗәт, катгый була. Ул әңгәмәдәшен сүзеннән җиңел бүлә, әмма үзен бүлсәләр, моны авыр кичерә. Әгәр нәрсәне дә булса аңлата башласа, моны «чәйнәп каптыра». Әгәр тыңлый икән, һичшиксез, ачыклаучы сораулар бирә. Бер сүз белән әйткәндә, аралашканда ул — лидер. Мондый аралашу һәрвакытта да күңелгә ятышлы булмый. Андый әңгәмәдәш белән тулы кыйммәтле аралашу өчен үзеңне тыныч һәм ышанычлы тотарга кирәк. Ләкин аны бүләргә яки аның бу гадәтеннән көләргә, нәрсә дә булса әйтергә ярамый. Шуны истә тотарга кирәк, акыллы доминант үзара тәэсир итү буенча шактый кыйммәтле партнер: ул үзенә җаваплылык ала белә. Тугрылыклары һәм киң күңеллелекләре белән аерылып торган андый партнерлар еш кына үз мохитләрендә «сөйкемле сөяк»ләргә әверелә.

Әле тасвирланган партнерга капма-каршы булган әңгәмәдәш күбрәк очракта оялчан, әңгәмәдәшенең көченең тышкы билгеләренә сизгер, кыюсыз. Аның белән үзара мөгамәлә урнашсын өчен шунысын истә тотарга кирәк: иң яхшысы — аны күбрәк мактау, дәртләндерү, бүләкләү. Доминантсыз әңгәмәдәшнең җаваплылыкны башка кешегә калдырырга тырышуын исәпкә алып, аңа «карар кабул итәргә ул үзе дә булдыра ала» дигәнне сиздерү уңышлы булачак.

Аралашуда икенче капма-каршы пар — *мобиль* һәм *ригид әңгәмәдәшләр.* Беренчеләре, гәрчә игътибарларын җиңел генә башка нәрсәгә юнәлдерсәләр дә, башка шөгыльләреннән бик тиз аралашуга күчәләр. Андый әңгәмәдәшнең сөйләме тиз, хәтта ашыгулы, мимикасы үзгәрүчән. Сөйләшкәндә ул еш кына бер темадан икенчесенә күчә. Әгәр андый әңгәмәдәш белән нинди дә булса проблема хәл итәргә кирәк булса, аның башына дистәләгән фараз килә, алар җиңел генә алышынып тора. Аңлашыла ки, мондый партнер белән уңышлы аралашу өчен

аңа уртак эшнең сайланган стратегиясенә туплану өчен ярдәм итү мөһим.

Ригид әңгәмәдәш — бөтенләй башка нәрсә. Әңгәмәгә ул шундук кушылмый, үз гамәлләрен алдан уйлау, план төзү өчен аңа вакыт кирәк. Ул, авыр маховик кебек, тизлекне әкренләп ала башлый, ә инде кызып киткәч, ныклылык күрсәтә. Гадәттә ул — идеаль тыңлаучы, уйлап сөйли, төгәлрәк сүзләр табарга тырыша, үзен бүлдергәнне яратмый. Үпкәләсә, тиз генә тынычланмый. Түземсез кешегә андый партнер белән аралашу шактый ялыктыргыч булып тоела. Ләкин андый кешенең үзенчәлекләрен белсәң, аларны уңышлы файдаланырга була, бары тик сез килешкән нәрсә турында тагын бер тапкыр кабатларга, ярсымаска һәм, партнер үзе өчен иң мөһимен ачыкламыйча торып, башланган сөйләшүне тәмамларга ашыкмаска гына кирәк.

Экстравертлар һәм *интровертлар* (лат. extra — тышта, intro — эчтә, versio — әйләндерергә, борырга) шулай ук үзара аралашканда тәэсир итүдә бер-берсеннән аерылалар. Экстравертлар әңгәмәгә шактый һәвәс. Сөйләшү мөмкинлеге булмаса, ул күңелсезләнә. Аңа теләсә нинди партнер кирәк; ул кешеләр бер-берсен һич тоткарлыксыз аңлап алалар дип ышана. Кайчак аның дустанәлеге җиңелчә, бик үк ныклы түгел. Игътибарны җәлеп итү өчен ул экстравагант гамәлләргә, сүз әйтүләргә, тышкы чагылуларга (кием өлешләре, чәче һ.б.) сәләтле. Ешрак мондый кеше белән уртак эшчәнлек җиңел, иркен бара, ул үпкәләүне белми, үч тотмый.

Интроверт, киресенчә, тышкы бәйләнешләргә исе китми. Аңа еш кына үзен аңламаслар кебек тоела (аны аңлау чынлап та кыен, чөнки ул үзе белән эчтән сөйләшә кебек). Күпләгән интровертлар башкаларга сәер булып тоела. Аңа юлны кешеләрдән сораганга караганда шәһәр планын өйрәнү җиңелрәк.

Әлбәттә, аралашу буенча партнерлар, үзара тәэсир иткәндә, еш кына әлеге идеаль типлар арасындагы ниндидер уртаклыкны гәүдәләндерәләр, аларда тегеләренең дә, боларының да сыйфатлары була. Шулай да, аралашу үзара уңышлы тәэсир итү булып узсын өчен, аралашуда катнашучыларның психологик үзенчәлекләрен истә тотарга, бер-береңне аңларга тырышырга, үзеңне икенче як урынында итеп тоярга тырышырга кирәк.

ЯШҮСМЕР ВАКЫТТА АРАЛАШУ

Аралашуга ихтыяҗ яшүсмер вакытта аеруча нык сизелә. Нәкъ менә шул яшьтә ата-ана, укытучылар, гомумән, үзеннән өлкәннәр белән аралашудан үзенең яшьтәшләре, үзенә тиңнәр белән аралашуга күчү бара. Андый ихтыяҗ иртәрәк башлана

һәм яшь арткан саен көчәя. Үсмерләрнең үз-үзләрен тотышы үзенең асылы буенча коллектив-төркемгә карый.

Яшьтәшләре белән интерактив аралашу яшүсмер өчен ник шулай бик мөһим соң? Беренчедән, бу — үсмерләргә һәм яшүсмерләргә өлкәннәр бирми торган кирәкле күпләгән мәгълүматлар бирүче бик тә мөһим үзенчәлекле канал.

Икенчедән, яшьтәшләре белән уртак эшчәнлектә социаль үзара тәэсир итү күнекмәләре, коллектив тәртипкә буйсыну, шул ук вакытта үз хокукларыңны яклау, шәхси мәнфәгатьләреңне иҗтимагый мәнфәгатьләр белән янәшә кую осталыгы барлыкка килә. Үзара мөнәсәбәтләр тигезлеккә корылган, статусны яулап алырга һәм сакларга кирәк булган яшьтәшләр җәмгыятеннән тыш бала үзендә өлкән кешегә кирәк булган коммуникатив сыйфатларны булдыра алмый. Төркемдә үзара мөнәсәбәтләрдә ата-ана белән мөнәсәбәтләрдә булмаган ярышучанлык шулай ук кыйммәтле тормыш мәктәбе булып тора. Яшьтәшләр белән аралашканда даими рәвештә үзеңнең ягымлылыгыңны, төркемгә кирәклегеңне исбат итеп торырга кирәк.

Өченчедән, бу — эмоциональ бәйләнешнең үзенчәлекле бер төре. Төркемдә булуны, бергәлекне, иптәшләрнең үзара ярдәмен тою-аңлау яшүсмергә бик тә мөһим эмоциональ иминлек һәм тотрыклылык хисе бирә. Тиңдәшләреңнең, иптәшләреңнең хөрмәтен һәм мөнәсәбәтен яулый алдыңмы — бу яшьтә үзеңне хөрмәт итү өчен хәлиткеч әһәмияткә ия булган сорау бу.

Үсмер һәм яшүсмер вакытта аралашу ике ихтыяҗның: аерымлашуның һәм нинди дә булса төркемгә яки бергәлеккә керү, анда булу ихтыяҗының каршылыклы кушылуы нигезендә корыла. Аерымлану барыннан да бигрәк өлкәннәр контроленнән котылырга тырышуда чагыла. Ләкин бу хәл яшьтәшләр белән мөнәсәбәтләрдә дә булырга мөмкин.

Тикшеренүчеләр үсмер чактан яшүсмерлеккә күчкәндә «ялгызлык» һәм «аралашу» кебек төшенчәләрнең эчтәлекләре турында күзаллаулар үзгәрә дип билгеләп үтәләр. Үсмер чактан яшүсмерлеккә таба ялгызлык турында уңай фикерләүләр арта, ә тискәреләре кими икән. Социаль ихтыяҗ гына түгел, ә ирекенлек, территориаль автономия, үзеңнең шәхси киңлегеңнең кагылмаслыгы, үз бүлмәңне булдырырга омтылу ихтыяҗлары да арта. Яшүсмер мөстәкыйльрәк һәм максатка юнәлгәнрәк булган саен, аның ялгызы булу ихтыяҗы һәм сәләте шулкадәр көчәя. Шагыйрь раслаганча, үз күңеле тынлыгында гына кеше үз яшәешенең тирән мәгънәсен аңлый ала.

Тыныч, уңайлы ялгызлыктан газаплы һәм киеренке ялгызлыкны (юксыну, рухи һәм күңел ялгызлыгының субъектив хәле, сине аңламаулары, аралашуга, кешеләр белән аралашуга булган канәгатьләндерелмәгән ихтыяҗ хисе) аерырга кирәк.

Сорап белешүләр күрсәткәнчә, үсмерләр һәм яшүсмерләр үзләрен ялгыз һәм аңланмаган итеп өлкәннәргә караганда ешрак тоялар. Яшьләр газеталары һәм радиостанцияләре бу темага күпләгән хат алалар: «Минем телефоным бар, ләкин ул гел дәшми, ә минем таныш тавыш ишетәсем, үземнең кемгә булса да кирәклегемне беләсем килә...»

Шәхеснең ныгып урнашуында яшь кыенлыклары белән бәйле ялгызлык һәм башкаларга кирәкмәгәнлек хисе яшүсмерләрдә яшьтәшләре белән аралашуга булган тыелгысыз теләк тудыра, ул алар арасында өлкәннәр бирә алмаган хисчән җылылык, ялгызлыктан качу һәм үзеңнең кирәклегеңне тану табарга өметләнә.

Аралашуга булган киеренке ихтыяҗны кайбер тикшеренүчеләр хәтта яшүсмерләрнең төп эшчәнлекләре дип исәплиләр. Аралашуга булган нык ихтыяҗ күпләрдә җиңеп булмаслык тойгыга әверелә: алар үзләренең, үзләренеке булмаса, нинди дә булса башка компаниясез бер көн түгел, бер генә сәгать тә түзә алмыйлар. Мондый ихтыяҗ малайларда аеруча көчле.

Социаль үз-үзеңне тотуның тышкы чагылышлары охшаш булу белән бергә, яшүсмерләрнең төркемдә булу ихтыяҗы артында ятучы тирән сәбәпләр индивидуаль һәм күптөрле. Берәүләр яшьтәшләре җәмгыятендә үзен хөрмәт итү яклау, үзенең кешелек кыйммәтләрен тану эзли. Икенчеләргә төркем белән эмоциональ бергә булу, кушылу мөһим. Өченчеләре аннан җитмәгән мәгълүмат һәм коммуникатив күнекмәләр ала. Дүртенчеләре хакимлек итү, башкалар өстеннән командалык итү ихтыяҗын канәгатьләндерә. Күпчелек өлештә бу сәбәпләр бергә кушыла һәм аңланмый. Төркемнәр турында тулырак итеп алдарак сөйләнеләчәк.

Өлкәннәрдән үзенең бәйсезлеген ярсып яклап, яшүсмерләр еш кына үз төркемнәре һәм аның лидерлары фикерләренә тәнкыйть күзлегеннән карамыйлар. Ныгып җитмәгән «Мин» көчле «Без»гә мохтаҗ, анысы, үз чиратында, ниндидер «Алар»га капма-каршы буларак раслана. Өстәвенә боларның барысы да «тупас һәм күренеп торырлык» булырга тиеш.

«Башкалар кебек булырга» көчле теләк (ә «башкалар» ул — фәкать «безнекеләр» генә) өс киеменә дә, эстетик зәвыкка да, үз-үзеңне тоту стиленә дә кагыла. Мондый каршылык, индивидуальлек бертөрлелек аша расланганда, яшүсмерләрне борчырга мөмкин.

Шуңа да карамастан, бу бертөрлелек нык яклана, кем дә булса аңа каршы килсә, аны авыр көрәш көтә. Бергәлек күпме гадирәк булса, ул индивидуаль төрлелеккә, башкача фикер йөртүгә һәм гомумән охшашмаулыкка шулкадәр түзеп тора алмаучанрак. Яшүсмерләрнең һәм яшь егетләрнең иң киң

таралган коммуникатив читенлеге — оялчанлык. Аны яшь егетләр аеруча авыр кичерә, чөнки оялу «ирләргә хас булмаган» сыйфат санала. Үзләренең коммуникатив кыенлыкларын җиңеләйтү өчен яшүсмерләр һәм яшь егетләр төрле үзенчәлекле хәйләләр табалар.

Беренчедән, һәрвакыт үзләре турында борчылып һәм, үзләренең бу борчылуларын башкалар уртаклаша дип уйлап, алар гадәттә ниндидер күзалланган аудиториягә исәп тотып эш итәләр. Икенчедән, үзләренең бердәнберлекләрен һәм үзенчәлекләрен арттырып күрсәтеп, яшүсмерләр еш кына үзләренә «шәхси дөнья», уйлап чыгарылган биография (ә аны саклау өчен даими тырышлык кирәк) булдыралар.

Яшүсмерләрнең һәм яшь егетләрнең аралашуы еш кына киеренке, гайре табигый, ике планлы була. Бу хәтта көнкүреш хәлләрендә дә чагыла. Мәсәлән, телефоннан сөйләшү өлкән сыйныф укучысы өчен гади мәгълүмат алмашу гына түгел, ә үзен раслау ысулы да; шунлыктан ничә тапкыр шылтырау, кемнең кемгә беренче булып шылтыратуы һ.б. бик мөһим. Үзләрендәге ышанып бетмәүне җиңү өчен, яшүсмерләр әңгәмәдәшен ничек итеп «начар күрсәтү», «кисеп ташлау» техникасын махсус камилләштерәләр, аны үзләренә карата бернинди үчләре булмаган, моның өчен сәбәп бирмәгән кешеләрдә сынап карыйлар.

Үзенең «шәхси миф»ын якларга мәҗбүр булып, яшүсмер яки яшь егет еш кына үзе дә буталып кала һәм беренче карашка сәбәбе булмаган ялган гамәл яки сәбәпсез мәрхәмәтсезлек кыла.

ЯШҮСМЕРЛӘР АРАЛАШУЫНЫҢ ФОРМАЛАРЫ

Яшүсмерләр аралашуына интим-шәхси, стихияле-төркемле һәм социаль аралашу хас.

Саналган аралашу формаларының беренчесе шәхси симпатиягә, ияләшүгә, мәнфәгатьләр, карашлар, кыйммәтләр якынлыгына нигезләнгән («мин» һәм «син» формуласы буенча) үзара тәэсир итүне күздә тота. Нәкъ менә яшүсмер вакытта кешеләр рухи яктан якын, аңлый белә, кирәк вакытта яклый, ярдәмгә килә ала торган кешегә актив тартылалар. Дуслык, якынлык, ярату — шәхесара үзара тәэсир итүнең барлык бу төрләре яшүсмерлек вакытында һичшиксез кыйммәтле булып торалар; алар булмаса, бу ялгызлык тирән кичерешләрнең сәбәбе итеп кабул ителә.

Стихияле-төркемле аралашу гадәттә «мин һәм очраклы алар» формуласы буенча бара. Ул ешрак очракта башкаларга җиңел генә алыштыру мөмкин булган танышлар белән аралашу характерында була. Аралашуның бу формасы вакытында үзара тәэсир итүнең эчтәлегенә килгәндә исә, ул ялны үткәрүдән,

мәҗбүри булмаган очрашулардан («тусовка»), дискотекаларда, кинода булудан, урамда «трай тибеп» йөрүдән, чынлыкта исә вакытны урамда яисә ишегалдында бушка үткәрүдән гыйбарәт. Мондый формада аралашу күп кенә өлкәннәргә охшамаса да, яшьләргә ул канәгатьлек китерә һәм еш кына интим-шәхси аралашуны алыштыра. Шулай да социологлар, яшь кешеләр арасында стихияле-төркемле аралашу өстенлек итсә дә, шәхси нигездә тыгызрак аралашуга тартылу көчле, дип билгеләп үтәләр. Һичьюгы, сорап белешү вакытында стихияле-төркемле аралашуның мәҗбүри булмаган характерыннан һәм ачык максаты булмаудан канәгатьсезлек ачыклана.

Үсә барган саен, социаль юнәлгән аралашуга («мин һәм бергәлек») керә барыла. Аралашуның бу формасы шәхескә тагын да киңрәк иҗтимагый өлкәләргә чыгу мөмкинлеге бирүче социаль әһәмиятле эшләр башкаруга нигезләнә. Андый аралашуның мисалы булып кеше чынлап та мөстәкыйль һәм үзкыйммәтле шәхес буларак ачылырга мөмкин булган уңай социаль эшчәнлек хезмәт итә ала. Психологлар һәм социологлар тикшеренүләре социаль юнәлгән аралашуда яшь кешеләр өчен мөмкинлекләр җитмәвен, моның исә шәхеснең тулы кыйммәтле формалашуы өчен күп җитешсезлекләре һәм тискәре нәтиҗәләре булган стихияле-төркемле аралашуга китерүен күрсәтә. Яшь кешенең хәлне ачыклаучы типик фикерен китерик: «... Ишегалдыннан һәм танцылардан тыш вакытны үткәрер урын юк. Мин күп, бик күп дусларым булуын телим, ләкин чын дусларны табу бик кыен. Минем классташларым, зурлар кебек булырга теләп, алтынчы сыйныфта ук тарта, аннары эчкәли башладылар. Күңелсез, кайчак гайрәт чигәрлек; тик тирә-якта барысы да шундый». Бу сүзләрдә мондый хәлдән күңел кайту да, нәрсәне булса да үзгәртергә теләмәү дә, ихтимал, моның өчен мөмкинлекләр булмау да сизелә.

Кызганыч ки, бүгенге җәмгыять, үзенең аралашу өлкәсендәге хәл ителмәгән социаль каршылыклары һәм объектив проблемалары белән, тулы кыйммәтле аралашу һәм үзара тәэсир итү өчен һәрвакытта да уңай шартлар тудыра алмый.

Төп төшенчәләр: шәхесара үзара тәэсир итү буларак аралашу; кооперация, көндәшлек, яшүсмер вакытта аралашу.

Терминнар: интеракция, доминат әңгәмәдәш, доминант булмаган әңгәмәдәш, экстраверт, интроверт.

Үзегезне тикшерегез

1. Аралашуның интерактив вазыйфасы нидән гыйбарәт? 2. Аралашуда кооперациянең асылын тасвирлагыз. 3. Аралашуда көндәшлек нәрсәсе белән куркыныч? 4. Аралашуда ке-

шенең нинди сыйфатлары үзара тәэсир итүгә булыша, ниндиләре комачаулый? 5. Яшүсмер вакытта аралашуның үзенчәлекләре нидән гыйбарәт?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Түбәндәгеләр керә торган төркемнәр өчен интерактив аралашуны оештырырга ярдәм итәчәк берничә киңәш тәкъдим итегез:

— сәламәтлек турында сөйләшүне җене сөйми торган артык аралашучы кыз;

— күптән түгел авыр җәрәхәт алган оялчан, тартынучан спортчы;

— тәҗрибәле, шул ук вакытта доминантлы (ата-анасының берсенең көчле сыйфатларын алган. — *Тәрҗ.*) массаж ясаучы;

— рус телен начар белүче, практика бик тә кирәк Көнчыгыш медицинасы белгече.

Төркемнәргә бүленеп (биш кешедән артык түгел), үз эшегезнең нәтиҗәләрен тикшерегез. Төркемдә сөйләшү-бәхәс үткәргәч, аның нәтиҗәләрен сыйныфта тикшерегез.

2. Аралашуның интерактив ягы карашыннан чыгып, А.П.Чеховның «Сагыш» хикәясендә сурәтләнгән түбәндәге хәлне анализлагыз. Аралашуга нинди факторларның комачаулавын, кайсыларының булышуын билгеләгез. Үзара тәэсир итү булганмы? Җавабыгызны дәлилләгез.

Йөк ташучы Ион Потаповичның улы үлә. Ул тирән хәсрәт эчендә, ә сөйләшер, эч серләрен уртаклашыр кеше юк. Бу хакта җайдакларга сөйләсәң генә инде... Ләкин аларны Ион сөйләгәннәр кызыксындырмый. Шулай бер көн үтә. «Ионның күз карашы урамның ике ягыннан баручы кешеләргә борчылып һәм интегеп юнәлә: меңнәрчә кеше арасында аны тыңларга теләүче бер генә кеше дә табылмасмы икән?» Табылмый. Һәм төн уртасында атын карарга дип торып, карт аның белән сөйләшә башлый:

«Менә шулай, туганкай, биякәем... Юк инде Кузьма Ионыч... Озак яшәргә кушкан идем дә... Үлде дә китте... Хәзер инде, әйтик, синең колының бар, ә син ул колынның әнисе. Һәм кинәт, әйтик, шул колынкай озак яшәргә боера... Кызганыч бит...

Бахбай ашый, тыңлый һәм үз хуҗасының кулына сулый... Ион мавыгып китә һәм аңа барысын да сөйли...»

3*. Түбәндәге күнегүне эшләгез.

Күз алдыгызга китерегез: сезнең йортны кар көрте басып китте ди. Ял көннәрендә беркем белән дә аралашып булмаячак, ярдәм дүшәмбедә генә киләчәк. Сез ялгыз, алга планлаштырылган бер эшегез дә юк. Бу көннәрне ничек файдалы итеп

үткәрүегез турында уйлагыз. Сезнең телевизорыгыз да, радиогыз, телефоныгыз да юк, аның каравы җитәрлек күләмдә ашарыгызга, китаплар, кәгазь, ручкагыз һәм барлык көнкүреш уңайлыкларыгыз бар.

Үз вакытыгызны үткәрү планын төзегез. Анда үзара тәэсир итүгә нинди урын бireләчәк? Әлеге очракта үзара тәэсир итү буенча кем партнер буларак карала ала?

Чыганак белән эшләгез

А.Батаршев китабыннан өзек укыгыз.

Уртак эшчәнлектә үзара тәэсир итү

Аралашуны кешеләрнең үзара тәэсир итешүе күзлегеннән караганда, аралашуның максатын һәрвакыт игътибар үзәгендә тотарга кирәк. Андый максат кешеләрнең уртак эшчәнлеге ихтыяҗын канәгатьләндерү була. Андый аралашуның максаты — башка кешеләрнең максатын, үз-үзләрен тотышын һәм эшчәнлеген үзгәртү. Аралашу монда шәхесара үзара тәэсир итү, ягъни кешеләрнең аларның уртак эшчәнлекләре вакытында барлыкка килгән элемтәләре һәм үзара тәэсир итүләренең җыелмасы булып тора. Мондый уртак эшчәнлек социаль нормалар һәм җәмгыятьтә кабул ителгән үзеңне тоту үрнәкләре нигезендәге социаль контроль шартларында бара. Кешеләрнең уртак эшчәнлектәге үзара тәэсир итүе һәм үзара мөнәсәбәтләре шул нигездә регламентлана.

Шул рәвешле, аралашуның интерактив ягы мәгълүматлар алмашуда гына түгел, ә кешеләрнең алар өчен уртак булган кайбер эшчәнлекне гамәлгә ашыру тырышлыкларында да чагыла.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Автор фикеренчә, интерактив үзара тәэсир итү буларак аралашуның максаты нидән гыйбарәт? 2. Автор шәхесара үзара тәэсир итүнең нинди билгеләмәсен бирә? 3. «Мондый уртак эшчәнлек социаль нормалар һәм җәмгыятьтә кабул ителгән үзеңне тоту үрнәкләре нигезендәге социаль контроль шартларында бара» дигәнне ничек аңларга? 4. Мәгълүмат алмашу һәм үзара тәэсир итү буларак аралашудагы гомумилек нәрсәдә?

§ 33. Аңлашу буларак аралашу

Исегезгә төшерегез:

мәгълүматны кабул итү буларак аралашуның асылы нәрсәдә? Аралашуның интерактив ягы нәрсә белән үзенчәлекле?

«Социаль перцепция» атамасы (лат. perceptio — кабул итү) кешеләрнең социаль объектларны (башка кешеләрне, үз-үзләрен, төркемнәрне, социаль бергәлекләрне) кабул итүен һәм аңлавын белдерә. Шәхесара аралашуда кабул итү проблемасы, беренчедән, шуның белән бәйле: объект кабул итүче субъектка карата пассив һәм битараф түгел. Асылда, бу очракта ике субъект эш итә, һәм мөнәсәбәтләр субъектлы характерда була. Һәр субъект билгеле бер рәвештә үзен күрсәтергә, игътибар иттерергә, кирәкле тәэсир калдырырга тырыша. Икенчедән, бу процесста субъектив як мөһим роль уйный: партнерларның бер-берсен кабул итүе һәм бәяләве һәрвакыт субъектив һәм еш кына конкрет шартларга, аралашучы партнерларның кәефенә бәйле рәвештә үзгәреп тора. Еш кына бәяләү партнерга чынлыкта анда булмаган сыйфатлар бирү белән бергә бара. Шуннан аралашу буенча партнерны аңлауда еш ялгышулар килеп чыга. Алар аралашуда катнашучыларның үз-үзләрен тотуының, гамәлләренең чын сәбәпләрен җитәрлек белмәү белән бәйле булырга мөмкин. Өченчедән, аралашу процессындагы кабул итү шәхесара контактларның эмоциональ ягы белән бәйле. Билгеле ки, кешеләр үзләренә охшаган кешенең уңай якларын арттырып, ә охшамаганнарыныкын киметеп күрсәтергә тырыша. Кайчак кешегә карата мондый мөнәсәбәт бары тик бер, әмма эмоциональ әһәмиятле вакыйга нәтиҗәсе була.

Бу параграфта, партнерлар арасында үзара аңлашу шарты урнаштыру буларак, аларның кабул итүе нигезендә ятучы төп механизмнар каралачак.

КАБУЛ ИТҮ НИЧЕК БАРА

Сер түгел, аралашучы партнерны «киеменә карап», ягъни тышкы билгеләре буенча каршы алалар. Аралашу процессы нәкъ менә тышкы билгеләрне кабул итүдән башлана. Өстәвенә гадәттә тышкы кыяфәт, физик сыйфатлар, кием, үз-үзеңне тоту, ягъни башкарган гамәлләр, эмоциональ реакцияләр, мимика, ым-ишарә күбрәк мәгълүмати була. Күзәтүче, әлеге тышкы чагылышларны күреп, аларны аерым бер рәвештә бәяли, фикер йөртә, еш кына партнерга билгеле бер сыйфатлар бирә, шулай итеп, «охшый-охшамый» дигән төшенчәгә сыешлы мөнәсәбәт урнашырга мөмкин.

Белгечләр социаль перцепция механизмнарын — кешеләрнең бер-берсен кабул итү, аңлау һәм бәяләү ысулларын ачалар. Андый механизмнар арасында *эмпатия*, *аттракция*, *казуаль атрибуция*, *идентификацияләү*, *социаль рефлексия* аеруча мөһим роль уйный.

Кыскача гына әлеге механизмнарның асылын карыйк.

Эмпатия — башка кешенең эмоциональ халәтен аңлау, әгәр алай әйтергә ярасa, «тою-сизү» ул, чөнки бу сүз «хис», «кичереш»не аңлатучы pathos тамырыннан һәм «эчтә, нәрсә дә булса чикләрендә булу»ны аңлатучы кушымчадан тора.

Кешеләрнең башкаларның кайгысын уртаклашуы, кызгануы борын-борыннан кешенең иң яхшы сыйфатларыннан санала. Борынгы Грециядә кайгы уртаклашуга Аллага табынган кебек табынганнар.

Эмпатия башкаларның хисен аңларга, кешеләрне генә түгел, барлык җан иясен кызганырга, җәлләргә, тоярга ярдәм итә. Эмпатиягә сәләт кешенең кичерешләрен, кайгысын аңлый алуы, аның үзенең мондый халәтне кичергәне бармы икәнлеге белән билгеләнә. Гадәттә эмоциональ тотенүчән кешеләр, өлкән яшьтәгеләр, кан кардәшләр яки карашлары буенча аралашучы партнерлар, кайгыны күбрәк уртаклашырга сәләтлеләр.

Эмпатиянең төрле формалары була. Иң гади төре — бер кешенең башка берәүнең эмоциясен турыдан-туры, ирексездән кабатлавы.

Мәсәлән, кечкенә балалар төркемендә еш кына бер бала елый башласа, шундук бернинди сәбәпсез-нисез башкалары да елый башлый. Нәкъ шулай ук кешеләр дә төркемдә, концерт залында башка берәүнең эмоциясе белән «агуланырга» мөмкин.

Эмпатиянең катлаулырак формасы — башка кеше тарыган хәлгә нигезләнгән кичереш. Мәсәлән, цирк куполында гимнастларның чыгыш ясавын «йөрәгегез ярыла язып» күзәткәнегез бардыр. Бу очракта эмпатия барлыкка килү шуның белән бәйле: сез үзегез күзәткән кешегә янаган куркыныч хисен кичерәсез, гәрчә ул кеше бу куркынычны сизмәсә яки бу аның өчен гадәти нәрсә булса да.

Эмпатиянең иң югары формасы — кайгы уртаклашу, кичерешү. Бу халәт кешенең башка берәүнең кичерешләрен уртаклашуда, аның белән бергә яки аның өчен шатлана яки кайгыра белүдә чагыла.

Ләкин еш кына катнаш хисләр кичерергә туры килә: башка берәүнең шатлыгына — көнчелек, ә кайгы кичерүенә бу хәлнең сезнең белән түгел, аның белән булуына җиңеллек хисе килеп кушыла.

Билгеле булганча, кешеләр күпчелек очракта якын кешеләре — туганнары, якыннары өчен борчылалар, аларның кайгыларын уртаклашалар. Кешене якынрак белгән саен, кайгы яки шатлык уртаклашу шулкадәр җиңелрәк барлыкка килә, бу очракта безгә үзебезне аның урынына кую җиңел. Башка җенескә караганда үз җенесеңдәге, үзеңнән өлкәнрәккә яки кечерәккә карата кичерү җиңелрәк.

Шунысы кызык: башка кешенең тискәре эмоциональ кичерешләре (кайгы, борчылу) уңай кичерешкә караганда (шатлык, рәхәтлек) эмпатияне җиңелрәк китереп чыгара. Кешеләр шатлыкка караганда кайгыны күбрәк уртаклашалар.

Тәҗрибәләрнең берсендә катнашучыларга өлкәннәр белән тәртип бозучылар ролен уйнаган яшүсмерләр арасындагы әңгәмәнең видеоязмасын күрсәткәннәр. Һәр яшүсмер билгеле бер хисне — шатлануны, кайгыруны, ачулануны, куркуны сурәтләгән. Кайбер очракларда яшүсмернең йөзендә бернинди дә хис булмаган. Тәҗрибәдә катнашучыларга бу яшүсмерләрнең бертөрле үк гаеп эшләүләрен әйткәннәр һәм аларга нинди җәза бирергә икәнлеген сораганнар. Күбрәк кичереш йөзләре кайгыны сурәтләгән яшүсмерләргә карата булган. Катнашучылар фикеренчә, нәкъ менә алар җиңелрәк җәза алырга лаек булган.

Башка кешене аңа карата тотрыклы уңай хисләр, хөрмәт, якынлык булдыруга нигезләнгән кабул итүнең һәм аңлауның аерым формасы — *аттракция*. Бу сүз «җәлеп итү»не, «үзеңә тарту»ны аңлата. Аттракция еш кына дуслык, ияләшү, мәхәббәт аркасында барлыкка килә. Психолог А.Маслоу әйткәнчә, нәкъ менә шул хисләр кешене «мәңгелек билге астында» күрү, ягъни анда булган иң яхшы нәрсәләрне күрү һәм аңлау мөмкинлеге бирә. Аттракция һәрвакыт индивидуаль сайлаулы. Эмоциональ ияләшү ешрак уртак мәнфәгатьләр, кыйммәтләргә юнәлгәнлек нигезендә барлыкка килә. Билгеле бер күләмдә, кеше никадәр сөйкемлерәк булса, без аның эш-гамәлләрен шулкадәр яхшырак аңлыйбыз дип әйтергә була.

Казуаль атрибуция механизмы кешегә үз-үзен тотышының билгеле бер сәбәпләрен йөкләүдән тора. Мондый йөкләү әлеге үз-үзен тотышның танылган прототиплар тотышы яки үзеңнең шундый хәлләрдәге тотышың белән охшашлыгына нигезләнә. Әлеге механизм аралашуга һәрвакытта да булышмый. Мәсәлән, ата-анагыз белән мөһим сөйләшү алдыннан алардан нәрсә дә булса сорауга кадәр бу хәлнең булачак сөйләшүгә уңай йогынты ясавына өмет итеп, сез үз бүлмәгезне җыештырдыгыз ди. Ләкин сезнең аралашуның уңышлы булуы өчен «иҗади тәртипсезлек»тән котылуыгыз ата-анагызны шатландырмаска, ә шикләндерергә мөмкин. Бу очракта аралашу нәтиҗәсе сез көткәнчә булмавы ихтимал.

Үзара аралашканда үзара кабул итүдә *идентификацияләү* мөһим роль уйный. Эмпатиядән аермалы буларак, анда төп роль хискә түгел, ә исәп-хисапка туры килә. Идентификацияләү процессында субъект үзен аның турындагы күзаллаулар нигезендә башка кеше урынына куя дип әйтергә була. Аңлаешлырак булсын өчен, идентификацияләү механизмын мисалларда карыйк. Америка язучысы Э.По үз хикәяләренең

берсендә үз яшьтәшләре белән «җөпме, такмы» уенында шактый уңышлы уйнаган малайны сурәтли. Уенның мәгънәсе шунда — бергә уйнаучының учында җөпме, такмы сандагы таш яшерелгәнен белергә кирәк. Бер уенчы икенчесеннән: «Җөпме, такмы?» — дип сорый. Дөрес әйтсә, җиңүче откан ташын ала. Хикәя герое барлык сыйныфташларын да ота. Моңа ничек ирешүен сорагач, малай болай ди: «Минә бу малайның күпме акыллы яки аңгыра, яки ачулы икәнен яки аның хәзер нәрсә турында уйлаганын беләсем килсә, мин үз чыраемны нәкъ аның чырае кебек итеп ясыйм да, әлеге чырай нигезендә миндә нинди фикерләр һәм хисләр барлыкка килүен көтәм...» Язучы үзеңне билгеле бер интеллектуаль дәрәҗәдәге каршы якка тулысынча тәңгәлләштерә алу сәләте ярдәмендә идентификацияләүнең барлыкка килүен бик оста күрсәтә.

Педагоглар, психологлар яки тикшерүчеләрнең профессиональ аралашуы вакытында идентификацияләү мөһим роль уйный. Танылган әдәби персонаж Шерлок Холмс бу механизмны шактый киң куллана.

Эмпатия белән бергә кушылып, идентификацияләү еш кына аңларга, башканы күрергә, аның эшчәнлеге мотивларына һәм мәгънәсенә төшенергә, үзеңне аның урынына куеп карарга ярдәм итә.

Социаль перцепциядә үзеңне кабул итү, үз эш-гамәлләреңне һәм теләкләреңне, үзенчәлекләреңне, аларның башка кешеләр тәэсиренә йогынтысын аңлау мөһим роль уйный. Бу процесс башкача *социаль рефлексия* дип атала. Әлеге төшенчә күптәннән барлыкка килгән. Әле Декарт ук рефлекция дигәндә кешенең үз фикерләре эчтәлегендә туплана, тышкы бар нәрсәдән арына алу сәләтен күздә тоткан. Ләкин социаль рефлексия процессында әле тагын безне аралашу буенча партнерларыбызның ничек аңлавына һәм кабул итүенә төшенү дә өстәлә. Бу вакытта игътибарыбыз партнердан үзебезгә күчә. Кеше социаль рефлексия процессында, ничектер, өч позициядә тора кебек:

— «мин», мин чынлыкта ничек;
— «мин», мин үземне ничек итеп күрәм;
— «мин», мине аралашу буенча партнерым ничек итеп күрә.

Аларның барысы да кешенең үз образын барлыкка китерүдә катнаша.

«КАБУЛ ИТҮ ТӘЭСИРЕ» ҺӘМ СТЕРЕОТИПЛАРЫ

Аралашу еш кына стереотиплар нигезенә корыла һәм партнерның «кабул итү тәэсирен» тудыра.

Стереотип грекчадан тәрҗемә иткәндә «көчле тәэсир» дигәнне аңлата. **Стереотип — нинди дә булса күренешнең яки**

кешенең мәгълүмат дефициты шартларында барлыкка килә торган тотрыклы, ә еш кына гадиләштерелгән образы. Ул безгә охшаш булып тоелучы, әмма һәрвакытта да алай булмаган хәлдә уйдан бирелә торган үзенә күрә бер штамп кебек. Мисал итеп беренче тапкыр Франциягә килгән һәм кунакханәдә җирән җыештыручыны күргән инглизне китерик. Үзенең кенәгәсенә: «Барлык французлар да җирән»,— дип язып кую өчен аңа беренче тәэсир җиткән.

Социаль стереотиплар ешрак мәгълүмат җитмәгәндә индивидның шәхси тәҗрибәсе гомумиләштерүе яисә башка кешеләрдән алынган ялгыш күзаллаулар нәтиҗәсе буларак барлыкка килә. Без бер үк китаплардан укыйбыз, безнең көндәлек тормышыбыз көн саен охшаш формаларда үтә. Мода һәм гадәтләр турында әйтеп тә тормастан, хәтта йортлар һәм фатирлар да күптәннән инде типикка әверелде. (Режиссер Э.Рязановның «Язмыш шуклыгы, яисә Җиңел пар белән» дигән фильмында сөйләнгән, әкият диярлек, ләкин шул ук вакытта ышандырырлык тарихны искә төшерик.)

Җәмгыять кешеләргә типик хәлләрдә үзеңне тотуның охшаш кагыйдәләрен күндерә, күрсәтмәләрне, омтылышларны көчләп тага, ихтыяҗлар барлыкка китерә. Стереотиплар — көнкүреш яки профессиональ эшчәнлектә формалашкан, фикерләүдә ныгып калган һәм тормыш куйган типик бурычларны хәл иткәндә даими кулланылучы үткән тәҗрибәнең бер өлеше.

Стереотиплар булу күп кенә хәлләрдә ярдәм итә. Кеше табибтан авырган вакытта — ярдәм, хәрбидән — кыюлык, хатынкыздан ягымлылык һәм йомшаклык көтә. Стереотиплар социаль мохиттә юнәлеш табарга ярдәм итә. Ләкин стереотипларның үзләрендә, дөрес як белән бергә, хаталарга һәм ялгышуларга да урын бар.

Бөтен тулылыкка дәгъва итмәстән, «стереотипларны формалаштыруга нәрсә йогынты ясый?» дигән сорауга җавап эзләп карыйк.

Социаль стереотиплар барыннан да элек төркем нормалары йогынтысында барлыкка килә. Күп кешеләр уйлаганча, күпләр риза булган нәрсәләр дөрес. Борынгы грек философы Диоген Синопский (б.э.к. 400 чамасы — 325 чамасы еллар), кешеләрнең күпчелеге акылдан шашудан «бер бармакта» торалар: әгәр кеше урта бармагы белән нәрсәгә дә булса күрсәтсә, аны юләргә санаячаклар, имән бармак белән булса — юк. Бу очракта стереотип әлеге хәлдә ничек эш итәргә кирәклеге турында урнашкан күзаллауга бәйле. Андый күзаллаудан читенү нормадан читкә китү булып санала.

Яшь, җенес, гаилә, профессиональ нормалар фикер агышын бер юнәлештә чикли, ә башкаларында хуплыйлар. Инглиз фикер иясе Фрэнсис Бэкон (1561–1626) дөньяны гомум кабул ителгән бәяләүгә, аны кайчак үзгәртелгән һәм тенденциоз кабул итүгә эчке күнегелгәнлекне «идоллар» проблемасы итеп карый. Кешеләр традицияләр белән изгеләштерелгәннең чынлыгына ышаналар, алар зиһенгә кабул иткәнне, үзләре күнеккәнне һәм кызыксынганны һәрьяклап сакларга тырышалар. Нәкъ менә шул дөньяның үз образын тотрыклы саклау мөмкинлеге бирә. Әгәр кеше нормалар, күрсәтмәләр, «идоллар» белән исәпләшмәсә, ул үзен аларны кабул иткән билгеле бер төркем кешеләргә каршы куя, һәм стереотипларны җиңүнең субъектив кыенлыклары шунда да.

Галим «ыруг идолларын», «театр идолларын», «мәгарә идолларын», «базар идолларын» аерып күрсәтә.

«Ыруг идоллары» — иҗтимагый фикер йогынтысы астында эшләнә торган хаталар ул. Алар кешеләрнең дөньяда чынлыктагыдан да күбрәк тәртип һәм бертөрлелек теләүләре, табигатькә уйлап чыгарылган охшашлыклар бирергә тырышулары, уйларында дөньяны тотрыклы итеп күзаллаулары белән бәйле. Хата — кешегә хас булган әлеге шартларда күпчелек кешеләрнең аның кебек эшләүләренә ышануында. Кешеләр киләчәккә фаразларны шул ышанудан чыгып коралар. Башкаларга бәя биргәндә, без, кешеләрнең төрле булуын инкарь итеп, социаль нормага яки идеалга ышанырга һәвәс.

Икенче бер стереотип: кеше үзгәрешсез хәлләрдә кешенең үз-үзен тотышы да элеккечә кала дип уйлый. Бу очракта без тышкы хәлләрнең генә түгел, кешеләрнең эчке халәтләре, максатлары, мотивлары, ниятләре дә хәрәкәттә булуын һәм үзгәрүен исәпкә алмыйбыз. Шунысы ачык: кешене озаграк белгән саен, без андагы үзгәрү ихтималлылыгын шулкадәр азрак таныйбыз.

«Ыруг идоллары» төркеменнән тагын бер стереотип шунда: кешеләр үз гамәлләрен — тышкы хәлләр белән, ә башкаларныкын аларның үз сыйфатлары белән аңлатырга тырышалар («мондый хәлләрдә мин башкача эшли алмый идем, ә ул, гомумән, үзе шулай булганга эшләгән»).

«Мәгарә идоллары» — аралашуда барлыкка килүче, ә аннары башка өлкәләргә үтеп керүче стереотиплар. Әлеге стереотипларны тагын «нәтиҗәлеләр» дип атыйлар.

Таралган нәтиҗәләрнең берсе — «ореол эффекты». Нинди дә булса бер предмет тирәсендә балкуны белдерүче бу сүзне психологлар күчермә мәгънәдә кулланалар. Балкыш урынына ореол тәэсир иткән очракта күзәтүченең яки аралашу буенча партнерның башка партнер, аның уңай һәм тискәре яклары

турындагы фикерен, әйтерсең лә аның реаль образы «чолгап ала».

«Ореол тәэсире» — үзен ниндидер бер эштә яхшы күрсәткән кешедән башка эшләрдә дә, ихтимал, аның моңа теләге, сәләте булмаса да, шундый ук уңыш көткән очракта барлыкка килә. Әйтик, кече яшьтәге мәктәп укучылары партадашының укудагы уңышларын аның шәхси сыйфатлары белән тәңгәлләштерә. Алардан: «Таня әйбәт иптәш, чөнки ул әйбәт укый»,— дигәнне ишетергә туры килә. Өлкән кешеләр дә «ореол тәэсире»нә нигезләнгән ялгыш күзаллаулардан азат түгел. Мәсәлән, шат күңелле шамакай ролен уйнаган артистны еш кына тормышта да шундыйдыр дип уйлыйлар, гәрчә ул бөтенләй дә андый булмаска мөмкин. Бу очракта профессия ореолы роль ореолына күчерелә һәм ялгыш фикергә илтә.

«Матурлык могҗизалар тудыра. Чибәрдәге эчке җитешсезлекләр чиркану тудыру урынына ничектер гадәттән тыш җәлеп итәрлеккә әвереләләр».

Н.В.Гоголь

«Ореол тәэсире» минус билгесе белән дә булырга мөмкин. А.Сент-Экзюпериның Кечкенә Принц турындагы повестенда шундый хәл турында сөйләнә: төрек киемендәге бер галим халыкара конгресста В-612 астероидын ачуы турында хәбәр иткәч, аңа беркем дә ышанмый. Ул шул ук докладын сүзгә-сүз Европа киемен киеп кабатлагач, аңа барысы да ышана. Бу очракта гадәти булмаган кием кешенең хәбәренә ышанмау тудыра, икенче очракта инде хәл бөтенләй үзгәрә.

«Проекция тәэсире» «ореол тәэсире»нә якын тора. Ул безгә ягымлы әңгәмәдәшкә үзебезнең дә яхшы якларыбызны, ә күңел ятмаганына үзебезнең дә кимчелекләребезне өстәргә теләгән вакытта барлыкка килә. Һәрберебез җиңел исенә төшерә ала: әңгәмәдәшебезне үзебезнең хаклы булуыбызга ышандыргач: «Акыллы кеше белән эш йөртүе күңелле шул»,— дип уйлыйбыз. Киресенчә, матур сүзләребез һичничек тәэсир итмәгән кешене киребеткәнгә саныйбыз.

Тагын бер киң таралган тәэсир — *«тәртип тәэсире»* (яки «беренчелек тәэсире»). Ул аралашудан алган гомуми тәэсиргә элек алынган мәгълүматлар йогынты ясаганда була. Күпләгән тәҗрибәләр шуны күрсәтә: бер рәткә салынган материалларның соңгы яки беренче элементларын искә төшерү ихтималы шул ук рәтнең урта элементларын искә төшерүдән югарырак. Таныш кеше турында өр-яңа яки вакыт буенча соңгы мәгълүмат, ә таныш түгел кеше хакында беренче мәгълүмат һәм беренче тәэсир әһәмиятлерәк.

«Ялган гомумиләштерү тәэсирен» дә «мәгарә идоллары» на кертәләр. Без аның белән социаль төркемнең аерым вәкилләрендәге билгеле бер сыйфатлар булуы турында раслаулар нигезендә мондый сыйфатларның төркемдәге барлык кешеләрдә дә булуы турында нәтиҗә ясаганда эш итәбез. «Ялган гомумиләштерү тәэсире» булып Гоголь героеның фикер йөртүе хезмәт итә ала. Кичләрен чумар ашаучы православныйлар булгач, димәк, аны барлык православныйлар да ашый, чумар ашамаган кеше православный түгел дип уйлый ул. Иҗтимагый тормышның башка өлкәләреннән мисалларны сез үзегез дә китерә аласыз.

«Базар идоллары» авторитетлар басымы астында, бөекләрнең фикере алдында баш игәндә барлыкка килә. Кемнеңдер кайчандыр канунлаштырылган бәяләве стереотипка әверелә. Танылган кеше яклаган ялгышудан да хәтәррәге юк. Әлеге стереотиплар һәрвакытта да ялгышу булмый, әмма булган очракта бик тә куркыныч.

Төп төшенчәләр: үзара аңлашу, идентификацияләү, эмпатия, шәхесара кабул итү тәэсирләре һәм стереотиплары.

Терминнар: социаль перцепция, аралашу вакытында үзара кабул итү механизмнары.

Үзегезне тикшерегез

1. Нәрсә ул социаль перцепция? 2. Аралашу буенча партнерның кабул итүе механизмнарын тасвирлагыз. 3. Аралашуда үзара аңлашу өчен эмпатия нинди әһәмияткә ия? 4. Казуаль атрибуциянең төп хаталары нәрсә белән аңлатыла? 5. Үзара аңлашуга кабул итү тәэсирләре нинди йогынты ясый? 6. Аралашу буенча партнерларның кабул итү стереотипларына мисаллар китерегез.

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Городничийлары Сквозник-Дмухановский булган өяз шәһәре кешеләре ни сәбәпле Хлестаковны бик җиңел генә Петербургтан килгән зур түрә дип кабул иткәннәр? Җавабыгызны дәлилләгез.

2. Маҗаралы хикәяләрнең берсендә башка планеталарга очу хокукына ия булу өчен имтихан тоткан космонавтларга мондый тест тәкъдим ителә: «Күз алдыгызга китерегез: сез космик корабльдән чыктыгыз һәм унике аяклы, агуга бик тә охшаган сыеклык саркып торган берничә уклы хәшәрәт бер үрмәкүч күрдегез ди. Үрмәкүч авыр таш белән бастырылып куелган һәм бик тә интегә. Шул чакта сез нишләр идегез?»

Бу сынауда нәрсә тикшерелде? Сезнеңчә, бу сынауны узган космонавт ничек эш итәргә тиеш?

3. Үз сыйныфыгызда зур булмаган социологик тикшеренү үткәрегез. Классташларыгызга язма рәвештә «танылган спортчы», «шук клоун», «танылган табиб», «модалы диджей» портретының телдән портретын төзергә тәкъдим итегез. Әлеге сурәтләүләрне чагыштырыгыз, классташларыгызның текстларында кабул итүнең нинди стереотиплары булуын билгеләгез.

Чыганак белән эшләгез

Бүгенге заман Россия психологы А.А.Бодалев тәҗрибәләрендә бер төркем өлкән яшьтәгеләргә фоторәсем буенча кешене тасвирларга тәкъдим иткәннәр. Бер үк фотопортретны күрсәтер алдыннан бер төркемгә «бу — герой портреты», икенчесенә «бу — җинаятьче портреты» дигәннәр.

Кабул итү ялгышлары

Кешенең тәкъдим ителгән статусына бәйле рәвештә, фоторәсем буенча тикшерелгәннәрнең тасвирлаулары да үзгәргән. Мәсәлән, *Җинаятьче.* «Бу ерткыч нәрсәнедер аңларга тырыша, акыллы итеп һәм текәлеп карап тора. Стандарт бандит ияге, күз астында — капчык, фигурасы массив, картая баручы, алга таба иелгән». Яисә «Түбән тәгәрәгән кеше, бик тә явыз, начар киенгән, чәче таралмаган. Җинаятьче булуга кадәр ул хезмәткәр яисә интеллигент булгандыр дип уйларга мөмкин. Бик тә явызларча караш». *Герой.* «25–30 яшьләрдәге яшь кеше. Ихтыяри, ирләрчә, дөрес сызыклы бит. Бик тә тәэсирле караш. Чәчләре тузгыган, кырынмаган, күлмәк якасы ычкындырылган. Күрәсең, гәрчә хәрби формада булмаса да, бу — нинди дә булса бәрелештә катнашкан геройдыр». Яисә «Бик тә ихтыярлы йөз. Бернәрсәдән дә курыкмаган күзләр маңгай астыннан карыйлар. Иреннәре кысылган, эчке көч һәм нык тору сизелеп тора. Йөзе аның горур кеше булуын чагылдыра».

Сораулар һәм биремнәр: 1. Экспериментта катнашучылар фикеренә социаль перцепциянең нинди механизмнары йогынты ясаган? 2. Тикшеренүчеләр нинди сыйфатлар күргәннәр һәм бәяләгәннәр? 3. Бу сыйфатларны күргәзмә өчен чагыштырма таблица рәвешендә күрсәтегез.

§ 34. Кече төркемнәр

Исегезгә төшерегез:

җәмгыятьтә кешеләр берләшкән төркемнәр нинди була? Шәхеснең үсүендә социаль төркемнәр нинди роль уйный? Нәрсә ул төркем нормалары?

Үзләренең тормыш эшчәнлекләрендә кешеләр берләшкән төркемнәр кайбер фәннәрдә: социологиядә, социаль философиядә, социаль психологиядә һ.б. кызыксыну тудыра. 11 нче сыйныфта сез зур социаль төркемнәрне һәм аларны өйрәнүгә социологик якын килүләргә өйрәнерсез. Бу параграфта без, нигездә, кече төркемнәргә социаль-психологик якын килүләргә тукталырбыз.

Кече төркемнәр белән кеше үзе тугач ук бәйле була. Кече төркемнәрдә ул дөнья турында мәгълүмат ала, башка кешеләр белән мөнәсәбәтләр урнаштыра һәм үз эшчәнлеген оештыра. Кече төркемнәрдә аралашуның һәр өч ягының уртак закончалыклары чагыла. Шундый төркем аша шәхес җәмгыятьтә барлыкка килә торган кыйммәтләрне һәм нормаларны белә.

Кече төркемнәр проблемасы социаль психологиядә тикшеренүләрнең күбрәк эшләнгән өлкәләреннән санала. Социаль психологлар кече төркемнәрдә барлыкка килүче психологик үзенчәлекләрне, закончалыкларны, процессларны тикшерәләр.

НӘРСӘ УЛ КЕЧЕ ТӨРКЕМ?

Кече төркем дигәндә социаль психология составы **буенча күпсанлы булмаган, әгъзалары гомуми эшчәнлек (максатлар һәм бурычлар) белән берләшкән һәм турыдан-туры шәхсән аралашуда торган кешеләр бергәлеген** аңлый.

Кече төркем характеристикасына аның әгъзаларының *психологик һәм үз-үзләрен тоту гомумилеген* кертәләр. Психологик гомумилек шуңа нигезләнә: кешеләр үзләренең билгеле бер төркемнәргә — үзенең аерым төркем мәнфәгатьләре, нормалары, кыйммәтләре һәм максатлары булган төркемгә керүләрен аңлыйлар. Төркемгә кергән индивид өчен аңа керүне тану төркемнең башка әгъзалары белән уртаклыкны аңлау, кайбер «без» бергәлеген аеру фактын аңлау аша килә. **«Безхисләр» дигәннең булуын күпләгән социаль психологлар төркемнең төп характеристикасы дип исәплиләр.**

Тикшеренүчеләр кече төркем 2–3 кешенең берләшүеннән башлана дигән белән килешәләр. Кече төркемнең өске саны чигенә килгәндә исә, төрле караш белдерелә — 8–10 нан алып 30–40 кешегә кадәр. Дөрес, егермедән артык кешеле төркем күп очракта «кече» дип билгеләнми. Моның сәбәбе, мөгаен, шундый төркемне аерып торучы сыйфатлар булган төркем әгъзаларының турыдан-туры үзара тәэсире һәм бер-береңә шәхси тәэсир итү азрак чагылудадыр.

Кече төркемне, кече төркемнәрне аерып алу принципларын, шулай ук сан параметрларын (кече төркем әгъзалары санының өске һәм аскы чикләрен) төгәл билгеләү мәсьәләләре әле бүгенге көндә дә бәхәсле булып кала.

Аралашу һәм уртак эшчәнлек төркемдә эмоциональ мөнәсәбәтләр (симпатия, антипатия, битарафлык), аерым төркем кыйммәтләре һәм үз-үзеңне тоту нормалары барлыкка килү өчен нигез булып карала.

Төп мәктәп курсыннан хәтерлисездер, *төркем нормалары* — төркем эшләгән яки кабул иткән һәм аның әгъзаларының тәртибе аңа буйсынырга тиешле билгеле бер кагыйдәләр ул. Ул нормалар төркемнең төркем кыйммәтләрендә (асылда, «Нәрсә ул яхшы, нәрсә ул начар?» дигән сорауга уртак җавап бирүдә) чагылыш тапкан социаль күренешләргә мөнәсәбәте уңаеннан урнашалар. Монда төркем нормаларының төркем кыйммәтләре белән бәйләнеше чагыла. (Уйлагыз: мәсәлән, кече төркем буларак, сезнең гаиләгезнең тормыш нормаларына һәм кыйммәтләренә нәрсәләрне кертергә була?)

Кече төркем структурасын өйрәнеп, тикшеренүчеләр уртак эшчәнлекләрендә төркем әгъзаларының функциональ бурычларын, рольләре җыелмасын (билгеле бер функциональ бурычлар йөкләнгән кешедән көткән эш-гамәлләр җыелмасы) һәм социаль контроль вазыйфасын башкаручыларның нормалары җыелмасын (иҗтимагый хупланган үз-үзеңне тоту күрсәтмәләре, таләпләре, теләкләре җыелмасы) аерып күрсәтәләр.

Кече төркем *социаль система* булып тора. Аның элементлары — башка социаль системаларның элементлары булган кебек үк, кешеләр һәм алар арасында барлыкка килгән мөнәсәбәтләр.

Кече төркем *динамикалы төркем* булып тора, моны аның үзгәрү, үсү процесслары дәлилли. Ул — *ачык система*, чөнки ул тышкы мохит белән бәйле, аның йогынтысын тоя һәм аңа җавап бирә. Ләкин, тикшеренүчеләр раслаганча, төрле төркемнәрнең тышкы мохит, җәмгыять йогынтысына ачыклыгы дәрәҗәсе төрлечә. Ачыклык дәрәҗәсе зур булмаган төркемнәрне җәмгыять еш кына нинди дә булса билгеле бер максатларга ирешү өчен файдалана. Андый төркемнәрнең мисаллары булып озак йөзүдә булган суднолар экипажлары, космик корабльләр, поляр экспедицияләр, армия подразделениеләре командалары хезмәт итә ала.

Кече төркемнең аңа үзгәреп торган тирәлеккә ярашу мөмкинлеге бирүче күпмедер мөстәкыйльлеге була. Шунлыктан кече төркемнәр шактый озак вакыт яши, аның әгъзалары шактый даими, ешрак бер үк урында очрашалар. Мәсәлән, мәктәп сыйныфы 10–11 елга кадәр яши ала.

ТӨРКЕМНӘР НИНДИ БУЛА

Фәнни әдәбиятта төркемнәрне классификацияләү проблемасына күпләгән төрле якын килүләр китерелә, әлеге классификацияләрнең төрле нигезләмәләре атала. Күбрәк кабул ителгәннәренә тукталыйк.

Төркемнәр арасыннан барыннан да элек *шартлы һәм реаль төркемнәрне* аерып күрсәтәләр. **Шартлы (нормаль) дип бер-берсе белән турыдан-туры үзара мөнәсәбәтләре булмаган кешеләрне берләштерүче төркемнәрне атыйлар.** Бу төркемнәргә берләшкән кешеләр бер-берсе белән очрашмаска гына түгел, бер-берсе турында бернәрсә дә белмәскә мөмкиннәр. Статистикада кешеләрнең шартлы төркемнәрен ниндидер билге буенча аерып күрсәтәләр. Мәсәлән, РФнең теге яки бу субъектларында яшәүчеләр арасыннан статистика кешеләрнең билгеле бер дәрәҗәдәге белеме яки билгеле бер авыруы, яисә аерым торакка мохтаҗ булган төркемнәрен аерып күрсәтә. (Төркем билгеләмәсенә таянып, бу рәвешле аерып күрсәтелгән төркемнең ни өчен шартлы булуын аңлатыгыз.)

Шартлы төркемнәргә кешеләрне тагын эшчәнлек характеры, җенес, яшь, милләт кебек һ.б. билгеләр буенча берләштерәләр. (Уйлагыз, шартлы төркемнәргә аеру тагын нинди билгеләр нигезендә булырга мөмкин?)

Шартлыларга капма-каршы буларак, **реаль төркемнәр — үзара билгеле бер мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән һәм үзләренең шул төркемгә керүләрен таныган кешеләрнең чынлап та яшәүче берләшмәләре ул.** Реаль төркемнәр йә җәмгыять ихтыяҗы уңаеннан төрле оешмалар тарафыннан булдырылалар, йә бу төркемгә керүче кешеләр теләге белән ирекле берләшмәләр буларак барлыкка киләләр. Реаль төркемнәргә, мәсәлән, гаилә, эшчеләр бригадасы, студентлар төркеме, мәктәп сыйныфы, ишегалды компаниясе керә.

Социаль-психологик тикшеренүләрнең үзенчәлекләрен аңлау өчен реаль төркемнәр арасында *лаборатор* һәм *табигый* төркемнәрне аерып күрсәтү мөһим. Лаборатор төркемнәр социаль психологлар тарафыннан махсус рәвештә үз тикшеренүләре максатында эксперименталь бурычларны башкару өчен булдырыла. Мәсәлән, телетапшыруларның балалар агрессиясенә йогынтысын тикшергән экспериментларның берсе

вакытында лаборатор төркемгә башлангыч мәктәптән берничә укучы берләштерелгән. Шаһитлары балалар булган рәхимсезлекләрнең «сыйфатын» контрольдә тоту һәм анык балаларның үз-үзләрен тотышына йогынтысын күзәтү өчен, тикшеренүчеләр телетапшыруларны лабораториядә карауны оештырганнар.

Табигый төркемнәр җәмгыять үсеше барышында барлыкка килә. Аларда катнашучылар санының күпме булуына карап, табигый төркемнәр арасыннан **зур һәм кече төркемнәрне** аералар. Зур табигый төркемнәрнең мисаллары этник төркемнәр, профессиональ төркемнәр, бер җенестәге кешеләр төркемнәре (аерым алганда, яшьләр, пенсионерлар һ.б.) була. Кече табигый төркемнәрнең мисаллары — мәктәп сыйныфлары, спорт командалары, дусларның ишегалды компанияләре.

Социаль психологиянең фән буларак барлыкка килүен гадәттә психологик күренешләрне беренче тапкыр *зур төркемнәрдә* тикшереп карау белән бәйлиләр (XIX гасырның икенче яртысы). Мәсәлән, «халыклар психологиясе», «массалар психологиясе» тикшерелә. XX гасырның 20 нче елларыннан башлап социаль психологлар *кече төркемнәрне* өйрәнә башлыйлар. Зур төркемнәр белән сез җентекләбрәк 11 сыйныфта танышырсыз. Без монда аларны төркемнәрнең нинди булулары турында бөтенлекле күзаллау бирү өчен искә алабыз.

Табигый төркемнәр арасыннан *беренчеләрен* һәм *икенчеләрен* аерып күрсәтәләр. Аерып күрсәтү критерие — төркем әгъзалары арасында турыдан-туры бәйләнешләрнең булу-булмавы. Беренчел төркемнәрдә (гаилә, дуслар төркеме, команда һ.б.) кешеләр арасында турыдан-туры багланышлар була. Икенчел төркемнәр — әгъзалары арасында турыдан-туры багланышлар булмаган, аралашу өчен төрле «арадашчылар» кулланылган төркемнәр. Әгәр студентлар төркемен беренчел төркем дип карап булса, курсның һәм факультетның барлык студентлары икенчел төркемне тәшкил итә. Югарырак дәрәҗәдәге системаның — икенчел берләшмәнең бер өлеше буларак, беренчел **төркемне кече төркем белән тәңгәлләштерәләр.** Бу караштан чыгып, кече төркемне еш кына *ассистема* буларак характерлыйлар.

Хәзер инде **кече төркемнәрнең** нинди булуын карыйк.

Тикшеренүчеләр *формаль* (оештырылган, рәсми) һәм *формаль булмаган* (рәсми булмаган) төркемнәр арасында аерма үткәрәләр. **Формаль төркемнәр аерым бер оешма тарафыннан нинди дә булса конкрет максатка ирешү өчен махсус боерыклар белән оештырыла.** Кече төркемнәрне беренче тапкыр формаль һәм формаль булмаганнарга бүлүне тәкъдим иткән Америка социологы Элтон Мейо (1880–1949) фикеренчә, формаль төркем

шуның белән аерыла: анда башта аның әгъзаларының статуслары билгеләнә, рольләре, лидерлык итү һәм буйсыну системасы («хакимият структурасы») катгый бүленә. Формаль төркемнәргә, мәсәлән, рольләре башта ук бүленеп куелган (һөҗүмче, сакчы һ.б.) футбол командасын кертергә була. (Формаль төркемнәргә үз мисалларыгызны китерегез.)

Формаль булмаган төркемнәр — кешеләрнең уртак мәнфәгатьләр, дусларча элемтәләр, үзара симпатияләр нигезендә урнашкан ирекле бергәлекләре ул. Алар бернинди ярдәмсез, ә кайчак оешманың яисә башка формаль структураларның теләгенә каршы килеп барлыкка килә. Андый төркемнәрдә статуслар да, рольләр дә алдан язылып куелмаган, үзара мөнәсәбәтләрнең бирелгән системалары да юк, әмма рөхсәт ителә торган үз-үзеңне тотуга һәм бурычларыңа кагылышлы язылмаган кагыйдәләре һәм нормалары бар. Формаль булмаган төркемнәр теге яки бу формаль төркемнәр эчендә түгел, ә аннан тыш мөстәкыйль төркем буларак барлыкка килә ала. Мәсәлән, ишегалды компанияләре шулай барлыкка килә. Кайчак андый төркемнәр кысаларында, аларның формаль булмаган характерына карамастан, уртак эшчәнлек барлыкка килә, һәм шул вакыт алар формаль төркемнәрнең кайбер сыйфатларын алалар: аларда позицияләрне һәм рольләрне аерырга була. (Мәсәлән, А.П.Гайдар китабында сурәтләнгән Тимурны һәм аның командасын исегезгә төшерегез.) Социаль психологлар еш кына формаль һәм формаль булмаган мөнәсәбәтләр структурасын, төркемнәрне түгел, ә алар эчендәге мөнәсәбәтләр тибын һәм мөнәсәбәтләрен карыйлар.

Әдәбиятта еш очрый торган классификацияләрнең тагын берсе — «әгъзалык төркеме» һәм «референт төркемнәр» (лат. refero — кертәм, инг. to refer— кертү, яраштыру).

РЕФЕРЕНТ ТӨРКЕМНӘР

Референт төркемнәрне аеру өчен нигез булып индивидның омтылышларын, аның үз-үзен тотышында төркем нормаларына һәм кыйммәтләренә, башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышына һәм үзбәясенә ориентлашуын формалаштыру өчен төркемнең *әһәмияте дәрәҗәсе* хезмәт итә.

Индивид тарафыннан ул бары тик анда була торган гына итеп каралучы төркемнәр индивидның кыйммәтләр системасына йогынты ясамый, аның өчен *әгъзалык төркемнәре* генә булып тора.

Мәсәлән, туристлык путевкасы сатып алып, кеше формаль (оешкан) туристлар төркеме әгъзасына әверелә. Андый төркемне әгъзалык төркеме дип санап була, чөнки аның кеше өчен

әһәмияте дәрәҗәсе һәм аның кыйммәтләр системасына йогынтысы дәрәҗәсе шактый кечкенә.

Кеше өчен ул үзен эталон итеп тиңләштерү әһәмиятенә ия булган, кыйммәтләрен, фикерләрен һәм бәяләмәләрен уртаклаша, алар белән үз карашларын һәм үз-үзен тотышын чагыштыра торган реаль һәм шартлы төркемнәрне референт төркемнәр дип атыйлар. Әлеге төшенчәне Америка социаль психологы Г.Хаймен (1942 елда туган) керткән. Ул, студентлар төркемен тикшеренгән вакытта, аларның бер өлеше үзеңне тотуның бу төркемдәге түгел, ә ниндидер башкасындагы, алар ориентлашкан нормаларны уртаклашалар дип тапкан.

Референт төркем башкара торган вазыйфалардан норматив һәм чагыштырма вазыйфаларны аерып күрсәтәләр. *Норматив вазыйфа* төркемнең индивидның үзен тотышы нормаларына, социаль омтылуларга һәм кыйммәти ориентлашуына йогынты ясаудан тора. *Чагыштырма* вазыйфа шунда чагыла: төркемнең кыйммәтләре, норма һәм кагыйдәләре системасы индивид өчен ул үзен һәм башкаларны шуның белән бәяли торган үзенчәлекле эталон булып тора.

Гадәттә һәр индивид шактый күп референт төркемнәргә керә, бу аның мәнфәгатьләре, шөгыльләнә торган эшчәнлек төрләре, аның хыяллары һәм теләкләре һ.б. белән бәйле (мәсәлән, гаилә, нинди дә булса клуб яки спорт секциясе, музыка ансамбле һ.б.). Кеше өчен реаль төркем дә (мәсәлән, ишегалдындагы компания яисә якын дуслар), шартлы төркем дә референт булырга мөмкин. Әгәр шартлы төркем референт булса (мәсәлән, китап геройлары, үткән заманнардагы язучылар яки галимнәр һ.б.), кеше, кагыйдә буларак, әлеге төркемнең үзе турында ихтимал булган фикерен фаразлый. Яшүсмер өчен шартлы референтлы төркемне еш кына әтисе, якын дусты, әдәби герой, башкаручы музыкант һ.б. тәшкил итә ала.

ТӨРКЕМНӘРДӘГЕ ШӘХЕСАРА МӨНӘСӘБӘТЛӘР

Психологик төркем кешеләрнең гомуми эшкә һәм берберсенә карата төрлечә шәхесара *мөнәсәбәтләреннән* оеша.

Төркемдәге мөнәсәбәтләр катлаулы, үзгәрүчән система барлыкка китерә. Анда *мөнәсәбәтләрнең берничә төрен* аерып күрсәтәләр.

Вазыйфаи дәрәҗәдә барлыкка килгән мөнәсәбәтләрне *рәсми* дип атыйлар. Алар расланган нормалар һәм кагыйдәләр (законнар, инструкцияләр, нигезләмәләр, уставлар һ.б.) белән урнаштырыла. Мәсәлән, күп кенә мәктәпләрдә укучыларның үз-үзләрен тотуларына таләпләр исемлеге бар. Аларда, аерым

алганда, укучылар белән укытучылар, шулай ук төрле яшьтәге укучылар арасындагы мөнәсәбәтләр характеры теркәлә.

Алардан аермалы буларак, төркемдә кешенең кешегә карата шәхси мөнәсәбәте нигезендә *рәсми булмаган* мөнәсәбәтләр урнаша. Алар өчен гомум кабул ителгән нормалар, кагыйдәләр, таләпләр һәм нигезләмәләр булмый.

Төркем өчен төп уртак эшчәнлек белән бәйле рәвештә, *эшлекле* шәхесара мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Алар төркем әгъзаларының вазыйфаи хәле һәм аларның үз функциональ бурычларын башкаруы белән нигезләнә. Төркемнең төп эшчәнлегеннән бәйсез рәвештә, *шәхси* мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Алар барыннан да элек симпатияләр һәм антипатияләргә нигезләнә. Эшлекле һәм шәхси мөнәсәбәтләр реаль тормышта бер-берсен тулыландыра.

Моннан тыш *вертикаль мөнәсәбәтләрне* (төркемнең рәсми яки рәсми булмаган структурасында төрле урынны биләгән кешеләр арасында барлыкка килә торган шәхесара мөнәсәбәтләрне) һәм *горизонталь мөнәсәбәтләрне* (төркемнең рәсми яки рәсми булмаган структурасында бер үк дәрәҗәдәге кешеләр арасында барлыкка килә торган шәхесара мөнәсәбәтләрне) аерып күрсәтәләр. Мәсәлән, башлык белән аңа буйсынган кеше арасындагы мөнәсәбәтләр; ә хезмәттәшләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр — горизонталь мөнәсәбәтләр.

Еш кына *рациональ* (аларда беренче планга кешеләрнең бер-берсе турында белгәннәре һәм аларның объектив характеристикалары чыга) һәм *эмоциональ* (кешенең кешене индивидуаль кабул итүенә нигезләнгән) мөнәсәбәтләр аерыла. Психологларны аеруча кешеләр арасындагы дуслык, якын күрү, ярату, симпатия һәм антипатия кебек эмоциональ мөнәсәбәтләр закончалыклары кызыксындыра.

Төркемдәге шәхесара мөнәсәбәтләр — шәхеснең төркем һәм аның һәр әгъзасы белән элемтәләренең катлаулы системасы ул. Әлеге мөнәсәбәтләр шәхес тарафыннан тоела һәм субъектив кичерелә.

Кече төркемнәрдәге шәхесара мөнәсәбәтләр структурасын практик тикшеренүләр Австрия-Америка психологы, психиатры һәм философы Якоб Морено (1892–1974) хезмәтләре белән бәйле. Үз хезмәтләрендә ул социометрия (лат. societas — җәмгыять һәм грек. metreo — үлчим) алымына нигез сала. Социометрия — төркем эчендәге мөнәсәбәтләрне аралашуның әлеге төркем өчен әһәмиятлерәк булган хәлләрен колачлаучы критерийлар буенча үлчәү ул. Социометрия алымы шуңа корылган: төркемдәге мөнәсәбәтләрне билгеләү кешеләрнең сайлау хәлләрендәге үз-үзләрен тотышлары белән бәйле. Социометриядә мондый хәлне махсус сораулар — социометрик

критерийлар китереп чыгара. Мәсәлән: «Сез сыйныфта кем белән дежур торырга теләр идегез?» яки «Сез театрга кем белән барыр идегез?» Сораулар төркем әгъзалары арасындагы үзара мөнәсәбәтләр характерын ачарлык һәм аларны тартылу, этәрү яки битарафлык итеп квалификацияләрлек итеп формалаштырыла.

Иң гади вариантта социометрик алым төркемгә кергән барлык кеше гамәлгә ашыра торган сайлап алуларны анализлаудан гыйбарәт. Өстәвенә, әһәмияте дәрәҗәсенә карап, бер сайлау (мәсәлән, сорау нигезендә бер кешене күрсәтү таләп ителә) яки берничә сорау («Беренче чиратта, икенчесендә, өченчесендә һ.б. сез кемне сайлыйсыз?»). Мондый алым ярдәмендә төркемнең һәр әгъзасының шәхесара мөнәсәбәтләр системасында торган урынын билгеләп була.

ТӨРЛЕ ҮСЕШ ДӘРӘҖӘСЕНДӘГЕ ТӨРКЕМНӘРДӘ ИНТЕГРАЦИЯ

Кече төркемне өйрәнү аспектларының берсе — **төркем интеграциясе** (лат. integer — бөтен) — **төркемнең социаль бергәлек буларак психологик бердәмлеге, аның бөтенлеге билгеләре белән характерланучы халәте.**

Төркем интеграциясенең дәрәҗәсен төркемнең бергәлек буларак үсеш дәрәҗәсе белән бәйлиләр. Тикшеренүчеләр, беренчедән, югарыда әйтелгән барлык төр мөнәсәбәтләрнең шактый дәрәҗәдә дифференцияләнгән системасы урнашкан, икенчедән, бу мөнәсәбәтләр социаль нормаларга туры килгән һәм җәмгыять тарафыннан шәхескә һәм социаль бергәлеккә куйган таләпләргә җавап биргән, әхлакый булган кече төркемнәрне үскән дип исәплиләр.

Хәзерге заман Россия психологы А.В.Петровский теориясе нигезендә төркемне шартлы рәвештә өч катламнан тора дип күзалларга була. Һәр катлам төркем әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләр төзелешенең аерым принцибы, димәк, интеграция дәрәҗәсе белән дә бәйле. Беренче, өстәге катламда кешеләр арасындагы бер-береңне эмоциональ кабул итүгә, кабул ителүгә яки ителмәүгә нигезләнгән турыдан-туры контактлар урын ала. Әлеге катлам төркем үсешенең беренче стадиясенә туры килә. Икенче катламда уртак эшчәнлеккә корылган мөнәсәбәтләр була. Өченче катламда төркемнең барлык әгъзаларының төркем эшчәнлегенең бердәм максатларын кабул итүгә нигезләнгән мөнәсәбәтләр үсә. Бу катлам төркем үсешенең иң югары дәрәҗәсенә туры килә. Төркем интеграциясе турындагы күзаллаулар өч катламдагы күзаллаулар нигезендә корыла. Төркем интеграциясе турында, бер яктан, кешенең

төркем һәм аның әгъзалары белән тәңгәллеге, ягъни төркемгә керүен аңлавы һәм кичерүе (беренче катлам чагылу), икенчедән, конкрет уртак эшчәнлек шартларында индивидуаль эшгамәлләрнең оптималь туры килүе, гомуми бурычларны хәл иткәндә төркем әгъзаларының үзләрен функциональ-рольле тотышының килешенгәнлеге дәлилле (икенче катлам чагылу). Ниһаять, төркем интеграциясенең тагын бер күрсәткече — төркем әгъзаларының төркемнең тормыш эшчәнлеге өчен әһәмиятлерәк булган объектларга карата күзаллауларының, позицияләренең, ориентлашуларының, фикерләренең туры килүе дәрәҗәсе (өченче катлам чагылу).

> **Бездә барысы да социаль, ләкин бу аерым кешенең психикасының барлык сыйфатлары да әлеге төркемнең барча әгъзаларына хас икәнлекне аңлатмый.**
>
> **Л.С.Выготский**

Төркем интеграциясе төркемнең чагыштырмача тотрыклы һәм туктаусыз яшәвендә барлыкка килә. Төркем интеграциясенең мөһим, даими эшләүче факторлары — *туплангалык, җитәкчелек һәм лидерлык процесслары.* Алар турында сез алдагы параграфларда белерсез.

Экспериментал мәгълүматларга караганда, төркем интеграциясенә булышлык итүче процессларга «Без» хисе барлыкка килүне һәм аның сизелерлек көчәюен (мәсәлән, төркем арасындагы ярышларда) кертәләр. Моннан тыш төркем интеграциясенә һәрвакыт төркем нормаларын һәм үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен көчәйтүче конфликтлы хәл йогынты ясый.

Шунысын истә тотарга кирәк: төркем интеграциясенең кире ягы да бар. Аның белән «Без» тойгысы «Мин» тойгысыннан көчлерәк булып әверелгәндә *төркемдәге шәхеснең деиндивидуальләшүе* процессы бәйле. Моның үз тәртибең өчен индивидуаль җаваплылыкның йомшаруына китерүе мөмкин. Мәсәлән, кайчак кешеләр үзе генә эшләргә теләмәгәнне бергәләп эшлиләр. (Әгәр кемгә дә булса дәрестән качарга туры килсә, моның ялгыз гынамы яки сыйныфташлар белән бергәме эшләнүен исегезгә төшерегез. Теге яки бу очракта сез үз гамәлегез өчен җаваплылыкны ни дәрәҗәдә тойдыгыз?) Шәхеснең деиндивидуальләшүе, аерым алганда, аерым параграфта каралачак антисоциаль характердагы төркемнәрдә барлыкка килә.

Гуманлы кыйммәтләргә нигезләнгән төркемнәрдә интеграция яхшы шәхси, эмоциональ уңайлы, ышанулы, дустанә мөнәсәбәтләр барлыкка килү һәм үсү белән бәйле. *Дустанә мөнәсәбәтләргә* **кешеләрнең бер-берсенә тирән эмоциональ якынлыгы хас.** Мондый мөнәсәбәтләр бер-береңә игътибар, киң күңелле-

лек, чаманы белү, хөрмәт, авыр вакытларда ярдәм итү, бер-береңнең кайгысын һәм шатлыгын уртаклашу белән тәэмин ителә.

Кече төркемдә дустанә мөнәсәбәтләр яшүсмерләр һәм өлкән мәктәп яшьтәшләренең шәхесара мөнәсәбәтләрендә иң мөһим үзенчәлекләрнең берсе булып тора. Дустанә төркемнәргә барлык балалар, үсмерләр һәм яшүсмерләр дә диярлек керә. Укучы өлкәнрәк булган саен, аның андый төркемнәргә булган ихтыяҗы шулкадәр күбрәк, чөнки ул аларда үзен тигез, кабул ителгән, кирәкле дип тою мөмкинлеге ала.

Төп төшенчәләр: кече төркем, шартлы төркем, референт төркем, төркем интеграциясе, дустанә мөнәсәбәтләр.

Терминнар: төркем нормалары, социометрия, деиндивидуальләшү.

Үзегезне тикшерегез

1. Кече төркемнең аерымлык билгеләрен атагыз. Аның төп характеристикасы дип нәрсәне саныйлар? 2. Система буларак кече төркемнең өч билгесен күрсәтегез. 3. Шартлы, реаль һәм лаборатор төркемнәргә билгеләмә бирегез. 4. Кече табигый төркемнәр нинди була? 5. Индивид үзенең тәртибен аларның кыйммәтләре, нормалары, күрсәтмәләре белән тиңләгән төркемнәр ничек атала? Аларны тасвирлагыз. 6. Кече төркемдәге мөнәсәбәтләр төрләрен сурәтләгез. 7. Кече төркемне тикшеренүнең социометрик алымы нәрсәдән гыйбарәт?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Дәресләрдән соң компьютер сыйныфларында персональ компьютерларда эшләүче төрле сыйныф укучыларын «кече төркем» дип атап буламы? Үз җавабыгызны дәлилләгез.

2. Кече төркем башкарган вазыйфаларга социальләштерү һәм психологик яклау вазыйфаларын кертәләр. Белемнәрегезгә таянып, аларның һәрберсенең эчтәлеген ачыгыз.

3. Параграф текстына таянып фаразлагыз: мәктәп сыйныфы яки спорт командасы кебек төркемнәргә керүче яшь кеше ни өчен хокук нормаларына каршы эш итүе белән аерылып торган компания нормаларына ориентлаша башлый? Эчтәлекле җавап бирү өчен сезгә параграфның нинди төшенчәләре кирәк булачак?

4. Сез кергән берничә төркемдә катнашуыгызның индивидуаль максатларын билгеләгез. Әлеге төркемнәрнең кайсылары сезнең өчен — әгъзалык, кайсылары референт төркемнәр?

5. Тикшеренүчеләрнең кайберләре референт төркемне ни өчен «эталонлы» дип атый?

6. Башка сыйныфлар белән ярышканда сезнең сыйныф

белән ни булганын күзәтү үткәрегез. Сыйныфташларыгызның үзләрен ничек тотуын; уңышсызлыкка очраганда бәхәсләшү һәм үпкәләүме, әллә бер-береңне яклаумы өстенлек итүен; өлкән һәм кече башка сыйныфларда ни булганын теркәп куегыз. Кече төркем булган сыйныфларда бара торган процессларның аның үсеш дәрәҗәсенә ничек бәйле булуы турында нәтиҗәләр чыгарыгыз.

Чыганак белән эшләгез

Бүгенге заман Россия психологы А.А.Бодалевның «Социаль-психологик теория нигезләре» дигән китабыннан өзек китерелә.

Аның тәэсирендә ахыр чиктә безнең алда нинди шәхес булуы һәм аның чынбарлыкның төрле якларына мөнәсәбәте аны башка кешеләрдән аерып торуы бәйле булган мөһим фактор — кече төркем — шәхес кергән һәм аларның әгъзалары белән көн саен турыдан-туры бәйләнештә торган гаилә, мәктәп сыйныфы, эшчеләр бригадасы, эшмәкәрләрнең зур булмаган берләшмәсе һ.б. ул.

Һәркемнең һәркем белән аралашуының турыдан-турылыгы, аларның төркемнең үзендә дә, аннан читтә дә барлык кеше күз алдында эшләнә торган вакыйгаларга, әлеге төркемгә керүче һәркемнең уңай яки тискәре мәгънәдәге мәнфәгатьләренә кагыла торган гамәлләргә үз карашларын даими рәвештә чагылдыруы сәбәпле, төркемнең күп төрле һәм күп юнәлешле, матди һәм рухи формалардагы тормышы шәхес үсешенә йогынты ясый, һәм ул әлеге төркем шәхес өчен психологик яктан никадәр әһәмиятлерәк булса, шулкадәр көчлерәк. <...>

Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең һәм аларның кешеләргә йогынтысының үзенчәлеге тагын шунда: аларда бер кеше икенче берәү белән аралашып кына калмый яки бер кеше икенче кешегә шундый кеше итеп кенә карамый, алар һәрвакыт бер-берсе белән билгеле бер иҗтимагый төркемнәр — җенси, яшь, профессиональ, милли һ.б. төркемнәр вәкилләре буларак үзара эш итәләр. Аларның һәрберсенең теге яки бу төркемдә булуы җәмгыятьтә үзеннән-үзе аңлашыла торган дип исәпләнүче, әлеге төркем вәкиле — ир-ат, укытучы, ир, әти, һ.б. өчен социаль нормаль тәртип таләп итә.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Шәхес формалашуының мөһим факторы итеп автор нәрсәне саный? 2. Текстта нинди кече төркемнәрнең мисаллары китерелгән? 3. Кече төркемнең шәхескә йогынтысының автор аерып күрсәткән сәбәпләрен һәм чагылышларын атагыз. 4. Авторның төркемнең шәхеснең үсешенә йогынтысы «әлеге төркем шәхес өчен психологик яктан никадәр әһәмиятлерәк булса, ул шулкадәр көчлерәк» дигән фикере параграфта ачылган нинди төшенчәгә туры килә?

§ 35. Төркемдәге тупланганлык һәм үз-үзеңне конформлы тоту

Исегезгә төшерегез:

кайсы берләшмәдә катнашырга икәнен кешеләр һәрвакытта да сайлый алалармы? Эшчәнлек һәм аралашуның нәтиҗәлелегенә нәрсә ярдәм итә? Кешенең фикеренә һәм бәя бирүенә социаль тирәлек ничек йогынты ясый? Социометрия алымы белән нәрсәне өйрәнеп була?

Социаль-психологик яктан кече төркем кешеләрне механик рәвештә берләштерүдән түгел, ә аларны үзенең һәр әгъзасына йогынты ясаучы бергәлеккә туплаудан башлана. Төркемнең аңа кергән кешегә ничек йогынты ясавын аңлау өчен социаль психологлар *төркем тупланганлыгын* һәм *төркем басымын* өйрәнәләр. Төркем тупланганлыгы процессы төркем әгъзаларының аның максатларын, норма һәм кыйммәтләрен *аеруы* белән турыдан-туры бәйләнгән. Төркем басымы процессы (соңгы вакытта аны еш кына «төркемнең социаль йогынтысы» дип атыйлар) төркемгә яңа кергән һәр индивидның аның тормышы нормаларын *кабул итүе*, димәк, төркемнең индивидны *буйсындыруы* белән бәйле. Индивидның төркем басымына буйсынуы дәрәҗәсен *чагылдыручы позициясе «конформлык»* дигән исем алды. Әлеге параграфта сүз барачак тупланганлык һәм конформлык мәсьәләләре тикшеренүчеләрне инде күп дистә еллар дәвамында борчып килә.

ШӘХЕСАРА СЫЕШУ

Аралашуда һәм уртак эшчәнлектә төркемнең һәр әгъзасына даими рәвештә төркемнең башка әгъзалары белән эш итәргә туры килә. Әлеге эш итүнең нәтиҗәлелеге күп яктан кешеләрнең төркемдә никадәр сыеша, бер-берсенә яраша алулары белән билгеләнә. «Төркем әгъзаларының сыешуы,— дип яза илебезнең бүгенге социаль психологы Г.М.Андреева,— төркемнең әлеге составының төркем тарафыннан аның вазыйфаларын үтәвен, төркем әгъзаларының үзара эш итүен тәэмин итү өчен яраклы булуын аңлата».

Уртак эшчәнлек шартларында конфликтсыз аралашу һәм эш-гамәлләрнең килешенгәнлеге мөмкинлеге сыешуның нигезендә ята.

Әдәбиятта сыешуны симпатия-антипатия нигезендә (ягъни эмоциональ эчтәлектә) сурәтләүне дә очратып була. Мәсәлән, бер авторлар шәхесара сыешуны аралашу һәм уртак эшчәнлек

буенча партнерларның үзара бер-берсен кабул итүләре дип карый. Икенчеләре сыешуны үзара тәэсир итешүче шәхесләрнең, аз психологик «чыгымнар» тотып, эшчәнлекнең күп нәтиҗә бирүче ярашуы нәтиҗәсе дип исәпли. (Уйлагыз: китерелгән әлеге билгеләмәләрнең һәркайсы сыешуның югарыда сурәтләнгән мәгълүматлары белән ни рәвешле бәйләнгән?) Ниһаять, сыешуны эшчәнлекнең уңышлылыгы белән бәйлиләр. Ләкин кайбер тикшеренүчеләр шәхесара мөнәсәбәтләр нигезендә формалашучы психологик сыешуны һәм төркем әгъзаларының *профессиональ* эшчәнлектә формалашучы һәм чагылучы бергә эшли алуын аерып күрсәтәләр.

Шәхесара сыешу уртак тормыш эшчәнлегенең катлаулы шартларында (космоска очуда, экспедициядә, альпинистлар походында һ.б.), ягъни гомуми максатка средстволар, вакыт, иркенлек, катнашучылар саны җитмичә ирешкәндә аеруча әһәмият ала. Мәсәлән, космик корабльнең кешеләр озак вакыт очыш дәвамында яшәгән һәм эшләгән кысрык, тар шартларны күз алдыгызга китерегез. Монда экипаж әгъзаларының үзара сыешуының ничек мөһим булуы турындагы нәтиҗәне үзегез дә бик җиңел чыгара аласыз.

Шәхесара сыешуны ачыклау белән оештыру, авиация, космик, гаилә психологиясе өлкәсендәге белгечләр шөгыльләнә. Сыешуны өйрәнү турындагы күзаллауны, мәсәлән, төркемдә төрле типтагы шәхесләр вәкилләренең берничә парының үзара тәэсир итешүен өйрәнү бирә. Аларның берсе — өстенлекле, икенчесе буйсынулы булган очракта, алар уңышлы эш итәләр. Әмма әгәр алар бер типтагы шәхес вәкилләре булсалар, алар арасында йә конфликтлар туа (икесе дә өстенлекле булырга теләсә), яисә (икесе дә буйсына гына алса) максатка берничек тә ирешелми.

Шәхеснең тибы — төркемдәге кешеләрнең сыешуына йогынты ясаучы күпләгән аспектларның берсе генә. Шәхесара сыешу кыйммәти ориентлашуның, социаль омтылыш, мәнфәгать, мотив, ихтыяҗ, характер, темпераментларның, физиологик реакцияләрнең темпы һәм ритмының, шәхесара эш итү өчен әһәмиятле булган индивидуаль-психологик характеристикаларның оптималь ярашуына (охшашлыгына һәм бер-берсен тулыландыруына) нигезләнә дип исәпләнелә.

Психологик *сыешмау*, сез инде фаразлый алганча, кыйммәти ориентлашулар төрле булуда, бер-береңне кабул итә алмауда, акыл һәм хәрәкәт реакцияләре тәңгәл булмауда, игътибарда, фикерләүдә һәм шәхеснең уртак эшчәнлеккә һәм, аеруча мөһим, кискен хәлләрдә эш-гамәлләрне килештерүгә комачаулык итүче башка сыйфатларындагы аермалыкларда чагыла.

Сыешу абсолют була алмый дип исәплиләр. Ул һәрвакыт нинди дә булса конкрет эшчәнлеккә яки үзара тәэсир итү өлкәсенә кагыла. Сыешуның югарырак яки түбәнрәк дәрәҗәләре була. Төркем сыешуының түбән дәрәҗәсен төркем әгъзаларының темпераментлары һәм характерларының психофизиологик сыешуы, алар уртак эшләр башкаргандагы сенсормотор килешүчәнлек, коммуникатив эчке-төркем элемтәләренең интенсивлыгы тәшкил итә. Төркемдә сыешу функциональ-рольле көтүләрнең — төркем әгъзаларының уртак эшчәнлек оештырганда һәркемнең нәкъ менә нәрсә, кем белән һәм нинди эзлеклелектә эшләргә тиешлеген күзаллауларының — килештерелгәнлеге булып тора. Төркемдә сыешуның югары дәрәҗәсе үз чагылышын төркем әгъзаларының үзара референтлыгында, аларның кыйммәти-ориентлашуы берлегендә (бу хакта сүз алдарак булыр) таба. (Уйлагыз: сыешу дәрәҗәләре инде сүз булган төркемнәрнең шартлы катламнары белән ничек бәйләнгән?) Сыешуның югары дәрәҗәләренең түбән дәрәҗәләренә йогынты ясавы төркемдә сыешуны яхшыртуы мөмкин. Мәсәлән, кыйммәти ориентлашуларның охшашлыгы характерлар, хәрәкәт реакцияләре туры килмәве аркасында килеп туган каршылыкларны булдырмый кала ала h.б.

Шәхесара сыешу критерие — партнерларның үзара тәэсир итү нәтиҗәсе һәм, иң мөһиме, процессы белән нык канәгатьләнүе. Шәхесара сыешу, кагыйдә буларак, үзара симпатия барлыкка килү белән бергә бара һәм күп яктан *төркемнең тупланганлыгында* сизелә.

ТӨРКЕМНЕҢ ТУПЛАНГАНЛЫГЫ НӘРСӘДӘ ЧАГЫЛА

Төркемнең тупланганлыгы *төркемнең аның әгъзалары өчен җәлеп итүчәнлеге дәрәҗәсе* белән билгеләнергә мөмкин. Әгъзаларның төркемгә карата мөнәсәбәте яхшырак булган саен, төркем тупланганлырак була, һәм киресенчә. Төркемдә сыешуның башка — килешү, кыйммәти ориентлашулар һәм карашлар охшашлыгы нәтиҗәсе буларак билгеләмәсе дә бар. Кеше омтылышлары һәм карашлары белән килешкән кешеләр арасында булырга тырыша.

Төркемнең тупланганлыгы аның составы төркемдә үз вазыйфаларын башкара алуын гына түгел (сыешуны характерлау уңаеннан югарыда нәкъ шуңа басым ясалды), төркем әгъзаларының яхшырак интеграцияләнүен һәм төркем максатларын һәм кыйммәтләрен күбрәк уртаклашуын аңлата.

Тупланганлыкны өйрәнүгә төрлечә якын килүләр бар. Күп кенә тикшеренүчеләр тарафыннан тупланганлык эмоциональ

күренеш буларак өйрәнелә һәм төркемнең эмоциональ җәлеп итүчәнлеге һәм анда катнашучыларның эмоциональ бәясе белән билгеләнә. Мондый караштагылар еш кына тупланганлыкны кешенең төркемдә булудан канәгатьләнү хисе алуы белән бәйли. *Төркемнең тупланганлыгының конкрет күрсәткечләре* сыйфатында, кагыйдә буларак, түбәндәгеләр карала: 1) шәхесара мөнәсәбәтләрдә үзара симпатия дәрәҗәсе — төркем әгъзаларының никадәр күбесе бер-берсенә ошаса, аның тупланганлыгы да шулкадәр югарырак; 2) төркемнең аның әгъзалары өчен җәлеп итүчәнлеге дәрәҗәсе — күпме күбрәк кеше төркемдә булуыннан канәгать булса, аның тарту көче, димәк, тупланганлыгы да шулкадәр югарырак; 3) төркемдә индивидның төрле ихтыяҗларының канәгатьләндерелүе дәрәҗәсе — төркемдә күбрәк ихтыяҗ канәгатьләндерелгән саен, анда катнашу сәбәбе, ягъни *сәбәпле тупланганлык* та шулкадәр югарырак (индивид төркемдә канәгатьләндерә ала торган *төп ихтыяҗларга* анда булуга, аралашуга, ярдәмгә, хакимлек итүгә, абруйга, хөрмәткә, үзен күрсәтүгә булган ихтыяҗлар керә).

Икенче тикшеренүчеләр тарафыннан тупланганлык килешү, кыйммәти ориентлашулар һәм карашлар охшашлыгы нәтиҗәсе буларак карала. Төркемнең төп эшчәнлегенең турыдан-туры максатлары белән бәйле рәвештә, төркем әгъзаларының карашлары, позицияләре, омтылышлары, фикерләре, бәяләмәләре һәм эш-гамәлләре килештерелгәнлегенең югары дәрәҗәсе төркемнең кыйммәти-ориентлы бердәмлеге дип атала. Кыйммәти-ориентлы бердәмлекне болай карау яклылар төркем тупланганлыгының интеграль күрсәткече дип исәплиләр.

Ачык чагылып тормаган тупланган төркем турында таркау төркем буларак сөйлиләр.

Тупланганлык халәте төркем үсеше өчен дә, конкрет һәр кеше өчен дә бик тә зур кыйммәткә ия. Төркемнең мондый халәте эшчәнлекнең нәтиҗәлелегенә булыша (тупланган төркемдә кешеләр яхшырак эшли), төркемне тагын да тотрыклырак итә. Тупланганлык төркемгә кергән кешеләрнең психологик сәламәтлеген яхшырта: үзбәяне күтәрә, борчылуны киметә, кешедә аның өчен кыйммәтле булган шәхси якланганлык халәте тудыра.

Төркемдә тупланганлыкны арттыруга булышлык итәргә сәләтле берничә *факторны* атыйк.

Аларның берсе — гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек. Ул үзара тагын да тыгызрак эш итүне таләп иткән саен, төркемнең потенциаль тупланганлыгы шулкадәр югарырак. Кызык, күңелле, мавыктыргыч гамәлләр тупланганлыкны арттыруга булышлык итүче уңай эмоцияләрне уртак кичерүгә китерә.

Аннары төркемдә уртак эшчәнлек уңышының тарихын аерып күрсәтергә кирәк. Андый уңышлар күбрәк булган саен, тупланганлык та шулкадәр югарырак.

Төркем тупланганлыгына төркем әгъзаларының шәхси үзенчәлекләре өлеш кертә. Кемнең сыйфатлары үзенекеләргә якынрак, кешеләр шуңа тартыла. Төркемдә андыйлар күбрәк булган саен, ул шулкадәр тупланганрак.

Тупланганлыкны арттыруга төркемдә булган стимуллар, шул исәптән бүләкләүләр, мактаулар системасы ярдәм итә.

Социаль нормалар, кыйммәти ориентлашу, традиция, гореф-гадәт һәм йолалар туплау ролен үтиләр. (Сезнең сыйныфта, спорт командасында яки формаль булмаган дуслар төркемендәге норма, традиция һәм йолалар мисалларын китерегез.) Норма, традиция һәм йолаларның үзара бәйләнеше төркемнең тупланганлыгын аңлау өчен мөһим булган «Без» хисе нигезендә ята. Бу хисне — «Без» хисен — кайбер тикшеренүчеләр тупланганлык белән тәңгәлләштерәләр. Мәсәлән, социаль психология буенча бүгенге дәреслекләрнең берсенең авторы Дэвид Майерс (АКШ) болай дип яза: «Тупланганлык — «Без» хисе, төркем әгъзаларының бер-берсе белән элемтәсе дәрәҗәсе, мәсәлән, үзара симпатия исәбенә».

Тупланган төркем шуның белән характерлана: ул тышкы йогынтыларга каршы тора һәм төрле хәлләрдә үзенең бөтенлеген саклый ала. Тупланганлык аспектлары күптөрле. Болар — төркемдә *уртак хисләр, кәефләр һәм карашлар* булу да, читтән яки аерым катнашучылар тарафыннан ясалган йогынтыга *бәяләр* һәм *реакцияләр гомумилеге* дә, *үзара булышлык* һәм *үзара ярдәм итү* дә, төркемнең теге яки бу эшләре өчен *коллектив җаваплылык* алырга әзер торуы да. Һәлакәткә эләккән авиалайнерлар экипажлары әгъзаларының үз-үзләрен тотышлары, уртак реакцияләре һәм максатка юнәлдерелгән эш-гамәлләре белән пассажирларны коткарулары, мәсәлән, төркем тупланганлыгының мисалы булып тора. Күп кенә әдәби жанр һәм кинематография осталарының үз әсәрләренең нигезе итеп тупланган төркемнең эш-гамәлен чагылдырган сюжетларны алулары очраклы түгел. (Тупланган төркемнәрнең язучылар һәм кинематографистлар иҗат иткән сезгә билгеле образлары үрнәкләрен китерегез.)

Төркемнең тупланганлыгы шулай ук төркем (аны кайчак киң төшенчә белән «иҗтимагый» диләр) фикерендә дә ачыла. Төркем фикере төркем өчен уртак кызыксыну тудырган вакыйга һәм процессларны чагылдыра. Төркем фикере аның күпчелек әгъзасы уртаклашкан фикер йөртү формасында белдерелә. Карашларда тулы бердәмлек булмау төркем фикере

булмауны аңлатмый. Тикшеренүчеләр бу уңайдан анық формалашуының теге яки бу дәрәҗәсе турында сүз алып баралар. *«Төркемнең тупланганлыгы фикерләр бердәмлегендә чагыла»* дип раслап, алар, тупланган төркемдә төркем фикере белән бергә индивидуаль зәвыкларның, мәнфәгатьләрнең төп эшчәнлекнең эчтәлеге белән бәйле булмаган һәм аңа комачауламаган төрле һәм хәтта капма-каршы күренеше булырга мөмкин, дип билгеләп үтәләр.

Тупланганлыкны характерлаучы фикерләр һәм карашлар бердәмлеген төркемнең конформлык белән бәйле бертөрлелегеннән аерырга кирәк.

НӘРСӘ УЛ КОНФОРМЛЫК, ЯКИ КОРОЛЬНЕҢ ЯҢА КИЕМЕ

Сезнең күбегезгә бала чактан ук Ганс Христиан Андерсенның шәрә король турындагы әкияте таныш. Әлеге әкиятнең геройлары гомуми фикергә буйсыналар һәм, чынбарлыкта булмаган нәрсәне мактап, хакыйкатькә каршы гөнаһ эшлиләр. «Башкалар кебек булмау»дан курку, уртак фикер белән килешмәүдән өркү әкияттә генә түгел, чын тормышта да бар. Күпчелек фикере белән килешкән кеше аралашуда үзенә проблемалар тудырмый, төркем аны яклый һәм хуплый. *Төркем көчләп таккан фикергә буйсыну* яклау табарга теләү яки гаепләүдән качарга тырышу, үз төркемеңә кабул итмәүләреннән курку белән бәйле.

Тикшеренүчеләр раслаганча, төркемдә урнашкан мөнәсәбәтләр, шулай ук төркемнәрнең кешеләргә йогынтысы кешенең хисләрен, фикер йөртүләрен һәм үз-үзен тоту нормаларын җайга салуның иң көчле чыганакларыннан санала. Шәрә король турындагы әкият — *конформлык* дип атала торган аерым социаль психологик күренешләрнең мисалы. Төркемдә шәхеснең конформлыгы феномены булу фактын Америка психологы Соломон Аш (1907–1996) раслый. Конформлык турында индивид белән төркем арасында конфликт булганда сөйлиләр, һәм бу факт төркем файдасына хәл ителә. Әлеге күренешнең асылы гадәти телдә тәмам билгеле эчтәлеккә ия һәм «яраклашучанлык» дигәнне аңлата. Фән **конформлыкны кешеләрнең үз-үзләрен тотышларындагы һәм максатларындагы башка кешеләрнең эш-гамәлләренә һәм үз-үзләрен тотышларына юнәлдерелгән үзгәрешләр дип билгели**.

Эчке һәм *тышкы* конформлык була. Тышкы конформлык индивидның (төркем әгъзасы булып калу теләгеннән) анық йогынтысына буйсынуы белән бәйле. Ул төркем белән тышкы килешүне генә күздә тота, бу вакытта кешенең эчке позициясе

кагылышсыз кала. Тышкы конформлыкны, гәрчә эчтән кабул итмәсәң дә, төркем таләпләрен үтәү белән тәңгәлләштерәләр. Эчке конформлык кешенең төркем фикере, аның таләпләре белән килешүе, аларны хуплавы белән бәйле.

Үзеңне конформлы тоту һәм уңай, һәм тискәре роль уйный. Бер яктан, ул, әгәр күпчелекнең фикере яки эш-гамәлләре дөресрәк булса, кешенең ялгыш фикерен яки үзен тотышын төзәтергә ярдәм итә. Икенче яктан, үзеңне конформлы тоту үзеңнең мөстәкыйль фикереңне яки үзеңне тотышыңны расларга комачаулый. Конформистлар уртак карарлар кабул итәргә булышалар, ләкин гадәттә бернинди дә яңалык тәкъдим итмиләр.

Кешеләрнең башка төр категорияләре — ризасызлык, кире кагу һәм хәтта куралмау очрату ихтималын белә торып та агымга каршы баручылар бар. Андый кешеләрне «киребеткән» дип тә атыйлар: алар төрле хәлләрдә башкалар фикеренә каршы төшәләр, төрле очракта каршы фикерне расларга тырышалар, кем әйтмешли, «үз сүзләрендә каталар». Андый кешеләрне *нонконформистлар* дип атыйлар. Нонконформистның андый ачык мисалы итеп: «Зинһар, миңа рәсем ясарга рөхсәт итмәгез, минем бит аз гына булса да рәсем ясыйсым килә»,— дип сораган баланы китерергә була.

Төркем позициясенә мөнәсәбәттә индивид позициясен характерлап, галимнәр индивидның төркем басымына буйсынуның *«үлчәме»* турында язалар. Әдәбиятта индивидның «акыллы» конформлык күрсәтүе яхшырак диган фикер очрый. Әйтик, дуслар белән очрашуга барырга җыенып, анда катнашучыларның ничегрәк киенүләре белән кызыксыну файдалы. Бу сорауга җавап табып, сез ала карга булып күренмәс өчен ничек киенергә икәнен белгели аласыз.

> **«Үз тирәлегенең даими куралмаучылыгына һәм битәрләвенә шулкадәр битараф һәм хиссез кешене ун мең кеше арасыннан да табып булмый».**
>
> Джон Локк (1632–1704), **инглиз философ-мәгърифәтчесе һәм сәяси фикер иясе**

Конформлык дәрәҗәсе нәрсә белән бәйле? Беренчедән, конформлык дәрәҗәсен төркемнең яңа булуы белән бәйлиләр — яңа төркемгә кергәндә индивид үз-үзен тотышында башкаларга иярергә тырыша, чөнки ул әле төркем кыйммәтләре һәм нормалары белән таныш булмый. Моннан тыш конформлык дәрәҗәсе социаль статус (ул түбәнрәк булган саен, конформлык шулкадәр югарырак булырга мөмкин) һәм төркемгә ияләшү,

ничек кенә булса да, анда булырга, катнашырга теләү белән бәйле. Шулай ук кешенең шәхес буларак характеристикасы (интеллект, борчылу, тәэсир көче һ.б.), җенесе, яше (кечкенә балалар өлкәннәргә караганда конформлырак) роль уйный. Мәдәният тә мөһим. Көнчыгышның коллективчылык җәмгыятьләре вәкилләре Көнбатышның индивидуальчелек җәмгыяте вәкилләренә караганда күпкә конформлырак. Ниһаять, конформлык дәрәҗәсе төркемнең тупланганлыгына бәйле: төркем тупланганрак булган саен, аның әгъзаларының конформлыгы шулкадәр югарырак, төркемнең аларга йогынтысы көчлерәк.

Төркемнең шәхескә йогынтысы турында сөйләүне тәгаллап, шуны билгеләп үтик: төркем басымына реакциясенә бәйле рәвештә, төркем әгъзасы түбәндәгечә була ала: 1) конформист, ягъни төркем фикере белән килешә һәм үз-үзен тотышын төркем басымы юнәлешендә үзгәртә; 2) нонконформист, ягъни төркем басымына каршы тора, үзенчә уйлый һәм эшли; 3) *үз-үзен билгеләүче шәхес* — төркем басымына сайлаулы реакция ясый, конкрет хәлгә карап, аның фикерен кабул итә, йә юк. Искә алынган әкияттә, король шәрә, дип белдереп, малай нәкъ шулай эшли.

Без монда «шәхеснең үз-үзен билгеләве» дигән атаманы сүзнең тар мәгънәсендә, индивидның төркемдә үзен аңа басым ясаган хәлләрдә ничек тотуына карата гына кулланабыз. Киң мәгънәдә «шәхеснең үз-үзен билгеләве» дигәндә социаль хәлне, профессияне, принципларны һәм үзеңнең шәхес буларак сыйфатларыңны белүгә нигезләнгән яшәү рәвешеңне аңлы сайлау процессын күздә тоталар.

Төп төшенчәләр: шәхесара сыешу, төркемнең тупланганлыгы, конформлык.

Терминнар: нонконформлык, шәхеснең үз-үзен билгеләве.

Үзегезне тикшерегез

1. Шәхеснең үз-үзен билгеләве нәрсә ул? 2. Уртак эшчәнлекнең катлаулы шартлары ни өчен шәхесара сыешуга югары таләпләр куя? 3. Төркемдә кешеләрнең сыешуына нәрсә йогынты ясый? 4. Төркемнең тупланганлыгы нәрсәдә чагыла? Аның күрсәткечләре дип нәрсәне атыйлар? 5. Төркемнең тупланганлыгы дәрәҗәсенә нәрсә йогынты ясый? 6. Нинди хәлләрдә төркемдә үзеңне конформлы тоту турында сөйләргә була? 7. Конформизмның өстенлекләре һәм кимчелекләре нәрсәдә? 8. «Конформизм» һәм «нонконформизм» төшенчәләрен нәрсә берләштерә?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Сезгә билгеле әдәби әсәрләр һәм нәфис фильмнар эчтәлекләренә таянып, шәхесара сыешу һәм төркемдә кешеләрнең тупланганлыгы мисалларын китерегез.

2. Төркем тупланганлыгының параграфта китерелгән ике билгеләмәсенең, сезнеңчә, кайсысы киңрәк?

3. Тикшерегез: сыйныфыгызның тупланганлыгын нинди уртак эш тагын да арттырырга мөмкин? Аны әзерләгез һәм үткәрегез.

4. Түбәндәге музыкаль традицияләрнең төркемнең тупланганлыгына ничек йогынты ясавы турында үз фикерләрегезне әйтегез:

а) барлык катнашучылар кулларын уң һәм сул яктагы күршеләре иңсәсенә салып, түгәрәк булып басып, яраткан җырларын җырлау традициясе;

б) учак яки шәм янында гитара уйнап җыр кичәләре үткәрү традициясе.

5. Кышкы көннәрнең берсендә тикшеренүчеләр үз ярдәмчеләренең 60 секунд дәвамында бернинди дә үзгәреше булмаган күккә карап басып торуларын сораганнар. Ярдәмчеләр күккә күбрәк карап торган саен, үтеп баручылар аларга шулкадәр күбрәк кушылган. Конформлык төшенчәсенә таянып, бу фактка аңлатма бирегез.

6. Г.М.Андреева нонконформлыкны «конформлыкның кире ягы» дип атый. Ничек уйлыйсыз: бу билгеләмә белән нәрсәгә басым ясала: нонконформистның бәйсез, мөстәкыйль позициясенәме, әллә аның төркемгә бәйлелегенәме?

7. Дусларыгызның кайсыларын сез конформистларга, ә кайсыларын нонконформистларга кертә аласыз?

Чыганак белән эшләгез

Ярты гасыр чамасы элек кешенең төркем басымына буйсынуын тикшергән танылган экспериментчыларның берсе Соломон Ашның бер тәҗрибәсенең барышы турындагы язмасыннан өзек китерәбез.

Аш сигез кешедән торган студентлар төркеменнән төрле озынлыктагы сызыкларны чагыштыруларын сорый. <...> Шактый җиңел мәсьәлә була бу. Төркем кешене ялгыш сайлауга этәрмәгән очракта, анда катнашучыларның 95% ы бертөрле 12 сызык таба; ә эксперименталь төркемдә катнашучылар өчен хәл үзгәртелә: алар үз күзләре белән күргәнгә каршы килүче социаль килешү нәтиҗәләре белән очраша. Сыналучылар үз фикерләрен әйткәнгә кадәр алар биш студентның (чынлыкта эксперимент ясаучылар ярдәмчеләренең)

ялгыш җаваплары белән килешкәннәрдер, күрәсең. Алданган катнашучылар сынауда үз фикерләрендә калганнармы, дөрес җавап биргәннәрме, әллә башкалар фикеренә ияргәннәрме? <...> Анда катнашучыларның бары тик 25% ы гына төркемнең ялгышын искә алмаган һәм бары тик дөрес кенә җавап биргән. Башка 75% үз тоюларына каршы җавап биргән һәм күпмедер дәрәҗәдә төркем фикеренә бирелгән. Гәрчә катнашучыларның берсе дә төркемнең барлык җаваплары белән килешмәсә дә, катнашучыларның берсе 12 очракның 11ендә төркем фикеренә кушылган. <...> башкаларга караганда иң күп ялгышучы булган һәм соңыннан, төркемнең башка әгъзаларының ышанган булып тоелулары аркасында ялгыштым, башкалар дөрес булып, мин генә ниндидер «иллюзия» корбаны булырмын дип уйладым, дигән. Аш тикшеренүе шуны күрсәтә: төркемнең ачык чагылган фикере белән очрашып, кешеләр гәрчә башкаларның ялгышуы ихтимал дип уйласалар да, аның белән килешәләр. Моннан тыш алар, төркем әгъзалары шактый ышанган булып тоелса, башкалар хаклы дип исәплиләр һәм үз тойгыларында икеләнәләр.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Соломон Аш параграфта бәян ителгән нинди социаль психологик күренешне өйрәнгән? 2. Алдагы параграфта алган белемнәрегезгә таянып, С.Аш җыйган студентлар төркемен социаль төркемнең кайсы төренә керүен билгеләгез. 3. Текстта экспериментның ничә этабы бәян ителгән? Шартлары һәм нәтиҗәләре буенча алар бер-берсеннән нәрсә белән аерылган? 4. Төркем йогынтысына бәйлелекләре буенча экспериментта катнашучылар ничек бүленгән? Эксперимент нинди нәтиҗәләр ясау мөмкинлеге бирә? 5. С.Аш экспериментларны кыска экспериментлар үткәргән вакытта очраткан таныш булмаган студентлар белән үткәргән. Үз тәҗрибәгезгә таянып, әгъзаларның яхшы мөнәсәбәте югары бәяләнә торган һәм төркем фикеренә таянучы тупланган төркемнең шәхескә йогынты ясавы мисалларын китерегез.

§ 36. Төркемдә бүленү һәм лидерлык

Исегезгә төшерегез:

сезгә кече төркемнәрдәге мөнәсәбәтләрнең нинди төрләре билгеле? Социометрия һәм социометрик сайлау ысулы белән нәрсәне өйрәнәләр? Формаль кече төркем нәрсә ул? «Социаль статус» һәм «социаль роль» төшенчәләренең мәгънәсе нәрсәдә?

Элегрәк каралган туплану һәм интеграция процессларыннан тыш төркемдә шәхесара тәэсир итүнең бүленүе һәм лидерлар — кече төркем тормышының төрле якларына билгеле бер йогынты ясаучы әгъзалары аерылып чыгу процесслары бара. Төркемнең тормыш эшчәнлеге процессында анда катнашучыларның берләре — өстенлекле, әйдәп баручы, икенчеләре буйсынучы позицияләр ала. Тикшеренүчеләр күп еллар дәвамында әлеге процессларны, бүленү механизмнарын, лидерлык табигатен һәм аның төрле чагылышларын билгеләп, махсус алымнар ярдәмендә тикшерәләр. Аерым алганда, төркемнең үсү процессын мәктәп сыйныфы мисалында күзәтәләр һәм өйрәнәләр.

ТӨРКЕМДӘ ШӘХЕСНЕҢ ТОТКАН УРЫНЫ

Төркемнең үз әгъзаларына мөнәсәбәте шунда чагыла: берәүләрне яраталар, икенчеләрен яратмыйлар, өченчеләрен искә дә алмыйлар, дүртенчеләрен кире кагалар. Фактта төркемдә *бүленү* — шәхесара мөнәсәбәтләр системасында төрле урын алган катнашучыларга аеру бара.

Төркемдәге психологик үзгәрешләр төркем активлыгының ике тенденциясенең — берләшү һәм бүленүнең үзара тәэсир итүе белән бәйле. Берләшү төркемнең бердәмлеген ныгытуда, шәхесара мөнәсәбәтләрне тотрыкландыруда һәм тәртипкә салуда чагыла. Бүленү төркем әгъзаларының эшлекле һәм хисси үзара элемтәләренең махсуслашуында, аларның функциональ һәм психологик статуслары аерылуында күренә.

Төркем әгъзаларының тоткан урыннары (статуслары) буенча аерымлыгын социометрик алым ярдәмендә белергә була. Социометрик алым һәм социометрик сайлау критерийлары турындагы беренче күзаллауларны сез кече төркемдә шәхесара мөнәсәбәтләрне өйрәнгәндә алдыгыз. Хәзер без тагын бер тапкыр социометриягә мөрәҗәгать итәбез, чөнки ул төркемдәге һәр әгъзаның социаль статусын — аның *төркем эчендәге иҗтимагый фикер иерархиясендәге урынын билгеләү* мөмкинлеге бирәчәк. Ранглар турындагы бу табельнең югары баскычын иң популярлары — «йолдызлар» һәм «лидерлар» алып тора. Анннары «күңелгә ятышлылар» һәм «өстенлеклеләр» китә. Анннары «түбәнсетелгәннәр», игътибардан мәхрүм ителгән «аерылганнар» һәм, ниһаять, кирәкмәсләр — «кире кагылганнар».

Аның нигезендә сайлау гамәлгә ашырылган критерий — мәсәлән, ялны үткәрүгә симпатия һәм антипатия булса (ягъни эмоциональ критерий), иң күп тавыш алган кеше — *социо-*

метрик йолдыз яки төркемнең эмоциональ лидеры. Әгәр сайлау эшлекле вазыйфалар критерие буенча эшләнсә, төп урынны төркемнең эшлеклелеген оештыручы *эшлекле лидер* ала. Еш кына «социометрик йолдыз» һәм «эшлекле лидер» төрле кешеләр була.

Төркемнең бүленүенә китерүче факторларны төркемнең төре (формаль яки формаль булмаган), аның эшчәнлеге, аның күпме вакыт яшәве, төркем әгъзаларының шәхси сыйфатлары белән бәйлиләр. Формаль булмаган төркемнәрдә күпчелек дәрәҗәдә кешеләрнең аралаша белү осталыгы, юмор хисе һ.б. шәхси сыйфатлар ачыла. Нәкъ менә шул сыйфатлар барыннан да элек социометрик сайлауга йогынты ясый. Формаль төркемнәрдә, (мәсәлән, хезмәт берләшмәләрендә) беренче планга оештыру сыйфатлары (эшне планлаштыру һәм оештыру, вазыйфаларны дөрес бүлү, эшләрне җайга салу) чыга. Формаль төркемнәрдә дә, формаль булмаганнарында да сөйкемсез, агрессив, конфликтлы, йомыкый, аралаша һәм элемтәләр урнаштыра белмәгән кешеләр кире кагыла.

НӘРСӘ УЛ ЛИДЕРЛЫК

Мөгаен, очратканыгыз бардыр, төркемнең билгеле бер әгъзаларына мөһим хәлләрдә карар кабул итү хокукы бирелә. Төркемнең андый әгъзасын *лидер* (ингл. leader — алып баручы) дип атыйлар. Лидер абруй казана һәм төркемдәге башка әгъзаларның үз-үзләрен тотуына һәм аңына сизелерлек йогынты ясый ала.

Шунысын билгеләп үтик, «лидерлык» атамасы «лидер» һәм «җитәкче» төшенчәләрендә аерма булмаган инглиз теленнән алынган. Рус телендә ике аерым атама бар, һәм илебез психологлары еш кына бу төшенчәләрне аерып карыйлар. Мәсәлән, лидер һәм җитәкче килеп чыгышлары белән аерылалар дип басым ясап күрсәтәләр: лидер — стихияле төстә, ә җитәкче максатка юнәлдерелгән рәвештә, социаль структуралар контроле астында алга чыгарыла. Лидерның эшчәнлек өлкәсе — кече төркем, ә җитәкче кече төркемне киңрәк социаль системада күрсәтә. Лидерлыктан аермалы буларак, җитәкчелек төрле санкцияләрне күздә тота. Бер үк вакытта шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: күп кенә психологлар җитәкче һәм лидер эшчәнлеген охшаш дип сурәтлиләр.

Лидерлыкның күпләгән билгеләмәсе бар. Аларның кайберләрен чагыштырыгыз.

Лидерлык — шәхесара мөнәсәбәтләр системасында өстенлек итү һәм буйсыну, йогынты ясау һәм башкару мөнәсәбәтләре.

Лидерлык — төркемнең башкаларга күбрәк йогынты ясау-

чы кайсы да булса әгъзасының үз-үзен тотышының психологик характеристикасы.

Лидерлык — төркемдә үзара эш итүнең инициаторы һәм оештыручысы буларак шәхеснең конкрет гамәлләре.

Лидерлык — төркемдә үзара мөнәсәбәтләр системасы; бу вакытта бер кеше инициатива белән чыга һәм төркемдәге эшләр, һәм аларның ихтимал булган нәтиҗәләре өчен җаваплылыкны үз өстенә ала, ә башкалар тәкъдим ителгән инициативага ияреpгә һәм моның өчен шактый тырышлык куярга әзер.

Уйлагыз: лидерлыкның әлеге билгеләмәләре бер-берсен нәрсә белән тулыландыра.

ЛИДЕРЛЫК РОЛЬЛӘРЕ

Лидерлыкны йөз ел чамасы өйрәнәләр. XX гасырның 50 нче елларында лидерлыкның ике фундаменталь роле аерып күрсәтелде — инструменталь (эшлекле, максатчан) лидер роле һәм социаль-эмоциональ (экспрессив) лидер роле. Беренче роль эшчәнлекнең максатына ирешү, төркем алдына куелган бурычны хәл итү өчен төркемне оештыруга юнәлдерелгән эшгамәлләрне колачлый. Инструменталь лидер — төркем бурычларын хәл итү һәм максатка ирешү өчен кирәкле зуррак белемнәргә һәм абруйга ия булган лидер. Икенче роль нигездә шәхесара мөнәсәбәтләргә кагылучы һәм аларны җайга салучы эшләрне күздә тота. Экспрессив лидер — төркем мәнфәгатьләрен, фикерен, кәефен чагылдыру, андагы киеренкелекне киметү сәләте аркасында төркемнең эмоциональ атмосферасына йогынты ясаучы лидер. Аңа башкаларның кичерешләренә битараф булмау, ул кичерешләрне аңлау, уртаклашу әңгәмәсе өчен вакыт табу хас.

Соңгырак тикшеренүләр, төркем тормышындагы хәлләрнең күптөрлелеге белән бәйләп, лидерлык исемлеген арттырдылар. Мәсәлән, илебез психологы Л.И.Уманский (1921–1983) лидерлык рольләрен тасвирлауны лидерлар гамәлгә ашыра торган вазыйфаларда төзеде. Ул лидер-инициаторларны, лидер-эрудитларны, лидер-эмоциональ кәеф генераторларын, лидер-осталарны аерып күрсәтте. Аның шәкертләре «үз эшләренең юнәлгәнлеге буенча лидер уңай яки тискәре булырга мөмкин» дип басым ясап, лидер-оештыручыларны һәм лидер-таркатучыларны аерып күрсәтергә тәкъдим иттеләр.

Лидерлык рольләрен тасвирлауны лидерлыкның ике процессы белән бәйлиләр. Алар — *формаль лидерлык* — кешеләргә биләгән вазыйфа карашыннан чыгып йогынты ясау процессы («җитәкчелек» атамасын да нәкъ шул мәгънәдә кулланалар) һәм *формаль булмаган лидерлык* — кешеләргә үзеңнең сәләт-

ләрең, осталыкларың һәм башка ресурслар ярдәмендә йогынты ясау процессы. Формаль лидер төркемдәге эшләрнең торышы өчен җаваплылык тота, хуплауга, җәза бирүгә рәсми хокукка ия була. Формаль булмаган лидерның хакимлек итү вәкаләтләре һәм рәсми бурычлары юк. Аның йогынтысы һәм абруе хезмәт урынына, вазыйфасына, статусына бәйле түгел. (Үзегезнең социаль тәҗрибәгезгә таянып, формаль һәм формаль булмаган лидерлык мисалларын китерегез.)

Әгәр вазыйфаи йогынты рәсми булмаган лидерлык белән яраша, төркемдә үзара яхшы мөнәсәбәтләр урнаша. Әгәр инде мондый туры килү юк икән, төркемдәге үзара мөнәсәбәтләр рәсми һәм рәсми булмаган лидерлар арасындагы мөнәсәбәтләргә бәйле булачак. Тискәре юнәлешле формаль булмаган лидер формаль лидер белән каршылыклы мөнәсәбәтләрдә булса, хәлләр бик үк яхшы булмый. Мондый очракта төркем эчке каршылыкларга һәм конфликтларга дучар булачак. Мондый хәлне күз алдына китерү өчен шуны исегезгә төшерегез: мәсәлән, сезнең сыйныфның старостасы һәрвакытта да сез чынлап хөрмәт итә торган, сезгә аның белән яхшы булган, үз артыннан ияртә торган, сыйныфны кызыклы һәм файдалы эшкә оештыра белгән кеше булдымы? Ул шулай булганда, сыйныфыгыз тормышының ул чорында старостагызда вазыйфаи йогынты белән формаль булмаган лидерлык бергә кушылган була. Ә хәзер инде исегезгә төшерегез: старостага комачаулау, аны кайбер укучылар белән талаштырырга тырышуы, аларны аның инициативасына каршы чыгарга котырту хәлләре булдымы? Һәм боларның барысы да тагын да кызыклырак һәм файдалырак эш тәкъдим итүдән түгел, ә болай гына, зыян салуга, сыйныф игътибарын, бик тә ихтимал, ул мизгелләрдә тискәре юнәлешле формаль булмаган бүтән берәүгә юнәлдерергә тырышудан булса?

ЛИДЕРЛЫК СТИЛЬЛӘРЕ

Төркемдәге мөнәсәбәтләр характеры һәм эшчәнлекне оештыру өчен лидерлык стиле зур әһәмияткә ия. Лидерлык стиле дип төркемнең башка әгъзаларына йогынты ясау өчен кулланыла торган алымнар җыелмасын саныйлар. Киң таралган стильләрне немец һәм америкалы психолог К.Левин (1890–1947) тасвирлый. Лидерлыкны һәм җитәкчелекне аермыйча, К.Левин өч стильне аерып күрсәтә: авторитар (директив), демократик (коллегиаль) һәм анархик (либераль).

Лидер-демократ коллегалары белән киңәшләшә, аларның инициативасын хуплый, дәлилләренә колак сала, төркем фикеренә йөз тота, бурычларын тикшерүне оештыра, вәкаләтләрнең бер өлешен төркем әгъзаларына бирә.

Авторитар лидер катгый тәртип урнаштыра, вазыйфаларны төгәл бүлә, төркем фикеренә колак салмый, бәхәсләр оештырмый, үз фикерен көчләп тага.

Лидер-анархист «нәрсә һәм ничек телисез, шулай эшләгез» принцибы белән җитәкчелек итә. Ул таләпләр куймый, көчләп такмый, төркем әгъзаларының барлык тәкъдимнәрен кабул итә, бәрелешүләрдән, конфликтлардан кача. Төркем практик яктан оешмаган, таркау, анда функциональ бурычлар теләсә ничек бүленә.

(Уйлагыз: сезнеңчә, лидерлыкның кайсы стиле нәтиҗәлерәк? Ничек уйлыйсыз, һәрвакыт, теләсә нинди хәлләрдә дәниндидер бер стиль булырга тиешме?)

Лидерлык стильләрен аеру шактый шартлы. Хәлнең торышына карап, лидер ешрак төрле стильне куллана. Шуңа да карамастан, теге яки бу лидерның стилен анализлап, билгеле бер өстенлекле сыйфатларны табып була.

Шуны билгеләп үтик: күп кенә лидерларның (җитәкчеләрнең) проблемасы шунда: аларның стиле төркемнең үсеш дәрәҗәсенә яки хәл ителә торган бурычлар характерына туры килми. Аерым алганда, бу күпләгән авторитар лидерларга кагыла. Баштарак алар таркау кешеләр массасыннан бердәм төркем оештыралар, аннары әлеге төркем андый лидерларны кире кага башлый — төркем үз үсешенең яңа дәрәҗәсенә чыга һәм аңа авторитар лидер кирәкми башлый.

УКУЧЫЛАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘГЕ ҮЗАРА МӨНӘСӘБӘТЛӘР

Үсмерләр һәм яшүсмерләр үз гомерләренең шактый өлешен үткәрә торган төркемнәрнең берсе — мәктәп сыйныфы. Аның мисалында эшлекле һәм эмоциональ шәхесара мөнәсәбәтләрнең үсешен, симпатия һәм антипатияләрне, шәхси элемтәләрнең тыгызлыгын, шәхеснең төркемнән канәгать булуын күзәтергә була.

Теләсә кайсы мәктәп сыйныфы укучыларының рәсми берләшмәсе — формаль кече төркем булып тора. Аның үзенең үзидарә органнары бар һәм үз-үзен оештыруга сәләтле була ала. (Сыйныфыгызның үзидарә органнары һәм укучыларның үзүзләрен оештыруы чагылган уртак эшләр мисалларын китерегез.) Башка формаль кече төркемнәр кебек үк, мәктәп сыйныфының җәмгыять йөкләгән уртак максаты бар. Мәктәп сыйныфы өчен андый максат — белем һәм тәрбия бирү максатлары — билгеле бер дәрәҗәдә белемнәр алу, осталыклар, күнекмәләр, эшчәнлек сәләтләре, әхлакый нормалар һәм үзүзеңне тотуның социаль хупланган принципларын үзләштерү.

Башка кече төркемнәр кебек үк, мәктәп сыйныфы психологик яктан кешеләрнең гомуми эшкә һәм бер-берсенә төрле мөнәсәбәтеннән тора. Уку, танып-белү эшчәнлеге укучыларның аралашуын һәм аның нигезендә урнашучы шәхесара мөнәсәбәтләрне булдыра.

Психолог В.Н.Мясищев (1893–1973) раслаганча, эшчәнлек, шул исәптән уку эшчәнлеге дә, нейтраль процесс булырга һәм, әгәр эшчәнлектә катнашучылар арасында иҗатташлыкны, хезмәттәшлекне, үзара ярдәмләшүне таләп итүче мөнәсәбәтләр урнаштырылмаса, шәхескә йогынты ясамаска мөмкин. Фәнни карашны раслау өчен В.Н.Мясищев педагог А.С.Макаренконың (1888–1939) яшьтәшләр төркеме мөнәсәбәтләренең шәхес үсешендәге роле турындагы нәтиҗәләреннән файдалана. Шәхесне төркемдәге мөнәсәбәтләрдән аеру мөмкин түгел. Шәхес еш кына килеп эләккән «кимчелекле» мөнәсәбәтләр аның үсешендә тайпылышларга китерә һәм, киресенчә, социаль нормаль мөнәсәбәтләр шәхеснең әхлакый һәм психологик сәламәт сыйфатларын үстерә.

Башка теләсә кайсы төркемнеке кебек үк, мәктәп сыйныфының үзенең үсеш баскычлары бар. Шунысы игътибарга лаек: бу баскычлар укучыларның үзләренең яшьләре үсә бару этаплары белән туры килми. Инде белгәнегезчә, алар тупланганлыкның төрле баскычлары һәм төркем активлыгының башка чагылышлары белән бәйле. Һәр мәктәп сыйныфы үсешнең тукталышлар, күтәрелүләр һәм төшүләр ихтимал булган катлаулы процессын үтә. Аерым хәл, мәсәлән, унынчы сыйныфны элек төрле мәктәпләрдә укыган укучылардан туплаганда барлыкка килә. Андый сыйныфлар үзенең үсешендә кече төркем психологик бергәлек буларак үткән юлның иң башында була. Әлеге сыйныф укучыларына төркем нормаларын һәм кыйммәтләрен эшләргә һәм үзләштерергә, тупланганлыкны үстерергә, лидерларны табарга туры килә. Мәктәптә өлкән сыйныфлар социаль-психологик үсешнең төрле дәрәҗәсенә ирешә ала. Әлеге дәрәҗәне билгеләү өчен, мәсәлән, түбәндәге сорауларга җавап алу мөһим: төркемдә барлыкка килгән эшлекле мөнәсәбәтләр төркемнең төп максатына туры киләме? Укучылар арасындагы шәхси мөнәсәбәтләр күпме үскән? Кемнең дә булса мәнфәгатьләре чикләнмиме? Җәмгыятьтә кабул ителгән законнар һәм әхлак нормалары сакланамы? Сыйныфның кече төркем буларак үсеш дәрәҗәсенең мөһим күрсәткече — уртак карарлар кабул итү процессы. Монда барысы да мөһим: тикшерү ничек бара, соңгы карар ничек кабул ителә, аның белән килешмәүчеләр үзләрен ничек тота, төркемдәге күпчелек аларның каршы килүенә (яшеренме, әллә ачыктаначыкмы) ничек карый. Кабул ителгән карарларның алга таба

ничек үтәлүе дә мөһим (ирекле яки билгеләп куелган җаваплы кешеләр бармы, лидер карарны тормышка ашыруга контрольлек итәме һ.б.). Мәсәлән, ике унынчы сыйныфны күз алдыгызга китерегез. Аларның берсендә төркем эчендәге үзара мөнәсәбәтләр бик тә әйбәт, барысы да бер-берсен яраталар һәм аңлыйлар, бәйрәмнәрдә бергә җыелалар, походларга баралар, ләкин шул ук вакытта укуда уңышлары төрлечә. Ә икенче сыйныфта укулары әйбәт, әмма анда һәрберсе үзе турында гына уйлый һәм контроль эш вакытында башкаларга шпаргалка ташламый. Теге яки бу сыйныфның кече төркем буларак үсеш дәрәҗәсен сез ничек бәяләр идегез? Аларның кайсысы социаль-психологик үсешнең югарырак дәрәҗәсе белән аерылып тора? Карар кабул итү өчен сез тагын нинди күренешләрне һәм процессларны күзәтергә теләр идегез?

Укучылардан шактый уртак тырышлык һәм зур эмоциональ киеренкелек таләп итми торган, алар өчен гадәти булган чагыштырмача гади бурычлар вакытында шәхси үзара мөнәсәбәтләр сыйныф эше нәтиҗәләренә сизелерлек йогынты ясамый. Әгәр алда укучылар өчен гадәти булмаган, килештерелгән, җайга салынган тырышлыклар, югары эмоциональ киеренкелек таләп итүче эшләр торса, социаль психологик яктан ныграк үскән төркемнәр яхшырак эшли. Бу, мәсәлән, төркем белән иҗади бурычларны, проект эшләрен башкарганда чагыла.

Хәзер игътибарны шуңа туплыйк: әйтик, мәктәп сыйныфында индивидлар гына түгел, ә башкаларга охшарга теләмәгән һәм башкаларның аларны тануын таләп иткән шәхесләр берләшкән ди. Әгәр сыйныфтагы мөнәсәбәтләр әлеге омтылышларны тормышка ашыру мөмкинлекләре тудырмаса, укучылар андый мөмкинлекләрне башка берләшмәләрдә эзли. Аларның күбесе үзләре теләп сыйныфтан тыш төрле укучылар берләшмәләренә кушыла. Аларга предметлы түгәрәкләр, фәнни-техник җәмгыятьләр, спорт секцияләре, иҗат студияләре, яшьләр клублары һ.б. керә. (Үзегезнең мәктәп тормышыгыздагы тәҗрибәгә таянып, исемлекне дәвам иттерегез.) Әлеге берләшмәләрдә укучыларның төрле мәнфәгатьләре канәгатьләндерелсә, аларның шәхесләре һәм индивидуальлекләре үсәргә мөмкин.

Сыйныф һәм сыйныфтан тыш укучылар берләшмәләре укучыларның формаль һәм формаль булмаган төрле мөнәсәбәтләре өчен шартлар тудыра, аларны бер-берсенә карата төрле позицияләргә куя. Төрле берләшмәләрдә *бер үк кеше төрле урын алырга мөмкин.* Укучы бер берләшмәдә лидер була, ә икенчесендә гади катнашучы булып кала ала. Мәсәлән, укучының позициясе крайны өйрәнүче турист позициясеннән калышса, лидерлык урынын укуда аерым уңышлары белән аерылып тормаган икенче берәү алырга мөмкин.

Укучылар берләшмәләре арасында кыска вакытка оештырылган төркемнәр мөһим роль уйный. Мәсәлән, җәйге каникуллар вакытында күп кенә мәктәпләрдә укучыларның хезмәт бригадалары булдырыла. Кыска вакытка оештырылган төркемнәрнең икенче мисалы — төрле сыйныф укучылары җәлеп ителергә мөмкин булган мәктәп бәйрәмен әзерләү өчен оештырылган төркемнәр. Һәр *вакытлы төркем* — укучы тормышындагы яңа социаль хәл. Ә бу төркемдә яңа статус, яңа роль, яңа шәхси казанышлар дигән сүз. Андый вакытлы берләшмәләр, бер яктан, укучының шәхесен формалаштыруда сизелерлек эз калдыра, икенче яктан даими, төп укучылар берләшмәсе — мәктәп сыйныфы эшчәнлегенә йогынты ясыйлар. Психологлар тарафыннан «шәхси казанышларны» укучыларның вакытлыча берләшмәләреннән даими эшләүчеләренә күчерү күренешләре тасвирланган.

Формаль булмаган төркемнәр — мәктәптә дә, аннан тыш та (мәсәлән, ишегалдында — күршедә яшәүче малай-кызлардан) барлыкка килүче танышлар һәм дуслар төркемнәре укучылар өчен аеруча әһәмиятле. Андый төркемнәрдә мөнәсәбәтләрнең ачыклыгы, эчкерсезлек, бәйсезлек, үзеңне күрсәтә алу ирекe бәяләнә. Андый төркемдә һәркем үз шәхесенең әһәмиятен тою мөмкинлеге ала, башкаларның аны тануыннан файдалана.

Төп терминнар: төркемдә бүленү, лидерлык.

Терминнар: лидер, лидерлык стиле.

Үзегезне тикшерегез

1. Кече төркемнең бүленүе нәрсәдә ачыла? 2. Кемне лидер дип атыйлар? 3. «Лидер» һәм «лидерлык» сүзләре синонимнар була аламы? 4. Лидерлыкның нинди рольләрен һәм нинди стильләрен аерып күрсәтү кабул ителгән? 5. Кече төркем буларак, мәктәп сыйныфы нидән гыйбарәт? 6. Укучыларның төрле берләшмәләре шәхеснең үсеше өчен нәрсә бирә?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Лидерның үз-үзен тотышының түбәндәге тәкъдим ителгән вариантларын карагыз:

а) лидер карарны үзе генә кабул итә һәм төркемгә белдерә;

б) төркем алдында торган проблеманы лидер төркемнең кайбер әгъзалары белән (барысы белән) чиратлап тикшерә, аннары үзе карар кабул итә һәм аны төркемгә белдерә;

в) лидер проблеманы бөтен төркем белән бергәләп тикшерә, аннары карарны үзе кабул итә һәм төркемгә белдерә;

г) лидер проблеманы бөтен төркем белән бергә тикшерә. Килештерелгән уртак карар кабул ителә;

д) лидер проблеманы төркемнең кайбер әгъзалары белән тикшерә, аннары бөтен төркемгә үзе катнашыннан башка гына карар эшләргә һәм кабул итәргә куша.

Лидерның үзен тотышы вариантларының һәрберсендә лидерлыкның нинди стильләре чагыла? Һәр вариантны сыйныфыгыз яки сез әгъза булып торган кече төркем (спорт командасы, яшьләр клубы һ.б.) тормышыннан конкрет хәлләр белән чагыштырып, лидерның үзен тотышының кайсысы максатка ярашлырак икәне турында нәтиҗә ясагыз.

2. Укучыларның үз сыйныфы һәм андагы мөнәсәбәтләр турында әйткәннәрен укыгыз. Аларны, кече төркем буларак, сыйныфның үсеш дәрәҗәсе арта барган эзлеклелектә урнаштырыгыз. Төзелгән эзлеклелекне дәлилләгез.

а) «Гомуми уңышсызлыклар һәркемнең күзенә ташлана, ә менә кем беләндер ялгызына нидер булса, аны күрүләре икеле»; б) «Безнең беребез дә үз сыйныфын башкага алыштырырга һичкайчан риза булмас иде; в) «Очрашканда без бер-беребез белән исәнләшәбез генә, безнең хәтта сөйләшер нәрсәләребез дә юк»; г) «Сыйныфта барыбыз да бер-беребезгә кирәк»; д) «Сыйныфыбызда мин үземне иркен тоям, чөнки без фикерләребез һәм тәэсирләребез белән уртаклашабыз».

3. Мәктәп тормышы тәҗрибәсенә һәм курс белемнәренә таянып, мәктәп укучылары эшчәнлеге төрләре исемлеген төзегез. Теге яки бу эшчәнлекнең төркемдәге мөнәсәбәтләрне үстерүгә ничек йогынты ясавын анализлагыз.

Чыганак белән эшләгез

Лидерлык процессларын тикшерүче Б.Д.Парыгин китабыннан өзек тәкъдим итәбез.

Лидерлык типологиясе моделе безнең карашка: а) лидер эшчәнлегенең эчтәлеген; б) стилен; в) характерын билгеләү белән бәйле төрле өч нигезләмәдә төзелергә тиеш. Мондый очракларда лидерлыкны бүлүнең түбәндәге төрләре турында сөйләргә мөмкин.

1. Эшчәнлекнең эчтәлеге буенча: а) үзеңне тоту программасын тәкъдим итүче лидер-рухландыручы; б) инде бирелгән программаны башкаруны оештыручы лидер-башкаручы; в) бер үк вакытта рухландыручы да, оештыручы да булган лидер.

2. Җитәкчелек итү стиле буенча: а) авторитар; б) демократик; в) үзендә теге стильнең дә, монысының да элементларын сыйдыручы.

3. Эшчәнлек характеры буенча: а) универсаль, ягъни үзенең лидерлык сыйфатларын даими күрсәтүче; б) ситуатив, ягъни лидер сыйфатларын фәкать билгеле бер махсус хәлләрдә генә күрсәтүче. <...>

Таррак һәм традицион мәгънәдә лидерлык төркемдәге бер кешенең үз артыннан башкаларны ияртү, аңа охшарга тырышу өчен үрнәк булу, үз тирәсенә башкаларны туплый белү һәм төркем эшчәнлегендә уңай нәтиҗә бирерлек эшләр инициаторы булу сәләте турындагы күзаллаулар белән бәйле. Әмма тормыш теләсә нинди лидерлыкның да кешеләрнең уртак эшчәнлеге өчен уңай нәтиҗә бирә алмавын күрсәтә.

Шунлыктан өч нигез — характер, стиль һәм масштаб буенча төзелгән лидерлык типологиясе турында без әйткәннәргә лидерның нәтиҗәлелеген бәяләү, дөресрәге, аның эшчәнлегенең юнәлгәнлеген бәяләү белән бәйле критерийларны да өстәргә кирәк. Бу критерий буенча лидерлыкны конструктивка (әгәр ул төркемнең уңышына һәм үсүенә ярдәм итсә) һәм, әгәр ул уртак эшләрнең нәтиҗәлелеген югалтуга китерсә һәм хәтта җәмгыятьне җимерү белән тәмамлануы ихтимал булса, деструктивка аерып булыр иде.

Шулай ук элек тәкъдим ителгән типологиягә лидер эшчәнлегенең предметлы юнәлгәнлеге белән бәйле критерийны өстәү дә дөрес булыр. Бу исә лидерлыкның сәяси, дини, фәнни, рухи, икътисади һ.б. төрлелекләре турында сөйләү мөмкинлеге бирер иде.

Һәм, ниһаять, лидерларны аларның энергетик активлыклары буенча яки, Л.Н.Гумилевның пассионарлык концепциясенә ияреп, аларның эмоциональ «йогышлылыгы» дәрәҗәсе һәм көче, алга куйган бурычын тормышка ашыру омтылышына бирелгәнлеге һәм, шуңа туры китереп, кече төркем лидерыннан бөтендөнья тарихында күренекле шәхес роленә кадәр эшчәнлек колачы буенча бүлү дөрес булыр.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Автор фикеренчә, лидерлык типологиясе нинди нигезләрдә төзелергә тиеш? 2. Параграф текстына таянып, автор тарафыннан һәр нигез буенча аерып күрсәтелгән лидерлык төрләрен тулыландырыгыз. 3. Аның юнәлгәнлеге, шул исәптән предметлы юнәлгәнлеге күзлегеннән караганда, лидерлык нинди була ала? Төрле юнәлгәнлекле лидерлар мисалларын китерегез. 4. Текстка таянып, «лидерлык» төшенчәсен киң һәм тар мәгънәдә характерлагыз.

§ 37. Гаилә — кече төркем

Исегезгә төшерегез:

нәрсә ул кече төркем? Кече төркемнең тотрыклылыгына шәхесара сыешу һәм төркемнең тулыланганлыгы ничек йогынты ясый? Бүгенге гаиләгә нинди билгеләр хас?

Күпчелек кешеләр өчен гаилә — әгъзалары никах яки туганлык мөнәсәбәтләре, уртак көнкүреш һәм үзара әхлакый җаваплылык белән бәйле социаль бергәлек ул.

Ләкин гаилә төшенчәсе үзе күпкә киңрәк, шуңа күрә дә гаилә төрле фәннәрнең тикшерену предметы булып тора. Мәсәлән, *этнография* үткәндәге гаилә көнкүрешенең үзенчәлекләрен, гаилә йолалары, гореф-гадәтләрен саклау механизмын тасвирлый һәм анализлый. *Социология* үз игътибарын гаиләнең социаль институт һәм кече социаль төркем сыйфатлары булган аерым социаль система буларак яшәвенә юнәлтә. *Гаилә һәм йорт хуҗалыгы икътисады* йорт хуҗалыгы һәм җитештерүе системасында гаилә әгъзаларының уртак эшчәнлеге үзенчәлекләрен ачыклауга йөз тота. *Гаилә хокукы* гаиләне никах, туганлык, уллыкка (кызлыкка) алу мөнәсәбәтләреннән килеп чыга торган хокуклар һәм бурычлар белән бәйле кешеләр даирәсе буларак, шулай ук никах төзегәндә яки аны юкка чыгарганда һәм тулаем гаилә яки аның аерым әгъзалары мәнфәгатьләренә кагылганда гаилә хәле мәсьәләләрен карый. *Демография* халыкның гаилә структурасын, гаиләнең күләме һәм составы, теге яки бу гаилә структураларының таралганлыгы турындагы демографик статистика мәгълүматларыннан файдаланып, аның җенес-яшь структурасы белән үзара бәйләнештә анализлый. *Социаль психология* гаиләдәге шәхесара мөнәсәбәтләр закончалыкларын, аларның тотрыклылыгы күзлегеннән гаилә эчендәге мөнәсәбәтләрне тикшерә. *Педагогика* гаиләдә балаларны тәрбияләү мәсьәләләрен карый.

Әлеге дәрес кысаларында без кече төркем буларак гаиләнең психологик-педагогик аспектын карарбыз; социаль институт буларак, аның үзенчәлекләренә соңрак (11 сыйныфта) тукталырбыз.

КЕЧЕ ТӨРКЕМ БУЛАРАК ГАИЛӘНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Башка социаль төркемнәр белән чагыштырганда, гаилә күп мөнәсәбәтләрдә бөтенләй дә аерым хәлдә тора. (Төп мәктәптә җәмгыять белеме дәресләрендә гаилә турында нәрсәләр белүегезне исегезгә төшерегез.)

Гаиләне кече төркем буларак карап, галимнәр психологик элемтәләрнең ролен аеруча басым ясап күрсәтәләр. Гаиләнең нинди мөнәсәбәтләр нигезендә оештырылуы турындагы сорау монда аерым әһәмияткә ия түгел. Исегезгә төшерик: мондый нигезләр йә никах, йә кан туганлык (мәсәлән, ана һәм балалар), йә булмаса торак һәм бюджет бергәлеге (никахсыз гына) булырга мөмкин. Иң мөһиме, бу кешеләрне үзара ярдәм итешү,

бер-берсе өчен, балалар, аларның сәламәтлеге һәм тәрбиясе өчен үзара җаваплылык мөнәсәбәтләре берләштерә.

Гаилә — кешеләрнең мәхәббәт, мәнфәгатьләр уртаклыгы, бер-берeңә ярдәм итү, бер-берeңнең проблемаларын һәм шатлыкларын үзара аңлау нигезендә берләшкән берлеге ул. Гаилә мөнәсәбәтләре, кешенең үзе кебек үк, күпкырлы, һәм өйдә уңайлы психологик климат урнаштыру өчен бер-берeң белән мөнәсәбәтләрдә килешүләр чылбыры аша үзара кирәк.

Нинди гаиләләр була? Алар бер-береннән нәрсәләре белән аерыла: составы, үзара мөнәсәбәтләр характеры, гаилә эчендә рольләрне һәм хакимлек итүне бүлү, балалар саны беләнме?

Бүгенге Россиядә 40 млн нан артык гаилә исәпләнә. Алар арасында бер түбә астында ике-өч буынны берләштерүче *киңәйтелгән (күп буынлы)* гаиләләр бар (галимнәр исәпләгәнчә, алар 20% тан артык түгел). Россиядәге күпчелек гаиләләр бер яки ике балалы ир белән хатыннан тора, аларны *нуклеар гаилә* дип йөртәләр.

Галимнәр *тулы* (ата-ана икесе дә бар) һәм *тулы булмаган* (ниндидер сәбәп белән ата-ананың берсе яки ата-ана буыны юк, ә балалар әбиләре-бабалары белән яши) гаиләләрне аерып күрсәтәләр. Балалар санына карап *баласыз, бер балалы, аз һәм күп балалы* гаиләләр була.

Гаилә бурычларын бүлү характерына, гаиләдә лидерлыкның ничек бүленүенә бәйле рәвештә, традицион төстә ике типтагы гаиләне аерып күрсәтәләр.

Традицион яки *патриархаль* гаилә ирнең баш булуын күздә тота. Мондый гаиләне бер түбә астында кимендә өч буын вәкиле берләштерә. Хатын икътисади яктан иренә бәйле, гаилә рольләре төгәл бүленгән: ир (ата) — акча табучы һәм туендыручы, хатын (ана) — йорт хуҗабикәсе һәм балаларны тәрбияләүче.

Партнерлык яисә эгалитар гаиләгә (тигезләр гаиләсенә) гаилә бурычларын гадел, тигез бүлүне, көнкүреш мәсьәләләрен хәл иткәндә ир белән хатынның бер-берсен алыштыруын, төп проблемаларны бергәләп тикшерүне, гаилә өчен мөһим карарларны уртак кабул итүне, шулай ук мөнәсәбәтләрнең эмоциональ тыгызлыгын кертергә була. Социаль психологлар нәкъ менә шул билгегә аерым игътибар бирәләр, шуның белән фәкать партнерлык тибындагы гаиләдә генә үзара хөрмәт итү, үзара аңлашу һәм бер-берeңә эмоциональ ихтыяҗ турында сөйләргә мөмкин, диләр.

Күчеш тибындагы гаиләнең төрле вариантлары бар. Мәсәлән, ир, сүздә вазыйфаларны иргә һәм хатынга бүлүне алга сөреп, хатынына хуҗалык эшләре буенча бик таләпчән булыша. Яисә, киресенчә, ир йорт эшләрен алып баруда аз катнаша, ә сүздә рольләрне тигез бүлү яклы.

Гаилә функцияләре дигәндә, билгеле бер социаль нәтиҗәләргә ия булган эшчәнлек күздә тотыла. Аларның берничәсен карап үтик.

Репродуктив функция җәмгыять әгъзаларын биологик җитештерү белән бәйле. Иске буынга алмашка килгән яңа буын социаль рольләрне үзләштерергә, тупланган белемнәр, тәҗрибә, әхлак һәм башка кыйммәтләр багажын алырга тиеш. *Тәрбия функциясе* шунда чагыла. *Хуҗалык-икътисади функция* гаилә мөнәсәбәтләренең төрле аспектларын: йорт хуҗалыгын һәм гаилә бюджетын алып баруны, гаилә чыгымнарын һәм йорт эшләрен оештыруны, картларны һәм инвалидларны яклауны һәм карауны колачлый. Гаилә кешегә тынычлык һәм ышаныч табарга ярдәм итә, иминлек һәм психологик уңайлык хисе булдыра, эмоциональ яклауны һәм гомуми тормыш тонусын саклауны тәэмин итә (*эмоциональ-психологик функция*). Галимнәр үзенә рухи-эстетик моментларны, шул исәптән буш вакытны үткәрүне оештыруны да эченә алган *рекреацион функция* турында аерым сөйлиләр. Моннан тыш гаилә үз әгъзаларына социаль статус бирә, шуның белән җәмгыятьнең социаль структурасын яңадан җитештерүгә булыша (*социаль-статус функциясе*). Гаилә, сексуаль мөнәсәбәтләргә кем, кем белән һәм нинди хәлләрдә керә алуын билгеләп, кешеләрнең сексуаль тотышларын җайга сала (*сексуаль функция*).

Санап кителгән функцияләр гаиләнең тормыш эшчәнлеген билгелиләр. Гәрчә нисбәтләре һәм гомуми өлешләре төрле булырга мөмкин булса да, алар бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән.

ГАИЛӘДӘГЕ ҮЗАРА МӨНӘСӘБӘТЛӘР ПСИХОЛОГИЯСЕ

Гаиләдәге үзара мөнәсәбәтләр үзара мөнәсәбәтләрнең берничә системасын колачлый: ир — хатын; ата-ана — балалар; балалар — балалар; балалар — әби (бабай); ир белән хатын гаиләсе — ир белән хатынның һәрберсенең ата-анасы гаиләсе һ.б.

Ир белән хатын мөнәсәбәтләре психологиясенә җентекләбрәк тукталыйк, чөнки, кагыйдә буларак, гаиләнең тормыш эшчәнлеген, никахтан канәгать булуны нәкъ менә алар билгели.

Социаль психологлар гаиләнең һәр әгъзасының үз-үзен тотуын һәм гамәлләрен билгеләүдә *төркем юнәлгәнлеге* мөһим роль уйный дип исәплиләр. Ул — төркем мотивларын, максат, омтылыш, кыйммәтләрен, мәнфәгатьләрен колачлаучы социаль-психологик күренеш. Шунысын билгеләп үтик: гаиләнең төркем юнәлгәнлеге төрле булырга мөмкин. Мәсәлән, бер гаилә әхлакый-психологик характердагы кыйммәтләргә: балаларны ярату һәм үзара аңлашу атмосферасында тәрбияләүгә, никахның ныклыгына ышануга; кызыклы ял итүгә йөз тотарга мөм-

кин. Икенчеләре өчен төп юнәлеш профессиональ эшчәнлек һәм профессиональ статусны күтәрү (кызыклы эш, яхшы белем) була ала. Кемдер матди яктан яхшы яшәүгә ирешүне барысыннан да өстенрәк күрә.

Бу соң гаилә әгъзаларының үз фикерләре, карашлары, мәнфәгатьләре, теге яки бу вакыйгаларга бәяләмәләре булмаска тиеш дигәнне аңлатамы? Юк, һич тә юк! Ләкин гаиләнең гомуми юнәлеше һәм уртак максатлары булмау, аерым әгъзаларның шәхси мәнфәгатьләре өстенлек итү гаилә эчендәге каршылыкларга китерә.

Гаиләдә *эмоциональ атмосфера* да мөһим. Гаиләнең психологик климаты ир белән хатынның һәм аларның балаларының гаилә тормышыннан канәгать булуларын чагылдыра. Ир белән хатын арасындагы мәхәббәт, ата-ананың балаларга мәхәббәте, бер-береңне хөрмәт итү һәм үзара аңлашу гаиләнең бергә муллык белән яшәвенең бик тә уңайлы шартларын булдыралар.

Гаилә тормышы динамикалы; ул билгеле бер тормыш хәлләренә бәйле рәвештә үзгәреп тора. Әйтик, яшь ата-ананың бәбиләре туу, йорт мәшәкатьләрен, ата-ананың вазыйфаларын арттыра. Боларның барысы да ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне һәм барыннан да бигрәк ир белән хатынның йорт эшләрен алып барудагы, баланы караудагы һәм тәрбияләүдәге хезмәттәшлекне җитди үзгәртеп коруны таләп итә. Андый үзгәртеп коруның ни дәрәҗәдә уңышлы булуына бәйле рәвештә никах йә тагын да өлгергәнрәк һәм ныклырак була, йә ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрдә бозылыш килеп чыга.

Россия галимнәренең социологик тикшеренүләренең түбәндә китерелгән нәтиҗәләренә аңлатма бирегез.

Никахлашкан яшь кешеләрнең 20% ында гына бер-береңнең характерына биргән бәясе ике яктан да уңай.

Кияү һәм кызларның яртысыннан күбрәге никахлашканчы ук инде бер-берсенең характерыннан канәгать түгел.

Шуңа да карамастан, булачак ир белән хатын (сораштырылганнарның 3/4 е диярлек), туйдан соң партнердагы кимчелекне төзәтү җиңел булачак дип ышана.

Гаилә конфликтлары төрле сәбәпләрдән килеп чыга. Мондый хәлләрдә һәр кеше акыл белән эш итәргә, килеп чыккан каршылыкларга аек карарга һәм үзара аңлашу нигезендә килешүгә ирешергә тырышырга тиеш. Беренче булып юл бирүнең бернинди дә гаебе юк. Л.Н.Толстой әйткәнчә, ярату — яраткан кешеңнең тормышы белән яшәү дигән сүз. Шунлыктан һәр кеше әдәпле һәм киң күңелле, татулашуга беренче адымны ясарга әзер булырга, икенче якның ялгышларын һәм кимчелекләрен кичерә белергә тиеш.

ҮЗЕҢНЕ ГЕНДЕРЛЫ ТОТУ

«Ир-ат» һәм «хатын-кыз» сүзләре репродуктив функцияләрнең, гәүдә төзелешенең, характерның, шөгыль төренең, социаль статусның һәм башка күп нәрсәләрнең аерымлыкларын кертеп, күпләгән төрле билгеләр белән берләшә.

Бүгенге фәнни әдәбиятта *җенес* төшенчәсе белән еш кына *гендер* төшенчәсе кулланыла. Алар үзара ничек бәйләнгән? *Гендер аерымлыклары* дигәндә бүгенге фән нәрсәне аңлата?

XX гасыр уртасына кадәр индивидның теге яки бу җенестә булуы күпмедер дәрәҗәдә ир-атлар белән хатын-кызлар арасындагы аерымлыкларны билгеләүче бертөрле биологик чынбарлык дип исәпләнде. Психология фәне үсү белән бергә, ир-атларның һәм хатын-кызларның биологик нигезләре булмау ихтималлы социологик һәм психологик аерымлыклары турында күзаллау формалашты. Шундый аерымлыклар «гендерлы» дигән исем алды да инде.

Гәрчә «гендер» һәм «җенес» сүзләре һәм алардан ясалган сүзләр кайчак синонимнар буларак кулланылсалар да, аларны аерырга кирәк.

«Җенес» (sex) төшенчәсе ир-атларның хатын-кызлардан биологик аерымлыклары җыелмасын күздә тота. Барыннан да элек сүз организмның җенес мөнәсәбәтен билгеләүче геннар, җенес хромосомалары, эчке репродуктив әгъзалар һ.б. турында бара.

«Гендер» (ингл. gender, лат. gens — нәсел) төшенчәсе, беренчедән, ир-атны хатын-кыздан аерып торучы теләсә нинди психологик һәм үзен тотышы сыйфатларын (элек җенси сыйфатлар яки аерымлыклар дип аталганны) күздә тота; икенчедән, ир-ат һәм хатын кызларның биологик җенес аерымлыкларына түгел, ә җәмгыятьнең социаль оешуына бәйле булган эшчәнлегенең ролен һәм өлкәсен күздә тотып, социаль җенесне билгеләү өчен таррак мәгънәдә кулланыла.

Һәр җәмгыять, үз кыйммәтләренә туры китереп, *гендерлы рольләрне* билгели, ягъни норматив күрсәтмәләр бирә һәм ир-атның яки хатын-кызның үзен «дөрес» тотышын көтүен белдерә. Тиешле гендерлы рольне башкару индивидның гендерлы тәртибенә шарт куя. Шулай булгач, гендерлы тәртипнең социо-мәдәни закончалыклары турында сөйләргә була.

Төрле тарихи чорларда (Антик чор, Урта гасырлар, Яңа вакыт) малайларны һәм кызларны тәрбияләүнең нинди социаль стереотиплары булганын исегезгә төшерегез. Гасырлар дәвамында алар ничек үскән: нәрсә үзгәргән, ә нәрсә, киресенчә, үзгәрешсез калган? Ничек уйлыйсыз, ни өчен?

XXI гасыр башында галимнәр, малайларда һәм кызларда нинди сыйфатлар тәрбияләргә кирәклеген ачыклау максатында, Россия вузларын тәмамлаучы бер төркемдә сорап белешү үт-

кәргәннәр. Ир-атлар белән хатын-кызлар җавапларында аерма әллә ни зур булмаган. Малайлар һәм кызлар өчен алар нинди сыйфатларны кирәк дип санаганнар соң? Малайларга: 1) мөстәкыйльлек; 2) җаваплылык; 3) кызыксынучанлык. Кызларга: 1) җаваплылык; 2) яхшы манералар; 3) тыңлаучанлык.

Шунысы кызык: кызларның тыңлаучанлыгы турында 56% ир-ат, 42% хатын-кыз искә алган. Малайлар өчен бу сыйфат соңгы урында тора (аны 18% ир-ат, 14% хатын-кыз атаган). Димәк, һәр ике җенес вәкилләре дә кызлардан тыңлаучанлыкны малайларга караганда өч тапкыр күбрәк таләп итәләр. Башка социологик тикшеренүләр дә, Россиядәге ата-аналар кызлардан барыннан да элек конформлык һәм төгәллекне, ә малайлардан инициативалыкны һәм үзүсешне көтәләр дигән нәтиҗә ясау мөмкинлеге бирәләр. (Үткәрелгән сорап белешү нәтиҗәләрен сез ничек бәялисез?)

Шул ук вакытта галимнәр хатын-кызларның иҗтимагый җитештерүдә һаман саен күбрәк катнашуы, аларның тигез, ә кайчак ир-атларныкыннан әһәмиятлерәк социаль позиция алырга омтылулары алардан тагын да күбрәк тырышлык куюны таләп итә: алар көндәшләргә каршы торырга гына түгел, ә гадәтләнгән стереотиплар инерциясен дә җиңәргә тиеш дип билгеләп үтәләр.

ГАИЛӘДӘ ТӘРБИЯЛӘҮ

Күпмедер дәрәҗәдә аңлы гамәл буларак, гаиләдә тәрбияләү, кагыйдә буларак, балаларга карата була. Әмма ир белән хатын да бер-берсен тәрбияләргә тырышып карый (аеруча гаилә тормышының беренче елларында), ә аларга үз чиратында аларның туганнары (каенана, биана, каенатай) йогынты ясарга омтыла. Беренче чиратта бер-береңне хөрмәт итәргә, башка кешедә шәхесне күрергә, аның да үз фикере булуга хокуклы икәнен аңларга кирәк. Башка кешеләр тәкъдим иткәнне сукырларча башкару мәҗбүри түгел, әмма тәҗрибәлерәк кешеләрнең фикеренә колак салу кирәк.

«Гаилә тәрбиясе» дигәндә балаларда шәхес формалаштыруда гаиләнең өлкән әгъзаларының аңлы йогынты ясавын күздә тоталар. Кагыйдә буларак, ул гаиләнең кече әгъзаларының өлкәннәрдәге бала, үсмер, егет, кыз ничек булырга тиешлеге турындагы күзаллауларга туры килүенә юнәлдерелергә тиеш.

Гаилә тәрбиясенең эчтәлеге, характеры һәм нәтиҗәләре баланың яшенә һәм җенесенә генә түгел, гаиләнең кайбер үзенчәлекләренә дә бәйле. Аларны җентекләбрәк карыйк.

Гаиләнең шәхеслек ресурслары гаилә составы (ата-ананың икесенең дә яки берсенең, ир һәм кыз туганнарның, башка якын

туганнарның булуы), шулай ук гаиләдәге өлкән әгъзаларның сәламәтлек хәле, характеры, белем дәрәҗәсе һәм төре, шәхси мавыгулары, зәвыклары, кыйммәти юнәлгәнлекләре, социаль омтылышлары, дәгъва дәрәҗәләре һ.б. белән билгеләнә. Әлеге факторлар гаилә тәрбиясенең максатларына һәм стильләренә йогынты ясый.

Гаилә тәрбиясе максатларының колачы бик тә киң. Ул кечкенәләргә гигиена күнекмәләре бирүне, көнкүреш осталыкларын, аралашу культурасын, физик, интеллектуаль үсүне, аерым осталыкларны үстерүне, билгеле бер профессиягә яки эшчәнлек өлкәсенә әзерләүне колачлый.

Кечкенәләр белән үзара тәэсир итешү алымнары һәм үзенчәлекләре системасы *тәрбияләү стилен* билгелиләр. Педагоглар үзара тәэсир итүнең дүрт төрен аерып күрсәтәләр: диктат, опека, тыкшынмау һәм хезмәттәшлек.

Гаиләдә *диктат* өлкәннәрнең кечкенәләрне үз йогынтысына мөмкин кадәр ныграк буйсындырырга омтылуы белән характерлана. Башкаларның инициативасы бөтенләй кысыла. Балаларның тотышларын, мәнфәгатьләрен һәм хәтта теләкләрен тулысынча контрольдә тотарга тырышып, ата-ана үз таләпләрен катгый үтәтергә тырыша. Моңа туктаусыз контроль һәм җәзалар ярдәмендә ирешелә, болар исә еш кына баланың табигый каршы килүен китереп чыгара. Мондый стиль кечкенәләрне дисциплиналаштыра, өлкәннәр теләгән омтылышлар һәм үз-үзен тоту күнекмәләре формалаштыра. Ләкин педагогик һәм әхлакый яктан акланмаган таләпләр балаларда өлкәннәрдән читләшү, тирә-яктагыларга карата дошманлык, протест һәм агрессия (еш кына апатия һәм пассивлык белән бергә) тудыра.

Гаиләдә опека — мөнәсәбәтләрнең шундый системасы ки, бу вакытта ата-аналар, баланың ихтыяҗларын канәгатьләндерүне тәэмин итеп, аны барлык мәшәкать, көч кую һәм кыенлыклардан саклыйлар, боларның бөтенесен үзләренә алалар. Гаиләдән тыш мохитнең тискәре йогынтысыннан саклап һәм шуның белән балаларга туган йорт бусагасының теге ягында чын тормышка әзерләнергә комачаулап, ата-аналар үз балаларына «оранжерея» шартлары тудыралар дип әйтергә мөмкин. Нәкъ менә шундый балалар коллектив тормышына авыррак ияләшә.

Тыкшынмау — гаиләдәге өлкәннәр һәм балаларның бәйсез яшәве мөмкин һәм хәтта максатка ярашлы икәнен тануга нигезләнгән шәхесара мөнәсәбәтләр системасы. Гаиләдә ике дөнья яши сыман: өлкәннәр һәм балалар; һәм тегеләренә дә, боларына да билгеләнгән «сызык»ны үтеп чыгарга ярамый.

Хезмәттәшлек өлкәннәрнең кечерәкләр белән җылы мөнәсәбәтләр урнаштырырга, аларны проблемаларны хәл итүгә

катнаштырырга, инициативаларын һәм мөстәкыйльлекләрен хупларга тырышулары белән үзенчәлекле. Өлкәннәр, кагыйдәләр урнаштырып, һәм аларны тормышка мөмкин кадәр ныклырак үткәрә, әмма үзләрен гөнаһсызга санамый һәм үз таләпләренең сәбәпләрен аңлаталар, аларны кечерәкләр белән тикшерүне хуплыйлар; кечерәкләрдәге тыңлаучанлык та, бәйсезлек тә бәяләнә. Мондый стиль мөстәкыйльлек, җаваплылык, активлык, дуслыкны сөю, түземлелек тәрбияләүгә ярдәм итә.

Кызганыч, бүгенге Россия җәмгыятендә гаиләдә тәрбияләү потенциалы кимү күзәтелә. Галимнәр бу беренче чиратта тулы булмаган составлы гаиләләрнең артуы һәм ата-аналарның балаларны тәрбияләү буенча белем һәм күнекмәләре дәрәҗәсе җитмәү аркасында килеп чыга дип исәпли. (Уйлагыз: сез тагын нинди сәбәпләрне әйтә аласыз.)

Моннан тыш соңгы елларда ятим балаларның артуына китерүче социаль-икътисади сәбәпләр (факторлар): табигый бәла-казалар, производствода һәм транспортта һәлакәтләр, террорчылык актлары, ата-аналарның вакытсыз үлеме шактый кискенләште. Гаиләнең әхлакый нигезләрен җимерүгә китерүче тенденцияләрнең нык арта баруы, рәхимсезлек, тормыш өчен мөһим кешелек кыйммәтләрен югалту хәлне катлауландыра. Ятим балалар саны ата-аналарны эчүчелек, әхлаксыз яшәүләре өчен ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, аналарның үз балаларын тотудан һәм тәрбияләвеннән баш тартуы, ялгыз аналарның, балигъ булмаган аналарның саны күбәю һәм башка сәбәпләр аркасында арта бара. Һәр төбәк буенча ел саен төрле сәбәпләр белән ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм булган уртача 2 дән алып 4 меңгә якын бала ачыклана, социаль ятимнәр барлыкка килә.

Йомгаклау ясыйк. Ата-ана гаиләсендә кешенең характеры нигезләре, аның хезмәткә, әхлакый, идея һәм мәдәни кыйммәтләргә мөнәсәбәте формалаша.

Ләкин бүгенге гаилә инде анда үткән дәвердә булган аерым әһәмияткә ия булган рольне уйнамый. Социальләштерүнең иҗтимагый институтларының (балалар бакчалары, мәктәпнең) үсә барган роле дә, гаиләнең үзенең структурасы һәм функциясе үзгәрү дә (атаның традицион роле кимү, хатын-кызның хезмәт эшчәнлеге һ.б.) үзләрен сиздерә.

Ата-ана абруе күптәннән инде абсолют түгел; тәрбияләүдә тыю һәм мәҗбүр итү алымнары урынына һаман саен күбрәк дәлилләү һәм инандыру кулланыла. Без бүген ата-ана хакимияте турында түгел, ә *ата-аналарның әхлакый абруе* турында сөйлибез. Ләкин, билгеле булганча, көчкә нигезләнгән, бигрәк тә мәгълүмат чаралары колачы һәм аралашу даирәсен сайлау киңәйгән бүгенге җәмгыятьтә, хакимлек итүгә караганда

әхлакый абруйны саклау шактый читен. Балалар аларның авторитар түгел, ә абруйлы ата-аналары булуын телиләр. Димәк, яшь кешеләр ир белән хатын һәм ата-ана рольләрен үтәүгә җитди әзерләнергә тиешлеге турында сөйләргә мөмкин.

Төп төшенчәләр: кече төркем буларак гаилә; гаиләдәге үзара мөнәсәбәтләр психологиясе, гендер, үзеңне гендерлы тоту, гаилә тәрбиясе.

Терминнар: киңәйтелгән (күп буынлы) гаилә, нуклеар гаилә, гаиләнең вазыйфалары, төркемнең юнәлгәнлеге, эмоциональ өлкә, гендер аерымлыклары, гаиләнең шәхеслек ресурслары, тәрбияләүнең максаты, тәрбияләү стиле.

Үзегезне тикшерегез

1. Гаиләне нинди фәннәр өйрәнә? Аларның гаиләне өйрәнүдәге аерымлыклары нәрсәдә? 2. Башка кече төркемнәр белән чагыштырганда, гаиләнең үзенчәлекләре нәрсәдә? 3. Сезгә гаиләнең нинди классификацияләре билгеле? 4. Гаиләнең җәмгыятьтәге төп вазыйфалары нинди? Аларның һәрберсен сурәтләүче мисаллар китерегез. 5. Гаиләдәге үзара мөнәсәбәтләр психологиясенә нәрсә йогынты ясый? 6. «Гендер аерымлыклары» атамасының асылын аңлатыгыз. Шәхеснең гендерлы рольләрен мисалларда ачып бирегез. 7. Нәрсә ул гаилә тәрбиясе? Аның эчтәлегенә, характерына һәм нәтиҗәләренә нинди факторлар йогынты ясый? 8. Тәрбияләүнең төп стильләрен атагыз.

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Бүгенге инглиз социологы Э.Гидденс гаиләне җәмгыятьнең бер-берсенә социаль, икътисади яки психологик булышлык итүче, яисә бер-берсен төркемне яклаучыга тиңләүче кешеләрдән торган ячейкасы дип билгели. Сезнеңчә, бу фикер параграф текстында китерелгән билгеләмә белән ничек яраша (аңа каршы киләме, аны тулыландырамы һ.б.)? Җавабыгызны дәлилләгез. Кече төркем буларак гаиләгә үз билгеләмәгезне бирегез.

2. Л. ның гаиләсе алты кешедән тора: ата, ана, дүрт бала. Гаиләдә вазыйфаларны гендерлы билге буенча төгәл бүлү юк. Ир эштән иртәрәк кайтса, кичке ашны әзерли, балаларны ашата, йокларга яткыра. Л. гаиләсен нинди типларга (төрле нигезләмәләр буенча) кертергә була?

3. Гаиләнең төп вазыйфаларын атагыз һәм аларның һәрберсен мисал белән сурәтләгез.

4. Шәрекъ зирәклеге гаиләне — коега, ә балаларны аны саклаучы таш плитәгә тиңли. Сез бу метафораның мәгънәсен ничек аңлыйсыз?

5. Гаиләдә тәрбияләүнең аталган һәр стиленең өстенлекләрен һәм кимчелекләрен күрсәтегез. Тарихи шәхесләр яки әдәби геройлар тормышыннан тәрбияләүнең, тиешле уңай һәм тискәре яклары белән бергә, теге яки бу стилен сурәтли алырдай мисаллар китерегез.

Чыганак белән эшләгез

Классик язучы Н.В.Гогольнең (1809–1852) «Россиянең бүгенге хәлендә гади йорт шартларында хатын ир өчен нәрсә була ала» дигән әсәреннән өзек укырга тәкъдим итәбез.

Яшь хатынга киңәшләр

Үз вакытыгызны бүлеп куегыз: барысына да мәҗбүри сәгать билгеләгез. Иртәләрен ирегез белән калмагыз: аның гомуми эшкә һәм бөтен дәүләт хуҗалыгына бирелергә тиешлеген ... аның, барлык вак мәшәкатьләрдән котылып, үзен бөтенләе белән нәкъ менә Ватанга бирү өчен өйләнүен, һәм хатынының аңа хезмәтенә комачаулык итү өчен түгел, ә аның хезмәттә ныгуы өчен бирелүен минут саен исенә төшереп, аны үз департаментларындагы вазыйфасына куыгыз. Һәр иртә сез һәрберегез үз һөнәре буенча аерым эшләрлек, шуның аша көндезге аш алдыннан күңелле күрешүегез һәм бер-берегез өчен берничә ел күрешмәгәндәй шатланырлык булсын, бер-берегезгә сөйләрлек нәрсәләрегез булсын һәм берегез икенчесен йомык авыз белән сыйламасын: аңа үз өегездә һәм йорт хуҗалыгыгызда нәрсәләр эшләгәнегезнең барысын да сөйләгез, һәм ул сезгә гомуми хуҗалык өчен үз департаментында нәрсәләр эшләгәненең барысын да сөйләсен. Һәм сез аның вазыйфасының асылын, аның өлешенең нәрсәдән торуын, аңа шул көндә нәрсәләр эшләргә туры килүен, аларның нидән гыйбарәт булуын, һичшиксез, белергә тиешсез. Моннан баш тартмагыз һәм хатын иренең ярдәмчесе булырга тиешлеген исегездә тотыгыз. Әгәр сез бер ел дәвамында гына булса да аннан барысын да игътибар белән тыңласагыз, икенче елга хәтта аңа киңәш бирерлек көчтә булырсыз, хезмәтендә нинди дә кыенлык белән очрашканда аны ничек хупларга икәнен белерсез, аның рухы да җитмәстәй нәрсәләргә түзәргә ничек мәҗбүр итәргә кирәклеген белерсез, аны барлык гүзәллеккә чын рухландыручы булырсыз.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Н.В.Гоголь гаиләнең нинди вазыйфасы турында яза? Җавабыгызны цитаталар белән ныгытыгыз. 2. XIX гасырда яшәгән язучының нинди киңәшләрен XXI гасыр кызы хәтеренә сеңдерергә мөмкин? Аларның ни өчен үз актуальлекләрен саклавын аңлатыгыз. 3. Н.В.Гоголь әсәренең исемендә җансыз объектларга карата кулланыла торган «нәрсә» сүзен куллана. Ничек уйлыйсыз, моның өчен язучыга үпкәләргә кирәкме? Җавабыгызны дәлилләгез.

§ 38. Антисоциаль һәм криминаль яшьләр төркемнәре

Исегезгә төшерегез:

шәхеснең юнәлгәнлеге нинди була? Кешегә төркем нигә кирәк? Төркем йогынтысының механизмнары нинди?

Үткән параграфлардан белгәнегезчә, төркем сездә булганны көчәйтергә, индивид үзе сәләтле булганнан да күбрәкне булдырырга сәләтле. Төркемдә йөгерешчеләр тизрәк йөгерә, ә тамашачылар көчлерәк көлә. Студент-интеллектуаллар, үзләре кебек үк интеллектуаллар белән очрашып, үзара байыйлар, һәм бу аларның антисоциаль юнәлгәнлекләренең көчәюенә китерә. Төркемнең нинди сыйфатларны көчәйтүенә яки басуына бәйле рәвештә, ул файда яки зыян китерергә мөмкин.

Бу параграфта сүз нигездә шәхескә дә, җәмгыятькә дә зыян китерүче төркемнәр — социаль булмаган һәм антисоциаль төркемнәр турында барачак. Андый төркемнәрне психологлар, социологлар, юристлар, педагоглар өйрәнә. Махсус игътибар предметы булып *социаль булмаган һәм антисоциаль яшьләр төркемнәре* тора.

ФОРМАЛЬ БУЛМАГАН ЯШЬЛӘР ТӨРКЕМНӘРЕ

Күп кенә үсмерләр һәм яшүсмерләр төрле сәбәпләр аркасында үзләрендәге мәнфәгатьләрне һәм ихтыяҗларны укучылар төркемнәрендә канәгатьләндерә алмыйлар. Алар, бик теләп, *мәктәптән тыш яшәүче формаль булмаган төркемнәргә* керәләр. Андый төркемдә берәүләр яклау һәм теләктәшлек эзли, икенчеләре үзләрен расларга тырыша, өченчеләргә эмоциональ мөнәсәбәт, төркем белән кушылу җитми, дүртенчеләргә командалык, башкалар өстеннән хакимлек итәргә кирәк, бишенчеләрен формаль булмаган төркемнәргә укудагы уңышсызлыклар, классташлар, укытучылар һәм ата-аналар белән конфликтлы мөнәсәбәтләр китерә. С.Т.Шацкий (1878–1934), «урам малайлары» берләшмәләрен тасвирлап, әлеге берләшмәләр «шуның белән яхшы, алар ирекле, хәрәкәтчән, тормыш белән бәйләнешкә якын торалар һәм төрлеләр» ди. Андый төркемнәрдә яшь кешегә бергә булу, аралашу, психологик, әхлакый физик яклау гарантияләнгән берләшмәдә булу мөмкинлеге бирәләр.

Үсмерләр һәм яшүсмерләр төркемнәре барлыкка килү — законченлыклы процесс. Куркыныч гомумән формаль булмаган үсмерләр һәм яшүсмерләр төркемнәрендә түгел, ә бары тик яшьләрнең криминаллаша барганнарында гына.

Мәктәптән тыш барлыкка килүче формаль булмаган төркемнәр укучылар төркемнәреннән үзизоляцияләнүгә, өлкәннәрдән, барыннан да элек ата-аналардан һәм укытучылардан котылып торуга һәвәслекләре белән аерылып торалар.

Социаль юнәлгәнлекләре характерына карап, формаль булмаган яшьләр төркемнәренең өч төрен аерып күрсәтәләр:

1) просоциаль яки социаль уңайлар;

2) төп социаль проблемалардан читтә торучы, тар төркем кыйммәтләре системасына бикләнгән социаль булмаганнар;

3) антисоциальлар яки социаль тискәре, җинаятьчел төркемнәр.

Просоциаль төркемнәрнең мисаллары — яшьләрнең социаль әһәмиятле максатлары, бурычлары, эш программалары булган мөстәкыйль формаль булмаган төркемнәре, мәсәлән, экологик, культурологик, саклау-тарихи, спорт берләшмәләре, социаль яклау (мәсәлән, индивидларны) төркемнәре, «Нәрсә? Кайда? Кайчан?» кебек күп белүчеләр клублары һ.б.

Төркемнәрнең икенче тибына берләштерүче үзәге — үзенчәлекле яшәү рәвеше, үз нормалары булган формаль булмаган яшьләр берләшмәләре керә. Андый берләшмәләр гомум кабул ителгән әхлакны кире кагуга, аңа төркем кыйммәтләрен каршы куюга корыла. Мәсәлән, *панкилар* кызларга карата әдәпсез карашка, законны санга сукмауга, үз тормышларының кыйммәтләрен төшерүгә юл куялар; *рокерлар* мотоциклларда төнлә белән төркемләп чыкканда йоклаган гражданнарның тынычлыгын гына түгел, юл йөрү кагыйдәләрен дә бозалар; *спорт фанатлары* еш кына башка командага теләктәшлек белдерүчеләр белән сугышырга әзер торалар. Социаль булмаган *ишегалды төркемнәренә* еш кына «авыр», гаиләдән һәм мәктәптән аерылган яшүсмерләр һәм яшь егетләр җыела. Аларның кайберләре өйләреннән киткәннән соң *сукбайлар һәм теләнчеләр төркемнәренә* берләшә.

Социаль булмаган төркемнәрнең аерылганлыгы, аларның тар төркем кыйммәтләре яшь кешеләрнең криминаллашуы һәм антисоциаль төркемнәргә күчүе өчен җитди алшартлар тудыра.

СОЦИАЛЬ БУЛМАГАН ТӨРКЕМНӘРДӘ КРИМИНАЛЛАШУ

Җинаятьләр әле эшләнми, әмма өлгереп килүче социаль булмаган төркемнәрне *криминоген төркемнәр* дип атыйлар.

Криминоген төркемнәр әгъзаларының, җинаятьчел төркемнәрдән аермалы буларак, җинаять эшләүгә ачык ориентлашулары булмый, ләкин еш кына моны проблемалы, конфликтлы хәлләрдә яки моңа уңай шартлар туганда эшлиләр.

Барлык формаль булмаган яшүсмерләр төркемнәрендә лидерлык процесслары шактый ачык сизелеп тора. Лидерның абруе тәҗрибәлеккә, «булдыклылыкка», ихтыярый сыйфатларга, ә еш кына физик көчкә хөрмәт белән карауга нигезләнә. Тышкы дөньядан аерылган тар төркемнәр элеккеге җинаятьчеләр арасыннан чыккан лидерларның тискәре йогынтысына тиз биреләләр. Андый лидерлар җинаятьчел дөньяның ялган романтикасы, барысына хокуклы булу хисе һәм әхлакый кыйммәтләргә, законга, тормышка җиңел мөнәсәбәтләре белән мавыктыралар.

Тәҗрибәле җинаятьчеләр йогынтысы яшүсмерләр һәм яшьләр төркемнәрен криминаллаштыру юлларының берсе булып тора.

Икенче юл — тәҗрибәле җинаятьчеләрнең турыдан-туры йогынтысыннан башка, төркем үсешенең эчке социаль-психологик механизмнары һәм закончалыклары нәтиҗәсендә.

Беренче чиратта шуны билгеләп үтик: формаль булмаган яшьләр төркемнәренең шартлары *конформлык барлыкка килүне* көчәйтә. Төркем әгъзалары үзләрен аның карамагына бик тә әзер төстә кергән һәм башкалар белән берләшү аларга күбрәк канәгатьлек биргән саен, *үзеңне конформлы тоту* шул кадәр ачыграк чагыла. (Исегезгә төшерегез, конформлык нәрсә ул, һәм сез аны төркем активлыгының нинди күренешләре белән бәйле төстә өйрәндегез.) Моннан тыш төркемдә йогынтының тагын бер механизмы — тирә-юньдәгеләр тукландырган тәэсирләнү буларак чагылучы социаль «агулану», тоткарлаучы механизмнарны югалту. Аз сандагы тамашачы өчен барган концерт вакытында рок-музыка яратучы берәүнең ялгызы кычкыруын күз алдына китерүе кыен, ә менә гала-концертта акыручы төркем беркемне дә гаҗәпләндермәячәк. Төркемнең социаль «агулавы» аерым кешеләрнең агрессивлыкка хирыслыгын көчәйтә, деиндивидуальләштерү, кешенең үзенең «мин»ен югалттыру механизмнарын эшкә җигә. Мәсәлән, рокерларның берсе: «Без кешеләр түгел, без мотоциклдагы җанварлар, без тиз баруны һәм кызларны яратабыз. Башка берни дә түгел»,— дип белдерә.

Төркемнең иң мөһим билгеләренең берсе буларак искә алынган «без» — «алар»ны аеру криминаль төркемнәрдә каршы куелган «үзебезнеке» — «читләр» белән алыштырыла башлый. Әгәр син «үзебезнеке» икәнсең, бөтен яктан: киемдә дә, үзеңне тоту стилендә дә, әхлакый принципларда да «үзебезнекеләргә» охшарга тиеш. Яшьләр төркемнәренә охшарга тырышу (бу да төркем йогынтысы нәтиҗәсе) еш кына эпидемия характеры ала. Бу эстрада музыкасы, дискотекалар, төркем символикасы белән мавыгуда, музыка, спорт фанатизмында күренә.

Төрле фильмнардан, ә бәлки үз тәҗрибәгездән, сезгә укучылар төркеменең даими рәвештә көчсезрәк укучыларны интектергәне билгеледер. Скандинавия илләрендә мондый төркемнәргә аерым исем биргәннәр — «көтүләр». «Көтүләр» феномены — формаль булмаган яшьләр төркемнәрендә билгеле күренеш. «Көтү» башлыкка тулысынча буйсына, аның фикеренә ышана. «Көтү»дә яшүсмер хокук бозуга, хәтта җинаятькә дә бик җиңел бара, бу хакта төркем вандализмы, хулиганлык һәм башка җинаятьләр фактлары дәлил булып тора. «Көтү»дә җинаятьләр аеруча әхлаксызлык белән эшләнә дип билгеләп үтәләр. Ярышу механизмы эшкә җигелә: кем корбанны мәсхәрәләүнең тагын да камилрәк алымын уйлап таба ала. Бу күренешне криминологиядә *«аңны төркем белән томалау»* яки төркем белән *«сукырайту»* дип атыйлар.

Конформлыктан беренче чиратта күбрәк мәдәниятле һәм интеллектуаль үскән яшь кешеләр җәфа чигә. Формаль булмаган бергәлекләрнең интеллектуаль дәрәҗәсе күпме түбәнрәк булса, аның әгъзалары индивидуаль аерымлыкларга шулкадәр түзеп тора алмый. Әхлаксыз яшь кешеләр төркемдәге башкаларның әхлаклылыгын үзләренеке дәрәҗәсенә төшерергә тырыша. Үсмерләрнең һәм яшүсмерләрнең культурасы күпме түбәнрәк булса, алар «көтү»гә шулкадәр тизрәк тупланалар, алардагы конформлык шулкадәр көчлерәк чагыла, алар үзләренә охшамаганнарга шулкадәр агрессиврак карыйлар.

«Кем «яхшылык» һәм «явызлык» сүзенә бер үк мәгънә сала һәм кемнең уртак дуслары һәм дошманнары бар, шулар дусларга әвереләләр. Безгә үзебезгә охшаган һәм безнең шөгыль белән үк мәшгуль кешеләр ошый».

Аристотель

Җинаятьчелекнең социаль-психологик механизмнары эшен социаль контрольне алып ташлауга, үзеңне тотуның аңланган регуляторларын «сүндерүгә» китерүче алкоголь көчәйтә. Моннан тыш җинаять эшләренең спиртлы эчемлекләр алу өчен акча эзләүдән гыйбарәт булган өстәмә сәбәпләре барлыкка килә. Шул рәвешле, алкоголь куллану үсмерләр һәм яшүсмерләр төркемнәрендәге криминоген куркынычны тагын да арттыра. Безнең илдәге җинаятьләрнең 80% тан артыгрдагы яшьләр тарафыннан исерек хәлдә эшләнә. Ә агрессив җинаятьләр өчен хөкем ителгәннәр арасында аларны исерек хәлдә эшләгәннәрнең саны 90% ка җитә.

АНТИСОЦИАЛЬ СУБКУЛЬТУРА

«Антисоциаль субкультура» атамасы, кагыйдә буларак киң мәгънәдә дә, тар мәгънәдә дә кулланыла. Киң мәгънәдә аның

астында социаль нормаларга каршы килүче үз-үзеңне тотуның барлык социаль-психологик үзенчәлекләрен, ә таррак мәгънәдә «антисоциаль субкультура» дигәндә, җинаятьчел яшәү рәвешенең төрле чагылышларын аңлыйлар. Аларга яшерен, серле характер; җәмгыятьтә булган нормаларга каршы тору; эшчәнлекнең социаль файдалы максатларын кабул итмәү, төркемдә әхлаксыз, хокук нормаларына каршы нормалар һәм санцияләр булу керә. Антисоциаль субкультура телдә (жаргонда), татуировкаларда, мимикада, хәрәкәтләрдә, кушаматларда, антларда, шулай ук ачык статуслы-рольле аерымлыкларда чагыла.

Антисоциаль нормалар башлык, аның өстенлекләрен аерып күрсәтүгә, шулай ук әхлаклылык принципларын, әхлаклылык төшенчәләрен бозып аңлауны формалаштыруга юнәлтелгәннәр. Кыюлык — бозык рәвештә ясалма тәвәккәллек, этәчләнү; таләпчәнлек — бәйләнчеклек, дуслык; ә иптәшлек — яшереп калу һәм җитлекмәгәнлек, кайгырту — чын ир-атка хас булмаган көчсезлек билгесе буларак аңлана. Кеше иң югары кыйммәт булудан туктый, средствога әверелә. Хезмәт имин-мул яшәүгә ирешүнең бердәнбер чыганагы һәм шәхесне бәяләү критерие булудан туктый. Төрле уңайлык-муллыкларга ирешүнең башка чыганаклары һәм ысуллары законсыз һәм әхлаксыз дип кабул ителми башлый. Гомумкешелек кыйммәтләре тормыш — «бер тиен» булган, хезмәт санга сугылмаган, статус-белемнәр дәрәҗәсенә түгел, ә антисоциаль төркем кагыйдәләрен һәм законнарын саклауга бәйле булган җинаятьчел дөнья кыйммәтләренә алыштырыла.

Антисоциаль субкультураның аерым феномены — үзара яшереп калдыруны, начар эшләрдә табыш алуны күздә тоткан *һәрьяклап яклап калу*. Иң зур «гаеп» булып чын күңелдән тану, бергә катнашучыларны судка яки балигъ булмаганнар эшләре комиссиясенә тарту, бөтен гаепне үз өстеңә алырга, башлыкны яклап калырга теләмәү санала. Мондый «гаепләр» эшләгән әгъзалар кимсетелүгә дучар була һәм еш кына көчләү объектына әверелә. Һәрьяклап яклап калу йогынтысы астында булмаган хокук бозучылар һәм яшьләр күп очракта, тәҗрибәлерәк җинаятьчеләр җәзадан котылу өчен файдаланган кебек, судта «сыгылып төшүләрен» күрсәтәләр.

Антисоциаль субкультураның «уртак казан» рәвешендәге матди нигезе була. «Уртак казан» революциягә кадәрге патша төрмәләрендә дә киң тарала, аның ярдәмендә тоткыннар бергәләп ашыйлар, үзара әйберләр бүлешәләр. Бүгенге шартларда «уртак казан» нигезендә хокук бозучылар үзара туплана. Төркемнең «уртак казан»ны тотырырга тырышуы аны хокук бозуларга, әлеге төркемгә кермәгән кешеләрдән талап һәм са-

лым рәвешендә алуларга этәрә. «Уртак казан»нан бүлү принциплары матди байлыкларга хокукның төркемдә тоткан статуска туры килүен чагылдыра.

Антисоциаль субкультурадагы мөнәсәбәтләр элементларының берсе — бурычлыны «счетчикка» кую. «Счетчик» «бурычлы»ның фактик яки уйдырма бурычы булса һәм аны түли алмаса җибәрелә. Бурычын түләп, ул «счетчик»ны туктата. Фактик бурыч «ачыктан-ачык», билгеле бер күләмдә акча яки ниндидер әйбер биреп тору юлы белән, «караңгы»сы алкогольле эчемлекләр, наркотиклар, сигаретлар, деликатеслар һ.б. биреп булдырыла. Мәсәлән, кредитор яшүсмерне дискотекада сигаретлар белән сыйлый, ә берничә көннән: «Сигаретлар өчен бурычыңны түлә»,— дип белдерә. Өстәвенә ул бурыч күләмен сигаретларның үз бәясеннән чыгып түгел, ә үзе теләгәнчә билгели. «Бүген бирмәсәң, «счетчик»ны җибәрәм. Иртәгә икеләтә түләрсең. Һәм бурычлы һәр көн саен сумма икеләтә артачак». Шулай итеп, бурычлы бәйлелеккә эләгә. Уйдырма бурыч төркемдә «салымнар» җыю вакытында да барлыкка килә. Мәсәлән, төркемнең югары статуслы әгъзасы түбән статуслыларга «алкоголь», «бәйрәм», «дискотека» салымнары салырга мөмкин. Кем дә булса түләмәсә, аңа «счетчик» җибәрелә. «Счетчик» буенча түләмәгәннәрдән үч алганда үсмерләр һәм яшүсмерләр уйлап табуга өлкәннәргә караганда да остарак була.

Антисоциаль субкультурада яңалар һәрвакыт «читләр» кебек кабул ителә. Алар сынау срогын үткәч кенә «үзләренеке» булалар. Антисоциаль субкультураларда яңаларга мөнәсәбәт «бабайлык» («дедовщина») дип атала.

«Бабайлык» дигәндә яңа бергәлеккә керүнең, статусны, хокук һәм бурычларны билгеләүнең, күп бурычлылыктан күп хокуклылыкка таба баруның формаль булмаган кагыйдәләре аңлана. Әлеге законнарны чыгаручылар — озак яшәүчеләр яки бабайлар. Әлеге күренешнең исеме дә шуннан алынган.

«Бабайлык»ның тарихы Петр I заманнарына ук барып тоташа. Ул вакытта хәрби устав буенча, хезмәткә яңа алынганнарга инде озак хезмәт иткән тәҗрибәле остаз — «дядька» беркетелә. Аңа яңа кешене сугышка әзерләү бурычы йөкләнә. Моның өчен яңа солдат аңа хезмәт күрсәтергә — коралын чистартырга, кием-салымын юарга тиеш була.

Вакыт үтү белән, «бабайлык» тискәре төсмер ала. Аның билгеләре патша хәрби училищелары казармаларын, кадетлар корпусларын сурәтләгәндә ачык беленә. Ул үзен кешеләрнең ябык яки ярым ябык бергәлеге, яшәүнең казарма тибы булган һәркайда: интернатларда, балигъ булмаган җинаятьчеләр өчен махсус учреждениеләрдә, армия подразделениеләрендә яңа кешегә төркем басымының аерым формасы буларак күрсәтелә.

Теләсә кайсы ябык яки ярым ябык төркемдә «бабайлык» җитди проблема булып тора.

АКШның кайбер хәрби академияләрендә «бабайлык» фактта законлаштырылган — кече курс кадетлары югары курстагыларның теләсә нинди боерыгын үтәргә тиеш. Бүгенге Россия армиясендә ул кайчак камилләшкән форма ала һәм кеше хокукларын рәхимсез бозуга әверелә. Армиядә «бабайлык», хезмәт итү срогына карап, һәр категория өчен хокуклар һәм бурычлар җыелмасы нигезендә хәрби хезмәткәрләрнең формаль булмаган иерархиясенә кайтып кала. «Бабайлык»ның психологик нигезе — «яңалар» һәм «бабайлар» төркемнәрендәге төрле статуслы хәл.

Human Rights Watch халыкара оешмасының Россия армиясендәге хәлләр турындагы 2004 елда басылган докладында «бабайлар»ның берсенең сүзләре китерелә: «Без монда яңа алынганнар сыйфатында килгәч, безне беркем дә кызганмады, без «бабайлар» өчен коллар булдык, безне бүгенге «яңа»ларга караганда да ныграк кыйнадылар. Без шикаять белдермәдек, без качмадык, аннары «бабайлар» белән дуслаштык. Хәзер инде безнең чират». Шундый кагыйдәләр бар: «Мин якын кешем белән минем белән эш иткәннәре кебек эш итәм». «Яңалар»ны кимсетеп, «бабайлар» үткәндәге үз кимсетелүләре өчен үч алалар.

«Бабайлык» Россия һәм халыкара законнарга каршы килә. Аның чагылышларының күпләгән фактлары судта каралу предметына әверелә. Андый күренешләргә каршы көрәш чаралары хәрби идарә органнары, часть командирлары, РФ хәрби прокуратурасы тарафыннан күрелә. Ышаныч телефоннары, консультация пунктлары, хәрби частьларны тикшерүләр оештырыла, иҗтимагый оешмалар белән үзара эш итүләр җайга салына.

КРИМИНАЛЬ ТӨРКЕМНӘР

Криминаль төркемнәр антисоциаль субкультура төркемнәре арасында аеруча куркынычлары булып исәпләнә. Алар башка социаль төркемнәрдән максатлары, төркем процессларының спецификасы, *иҗтимагый куркынычлылыклары* белән аерылып торалар. Алар җинаятьчел эшләргә тәгәл юнәлеш тотулары белән характерлана. Аларны хокук бозулар, әзерләнгән, оештырылган җинаятьләр эшләү аерып тора. Шуңа күрә андый төркемнәрне әле тагын *җинаятьчел* төркемнәр дип тә атыйлар.

Юридик факт буларак, җинаять — җинаять составы булган һәм суд тәртибендә шундый дип табылган эшләр ул. Җинаятьчелекне һәм җинаятьне үз-үзеңне тотуның тайпылган күренеше буларак сез әле 11 нче сыйныф курсында өйрәнерсез.

Хәзер без җинаятькә бары тик җинаятьчел төркемнәр эшчәнлеге яктылыгында гына кагылабыз һәм игътибарны әлеге күренешнең социаль-психологик аспектларына юнәлтәбез. Психология күзлегеннән караганда, җинаять — әлеге вакыйгага юридик бәя бирелгәнме икәненә карамастан, гаеп, җаваплылык хисе белән характерланучы факт ул. Җинаять турында бу мәгънәдә рус язучысы Ф.М.Достоевский (1821–1881) һәм аның билгеле әсәре карашыннан чыгып та сөйләргә була: җинаять ул — ихтыяҗларны канәгатьләндерүнең, максатларга ирешүнең конфликтлы ысулы.

Җинаятьчел төркемнең барлыкка килүен күпмедер дәрәҗәдә стихияле күренеш дип карап була. Җинаятьчел төркемнәрне, кагыйдә буларак, билгеле бер шөгыле булмаган, беркайда да эшләмәүче һәм укымаучы кешеләр: хулиганнар, көчләүче, карак, наркоман, сукбайлар — шәхси мәнфәгатьләрен һәм ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатында төрле жинаятьләр эшләүчеләр оештыра.

Җинаятьчел төркем акрынлап тагын да катлаулырак оештырылган төркемнәргә һәм катнашуның тагын да куркынычрак формасына — төп билгеләре тупланганлык, аеруча авыр җинаятьләр эшләргә максатчан омтылышлары, җентекле конспирацияле, саклану чаралары системалы, эчке контрразведкалы, сакчылары, сугышчылары һ.б. белән катлаулы оештыру-иерархик элементләре булган *җинаятьчел бергәлекләргә* керә. Оештырылган җинаятьчел төркемнәрнең коллегиаль җитәкчелек органнары, мәгълүмат базасы, формаль булмаган нормалар, традиция, закон, санкцияләр исемлеге рәвешендәге уставы була.

Җинаятьчел төркемнәрне тикшеренүчеләр аларның структурасындагы башлык-лидер һәм аның якын ярдәмчеләре кергән төштән торган «эчке түгәрәк»не һәм гади әгъзалардан яисә «юлдашлардан» торган «тышкы боҗра»ны аерып күрсәтәләр. Төркемнәрдә һәрвакыт әгъзаларның бер-берсенә бәйлелеге хөкем сөрә. Җинаятьчел төркемнәр белән калган барлык әгъзаларны басарга омтылучы, авторитар характеры ачык чагылып торган башлык-лидерлар җитәкчелек итә. Үзләренең лидерлык стильләре белән алар, сайлау, башкача фикерләү, ә еш кына төркемнән чыгу хокукыннан мәхрүм итеп, төркемнең башка әгъзаларын курчакларга әверелдерәләр. Лидерның роле җинаятьчел төркемне формалаштыруның бөтен механизмын эшләтә башлаучы үзенчәлекле «детонатор»лык роле дә күренеп тора. Ул аның «махсуслашуын», җинаять эшчәнлегенең колачын, төркем эчендәге мөнәсәбәтләр характерын билгели.

Өлкәннәр, еш кына элек хөкем ителгән лидерлар, үсмерләрне һәм яшүсмерләрне җинаятьчел төркемнәр эшчәнлегенә тартып кертәләр. Алар төрле-төрле, кайчак бик тә хәйләле ысуллар:

«файдалы» мәкерле тәкъдимнәр, «иптәшләрчә» үтенеч һәм бурычлар, ялагай үгетләүләр, киңәш бирүләрне кулланалар; үсмерләрне һәм яшүсмерләрне акрынлап бергәләп эчүдә, ә кайчак җенси бозыклык эшләүдә катнаштыралар. Шантаж, куркыту, алдау, шулай ук кыйнау һәм җәзалау кулланылырга мөмкин.

Җинаять күпме авыр булса, аңа шулкадәр озак әзерләнәләр. Аның планнары алдан әзерләнә, рольләр бүленә, нәтиҗәләр ясала. Җинаять эшләгәндә бу төркемнәр еш кына корал да куллана.

Җинаятьчел бергәлекләрне ачу җиңел түгел, чөнки алар яшеренә белә, эшмәкәрлекнең төрле өлкәләрендә легальләшергә, дәүләт структураларына үтеп керергә тырышалар, саклану чаралары системасы эшлиләр.

Бүгенге тикшеренүчеләр В.М.Быков һәм Л.Н.Иванов мәгълүматларына караганда (Право и политика. 2001. №1), һәр өч җинаять эшенең берсендә җинаятьне оешкан җинаятьчел төркемнең эшләве билгеләре бар.

Кылган эшләрен ачу һәм аннан соңгы суд хөкеме яки балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе карары теге яки бу криминал төркемнең җинаять эшчәнлеген туктата, ләкин, кагыйдә буларак, аның әгъзаларының криминоген юнәлгәнлеген тәмам бетерә алмый, ә еш кына аларның хокук нормаларына каршы агрессив эшләргә һәвәслекләрен көчәйтә генә.

Төп төшенчәләр: формаль булмаган яшьләр төркемнәре, антисоциаль субкультура, криминаль төркемнәр.

Терминнар: криминоген төркемнәр, «бабайлык».

Үзегезне тикшерегез

1. Формаль булмаган төркемнәр үсмерләргә һәм яшүсмерләргә нинди мөмкинлекләр бирә? 2. Мәктәптән тыш барлыкка килүче формаль булмаган төркемнәр нәрсә белән характерлана? 3. Формаль булмаган яшьләр төркемнәренең социаль юнәлгәнлеге нинди? 4. Социаль булмаган төркемнәр антисоциальләрдән нәрсә белән аерыла? 5. Социаль булмаган төркем әгъзаларының криминаллашуы ничек бара? 6. Антисоциаль субкультураның төп чагылышлары нидән гыйбарәт? 7. Ни өчен криминаль төркемнәр аеруча куркыныч булып санала?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. Сез аның әгъзасы булырга җыенган һәм сезгә йогынты ясаячак төркемне ни өчен акыл белән һәм аңлап сайларга кирәк?

2. Юридик психология вәкилләренең берсенең: «Яшүсмерләрнең үз-үзләренә ташланган төркемнәре — җинаятьчелек

үсүнең иң ышанычлы фаразлы диаметры»,— дигәнен ышандырырлык дәлилләр белән раслагыз яки кире кагыгыз.

3. Шунысы ачыкланган: хокук бозуларга сәләтле унбиш яшьлек яшүсмерләр күршеләр булса, алар ярашалар һәм һәрберсе аерым эшли ала торганнан да зуррак бәла-каза китереп чыгаралар. Аңлатыгыз, ни өчен шулай була?

4. Швециядә уенчык кораллар — пистолет, автомат, танк һ.б. ны җитештерү күптән туктатылган. Массакүләм мәгълүмат чаралары бу хакта: «Сугыш уены уйнау — барлык каршылыкларны көчләү ярдәмендә хәл итәргә өйрәнү ул»,— дип белдерделәр. Үзегезнең шәхси социаль тәҗрибәгезне һәм курс белемнәрегезне җәлеп итеп, мондый инициатива турында үз фикерегезне формалаштырыгыз һәм нигезләгез.

5. Тикшеренүчеләрнең берсенең: «Кешене үтерү киләчәктә бүген каннибализм исәпләнгән кебек үк җирәнгеч гамәл булып исәпләнәчәк»,— дип раславына үз мөнәсәбәтегезне әйтегез һәм дәлилләгез.

Чыганак белән эшләгез

Россиянең бүгенге социаль психологы, озак вакыт үсмерләрнең һәм яшьләрнең социаль булмаган криминаль төркемнәрен өйрәнүче И.П.Башкатов китабыннан өзек китерәбез.

<...> Яшүсмерләрнең стихияле, үзләреннән-үзләре барлыкка килүче төркемнәре социаль уңай, социаль битараф юнәлгәнлек тә, социаль булмаганын да алырга мөмкин. Барысы да лидерга, аның социаль һәм педагогик түбән төшүе дәрәҗәсенә, аның тормышка карашына, төркем әгъзалары һәм педагоглар белән үзара мөнәсәбәтләренең ничек корылуына бәйле булачак. Лидердан тыш төркемдә икенче, өченче урынны алып торучылар да аерылып тора. Алар урынны абруйлылык дәрәҗәсенә карап бүлешә. Төркемдә икенче, өченчеләр берничә булырга мөмкин, ә лидер берәү генә. Рольләрнең һәм позицияләрнең бу катлавын беркем дә алдан эшләп куймый. Ул, беренчедән, үсмернең индивидуаль сыйфатларына, икенче яктан — төркемнең социаль психологик үзенчәлекләренә, аның үсеш дәрәҗәсенә бәйле. Үсмернең төркемдә үз шәхесен раславы аның үзенә хөрмәт, тану, ярдәм, яклауны тәэмин итүче урынны алырга тырышуында чагыла. Төркемнең аерым әгъзаларының «читләштерелүе» катгый характер ала. Алардан көләләр, ә кайчак мыскыл да итәләр. Төркемдә алар ешрак «шамакай», «гөнаһ оясы» ролен үтиләр һәм һәрвакыт популяррак әгъза яклавында булалар. Лидерлар аларны мәкерле максатларында файдаланырга: нәрсә дә булса урларга яисә берәр хурлыклы эш башкарырга һ.б. кушарга мөмкин. Аларны чит итү аларның шәхси сыйфатларына, физик яки психик кимчелекләренә бәйле.

Лидерларның турыдан-туры яки читләтеп котыртуы аркасында «читләштерелгәннәр» башкаларның төрле тәртипсезлекләр һәм хокук бозулар, законсыз эшләр эшләвен китереп чыгарырга мөмкин.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Үсмерләрнең үзләреннән-үзләре барлыкка килүче төркеменең юнәлгәнлегенә авторның карашлары нинди? 2. Автор фикеренчә, төркемдә рольләр һәм позицияләр катламын нинди факторлар билгели? Текстта күрсәтелгән рольләрне һәм позицияләрне атагыз. 3. Китерелгән өзектә антисоциаль эшләрнең нинди мисаллары бар? 4. Текстта сурәтләнгән төркемне нинди төркем дип атарга мөмкин? Үз җавабыгызны параграф материалына таянып дәлилләгез.

§ 39. Шәхесара мөнәсәбәтләрдә конфликтлар

Исегезгә төшерегез:

шәхесара мөнәсәбәтләрдә конфликт нәрсә ул? Конфликтның үсүе өчен нинди стадияләр хас? Конфликтта үзеңне тотуның нинди стратегияләре бар?

Конфликтлар проблематикасын төрле фәннәр: социология, политология, социаль психология, юриспруденция, философия, логика һ.б. өйрәнә. Санап үтелгән фәннәрне интеграцияләү нәтиҗәсендә белемнең махсус өлкәсе — конфликтларның эчтәлеген, сәбәпләрен, шартларын, механизмнарын, барлыкка килү закончалыкларын, барышын, хәл ителүен, җайга салынуын тикшерүче конфликтология барлыкка килде.

Әгәр конфликтка керүче яклар сыйфатында безнең «Мин»ебезнең бәрелешкә керүче төрле өлешләре булса, *шәхес эчендәге конфликт* барлыкка килә. Ул исә мотивлар көрәшендә, максатны сайлауда кыенлыклар кичергәндә, кайгырганда, икеләнгәндә, ныклы ышаныч булмаганда, уңайсызлыклар килеп туганда чагыла. Безнең күбебезнең мондыйрак конфликтны кичергәне бар: мәсәлән, эшне дә эшләргә кирәк, телевизордан кызыклы спорт матчын да карыйсы килә — кайсысын сайларга?

Әгәр конфликт ике яки берничә кеше арасында максатлар, мотив, позиция, мәнфәгатьләр төрлелеге аркасында килеп туса, андый конфликтны *шәхесара* дип атыйлар. Бу очракта якларның һәрберсе нәтиҗәне үзе өчен алырга, башка кешенең уңышына комачауларга тырыша.

Төркемара конфликтларның субъектлары төрле максатларны күздә тотучы, үз мәнфәгатьләрен, кыйммәтләрен, күзаллауларын һ.б. яклаучы төркемнәр була.

«Конфликт» төшенчәсенең үзенең күпләгән билгеләмәләре бар; аларның һәрберсе төшенчә артында торган катлаулы, күпкырлы күренешнең нинди дә булса ягын ача. Өстәвенә күпчелек белгечләр төп игътибарны конфликтның үзендә барлыкка килүче шәхесара мөнәсәбәтләргә юнәлтәләр.

Еш кына конфликт уңышлы аралашуга каршы куела, ә конфликт төшенчәсе бу вакытта үзендә тискәре төсмер йөртә, чөнки ул каршы көрәш, каршы тору белән бәйле. Конфликтны шәхеснең, төркемнең, бербөтен социаль күренешнең эчке үсеше чыганагы буларак карау фәнни тикшеренү өчен чагыштырмача яңа булып тора.

ШӘХЕСАРА КОНФЛИКТНЫҢ СТРУКТУРАСЫ ҺӘМ ДИНАМИКАСЫ

Конфликтның структурасы турында хәзерге тикшеренүләрдә тәкъдим ителә торган кайбер күзаллауларны карап үтик.

Конфликтны сурәтләүнең беренче моделе түбәндәгеләрнең булуын танудан килеп чыга:

- *конфликтлы хәлне* — конфликт өчен нигезне;
- *конфликт объектын* — оппонентлар (хакимият, авторитет, вазыйфаи урын һ.б.) яулап алырга теләгән нәрсәне;
- *катнашучыларны* (оппонентларны) — каршылыкларны, төрле юнәлгәнлектәге тенденцияләрне (максатларны, мәнфәгатьләрне һ.б.) «йөртүчеләрне».

Хәл потенциаль мөмкин булганнан чын, актуаль конфликтка үсеп җитсен өчен, максаты бары бер як өчен генә уңай нәтиҗә алу булган *инцидент* — каршы якларның ачыктан-ачык бәрелеше кирәк.

Гадәти аң дәрәҗәсендә конфликт, көндәшләрнең көрәше ачык фазага чыккач, ягъни бәрелеш турыдан-турыммы яки читләтепме капма-каршылыклы үзара тәэсир итү формасында баргач, еш кына нәкъ менә конфликтка тиңләштерелә. Оппонентларның тырышлыгы, бер яктан — куелган максатларга ирешүгә, икенче яктан — каршы якка аның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүгә юл куймау. Шул рәвешле, конфликтта катнашучылар «отарга, җиңәргә», «оттырмаска» дигән күрсәтмә буенча эш итәләр. Бу очракта *конфликт* хәлне турыдан-туры инцидент вакытында, ачык көрәш вакытында чишү белән чагыштырганда куркынычсызрак формада кисәтү яки аны хәл итү мөмкин булган потенциаль зона буларак карала ала.

Конфликт структурасының башка моделе аларда түбәндәге элементлар булуыннан чыгып эш итә:

1) конфликтта катнашучылар (яклар);

2) конфликтның бару шартлары;

3) катнашучыларда инцидент башлануга кадәр булган конфликтлы хәлләр образлары;

4) конфликтта катнашучыларның оппонентка юнәлдерелгән ихтимал булган эшләре яки үзен тоту стратегиясе;

5) конфликтлы гамәлләрнең үзеңне тоту стратегиясен сайлауга да, калган барлык структур элементларның эчтәлегенә дә бәйле булган ахыры.

Шулай итеп, әйтелгәннәргә йомгак ясап, шуны билгеләп үтәргә кирәк: конфликт структурасын сурәтләүдә белгечләрдә бердәмлек юк. Шул ук вакытта барысы да конфликт һәрвакыт төрле максатлары һәм бурычлары булган, хәлне төрлечә кабул иткән кимендә капма-каршы ике катнашучы (оппонент) булырга тиеш дигән белән килешә. Оппонентлар гадәттә турыдан-туры үзара тәэсир итүгә конфликт объекты аркасында керешәләр. Әлеге үзара тәэсир итешү туры бәрелеш характерын ала. Кискен фазадан соң конфликт ниндидер ахырга (дөрес, һәрвакытта да оппонентлар көткәнчә үк түгел), җитә.

Конфликт *динамикасы* традицион төстә дүрт стадиянең эзлекле алышынуы буларак карала. Беренче стадиядә объектив конфликтлы хәл килеп туа. Икенче стадиядә объектив хәл шундый итеп катнашучыларның берсе тарафыннан булса да танылa. Инде бу очракта ук конфликтның булуы турында сөйләргә нигез бар. Өченче этапта конфликтлы үзара тәэсир итүгә күчелә. Конфликтлы тотыш эмоциональ кушылып китүне арттыра, эмоциональ фонны кискенләштерә. Үз максатларыңа ирешүгә юнәлдерелгән эшләрнең һәм башка якның каршы эш итүе үпкәләү, ризасызлык, кәефсезлек тудырганлыктан, еш кына әлеге фон тискәре характерда була. Ниһаять, дүртенче фазада конфликт өлешчә яки тулысынча хәл ителә. Тулысынча хәл ителү конфликтның нигезен тәшкил иткән объектив каршылыкларны бетерүне, шулай ук оппонентларның конфликтның ахырында субъектив канәгатьлек алуын күздә тота. Конфликтның өлешчә хәл ителүе, каршылыкларның объектив сәбәпләре бетеп, объектив каршылыклар яисә субъектив канәгатьсезлек сакланган хәлдә, бер якта гына булса да субъектив канәгатьләнү булганда барлыкка килә.

Шулай итеп, конфликт динамикасы турындагы шундый күзаллаулар белән бергә башка караш та бар. Аның буенча теләсә нинди конфликт вак, «элементар» конфликтлардан, ягъни конфликт адымнарыннан тора. Бу адымнар берсе артыннан икенчесе ясалмаска да мөмкин. Алар вакыт буенча туры килергә, суга ташлаган таштан барлыкка килгән түгәрәкләр бер-берсен көчәйткән яки «сүндергән» кебек, бер-берсенең гамәлен көчәйтергә яки көчсезләндерергә мөмкин.

Конфликт аның нигезендә каршылык яткан төп проблема (яисә конфликт объекты) барлыкка килүдән башлана. Башлангыч каршылык катнашучыларның бер-берсеннән канәгатьсезлек тудыручы күптөрле гамәлләрен тудыра. Конфликт үсүдәге әлеге этап вакыт буенча сузылырга яки бик тиз барырга мөмкин булган «конфликт алды фазасы» дип атала. Икенче этапка — конфликтлы фазага (инцидент башлануга) этәргеч ниндидер сәбәп була, мәсәлән, үзара тәэсир итүне каршылыкка, бәрелешкә китерүче факт, вакыйга нәтиҗәсендә конфликтлы хәл ачыкка әверелә. Конфликт процессында анда катнашучылар төрле ахыргы нәтиҗәләр алалар.

ШӘХЕСНЕҢ КОНФЛИКТТА ҮЗЕН ТОТЫШЫ

Сезгә инде билгеле булганча, аралашу вакытында үзара тәэсир итүнең бик тә күп төрләрен психологлар капма-каршы ике типка: хезмәттәшлеккә һәм көндәшлеккә аералар. Үзара тәэсир итүнең бу типлары конфликтлы гына түгел, ә теләсә нинди аралашуда чагылырга мөмкин.

Типологияләрнең берсе үзара тәэсир итү стратегиясен ике үлчәмле модель буларак карый:

үз мәнфәгатьләреңә йөз тоту, аларны канәгатьләндерү	⟺	башка кеше мәнфәгатьләренә йөз тоту, аларны канәгатьләндерүдә ярдәм итү

Конфликтта аны хәл итү процессында үзара тәэсир итүнең төп биш стратегиясен аерып күрсәтәләр. Үзеңне тоту стратегиясен сайлау конкрет хәлгә бәйле.

1. *Көндәшлек* —үз мәнфәгатьләреңә, үзең өчен генә нәтиҗәләргә ирешүгә йөз тоту. Башка кешенең мәнфәгатьләре, аның белән аралашу инкарь ителә, берничек тә искә алынмый. Бу — үзеңне тотуның актив индивидуаль тибы. Көндәшлек конфликтта катнашучыларның берсенең икенчесеннән өстен чыгуына, отышына, җиңүенә китерергә мөмкин. Шул ук вакытта анда кешенең үз мәнфәгатьләрен, позициясен, карашын яклауга булган табигый ихтыяҗлары чагыла.

2. *Хезмәттәшлек* — бер үк вакытта каршы як мәнфәгатьләрен дә, үзеңнекеләрне дә канәгатьләндерүгә йөз тоту. Өстәвенә конфликтта катнашучыга үзара тәэсир итү нәтиҗәләренә ирешү, аларны саклау һәм ныгыту бер үк дәрәҗәдә әһәмиятле. Хезмәттәшлек актив уртак эшчәнлек формасында бара, конфликтны хәл итү буенча теләсә нинди тәкъдим ихтимал булган барлык катнашучыларның мәнфәгатьләрен кушуны күздә тота. Бер якның мәнфәгатьләре икенче як

ихтыяҗларын канәгатьләндермичә канәгатьләндерелә алмый. Хезмәттәшлек иткәндә ике як та икеләтә отышта кала: мәнфәгатьләрен канәгатьләндерәләр һәм үзара тәэсир итүләрен үстерәләр. Бу стратегия, башкалардан аермалы буларак, вакытны күбрәк сарыф итүне сорый, чөнки барлык катнашучыларның эчке позицияләрен өйрәнергә, аннары аларны эзлекле төстә тикшерергә кирәк. Катлаулыгы шунда: чын ихтыяҗларны ачу һәм барлык якларны канәгатьләндерүче альтернативаларны табу читен.

Хезмәттәшлек — проблеманы хәл итү барлык яклар өчен мөһим, ә конфликт анда катнашучылар өчен озак вакытлы мөнәсәбәтләрдә фәкать эпизод кына булганда, яклар алда озак проект өстендә эшләргә кирәк дигән караштa торганда үзеңне тотуның бердәй тибы булып тора. (Мисал: бәхәстә бәхәс түгел, ә чынлап та хакыйкать табылганда.)

3. *Компромисс* (килешү) — ярым-йорты стратегия. Үз мәнфәгатьләреңнән өлешчә баш тарту, шулай ук аларны өлешчә канәгатьләндерү мөмкинлеге бирә. Компромисс хезмәттәшлеккә караганда өстенрәк нәрсәләргә кагыла, чөнки, тирән ихтыяҗларны һәм мәнфәгатьләрне ачыкламыйча, нигездә тышкы мөнәсәбәтләр тикшерелә. Еш кына карар вариантның ике як өчен дә кабул ителгәнлегеннән чыгып кабул ителә, чөнки мәнфәгатьләрне тулысынча канәгатьләндерү мөмкин булмый. Үзеңне тотуның мондый тибы индивидуаль һәм уртак, актив һәм пассив гамәлләрне тигез күләмдә куллануны күздә тота.

Компромисс еш кына ике якның да капма-каршы мәнфәгатьләре булганда һәм тиз арада карар кабул итү зарурилыгы туганда яисә вакытлыча килешү төзү канәгатьләндергәндә нәтиҗәлерәк була.

4. *Качу* үзеңне тоту стратегиясе буларак үз мәнфәгатьләреңне канәгатьләндерүдән качуны күрсәтә, бу исә башка катнашучыга үз мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү мөмкинлеге бирми. Шул ук вакытта катнашучы нәтиҗәгә ирешүдән дә, үзара мөнәсәбәтләрне дәвам иттерүдән дә баш тарта. Шулай итеп, качу индивидуаль пассив стратегия булып тора. Ул — конфликт кысаларыннан вакытлыча гына яки даими рәвештә чыгу, ләкин моның алга таба эшләрдә җаваплылыкның икенче якка автоматик күчүенә китерүе ихтимал.

5. *Ярашу* — барыннан да элек башка кеше мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү хакына үз мәнфәгатьләреңнән ваз кичү ул. Монда үзара тәэсир итүнең нәтиҗәсе реаль максатка ирешү түгел, ә ярашуны сайлаган кеше өчен зур әһәмияткә ия булган үзара мөнәсәбәтләрне саклау була. Үзеңне тотуның әлеге тибы уртак пассивлык буларак бәяләнә. Кеше башка кеше белән бергә аның таләпләрен үтәргә килешеп эшли.

Конфликтта катнашучыларның берсе өчен проблема әллә ни әһәмиятле булмаса яки тынычлык һәм дуслык мөнәсәбәтләрен саклау өстенлек итсә, ә икенчесе өчен конфликтның нәтиҗәсе күпкә әһәмиятлерәк булса, ярашу максатка ярашлырак була. Җәмгыятьне, җитештерү белән идарә итүне, мәгарифне гуманлаштыруга булган дөньякүләм тенденцияләр тирә-яктагылар белән хезмәт итәргә, уртак эшчәнлек урнаштырырга, килешүләр табарга тырышуның аеруча әһәмият алуларын дәлилли.

Хезмәттәшлек һәм уртак эшчәнлек оештыру стратегиясен сайлау нәрсәгә бәйле соң?

Беренчедән, конфликтта үзеңне тоту ысулын сайлау шәхеснең *кыйммәтләренә һәм кыйммәтләргә ориентлашуына* бәйле. Мәсәлән, хезмәттәшлек стратегиясенә йөз тоткан кешегә аралашу яки конфликтка үзара тәэсир итү буенча партнерны үзенә тиң уникаль зат итеп кабул итү хас. Андый шәхеснең төп мәнфәгатьләренең нигезен тирә-яктагыларның һәм үзенең эчке дөньясын танып-белергә омтылыш хасил итә. Хезмәттәшлек итүче шәхеснең өстенлекле омтылышлары — уртак эшчәнлектә һәр ике якның да мәнфәгатьләрен канәгатьләндерергә, башка кешенең эчке дөньясын аңларга, игътибарны, тискәреләрнең ролен киметеп, оппонентның уңай чагылышларына юнәлтергә әзер тору; иҗади, көч кулланмыйча хезмәттәшлек итеп һәм килешеп яшәргә омтылу.

Эмоцияләр өлкәсендә уңай үзүсешкә омтылыш; үзеңә ышаныч; башка кешеләрне нәкъ үзләре булганча, аларны үзгәртергә, яңартырга омтылмыйча кабул итү; хөрмәт, ышану, ачыклык, гафу итәргә әзер тору, үзеңә ышаныч өстенлек итә.

Хезмәттәшлек итүче шәхеснең характерлы сыйфатларын үзеңне ничек бар шулай кабул итү, үз-үзеңне хөрмәт итү, үзеңне кабул итүнең уңай ягының өстенлеге, үз көчеңә, мөмкинлекләреңә, сәләтеңә, үзеңне тормышта табу, ныгыту тәшкил итә.

Конфликтларны уңышлы хәл итүгә генә түгел, ә бәлки нәтиҗәле аралашуга дә булышлык итүче иң мөһим *сәләтләрнең* берсе — эмпатия (бу хакта сүз булды инде). Эмоциональ өлкәнең үзконтроль, үзен җайга салу сәләтләрен үстерү эмоцияләрне конфликтларның төп чыганакларының берсе буларак үзгәртеп корырга ярдәм итәләр. Мәсәлән, ярсынуны яки куркуны җиңү позицияне, мөнәсәбәтне, оппонентны аңлау һәм тулаем хәлне үзгәртүгә йогынты ясый. Мөмкинлекләрне һәм альтернативаларны иҗади эзләү конфликт кысаларыннан тагын да киңрәк контекстларга чыгарга ярдәм итә, дөресе генә түгел, әлеге шартлар өчен бердәнбер мөмкин һәм иң яхшысы булган карар эзләп табыла.

Хезмәттәшлеккә омтылучы шәхес мантыйклы дәлилләр,

уңай эмоцияләр, шәхси үрнәге, әхлакый инанулары белән көч кулланмыйча йогынты ясый һәм ышандыра алуын күрсәтә. Мондый мөгамәлә партнер белән уңышлы эшләү, кооперация, сөйләшүләр алып бару мөмкинлекләрен арттыра.

Шәхеснең конфликтлы хәлдә хезмәттәшлек итүгә юнәлдерелгән коммуникатив сәләтләре элемтә урнаштыру һәм тоту, башка берәүнең позициясен аңлау, хисләрне тота белү, оппонентның каршы торуын киметү, тыңлый белү һ.б. мөмкинлекләре бирә.

> «Кешеләр арасындагы салкынча мөнәсәбәтләр үзара ышкылу нәтиҗәсендә барлыкка килә. Моңа ни диярсең, физика?»
>
> Станислав Ежи Лец (1909–1964, поляк язучысы)

Хәзер инде үзен бозык тотарга, бар нәрсәгә каршы торырга һәвәс шәхескә нинди үзенчәлекләр хас булуын карыйк.

Психологиядә «конфликтлы» шәхес, ягъни теләсә нинди хәлләрдә дә үзе тирәсендә проблемалы, конфликтлы хәлләр һәм үзара мөнәсәбәтләр тудыручы кеше дигән махсус төшенчә бар.

«Конфликтлы» шәхеснең юнәлгәнлегенә еш кына хәтта аңлап җиткерелмәгән эгоистик мотивлар да керә, бу исә җитди эчке проблемалар булу белән бәйле. «Конфликтлы» шәхеснең инанулары, «барлык кешеләр дә явыз», шуңа алар дошманнар, аларны төп башына утыртырга, йә булмаса җиңәргә кирәк, дип инануга нигезләнә.

Болай якын килгәндә, кешенең табигате башта ук тискәре, түбән инстинктлары югарыга омтылган булып карала.

Андый «конфликтлы» шәхеснең кыйммәтләре эчтәлекләре буенча төрле булырга мөмкин, ләкин аларны бик тә нык рәхимсезлек, киребеткәнлек һәм консерватизм аерып тора. «Конфликтлы» шәхеснең мәнфәгатьләре барыннан да элек үзен раслау ихтыяҗын канәгатьләндерү белән бәйле. Мөнәсәбәтләр структурасында үзен кабул итмәү, үз-үзенә тискәре мөнәсәбәт өстенлек итә. Бу очракта үзбәя йә арттырыла, йә булмаса киметелә. Эмоциональ-ихтыярый омтылышлар эчке шартларны саклауга, үзгәрешләрдән качуга, үз өстеңдә эшләүдән баш тартуга юнәлдерелгән. Шәхесара мөнәсәбәтләр башка кешеләрне алар ничек булган шулай кабул итүдән баш тарту, тирә-яктагыларны үзгәртергә тырышу, ышанмау, кире кагу, хөрмәт итмәү, йомыкыйлык, җиңәргә, өстен чыгарга тырышу, үҗәтлек белән характерлана.

Конфликтлы типтагы кешеләрнең шәхси сыйфатларына тәнкыйть белән артык мавыгуны, күзгә бәреп әйтү, үҗәтлек, эгоцентризм, мин-минлек, санга сукмау, үзенә бәяне дөрес бирмәү, кирелек, тәрбиясезлек, тотнаксызлыкны һәм хәтта агрессивлыкны, авторитарлыкны һ.б. ны кертеп була.

«Конфликтлы» шәхес бик еш конфликтларның аерым төрен — *реаль булмаган яки субъектив юнәлтелгән конфликтлар* тудыра. Андый конфликтларда эшчәнлекнең нинди дә булса нәтиҗәсенә ирешү максаты булмый. Ул — «конфликт өчен конфликт». Шәхес өчен анда тискәре эмоцияләр булдыру процессы мөһим. Реаль нәтиҗә психологик файда алу — башкалар исәбенә үзен раслау, үзенең «мин» образын яклау һәм ныгыту, тискәре эмоцияләрдән котылу. («Минем кәефем начар, шулай булгач, башкаларныкы да бозылсын») белән алыштырыла.

Андый шәхес үзенең үсешен, үзенең мөмкинлекләрен һәм сәләтләрен тулы күләмдә ачуны чикләп кенә калмый, конфликтлы үзара тәэсир итүдә катнашучыларга һәм шаһитларга кире йогынты да ясый.

Бүгенге психологлар максатлары коммуникатив компетентлыкны, аралашу, конфликтларны хәл итү, сөйләшүләр алып бару күнекмәләрен үстерү булган күпләгән практик тәкъдимнәр, курслар, социаль тренинг программалары эшләделәр.

КОНФЛИКТЛАРНЫ НИЧЕК УҢЫШЛЫ ХӘЛ ИТӘРГӘ

Шулай итеп, конфликттан куркырга кирәкми. Аңа каршылыклар чагылышы буларак карасаң, конфликтта бернинди дә куркыныч юк, дип чынлап торып әйтергә була. Өстәвенә конфликтологларның күпчелеге «практик яктан һәр конфликтны рациональ һәм уңай хәл итеп була» дип уйлый.

Конфликтны уңай хәл итү юллары — сөйләшүләр, арадашчы ярдәме, тынычлык эзләү (якларны килештерү).

Конфликтны уңай хәл итү өчен аның асылы нәрсәдә, нәрсәдән килеп чыккан, аның нигезендә нинди каршылык ята икәнен ачык аңларга кирәк. Аннары конфликтта чын катнашучы кем икәнен, аның турыдан-туры нәрсәгә кагылуын аңлау зарур. Әгәр бу сорауны ачыкламасаң, үз гамәлләрең белән конфликтлы үзара тәэсир итү зонасын киңәйтүең, конфликтка башкаларны да җәлеп итүең ихтимал. Икенче адым катнашучыларның карашларын, мәнфәгатьләрен һәм рангларын белү булырга тиеш. Ранг ул «дәрәҗә», «көч» булып санала. (Мисалга, әгәр ул шәхсән үз исеменнән чыкса, 1 нче ранг була, әгәр төркем кешесе исеменнән булса — 2 нче һ.б.) Катнашучыларның бер-берсенә эмоциональ мөнәсәбәтләрен белү дә әһәмиятле. Бары тик барлык бу мәгълүматларга ия булып һәм аларны яхшылап аңлап кына, эш ысулын (стратегиясен) сайлап һәм аны гамәлгә ашырып була.

Өстәмә рәвештә түбәндәге сорауларга уйлап җавап табу файдалы. Беренчедән, конфликт нәрсәгә өйрәтергә мөмкин?

Ихтимал, конфликт барышында сез карашларыгызда җитди аермалар булган кешене яхшырак аңларсыз. Яисә «яхшы талашка караганда начар тынычлык яхшырак» икәнен, сезнең бу каршы торуыгыздан беркемгә дә файда булмаячагын аңларсыз. Ни генә булмасын, конфликтка кереп, аңлы кеше аңа упкынга ташланган кебек ташланмаячак. Аннары сез үзегез өчен шуны хәл итәргә тиеш: башкаларның кыйммәтләрен үзегезнеке кебек үк итеп таныйсызмы? Аңлашыла ки, практикада моны эшләү читен. Әмма, гамәлдә эмпатия күрсәтеп, конфликтның тышкы сәбәпләреннән югарырак күтәрелә алсагыз, ихтимал, сезгә булган хөрмәт артачак. Тагын шунысын да анализлагыз: сез тигез хокуклы мөнәсәбәтләрне якларга әзерме, объектив булырга һәм проблеманы шәхестән аерырга омтыласызмы, икенче як позициясе артында нинди ихтыяҗлар һәм мөнәсәбәтләр яшеренгәнен аңларга тырышасызмы. Мөгаен, бу очракта конфликтның асылын һәм сәбәпләрен ачык аңлау аеруча мөһимдер. Әгәр конфликт кискен төс алса, шуларны хәл итегез: сез каршылыкларны тикшерергә әзерме, карарларның яңа вариантларын эшләү, альтернативалар һәм мөмкинлекләр эзләү теләгегез бармы, сез башка як өчен партнер булырга, хезмәттәшлек һәм кооперация юллары эзләргә әзерме?

Әгәр конфликтны хезмәттәшлеккә әверелдерергә телисез икән, 4 адымлы алым кулланыгыз:

1) оппонентыгыз белән әңгәмә корырга вакыт һәм бер-берегезне аңларга ярдәм итәчәк төп кагыйдәләрне табыгыз;

2) диалогны үстерүгә ярдәм итәчәк шартлар — урын, вакыт, тирәлек әзерләгез;

3) төп проблеманы әзерләгез, аны берничә вак проблемага бүлегез һәм, иң гадиеннән башлап, ихтимал булган чишелешләрне тикшерегез;

4) иң яхшысы — язма рәвештә шартнамә яки килешү төзегез, чөнки вакытлар үтү белән, мәгълүмат бозыла яки онытыла, моның исә яңа конфликтка китерүе ихтимал.

Ахыр нәтиҗә ясап, инде сезгә билгеле булган кагыйдәләрне исегезгә төшерегез. Конфликтны сүндерүгә караганда аны булдырмый калу җиңелрәк. Әгәр сез конфликтларны булдырмый калырга һәм аны үз-үзегезне тотышыгыз белән кузгатып җибәрергә теләмисез икән, бәя бирергә түгел, фактларны, күзәтүләрне тасвирларга өйрәнегез. Хәлне тасвирлаганда еш кына ул бик үк кискен булып күренми. Уңай хисләрегезне дә, тискәреләрен дә чын күңелдән, әдәпле итеп чагылдырырга өйрәнегез. Моның өчен шуны истә тотарга кирәк: конфликт ул ике яклы, ихтимал, кемдер сезнең турында да бик үк яхшы фикердә түгелдер. Теләсә нинди хәлдә дә игелекле, тотнаклы, тыныч булыгыз. Ничек кенә булса да җиңәргә тырышмагыз. Аралашу

кагыйдәләрен белү сезгә үз фикерегезне башкалар ишетерлек итеп әйтергә, оппонентны ул үзен аңлауларына ышанырлык итеп тыңларга ярдәм итәчәк. Еш кына үзегезне башка кеше урынына куеп карагыз, үз хисләрегезгә хуҗа булыгыз, гафу итә белегез.

«Үтәүгә караганда киңәш бирү җиңел ул» дияргә мөмкин. Ләкин конфликтның «анатомиясен» белү, каршылыкларны хәл итү ысулына әверелдереп, аннан уңай нәрсә алырга ярдәм итә.

Төп төшенчә: конфликт.

Терминнар: конфликтлы хәл, инцидент, көндәшлек, компромисс, качу, ярашу, сөйләшүләр.

Үзегезне тикшерегез

1. Конфликтлы хәл конфликттан нәрсә белән аерыла? 2. Конфликтның структурасын сурәтләүче барлык белгечләрнең фикерләре нәрсәдә туры килә? Аларның карашлары нәрсәдә аерыла? 3. Шәхеснең конфликтта үзен тотышы стратегиясе нәрсәгә бәйле? 4. Конфликтта үзеңне тотуның төп стратегияләрен тасвирлагыз. 5. «Конфликтлы» кешенең үзенчәлекләре конфликтны уңышлы хәл итүгә ничек комачаулый?

Уйлагыз, тикшерегез, эшләгез

1. «Ромео һәм Джульетта» хикәятеннән дә кайгылырак хикәят дөньяда юктыр». Конфликтның структурасы һәм динамикасы турындагы белемнәрегезне кулланып, У.Шекспир трагедиясенең сюжетын сурәтләргә тырышыгыз.

2. Конфликт ерып чыгып булмый торган котылгысыз хәл ул дигән фикер яши. Бу мәсьәләдә сезнең фикерегез нинди? Дәлилләр китерегез.

3. «Конфликтның файдасы турында» дигән чыгыш әзерләгез.

4. Түбәндәге мәгълүматлардан нәтиҗә ясагыз. Яшүсмерләр конфликтны еш кына — «бәрелешү», «сугыш», «эткәләш», «якага яка тотыну», ә кызлар «әйткәләшү», «талашу», «ямьсез сүзләр әйтешү», «тарткалашу» сүзләре белән тиңләштерәләр.

Чыганак белән эшләгез

Бүгенге Россия галимнәре Б.И.Хәсән, П.А.Сергоманов китабыннан өзек укыгыз.

Сөйләшүләрнең типовой сценарийлары

Сөйләшүләр — конфликтларны һәм фикер каршылыкларын оештыруның катнашучыларның үз фикер каршылыкларын ачык тикшерүләре аша капма-каршы якларның мәнфәгатьләрен «туры» китештерүне күздә тотучы моделе ул.

[...] «Позицион сатулашу» ул шундый сценарий ки, бу вакытта яклар, кагыйдә буларак, каршы якның һәм сөйләшү алып баручының үзенең ни теләвен ачыкламый торып, тикшерүне конкрет хәл итүләрдән башлыйлар. «Позицион сатулашу», кагыйдә буларак, якларның конкрет карарлар тәкъдим итүенә, аннары аларны тырышып яклауга кайтып кала. Мондый сатулашу еш кына нәтиҗәсез була, чөнки сөйләшүләр бу очракта түгәрәк буйлап бара. Сөйләшүләрнең мондый сценарие катнашучыларга ирекле эш итү иреге калдырмый диярлек. Караш артында нәрсә торганын ачыклау файдалырак һәм нәтиҗәлелерәк.

«Мәнфәгатьләр буенча сөйләшүләр» — катнашучыларның чын мәнфәгатьләрен ачыклаудан, карарлар кабул итүдән, якларның карарлар кабул итүдәге тиешле мәнфәгатьләрне һәм карашларны тикшерүдәге гаделлек кагыйдәләрен билгеләүдән башлана торган сценарий.

[...] Арадашчы ярдәмендә сөйләшүләр вакытында сөйләшүләрнең уңышлы үтүе өчен җавап бирүче, нәтиҗәле коммуникация оештыручы һәм сөйләшүләрдә катнашучылар арасында уңай мөнәсәбәтләр булдыручы махсус кеше билгеләнә.

[...] Арадашчының эш предметы — сөйләшүләр процедуралары һәм катнашучыларның үзара мөнәсәбәте. Технологияләр һәм процедуралар дөрес оештырылса, сөйләшүләр, кагыйдә буларак, уңышлы үтә. Әгәр катнашучылар бер-берсенә каршы төшә башласа, мөнәсәбәтләрне җайга салмый торып, сөйләшүләр гадәттә нәтиҗәсез тәмамлана, шунлыктан арадашчыга шәхесара мөнәсәбәтләрне җайга салу зарур.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Сез «сөйләшүләр — конфликтларны хәл итүнең универсальрәк моделе» дигән белән килешәсезме? Үз карашыгызны яклау өчен дәлилләр китерегез. 2. Текстта сөйләшүләрнең нинди төрләре китерелгән? Сөйләшүләрнең һәр төрен сурәтләүче үз мисалларыгызны бәян итегез. 3. Әлеге төр сөйләшүләрнең уртаклыгы нәрсәдә? 4. Алар нәрсә белән аерыла? 5. Сез сөйләшүнең кайсы моделен универсаль дип атар идегез? Ни өчен шулай уйлыйсыз? Сөйләшүләрнең төрле төрләренең нәтиҗәлелеге турындагы фикерегезнең нигезендә ни дәрәҗәдә сезнең шәхси тәҗрибәгез ята?

V бүлеккә йомгаклаулар

1. Шәхес структурасы катлаулы һәм иерархияле. Ул кешенең биологик сыйфатлары: темпераменты, җенесе, яше, психик процессларның (зиһенгә кабул итү, фикерләү һ.б.) бару үзенчәлекләре белән бәйле компонентларны үз эченә ала. Шәхес структурасының икенче бер дәрәҗәсенә гадәт, осталыклар,

күнекмә һәм белемнәр кирә. Шәхес структурасының тагын бер компонентлар рәте фәкать социаль бәйлелеккә ия, шәхеснең юнәлгәнлеген тәшкил итә һәм мавыгулар, теләк, омтылыш, мәнфәгать, һәвәслек, идеал, дөньяга караш һәм инанулардан тора.

2. Шәхеснең юнәлгәнлеге эгоистик (шәхси мәнфәгатьләр мотивларының өстенлек итүе), альтруистик, коллективистик, просоциаль (башка кешеләр мәнфәгатьләре белән бәйле мотивлар өстенлек итә) булырга мөмкин. Шул нигездә социаль үзеңне тоту үзенчәлекләре һәм тормыш максатлары формалаша. Тормыш максатларына социаль омтылыш (шәхеснең үзен билгеле бер рәвештә тотарга шәхси яки социаль үткәндәге тәҗрибәсе белән алдан билгеләнгән яки бәйләнгән психологик әзерлеге) йогынты ясый. Кеше әзер социаль омтылышлар җыелмасы белән тумый, ул аларны өлкәнәя барган саен үстерә.

3. Шәхеснең үсеш процессы мотивация — ихтыяҗ өлкәсенең акрынлап катлауланувы һәм предметлы эшчәнлекнең төрле төрләрен үзләштерүе буларак тормышка ашырыла. Яшәүнең һәр чоры (яшь буенча) — кабатланмас, үзенчәлекле һәм шәхеснең ныгып урнашуында мөһим әһәмияткә ия. Тормыштагы уңышлар һәм яшәүдән канәгатьлек алу дәрәҗәсе билгеле бер яшьтәге кешенең үзен никадәр тулырак, кыйммәтлерәк итеп күрсәтүенә бәйле.

Кешенең паспорт һәм психологик яше туры килмәскә мөмкин. Гадәттә җаваплы һәм мөстәкыйль кешеләр үзләренең психологик яшьләре буенча инфантиль (физик һәм психик яктан артта калган) яшьтәшләрен узып китәләр.

4. Аралашу кеше өчен рухи эшчәнлек нәтиҗәләре (үзләштерелгән мәгълүмат, фикер, хис, бәяләү, кичерешләр һ.б.) алмашу белән бәйле үзенчәлекле эшчәнлек булып тора. Ул өч якның (коммуникация, интеракция һәм социаль перцепция) бердәмлеге белән характерлана. Формалашып килгән мәгълүмати алмашуда мәгълүматны туплау һәм эшкәртү мөмкинлекләре киңәеп кенә калмый, аралашу формалары да шактый үзгәрә. Мәгълүмат тапшыруның техник чаралары һаман саен зуррак роль уйный.

Аралашу үсмер һәм яшүсмер чакта аеруча мөһим роль уйный, ул эшчәнлекнең төп төрләренең берсе булып тора. Аңа кайбер үзенчәлекләр хас: интим-шәхесле, социаль-төркемле һәм социаль юнәлгәнлекле аралашу белән кызыксыну, үрнәкләргә иярү аша аралашуның үз стилен булдыру һәм төркем өстенлекләрне сайлау, өлкәннәрнең аңламавы аркасында ялгызлыкны һәм уңайсызлыкларны авыр кичерү һ.б.

5. Нәтиҗәсез аралашу еш кына шәхесара конфликтлар сәбәпләренең берсе була. Конфликт һәрвакыт төрле максатлары

һәм бурычлары булган, хәлне төрлечә бәяләүче субъектлар (оппонентлар) булуны күздә тота. Оппонентлар гадәттә турыдан-туры үзара тәэсир итүгә конфликтлашу объекты өчен кирәләр. Конфликт кайбер фазаларны үтә: объектив конфликтлы хәл һәм оппонентларның аны субъектив аңлавы, конфликтлы үзара тәэсир итү һәм конфликтны хәл итү. Шәхеснең конфликтта үзен тотышы (көндәшлек яки хезмәттәшлек) аның юнәлгәнлеге, тәрбия үзенчәлекләре, характеры, психик үзенчәлекләре белән билгеләнә. Шәхесара конфликтларны хәл итүнең нәтиҗәле ысулы — хезмәттәшлек, сөйләшүләр, шул исәптән арадашчы яки вәкил катнашындагы сөйләшүләр.

6. Турыдан-туры шәхси аралашу һәм эмоциональ мөнәсәбәтләр (симпатия, антипатия, битарафлык) нигезендә җәмгыятьтә кече төркемнәр — составлары күпсанлы булмаган, уртак эшчәнлек (максатлар һәм бурычлар) белән берләшкән кешеләр җыелмасы формалаша. Төркем бергәлегенең нигезен кешеләрнең аерым төркем мәнфәгатьләренә, норма, кыйммәт һәм максатларына керүләрен субъектив аңлаулары ята.

Төркемдәге шәхесара мөнәсәбәтләр — шәхеснең төркем һәм аның һәр әгъзасы белән элемтәләренең катлаулы системасы ул.

7. Кече төркемнәр арасында формаль булмаган яшьләр төркемнәре аерым урын алып тора. Алар арасында социаль уңай да (просоциаль), социаль булмаган, төп проблемалардан читтә торучылар, «тар түгәрәк» кыйммәтләре системасында бикләнгәннәре дә бар. Социаль куркынычны антисоциаль яисә социаль тискәре, җинаятьчел төркемнәр тудыра.

Криминаль төркемнәр кешеләрнең башка социаль төркемнәреннән максатлары, төркем процессларының үзенчәлеге, җәмгыять өчен аеруча куркыныч булулары белән аерылып тора. Алар җинаять эшләренә, хокук нормаларына каршы төгәл юнәлеш тотулары, җинаятьләрне оешкан төстә башкарулары белән характерлана.

8. Гаилә төркемнәре җәмгыятьтә аерым кече төркемнәр булып тора. Кече төркемнәрнең барлык төп сыйфатларына ия булган хәлдә, хезмәт һәм уку микроклиматларыннан аермалы буларак, гаилә никах институты нигезенә корыла, хуҗалыкта репродуктив, хуҗалыклы-икътисади, рекреацион, тәрбияви, сексуаль, социаль-статуслы функцияләр башкаралар. Кече төркемдәге кебек үк, гаиләдә күп яктан мәхәббәт, мәнфәгатьләр уртаклыгы, үзара ярдәм итешү һәм бер-береңнең проблемаларын һәм шатлыкларын аңлау белән билгеләнә торган үзенең социаль-психологик климаты урнаша. Җәмгыятьтә гаилә-җенес рольләрен (күрсәтмәләр системасы, үзеңне тоту модельләре) гамәлгә ашыру кабул ителгән үрнәкләр белән билгеләнә.

V бүлеккә сораулар һәм биремнәр

1. «Шәхес башлангычы индивид башлангычыннан күпкә соңрак калып килә» (Б.Г.Ананьев) дигән фикер белән килешәсезме? Үз карашыгызны раслау өчен нинди дәлилләр китерә аласыз?

2. Аралашуда һәм танып-белү эшчәнлегендә стереотиплар уйнаган рольләрне чагыштырыгыз. Охшашлык һәм аерымлык сыйфатлары турында нәтиҗә ясагыз.

3. Сюжеты социаль перцепция хаталарына корылган әдәби әсәрләрне атагыз. Әлеге хаталарның нәрсәләрдә чагылуын күрсәтегез. Әлеге хаталарның нигезендә нинди механизмнар ята?

4. Соңгы вакытта илдә «ышаныч телефоннары» һаман саен күбрәк тарала. Кискен хәлләрдә кешеләрнең телефон аша аралашуга өстенлек бирүләрен нәрсә белән аңлатырга була?

5. Гомумиләштерүче схема төзегез, анда төрле нигезләр буенча аерылып торучы кече төркемнәрнең барлык күптөрлелеген күрсәтегез.

6. Козьма Прутков әйткән: «Фил читлегендә «буйвол» дигән язу күрсәң, үз күзләреңә ышанма»,— дигән. Күз алдыгызга китерегез: бу язуга конформист һәм нонконформист ничек карарлар иде икән? Әдәби геройларның нонконформистлык тотышларына үз мисалларыгызны китерегез.

7. Тарихтан белемнәрегездән файдаланып, Петр I гә кадәрге традицион Россия гаиләсендә һәм хәзерге демократик гаиләдәге гендерлы рольләр үзгәрүен тасвирлагыз.

Имтиханга әзерләнәбез

1. Кеше эшчәнлегенең уен һәм аралашу төрләрендә нинди уртаклар бар:

1) билгеле бер тәртипне саклауны таләп итәләр;
2) партнерның һичшиксез булуы кирәк;
3) индивидуаль характерда була алалар;
4) имитацияне (охшатып ясалган нәрсәне) куллануны күздә тоталар?

2. Төшенчәләрнең китерелгән исемлегеннән «Иҗтимагый мөнәсәбәтләрдә һәм аңлы эшчәнлектә катнашучы буларак кеше:

индивид;
объект;
индивидуальлек;
шәхес

дип атала» дигән фикерне дөрес тулыландыручы бердәнбер сүзне сайлап алыгыз.

3. Кайсы фикер дөрес?

А. Шәхеснең юнәлгәнлеге эшчәнлекнең төп мотивлары җыелмасын билгели.

Б. Социумда үзеңне тоту характеры күп яктан шәхеснең юнәлгәнлеге белән билгеләнә.

1) А гына дөрес;
2) Б гына дөрес;
3) һәр икесе дә дөрес;
4) икесе дә дөрес түгел.

4. Түбәндәге әйтемдә төшеп калганны тутырыгыз:

«________________ — сүз-пакет, аңа радиотапшыруны, тәрбияне, шахмат партиясен, лекцияне, музыканы, бәбинең «үә-үә»сен, очраклы карашны, аноним хатны, театрны... төреп була».

5. Схемада төшеп калганны тутырыгыз:

6. Түбәндә китерелгән исемлектә нәрсә үзара тәэсир итү буларак аралашуга керә? Җавабыгызны аралашуның интерактив ягы характеристикалары урнаштырылган саннар комбинациясе рәвешендә күрсәтегез.

1) эшлекле партнерларның булачак производство киңәшмәсе турында язмача хәбәр итүе;
2) гыйльми хезмәтне күп кеше алдында яклау;
3) сүз иреген яклаган митингта катнашу;
4) роман уку;
5) Интернетта мәгълүмат эзләү;
6) хат алышу;
7) газетага хат язу.

7. «Эмпатия» төшенчәсен кулланып, аралашуны характерлаучы өч сүзтезмәне төзегез.

8. Шәхесара конфликт структурасы элементлары исемлегенә өстәгез:

1) конфликт объекты;
2) конфликтлы юл;
3) инцидент;
4) ....

ISBN 978-5-94113-303-1

9 785941 133031 >

Учебное издание

Серия «Академический школьный учебник»

***Боголюбов** Леонид Наумович*
***Лазебникова** Анна Юрьевна*
***Смирнова** Наталия Михайловна и др.*

ОБЩЕСТВОЗНАНИЕ

10 класс

Учебник
для общеобразовательных учреждений

ПРОФИЛЬНЫЙ УРОВЕНЬ

(перевод с русского на татарский язык)

Редакторы *М.Х. Вәлиев*
Корректоры *Ә.Ф. Әхмәдуллина*
Компьютерда биткә салучысы *В.М.Садыйкова*

Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты.
420111, Казан, Тельман ур., 5.
Хатлар өчен: 420014, Казан, Кремль, а/я 54.
Тел. (факс): (843) 264-67-96

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 10.11.2009. Форматы 60×90 1/16.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 26.
Тиражы 2600 д., Заказ В-1787.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Россия Фәннәр академиясе
Россия Мәгариф академиясе
«Просвещение» нәшрияты

A

Мәктәпләр өчен академик дәреслек

Җәмгыять белеме

ПРОФИЛЬЛЕ ДӘРӘҖӘ

- җәмгыять белеме буенча Л.Н.Боголюбов редакциясендәге уку һәм методик ярдәмлекләр комплектына керә
- җәмгыять белеме фәненең профиль дәрәҗәсенә туры килә
- социаль-гуманитар яки социаль-икътисади уку профилен сайлаган 10 сыйныф укучыларына социология, политология, социаль психология фәннәренең нигезен тәшкил иткән белемнәр системасын үзләштерергә ярдәм итәчәк (сайлап алынган профильгә бәйле рәвештә бу курс хокук белеме һәм икътисадның аерым курслары белән өйрәнелә)

ПРОСВЕЩЕНИЕ
ИЗДАТЕЛЬСТВО

ТаРИХ